# Абдурахман Абсалямов

## Избранные произведения

В пяти томах

Том 1

РОМАН

Казань
Татарское книжное издательство
2009

# Габдрахман Әпсәләмов

## Сайланма әсәрләр

Биш томда

1 том

РОМАН

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44
Ә64

Редколлегия:
*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Л.М.Шәехов, Ф.И.Фәтхетдинова*

**Әпсәләмов, Г.С.**

Ә64 Сайланма әсәрләр : 5 томда / Габдрахман Әпсәләмов ; кереш сүз авт. Н.Йосыпова, Г.Гайнуллина. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.
ISBN 978-5-298-01885-2
1 т. : Газинур : роман. – 2009. – 399 б.
ISBN 978-5-298-01886-9

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Габдрахман Әпсәләмов әсәрләренең бу томында әдипнең «Газинур» романы урын алды.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44

ISBN 978-5-298-01886-9 (1 т.)
ISBN 978-5-298-01885-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2009



## ВАКЫТ СЫНАВЫН УЗГАН ӘДИП

Күренекле язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Габдрахман Әпсәләмов – XX йөз татар совет әдәбиятында аеруча популяр әдип, замандашларының тормышын югары романтик пафос белән сугарып яктырткан, әмма соңгы елларның иҗтимагый-сәяси, эстетик үзгәрешләренә мөнәсәбәттә күләгәдәрәк калып, берьяклырак бәяләнергә дучар булган каләм осталарының берсе...

Һәр буын үткәннәрне, элгәреге иҗади мирасны үзенчә укырга, үз әдәби-эстетик зәвыгы югарылыгыннан, үз иҗтимагый-мәдәни мөнбәреннән бәяләргә омтыла. XX–XXI гасыр аралыгында милли мираска мөнәсәбәтнең үзгәрүе нәтиҗәсендә халыкның мәдәни байлыгына үзгә караш ташлавы, соңгы елларда күләгәдә калып күренми яткан әдәби катламнарны «ачуы», әдәбият тарихына, әдәби хәзинәләргә, шул исәптән совет чорында актив иҗат иткән әдипләрнең мирасына яңача карау, тикшерү-бәяләү мөмкинлеген бирде. Без бүген XX гасыр татар әдәбиятында соцреализм традицияләренә тугрылыклы иҗат иткән, шуның белән янәшәдә 1960–1970 елларда романтик алымнар ярдәмендә эстетик идеал эзләү, кешене үткән белән киләчәкне тоташтыручы итеп карау, әдәби фикерләүдә милли сурәтне алга чыгарырга омтылган Габдрахман Әпсәләмов прозасын да яңача укыйбыз, бәялибез, фикер төрлелегенә киләбез. Шул чорда әдәби мәйданда дан казанган әдип иҗатын барламыйча, хәзерге заман күзлегеннән өйрәнмичә торып, әдәби-мәдәни дәвернең бербөтен картинасын тудыру мөмкин дә түгелдер. Язучының иҗади мирасына кабаттан әйләнеп кайтып, җентекләп күзәтеп чыгу XX гасыр татар әдәбиятын бәяләү мөмкинлеген бирә, бүген инде совет әдибе булып исәпләнгән Г.Әпсәләмов иҗатының чор идеологиясеннән өстенлеген, совет идеалларына бәйләп, кеше, тормыш фәлсәфәсен тәкъдим итүен танырга этәрә.

Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов 1911 елның 28 декабрендә элекке Пенза губернасының Краснослободск өязе Иске Аллагол авылында (хәзерге Мордовия Республикасының Рыбкино авылы) дөньяга килә. Алты балалы гаиләдә иң олысы булган Габдрахман, үз авылларында башлангыч мәктәпнең өч классын тәмамлагач, Мәскәүгә китеп, укуын Н.Нариманов исемендәге 27 нче номерлы татар урта мәктәбендә дәвам иттерә, әнә шулай әдипнең үсмер чоры һәм яшьлек еллары Мәскәү шәһәре белән бәйләнеп китә. Бу еллар аның күңелендә якты хатирәләр булып саклана, тормышының шушы этабы – халык телендә Әсәдулла мәктәбе дип йөртелгән әлеге уку йортында белем алган чоры хакында ул горурланып сөйли, татар теле укытучысы Фазыл Исхаковны, математика һәм физика укытучылары Нури Йосыпов, Җәлил Хәсәновларны җылы хисләр белән искә ала.

Шунда укыганда, булачак әдип иҗат эше белән кызыксына башлый, әдәбият мәйданына юл сызган әлеге кызыксыну, иҗатка омтылыш яшүсмер малайны Мәхмүт Максуд, Мәхмүт Галәү, Муса Җәлилләр белән таныштыра, М.Җәлил җитәкләгән әдәби түгәрәккә алып килә, шигырьләр, хикәяләр, пьесалар язып, каләмен, иҗат куәсен сынап карауга этәрә. Вакытлы матбугат битләрендә яшүсмер Габдрахманның исеме күренә башлый: «Әнвәр тегермәне» исемле беренче шигыре «Октябрь баласы» журналында басылып чыга, югарырак классларда укыганда, ул Казандагы «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») һәм «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналлары белән тыгыз элемтәдә тора, актив языша.

Һөнәр училищесында уку, заводларда слесарь, токарь булып эшләү дәверендә Г.Әпсәләмов әдәби иҗатка ныклап тартыла башлый, хикәя, пьесалар яза, бу еллар иҗатының өйрәнчеклек чоры буларак аерылып чыга. 1936–1940 елларда Мәскәүдә әдәбият институтында белем алуы, 1937 елда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында «Маһинур» исемле хикәясе басылганнан соң, М.Җәлилнең «Ике Әпсәләм» шигыре белән «кыюсыз» егеткә фатиха бирүе, 1938 елда Казанга килүе булачак әдипне иҗади үрләргә канатландыра.

Әмма Габдрахманга бәйсез сәбәпләр күпмедер вакытка актив иҗаттан читләшеп торырга мәҗбүр итә. 1941 елның августында ул сугышка китә: Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры, 1943 елның җаеннән 1945 елның маена кадәр шул ук

фронтта чыккан «Ватан өчен сугышка» дигән газетаның җаваплы секретаре, 1945 елның җәеннән 1946 елның апреленә кадәр (армиядән демобилизацияләнгәнче) Ерак Көнчыгыштагы «Сталин сугышчысы» исемле фронт газетасы хезмәткәре буларак көрәш юлын уза.

1941 елдан әдип каләмен «Ватан өчен сугышка», «Сталин сугышчысы» газеталарында, «Совет әдәбияты» журналында чарлый, хикәя-очеркларын укучыга тәкъдим итә. 1941 елда – әле сугыш башланганчы – Г.Әпсәләмовның «Бәхет кояшы»н кулларына алган әдәбият сөючеләр 1944 елда аның «Төньяк балкышы» исемле җыентыгы белән таныша. Язучы үзе дә истәлекләрендә әдәби эшчәнлегенең нәкъ менә «Төньяк балкышы»ннан башлануы хакында хәбәр итә: «Аңарчы мин эзләнгәнмен, күңел төбендә яткан кайбер үрентеләр зәгыйфь кенә баш күтәргән, ләкин үземнеке дип әйтерлек төп сызык булмаган. Сугыш уты эчендә мин әнә шул орлыкны – туган ил романтикасын тапканмын». Бу җыентыгында тәкъдим ителгән әсәрләрендә әдип сугышчыларның Ватан азатлыгы өчен көрәштәге батырлыгын сурәтләүгә йөз тота, патриотизм идеясенең, интернациональ мотивларның көчле булуы күзгә ташлана.

Шушы чордан башлап сугыш темасы Г.Әпсәләмов иҗатындагы үзәк темаларның берсенә әйләнә, чор таләп иткән батырлык культы, күтәренке романтик пафос алга куела. Язучының «Ватан улы» (1941), «Үлемнән көчлерәк» (1943), «Хәйбулла солдат» (1944) кебек беренче хикәяләре һәм «Ак төннәр» (1946) повесте ук шул хакта хәбәр итә. С.Хәким үз чорында аның иҗатын: «Берәү дә алдан ук үз стилен тудырып килми әдәбиятка. Чор, заман язучыга аны тәкъдим итә. Әпсәләмов – тулысы белән Ватан сугышы чоры язучысы. Шул заман рухы тудырган язучы. Күтәренке рух, романтик рух. Стиленең публицистик характеры да шуннан. Сугыш һәм яшьлек, героика бергә кушылды. Заманы романтик. Ватан сугышы ул – поэзиядә – Фатих Кәрим, прозада – Габдрахман Әпсәләмов», – дип бәяләп ялгышмаган. Әдәбият тарихына күз салу да Г.Әпсәләмовның «үз сызыгын» табып, сугыш һәм сугыштан соңгы еллар татар әдәбиятының йөзен билгеләгән, төп контурларын сызган әдипләрнең берсенә әверелүен күрсәтә.

Сугыш һәм сугыштан соңгы еллар Г.Әпсәләмов иҗатының икенче чорын тәшкил итә. Ул шул чор сүз сәнгате кысаларында, үз чоры куйган таләпләр яктылыгында иҗат итә, шушы дәвер әдәбиятындагы төп тенденцияләр

аның иҗатындагы үсеш юлларын билгели. Мәгълүм булганча, XX гасыр татар әдәбиятының бер юнәлешен билгеләүче иҗтимагый-идеологик максатка буйсындырылган гомуми тенденция инкыйлабтан соң башланып 50 нче елларга кадәр әйдәп бара. Бөек Ватан сугышы елларында да татар прозасында төп юнәлешне 1917 елдан соң сәяси тормыштагы үзгәрешләр һәм иҗтимагый вазифаларның әчтәлеге яңаруы нәтиҗәсендә яшәп килүче идеология шартлары әзерли. Әлеге вазгыять кешене иҗтимагый тормышта һәм көнкүрештә тасвирлауны алга сөрә, үзара дуслык һәм ышанычка корылган мөнәсәбәтләр тәрбияләү бурычын куя. Пролетариат мәнфәгатьләренә хезмәт итәрлек, социалистик җәмгыять үсешендә таяныч булырлык идеяләр алга чыга. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина яңа концепциянең нигезенә революцион сәнгатьтә революциянең үзе чагылуын, чынбарлык материалы сәнгать әсәренә күчерелгәндә, коммунизм идеалы яктылыгында күчерелүен, әсәрнең тормышка яңадан актив тәэсир ясавын – хезмәт ияләрен коммунизм идеяләре рухында тәрбияләүгә булышу принциплары салынуын билгели. Шушы шартларда яңа тормышны социалистик идеяләргә нигезләнеп төзү мәсьәләсен үзәккә куйган әсәрләр языла. Татар әдәбиятында ул коммунизмның җиңәчәгенә чиксез ышаныч, оптимизм белән сугарыла. Кешедәге героизм сыйфатларын данлап, яңа тормыш хакына үзен корбан итүчеләргә сокланып мәйданга килгән, 1934 елны рәсми рәвештә расланган соцреализм иҗат агымы 1940–1950 еллар әдәбиятында төп юнәлешне хасил итә. Ләкин сугыш чоры әдәбиятка алып килгән яңа тема-проблемалар, әсәрләрдә сюжет хасил итүче сугыш – тыныч тормыш, дошман – илне саклаучы, чит җир – туган җир, яшәү – үлем каршылыклары бу агымны да күпмедер үзгәрергә мәҗбүр итә. Сугыш чоры әдәбиятында үлем – үлемсезлек төшенчәләре яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең төп терәгенә әверелә. Яшәүнең төп максаты хакыйкать белән тәңгәлләшә, ә хакыйкать туган илне дошманнардан саклау рухы һәм шуның гамәлгә ашуы белән бәйләп куела, үлемгә фәлсәфи якын килгән әдипләр моңа кадәр бетү, югалу мәгънәләрендә кулланылган үлемне мәңгелеккә илтүче чара дип кабул итәләр; Ватан азатлыгы өчен үлем үлемсезлеккә, үлгәннән соң яшәүгә (азатлыгы өчен үлгәннәрне Туган ил бервакытта да онытмас, халык йөрәгендә мәңге яшәр дигән гыйбарәсе шуңа тоташа) юл алу буларак кабул ителә, нәкъ менә шул яссылыкта үлем

яшәү белән тигезләшә. Халыкны батырларча сугышырга өндәгән, әдәбиятны шул максатка буйсындырган идеология көрәшеп үлүне укучы күңеленә бердәнбер дөрес юл дип сеңдерә.

Чор әдәбиятының әлеге тенденцияләре Г.Әпсәләмов иҗатын кисеп үтә. Әдип социалистик реализм агымын романтик алымнарга баеткан иҗатчы төсендә калка һәм сугыш чоры татар прозасында хикәя, очерк жанрын үстерүче буларак танылა. Әдипнең документаль нигезгә корылган, вакыйгалар тезмәсен сөйләп бирү кебек оештырылган хикәяләрендә конфликт тыныч тормыш һәм сугыш чынбарлыгы, бурыч һәм намус, яшәү һәм үлем арасындагы кискен каршылык төсен ала, әлеге мәгънә еш кына теге яки бу образга йөкләтелә. Мәсәлән, «Зәңгәр иртә» (1945) хикәясендә иртә образына яшәү – үлем, юк ителү конфликтын көчәйтеп килү вазифасы йөкләнә. Автор каты яраланган ак халатлы Нурулланың бурычын үтәве – пакетны комбатка тапшыруы вакыйгасын әсәр сюжетына сала. Үз чорының идеалы схемасында иҗат ителгән Нурулланың яшәү кагыйдәсе – намус, ул сынаулар килгәндә дә вөҗданын саклап кала алучы герой булып ачыла. Төп герой тарафыннан яшәүне һәм үлемне мәгънәле итүче бердәнбер хакыйкать – туган иленә, торган җиренә, сөйгән ярына, гаиләсенә, баласына карата изгелек кылу автор фикере кебек җиткерелә: *«Нурулла ерак колхозда калган хатыны Тәнзиләне, «Әткәем кайчан кайтыр» дип тилмереп көткән биш яшьлек улы Сәлимне, чал сакаллы әтисе белән карчык әнкәсен, «Абыем!» дип өзелеп хатлар язучы сеңлесе Дилбәрне, гүзәл Ык суы буйларын, киң кырларны, матур болыннарны хәтерләде һәм йөрәге яңа бер ашкыну белән тибәргә тотынды»*. Яшәү – үлем каршылыгын алга куйган «Зәңгәр кыя» (1944) хикәясе исә җаваплылык хисен мәхәббәтнең эчтәлеге дәрәҗәсендә тәкъдим итә: *«Үлем Мостафаның бугазына ук ябышкан иде. Шул чакта егетнең күз алдына Гөлбәдәре килеп басты. Ул моңсу да, бераз борчулы да күзләре белән Мостафага карый»*.

Сәнгати эшләнеш ноктасыннан килеп караганда, 1941–1945 еллар аралыгында язылган татар хикәяләрендә эчке мәгънә хасил итүче элементлардан урын-вакыт төгәл билгеләнә: вакыйгалар сугыш вакытында взвод, рота, госпиталь, авыл, камалышта калган торак пунктта, елга тирәсендә һ.б. урыннарда бара. Г.Әпсәләмов та урын билгеләшенә аерым игътибар юнәлтә, аның хикәяләрендә су-

гыш чоры өчен традицион урын-вакыт бирелеше милли прозада символ буларак укылган образлар белән янәшә куелып, лирик-эмоциональ яңгыраш хасил итә. Мәсәлән, «Үлемнән көчлерәк» (1943) хикәясендә диңгезче егет Искәндәрнең соңгы батырлыгы, тау итәгендәге Логи-Ярви күле янында утырган егетнең диңгезне сагынуы тасвирлана. Дошманны «Үлем кыясына» китереп, үз гомерен корбан итү хисабына иптәшләрен коткарган геройның күңел халәте диңгез образында аеруча ачык чагыла: *«Диңгез! Сөйкемле дә ул, куркыныч та ул, матур да ул, моңлы да ул. Аның көчлелеге, чикләнмәгән киңлеге, ак күбекләр чәчеп үкергән дулкыннары, ачы тавышлар белән кычкырып очкан акчарлаклары!..»*. Әлбәттә, романтик идеаллар, югары романтик пафос әсәрне шул чор әдәбияты контекстында аңларга, кабул итәргә этәрә.

Лирик төсмерле хикәяләү исә ретроспектив вакытка мөрәҗәгать итүне сорый. «Бөркет токымы» (1944) хикәясе нәкъ шул юлны сайлый. Тыныч тормыш – сугыш кебек билгеләнүче үткән һәм бүгенгенең кырыс чынбарлыгы каршылыгы Рәшит Гыйззәтуллинның бабасы Шаһи карт белән сөйләшүләрен искә төшерүе кебек оештырыла: *«Фронтта, сугышлар тынган арада, Рәшит шул үткәннәрне һаман исенә төшерә торган иде. Бәләкәй капчыгын аркасына асып, Шаһи карт белән ике куллап күрешеп, өеннән чыгып киткәннән бирле бик күп айлар үтте инде. Ләкин Рәшит Гыйззәтуллинның тыныч җаны тиз генә үзгәреп китмәде. Бөтен гомере хезмәттә, тынычлыкта, төзүдә үткән Рәшиткә яндырылган, туздырылган авылларны, хәрабәләр өеменә әверелдерелгән шәһәрләрне, бигрәк тә ерткычларча үтерелгән бала-чагаларны күрү шулкадәр гайре табигый бернәрсә булып тәэсир итте, ул берникадәр вакыт аңына килә алмыйча йөрде. Бу кадәр вәхшилекне, бу кадәр мәгънәсез вату-сындыруны аның сәламәт акылы сыйдыра алмый иде»*.

Сугыш чорында язылган намус һәм бурыч каршылыгына корылган хикәяләрдә олы җанлылык, сабырлык, хакыйкать мәгънәсен символлаштырып, даими кабатланып килүче карт образы бар. Г.Әпсәләмовның «Хәйбулла солдат» (1944) хикәясендә дә якты күңелле, шук табигатьле, кайгыртучан, «отделениенең горурлыгы һәм мактанычы» булган карт солдат образы тудырыла. Ә сугыштан соң язылган хикәяләрендә автор сюжет тукымасын шартлы образлар белән баетуга игътибар бирә. «Онытырлык

түгел» (1954), «Аккош күле» (1958), «Миләш» (1960), «Әттиләү» (1961) һ.б. хикәяләре шул юлны дәвам итә, баета.

Г.Әпсәләмов бу чор иҗатында очерк жанрына да мөрәҗәгать итә. Хикәяләрендәге кебек үк, очеркларында да ул чорга аваздаш яшәү – үлем фәлсәфәсен үзәккә куя. Әдипнең гражданлык рухы белән сугарылган, гади хезмәт кешесенең сугыштагы батырлыгын данлаган очеркларын кисеп үткән төп лейтмотив – язучыны халык тормышы белән бәйләгән күзгә күренмәгән бик нечкә җепләрне кадерләп саклау, югалтмау. Сугыш чорында язылган очеркларын әдип «Карелия блокнотыннан», «Заполярье блокнотыннан», «Манжур сызмаларыннан» дип өч циклга бүлеп тәкъдим итә.

Г.Әпсәләмовның бу дәвердә язылган хикәя һәм очеркларында композицион корылыш, тема-проблематика, сюжет оештырылуы ягыннан жанр чикләрен сакламавы табигый. 1943 елда язылган «Карелия блокнотыннан» циклына кертелгән «Наратлар шаулыйлар», «Йөрәк яна», «Курай» очерклары хикәя жанрының лирик эчтәлеген, кабатлау алымын үз итә. Мәсәлән, кичәге авыл кешесе Сахабетдин Садретдинов батырлыгы хакында хәбәр иткән «Наратлар шаулыйлар» очеркын хикәя жанры белән якынайтучы як – нарат шаулавы турындагы лирик катламның кайма хасил итүе. Әдип публицистикасының бер үзенчәлеге буларак авторның укучысына мөрәҗәгать итеп сөйләве ассызыклана: *«Наратлар шаулавын тыңлаганың бармы синең? Йөзәр ел буенча җәйләрдә яшел ылысларына – ак томаннар, кышларда ак укадай бәсләр уралып торган төньяк наратларының шаулавы үзе бер тарих ул»*. Очерк 138 фашистны юк иткән егерме өч яшьлек Сахабетдинне дусларының мактавы белән тәгәлләнә. Яшәештәге төп кыйммәт буларак изгелек эшләп яшәүне раслаучы автор егетнең батырлыгын «өйдә калган ачык йөзле әнкәсе, шаян, чая Зәйтүнәсе, энесе Гыйлаҗетдиннәр»нең киләчәген яклау белән бәйли һәм Сахабетдин образын яшәү мәгънәсе турындагы «йөзәр еллык» хакыйкатьне – автор фикерен җиткерүче кебек укучыга тәкъдим итә.

Үлем – үлемсезлек төшенчәләрен яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең төп терәге дип раслау фикере әдипнең «Заполярье блокнотыннан» циклына кергән очеркларында да дәвам итә. 1944 елда язылган «Мәңгелек дан», «Варангер-фиордта» очеркларында Нургали Хәсбиуллин батырлыгы үрнәгендә Ватан өчен, дусларың, якыннарың

өчен үлем үлемсезлеккә юл алу буларак раслана, чиксез кыю операция башкарган Георгий Покромович исеме мактала.

1945 елда язылган очерклар «Манжур сызмаларыннан» дигән циклга туплана. «Ли Чен Чан картның әкияте» очеркы корея картыннан язып алган әкиятне сөйләп бирү кебек тәкъдим ителә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр җылылыгы турындагы әлеге очеркта игътибарлылык, җаваплылык кебек сыйфатлар югары күтәрелә. Сукыр ата Сим-понсны коткару өчен кызы Сим-ченның үзен корбан итүе турындагы якты әкият укучыны тормышны газиз кешеләр өчен җаваплы була алу гына мәгънәле итә дигән фикергә алып килә, ул автор фәлсәфәсе, әдипнең тормышны гармониягә китерү юлын тәкъдим итүе кебек укыла. Әнә шулай сугышчы әдипнең истәлек язмалары фронттагы иптәшләренең исемнәрен мәңгеләштерү, чорга аваздаш яшәү – үлем фәлсәфәсен очерклар материалында тәкъдим итүе җәһәтеннән әдәбият тарихында үз урынын ала.

Сугыштан соңгы еллар Г.Әпсәләмов иҗатының, эчтәлеген саклаган хәлдә, форма өлкәсендә эзләнүләр һәм табышлар чоры буларак әдәбият тарихына кереп кала. Сугыштан соңгы татар прозасында Г.Әпсәләмов иң күп романнар авторы буларак танылу ала, роман жанрының чикләрен, мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендә актив эшли. Әдипнең сугыш эчендә туган ил романтикасын тергезгән «Ак төннәр» (1946) повесте, «Алтын йолдыз» (1948) романы героик-романтик әсәр үрнәкләре буларак билгеләнә. Хикәяләүдәге героик пафос, дәвернең йөзен күрсәтү максатыннан патетик гомумиләштерүләргә киң урын бирү, лирик башлангычның тарихи материалдан өстенлеге, субъективлык алга чыгу – Г.Әпсәләмовның әлеге чор иҗатын билгеләгән төп үзенчәлекләрдән.

«Алтын йолдыз» (1948) әсәрендә мәктәпне тәмамлаучы бер төркем үсмерләр, укучылар тормышы сурәтләнә һәм якты хисле яшьләрнең үзара мөнәсәбәтләре олылар тормышының моделе буларак бирелә. Күпсанлы экспрессив диалогларда, төрле ситуацияләрдә аларның үз-үзләрен тотышлары идеаль чынбарлык кебек тәкъдим ителә. Сугыш шартларында төрле рухи-әхлакый сынаулар үткән, тормышка, киләчәккә якты уйлар, хыяллар аша караган яшьләр автор идеалының гәүдәләнеше булып күренә. Алар шул дәвернең заман герое буларак кабул ителә, әдип үзе дә бу геройларын замана геройлары югарылыгына

күтәрә: *«Безнең алдыбызда нинди якты юллар тора, Галим, – диде ул, Галимнең кулын кысып. – Минемчә, сугыштан соң илебездә шундый зур төзелешләр башланыр, алар турында хәзер хыялланыуы да кыен»*.

Г.Әпсәләмовның «Газинур» (1950), «Мәңгелек кеше» (1960) романнары герой концепциясендә үзгәрешләрне хәбәр итә, алар геройларның бердәй модельгә корылуы ягыннан аваздаш. Үзәккә төп геройларның тормыш юлын, эчке кичерешләрен, шәхси батырлыкка ирешү юлларын куйган әлеге романнар тарихи-биографик материалга – документальлеккә мөрәҗәгать итүе, эпик материалның төгәлләнгәнлеге, милли яшәеш сурәтләре белән баетылуы ягыннан да үзенчәлекле.

Каһарман сугышчы Газинур Гафиятуллин язмышына бәйле героик пафос белән сугарылган, тел-сурәтләү чараларына һәм оста итеп сюжет тукымасына үрелгән композицион элемент-алымнарга бай «Газинур» романы дөнья күргәч, әдипнең каләмдәше Г.Бәширов: «Бу роман Г.Әпсәләмов өчен бер адым алга атлау дигән сүз», – дип язып чыга.

Романның үзенчәлеге герой концепциясенең бирелешендә: Газинур образы катлаулы схемага корып иҗат ителә, берничә характерлы якны берләштергән герой буларак алга чыга. Бер яктан, ул башка геройлар белән беррәттән Г.Әпсәләмов тарафыннан соцреалистик концепциягә тугрылыклы калып языла: колхозның конный дворында эшләп ат караучы, көтүче Газинур соңрак леспромхозда урман кисә, һөнәр өйрәнә; туган якларына кайтып колхозда эшли башлый; Бөек Ватан сугышы башлангач, армия сафларына алына, башта санитар булып, аннары разведкада, соңрак пулеметчылар батальонында хезмәт итә; бәрелешләрдә катнаша, командование тарафыннан аерып мактала торган солдат кече командирлар курсларына укырга җибәрелә, аннан кайткач, озак та үтми Газинур сугыш кырында Александр Матросов батырлыгын кабатлап һәлак була. Герой тормышы чын совет кешесе моделенә, коммунистик идеалларга туры китереп сурәтләнә. Романдагы башка персонажлар да – Гали абзый, Володя Бушуев, Зәбиров, Григорьян һ.б. – автор идеалына якын кешеләр буларак тәкъдим ителә.

Икенче яктан, Газинур көчле шәхес моделенә җавап бирә, ныклык, ихтыяр көче, максатчанлык аны билгеләүче төп сыйфатлар буларак калка һәм табигать күренешләре, портрет бирелеше, психологик алымнар аша көчәйтелә.

Мәсәлән, әсәрдәге пейзаж сурәтләнеше еш кына геройларның психологик портретлары белән аваздаш укыла: *«Ажгырып торган амбразурага берничә адым калгач, Газинур бик азга гына тукталды. Язгы аяз күктә, биектә-биектә, бөдрә ак болытлар йөзә иде. Кояш нурлары аларны үтәдән-үтә яктырткан, алар шундый җиңел сыман тоела, өрсәң, тузганак башы кебек очып китәр төсле. Үзләре шундый ак, беренче яуган кар да андый ак булмый бугай... Кайда, кайчан күргән иде соң Газинур шундый ак болытларны?»* Бу очракта ак төс символик мәгънәгә ия: язучы аңа җан, күңел аклыгы, пакьлеге, чистарыну, үлемсезлеккә бару мәгънәсен сала.

Яшәү – үлем, үз чорына аваздаш корбанчылык фәлсәфәсе роман материалында тәкъдим ителә: Газинур туган иле, Ватаны, сөйгән яры, балалары хакына гомерен кызганмый, бу батырлыгы аны үлемсезләр сафына күтәрә; үлеме алдындагы мизгелдә җаны авырлыклардан арына. Башлам өлешендәге җәйге төн сурәтләнеше үк үлемсезлеккә, мәңгелеккә, Газинур батырлыгының бөеклегенә ишарә булып укыла: *«Җәйге җылы төн. Күк йөзе япякты. Әйтерсең аның көндезге зәңгәрлеген бик юка, бик җиңел пәрдә белән генә өретеп куйганнар. Шул үтә юка, үтә җиңел пәрдә астыннан Иләк йолдыз тоныкк кына җемелди. ...Еллар үтәр, кешеләр, бәлки, иләк дигән нәрсәне дә онытырлар, әмма бу шагыйранә исем халык телендә бик озак сакланыр».* Экспозициядә яз күренешен сурәтләү логик-символик чылбырны тәмамлый: *«Яз шаулый. Җир яшәрә, агачлар яфрак яра. Тирәкләрдә кошлар сайрый. ...Ә тирә-якта яз шаулый. Җылы җилләр исә. Күгелҗем урман өсләрендә беренче күкрәү яңгырый. ...Бу күкрәү сугышчыларны киң кырларга, тыныч хезмәткә чакыра, туган җирләрен сагындыра, ашыктыра, җилкендерә».* Солдатлар Җиңү көнен сугышта һәлак булган иптәшләрен сагынып, ләкин киләчәк тыныч тормышка сусап каршы алалар. Автор тормыш сугыш бетү белән төгәлләнми, яралар төзәлә, сагыш-сагыну сүрелә, ә алда – бәхетле, тыныч, якты киләчәк дип кабатлый сыман.

Композицион төзелеше ягыннан бүлекләргә бүлеп бирелгән «Мәңгелек кеше» (1960) романы да шушы юлны дәвам итә, үстерә. Ул герой сурәтләнеше ягыннан Г.Әпсәләмовның соцреалистик таләпләр кысаларында гына калмавын дәлилләп мәйданга чыга. Бухенвальд лагеренда бөтен авырлыкларны, газапларны үз җилкәсендә татыган Бакый Назимов белән танышуы иҗатчы-

ны әлеге әсәрен язуга этәрә. Роман тукымасында сурәтләнгән сюжет, тарихи вакыйгаларны детальләп, фактологик хаталарсыз китерү, реаль тарихи персонажлар белән эш итү «Мәңгелек кеше» романын документаль прозаның матур бер үрнәге итеп укырга мөмкинлек бирә.

Романның баш герое – реаль прототибы булган Бакый Назимов – әсәр тукымасында характерлы образ буларак ачыла. Бер яктан, ул совет кешесенең типик сыйфатларын үзендә туплаган герой буларак бирелә. Беренче бүлекнең исеме үк («Мин – коммунист!») геройның соцреализм принципларына таянып иҗат ителүен ассызыклап куя. Бакый совет идеалларына ихластан ышанган, шул система хакына көрәшүче герой, коммунист итеп сурәтләнә, аның һәр эш-гамәле шушы яссылыкта бәяләнә башлый.

Ләкин икенче яктан, Бакый образы соцреализм кысаларыннан чыгып китә. Г.Әпсәләмов аны, сынмас-сыгылмас көчле рухлы, нык ихтыярлы кеше буларак сурәтләп, көчле шәхес концепциясен билгели. Бакыйның гестапода коточкыч газапларга түзүе, дошманга каршы көрәше әлеге сыйфатларны алга чыгара һәм укучы аңында шәхси ныклык, ихтыяр көче тигезсез көрәштә дә җиңүгә илтә дигән фикерне ныгыта. Пейзаж, портрет, хронотоп бирелеше дә Бакыйны шушы яссылыкта сурәтләүгә юнәлтелә. Мәсәлән, хронотопның еш алмашынып торуы, бүлектән бүлеккә үзгәрүе геройның төрмәдә, соңрак лагерьда булуы белән аңлатыла: Бакый реаль чынбарлыктан уенда гына булса да качу өчен, җәзалауларга түзә алмыйча аңын югалтканда, хыялларына, уй-хатирәләренә чума.

Төп геройның күңел дәрьясын сурәтләү юлында прозаик үзен психологизм остасы итеп күрсәтә, Бакый хатирәләре психологизмның төрле алымнары ярдәмендә бирелә. Геройның, камерада булганда, сөйгән ярын искә төшерүе, аның турында кайгырту мизгелләре эчке монолог алымы белән сурәтләнә: *«Чү, кем әйтә бу сүзләрне? Күр, Кадриясе баш очында утырып, бәләкәй кулы белән аның чәченнән сыйпый бит. «И Кадрия, Кадрия! Кайдан килеп чыктың әле син бирегә? Менә күр, Бакыеңны нишләттеләр... Ярар, төзәлермен әле... Син елама... Көл. Менә шулай яшь аралаш көл. Их син, минем нәни курчагым... Көнләшмәс дисеңме? Ай, юк, барыбер көнләшермен, көнләшермен! Мин шундый көнче инде... Ачуланма, бәгырем. Әйдә, чәчрәп көл! Менә шулай... Син мине күтәрсең бит, ә алар... Әйдә, дошман теләсә ни сөйләсен. Төкерәм мин аларның сүзләренә»*. «Газинур» романыннан аерма-

лы буларак, «Мәңгелек кеше»дә пейзаж бирелеше үзенчәлекле. Беренче әсәрдә ул персонажларның психологик портретларын, эчке кичерешләрен сурәтләү өчен кулланылса, биредә табигать күренеше тасвиры фәлсәфи-семантик алым түгел, ә бәлки эстетик сурәтләү объекты вазифасын башкара: *«Эттерсберг тавының көньяк-көнчыгыш ягын йөзәр еллык бук һәм нарат агачлары каплаган. Гүя тау башындагы лагерь урнашкан бәләкәй сөзәклеккә кояшның җылы нурларын үткәрмәс өчен, анда мәңге дымлы салкын томан, кар-яңгыр булсын өчен, калын кара урманны юри көньякка китереп куеп, ә барлык зәһәр җилләр теләгәнчә уйнап йөри алсын өчен тауның төньяк-көнбатыш ягын сыер ялаган кебек шәп-шәрә иткәннәр. Шуның өстенә биредә һава гел үзгәреп тора: бер карыйсың, юка арестант киеме белән дә эссе, икенче карыйсың, салкыннан тешләр тешкә тими»*. Лагерь тормышы авырлыкларын күрсәтү юлында автор тирә-як пейзаж, экстерьерны сурәтләүдән тыш лагерь бараклары, төрмә камерасы, кабинетлар интерьерын детальләп тасвирлауга басым ясый: *«...Лагерь әйләнә-тирәсенә тыштан да бик күп дзотлар, дотлар тезеп чыкканнар. Лагерьны ураган сукмак буенча, өйрәтелгән этләр ияртеп, эсэсчылар йөри. Менә шушы катлы-катлы тимер алка эченә алынган кысан мәйданга гитлерчылар ун меңнәрчә тоткыннарны китереп тыгалар. Соңга таба монда икешәр һәм берәр катлы итеп алтмышлап барак салына. Шул баракларда, яки, биредәгечә әйтсәк, блокларда, өчәр-дүртәр катлы шәрә сәкеләрдә тоткыннар яши. Мондагы кысанлыкны бары тик кабер тарлыгы белән генә чагыштырырга мөмкин»*.

Романда көчле позициягә чыгарылган «мәңгелек кеше» метафорасы да яңа сыйфатларны билгеләү мөмкинлеген бирә: Г.Әпсәләмов бу романында кешене иң югары биеклеккә, мәңгелек кыйммәт дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли, үз чоры таләпләренә туры килерлек көчле кеше фәлсәфәсен тәкъдим итә.

1959 елда Г.Тукай бүләгенә лаек булган «Сүнмәс утлар» (1953–1958) романы Г.Әпсәләмовны яңа иҗат дәверенә алып чыга, әдип прозасында 1960 елларның икенче яртысыннан башланачак яңа баскычны әзерли. Язучының производство романы дип исем алган, яңа тормыш төзүчеләр яшәешен яктырткан әлеге «Сүнмәс утлар» романы шушы дәвердә соцреализмның үсеш юлында яңа баскычка күтәрелеп, аерым кеше тормышының, яшәешенең

кыйммәте хакында уйланулар белән баетылуын да раслый.

Казан заводларының берсендә эшләгән Уразмәтовлар династиясен сурәтләгән «Сүнмәс утлар» романы Г.Әпсәләмовны психологизм остасы итеп күтәрә. Язучының талант дәрәҗәсен билгеләрлек тирән психологизмны прозаик шушы романында сәнгати дәрәҗәгә күтәрә, киеренке эпизодны сурәтләү барышында бер алым белән генә чикләнми, ә бәлки алымнарның гармонияле синтезын тәкъдим итә: *«Шундый шат, көләч, мөлаем Гөлчирәнең кинәт бөтенләй үзгәреп, ярсып, театрны ташлап китүен Назиров башта берничек тә аңлый алмады. Нәрсә булды аңа? Ни өчен ачуланды ул? Ник китте? Гөлчирәнең хәтерен калдырырлык нәрсә эшләде соң ул? Бер генә минутка, анда да гафу үтенеп, Идмас янына барган икән... Назиров ачуланышуның бөтен сәбәбен Гөлчирәдән генә, аның аңлашылмас холкыннан гына эзләде. ...Назировның колаклары, битләре, муены, бөтен тәне әкренләп кыза башлады. Алдады бит ул теге вакытта Гөлчирәне. Антлар эчкәндә чынын әйтмәде!..»* Шунда ук геройның эчке хисләре тышкы билгеләр аша да ачыла башлый: *«Назиров төне буе йокламады, юләр кеше шикелле почмактан почмакка йөренде, аннары хат язарга утырды. Кулына каләм алганда, аның кулы дер-дер калтыранды. Ул көчхәл белән генә бер сүз яза алды: «Гөлчирә...» Артык яза алмагач, торып, яңадан йөрenә башлады, яңадан хат язарга утырды»*. Герой өзгәләнә, җаны сыкрый, күңелендәге туфанны әйтеп бирерлек сүзләр таба алмый, икеләнү катыш сагыну, үкенү туа, хис-фикерләре үзгәреш кичерә: *«Назиров, рәсемне кулына алып, шашкан кеше сыман аңа карап тора башлады. Гөлчирә чак кына елмайган. Элек Гөлчирәнең бу елмаюында Назиров тыйнаклык, нәфислек, оялчанлык, горурлык, яшерен теләкләр чагылышы гына күрә иде. Хәзер исә ачы ирония, үчекләү, рәхимсезлек кенә күрде. ...Назиров, җан газабына чыдый алмыйча, чишенми-нитми кроватена ташланды, йөзтүбән капланып бик озак хәрәкәтсез ятты. Аннары, сикереп торып, тагын хат язарга утырды. Бу юлы буа ерылып киткәндәй булды, ул, сулыш та алмыйча, дүрт-биш битне язып та чыкты. Аңа калса, аның кайнар сүзләреннән кәгазьгә ут кабарга тиеш иде, ләкин Назиров, хатын укый башлагач, аның сап-салкын икәнлеген күреп, ерткалап ташлады. Әгәр мөмкин булса, ул үзен дә шушылай вак кисәкләргә өзгәләп ташлар иде»*.

Г.Әпсәләмов прозасына хас булганча, көчле позициягә (эпиграфка) чыгарылган әсәрнең идеясе К.Тинчурин сүзләре белән дә көчәйтелә: «Без кабызган утлар сүнмәс алар, Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...» Әсәрнең исеме җыр сүзләре белән аваздаш килеп, сүнмәс утлар вакыйгалар барышында буыннар арасындагы бәйләнешләр, онытылмас хезмәт батырлыклары, бер буын төзегән тормышны икенче буынның дәвам итүе, бөек эшләр эшләүче гапгади эшчеләр символы булып укыла. Әлеге роман әдәбият тарихы өчен чын мәгънәсендә хисси борылышлар, тирән эмоциональлеккә ия вакыйгалар белән сугарылган хезмәт романының матур үрнәге буларак кыйммәтле. Әлеге сүз-сурәт үзенчәлеге, сәнгати алымнар «Сүнмәс утлар» романыннан соңрак язылган «Күк күкрәр» (1972), «Агыла болыт» (1977) кебек романнарында да дәвам итә, үстерелә.

Г.Әпсәләмов романнарында кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләр милләтара мөнәсәбәтләрнең нигезе дип тәкъдим ителә. Шушы чорда иҗат ителгән хикәя-повестьларында да әдип тормыш фәлсәфәсен кеше күңеленең байлыгы, тирәнлеге белән бәйләп куя. «Дустым мәхәббәте» (1958) повесте Мин Ин исемле кытай кызы белән Вася Дубровин арасындагы якты хисләрне хикәяләп бирүгә корыла. Дустын татар театрлары, операсы, композиторлары белән таныштырганнан соң һәм татар шагыйрьләре, артистлары турында сөйләгәннән соң, кытай кызының «татар музыкасы безнекенә охшаган икән» дип соклануы әдипнең кешелек фәлсәфәсен җиткерүе кебек кабул ителә: *«Мин чәчәкләр яратам. Җәй көне бакчамда үрмәле гөлләр үстерәм. Алар шундый матур, шундый купшы була, сокланмаган кеше калмый. Ничек сокланмасыннар! Үрмәле гөлләр дуслык билгесе бит»*. Повестьта дуслык һәм гаилә шәхес өчен терәк дип иң олы кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә. Әнә шулай 1950–1960 елларда язылган романнарында Г.Әпсәләмов яшәү фәлсәфәсен каткат төрле яссылыкларда кабатлый. Аның бу дәвер иҗаты автор-хикәяләүченең укучысы белән герое ярдәмендә җылы, ихлас сөйләшүе буларак кабул ителә, әсәрләрендә сурәтләнгән дөньяның бай һәм төрле булуы күзәтелә.

1960 еллар әдәбиятындагы үзгәреш-яңарышлар Г.Әпсәләмов иҗатына да «иҗади борылыш», билгеле дәрәҗәдә үзгәрешләр алып килә: аның әсәрләрендә тематик-проблематик яңарыш, яңа сәнгати алым-чаралар күзгә ташлана. Әдип иҗатындагы әлеге үзгәрешләр чор әдәбиятын-

да барган үзгә стиль тенденцияләренең формалашуына мөнәсәбәтле килеп керә.

Билгеле булганча, 1960–1980 еллар — татар әдәбиятының милли нигезләргә кайту чоры – татар прозасында яңа эзләнүләр, яңа сукмаклар, психологизмның, тәнкыйди башлангычның көчәюе, лирик-эмоциональ, публицистик башлангычларның зур урын алуы һ.б. сыйфатларның алга чыгуы, стиль тенденцияләренең, сәнгати алымнарның байлыгы белән билгеләнә. Шушы еллардан әдәбиятта бер тармакның соцреализм кысаларыннан чыгып китеп, классик, традицион реализмга якынаюы, реализм юнәлешен тәнкыйди башлангыч белән баетуы күзәтелә, сүз сәнгатендәге яңарыш-үзгәрешләр хакында хәбәр итә. Тәнкыйди парадигма шәфкатьсезлек, имансызлык, ялган кебек сыйфатларга юнәлтелеп, җәмгыятькә шул сыйфатларның хас булуын, кешеләрнең рухи ярлылануын күрсәтә һәм заман кешенең дөньяга карашын да, әхлагын да, холык-фигылен дә үзгәртә, үзенә яраклаштыра дигән фикерне ныгыта, алар җәмгыятьтәге, аерым кешеләр күңелендәге начарлык, ямьсезлекнең кешене кеше буларак юкка чыгаруы хакындагы фикерләр белән үрелеп китә. Шуның белән янәшәдә тәнкыйди катлам милли әчтәлекле мәсьәләләргә – рухи бәйләнешләр өзелү, традиция-гадәтләрнең, телнең югала баруы, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүе, туган җир, туган нигез кадеренең кимүе, татар авылларының юкка чыгуы кебек проблемаларга игътибарын юнәлтә.

Тәнкыйди дискурс авыл темасына язылган әсәрләр белән янәшәдә шәһәр прозасында да күзәтелә. Гомумбилгеле төзелешләрне, шәһәр тормышын әдәби сурәтләү омтылышы «шәһәр прозасы»ның формалашуына этәргеч бирә, заман биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, шул чор вакыйгаларын, шәһәр тормышын сурәтләү аша җәмгыятьтәге тәртипләргә мөнәсәбәт белдерү урын ала. Бу юнәлештәге әсәрләр шәһәр кешесенең эчке дөньясын, тормышын сурәтләүне алга куя, аны гадел хезмәт кешесе, эшче яки зыялы, интеллигент итеп сурәтләүгә йөз тота. Шәһәр прозасы җәмгыятькә хас проблемаларны да шәһәр тормышы материалында, фонында ачарга омтыла, шуңа мөнәсәбәттә аларда эшчеләр тормышына, зыялылар катлавындагы аерым проблемаларга карата тәнкыйди башлангыч көчле яктыртыла.

Икенчедән, бу юнәлештәге мәгълүм торгынлыктан соң, 1960 еллардан милли әдәбиятта психологизм көчәю кү-

зәтелә. Аерым әсәрләрдә шәхеснең уй-фикер, хис-кичереш, теләк-омтылышлар үзгәреше, аның эш-гамәлләре белән бәйләнештә яктыртылып, төп сурәтләү объекты итеп күтәрелә, тышкы дөньяны геройның психологик кичерешләре аша бәяләргә омтылыш күзәтелә. Геройның эчке дөньясын, дөньяга карашын, мөнәсәбәтен ачу барышында психологизмның көчәюе күзгә ташлана. Әлеге сурәтләр авторның тормыш-яшәеш хакында күзаллаулары белән үрелеп китә. Аерым әсәрләрдә геройларның тирәлектә җәмгыять кануннарына буйсынырга мәҗбүр булуы, татар тормышына хас мәсьәләләр реалистик традицияләрне яңарта, геройларның эчке дөньясын, мәхәббәткә бәйле хис-тойгыларын үзәккә алу, психологик тирәнлек белән сугару, идеаллар яктылыгында, лирик-эмоциональ яссылыкта бәяләргә омтылу барышында язучылар романтик принципларга йөз тота.

Аерым бер язучылар иҗатында лирик-эмоциональ башлангычка өстенлек бирелә. Авыл һәм шәһәр тормышын, кешеләрен хис-кичереш дулкынында сурәтләү әсәрләрнең тәэсир итү көчен арттыра. Аларда хикәяләүче яки автор образы, вакыйгаларны күзәтүче генә булып калмыйча, аларда катнашучы герой халәтенә күтәрелә. Д.Заһидуллина билгеләгәнчә, әсәр чынбарлыгын сөйләүче-күрсәтүче генә түгел, ә бәлки шушы чынбарлыкка мөнәсәбәтен үсеш-үзгәрештә, хәрәкәттә сурәтләүче автор «мин»е, шуның тирәсенә тупланган лирик-субъектив катлам вакыйгалар катламыннан да зураеп китә... Нәтиҗәдә әсәрдәге төп каһарман булган «мин»нең рухи дөньясы, аңы укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә ала. Мондый әсәрләрдә үткәндәге якты-бәхетле яшәү рәвешен хәтердә тергезү мотивлары калкытылып, герой язмышы балачак хатирәләреннән алып хәзергенең үткен, каршылыклы күренешләренә кадәр аралыкта тирбәлә. Шул ук вакытта кеше язмышы вакыйгаларда гына түгел, бәлки ниндидер хәлләргә мөнәсәбәтле формалашкан хис һәм мөнәсәбәт тарихы кебек бирелә. Рухи тормыш иҗтимагый тормыштан югарырак куела, әсәрләр хикәяләүче яки үзәк герой турында сөйләү төсле кабул ителә.

Көчле бер агым буларак башланып киткән әлеге сыйфат үзгәрешләре Габдрахман Әпсәләмов иҗатына да йогынты ясамый калмый. «Ак чәчәкләр» (1966) романы аның иҗатындагы сыйфат үзгәрешләренең хәбәрчесе буларак дөньяга чыга, язучының соцреализм иҗат кысаларыннан чыгып, «лирик агым»га йөз тотуын раслый. Габ-

драхман Әпсәләмов иҗатының гына түгел, чор әдәбиятының гәүһәр ташы булган әлеге роман популярлыгы белән дә, образларның сәнгатьчә эшләнеше, әсәрнең әдәби камиллеге ягыннан да аерым урын тота. Үз вакытында ук әлеге әсәр социалистик реализм турындагы карашны киңәйтә һәм реалистик материалда романтик алымнарны уңышлы куллану мөмкинлекләрен дәлилли, авыл прозасының сәнгати традицияләрен дә читкә куймый һәм аларны, шәһәр кешеләренең тормышын сурәтләүгә юнәлтеп, шәһәр прозасы үсешенә өлеш кертә. Шул чор әдәбиятында, бигрәк тә авыл яшәешен сурәтләгән әсәрләрдә, геройны лирик-эмоциональ кичерешләр дулкынында тасвирлау күренеше Г.Әпсәләмовның шәһәр прозасына караган әсәрләренә дә тәэсир итә, яңа сулыш өрә. Бүгенге көн югарылыгыннан торып бәяләгәндә, романның кыйммәте шәһәр кешеләрен производствода, завод-фабрикаларда хезмәт иясе буларак сурәтләүдән китеп, зыялылар катлавын, аларның тормыш-яшәешен хис-кичерешләр, уйтойгылар дулкынында тасвирлавы белән билгеләнә торгандыр.

Романда вакыйгалар катламы медицина институтын тәмамлап, гади татар авылында эшләгән Гөлшәһидәнең профессор Әбүзәр Таһиров җитәкчелегендә врач булып өлгерүе, үзенең хакыйкатен раславы һәм Мансур белән мөнәсәбәтләре, гаилә кору тарихы хакында сөйли. Төп геройның бәхеткә ирешү юлын тасвирлаган күпсанлы вакыйгалар төп ике сюжет чылбыры тирәсенә җыела: бер сызык медицина тормышын яктыртып, аңа хас проблемаларны күтәрсә, икенче сюжет сызыгы Гөлшәһидә белән Мансурга бәйле вакыйгаларны бер бәйләмгә туплый һәм романтик алымнарга таяна. Биографик вакыт чикләре Гөлшәһидәнең яшүсмер елларыннан башлап шәхес буларак өлгерү чорына кадәрге вакыйгаларны берләштерсә, тарихи вакыт 1940 еллардан 1960 елларның урталарын үз эченә ала.

Мәхәббәт тарихы белән бәйле романтик сюжет сызыгы Гөлшәһидәнең Мансур белән танышуы, гашыйк булуы, үткән мәхәббәт тарихлары һәм алдагы мөнәсәбәтләре турында хәбәр итә. Бу катламда мәхәббәткә бәйле эчке каршылык алга чыга һәм Гөлшәһидә белән Мансур күңелендәге хис – акыл көрәшен ача. Шушы башлангыч әсәрне психологик дулкынга көйли: күңел кичерешләре, теләкомтылышлары әсәрнең буеннан-буена төрле сурәтләрдә укучыга җиткерелә, геройларның эчке дөньясын, ки-

череш-тойгылар үзгәрешен, күңел кичерешләрен ачуга юнәлтелә. Биредә психологизмның геройның үз эчке уйлануларын бәян иткән эчке монолог, үзанализ, психологик анализ алымнары күзәтелә. Автор Гөлшәһидә һәм Мансур күңелендә туып, үстерелә барган хис һәм фикер көрәшен, үсеш-үзгәрешен детальләп сурәтли, укучыны аларга сокланырга, алар өчен борчылырга, алар тормышы белән яшәргә мәҗбүр итә. Текстта символик, метафорик образлар һәм детальләр дә еш кына психологик характерда булуы белән үзенчәлекле, «Ак чәчәкләр» романының уңышы да, бәлки, әсәрдә психологик кичерешләрнең киң һәм иркен бирелүенә бәйледер.

Геройларның субъектив кичерешләрен җиткерү барышында киң таралган алым буларак әсәргә җыр текстларын урнаштыру аерылып чыга. Әсәр тукымасында җырлар метафора буларак ике мәгънәне – гомер агышын һәм мәхәббәт кичерешләрен ачуга буйсындырыла, аеруча соңгысы киң кулланыла. Ул Мансурны өзгәләнеп көткән кыз кичерешләрен дә (*«Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы, Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы»*), күңелдә даими яшәп килгән Олы хисне дә (*«Гыйшык уты сүнә, диләр, Сүнми дә, сүрелми дә»*), Фазылҗанның мәхәббәтен кабул итә алмыйча бәргәләнү газабын да (*«Җил исә тын гына, ай йөзә моң гына, Күңелдә ул гына, йөрәктә ул гына...»*), Мансурның Гөлшәһидәне юксынып бәргәләнү тойгысын да (*«Ул уйнаган көйнең авазлары кемнедер әзлиләр, сагыналар, юксыналар, кемгәдер омтылалар, аннары диңгез дулкыннарыдай ярсып ярга бәреләләр дә, меңгә чәчрәп, кире чигенәләр... Күзгә яшь килә, бугаз кысыла. Аннары буйсынырга теләмәү, язмышка риза булмау авазлары яңгырап калкып чыга, яңадан көчле, дәртле, өметле авазлар яңгырарга тотына».*) укучыга җиткерергә ярдәм итә.

Психологик кичерешләрне җиткерү юлында автор табигать күренешләреннән дә уңышлы файдалана. Романда еш кабатланып торган Гөлшәһидәнең кыр казлары тавышын ишетеп сихерләнүе (*«Көн аяз, күк йөзе чип-чиста. Шушы саф зәңгәрлектә кыр казлары озын муеннарын сузып очып баралар. Уйсурак җирләрдән әле эрегән кар исе аңкый, урләр өстендә җиңел рәшә тирбәнеп тора. Язның сихерле авазлары белән тулы шушы киң кырда кыр казларының һичнч белән чагыштыргысыз моңлы җырлары Гөлшәһидәнең күңелен әсәрләндерде».*), айның, кояшның болытлар белән каплану күренеше, яшенле яңгырның тынып калып, табигатькә тынлыкның иңүе

кебек табигать сурәте, аның күңел кичерешләрен, эчке дөньясындагы үсеш-үзгәрешләрне ачу белән бергә, рухи чисталыгына, «табигать баласы» булуына да басым ясый. Г.Әпсәләмовның Гөлшәһидә, Мансур образларын сурәтләүдә портретның психологик портрет төренә ешрак мөрәҗәгать итүе дә психологик кичерешләрне тирәнәйтү максатына йөз тота. Бу геройлар язмышы укучыда бер фикерне ныгыта: кеше көрәш һәм сабырлык аша гына үз бәхетенә ирешә ала.

Врачлар, медицина хезмәткәрләре тормышын яктырткан, алар белән бәйле вакыйгаларны бер бәйләмгә туплаган реалистик сызыкта конфликтның эчке каршылык, тышкы каршылыклардан *герой – герой* кебек формалары чагылыш таба. Әбүзәр Гиреевич, Мансур, Гөлшәһидә – Фазылҗан, Сәлах Саматовлар каршылыгы кешеләр яшәешенә, алар арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйле сыйфатларны аерып чыгарырга һәм автор позициясен төгәлләштерергә ярдәм итә.

Романда геройлар соцреалистик әсәрләрдәге кебек капма-каршы ике төркемгә җыела һәм яхшылык – яманлык оппозициясе тирәсенә туплана. Гөлшәһидә, Мансур, профессор Әбүзәр Таһиров, Диләфрүз, Юматша кебекләр оппозициянең бер ягына карый, аларның эш-гамәлләрендә дә, эчке дөньяларында да яхшылык кылу сыйфаты калкып чыга, Фазылҗан Яңгура, Илһамия, Сәлах Саматов, Клавдия Сергеевна кебекләрнең гамәлләрендә дә, күңелләрендә дә яманлык әйдәп бара. Уңай геройлар буларак бирелгән Таһиров, Гөлшәһидә, тискәре герой — профессор Яңгура медицинада, врач хезмәтенә мөнәсәбәттә капма-каршы позицияләрдә торган кешеләр буларак алга чыгалар. Шушы катламда сурәтләнгән сыйфатлар, күтәрелгән проблемалар врачларның хезмәткә мөнәсәбәтенә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә тәнкыйди бәя булып формалаша.

Бу катламдагы төп каршылык Әбүзәр Гиреевич белән Фазылҗан, ягъни дөньяга төрле карашлы шәхесләр арасында бара, Мансур, Гөлшәһидә, Юматша, Сәлах Саматов, Клавдия Сергеевна кебек күп кенә геройлар йөзендә кабатлануы проблемаларны тирәнәйтә, калкуландыра. Таһировның Фазылҗан Яңгура белән каршылыгы врачлар тормышында хөкем сөргән ялганны, үз эшеңә салкын мөнәсәбәт, бюрократлык, хәйләкәрлек, мин-минлек мәсьәләләрен ачып бирсә, Гөлшәһидә белән Яңгура, Сәлах Саматов мөнәсәбәтләре икейөзлелек, астыртынлык, үз эшеңә

салкын мөнәсәбәт, эчке бушлык кебек сыйфатларны кешеләр тормышын түбәнгә тартучы көчләр дип күрсәтә, Мансур белән Фазылҗан каршылыгы бу проблемаларны тагын да тирәнәйтеп, кешенең үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртуын, аны бердәнбер хакыйкать дип раславын, тар күңеллелек, эгоизм, көнчелек сыйфатларын ачып бирә, кеше белән җәмгыять, яшәеш идеаллары арасындагы аерымлыкны ассызыклый. Әнә шулай иҗтимагый эчтәлекле проблемалар гомумкешелек мәсьәләләренә үрелеп китеп, медицина хезмәткәрләре тормышына тулы, төрле яклап бәя бирелә. Бу проблемалар бергә кушылып, тәнкыйди башлангычны да формалаштыралар. Шушы бәяне тулыландыру өчен автор метафоралардан да уңышлы файдалана. Мәсәлән, *«Бик зур буалар була. Су өсте көзге кебек шоп-шома, тып-тыныч, гүя ул юаш, күндәм. Улагын ачсалар, гөрләргә тотына, тегермән ташларын, турбиналарны әйләндерә, улагын япсалар, тагын тынып кала һәм мәңге шулай буйсынучан булып яшәр төсле. Әмма тәҗрибәле гидролог аның эчендә кайнаган «ачуын» сизә, аның колагы кайдадыр төптә бөтерелгән дулкыннарның ярсу гөрелтесен ишетә»* күренеше, метафора буларак, Фазылҗанның яшәү рәвешен генә түгел, аның кебек күпләрнең эчке дөньясын ачарга, тормыш позициясен күзалларга мөмкинлек бирә.

Аларның караңгы якларын тагын да көчәйтү, тирәнәйтү барышында автор идеаллаштырылган геройларга мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә Гөлшәһидә, Әбүзәр кебек үзенчәлекле геройлар әдәби мәйданга чыга. Бер яктан, Гөлшәһидә – табигать тарафыннан бүләк ителгән табигый хискә буйсынып, Мәхәббәткә омтылучы, яратырга, яратылырга теләп яшәүче, Туган җиргә, Яхшылыкка, Табигатькә, Хакыйкатькә табынып яшәүче зат. Әсәр үзәгенә аның нәкъ менә шушы теләкләре, хис-кичерешләре, ышану-омтылышлары куелу әсәрне бүгенге укучы өчен дә кызыклы итә, тәэсир көчен арттыра. Ләкин шуның белән янәшәдә ул – хезмәт кешесе, совет чоры идеаллары белән яшәүче, аларны тормышка ашыру юлында армый-талмый эш-гамәлләр кылучы Галияләрнең (Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы) дәвамы да. Экспозиция өлешендә үк Г.Әпсәләмов, кызның холык-фигыленә ишарә ясап: *«Гөлшәһидә башын гадәттәгедән югарырак тотып, дөньяга күзләрен зур итеп ачып карап, агач баскычтан су буена төште, дамба буйлап Кремльгә таба китте. Троллейбуста да, аннары трамвайда да керфекләрен тү-*

*бән төшермәде»*, – дип таныштырып куя. Әлеге портрет аның дөнья күзенә туры карый алучы, сер бирмәс шәхес булуын шәрехли, вакыйгалар агышында да әлеге сыйфатлар ассызыкланып бара.

Үз эшенә табынып яшәүче профессор Әбүзәр Гиреевич Таһиров образы да идеягә инануы ягыннан «Сүнмәс утлар»дагы Сөләйман Уразмәтовның дәвамы кебек кабул ителә. Вакыйгалар хикәяләүче исеменнән сөйләнә. Әмма язучының медицина хезмәткәрләренә, мәхәббәткә карата шәхси позициясе әледән-әле әйтелә тора, ул аларны Әбүзәр фикерләре, бәясе аша да җиткерә. Аның «*Врач үзе өчен генә яшәми, ул барыннан да элек башкалар өчен яши! Үз кайгысы чыдый алмаслык булса да, аның җебергә хакы юк. Ул бөек артист булырга тиеш!*» кебек әсәр тукымасында даими кабатланып торган фикерләре, тормыш позициясе, яшәү рәвеше авторның да врач намусы аклыгы турындагы уйлану-фикерләре булып күзаллана. Шуңа бәйләп, врачлар тормышының формуласы, теориясе ачыклана: ул даими кешеләр тормышы хакына яшәргә тиеш, кешелекнең киләчәге алар кулында.

Үз идеясен җиткерү барышында автор, тагын да уңышлырак юлны сайлап, ак чәчәкләр образына мөрәҗәгать итә. Көчле позициягә – әсәр исеменә үк чыгарылган әлеге образ вакыйгалар агышында күп мәгънәле символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Бер яктан, ул врачлар, кеше гомере өчен көрәшүче медицина хезмәткәрләре буларак аңлашылса, икенче яктан, аның аклыгы Әбүзәр, Гөлшәһидә, Мансур, Юматша, Диләфрүз кебекләрнең күңел аклыгына, тормышларындагы якты идеалларына аваздаш, өченче яктан, ул рухи югарылыкка ирешү символы булып кабул ителә. Шул рәвешле, романда кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләргә, врачлар тормышындагы хезмәткә табынуга нигезләнгән тормыш фәлсәфәсе татар укучысына якын лирик-эмоциональ дулкында бирелә. Язучының моннан соң язылган «Яшел яр» (1968) романы, «Идел хикәяте» (1971) повестьлары да шушы дулкынны дәвам итә.

Әдәби иҗат эшеннән тыш Г.Әпсәләмов татар әдәбиятын дөнья киңлекләренә чыгарган, аның дөньякүләм танылуына өлеш керткән әдип буларак билгеле. 1940–1983 еллар арасында татар, рус телләрендә, СССР һәм чит ил халыклары телләрендә әдипнең йөзгә якын китабы дөнья күрә. Г.Әпсәләмов үзе дә тәрҗемә эше белән актив шөгыльләнә: А.Гайдарның «Тимур и его команда» («Ти-

мур һәм аның командасы», 1941) повестен, Э.Казакевичның «Весна на Одере» («Одерда яз», 1951), А.Фадеевның «Молодая гвардия» («Яшь гвардия», 1950, 1956) романнарын һәм В.Короленко, Н.Лесков, Д.Мамин-Сибиряк, А.Новиков-Прибой, М.Пришвин, Н.Тихонов кебек күренекле рус язучыларының хикәя китапларын татар теленә тәрҗемә итә. Актив иҗат эше белән шөгыльләнгән әдип гомеренең соңгы көннәренә кадәр каләмен кулыннан төшермичә, 1979 елның 7 февралендә Казанда вафат була.

Г.Әпсәләмов иҗаты иң олы һәм гадел хөкем саналган вакыт сынавын узды. Әдипнең Газинур язмышына бәйләп сугыш чорын тасвирлаган «Газинур» (1951), көчле шәхес концепциясен тәкъдим итеп, кешене мәңгелек кыйммәт югарылыгына күтәргән «Мәңгелек кеше» (1960), медицина хезмәткәрләре тормышын гәүдәләндереп, бүгенгәчә популяр булган «Ак чәчәкләр» (1966), мәктәп, укытучылар тормышын һәм хезмәтен мәхәббәт, әхлак проблемалары белән бәйләнештә сурәтләгән «Яшел яр» (1968) һ.б. романнары, сугыш чоры яшьләренең эчке дөньясын, теләк-максатларын сурәтләү объекты иткән «Миңа унтугыз яшь иде» (1968), һәвәскәр рәссамның рухи кичерешләрен укучыга җиткергән «Идел хикәяте» (1971) повестьлары, дистәләрчә хикәяләре, очерклары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, публицистик язмалары һәм истәлекләре Г.Әпсәләмов иҗатының киң кырлы, күп катламлы, жанр төрлелеге һәм тема ягыннан гаять бай булуын раслый. Аларның барысын да бер максат – хезмәт һәм сугыш кырында замандашларының теләк-омтылышларын, хыялларын, батырлыгын, эчке дөньяларын ачу, заман героен сурәтләү бер бәйләмгә туплый, шул яктан аның әсәрләре үткән XX гасыр тормышының иҗади елъязмасы булып укыла һәм әдәби мирасның бер хәзинәсен тәшкил итә.

*Нурфия Йосыпова,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*Гөлфия Гайнуллина,*
*филология фәннәре кандидаты*

# Газинур

*Рус баһадиры Александр Матросовның бөек батырлыгын кабатлап, дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплаган халкыбызның турылыклы улы – Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинның якты истәлегенә багышлыйм бу әсәремне.*

...Көрт баскан тар амбразурадан көчле ут ыргылды. Бер генә минутка туктап торган фашист пулеметы яңадан котырынып ата башлады. Кар өстенә яңа яралылар ауды. Сугышчылар, ут астыннан чыгар өчен, бөтен көч белән алга ташландылар, ләкин аларның сафлары сирәгәйгәннән-сирәгәя барды...

Күзләрен зур итеп ачкан, күңеле нәфрәт белән ташыган хәлдә, Газинур үкереп торган дошман пулеметына өзгәләрдәй булып карый. Ул якын гына, ләкин аңа барып җитәргә мөмкин түгел. Аның утлы бугазын тыгарлык бер көч тә юк шикелле.

– Юк, барыбер туктата алмассың, явыз! Барыбер муеныңны борам!

Газинур яткан җиреннән сикереп торды. Моңарчы кара кургашын тутырган сыман авыр тоелган гәүдәсе кинәт җиңeлəеп киткәндәй булды. Әйтерсең аңа канатлар чыкты. Ул дзотка таба йөгерә башлады.

Батальон тетрәп тынып калды. Аның күз алдында гади совет солдаты үлем белән үлемсезлек арасын үтә, буыннардан буыннарга калырлык, телләрдән телләргә күчеп легенда итеп сөйләрлек, җырларда җырларлык батырлык эшли иде.

Ажгырып торган амбразурага берничә адым калгач, Газинур бик азга гына тукталды. Язгы аяз күктә, биектә-биектә, бөдрә ак болытлар йөзә иде. Кояш нурлары аларны үтәдән-үтә яктырткан, алар шундый җиңел сыман тоела, өрсәң, тузганак башы кебек очып китәр төсле.

Үзләре шундый ак, беренче яуган кар да андый ак булмый бугай...

Кайда, кайчан күргән иде соң Газинур шундый ак һәм җиңел болытларны?

Фашист пулеметы котырынуының соңгы чигенә җитеп үкерә. Кара амбразурада пулемет авызыннан чыккан ялкын утлы хәнҗәр төсле айкала. Кышкы зәһәр җил кебек, пулялар чыелдап сызгыра.

Һәр секунд кыйммәт...

## Беренче бүлек

### 1

Җәйге җылы төн. Күк йөзе яп-якты. Әйтерсең аның көндезге зәңгәрлеген бик юка, бик җиңел пәрдә белән генә өртеп куйганнар. Шул үтә юка, үтә җиңел өрфия пәрдә астыннан Иләк йолдыз тоныкк кына җемелди. Өелешеп-өелешеп торган бу йолдызларны нинди шагыйрь иләккә охшаткандыр – хәзер берәү дә белми, һәм моннан соң да ул серне һичкем ача алмас инде. Еллар үтәр, кешеләр, бәлки, иләк дигән нәрсәне дә онытырлар, әмма бу шагыйранә исем халык телендә бик озак сакланыр.

Иләк йолдызның нуры җиргә сизелер-сизелмәс кенә, оялчан гына агыла, алар әйтерсең яктылыктан куркалар. Әгәр шундый төннәрдә Иләк йолдызга күз текәп озаграк карап торсаң, алар хәрәкәттә кебек, гүя бөтен төркемнәре белән биеккә-биеккә менеп баралар, гүя күз алдында боз кисәкләредәй әкрен-әкрен генә эриләр.

Ай арасы булганлыктан, ай калыкмый. Тирә-як җылымса, йомшак зәңгәрлеккә чумган. Спасс сырты ягыннан искән төнге әкрен җил авылга болын печәненең хуш исләрен алып килә. Көндез кояш кыздырган җир хәзер ягылган мичтәй рәхәт җылылык бөрки. Авылның түбән очындагы чишмәнең әргән уйнаган шикелле чылтыр-чылтыр агуы, этләрнең ялкау гына өреп алулары, кайдадыр Гафиятулла бабайлар ягында сыздырган гармун көенә кемнәрнеңдер кушылып җырлап җибәрүләре ишетелә. Төз киң урам, рәшәткәле яшь бакчалар, шул бакчалар эчендә сыенып утырган җыйнак кына ап-ак өйләр җәйге төннәрдә генә була торган матур һәм серле бер төс алганнар. Авыл уртасындагы киң мәйданда мәктәп, клуб һәм колхоз идарәсе йортларының калай түбәләре, зур-зур тәрәзәләре тимгелләнеп ялтырыйлар.

«Красногвардеец» колхозы киң үзәнлеккә утырган. Аның дүрт ягында да артык биек булмаган таулар калкып тора. Төнлә ул таулар авылга тагын да якынрак елышалар төсле, гүя авылның татлы йокысын саклыйлар.

Өйләрдә утлар күптән сүндерелгән. Тик правлениедә ут бар да, ферма капкасына эленгән ялгыз фонарь гына сыңар күзен кыскалый. Вакыт бик соң, озакламыйча әтәчләр өченче тапкыр кычкырыр. Ул чагын авыл яңгырап торыр. Ә хәзер тирә-якта шылт иткән тавыш юк. Хәтта тынгысыз чишмә дә, үзенең агышын әкренәйтеп, шыпырт кына сөйләшә кебек.

Кырыйдагы бер өйнең ян тәрәзәсен ачып, ак пәрдәсен күтәрделәр. Чокырланып торган яфраклы, вак кына ак чәчәкле хуш исле чүмеч гөлләр арасыннан чәчен турыдан ачып ике толым итеп үреп салган яшь кыз күренде. Ул төнге урамга бераз карап торды да кинәт тагын юк булды. Ак пәрдә төште. Күп тә үтмәде, өйнең болдыр ишеге сак кына ачылды. Аннан иңенә тимерьюлчылар кия торган җиз төймәле кыска жакет салган бер кыз чыкты. Баскыч төбендә ул уңга-сулга карап алды, аннары ишегалды аркылы йөгереп үтеп, бакча рәшәткәсенә килеп сөялде дә каршыдагы тауларга карап тора башлады. Шунда ук аның аяклары янына Сарбай килеп ятты һәм, салпы колаклы йөнтәс башын ал аякларына куеп, койрыгын ялкау гына болгарга тотынды. Кыз исә аңа борылып та карамады. Мондый игътибарсызлыктан Сарбайның хәтере калды булса кирәк, ул, төнлә бик сәер елтыраган күзләрен бер ачып, бер йомып, кызга, кунакка кайтканда да безне бар дип санамыйсың, ичмасам, дигән шикелле карый иде.

Ул арада күрше йорт кулэгәсеннән озын буйлы бер кеше килеп чыкты. Ул биредә күптән көтеп торган, күрәсең. Адымнарын шундый әкрен, шундый сак атлый, әйтерсең кош тотарга килүче бер чуар песи. Шулай да эт аны сизеп алды да, һаулап өрә-өрә, каршысына ташланды. Уйга калган кыз, куркып, «Әбәү!» дип әкрен генә кычкырып җибәрде.

Шуның артыннан ук ир кеше:

– Сарбай, юләрләнмә әле! – дип кычкырды.

Эт тавышны таныды булса кирәк, өрүдән туктап, килүченең ялт-йолт итеп торган күн итекләре тирәсендә бөтерелергә тотынды. Егет аны этеп җибәрде дә ягымлы һәм серле тавыш белән кызга дәште:

– Миңнурый!

Кыз, пошынып:

– Кем бу? Сәлим, синме? – дип сорады.

– Мин булмыйча кем булсын, – диде егет, көлеп. Ләкин кызның салкын карашын күргәч, шунда ук көлүдән туктады. – Калтыранасың ич, Миңнурый, әллә Сарбай ләгънәт котыңны алдымы?

Сәлим эткә яңадан сукмакчы булган иде, ләкин акыллы Сарбай, аның холкын яхшы белгәнгә, әкрен генә чинап, читкә китеп өлгерде.

– Син нишләп сукбай шикелле төнлә йөрисең монда? – дип сорады кыз, ярым ачулы тавыш белән.

Сәлим, аның алдына килеп, кул биреп күреште дә рәшәткәгә сөялде. Аның өстендә билен Кавказ каешы белән буган ачык якалы ак күлмәк, галифе чалбар, башында ак эшләпә иде.

– Син кайтканны ишеттем дә, – диде ул бераздан, – әнкәйнең токмачын да көтмичә клубка чаптым. Ә сине анда ай күргән дә кояш алган. Шуннан соң урамнан юри кычкырып җырлап үттем. Мин әйтәм, ишетсә, ни... чыгар әле, чыкмый түзмәс әле.

Сәлим үзенең мәхәббәтен яшерә алмыйча, эчке бер дулкынлану белән сөйли иде. Озак көттергәнгә тавышында үпкәсе дә бар, ләкин үзе кызга моны сиздермәскә тырыша.

– Һи... Синең чыпчык кебек чәрелдәвеңне ишетәләр ди. – Миңнурый, авызын учы белән каплап, әкрен генә көлеп алды. Аның әче теллелеген яхшы белгәнгә күрә, Сәлим бу хурлыклы чагыштыруны ишетмәмешкә салынды.

– Матур кызлар шулай инде алар, – диде ул, аска карап, – ишетсәләр дә ишетмәдем дигән булалар. Галимә апалар озак ятмаганга чыга алмадың. Мин барысын да күреп тордым ич.

– Син әле кеше тәрәзәсенә дә карап йөрисеңмени? Менә апага әйтеп чыбык белән ярдырыйм әле үзеңне.

Егет җитез акыллы, өлгер сүзле кеше түгел иде, ахрысы. Миңнурыйның бу сүзләреннән соң ул, аптырап калып, сүз таба алмый торды. Ул арада Миңнурый шаркылдап көлеп җибәрде:

– Сәлим, иреннәреңне җый, ичмасам, җиргә төшәләр ич!

Миңнурый, кечкенәдән үк үз көнен үзе күреп үскәнгә, ирек сөюче, чая һәм шаян кыз иде. Дуслары арасында уенга дисеңме, җырга дисеңме, һәркайда беренче була. Берәүдән дә тартынып тормый, берәүгә дә баш бирми, әче теле белән теләсә кемне чагып алырга әзер. Егетләр аны үзара «татлы торма» яки «гөләп чәчәге» дип йөртәләр. Бу кушаматларның кайсы тапкыррак икәнен әйтү кыен. Һәр икесе аның холкына гына түгел, тышкы кыяфәтенә дә беркадәр туры килә: тыгыз тәнле кыска буе, очларын бераз тузгытып калдырырга яраткан чем-кара толымнары чыннан да торманы бераз хәтерләтсәләр, түгәрәк алсу

йөзе, шул йөзгә нур сибеп, уйнаклап торган кечкенә кара күзләре ачылып килгән гөләп чәчәген күз алдына китерәләр.

Бу җирләргә күчеп килүдән күп еллар элек, алар әле Шөгер районының Сугышлы авылында торган чагында, Миңнурыйның әти-әнисе үлеп киткән. Миңнурый бик кечкенәдән авыл кулакларында бала карарга, өй эше эшләп йөрергә мәҗбүр булган. Аннары аны Казаннан кайткан кардәш тиешле абыйсы – Гали абзый – үзенә тәрбиягә алган, укыткан, «Красногвардеец»ка күчкәч, Бөгелмәдәге тимер юл училищесына урнаштырган. Хәзер Миңнурый менә шуннан берничә көнгә кунакка кайткан иде.

«Красногвардеец» егетләренең бик күбесе аның тирәсендә бөтерелә. Миңнурый моны үзе дә белә һәм, шуңа күрә булса кирәк, алар белән һәрвакыт бераз мыскыллабрак сөйләшә.

– Шаян син, Миңнурый. Гел кешеләрдән көләсең. Әйтерсең үзеңнең бер дә килешмәгән ягың юк, – диде Сәлим кыюсыз гына.

Миңнурыйга шул җитә калды. Ул аны тагын да катырак үртәргә кереште. Аннары, егетнең күзенә чәчрәп керердәй булып:

– Йә, йә, әйт, нинди килешмәгән ягым бар минем? – дип сорады. – Исән чакта белеп калыйм. Югыйсә, үлеп китсәм, үкенече ни торыр.

Аптырап калган Сәлим, кесәсеннән көмеш тәмәке савыты чыгарып, авызына папирос капты, ләкин ут кабызмады, папиросын кулында бераз бөтергәләгәч, кире савытка салды. Сәлимнең тәмәке тартмавы, әмма кесәсендә һәрвакыт папирос йөртүе, моны күбрәк күзгә төтен җибәрү өчен, ягъни көмеш тәмәке савыты белән мактану өчен эшләве колхоз яшьләренә күптән билгеле иде. Миңнурый да моны белә иде.

– Шырпың юкмы әллә, Сәлим? Безнең өйдә папирос кабыза торган махсус шырпы бар, алып чыгыйммы? – диде Миңнурый.

Кызның үчекләвен Сәлим сизде. Миңнурый шырпы өчен гомердә өйгә керәчәк түгел, ә керсә – яңадан чыгачак түгел.

– Миңнурый... – диде Сәлим, һәм аның тавышы калтыранып китте. – Иплəп сөйләшик әле...

– Әнекәем, без болай да иплəп сөйләшәбез ич.

Миңнурый, кинәт шунда Сәлимне бөтенләй онытып, каядыр еракка карый-карый сагаеп тыңлый башлады.

– Син кемнедер көтеп торасың... – дип пышылдады Сәлим.

Миңнурый җавап бирмәде.

Ерактан, «Алга» колхозы ягындагы таудан, җигүле ат белән төшеп килгән юлчының җыры ишетелде. Башта җыр ерак, әкрен иде. Аннары ул якынрак, ачыграк ишетелә башлады. Җырчы бирелеп, бөтен күңеле, бөтен йөрәге белән җырлый. Аның иркен тавышында көчле моң һәм ашкынулы дәрт яңгырый.

Алъяпкыч мандым көрәнгә,
Көрән матур кергәнгә...

Миңнурый, рәшәткәгә тотынган кулын алмыйча, бер адым алга атлады. Әгәр агачлардан төшкән күләгә капламаса, Сәлим аның түгәрәк йөзенең, кечкенә кара күзләренең эчке нурдан җәүһәр кебек балкып китүен күргән булыр иде. Күләгәдә исә Миңнурыйның йөзе бераз сагышлы һәм моңсу булып күренде.

Төнлә төшләремдә күрәм, Миңнурый,
Көндез уйлап йөргәнгә.

Миңнурый, гүя җырны яхшырак ишетергә теләгәндәй, тагын бер адым алга атлады. Бу – ул, ул, Газинур җырлый! «Нурия» – Газинурның яраткан көе. Ул гына бу җырны шулай киң сулыш белән, бар дөньяга ишеттерергә теләгәндәй кычкырып җырлый. Бүген, җитмәсә, «Нурия»не Миңнурыйга алмаштырган.

Таудан төшеп килгән җырчының кем икәнен Сәлим дә бик яхшы белә иде. «Красногвардеец»та Газинурның җырын ишетмәгән кеше юк. Ул эшкә барганда да, эштә дә, эштән кайтканда да, юл йөргәндә дә, кайгысын-шатлыгын көйгә салып, гел җырлый.

Сәлим ачуланып мышный башлады. Күкрәгендә инде күптән кабынган, бик күп төн йокыларын качырган көнчелек уты яңа бер көч белән дөрләп китте. Ә караңгы таулардан дулкын-дулкын булып агылып килгән иркен җыр һаман дәвам итте. Хәзер ул тагын да көчлерәк һәм дәртлерәк яңгырый иде. Гүя бу җырны тарантас түренә утырган ялгыз юлчы гына түгел, ә караңгыга чумган барлык таулар, йолдызлар, кырлар, болыннар җырлый иде.

Кинәт Сәлим кызның беләгеннән кысып тотты:

– Миңнурый, мин беләм, син шадра Газинурны көтәсең!

Күңеле якты уйлар белән тулган Миңнурый Сәлимнең болай тупас кагылуына ачуланмады. Ниндидер яшерен шатлык, мәкерле шаяру белән:

– Нигә көтмәскә, икәү булгач, кадерем арта төшәр, – диде һәм яшь кызларга гына хас назлы шелтә белән егеткә карап алды: – Югыйсә мине бөтенләй яратмый башла-

дың бит. Кич саен «Тигез басу» кызларына чабасың дип сөйлиләр... Җибәр кулымны, авырттырасың ич, хәсрәт!

Кызның болай бер үк вакытта мыскыллап та, үпкә һәм шелтә белән дә сөйләшүе,ерактагы җырга колак салып та, янындагы Сәлимне, ичмасам, барга да санамавы егетне тәмам шашындырып җибәрде. Ул, йөрәгенә чыдый алмый, кызның иkенче беләгеннән дә эләктереп, аны үзенә таба борды. Миңнурыйның иңбашындагы кыска жакеты җиргә төште.

– Миңнурый, син ике ут белән шаярасың, – диде ул, кызның мәрҗән кебек ялтырап торган кечкенә күзләренә текәлеп карап. – Ә ике ут кара-каршы бәрелгәндә хәтәр була. Син бел моны! – Һәм, тавышын әкренәйтеп, янаган сыман өстәде: – Кара, кызый! Мин шаярмыйм!

Миңнурый көтелмәгән бер җитезлек белән Сәлимнең кулыннан ычкынды да, жакетын иелеп алып, шул ук шаян, мыскыллы, чәнечкеле тавыш белән:

– Бик беләсең килсә, Сәлимҗан абый, мин ике ут белән генә уйнамыйм. Синең кебек хәсрәт утларым минем унлап бар! – диде һәм ачуланып Сәлимгә карады.

Гадәттә Миңнурый алдында каушап кала торган Сәлим бу юлы тиз генә бирелергә теләмәде. Ул, еш-еш сулап:

– Юк, монысын ялганлыйсың, – диде. – Синең күңелең Газинурда гына! – Ул бераз тын торды, аннары батучы кеше кебек саламга тотынырга да әзер булып, яшерен өмет белән сүзен дәвам иттерде: – Белмим, шул шадраның кай җиренә кызыгасыңдыр. Ул бит көтү көтә генә белә. Ә мин курста укыган кеше. Ветфельдшер...

– Харап инде, ат докторы... – диде Миңнурый һәм кычкырып көлеп җибәрде.

## 2

Бүгенге көн Газинурның бөтен тормышында онытылмаслык эз калдырды. Бу көн аның кайнар йөрәгендә кышкы йокыдан уянучы киң кырлар өстеннән шаулап үткән беренче язгы күкрәү кебек дәртле ашкынулар тудырды. Бераз гына кире кайтып булса да, бу турыда тулырак сөйләп бирмичә мөмкин түгел.

Моннан бер-ике атна элек «Красногвардеец»ка аның беренче оештыручысы, беренче председателе – Гали абзый Галиуллин кайтты. Хәзер ул Бөгелмәдә райкомда эшли иде. Кулаклар аны ат койрыгына бәйләп сөйрәтеп йөрткәндә, акларның үлем эшелонында газап чиккәндә һәм Гражданнар сугышы фронтларында йөргәндә какшаган сәламәтлеге соңгы вакытта тагы да начарланып

киткәнгә, иптәшләре Гали абзыйга курортка путевка килеп җиткәнче колхозга кайтып бераз хәл җыярга киңәш иткәннәр.

Гали абзыйның авыруы «Красногвардеец»ны да борчуга салды. Колхозның карты-яше хәл белергә дип аның йортына агылды. Беренче булып, билгеле инде, картлар килде. Гали абзыйның хатыны, ак яулыгын колак артына кысып бәйләгән кара кашлы, күркәм йөзле, тулы гына гәүдәле Галимә апа, аларны ачык йөз белән каршы алып, ак өйгә, Гали абзый янына кертә торды. Өстәлдә самовар шаулый иде. Кунакларны табынга кыстады. Таякка таянган ап-ак сакаллы Галәк бабай:

– Рәхмәт, Галимә килен, рәхмәт, – диде әкрен генә, – без чәй эчәргә дип килмәдек әле. Чәй бездән качмас. Чәйне без аны күп эчтек, тагын да күбрәк эчәселәребез бар. Менә Әхмәтгалинең хәлен белешеп чыгыйк дидек. Куркытты бит. Авыру, кем, Галимә килен, килә потлап, китә мыскаллап. Әйе. Ничек соң, Әхмәтгали энем, – Галәк бабай ак мендәргә терәлеп утырган Гали абзыйга таба борылды, – кәеф начарланып киттемени? Махы бирдеңмени?

Гали абзыйның болай да чандыр йөзе тагын да ябыккан, кылыч борыны да югары төшкән кебек, әмма ягымлы соры күзләре әүвәлгечә күңелле һәм өметле карыйлар. Гали абзый үзе дә сыкранып түгел, елмаеп сөйләшә:

– Юк әле, Галәк бабай, алай тиз генә махы бирергә исәп юк, – диде ул, тирләгән башын сөлге белән сыпырасыпыра.

– Шулай кирәк, Әхмәтгали энем, шулай кирәк! – Берьюлы җанланып киткән Галәк бабай Галимә апа китереп биргән урындыкка утырды да киез эшләпәсен салып тезләренә куйды. – Бирешергә ярамый. Өметсез бер шайтан. Авыру кешенең күңеле нык булырга тиеш. Безнең мәрхүм әткәйләр әйтә торган иде: күңеле нык кешедән чир үзе качар, күңеле йомшак кешегә юк чир дә тагылыр. Аннары, көннәр дә бик әйбәт тора әле. Колхозыбызның һавасы бик шифалы, күр дә тор, килешеп китәр үзеңә. Менә Галәк бабай әйтте диярсең.

Бабайның сүзе чыннан да дөрескә чыкты. Ике-өч көн үтүгә, колхозчылар Гали абзыйны урамда, абзарлар тирәсендә, правление утырышында күрделәр. Колхоз председателе Хәнәфи, өзлекмәгәе дип борчылып, кайтарып җибәрмәкче иде дә, Гали абзый тыңламады. «Эшсез ятсам, авыруым гына көчәя», – дип шаяртты.

Бөгелмәдән аның янына кешеләр килеп китә иде. Беркөнне, ерак колхозларга барышлый, райком секретаре да кагылды.

– Тыныч кына ял ит, Гали Галиевич, – диде ул, саубуллашкан чакта. – Борчымаска тырышырбыз.

Ләкин кичә райкомнан махсус кеше килеп Гали абзыйны бюрога чакырып китте.

Иртән Гали абзыйның рәшәткәле йорты каршына җигүле ат килеп туктады. Шул вакыт баскычта башына күк фуражка, өстенә шундый ук күк төстәге гимнастерка кигән, билен киң каеш белән кысып буган, беләгенә юл плащы салган Гали абзый үзе дә күренде.

Ыргылып чабып китәргә әзер торган ак бәкәлле, озын торыклы ярсу кара айгырның дилбегәсен нык итеп тоткан килеш кучерда утырган егеткә Гали абзый, баскычтан төшә-төшә, игътибарлы караш ташлады. Егетнең өстендә кояшта уңа төшкән бишмәт, башында җилкә чокырына ук этелгән кепка. Үзе киң җилкәле, уртачарак буйлы. Менә ул Гали абзыйга таба борылды. Бите озынча, чак кына шадрасы бар. Сызылып киткән кара кашлары, зур кара күзләре аның йөзен тагын да ягымлырак итәләр. Егеткә күп дигәндә егерме-егерме бер яшь бирергә мөмкин.

– Саумы, Газинур, – диде Гали абзый һәм тарантаска менеп утырды.

Көчен кая куярга белмичә бер урында биеп торган кара айгыр, Газинурның ирен чупылдатуын ишеткәч, элдереп алып та китте.

Кояш әле яңа гына күтәрелеп килә иде. Күк йөзе юып алган кебек чип-чиста. Яфрак селкетерлек тә җил юк. Көн бүген дә бөркү булачак. Бөркү һава үзен аеруча йончытканга, Гали абзый юлга шулай иртәрәк чыгарга тырышты.

«Красногвардеец»ның бик күп сандагы терлек абзарлары янынанан үтеп, тауга күтәрелгәч тә, Гали абзый Газинурга кузладан үз янына күчеп утырырга кушты, аның кулыннан дилбегәне алды.

– Кунак абзый булып йөрергә яратмыйм, – диде ул, көлемсерәп.

Газинур чаптарның бик хәтәр айгыр икәнен, юлда берәр нәрсәдән өрексә, дулый торган гадәте барлыгын сөйләп китте. Гали абзый яңадан көлемсерәп куйды:

– Курыкма, Газинур, минем ат тотканым бар.

Гали абзыйның йөзе тыныч иде. Газинур аңа «ихтыярың, Гали абзый» дигән шикелле күз кырые белән карап алды да күчеп утырды.

Чаптар чыннан да теләсә кемгә баш бирә торган ат түгел икән. Симез янтавына дилбегә тигәч тә, ул, муенын дугаландырып, авызлыкны тешләде, колакларын шәм кебек торгызды. «Кем минем дилбегәмне тота?» дип ба-

шын борып артка караганда, шәмәхә төсендәге күзе ялтырап китте.

– Ыграк тотыгыз, Гали абзый. Дилбегә йомшартканны яратмый ул, – диде Газинур.

Аның шулай дип әйтүе булды, ат бөтен көче белән ыргылып чабып та китте. Газинурның битенә тыгыз, салкынча җил бәрелде. Тарантас юл сикәлтәләрендә дөбердәп бии башлады. Гали абзыйның авырудан бераз саргая төшкән ябык йөзенә кызыллык йөгерде, йомшак соры күзләре чак кына каралгандай булды. Күрәсең, шулай җилеп бару аңа рәхәт иде. Ул атны кызулаткannan-кызулатты һәм бары тик шлея каешлары астында ак күбекләр күренә башлагач кына юыртудан туктатты. Чаптар, башын чайкап, атлап кына бара башлады.

– Эх, Газинур, бер уйласаң, күпме гомер үткән, күпме сулар аккан, ә баштан узганнар онытылмый. Украина далаларында дүртәр ат җигелгән тачанкаларда ак полякларны куып йөргәннәребез әле булса хәтеремдә. Кайчакта бер төн эчендә утыз-кырык чакрым китәбез дә, таң алдыннан, йокының иң каты вакытында, пилсудчиклар лагерена бәреп керәбез, пран-заран китерәбез, аннары син күр дә мин күр!.. Безнең взводта бигрәк тә Ваня исемле бер пулеметчы дан тота иде. Егет кеше – арысланга тиң кеше дип әйтәләрме? Нәкъ үзе! Йөрәге шундый кызу – эрегән кургашынмыни! Пулеметтан ата башласа, дошманнарны яндыра гына!.. Берсе-бер якын килә алмый... Ә үзе, Ваня, йөри дә алмый иде. Герман сугышында ике аягын да өздергән. Безгә төнлә килде. Бер украин шәһәрен сугышып алып, ялга туктаган идек. «Хезмәт халкына хезмәт итәргә телим, чөнки үзем дә хезмәт халкы улы мин. Тачанкага утыртыгыз», – диде. Мин аны үз отделениемә алдым. Алуына соңыннан үкенмәдем. Бөтен Украинаны диярлек бергә сугышып үттек. Мин каты яралангач кына аерылыштык...

Гали абзыйның сүзләрен җаны-тәне белән тыңлап барган Газинур күкселләнеп торган үзәннәрдән, урман буйларыннан зур кара күзләрен алды. Нәкъ менә шушы минутта аннан тачанкалы атлар ыргылып чыгар күк тоела иде.

Кинәт юл борылышында чыннан да нәрсәдер күренде. Ләкин бу тачанка түгел иде. Юл буйлап өсте ачык автомобиль җилеп килә. Кояш нурында аның фаралары, кабина пыяласы ялтырый. Кабина баскычына күк комбинезонлы, яланбаш бер егет аягүрә баскан. Егетнең гадәттәгечә утырып килмәве, аксыл чәченең җилдә тузгуы һәм, кулын сузып, кочаклап алырга теләгәндәй каядыр киң

кырларга таба күрсәтүе Гали абзый хикәясеннән соң тәэсирләнгән Газинурда чиксез соклану тудырды. «Бу егет тачанкада булса да сынатмас иде», – дип уйлап алды ул.

Ат өркеп читкә тайпылды, ләкин Гали абзый дилбегәне нык тоткан иде. Автомобиль, алар турысына җиткәч, шып туктады.

– Хәерле иртә, Гали абзый! – дип кычкырды баскычта аягүрә торган егет. Бу бөтен районга атаклы тракторчы Исхак Зәбиров иде.

Өркүеннән калтыранып торган атны көч-хәл белән тыеп торган Гали абзый:

– Кая киттегез болай? – дип сорады.

– «Тигез басу»га барабыз, Гали абзый. Безнең тракторлар анда эшли.

– Ярар, исән булыгыз алайса. Егетләргә сәлам.

– Рәхмәт, әйтермен.

Машина китеп барды. Исхак һаман да аягүрә баскан килеш бара иде.

– Менә Исхак та ут егет, – диде Гали абзый, дилбегәне кагып. – Сиңа да, Газинур, трактор йөртергә өйрәнергә кирәк. Тиздән колхозның төп эшчесе тракторчы булачак. Аннары сугыш була калса да... Бу юлы инде, туганкай, теге вакыттагы кебек тачанкаларда сугышып йөрмәсләр. Танкларда сугышырлар. Ә бүгенге тракторчы иртәгә танкист дигән сүз...

Газинур җавап бирмәде. Аңамы соң тракторчы булырга! Трактор артыннан сабан тотып йөрсә дә ярар иде әле.

Гали абзый яңадан атны юырта башлады. Юл урман эченнән сузыла иде. Коры елгага төштеләр, үргә күтәрелделәр. Юл чатындагы куш нарат башында чуар саескан күренеп калды. Каен яфраклары арасыннан күзгә күренми торган кошларның чыр-чулары ишетелде.

– Эх, безнең урманнарның һавасы! – диде Гали абзый.

Әллә кызу барганга, әллә Гали абзыйның сүзләре бик кызык булганга, Бөгелмә юлы бик кыска тоелды. Кай арада «Алга» колхозын үтеп киттеләр дә кай арада «Красная горка» артта калды. Алда, аксыл рәшә эчендә, Бөгелмәнең биек таш йортлары, элеваторы, тегермән биналары, завод трубалары күренде.

Бөгелмә – СССРның Европа өлешендә иң биек урында урнашкан шәһәрләрнең берсе. Моннан ике йөз еллар элек ул дала уртасында адашып калган кечкенә бер авыл булган. Аны дөньяның кырые дип йөрткәннәр, Бөгелмәдән ары юл юк дип исәпләгәннәр. Патшага, алпавытларга каршы күтәрелгән кешеләр бирегә сөргенгә җибәрелгән. Бөгелмәгә Ялачич, Шкапский дигән алпавытлар, миллио-

нер Хәкимовлар хуҗа булган. Бөгелмәнең барлык халкы, тирә-як авыллар – барысы да аларга эшләгән. Заводлар, тегермәннәр, трактирлар, кибетләр аларныкы булган. Фәхешханәләрне дә алар тоткан...

Гали абзый дилбегәне Газинурга бирде һәм атлатып кына барырга кушты. Олы юлда машиналар, атлылар бертуктаусыз йөреп торганга, күз ачкысыз тузан иде.

Баулы юлы буендагы «Ундүрт батыр» мәйданына якынлашкач, аларга рәшәткә белән уратып алынган кеч-кенә генә һәйкәл яныннан чыгып килгән мәктәп балалары очрады. Баш киемен салган уйчан йөзле карт укытучыны чолгап алган балалар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, аңа ниндидер сораулар яудыралар.

– Нәрсә турында шулкадәр чәбәләнешеп сорашалар икән бу чебиләр? – диде Газинур.

Ул бу сорауны болай гына биргән иде кебек, әмма Гали абзый аның үтә кызыксынуын күрде. Ул сәгатенә карап алды. Бюро башланырга шактый вакыт бар әле. «Балаларга бу һәйкәлнең тарихы турында укытучылары сөйли, ә сиңа кем сөйләр?» – дип уйлап алды ул. «Син бу олы юлдан йөз генә тапкыр үткәнсеңдер, әмма юлың өстендә нинди изге урын бар икәнен бер тапкыр да уйлаганың юктыр, күрәм».

Гали абзый укытучы белән исәнләште дә Газинурга атны туктатырга кушты. Аннары алар, тарантастан төшеп, рәшәткә эченә керделәр. Башына калайдан эшләнгән урак-чүкеч һәм Кызыл байрак куелган таш постаментка бик озак карап тордылар. Гали абзыйның ябык йөзе уйчан, күзләре моңлы иде.

Кинәт ул башын күтәрде. Газинур аның әзрәк кысыла төшеп каядыр еракка караган күзләрендә тимерче миченДә дулап янган ялкынны хәтерләткән бер нәрсә күреп алды.

– Бу каберләрдә яткан кешеләр турында, Газинур, тыныч кына сөйләп булмый. Җанлы булып басып торалар алар минем күз алдымда – революциянең батыр солдатлары.

Газинур Гали абыйның тамагы буылып китүен сизде: гүя аңа һава җитми иде.

Ил картлары вакыт иң авыр кайгыны да оныттыра, иң каты газаплардан да әрнүсез истәлекләр генә кала дип сөйлиләр. Ләкин бу юлы хөрмәтле картлар, күрәсең, ялгышканнар. Күрәсең, вакыт Гали абзыйны сугышчан дусларын онытырга мәҗбүр итә алмаган.

– Әйе, шулай, Газинур, – диде Гали абзый, ниһаять. – Һәр җирдәге кебек, Бөгелмәдә дә совет властен төзү һәм урнаштыру көрәшсез генә булмады. Эчке дошманнарга

каршы да, чит ил интервентларына каршы да сугышырга туры килде. Англия-Америка империалистлары оештырган чех офицерлары фетнәсе, Колчак ак бандалары Бөгелмәне ике тапкыр канга батырдылар. Алар котыртуы буенча кулак баш күтәрде. Менә болар, – Гали абзый яшел үлән үскән каберләргә күрсәтте, – менә болар барысы да аларның канлы кулларыннан үткән корбаннар.

Бераздан алар шәһәр бакчасындагы икенче һәйкәл каршына килеп туктадылар. Бер ягына кызыл йолдыз, икенче ягына якорь төшерелгән бу зур соры таш астында Бөгелмә ревкомының членнары Петровская белән Просвиркин иптәшләрнең һәм билгесез матросның гәүдәләре ята.

– Газинур, – диде Гали абзый, егетнең иңбашына кулын салып, – мин Петровская белән Просвиркин иптәшләрне яхшы беләидем. Алар җитәкчелегендә эшләдем. Чын кешеләр иде, халык өчен җаннарын кызганмадылар. Башкача ярамый да иде, Газинур, куян йөрәкле кешеләр беркайчан да җиңмиләр. Революция көрәшчесенә тау бөркете йөрәге кирәк... Матросны да һич онытасым юк. Ул Бөгелмәгә иң кыен чакта килде. Бөгелмәне камап алган дошманнар боҗрасыннан ничек үткәндер, анысын белмим. Без соңгы сугышка әзерләнгәндә, ул ревком бүлмәсенә пулемет сөйрәп керде. Яшь, матур, таза егет. Билендә гранаталар, иңбашлары аркылы патронташлар аскан, башында бескозырка. «Мин Лениннан килдем, – диде ул, елмаеп. – Совет властен яклап вахтага басарга рөхсәт итегез». Һәм тәрәзә янына пулеметын урнаштыра башлады. Урамда атышлар якынлаша иде. Ләкин алар бу бәрелештә түгел, Ютазы белән Туймазы арасындагы кечкенә бер разъездда икенче бер бәрелештә һәлак булдылар, Газинур. Аларны дошманнар сырып алалар. Актыккы патронга, актыккы гранатага кадәр сугышалар алар. Куркуның ни икәнен белмәгән батыр коммунистка Петровская, аннары Просвиркин һәлак булалар. Матрос канга батып егылган иптәшенең кулыннан мылтыкны тартып ала да дошманнарга штык белән ташлана. Яраланып, хәлсезләнеп егылгач кына дошманнар аның янына килә алалар...

Газинур шаккатып тыңлады. Бу минутта аңа алар барысы да – Просвиркин да, Петровская да, билгесез матрос та һәм исемнәре әйтелмәгән башка геройлар да әтисе белән әнисе кебек бик якын, кадерле кешеләр булып тоелды. Гали абзый исә тагын да якынрак, кадерлерәк булып китте. Хәзер Газинур аның йөзендә Гражданнар сугышының җанлы героен күрә иде.

Гали абзый берничә минут эндәшми торды да:

– Әгәр дә сиңа кайчан да булса кулыңа корал тотып Туган илне сакларга туры килсә, син бу кешеләр турында да онытма, Газинур! – дип өстәде.

– Онытмам, Гали абзый, – диде Газинур.

Һәйкәл төбендә борынгы авыр туп көпшәсе ята иде. Бу – Пугачев тубының көпшәсе. Моннан күп еллар элек алпавытларның коточкыч изүенә һәм тормышның чиксез авырлыгына түзә алмыйча баш күтәргән крепостной крестьяннарның юлбашчысы Пугачев күпмедер вакыт Бөгелмә тавында лагерь корып торган. Ядрә белән ата торган бу чуен тупның көпшәсе әнә шул заманнардан калган.

– Халык үзенең азатлыгы өчен, Газинур, – диде Гали абзый, һәйкәл тирәсендәге урындыкларның берсенә утырып, – гомер-гомергә көрәшеп килгән. Кешелекнең бөтен тарихы, Газинур, азатлык өчен көрәш тарихы ул. Моны да онытма.

Кич белән берүзе «Красногвардеец»ка кайткан чагында да Газинур гел шул турыда гына уйлады. Моңарчы аның Бөгелмәдә әллә ничә тапкыр булганы бар иде, әмма шушылай дулкынланып кайтканы һичкайчан юк иде. Күңел кичерешләрен җырга салырга яратканлыктан, ул юл буе диярлек халык бәхете өчен үлемнән дә курыкмаган батырлар турында җырлап кайтты. Кайчак Газинур үз тавышына үзе дә гаҗәпләнде: борынгы моңлы озын көйләр бу юлы ничектер дәртле, якты булып яңгырадылар. Күрәсең, җыр булып җыр да егет йөрәге аркылы үткәч яшәрә икән!

«Алга» тавыннан төшкәндә, Газинур үзенең гөләп чәчәге – Миңнурые турында җырлый башлады. Әллә югыйсә үзе дә бирeдәме? Шәһәрдә Газинур аларның өйләренә ике тапкыр кагылды, ләкин ишекләре бикле иде.

Конный дворда Газинур, ат караучы Сабир бабай белән уен-көлке катыштырып сөйләшә-сөйләшә, атын туарды. Туарып бетергәч, атны тезгеннән тотып, бер читкә алып барды һәм әкрен генә сызгырырга тотынды. Ат җирне иснәп бер әйләнде дә ятып ауный башлады. Аунап туйгач, торып селкенде. Газинур бияләе белән аның өстен яхшылап сыпырды, абзарга кертеп, печән бирде. Ат яныннан чыгып китәр алдыннан тагын берничә тапкыр аның муеныннан сыйпап алды.

– Тыныч төн, татлы йокы, Чаптар дускай!

Сабир бабай тарантасны лапас астына кертеп маташа иде. Газинур, йөгереп килеп, аңа булышырга тотынды.

Тарантасны лапаска кертеп куйгач, Сабир бабай белән Газинур келәт бусагасына утырдылар.

Сабир бабай яше җитмешкә якынлашып килгән, түгәрәк ак сакаллы, тәбәнәгрәк буйлы бер карт иде. Җәй булуга карамастан, башына малахай бүрек, өстенә тун кигән – карт сөяк җылы ярата бит. Заманында солдат хезмәтен дә күргән, эш эзләп, киң Россиянең буен буйлаган, иңен иңләгән бу карт бик күп хикмәтләр белә иде. Гадәттә, Газинур аңардан «Сабир бабай, Карпат тауларында булган чакларыңны тагын бер сөйләп җибәр әле» яки «Сабир бабай, эшчеләргә атудан баш тартуыгыз турында сөйләп бир әле» дип сорый торган иде. Һәм, калынрак иреннәрен чак кына ачып, кар түбәле Карпат таулары турындагы тылсымлы солдат хикәясен яки баш күтәргән эшчеләрне аттырыр өчен китерелгән, ләкин үзләренең туганнарына атудан баш тарткан «мятежный полк» солдатлары әңгәмәсен төннәр буе бирелеп тыңлый иде.

– Сабир бабаңның башыннан күп хәлләр үтте шул, улым. Россиядә аның йөрмәгән җире, эчмәгән суы калмагандыр, – дип, карт сүзен бетергәч, алар байтак вакыт һәр икесе үз уйларына чумып тын гына утыралар һәм тәмәке көйрәтәләр иде.

Ләкин бүген сүз Сабир бабайның башыннан үткән хәлләр турында бармады.

– Йә, Газинур, Бөгелмә юлы күңелле булдымы? Әхмәтгалине исән-сау алып бардыңмы? – дип сорады карт.

– Бик әйбәт алып бардым, Сабир бабай, автомобильгә утыртып илткән шикелле. Юл да бик күңелле булды. – Газинур елмайды һәм сокланып кычкырып җибәрде: – Гали абзый белән күңелсез буламы соң! Алтын кеше бит ул, Сабир бабай!

– Әйе, бик дөрес. Әхмәтгали – зур кеше ул. Илгә дә, колхозга да файдасы күп тиде. Безнең колхозны оештыручы кеше дә, аңа исем табып бирүче дә ул булды.

– Менә мин дә шуны әйтмәкче булам әле, Сабир бабай. Зур кеше ул. Бик зур! Мин Гали абзыйның эчентышын беләм дип йөри идем. Кая ул!

Газинур яңадан, дулкынланып китеп, Гали абзыйның тачанкада йөрүләре турында, аяксыз пулеметчы турында, Лениннан килгән матрос турында сөйли башлады.

Сабир бабай Газинурга сиздерми генә аңа карап үз алдына көлемсерәп куйды, һәй, бу яшь йөрәк дигәнең! Синениләр генә җилкендерми.

– Менә бит, Сабир бабай, нинди әйбәт кешеләр бар дөньяда! – диде Газинур сокланып та, гаҗәпләнеп тә: – Уйласаң, исең китәр.

– Әйе шул, безнең Россия халкы арасында кемнәр генә юк.

Шуннан соң икесе дә бераз сүз кушмый тордылар. Һавада, нечкә һәм якты эзләр калдырып, утлы бөҗәкләр очты. Май коңгызлары пырылдады. Күктә йолдызлар атылды.

– Сабир бабай, син Хәкимовларны беләидеңме? – дип кинәт сорап куйды Газинур.

– Кайсы Хәкимовларны? Бөгелмә миллионерларын әйтәсеңме? Бик яхшы беләм. Балаларыма да аларның әшәкелеген онытмаска әйтеп калдырырмын...

Карт, кәкрәеп беткән бармаклары белән кемнеңдер бугазыннан кысарга теләгәндәй, кулын күтәрде. Әгәр караңгы булмаса, Газинур картның йөзенә нинди тирән газап чыкканын бик ачык күрер иде.

– Шул үрмәкүчләр инде безнең канны суырдылар, – диде карт, әкрен, газаплы тавыш белән. – Рус, чуваш, мари, татар батраклары – барыбыз да аңа бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләдек. Бөтен Бөгелмә алар кулында иде. Нәрсә теләсәләр, шуны эшләделәр, кылмаган явызлыклары калмады. Аларга закон да, суд та юк иде. Городской глава белән пар атларда, файтуннар җиктереп, кеше таптатып йөрделәр. Күренүләре була, «шапки долой!» дип кычкыралар. Хәкимов главаның помушнигы санала иде. Ялачич бояры белән Шкапский бояры – аның дуслары. Бөтен тирә-як авылларның җирләрен тартып алганнар иде, кабахәтләр. Крестьяннар аларга бөтен семьялары белән эшләде. Синең әтиең дә Шкапский боярының көтүләрен көткән кеше. Ул чакта син тумаган идең әле...

– Ялачич боярының 14 мең десятина җире булган, ә халык җирсез тилмергән, ачтан кырылган! – диде Газинур ачу белән.

– Бөгелмәдә аның аракы заводлары гына да әллә ничә иде... Ул чакта Бөгелмәдә атлаган саен трактир да аракы кибете – «монопулька». Тфү! Мулла белән побы гына җитмәгән, аракы чүмертеп тә халыкның миен черетteләр... Эх!.. – Карт кулын селтәп алды. – Ул заманнарны искә төшерсәң, күңел генә әрни. Өй тулы бала-чага, ашарга юк, кияргә юк, ягарга юк. Башыңны кашып ала идең дә хәйран калып карап тора идең дөньясына: «Нихәл бу? Кайда хаклык? Кайда якты юл? Кыр тутырып иген үстерәсең, урман тутырып утын кисәсең, ә тамагың ач, өең салкын...» Ярар, Газинур улым. Сүз артыннан сүз чыга. Әзрәк черем итеп алырга да кирәк. Югыйсә әнә яктыра да башлады бит.

– Хәзер миңа йокламасам да ярый, Сабир бабай. Валлаһи, күңелем нурланган кебек. Иртәгә Хәнәфи абыйны күреп рәхмәт әйтәм әле.

Ул, абзарга кереп, атларга печән өстәп чыкты да кычкырып җырлый-җырлый кайтып китте. Коры чокыр аркылы салынган күпердән узган чагында, клуб янында кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышларын ишетте. Тәмәке утлары җемелдәде. Газинур шунда таба китте. Гали абзыйлар турысына җиткәч, Сарбайлары өреп җибәрде. Читән буенда нindидер ак күлмәкле хатын-кыз шәүләсе күренде. «Миңнурый кайтканмы әллә?» – дип уйлады Газинур.

Күз ачып йомганчы киң урамны аркылы чыгып, бакча буена килде:

– Миңнурый... – диде ул, ашкынып. – Син биредәмени, Миңнурый? Ә мин сине Бөгелмәдә эзлим. Бераз гына көткән булсаң, тарантас түренә утыртып алып кайта идем бит үзеңне.

Газинур сөялләнеп беткән киң учы белән кызның кеч-кенә кулын кысты.

– Әбәү, Газинур... – дип кычкырып җибәрде Миңнурый. – Тиле, шулай кысалармыни?

– Яратып кына, Миңнурый, ачуланма, – диде Газинур һәм нурланып торган зур кара күзләре белән Миңнурыйга текәлде.

Кыз аяк очларына кадәр кызаруын сизде, серен яшерер өчен, авырткан кулын назланып селкә-селкә, аска карады, аннары башын күтәрде, елмайды, яңадан башын түбән иде. Менә шушы бик кыска вакыт эчендә Газинур аның җанын күргәндәй булды: Миңнурый сөя дә, сөелүен дә тели. Миңнурыйның серле абага чәчәге төсле ачылып киткән минутлары бик сирәк һәм кыска була, әмма шундый минутларда гына аның күңелендәге чын тойгыны сизәргә мөмкин, чөнки икенче секундта ул инде, йомарланган керпе сыман, чәнечкегә әверелә. Менә ул уң кашын сикертеп куйды, иреннәрен кысты, әле күптән түгел генә Сәлим белән сөйләшкәндәге кебек мыскыллы тавыш белән сөйләшә башлады:

– Минем кайтуыма бишбылтыр инде, – диде ул коры гына. – Тик син генә кайтып җитә алмыйсың. Конный двор белән безнең йорт арасы, ахрысы, Бөгелмәдән дә ераграк.

– Сабир бабай белән сөйләшеп утырдык, – диде Газинур, акланырга теләмичә.

– Атлар турындадыр әле, – диде Миңнурый, күз кырые белән генә карап.

Газинур көлемсерәде.

– Юк, Миңнурый, кешеләр турында.

Газинурның клубта булмавына һәм кайткач та бик озак көттерүенә ачуланган Миңнурый хәзер егеттән шуның үчен ала иде. Газинурның һәр сүзенә юри аркылы төшә.

– Менә иске авыздан яңа сүз, – диде ул. – Кешеләр турында гайбәт сатмыйча, нәрсә сөйләшәсең? Аның ни кызыгы бар?

Газинур аяклары янына килеп иркәләнә башлаган Сарбайның колак артларын кытыклап алды да көлеп җавап бирде:

– Гайбәт сатып утырырга мин Мөкәррәмә апа йә Сабир бабай Зәйтүнә кодачасы түгел. Ә кешеләр турында сөйләшүнең кызыгы бар, Миңнурый.

Миңнурый, Газинурның күзләре ялтыравыннан сөйләшүнең чыннан да гайбәт булмавын бик ачык күрсә дә, һаман да әле үзенең чәнечкеләрен яшерми иде.

– Миңнурый, – диде Газинур, аның кулыннан тотып. – Менә син Бөгелмәдә торасың. Әйт әле, ул нинди урын?

Миңнурый ихтыярсыздан көлеп җибәрде.

– Таулы-чокырлы бер урын. Җәй булса, тузан, күз ачып булмый, көз җитсә, пычрагын ерып үтәр хәл юк.

– Белмәдең, белмәдең! – диде Газинур. – Бөгелмә ул... Бөгелмә ул... иң биек урын!

Миңнурый тыела алмыйча көлә башлады.

– И абзый, абзый... нигә тузга язмаганны сөйлисең. Мин Бөгелмәдә ничә ел торып та аның иң биек урын икәнен күрмәдем, ә син...

Газинур, Гали абзый сүзләрен буташтыруын сизеп, бераз уңайсызланса да, сер бирергә теләмәде.

– Көлмә, мәктәпкә кергәч, тузга язганны да сөйләрбез әле, – диде ул һәм, бераз уйланып торгач, ышаныч белән әйтте: – Укырга җибәрсеннәр дип сорыйм әле.

– Карап торам-торам да, Газинур, син Бөгелмәдән Хуҗа булып кайткансың.

Миңнурый тагын көлә башлады. Аның көлүе сүзләре кебек чәнечкеле түгел, ул җанны эретердәй ягымлы көлә, һәм аның шулай көлүе бу чәнечкеле кабык эчендә бик йомшак күңелле икенче бер Миңнурый барлыгын ачык әйтә иде. Газинур да аңа кушылып көлә башлады.

– Бер дага таптың, тагын өч дага белән ат кына табасың калды. Аннары атка утырып йөри башлыйсың дип әйтмәкче буласыңмы, Миңнурый?

– Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә, диләр ич, Газинур.

– Сандугачым! – диде Газинур, кызны кинәт кочагына тартып. – Хуҗа бик тапкыр булган, әмма безнең за-

манда яшәгән булса, ул да башкачарак сөйләр иде. Син миңа ышанмыйсыңмы, Миңнурый? – Газинур кызның күзләренә карарга теләде, ләкин Миңнурый озын керфекләрен түбән төшерде. – Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул, шулаймы? Ләкин мин бит карт түгел әле. Аю да биергә өйрәнә...

– Синең биергә өйрәнәсең юк инде. Биегән саен олтанның төшеп кала.

– Биергә өйрәнмәсәм, башка күп нәрсәгә өйрәнәсе бар. Өйрәнермен дә!

Миңнурый Газинурның күкрәгенә башын куйды һәм, иркәләнеп:

– Газинур, син, ичмасам, мине шул Сәлимнән аралар идең. Югыйсә теңкәмә тиеп бетте бит, тигәнәк кебек ябыша, – диде.

– Сәлим?! Аңа ни калган?

Миңнурый, күңеле кинәт нечкәреп китүдән оялыпмы, әллә кызлык горурлыгыннанмы, әллә Газинурның шушылай ярсып кычкыруыннан канәгатьләнепме, яңадан үзенең чәнечкеләрен өскә чыгарды.

– Күрәсең, – диде ул, көлеп, – синнән башка да күңел юатучыларым бар минем... Икенче тапкыр иртәрәк килергә тырыш, югыйсә бөтенләй соңга калуың мөмкин.

Шул сүзләрне әйтте дә, Газинурның кочагыннан, күгәрчен кебек очып, йөгереп китеп тә барды. Баскычта ул туктады, хуш, хуш дигәндәй, кулын болгады һәм ялт итеп өйгә кереп китте.

Газинур, аның артыннан елмаеп карап, башын чайкады.

– Һай, минем чәнечкеле гөләп чәчәгем! – диде ул һәм тын авыл буйлап җырлап китте. Бу вакытта ферма фонаре да сүнгән иде инде.

## 3

Чормасына төрле дару үләннәре: бәйләм-бәйләм ак әрем, юкә чәчәге, үги ана яфрагы, мәтрүшкә, ак чәчәк, яшь кычыткан һәм сирень чәчәкләре кибәргә элеп куелган, шунда ук аркылы колгага каен себеркеләре парлап-парлап асылган бәләкәй генә өйалдында Газинур, юка юрганга төренеп, йокларга ятты. Ятканга байтак вакыт үтте инде, ләкин һаман да күзенә йокы керми. Борынына юкә, сирень чәчәкләренең хуш исе белән бергә ак әремнең әче исе килеп бәрелә, аннары мәтрүшкә исе көчәеп киткәндәй була. Һәм болар барысы бергә Газинурга колхоз болыннарын хәтерләтә. Кайда булса, урман буендагы

яки умарталыктагы болында, печән богылы өстендә ятканда, нәкъ менә шундый күптөрле исләр, бергә кушылып, аның борынын кытыклый иде. Ә болын исенә төштеме, Газинур ак тырмаларын уйнатып печән җыючы чуар киемле колхоз кызларын, алар арасында үзенең гөләп чәчәге – Миңнурыен күз алдына китерә. Аның иреннәре үзеннән-үзе елмая, күңеле яктырып, нурланып киткәндәй була. Бүген дә, урынына килеп ятканнан соң, Газинур нәкъ менә шундый якты хисләр кичерде. Алай гына да түгел, бүген аның хисләре аеруча матур иде, чөнки ул әле яңа гына Миңнурый белән сөйләште, кулларында Миңнурый кулларының җылысы бетмәгән, колакларында аның шелтәле дә, үпкәле, дә, назлы да тавышы яңгырый. Тышта яктырганнан-яктыра бара, ә ул үзенең яңа кичерешләре турында һаман уйлый да уйлый. Әле өермәдәй очып баручы тачанкага утырган аяксыз пулеметчы, әле Лениннан килгән матрос күренгәндәй була. Газинур аның нык кысылган калын иреннәрен, пулемет гашеткаларына бөтен көч белән ябышкан бармакларын ап-ачык күрә. Ул да булмый, кулына дүрт атның дилбегәсен тоткан Гали абзый сызгырып җибәрә, имеш. Тачанкага җигелгән акбүз атлар очсыз-кырыйсыз киң дала буйлап чабалар. Ялларын җил тузгыта, авызларыннан канлы күбекләр оча. Алар артыннан, кылыч уйнатып, дошманнар куып килә. Аяксыз пулеметчы аларны якын җибәрми – кистерә генә! Ул да булмый, ефәк тасмаларын җил тузгыткан матрос, кулына граната тотып, алга чыга һәм дошманнарны кыра башлый...

Төрек, япон, герман сугышларында булып кайткан карт солдатлардан Газинур: «Яраланып сугыштан чыга алсаң, үзеңне бәхетле кеше итеп сана, үлемнән котылдың дип исәплә», – дигән сүзләрне күп тапкыр ишеткәне бар иде. Моны сугыштан котлары очкан, үлемнән курыккан кешеләр сөйләмәде. Батыр йөрәкле ирләр сүзе бу. Тормышны җаны-тәне белән яраткан Газинур моңарчы үзе дә үлемнән котылган кешеләрне бәхетле дип саный иде. Әмма Гали абзыйның чын батырлар турындагы сүзләрен тыңлагач, ул бик тирән уйга калды. Үлемнән котылу гына бәхет түгел икән әле. Тачанкадагы пулеметчы ике аягы өзелгәннән соң да сугыштан китмәгән бит. Ни өчен китмәгән? Бик сугышчы кеше булганмы әллә? Яки үчен алу өчен шулай сугышканмы? Ни өчен матрос актык сулышын алганда да дошманнан мәрхәмәт сорамаган? Иелгән башны кылыч кисми бит.

Бәхет һәм үлем. Бер-берсенә капма-каршы булган бу ике нәрсәнең янәшә торуын ул төшенеп бетә алмый иде әле.

Газинур үзен матрос урынына куеп карый. Аның кебек була алыр идеме ул? Юк, була алмас иде. Ул матросны Ленин җибәргән бит. Ул йә коммунист, йә комсомолец булгандыр. Ә Газинур – гади бер көтүче. Каян килсен аңарга ул кадәр зур батырлык?

Газинурның бала чагы авыр елларга туры килде. Ул туганда, аның әтисе Гафиятулла абзый патша солдаты була. Алар бара торган эшелон Кавказ тауларында крушениегә очрый, һәм Гафиятулла абзый тәмам имгәнеп, биртелеп өенә кайтып егыла. Аның өчен иң караңгы, иң авыр көннәр башлана. Күңеле әрни, йөрәге сыкрана. Кем аны шушы көнгә калдырды? Кемгә кирәк ул хәзер? Өй түрендә улаган кышкы җилгә колак салып, полкташ иптәшләрен исенә төшерә. Максимов фамилияле бер карт солдат әйтә торган иде: «Патша белән байлар өчен сугышабыз, егетләр. Безнең йөрәкләрдән аккан кан алар кесәсенә алтын булып коела... Аңлагыз шуны, егетләр, һәм мылтыкларыгызны кая таба борырга кирәклеге турында уйлагыз...» Гафиятулла абзый көрсенеп куя. Аңлап җиткермәгән шул. Менә хәзер аңлый да... Терсәкне тешләп булмый.

Шулай көннәрен мең газап белән үткәргән чагында, Гафиятулла абзыйның өмет йолдызы кабынып китә. Авылда патшаны төшергәннәр икән дигән хәбәр тарала. Тагын берничә айдан соң Гафиятулла абзыйга Җир һәм Солых турында Ленин үзе кул куйган декретны укыйлар. Ул канатланып китә, чиксез зур шатлык аңа аякка басарга ярдәм итә. Ләкин ныгып өлгерми, илдә коточкыч ачлык башлана. Шул ачлыктан Газинурның әнисе дә үлеп китә. Гафиятулла абзый аны җирли дә, җидесигез яшьлек улын ияртеп, авылдан авылга йөрергә китә, җәйләрен көтү көтә, кышларын берәр кулакка ялланып тамагын туйдыра. Вакытсыз картайган, һәрвакыт ыңгырашып-сыкранып йөргән әтисен кызганган Газинур көче җиткән кадәр аңа булышырга тырыша.

Шулай өч-дүрт ел вакытны көч-хәл белән үткәргәч, беркөн Гафиятулла абзый:

– Юк, болай эш чыкмый, улым, кош та оясыз яшәми, – дип, Шәмсинур исемле әдәпле генә бер тол хатынга өйләнеп куя. Хатынга ияреп, аның Газинурдан бер-ике яшькә олырак Мисбах исемле улы да килә. Гәүдәгә-сынга артык таза булмаган, юаш кына, басынкы гына унөчундүрт яшьлек бу малай Газинурга ошый. Ул аңардан беренче сүз итеп:

– Чыбыркы шартлата беләсеңме? – дип сорый.

– Белмим, – ди Мисбах, борынын тартып куя. Аннары эре генә өсти: – Без көтүче түгел!

– Теләсәң, үзем өйрәтермен, – ди Газинур, аның мыскыллы тавышын ишетмәмешкә салышып һәм озын чыбыркысын мылтык аткан шикелле шартлатып куя. Аннары ераkларга китеп, урман буйларыннан әйләнеп кайткан яңгырашка колак сала. – Ишеттеңме? – Ул Мисбахка таба борыла, аның кара күзләре канәгатьләнеп ялтырый. – Мин берүзем көтү көтә алам, – дип сөйли башлый ул яңадан. – Кәшиф Җәләйләренең мүкләк сыеры гына качкын, һәр көн көтүдән аерылып китә. Мин әтигә әйтәм, муенына аркылы таяк тактырыйк, дим. Әти әйтә, малны рәнҗетергә ярамый, ни өчен качканлыгын әйтергә аның теле юк, ди.

Бу җәйне алар көтүдә өчәүләп йөрделәр. Узган-барган авыл кешеләре озын таягына күкрәге белән таянып, маллар артыннан сабыр гына күзәтеп торган Гафиятулла абзыйдан исәнлек-саулык сорашалар да, көлдә бәрәңге пешереп утырган малайлар ягына ымлап:

– Пумушникларың үсә бит, Гафиятулла кордаш, – дип куялар иде.

– Җаны бар нәрсә, кем, яхшы кешем, дөньяга тугач, үсми тормый инде ул, – дип башын кагып ала Гафиятулла абзый һәм үзара шундый тату, дус яшәгән улларына сөйкемле бер караш ташлый. Җаны сөенеп китә аның. Ул гомер буе ызгыш сөймәде, өйгә яңа хатын алып кайткач та, юк-барга чәпчеп йөрүче җан көеге генә булмасын дип борчылды. Әмма дә Шәмсинур, бераз кыбырсыграк күренсә дә, акыллы гына хатын булып чыкты, Газинурга да кырын карамый, үз малаен да артык иркәләми.

Малайлар никадәр тату, дус булып яшәсәләр дә, берберсенә охшамаганнар иде. Газинур җитез, зирәк, шаян. Мисбах исә басынкы, юаш, оялчан, аз сүзле. Аның урман чикләвеге кебек саргылт күзләре кешегә кыяр-кыймас кына карый, берәрсе шаянрак сүз әйтсә, кызлар кебек кызара, берүзе генә булса, малларга чыбыркы белән дә сыптыргалый, ә Газинур малларга бөтенләй диярлек сукмый.

Ләкин Гафиятулла абзый Мисбахны да үз улы кебек ярата иде. Икәү генә калганда, ул, аның йомшак чәченнән сыйпап:

– Мисбахетдин улым, син алай йомшак булма. Йомшак агачны корт баса. Малайның чәчрәп торганы яхшы, – дип әйткәли торган иде.

Беркөнне Гафиятулла абзый иртән үк бик кирәкле йомыш белән авылга кайтып китте.

– Карагыз аны, малларны игенгә җибәрә күрмәгез, – дип, малайларга кат-кат кисәтеп калдырды.

Җәйнең эссе вакытлары иде. Иртәнге караңгыдан торган малайларның йоклыйсылары килә. Алар малларны төшлеккә туплыйлар да чиратлашып йокларга булалар. Башта Газинур йоклый, аннары, күләгә өч чабатага кыскаргач, Мисбах йокларга ята дип сүз куешалар. Йокы мендәр сорамый. Газинур баш астына йодрыгын куя да шунда ук мышный да башлый. Мисбах көтү тирәсен бер әйләнеп чыга, гайрәт өчен чыбыркысын шартлаткалый, – хәзер ул чыбыркыны Газинурдан бер дә ким шартлатмый инде!

Сыерлар, койрыкларын селкеп, башларын бер-берсе өстенә куеп, өелешеп торалар. Кайберләре буага кергән, сыртлары гына күренә. Сарыклар, басып торганнары да, ятканнары да, борыннарын җиргә төрткәннәр, еш-еш сулыйлар. Мондый эсседә аларны кусаң да, урыннарыннан кузгатып булмый.

Мисбах әледән-әле үзенең күләгәсен чабата белән үлчәп карый. Көн уртасында күләгә бик әкрен кыскара икән. Ә Мисбахның аягүрә килеш күзләре йомыла. Ул аларны йодрыклары белән угалап та ала, суга төшеп битен дә юа, ләкин файдасы аз, йокы һаман изрәтә. Ул, аякларын ял иттерергә дип, карама төбенә утыра һәм үзе дә сизмәстән йоклап китә. Шуннан алар күпме вакыт йоклаганнардыр, икесе дә белми. Маллар торганнар-торганнар да, көн сүрелә төшкәч, әкрен-әкрен басуга таба менеп киткәннәр...

Малайлар этиләренең каты тавышына уяналар һәм беркадәр вакыт берни аңламый башларын иеп басып торалар. Гафиятулла абзый бигрәк тә Газинурга каты ачулана, Мисбахка тел тидерми. Газинур аңга килә: «Нишләдең син, Мисбах? Сүз куешу шул буламыни?» – дип, аңа карап ала. Ләкин Мисбах башын түбән игән дә дердер калтырый.

Болай бик юаш, кече күңелле Гафиятулла абзый, бу юлы бөтен сабырлыгын югалтып тирги дә тирги:

– Юньсез малай, булмаган нәрсә! – дип кычкыра ул Газинурга һәм таягы белән кизәнә. – Нихәтле игенне таптаткансың бит. Син юньсез аркасында хәзер халыктан сүз ишет инде. Бар, күземнән югал!

Бу әрнүле каргышларны яудырганда, Гафиятулла абзый, билгеле, Газинурны куу турында башына да китерми. Аның «күземнән югал» дигән сүзләре «әнә тегендәрәк китеп тор» мәгънәсендә генә. Ләкин горур холыклы Газинур, гаебе булмаса да, үзен аклап маташмый, Мисбах турында да берни әйтми. Озын чыбыркысын иңбашы аркылы сала да бер колагы өзелеп төшкән иске бүреген басыбрак китеп бара. Ул, башын түбән иеп, тузган чаба-

талары белән тузан күтәрә-күтәрә, олы юл буйлап атлый, артыннан, елан кебек боргаланып, озын чыбыркысы сөйрәлә. Газинурның күңеле гарьләнеп ташый, күзләре мөлдерәмә яшь белән тула. Ләкин ул еламый. Югалмам әле дип, үз-үзен юата.

Ул күрше рус авылына бара. Рус һәм татар сүзләрен бергә буташтыра-буташтыра көтү көтәргә теләгәнлеген аңлата. Аңа, бездә дуңгыз көтүе генә бар, диләр. Газинур дуңгыз көтүе көтәргә дә риза икәнлеген әйтә. Көрәк сакаллы рус картлары башларын чайкап куялар.

– Батыр малай, – ди берсе.

– Син кем улы буласың? – дип сорый икенчесе.

Газинур әйтеп бирә. Картларның күбесе Гафиятулла бабайны күреп беләләр икән. Әтиең кайда, ни өчен әтиеңнән киттең, дип сораштыралар да, үзара киңәшкәннән соң, малайны сынап карарга булалар.

– Берничә көн көтеп кара, аннары, булдыра алсаң, сөйләшербез, – диләр.

Шулай Газинур берүзе көтү көтә башлый. Кыю, булдыклы, җитез татар малаен рус авылында да бик тиз яратып өлгерәләр. Яхшы күңелле карчыклар аңа сөт, ипи, йомырка бирәләр. Ят кеше дип аны берәү дә кыерсытмый. Кичләрен ул рус малайлары белән бергә уйный. Кайчакта аны уртага алып татарча җырлаталар яки русча җырларга өйрәтәләр.

– Молодец наш Газинурка! – дип, малайлар аңа кул чабалар.

Газинур ачу саклап йөри торган малай түгел иде. Әтисе белән абыйсына булган үпкәсе күптән онытылды, ләкин гаепле кеше кебек баш иеп кайтырга холкы кушмый иде аның.

Гафиятулла бабай улының кайда икәнлеген белгәч тә шунда ук килеп җитте, ил алдында ата-баба нигезен оятлы итеп өйне ташлап китүе өчен Газинурны бик каты кыздырды, «Иртәгә үк кайтып җит» диде. Газинур кайтырга әзер иде, ләкин кинәт кабынып киткән малайлык кирелеге барысын җимереп ташлады. «Гомердә кайтасым юк», – диде ул әтисенә. Соңыннан, кирелеге суынгач, ул әтисенең хәтерен калдыруын, аның карт йөрәгенә бик авыр яра салганлыгын аңлап, сагышлана башлады. Семьясын, туган авылы Сугышлыны, аның болыннарын, үзенең тиңнәрен сагынды. Ул хыялга, тирән уйга чумып, онытылып утыручан булып китте.

Менә аның «чибәр маллары» урман аланында борыннары белән чирәм казыйлар. Газинур бер читтә, йомшак үләнгә чалкан ятып, күккә карый.

Очсыз-кырыйсыз зәңгәр күктә ялгыз тургай сайрый. Ул үзе күренми. Тик моңлы тавышы әле катырак, әле әкренрәк ишетелә, әйтерсең аны җепкә такканнар да бер күтәреп, бер төшереп торалар. Ни рәхәттер тургайга күктә очу! Аңа бөтен җир: авыллар, кырлар, шәһәрләр – барысы да, барысы да күренә торгандыр. Менә канатларың булсын иде дә шул тургай кебек биеккә-биеккә күтәрелсәң иде!

Газинурның Шөгер белән Бөгелмәдән ары беркайда да булганы юк. Һичкайчан кыш булмый торган Кавказ турында, Кара диңгез турында әтисе сөйли иде сөйләвен. Ләкин менә шул Кавказ таулары башына үзең менеп, үз күзең белән диңгезне күрсәң иде! Нинди була икән ул диңгез?! Кара дигәч тә, чыннан да кара түгелдер әле.

Чалкан яткан Газинур кулларын каш өстенә куя. Болай ераграк күрергә мөмкин: кояш нурлары күзне чагылдырмый. Газинур тургайны эзли. Бәләкәй кошчык күренми. Малай бер күзен йома, икенчесен кыса төшә. Болай тагын да ераграк күреп була. Кинәт саф зәңгәрлек эчендә аның күзенә бер кара нокта чагыла. Тургаймы, әллә күзнең алдануымы? Юк, тургай, әнә ул түбән төшә, зурая, тавышы көчәя.

Газинур, яткан җиреннән торып, аяк бөкләп утыра. «Чибәр маллар»ына күз төшерә. Алар үзләре актарган туфракка ятканнар да әкрен генә мыркылдыйлар. Ак, шома яннары күпереп-күпереп китә.

Офык буенда болыт таулары йөзә. Газинур, башын кыңгыр салып, шул ак болыт тауларына карап тора башлый. Аның сөйкемле йөзе уйчан да, хыяллы да. Болыт таулары һаман күченә, һаман күченә. Кояш нурлары аларны үтәдән-үтә яктырткан, алар шундый җиңел сыман, өрсәң, тузганак кебек очып китәрләр төсле, үзләре шундый ак, беренче яуган кар да андый ак булмый. Эх, ил өстеннән шул ак болытлар кебек гизеп йөрсәң иде.

Газинур шулай байтак уйлана. Аның сабый хыялы кайларга, кайларга гына барып кайтмый да ниләр, ниләр генә эшләргә теләми. Ләкин Газинур хыялчы малай гына түгел. Аның үзе уйлаганнарны сынап та, татып та карыйсы килә. Күз карашы алан уртасындагы ялгыз усакка туктала. Көрәшкә чакырырга теләгәндәй, кара күзләрен кыса төшеп, аңа бер минут сынап карап тора да, кинәт ашыгып-ашыгып, чабаталарын чишенә башлый. Өстендәге бишмәтен салып ыргыта. Бер колагы өзелгән бүреген җиргә ташлый. Аннары учларына төкерә дә усак янына йөгереп килә.

Усак төз һәм ботаксыз. Урмандагы барлык агачлардан биек торган ябалдашында гына тармаклар бар. Газинур башын күтәреп карауга, түбәтәе җиргә төшеп китә.

– Ух, нинди биек! – ди Газинур һәм аяклары, куллары белән усакка кысла кебек ябыша.

Кара каргаларның йомыркалары өчен Газинурның менмәгән агачы юк иде. Бу юлы да ул мәче кебек үрмәләп менеп китте. Берәү дә аны бу акылсыз эшеннән тыймады. Дөрес, югары менгәндә, баш әйләнмәсен өчен, аска карарга ярамаганлыгын ул белә иде. Шуңа күрә гел өскә генә карады. Нихәтле менәсе бар әле! Ә Газинур арый да башлады. Уч төпләре, аяк табаннары кыза. Бәлки, суелып кан да чыккандыр. Шулай да ул түбән төшми, тешләрен кысып, үзсүзләнеп, һаман югары үрмәли.

Менә, ниһаять, ул усак башында! Аның аяклары астында, бер якта, яшел диңгез кебек урман җәелеп ята, икенче якта кырлар күренә. Әнә кемдер ат белән бара. Аты-арбасы уенчык арба-ат кебек кенә. Әнә кемнәрдер авылга төшеп бара. Әнә бер, ике, өч, дүрт авыл күренә... Кинәт Газинурның йөрәген кыргый бер ярсу һәм шатлык биләп ала, ул моңа кадәр үзенә билгеле булмаган биеклек тойгысын татый башлый. Калын ботакка утырып, аякларын селкә-селкә кычкырып җырлап җибәрә:

Совет иле – бәхет иле
Гөлчәчәктәй үсәчәк.

Бу көнне Газинур аеруча канатланып, дәртләнеп йөрде. Хәзер аңа барысы да мөмкин күк тоелды. «Кыш җитсен дә мәктәпкә керәм, ә аннары дөнья күрергә китәм», – дип хыялланды ул. Бу хыял аны җәй буе ташламады. Ләкин җәй үтте, көз, аннары кыш килде. Газинур тагын мәктәпкә керә алмады. Тормыш аны, баш бирми торган юртак ат кебек, көтүче малайга аңлашылмаган үз юлыннан үзе теләгәнчә алып бара бирде. Ашарга кирәк, өскә кием кирәк. Ә Гафиятулла абзый – Газинур шул көздә аның янына кайтты – һаман чирли. Газинур, ирексездән, берәр хәллерәк кешегәме, кулаккамы тамак хакына яллана, ә яз килгәч, тагын көтүгә чыга...

Крестьян тормышы һаман саега, кибә барган җәйге инеш кебек тын гына агып барган бер заманда Газинурның туган авылы Сугышлыда совхоз төзелә дигән хәбәр тарала. Сугышлы халкының бер өлеше совхозда эшләргә кала, имеш, бер өлеше икенче районга күчеп утыра, имеш. Авыл гөж килә. Әмма мунча кебек иске өеннән башка

бернәрсәсе дә булмаган Гафиятулла абзый күп баш ватмый, ул авыл халкының бер өлеше белән Бөгелмә районына күчәргә ризалыгын белдереп тә кайта.

Бу хәбәрне ишеткәч тә, Гафиятулла бабай көтү көтеп йөргән күрше Урманай авылы картлары аның янына килеп җитәләр, аны көтүче булып калырга димлиләр.

– Хатыннарыбыз әйтә, Гафиятулла бабайның кулы җиңел, сыерларыбыз сөтне күп бирә. Кадереңне белеп тотарбыз, кордаш, рәнҗетмәбез, кал.

Җылы сүз еланны да оясыннан чыгара, ди. Әмма гомере буе сүз тыңлаучан булып яшәгән Гафиятулла абзыйны бу юлы бернинди җылы сүзләр дә беркеткән фикереннән кире кайтара алмый.

– Рәнҗеп калмагыз, кордашлар, – ди ул, тирән бер ышаныч белән. – Сакалым сәлперәеп агарганчы кеше малын көттем. Ләкин сакалым агарса да, өметем һаман яшь әле. Яңа җиргә яңа тормыш төзергә барам. Әхмәтгалигә сүз дә бирдем. Карт кешегә ике төрле сөйләп йөрү килешми.

Күп тә үтми, Казаннан кайтып төшкән Гали абзый Галиуллин җитәкчелегендә, Бөгелмәдән унсигез километр җирдә, борынгы рус авылы Исаково күршесендә, кырыклап хуҗалыктан колхоз төзелә. Колхозның беренче председателе итеп Гали абзыйны сайлыйлар һәм аның тәкъдиме буенча колхозга «Красногвардеец» дип исем кушалар.

Газинур җаны-тәне белән Гали абзыйга омтыла. Мәктәп партасына утыра алмый калган бу егет күп нәрсәне төшенмәсә дә, Гали абзый кебек кешеләргә якынрак торырга кирәклеген күңеле белән сизә иде.

Беренче колхоз язы килеп җитә. Колхозчылар күмәкләшеп кырга чыгалар. Гали абзый, планга карап, колхоз җиренең кырыйларын күрсәтә дә Газинурга ат башыннан тотарга куша.

– Йә, Газинур, беренче бураznаны туры сыз! – ди ул, елмаеп һәм үзе бер кулына дилбегәне алып, икенче кулын сабан тоткасына куя: – Бәхетле бураzна булсын, картлар!

Шат, көләч Газинур, ике атның авызлыклары төбеннән тотып, башын югары күтәреп, алдан бара. Ул артына борылып карамый, ләкин бураzнаның туры булуында шикләнми. Бәхет бураzнасын кәкре сызамы соң ул!

...Газинур ничек йоклап киткәнен үзе дә сизми калды. Бары тик үги әнисенең өйалдындагы лар капкачын каты итеп япканын ишеткәч кенә уянды. Күзләрен ачуга, бөтен йокысы таралды.

Кояш тәртә буе күтәрелгән иде инде. Газинур ишегалдына чыкты, бауга асып куелган озын һәм нечкә борынлы чуен комганнан битен юды. Кызыл башлы сөлгегә сөртенде. Аннары, әнисенең самовары кайнап чыкканчы, ат абзарларына йөгерде.

– Озаклама, улым, этиеңә дә, Мисбахетдингә дә әйт: чәй эчәргә килсеннәр, – дип кычкырып калды Шәмсинур җиңги. Ул, ак яулыгын колак артына бәйләгән, җиңнәрен сызганган, күлмәк итәген кыстырган килеш, кар базына иртәнге сөтне алып чыга иде.

## 4

Колхозның эш атлары гына да туксан баштан артып китә. Кырыкмышларын, тайларын, колыннарын санаганда тагын утызлап җыела. Бу бит бер өер дигән сүз! Ак маңгайлы, ак бәкәлле, чем-кара йоннары елкылдап торган сөлек кебек атларның киң болында утлап йөрүләрен, башларын чайкап бер җилкенеп кешнәп җибәрүләрен ишеткәндә яки кичләрен тояк тавышлары белән җир селкетеп авылга кайтып керүләрен күргәндә, колхозчыларның йөрәкләре сөенеп туя алмый. Ялачич боярының атлары түгел, колхоз атлары, үз атларыбыз ич!

Хәзер җәй көне, уракка төшәр алдыннан, буш бер вакыт булганлыктан, эш атларының да күбесе каты басуда утлап йөри. Тайлар, кырыкмышлар исә көзгә кадәр кайтмаячак. Ат караучылар аларны чиратлашып саклыйлар. Шушы көннәрдә алар урман артында, Батурин авылы янында, бүреләр күргәннәр. Бүреләр бигрәк тә яшь колыннарга ябышучан була. Шуңа күрә ат саклаучылар, утлар яндырып, һай-һулап, төннәр буе йокламый йөриләр.

Сабир бабай белән Газинур, кырда бер атна торып, моннан ике генә көн элек колхозга кайтканнар иде. Алар урынына Гапсаттар белән Газзән китте. Хәзер кул астындагы барлык атларны карау, абзарларны чистарту, ком сибү, атларга азык әзерләү, су ташу кебек эшләр барысы да Сабир бабай белән Газинур өстенә төшә. Бу җиңел түгел. Сабир бабай әйтмешли: «Туксан атның туксан төрле эше бар».

Газинур конный дворга килеп җиткәндә, Сабир бабай эшкә китәсе атларны чистартып, сугарып, тиешле кешеләренә биреп җибәргән иде инде. Абзар янындагы баганага әлегә эшкә китми калган дүрт ат бәйләнгән. Абзарда, тимер чылбыр тезгенен чыңлата-чыңлата, колхозның нәселле айгыры Батыр сабырсызланып кешни. Ул

кешнәгәндә, абзар тирәләре генә түгел, бөтен колхоз урамы яңгырап тора.

– Ялкау киндерәсен ураганчы, тырыш эшен бетерер дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр икән! – дип, ерактан ук көлә килде Газинур. – Мин тинтәк йоклап ятканчы, Сабир бабай бөтен эшне бетергән. Хәерле иртә, Сабир бабай!

– Әйдүк, Газинур улым, әйдүк. Эшне без түгел, безнең бабайлар да бетерә алмаган. Бер дә кайгырма, сиңа да өлеш җитәрлек әле.

– Һәй, әйттең, Сабир бабай, сүз. Бабайларның эше ни дә, безнең эш ни! Колхоз эшен элекке мужик эшенә тиңләп буламыни. Күр, әнә ничек гөрли безнең колхоз иртәсе!

Газинур, кулларын җәеп, тирә-ягына күрсәтте. Тимерчелектә дәү һәм бәләкәй чүкеч белән сандал суккан тавышлар чыңлый, чүкеч тавышлары тынган арада, ферма өеннән сепаратор әйләндерүче кызларның күңелле җырлары ишетелә, келәт алдында атлар җигелгән арбаларга ак бидоннар төйиләр, сөт ташучы Мәрфуга апа Спасс авылына – май заводына барырга дип арбага утыра, кошлар фермасында ак алъяпкычлы бер кыз тавыкларга җим сибә, аның әйләнә-тирәсе ак диңгез кебек. Арырак дүртбиш хатын-кыз терлек абзарларын акшарлый, яңа салына торган май чыгару заводы каршында балта осталары эшли. Өр-яңа йөк машинасы каядыр китәргә әзерләнә, аның тирәсендә кешеләр чуала. Колхоз председателе Хәнәфи дә алар арасында. Ул, кабина баскычына басып кул болгый-болгый, кемнәрнедер ашыктыра...

– Йә, әйт, Сабир бабай, син – күп яшәгән, күп күргән кеше. Мондый хәлләр элек бар идеме?

Газинур, җиңнәрен сызганып, кулына кыргыч, щетка алып, бәйдәге атлар янына килде. Ул, җирән кашканың муеныннан сыйпап:

– Һай, Малинам, син өйдәмени? Ә син, Чабата, нигә башың иден? – Ул олы аяклы туры атның арт санына учы белән шап итеп сукты. – Ә син, Игрун, нигә шаярасың? Кара, кара, тешләмәкче була бит, әнкәсенең усал кызы. Иркә ничек тора? Һай-һай, наян, башын кыңгыр салып кызлар кебек назланырга да әзер.

Газинур атларның һәрберсен муеннарыннан сыйпапсыйпап үтте дә йомшак щетка белән чистартырга керешге.

Аның көчле куллары астында атларның сыртлары сыгылды.

– Һай, җанкисәгем, чыдамсыз нәрсә икәнсең. Мин җиңелчә генә ич, сөеп кенә ич...

Абзар ишеге төбен себерергә дип кулына себерке алган Сабир бабай, Газинурга хәйләле генә карап, елмаеп

торды. Аңа Газинурның яратып, дәртләнеп эшләве ошый иде.

– Ярый әле, – диде ул, чал кергән түгәрәк сакалын буыннары бирчәйгән бармаклары белән бөтерә-бөтерә, – гөләп чәчәгең биредә юк. Күрсә, көнләшеп үләр иде. Баярак, печәнгә китәр алдыннан, бер килеп күз төшергән иде инде. Үзе сыер савучылар янына килдем дигән була, үзе ат абзарларына карый. Мин әйтәм, балакаем, ат абзарында сыер саумыйлар бит.

– Шулаймыни? Килгән идемени? – диде Газинур, елмаеп. – Ә мин юләр йоклап ятканмын.

Газинурның күңеле тагын да көчлерәк сөенеп, яктырып китте. «Татлы тормаң дими бит, Миңнурыең да дими, ә, гөләп чәчәгең, ди! Һай, хәйләкәр дә була бу картлар! Бияләй эчендә бармак кыймылдатканны да сизәләр. Мең яшә, Сабир бабай!»

Шулай да егет берьюлы бөтен серен ачып салырга теләми.

– Акылы булса, көнләшмәс әле, Сабир бабай.

Карт, ике кулы белән себерке сабына тотынып, башын кыйшайта төшебрәк кеткелдәп көлә.

– Кызларның акылы, Газинур энем, тоштән соң. Ә чибәрләренең төштән соң да булмый бугай. Шуңа күрә син бик мутланып китмә әле. Өченче әтәчләргә кадәр сайрашмаганда да ярый торгандыр бит.

– Яшь гомерләр ике килми, Сабир бабай. Әллә минем сайрашканны күрдеңме? – дип сорады Газинур һәм атның маңгай ялын тарарга кереште.

– Әллә күрдем, әллә юк, – диде карт, үзе, мыек астыннан елмаеп, ишек төбен себерергә тотынды.

Газинур атларны чистартып бетереп, йөгәннәрен салдырды. Атлар абзарга кереп киттеләр. Алар артыннан Газинур да атлады. Бераздан ул ыргылып, биеп, күзләреннән ут чәчеп торган алмачуар Батырны абзардан алып чыкты. Караңгы абзардан көн яктысына чыккан айгыр, арт аякларына басып, үрә торырга, ычкынып, кырларга чабып китәргә ашкына. Газинур, аның чылбырлы тезгенен беләгенә урап, авызлык төбеннән үк тоткан һәм, гәүдәсен бераз арткарак ташлап, аякларын җиргә тери-тери атлый иде.

Урам буйлап Исаковога таба җигүле атлар үтеп китте. Батыр башын күтәреп кешнәп җибәрде. Аның көчле тавышыннан бөтен өйләрнең тәрәзә пыялалары зыңлап коелып төшкәндәй булды. Ферма артындагы таулардан көчле яңгыраш әйләнеп кайтты.

– Йә, йә, тынычлан, Батыр! – диде Газинур һәм, ай-

гырның башын югары күтәреп, чылбыр тезгенне юан бөҗрага кертеп бәйләде.

Елкылдап торган тиресенә щетка тигәч, айгыр яңадан биергә, сабырсызланырга тотынды.

– Кети-кети уйнаганны яратмыйсыңмыни, малкаем. Курыкма, мин шүрәле түгел.

Газинур, мыштым Газзән кебек, авызына су капкандай дәшми-тынмый гына эшләүне яратмый иде. Ул биредә булганда, абзар тирәләре һәрвакыт гөрләп тора: әле атларга иркәләп эндәшә, әле яныннан үтеп баручы кызлар белән бер-ике авыз сүз алыша, әле үзенең моңлы, ачык тавышы белән җырлап җибәрә, әле күңелле генә сызгырып куя. Җиңнәрен сызганган, аякларына тула оек белән резина галош элгән бу шат күңелле егеткә колхозның олысы-кечесе сөеп карый, аны бары тик шул сыйфатта гына күрергә күнеккән иде.

Ул арада Сабир бабай абзардан алгы аягына аксаган өч яшьлек кара атны тезгененнән җитәкләп алып чыкты.

– Газинур, – диде ул, уңайсызланып, – сиңа әйтмәдем бит әле. Кичә Зәйтүнәнең юньсез малае Маймылны харап итә язган, ахмак нәрсә. Әтисе булды әтисе мал-туар кадерен белмәде, әнисе булды әнисе эштән баш тартып йөри, инде малайларыннан да рәт юк.

Газинур, биеп торган Батырны ташлап, Маймыл янына йөгереп килде. Бу өркәк атка кем шундый хурлыклы исем биргәндер, ул кадәресен Газинур белми иде. Колхоз председателе Хәнәфи аны Минзәлә базарыннан алып кайтты. Атның паспортында исеме «Маймыл» дип язылган иде. Газинур бу атны ярата, берәрсенә эшкә биреп җибәргәндә кисәтеп куя торган иде. Малай-шалайга ул аны бөтенләй бирми иде.

– Нишләткән? Кем аңа Маймылны бирде? – дип сорады ул, борчылып.

– Аягын имгәттергән, булмаган нәрсә, – диде Сабир бабай.

Ат уң аягын җиргә тидерер-тидермәс кенә басып тора. Газинур кулын суза башлагач, Маймыл, өч аягында сикергәләп, читкәрәк тайпылды.

– Курыкма, курыкма, җаным, авырттырмыйм, – диде Газинур һәм атның авыру аягын бөгеп тезенә куйды. Ярага уралган канлы чүпрәкне сүтеп ташлагач, Газинурның озынча йөзе башта агарынып, аннары кызарып китте.

– Харап иткән бит бу, Сабир бабай! – дип кычкырды ул ачу белән. – Кем шул тиле малайга ат бирде? Нигә миңа кичә үк әйтмәдең?

Газинур янына чүгәләгән Сабир бабай көрсенеп куйды.

– Гаеп миндә булды, Газинур. Атны мин бирдем. Кара, сакланып кына йөр, дидем юньсезгә. Күрәсең, минем сүзләрем бер колагыннан кергән, икенчесеннән чыккан.

– Ярый әле мин булмаганмын, югыйсә яңакларыннан ут чәчрәткән булыр идем мин аның бу эш өчен.

Сабир бабай башын чайкап куйды, аннары кулын селекте:

– Һәй, сиңамы соң, Газинур, кешегә кул күтәрергә. Син бит кешегә түгел, малга да сукмыйсың.

– Малга сукмыйм, – диде Газинур, атның аягын яңадан җиргә бастырып, – әмма йоклап эшләгән күзле бүкәнгә суккан булыр идем. Ярый, нигә ветфельдшерга күрсәтмәдең, Сабир бабай?

– Өч тапкыр өенә бардым – юк. Тымытыкка киткән, шуннан һаман кайтып җитә алмый, диләр.

– Кем, Сәлимме? – дип кычкырды Газинур. – Әллә кайчан кайткан ул!

– Кайткан? Белеп әйтәсеңме? Мин энисеннән сорадым. Кайтмады, ди. Һе, соң син үз күзең белән күрдеңме? – Карт ачуыннан бер урында таптана башлады: – Ничек була инде бу, кем, Газинур? Җитмеш яшьлек карт өч тапкыр бара, ә алар аны, алдалап, ишек төбеннән борып җибәрәләр. Бу ниткән эш бу? Юк, хәзер үк барып җилтерәтеп алып киләм мин аны, болай булгач. Аннары Хәнәфи янына да алып барам үзен. Председатель алдында җавап бирсен!

Газинур, эндәшмичә, атның шешкән һәм дереллдәп торган аягына карап тора иде. Сабир бабай китеп бара башлагач, башын күтәрде.

– Тукта, Сабир бабай. Син малай түгел, Сәлим түрә түгел. Авыру ат барын ишеткәч, чакырмый да килергә тиеш. Атның ярасын хәзер үзем бәйлим. Син шунда бераз торып тор. Батыр янына бала-чага килмәсен. Тибеп үтерер.

Газинур кышын ат карауч ылар тора торган өйгә таба йөгереп китте. Анда аның аптечка сыман бер шкафы бар иде. Шуннан ак сөлге, ак чүпрәк, май алып килде. Аннан энисенә, җылы су сорап, бер малайны йөгертте. Бераздан атның ярасын әйбәтләп юып, май сөртеп, ак чүпрәк белән бәйләп тә куйды.

– Хәзер Маймылны коры аранга урнаштыр, Сабир бабай. Кара, ярасына пычрак керерлек булмасын. Ә Зәйтүнә малае белән Сәлим турында Хәнәфи абзыйга әйтергә кирәк. Уен эш түгел бу.

– Ниткән уен эш булсын, – диде карт, атның тезгенен кулына алып.

– Икенче тапкыр син дә, Сабир бабай, әйтүемне күңеленә авыр алма, ныграк бул. Малай-шалайга ат ышанма.

– Дөрес әйтәсең, Газинур улым, дөрес. Ник авырга алыйм...

Сабир бабай, үз алдына сөйләнә-сөйләнә, аксак атны ияртеп, абзарга кереп китте. Газинур алгы аягы белән җир тырнап торган алмачуар янына килде. Муеныннан сыйпады, баягыча чылбыр тезгенне беләгенә урап, авызлык яныннан тоткан килеш, абзарга алып керде. Ындыр табагы кебек тап-такыр киң мәйдан бушап калды. Ләкин бер минут та үтмәгәндер, анда ак эшләпәле Сәлим күренде. Мәйдан уртасына җиткәч, ул туктады, чалбар кесәсеннән көмеш тәмәке савыты чыгарды, кояш нурларында җем-җем итеп торган капкачына беравык карап торды.

Колхоз келәтләре ягыннан, кулына кәгазьләр тотып, ак алъяпкычлы, ал яулыклы, аягына биек үкчәле сары читек кигән колхоз хисапчысы – Миңнурыйның якын дусты Әлфия килеп чыкты. Зифа буйлы, кыйгач кашлы, зәңгәр күзле Әлфия, Миңнурыйның киресе буларак, бик оялчан иде. Сәлим Миңнурый белән бер үк вакытта аңа да хатлар яза, ләкин кызларның ул язган хатларны бергәләп укый-укый аңардан көлүләрен генә белми иде. Миңнурыйдан Сәлим курка, әмма Әлфиянең йомшак күңелле, оялчан булуыннан файдаланып, аны яхшы ук газаплый иде.

– Әлфия җан, бүген төшеңдә мине күрмәдеңме? Кайчан туйны ясыйбыз? – диде Сәлим һәм кулындагы тәмәке савытын шалт иттереп ябып, учында әйләндергәләп алды да кесәсенә салды.

– Китсәнә, Сәлим, йөземне кызартма әле, – диде Әлфия, туктамыйча.

– Кара, кара, борынын ничек күтәргән, туктарга да теләми бит.

Сәлим аны беләгеннән тотмакчы булып кулын суза гына башлаган иде, ат абзарларыннан Газинурның тавышы ишетелде:

– Сабир бабай, сәнәкне бир әле!

Сәлим, корт чаккан шикелле, кулын тартып алды, шунда ук кыяфәтен алмаштырып, үтә эшлекле бер кеше сыман абзарга таба атлады. Әлфия, аның кыланышыннан көлеп җибәрмәс өчен, учы белән авызын каплап, аның артыннан бераз карап торды да правлениегә таба йөгерде.

– Сабир бабай, син кайда, әй? – дип кычкырды Сәлим, абзарга кергәч.

Кулына сәнәк тоткан Сабир бабай араннан чыкты.

– Монда мин, Сәлим энем. Исән-сау кайтып җиттеңме?

– Маймылны нишләттегез? Нигә яхшылап карамадыгыз? – дип, Сәлим нечкә тавышына эрелек һәм кырыслык бирергә тырышты. Ул Сабир бабайның соравын ишетмәмешкә салынды, чөнки картның тел төбен бик тиз аңлады.

Бер кочак печән күтәреп, «әллү генәем, бәллү генәем» дип көйләп килгән Газинур юл өстендә басып торган Сәлимгә:

– Әзрәк читләш әле, егет, күлмәгеңә печән ябышмагае, – диде.

Сәлим, атны яктыга чыгартып, ярасын аннан-моннан карады да блокнотын чыгарды.

– Акт төзергә туры килә. Кул куярсыз.

– Кул куярбыз, – диде Газинур, Сабир бабайга күз кысып, – ләкин актта иң башта болай яз: ат караучы җитмеш яшьлек Сабир бабай мине, Сәлимгәрәй Салмановны, өч тапкыр килеп чакыруга карамастан, мин авыру атны барып карамадым, әниемнән мин өйдә юк дип әйттердем, ник дисәң, төне буе Миңнурыйның тәрәзә төбен сакладым...

Сәлим агарынып китте, салынкы иреннәре селкенә башлады.

– Алайса, правлениедә сөйләшербез, – диде ул һәм ашыгып китеп барды.

Газинур көлә башлады.

– Нигә көләсең? – диде Сабир бабай.

– Болай гына. Акт белән куркытмакчы була! Җиңел юл тапкан.

Янгын сараеннан өстенә кыска көрән бишмәт кигән бер кеше чыкты һәм, кулларын артына куеп, кырпулы бүрек кигән башын аска ия төшеп, правлениегә таба юнәлде. Бу Газинурның этисе Гафиятулла бабай иде. Май заводы каршында эшләүче балта осталары яныннан узганда:

– Хезмәтең уң булсын, Мирвәли! – дип кычкырды. Гафиятулла бабайның элеккеге гренадер солдат сыны хәзер бик нык бирешкән. Башын иеп йөрергә гадәтләнгәнлектән, ул хәтта бераз бөкре дә кебек күренә. Йөргән чагында да, насос яки сулы мичкә арбасына көннәр буе утырып торган чагында да, ул һәрвакыт үз алдына ни дә булса сөйләнә. Кайчагында әкрен генә сөйләнә, кайчагында аның тавышы бөтен ишегалдына яңгырый. Монысы кәефе кырылган көннәрдә була. Ләкин колхозчылар моңа бер дә гаҗәпләнми, алар аның сөйләнүләренә күнеккәннәр инде. Колхозга кергәч, Гафиятулла бабай берме-

икеме җәй колхоз көтүен көтте дә, сәламәтлеге начар булганлыктан, правление аны җиңелрәк эшкә күчерде. Аны пожарник итеп куйдылар. Шуннан бирле, менә өченче ел инде, Гафиятулла бабай шул хезмәттә тора. Шушы өч ел эчендә бүгенгә кадәр колхозда бер генә дә янгын булганы юк. Дөрес, бер тапкыр Гарәфиләрнең бик кызу ягылган мунчасы яна башлады. Ләкин Гафиятулла бабай сулы мичкәсе белән анда кош кебек очып барып җитте, янгынны зурга җибәрмичә сүндереп тә өлгерде. Икенче тапкырында мыштым Газзәннәрнең морҗасыннан ут сикерә башлады. Анда да Гафиятулла бабай бик вакытлы барып җитте. Өй эчендәгеләр йөгерешеп чыгарга өлгергәнче, Гафиятулла бабай, картлыгына һәм сәламәтлеге какшаган булуга карамастан, өй түбәсендә иде инде. Бу юлы да янгынны зурга җибәрмәде. Мыштым Газзән соңыннан Гафиятулла бабайга өенә килеп рәхмәт әйтте.

– Син инде, Газизҗан туган, миңа рәхмәт укыма, – диде Гафиятулла абзый аңа. – Минем ил алдындагы хезмәтем шундый. Син хатының Өммегөлсемгә әйт, морҗасының корымын ешрак чистартып торсын. Балчыкны да кызганмасын, балчыкны сатып аласы юк, үзебездә тулып ята, төтен юллыгындагы тишекләрне яхшылап сыласын. Мин чормагызга менеп карадым, кирпеч араларында бармак сыярлык ярыклар бар.

Озак еллар колхозда янгын булмавы кайбер кешеләрне гамьсезлеккә этәргән иде, ахрысы. Әле кичә генә кайсы юньсезедер правлениедә: «Пожарникның эше эшмени ул, аңа ни дип хезмәт көне язып торырга», – дип ычкындырып ташлаган, имеш. Бу ахмак сүзне ишеткәч, Гафиятулла бабай төне буе үз алдына сөйләнеп чыкты:

– Һе, пожарникның эше эш түгел, имеш. Ничәмә-ничә еллар буе табылган мал күккә очса, ул эш булыр. Пожарник боз киптереп ятучы, имеш, һе... Тиле авыздан тиле сүз шул үзе була инде.

Менә шул нәрсә инде Гафиятулла бабайны карчыгының иртәнге чәен дә эчмичә председатель янына алып килде.

– Хәнәфи туган, – диде ул үзен ачык йөз белән каршы алган председательгә, – мин үземнең хезмәтем турында бер яман сүз ишеттем, дөресме шул сүз?

– Утыр, Гафиятулла абзый, бер буш сүз өчен җаныңны борчыма әле, – диде Хәнәфи, – син, колхоз милкен саклап, боевой постта торасың. Сине берәүдән дә кимсеттермәбез.

– Рәхмәт, Хәнәфи туган, – диде карт, бераз тынычланып, – югыйсә бит кеше аркылы ишеткән сүзгә күңел

кыйнала. Колактан кергән салкын сүз йөрәккә барып җиткәнче боз була, ди. Янгын булмаганда гына ул берни түгел, бер булса, ай-һай хәтәр нәрсә. Герман сугышы башланган елны безнең Сугышлыда янгын чыккан иде. Ярты авылдан көл генә калды.

Гафиятулла бабай, ерак үткәннең фаҗигале күренешен күз алдына китереп, тынып калды, озак кына сүзсез утырды.

Правлениедән чыккач, Гафиятулла бабай туп-туры өенә кермәкче иде дә, Газинур абзарлар тирәсендәдер әле дип, тагын конный дворга таба атлады.

Гафиятулла бабай, такыр мәйданны аркылы үтеп, абзар ишекләре янында туктады һәм, башын эчкә тыгып, бераз карлыга төшкән тавыш белән кычкырды:

– Газинур улым, син биредәме? Әниеңнең самовары күптән кайнап чыккандыр инде. Әйдә, булмаса, тамакны ялгап килик.

Газинур араннарга ком сибеп йөри иде.

– Хәзер, эткәй. Комны гына сибеп бетерәм.

Газинур тимер көрәген почмакка илтеп сөяде дә уртадагы юлдан ишеккә таба килә башлады. Аның артыннан кулына себерке тоткан Сабир бабай да күренде. Башындагы малахай бүрегенең алды артка борылган иде.

– Сабир, – диде Гафиятулла абзый, көлемсерәп. – Тегермән ташың тискәре якка әйләнә башлаган икән.

– Булыр, булыр, – Сабир бабай бүреген төзәтеп алды. – Абайламый йөрсәң, шулай була ул.

Шул сүзләрдән соң картлар бер-берсенә хәерле иртә теләделәр. Сабир бабай, кулын каш өстенә куеп, бер генә болыт та күренмәгән аксыл күк йөзенә карап алды.

– Бүген дә бик каты кыздырыр, ахрысы.

– Төштән соң яңгыр явардыр, – диде аңа кушылып Гафиятулла бабай. – Әнә кара каргалар көтүләре белән оча. Аннары арка сөякләрем дә төне буе сызлады. Әле Хәнәфи туганга да әйттем, печәнгә кешене күбрәк җибәр, дидем. Коры чакта җыеп алырга кирәк.

– Абыйны күрмәдеңме, эткәй, әни аны да алып кил дигән иде, – диде Газинур.

Мисбах, өйләнеп, башка чыккан иде. Аның үз өе дә урам аркылы гына булуга карамастан, алар, иске гадәт буенча, иртәнге яки кичке чәйгә еш кына бергәләп кайталар һәм үзара тату гына сөйләшеп, көлешеп чәй эчәләр иде. Мисбах булмаса, Шәмсинур җиңгигә табын яны буш кебек күренә.

– Мисбахетдин иртүк печәнгә китте шул, – диде Гафиятулла абзый һәм кулларын артына куеп, башын аска

салындырып, үз алдына әкрен генә сөйләнә-сөйләнә китеп барды. Хәзер аның күңеле тәмам тынычланган иде инде. Газинур аның артыннан атлады.

Алар урамны бераз кыеклап аркылы чыктылар да әле бөтен яктан киртәләп тә өлгермәгән ишегалдына җил капкадан килеп керделәр. Гафиятулла бабай, туктап, ишегалдының бер почмагына утыртылган алмагачларның тәрәкләрен төзәткәләде, кайсыдыр төшереп калдырган утын кисәген аяк астыннан күтәреп, өй нигезенә илтеп куйды. Газинур, ишек төбендәге чуен комганнан су коеп, кызу-кызу хәрәкәтләр белән кулларын юган арада, Гафиятулла бабай ашыкмыйча гына бишмәтен, бүреген салып чөйгә элде. Бүреге белән бергә салынган ялтыр кәләпүшен яңадан алып киде. Шуннан соң гына ул комган янына килде.

Бит-кулларын югач, алар аталы-уллы өйгә керделәр. Шакмаклы кызыл ашъяулык җәелгән өстәлдә сары самовар шаулап тора. Шәмсинур җиңги өстәл белән мич арасында йөри.

– Ник бу кадәр соңладыгыз? – дип каршы алды ул ире белән улын.

– Хәнәфи туган янына кергән идем, – диде Гафиятулла бабай, түр башына утырып.

Шәмсинур җиңги самовар янына урнашты, Газинур кырыйдан утырды. Газинурның унике-унөч яшьлек энесе Халикъ өйдә юк иде.

Чәйне колхозның көндәлек эшләре турында сөйләшә-сөйләшә эчтеләр. Газинур ара-тирә тәрәзәдән тышка күз салгалады. Түр тәрәзәдән урам аръягындагы биек тауның сырты күренә. Чынаяктай ак болыт кисәге тау түбәсенә тияр-тимәс кенә йөзә. Хәзер болытлар турында Газинур бала чагындагы кебек беркатлы хыялланмый инде. Аны хәзер бүтән нәрсә кызыксындыра. «Их, – дип уйлый ул, тоз сипкән кайнар бәрәңгесен икмәк һәм әйрән белән тәмләп ашый-ашый, – менә шул шәп-шәрә тауның буеннан-буена бакча үстерсәң иде. Кура җиләге, кара карлыган бакчасы. Ә ике тау арасындагы уйсулыкта алма бакчасы. Анда бервакытта да җил булмый. Алмагач җилсез урынны ярата. Нәкъ алма бакчасы урыны инде! Тау итәгендә мәктәп салдырыр иде ул. Бөгелмәдәге шикелле зур тәрәзәле, калай түбәле мәктәп...»

Кичә Бөгелмәгә барганда, Гали абзый: «Җил двигателе турында безгә ныклап уйларга вакыт. Бу хәтле терлекләрне коедан чиләк белән су чыгарып сугару эш түгел. Әнә шул тау башына җил двигателе куйсак, һәрбер абзарыбызга су труба буенча гына агып торачак», – дигән

иде. Менә шул җил двигателен тизрәк куеп җибәрсәк иде!

Газинур әле чынаягын да капламаган иде, ишектән Халикъ атылып килеп керде. Ул яланаяк, яланбаш, күлмәкчән генә. Күзләре Газинурныкы кебек калкып тора, тере, шаян малай. Битләрен куе сипкел каплаган.

– Газинур абый, – диде ул, ашыгып, – сине правлениегә чакырдылар. Хәнәфи абый әйтә, немедленно-моментально килеп җитсен, ди.

«Сәлим...» дип уйлап алды Газинур.

– Ул кадәр нинди ашыгыч эш тагы? – дип сорады Шәмсинур җиңги, кашларын җыерып. – Тынычлап чәй эчәргә дә бирмиләр. Газинур да Газинур. Әйтерсең бөтен колхоз шул бер Газинурдан гына тора. Ашыкма, улым, яхшылап тамагыңны туйдыр. Аш вакыты бер була. Ут чыкмагандыр әле, көтәрләр.

Гафиятулла бабай ризасызлык белән хатынына карап алды.

– Авызыңнан җил алсын, анасы, нинди ут чыксын. Хәерле сәгать бар, хәерсез сәгать бар, юк нәрсә турында сөйләмиләр!

Кулына бер бөтен бәрәңге тотып өлгергән Халикъ яңадан сүзгә кысылды:

– Абзар янында халык җыелган, – диде ул, ашыга-ашыга, – Маймылны карыйлар. Хәнәфи абзый бик каты ачуланган. Ветфельдшер Сәлим абыйны утлы табага бастырган кебек биетә. Атны өч көндә төзәтмәсең, подсуд бирәм, ди. Сабир бабайга да зрә эләкте...

– Хәнәфи абзый хәзер кайда, абзар янындамы?

– Юк, төзелешкә менеп китте.

Газинур, рәхмәт әйтеп, өстәл артыннан тиз генә торды да, кепкасын чөйдән эләктереп, чыгып та китте.

Урам уртасыннан алсу яулыгын баш түбәсенә генә беркеткән колхоз хисапчысы каядыр бик ашыгып бара иде.

– Әлфиякәй, Хәнәфи абзый кайтмадымы? – дип кычкырды Газинур аңа.

Әлфия тиз генә борылып карады. Колагындагы алкалары кояш нурында җемелдәп киттеләр.

– Төзелешкә барам дигән иде, Газинур абый, – диде ул ягымлы тавыш белән. – Сиңа да шунда менәргә кушты.

– Әллә берәр җиргә җибәрмәкчеме?

– Юк, такта яручы Степан авырган. Сине аның урынына куеп торырга булдык.

– Нигә мине, нигә Һашимны түгел, – диде Газинур, шаяртып. – Әһә, кызарасың. Мине яратмагач, Газинур абыйга кайда булса да барыбер дисеңме?

– Юк ла инде, Газинур абый. Һашим такта яра белми ич.

– Ә мин беләммени?

Әлфия дә төзелешкә бара икән. Уен-көлке катыштырып сөйләшә-сөйләшә, бергәләп киттеләр.

Быел колхоз яңадан ике зур амбар салдыра, бәрәңге, яшелчә саклар өчен өч землянка казыта. Колхозның уңышы елдан-ел арта барганга, иске келәтләр, иске базлар гына аны канәгатьләндерә алмый иде. Болардан тыш колхоз май заводы салдырырга да кереште. Менә шуларның барысын бергә колхозда бер сүз белән «төзелеш» дип атый башладылар. Күмәкләшү елларында гына авылда телгә кереп киткән бу яңа сүз колхозчыларның күңелендә үзенә бертөрле шатлык һәм горурлык уята иде.

Газинур, Сабир бабай янына абзарга кереп, кая киткәнлеген әйтте дә фермалар артындагы кашлакта казыла торган землянкаларга таба юнәлде. Землянкаларның икесе казылып беткән, тик түбәләренә туфрак ташлыйсы гына калган. Кулларына тимер көрәкләр тоткан хатын-кызлар шул эшкә керешкәннәр дә инде. Ирләр шунда ук өченче землянканың нигезен казыйлар. Балта осталары өрлекләр әзерлиләр.

Газинур, уңыш теләп һәм берничә шаян сүз әйтеп, кызлар яныннан үтте дә, колхоз председателенә ияреп, землянка эченә керде. Землянка озын, иркен иде.

– Йә, җир асты сараеннан кай җире ким моның? – диде Хәнәфи, кара мыегын бөтереп. – Күрдеңме, Газинур, безнең колачны. Шулай эшләргә кирәк!

– Әйе, Хәнәфи абый, безнең әнинең идән асты да, кар базы да түгел инде бу.

Хәнәфи кычкырып көлеп җибәрде. Өстенә ярым хәрби кием кигән бу озын буйлы, җиңел сөякле, калын кара кашлы, кара мыеклы кешенең көлүе күңелле, дәртле иде.

– Идән асларын, кар базларын онытырга вакыт инде, Газинур. Тиздән без менә дигән холодильниклар салдырырбыз.

Хәнәфи Газинурга хәзер үк ындырга, амбарлар янына барырга, Степан терелгәнче такта ярышырга «боевое задание» бирде. Газинур җир исе килеп торган землянкадан чыкты да ындырга юнәлде.

Тау башында һәйбәт нарат бүрәнәләреннән салына торган озын, биек амбарларга Газинур ерактан ук сокланып карап барды. Түбәләрен ябып җибәргәч, таш пулатлардан бер дә ким булмаячак.

Балталар астыннан, кояшта ялт-йолт килеп, ак йомычкалар оча. Пычкылар чыжылдый. Бүрәнә тәгәрәтүчеләр-

нең: «Раз, два, взяли!» – дигән күңелле тавышлары ишетелә. Бураның бер почмагына киез эшләпәле Гарәфи абзый атланган, икенче почмагын зур сары сакаллы дядя Митрий иярләгән. Аның сакалы кояшта бер көлтә ялкын кебек ялтырый.

Төзелештә «Красногвардеец»ның үз балта осталары белән бергә күрше рус, чуваш колхозларыннан килгән мастерлар да эшли иде. Газинур аларның һәммәсен белә, ә такта яручы Степан һәм аның юлдашы аксыл бөдрә чәчле, киң күкрәкле чуваш егете Пашка белән якын дус та иде.

– Буламы, Гарәфи абзый! – дип кычкырды Газинур, башын югары күтәреп. – Сәлам, дядя Митрийга! Ай-һай, кызу тотасыз. Әле кичә генә нигезен сала идегез, бүген матчага үреләсез.

– Митрий Иваныч белән пар эшләгәндә кызу тотмыйча кара, – диде Гарәфи һәм күршесенә сөйкемле караш ташлап көлеп җибәрде. – Дядя Митрий шаляй-валяй эшләгәнне яратмый ул.

– Эшне эш дип эшләргә кирәк, – диде аңа каршы карт оста. – Хәзер бер «Красногвардеец» кына амбарлар салдырмый бит. Безне «Заря»да да, «Прогресс»та да, «Тигез басу»да да көтәләр.

Пашка озын пычкысын кайрап утыра иде. Газинур аның белән кул биреп күреште.

– Степан авырды бит әле, – диде Пашка, иптәше өчен борчылып. – Ә монда эш тоткарланып тора. Иртәгә түбәне яба башлаячаклар, такта кирәк.

– Бездән эш тормас, Пашка дус, – диде Газинур, бишмәтен салып ташлап. Аннары биек кузлаларга аркылы салынган бүрәнә өстенә сикереп менде. Бүрәнәне бер буй кисеп үткәннәр, икенче буйның да яртысы ярылган.

Газинур, моңарчы да такта яргалаган булганга, эшнең рәтен белә иде. Шуның өстенә яшь чагында такта яручы булып эшләгән Гафиятулла бабай да бу һөнәрнең сере турында улына күп нәрсә сөйләгән иде. Степан авырып кайтып киткәч тә, Пашка колхоз председателеннән Газинурны үзе сорады.

Газинур, пычкының шомарып беткән сабына ике кулы белән тотынган килеш, тирә-ягына сөенеп карап алды. Аның каршында, карасу-яшел урман буена сыенып, «Красногвардеец»ның киң кырлары җәелеп ята. Саргаеп килә торган игеннәр салмак кына дулкынлана. Дулкыннар, берберсен куышып, еракка-еракка китәләр дә урманга кереп югалалар. Югалганнары урынына яңалары калка. Кыр уртасыннан беленер-беленмәс кенә сузылган юлдан кемдер ат белән килә. Ләкин аты да, арбасы да күренми,

тик дугасы гына тырпаеп чыккан. Уңдарак, үләне чабып алынган болынлыкта көтү йөри. Колхозның нәселле ак үгезе болын уртасындагы үр өстенә менеп баскан да ак мәрмәрдән киселгән һәйкәл сыман кузгалмыйча тора. Тамак асты җиргә тигән, мөгезләре дисәң – колач җитмәс.

– Башлыйбыз, Пашка дус, – диде Газинур шат тавыш белән.

Пычкы, чыжылдап, җиңел генә түбән шуды. Аның эре, үткен тешләре астыннан җиргә сап-сары «ярма» коела башлады.

Пычкы бер күтәрелеп, бер төшеп торган уңайга Газинурның күз алдындагы киң кыр да, карасу-яшел урман да мәгълүм бер ритм белән тибрәнергә тотынды...

## 5

Утлап йөргән җирләрендә, бер дә көтмәгәндә, колхозның өч баш аты авырый башлады. Бу күңелсез хәбәрне авылга Газзән китерде. Ул, атын шабыр тиргә батырып, басудан кайтты да,ияреннән төшмичә, Сәлимнәрнең капкаларын шакыды. Гадәттә үтә әкрен кыймылдаучан Газзән бу юлы капканы шундый ярсып дөбердәтте, Сәлим генә түгел, аның тирә-күршеләре дә өйләреннән йөгерешеп чыктылар.

Газзән вакыйганы берничә сүз белән Сәлимгә аңлатты да колхоз правлениесенә таба чаптырып китте.

Колхоз председателе Хәнәфи правление тәрәзәсеннән карап тора иде, Газзәннең килеп җитүен дә көтмичә:

– Ни булды, Газизҗан? – дип кычкырды һәм мыштым Газзән җавап бирергә өлгергәнче, «бүреләр...» дип уйлап алды.

Газзән, атын тәрәзә турысында туктатып, сулышын көч-хәл белән ала-ала:

– Бәла, Хәнәфи абзый... Атлар авырый башлады, – диде.

Хәнәфинең кашлары җыерылып, кара мыегы селкенеп куйды.

– Кайчан авырый башладылар? Нәрсә белән? Ничә ат?

Газзән, кояшта уңып беткән күлмәгенең җиңе белән маңгай тирен сөртә-сөртә:

– Өч ат... – диде. – Яктырткач күрдек. Карыйбыз: калтырыйлар, башларын салындырганнар.

– Кемнәр-кемнәр саклый идегез?

– Мин, Гапсаттар абзый...

Хәнәфи, Газзәнгә текәлеп карап, аның әйтеп бетерүен көтте. Ләкин Газзән һаман да сузды.

– Өченчегез кем иде? – дип ашыктырды председатель.

– Өченчебез Газинур иде дә...

Газзән, тагын әйтеп бетермичә, тыныч кына басып торган атының авызлыгын ачу белән тартып алды.

– Нишләде Газинур? Әллә төнлә кызлар янына кайтып киттеме?

Газзән караңгы чырай белән җавап кайтарды:

– Үзеннән сорарсыз әле, Хәнәфи абзый. Мин кеше өчен ответчик түгел.

– Сәлимгә әйттеңме?

– Әйттем.

Хәнәфи атларның кай тирәдә утлап йөрүләрен сорады да сәламәт атларны авыру атлардан аерып ераграк куарга кушты. Аннары, син бара тор, мин дә хәзер барып җитәм, диде. Газзән атына камчы белән орды һәм күз ачып йомганчы юк булды. Хәнәфи кәгазьләрен, җыеп, өстәл тартмасына ашыгып тыкты да борчылып башын күтәргән хисапчы кызга:

– Әлфия, Галәк бабайны тиз генә чакырып кил әле, – диде. – Хәзер үк ферма янына барсын.

Әлфия чулпыларын чыңлатып йөгереп чыгып китте. Хәнәфи кулын йомарлап ачу белән өстәл кырыена сукты: уракка төшәр алдыннан шул гына җитмәгән иде!

Ун минуттан соң Хәнәфи белән Галәк бабайны җиңел тарантаска җигелгән Чаптар Спасс сыртына җилтерәтеп алып менә иде инде. Уң кул якта – көтү, сул якта түбәләре ябыла башлаган яңа амбарлар күренеп калды. Башка вакыт булса, председатель төзүчеләр янына туктамый үтмәс иде, хәзер ул аларга күз генә төшереп алды.

Акыллы Чаптар колхоз председателенең холкына тәмам күнегеп беткән иде. Ул дилбегәне ничек тотуыннан ук хуҗаның кәефе яман икәнен сизде. Мондый чакларда Хәнәфи атны кызганып тормый, бөтен көченә куа.

Юл сикәлтәле. Тарантас коточкыч дөберди, Галәк бабай, төшеп калмасын өчен, бер кулы белән киез эшләпәсен тотып, икенчесе белән тимергә ябышып, тарантас түрендә биеп бара. Һәм:

– Хәнәфи энем, эчәгеләрем коелып төшмәсме икән? – дип, әледән-әле председательнең ярсуын басарга тырыша.

Бераздан аларга ике ягында игеннәр дулкынланып торган юл буйлап җан-фәрман чабып килгән ялгыз ат очрады. Ат иярләнгән булса да, ияре буш иде. Чаптар якынлаша башлагач, ул кире борылды һәм аның алдыннан чаба башлады.

– Кем аты бу? – дип сорады Хәнәфи, борчылып, тарантаска аягүрә басты. – Әллә Газзән атымы?

– Сәлимгәрәй ак атка атланып киткән иде. Аныкы түгелме?

Бу чыннан да Сәлим атланып киткән ат иде. Арыш арасыннан кинәт күтәрелгән ябалактан өреккән ат иярдә ныклап утыра белмәгән Сәлимне күз ачып йомганчы сыртыннан ташлады. Лап итеп юл уртасына килеп төшкән Сәлим, ни булганын белмичә, бака кебек җәйрәп ята иде. Ул бары тик: «Йә башым ярылды, йә арка сөягем сынды», – дип уйлап өлгерде. Ләкин юлда тояк дөпелдәвен ишеткәч, берәрсе күрмәгәе һәм таптап китмәгәе дип куркып, тиз генә урыныннан торды. Ул арышлар арасына посарга теләде, ләкин соң иде, аны күреп алдылар. Башта Сәлим өчен борчылып куйган Хәнәфи, ветфельдшерның тузанга буялып юл кырыенда карачкы кебек басып торуын күргәч, түзмәде, янында олы кеше булуга карамастан, каты итеп сүгенеп алды. Аннары, ачуын чак тыеп:

– Утыр, мәми! – дип кычкырды.

Такыр басуда аларны Газзән каршы алды. Ул, кулын каш өстенә куеп, килүчеләрне ерактан ук күзәтеп тора иде.

– Йә, ничек? – дип сорады Хәнәфи, кыска гына итеп.

– Начар, Хәнәфи абзый...

Атларның берсе бик сәер рәвештә ал якка сузылган аяклары өстенә яткан, икенчесе боегып башын салындырып тора, өченчесе шабыр тиргә баткан, ис тигән шикелле, авызын ачып, әледән-әле иснәп тора. Болар колхозның Кызыл Армиягә дип атап үстерелә торган иң яхшы яшь атлары иде. Аларның кызганыч хәлләрен күргәч, Ханәфинең йөрәге әрнеп китте.

– Нигә яхшылап карамадыгыз, Газзән! – диде ул каты шелтә белән. – Без сезгә ышанып торабыз, ә сез...

Ул, акланып маташа башлаган Газзәнгә кул селтәп, атлар янына атлады, аларның күзләрен, борын тишекләрен, авызларын карый башлады.

– Баштарак дуламадылармы, кем, Газизҗан? – дип сорады Галәк бабай.

– Юк, дулаганнарын күрмәдек. Иртәдән бирле шулай боегып торалар.

– Талпаннар, озын борыннар бик аптыратмадылармы?

– Юк, алай аптыратмаганнар иде, Галәк бабай.

Сәлим берни әйтә алмый бер аттан икенчесенә йөгерә иде. Хәнәфи аңа карап торды-торды да:

– Стой! – дип кычкырды. – Җен куасыңмы әллә. Атларда нинди авыру? Аларны коткарып калу өчен нәрсә эшләргә кирәк?

Сәлим калтырана башлады. Аның авызыннан чыккан сүзе аңлашылмый иде. Хәнәфи кулларын йомарлады.

Ләкин шунда ук үз-үзен кулга алып, әкренрәк тавыш белән:

– Суярга алып бармыйлар ич, нәрсә калтыранасың ул кадәр? – диде.

– Мин... мин... минемчә, Хәнәфи абзый...

Элекке пограничник Хәнәфи Сабиров саруны кайната торган мондый кешеләрне җаны-тәне белән куралмый иде. Шул ук вакытта ул үз-үзенә дә ачулы иде. Ни пычагыма ул шушы аяклы хәсрәткә түзеп торды? Әллә кайчан яңа ветфельдшер табарга кирәк иде.

Галәк бабай, эшләпәсе белән атны өркетеп, бераз йөртеп карады. Ат теләр-теләмәс, алпан-тилпән атлап шунда ук туктады.

– Ми авыруы булса кирәк, – диде ул янына килгән Хәнәфигә. – Аяк атлаулары алпан-тилпән. Руслар шатун диләр.

– Шатун булса, Галәк бабай, ат дулый, алга омтыла, стенага үрмәли, бәргәләнә-суккалана. Ә болар урыннарыннан да кузгалмыйлар.

– Төрлечә була ул, Хәнәфи энем. Кайчагында ат бик яман дулый, кайчагында тыныч кына да үткәрә. Бер елны шулай... – Ул бик күп тәҗрибәләрнең берсе турында сөйләп китте. Аннары, сүзен очлап, – Исаководан Гөргери Ивановичны чакыртырга кирәк, – диде. – Ул барысын да әйтеп бирер.

Болын ягыннан Газинур килеп чыкты. Аның тиргә манчылган ак күлмәге тәненә сыланган, яңа чалбары таушалып, балакларына ат төкләре, тигәнәкләр ябышкан, ботинкалары соры тузанга манчылган.

Хәнәфи, аның кыяфәтенә карап алгач ук, Газинурның төнлә кайда булганлыгына тәмам ышанды. Кинәт аның йөзе ачудан бүртенеп китте.

– Син нәрсә, шар күз, атлар саклыйсы урында кызлар янына чаба башладыңмыни?

– Гаеп миндә, Хәнәфи абзый, – диде Газинур, туры карап.

Газинурның гаебен танымавы Хәнәфине беркадәр уңайсыз хәлгә куйса да, ачуын баса алмады.

– Иелгән башны кылыч кисмәс дип, гаебеңне тиз генә танымакчы буласыңмы? Без әле синең белән сөйләшербез, энекәш! Ә хәзер утыр тарантаска.

Сәлим белән Газзәнгә атларны лазаретка алып кайтырга кушып, Хәнәфи үзе дә тарантаска менеп Галәк бабай янына утырды. Чаптар кузгалып китте.

Колхозга кайткач, Хәнәфи белән Галәк бабай тарантастан төшеп калдылар, Газинур шул ук атта Исаковога тирә-

якка атаклы карт ветфельдшер Григорий Ивановичны алып килергә китте.

– Тиз бул, – диде Хәнәфи, кисәтеп. – Пуля кебек оч! Правлениегә туктап та тормагыз, туп-туры лазаретка узыгыз. Эшләрең беткәч, минем янга керерсең.

Газинур, Чаптарны бөтен көченә юырткан хәлдә, берсеннән-берсе күңелсезрәк уйларга чумды. Утыз икенче елда да атларда шундый бер әшәке авыру таралган иде. Баштарак бу бәла каян килеп төште икән дип аптыраганнар иде, соңыннан моның колхозга сырышкан кулаклар эше икәнлеге беленде. Әллә нихәтле атны әрәм иттеләр алар ул чакта. Хәзер ул кулаклар колхозда юк югын, шулай да... Былтыр колхоз келәтеннән ашлык урладылар, аннан элекке елда язгы чәчүгә чыгасы көннәрдә генә кемнәрдер чәчкечләрне җимереп ташлаганнар иде. Газинур сискәнеп китте, ачудан куллары йомарланды. Эт этлеген итмәсә, эче күгәрә, ди бит. Әллә тагын... Газинур, шул әшәке эшкә очраклы рәвештә юл кую мөмкинлеген исенә төшергәч, баш сөягенә искәрмәстән китереп суккан кебек сызланып куйды.

Кичә ат каравыллап йөрүче Тавык Мортый авырып киткәч, бригадир Габдулла Газинурга каравылга чыгарга кушты. «Яктыртканчы әзрәк торырсың да кайтырсың», – диде. Бүтән вакыт булса, Газинур шулай иткән дә булыр иде. Ләкин кунакка гына кайткан Миңнурыйны бик сагынганлыктан, ул, Газзән һәм Гапсаттар абзый белән сөйләшеп, бераз торгач та авылга чапты.

– Бар, бар, үзебез карарбыз, – диде Гапсаттар, – кайсыбыз егет чакта каравылдан кызлар янына йөрмәгән...

– Озак тормам, бер-ике сәгатьтән әйләнеп тә кайтам, – диде Газинур.

Ләкин бер-берсен яраткан кешеләр вакыт үткәнен сизәләрмени. Газинур Миңнурый яныннан чыкканда, яктыра башлаган иде инде. Күңеле нәрсәдер сизенгәнгә, яңа киемнәрен дә алмаштырмыйча, кырга чапты. Ләкин...

Үз-үзен өзгәләргә җитешкән Газинур атын тагын да кызурак куды.

Григорий Ивановичның йорты авыл уртасында иде. Газинур аның сырлап эшләнгән борынгы капкасы төбенә атын боруга, күзлек кигән тәбәнәк кенә буйлы бер карт ишегалдына чыкты. Бу Григорий Иванович үзе иде. Газинур, бик борчылып, йомышын сөйләп биргәч, ул өенә кереп китте. Бераздан әйләнеп тә чыкты. Аның өстендә юл плащы, башында ак фуражка иде. Кулына кечкенә генә чемодан да тоткан.

– Кузгалдык, – диде ул, тарантаска менеп утыргач.

Берничә минут ял итеп өлгергән Чаптар, башын чайкап, юыртып китте.

– Үз ветфельдшерыгыз берәр җиргә китеп бардымы әллә? – дип сорады Григорий Иванович.

Кузлага утырган Газинур артына борылып җавап бирде:

– Аны бар диден ни дә, юк диден ни, Григорий Иванович. Исәпкә бар, санга юк безнең ветфельдшер.

Юл түбән таба төшкәнлектән, Газинур дилбегәне ныграк тотты. Авылны дөбер-шатыр китереп, түбән очтан тракторлар колоннасы менеп килә иде. Алгы тракторда Газинур Исхак Зәбировны күрде. Зәбиров, елмаеп, трактордан аңа кул болгады. Бу юлы ул яланбаш түгел, кызлар киеп йөри торган куе зәңгәр береттан иде. Газинур күңеленнән: «Иптәш Зәбиров гомердә дә минем кебек ахмак эш эшләмәс иде», – дип уйлап алды.

Григорий Иванович үз сүзен дәвам иттерде:

– Шулай да сезнең ул егетегез үзен зурга санап йөри, ахрысы. Мин аңа, яңалыклар белән танышырга кил, бик әйбәт китаплар алып кайттым, дигән идем – килмәде.

Карт, кесәсеннән кулъяулык чыгарып, ап-ак мыекларын, көмеш сакалын сыпырып алды.

– Аны булдыра ул, Григорий Иванович, – диде Газинур, ачы көлемсерәп. – Мин беләмлек безнең Сәлимдә вагоны белән бар.

Сынын гаҗәп дәрәҗәдә туры тотып, үзенә бертөрле олылык белән тарантас түрендә утырган Григорий Иванович кузладагы Газинурга сынаучан караш ташлады.

– Яшь кешегә алай килешми ул. Безнең халык койрыкка тагылып йөрүчеләрне яратмый.

Газинур чөңгереп куйды. Ат яңадан бик кызу чаба башлады. «Красногвардеец»та туктамыйча гына үтеп киттеләр. Лазарет фермалардан читтә, махсус эшләнгән бер абзарда иде. Газинур атны шунда таба борганда, аларга болыннан кайтып килүче кызлар очрады. Кызлар арасында Миңнурый да бар иде. Газинурны күргәч, ул иптәшләренә нидер әйтте, тегеләр барысы да пырхылдашып көлеп җибәрделәр. Ләкин Газинур алар яныннан күңелсез генә юыртып үтеп китте. Хәтта Миңнурыйны күрү дә бу юлы аны шатландырмады.

Лазаретка килеп җиткәч, Григорий Иванович тиз генә тарантастан төште дә өс киемен салып ташлады. Каршы чыккан Сәлимгә баш иеп, «исәнмесез» диде һәм, ашыгып, ничектер ян беләнрәк атлап, абзарга кереп китте. Газинур ат янында калды. Хәзер аның борчылулары бермә-бер арткан иде. Аның миен кызган энә шикел-

ле бер уй чәнечкәли: әллә чыннан да берәрсенең этлегеме?

Ярты сәгатьләр чамасы вакыт үткәч, Григорий Иванович абзардан чыкты. Ул ачулы иде.

– Сез хаклы түгел!.. – диде карт ветфельдшер, кулын селтәп. – Бөтенләй! Күрәм, сез берни аңламыйсыз. Галәк бабай дөрес әйткән, атларда энцефаломиэлит. Гади телдә аны шатун диләр яки ми авыруы.

– Ә сәбәбе? – дип сорады Сәлим, куркып. Чөнки мие авыручы атларның ике-өч көннән һәлак булырга тиешлеген ул азмы-күпме белә иде. Әгәр атлар үлсә, иң элек аңардан җавап сораячаклар.

– Сәбәбе күп аның. Йогышланган азык, су, талпаннар, озынборыннар, кигәвеннәр... Азмыни. Инфекциянең авыру атлардан таралуы да сезгә сер түгелдер. Аннары... – Карт сүзен әйтеп бетермичә плащын кия башлады. Тарантаска менеп утыргач, имән бармагын күтәреп өстәп куйды: – Минем киңәшләремне онытмагыз: кичекмәстән дезинфекция ясарга керешергә кирәк. Сәламәт атларны сакларга кирәк! Мин председателегез белән сөйләшермен.

Газинур үзен борчыган сорауны бирергә ашыкты.

– Әйтегез әле, Григорий Иванович, бу гади бер чирме, әллә?..

Карт аңа күзлек өстеннән карап торды да:

– Әйтүе кыен, – дип тирән сулап куйды. – Һәрхәлдә, күңелсез вакыйга.

Шуннан соң, правлениегә килеп җиткәнче, Григорий Иванович бер сүз дә дәшмәде. Ул күзләрен йомып, гүя йокымсыраган шикелле утыра иде. Газинур сорашасы сүзләре күп булса да, сүз ачарга батырчылык итмәде.

Чаптар правление каршына килеп туктауга, Григорий Иванович гаҗәп җиңел генә тарантастан сикереп төшеп правлениегә кереп китте. Газинур, атны күләгәгә илтеп, коймага бәйләп куйды. Аннары тәмәке тарта башлады.

Аның янына Миңнурый йөгереп килде.

– Газинур, сиңа ни булды? Нигә төсең качкан? – диде ул, борчылып, һәм, ярдәм итәргә теләгәндәй, Газинурның кулыннан тотты.

Газинур атлар турында сөйләп бирде. Григорий Ивановичның сүзләреннән соң бигрәк тә каты кайгыга төшүен әйтте.

Миңнурый чәч толымын бер сүтеп, бер үреп, эндәшми тыңлады, аннары тирә-ягына каранып алды да, әкрен генә:

– Газинур, син миңа ачуланасыңдыр инде? – дип сорады.

Газинур гаҗәпләнеп аңа карады.

– Нишләп мин сиңа ачуланыйм ди, Миңнурый? Моны каян алып әйтәсең? Үз гаебемне кешегә сылтый торган гадәтем юк иде бугай минем.

– Алай булса, син Хәнәфи абыйга барысын да яшермичә сөйләп бир.

– Ул инде барысын да белә.

– Ни әйтте?

– Кыздырды. Гапсаттар абзый белән Газзән абыйга да эләкте. Миңа, эшләреңбеткәч, тагын кереп чык, диде.

Ишек ачылды. Анда Григорий Иванович белән Хәнәфи күренде. Миңнурый ялт өй артына кереп китте.

– Дезинфекцияне үзегез тикшерерсез, – диде Григорий Иванович, – мин кушканнарны төгәл эшләгез. Иртәгә тагын килеп карармын. Алай-болай булса, ат җибәрегез. Хушыгыз.

– Хушыгыз, Григорий Иванович, – диде Хәнәфи, картның кулын кысып. – Бик зур рәхмәт сезгә. Борчуыбыз өчен гафу итегез.

– Нинди борчу ул... Кулымнан килгән ярдәмне күрсәтергә һәрвакыт әзермен...

Кичкырын, ветфельдшерны Исаковога озатып куйганнан соң, Газинур амбарлар каршында җыелган колхозчылар янына килеп утырды. Биредә дә сүз авыру атлар турында бара иде.

– Дөнья булгач, атлар түгел, кешеләр дә чирли, үләләр дә, – диде муенына сөлге ураган Мортый. – Удивительный хәл түгел. Менә Батуринда ике башлы бозау туган, ди, анысы менә дисвительно удивительно.

Ул теш арасыннан черт итеп төкерде дә көлә башлады. Ләкин аңа берәү дә кушылмады. Газинур исә бу кешене элек-электән үк яратмый иде. Аның сүзләре һәрвакыт Газинурның ачуын кабарта иде.

– Мыек чуалтып утырма әле, Тавык! – диде ул аңа ачу белән. – Кулак сүзләрен такылдыйсың ич.

Кошчылык фермасында эшләгән чагында йомырка урлап тотылганнан соң калган «Тавык» дигән кушамат Мортыйны чамадан тыш гарьләндерә иде. Ул урыныннан сикереп торды да, этәчләнеп, Газинур каршына килеп басты.

– Авызың сөйләгәнне колагың ишетсен, понимаешь! – дип кычкырды, бүреген җилкә чокырына этәреп. – Нинди кулак бар хәзер бездә?! Әнә алар Себердә чери. И черессннәр дә! Ничәмә-ничә мең чакрымнан кулак сүзе ишетелә, ди. Ахмак.

– Сүз иясе белән йөрми, – диде Газинур тыныч кына.

Тавык Мортый, кулын бөеренә куеп, көлә башлады.

– И-и, энем, энем! Әзрәк үсә төш, шуннан соң кешеләргә акыл өйрәтерсең, яме. Югыйсә авызыңда әниеңнең сөте дә кипмәгән бит әле.

– Әни сөте кибәр, менә колхоз фермасыннан урлап эчкән йомырканың Мортый иреннәренә ябышып калган сарысы кибәрме?

Шунда көтелмәгән бер хәл булып алды. Тавык Мортый, үзе дә сизмәстән, җиң очы белән авызын сыпырып куйды. Моны күргәч, амбар янындагы бөтен кеше шаркылдап көлеп җибәрде.

– Каракның бүреге яна дигәннәр иде, дөрес икән!

– Эшең бетте, Тавык, – диде икенче бер колхозчы, – хәзер йоныңны йолкыйсы да казанга саласы гына калды.

Мортый, муенына ураган киҗүле сөлгенең ике башыннан тотып, дулый-дулый, Газинур алдында тыпырчынды:

– Юк, шалишь, браток! Син үзеңне бел! Минем атлар саклаган җирдән кызлар янына шылганым юк. Мин саклаганда бер генә атка да җил-яңгыр тидертмәдем. Ә син саклаганда...

Мортыйның ачы, ләкин урынлы сүзләренә каршы нинди дә булса җавап табу кыен иде. Билгеле, Газинур монда үзе генә түгел, Гапсаттар белән Газзән дә гаепле дип аклану юлын эзләмәде. Ләкин Тавык Мортый үчекләрлек хәлгә калуыннан бик нык гарьләнде.

– Бер тапкыр абынганмын икән, анысы өчен җавап бирермен. Менә син көн дә абынасың, бер тапкыр да җавап бирмисең. Ләкин онытма: кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә!

Газинур урыныннан торды һәм Хәнәфи янына китте.

Правлениегә якынлашкан саен, Газинурның адымнары әкренәя, башы иңнәренә тирәнрәк бата барды. Гаебе булса, тикшерерләр дә тиешле җәзасын бирерләр. Анысы Газинурны аз борчый, ә менә Тавык Мортыйлар рәтенә төшү, аларның телләренә эләгү, халык каршында ышанычыңны югалту – болары инде саф күңелле Газинур өчен аерата авыр иде. Бүген ул көне буе авызына бер генә валчык та капканы юк, ләкин үзе карыны ачлыгын да сизми. Маймылны аксаткан өчен Зәйтүнә малаен орышкан булды, Сәлимнән көлгән булды, ә үзе... Ачык авыз син, Газинур, йонлы колак син, Газинур! Егет, имеш, сөйгән кызы янына чаба, имеш. Ахмак!

Шул ачы уйларга чумып килгән Газинур, правление каршында райком машинасын күргәч, туктап калды. Аннары, Хәнәфи абый янында кеше бар икән, соңрак керермен дип, кире борылып китте. Кая барырга? Өйгә кай-

тасы килми. Әллә авыру атларны тагын бер карап килергәме? Үлмәсәләр генә ярар иде мескеннәр. Колхозның иң шәп яшь атлары бит. Григорий Иванович әйтә, ми авыруы өч көнгә сузыла, ди, шуннан ат йә үлә, йә төзәлә башлый. Өч көн! Моңарчы Газинур көннәр үткәнен бөтенләй сизми иде. Ә хәзер минуты – ай, сәгате ел булып тоела аңа.

– Менә ул безнең өч батырның берсе! – дигән мыскыллы тавышка Газинур башын күтәреп караса, аның алдында Хәнәфи белән Гали абзый басып торалар. Гали абзыйны күргәч, Газинурның йөрәге жу итеп китте. Ул Гали абзый Бөгелмәдә дип уйлый һәм ыгы-зыгы эчендә аның турында бөтенләй оныткан иде.

Йөк машинасы белән Баулыдан кайтып төшкән бригадир Габдулланы күргәч, Хәнәфи тиз генә аның янына китеп барды.

– Ничек булды соң бу эш, Газинур? – дип сорады Гали абзый, конный двордагы буш арбага утырып.

Газинур аның алдында башын иеп басып торды. Хәнәфинең «өч батыр» дип бу囗 эштә Гапсаттар белән Газзәннең дә бертигез җаваплы икәнлегенә ишарә ясавына карамастан, Газинур Гали абзыйның соравын, гомумән, вакыйгага карата түгел, үзенә карата гына аңлады.

– Тилелек белән эшләдем, Гали абзый. Хәзер үзем дә үкенәм, ләкин үткән эшне кайтарып булмый.

Гали абзый озак кына вакыт эндәшми торды. Ул, кашларын җыерып, каядыр читкә текәлгән. Газинур исә, аска карап торганлыктан, Гали абзый һаман да аны күзәтә дип исәпли, аның йөрәк әрнүе торган саен көчәя бара иде. Ахырда ул түзмәде, башын күтәрде һәм, Гали абзыйга туры карап:

– Гали абзый, киләчәктә мин акыллырак булырмын. Ә монысы өчен бер-ике тапкыр яңак төпкә утыртыгыз! Сабак булсын мин юләргә, – диде.

Гали абзый аңа кашларын җыерып карап алды. Газинур моңарчы аның күзләре бу кадәр рәхимсез ялтыравын һичкайчан күргәне юк иде.

– Син, Газинур, юләргә салынма әле, – диде ул, коры гына итеп. – Нинди зур җинаять эшләгәнеңне беләсеңме? Син бит постыңны ташлап киткәнсең. Ә дошман синең кебек алдын-артын уйламый йөрүчеләргә шат. Аңа шул кирәк тә... Чөнки яхшы атны үстерү өчен өч-дүрт ел вакыт кирәк булса, юк итү өчен берничә минут җитеп тора.

Бу сүзләрдән сискәнеп киткән Газинурның күз алдына Тавык Мортый килеп басты. Ул аның сүзләре турында Гали абзыйга әйтергә теләде, ләкин теле әйләнмәде.

– Шуннан соң инде син бер-ике тапкыр яңак төпкә салу белән котылмакчы буласың, – дип, Гали абзый тагын да катырак сүзләр әйтә башлады. – Юк, Газинур, бик кечкенә җәза сайлагансың үзеңә. Син бу ахмаклыгыңны яңадан һичкайчан кабатланмасын өчен йөрәгеңә уеп куярга тиешсең. Бу вакыйга сиңа гомерлек ачы сабак булырга тиеш. Аңладыңмы?

– Аңладым, Гали абзый.

Газинур тагын бер-бер сүз әйтмәсме дип, Гали абзый бераз эндәшми утырды. Ул ахырдан гына булса да Газинур гаебен җиңеләйтү өчен Газзән белән Гапсаттарны телгә алыр дип көткән иде. Ләкин Газинур артык берни дә әйтмәде. Күрәсең, ул бөтен гаепне үз өстенә алырга уйлый. Егетнең бу сыйфаты Гали абзыйга ошады булса кирәк, ул бөтенләй икенче тавыш белән:

– Ярый, бар, кайт, – диде.

Гали абзыйдан аерылгач, Газинур туп-туры чишмә янына барды, боз кебек салкын суга башын тыкты. Шунда чиләк тавышы ишетелде. Иңенә көянтә салган Миңнурый, куркып һәм борчылып, аңа карап тора иде. Газинур юеш чәчләрен кулы белән артка сыпырды. Эңгер-меңгер яктысында Миңнурыйга ул ябыгып киткән күк тоелды. Аның эчке куркуы тагын да көчәйде. Ләкин тыштан гадәтенчә салкын калды.

– Син нишләп монда чишмә пычратып йөрисең?! – диде ул коры гына.

Газинур елмайды.

– Гали абзыйның мунчасы бик эссе булды, чак янмадым.

Бу сүзләр Миңнурыйны бөтенләй кызыксындырмаган кебек:

– Хәнәфи абзый белән сөйләштеңме? – дип сорады.

– Хәнәфи абзый хәйләкәр ул. Башта мине Гали абзыйга тотып бирде, аннары үзе каезлаячак.

Миңнурый чишмәдән су чумырып алды да китә башлады. Аннары, туктап, кулбашы аша гына:

– Бүген минем яныма килеп йөрмә! – диде һәм авыр чиләкләрдән бераз сыгыла төшеп китеп тә барды.

## 6

Колхоз председателе Хәнәфи Сабиров правлениедә Сәлим белән сөйләшеп утыра иде. Икенче өстәлдә ал яулыгын колак артына кысып бәйләгән хисапчы кыз Әлфия, җитен чәчәге төсле зәңгәр күзләрен кәгазьләр өстеннән җитез генә йөртеп, ниндидер квитанцияләрне тикшерә.

Ара-тирә тәрәзәгә күз салгалый, колагындагы тамчылы алкаларга охшаган тамчылы гөлләргә карап сөенә.

Әлфиянең өстәл тирәләре генә түгел, бөтен идарә бүлмәләре бик пөхтә итеп җыештырылган, һәрнәрсәдә уңган кыз кулы сизелеп тора. Стенадагы рәсемнәр кыр чәчәкләре белән бизәлгән. Тәрәзә пәрдәләре ап-ак, каршыда төрле плакатлар, диаграммалар эленгән. Алар күп басулы кырлар турында, уңышны күтәрү, терлекләрнең нәселләрен яхшырту, якын киләчәктә төзеләчәк яңа фермалар, колхоз клублары, колхоз электростанцияләре турында сөйлиләр.

Бу җыйнак, матур, якты бүлмәгә килеп кергәннән соң, кешеләр үзләрен ничектер олырак, яхшырак хис итәләр һәм, башын иеп, счет төймәләрен әкрен генә шалтыратып утырган яшь кызга ымлап:

– Әллә Әлфия үзе матур, әллә бүлмәсе матур? – диләр, ә шаянраклары: – Кем бәхетенә үсә икән бу йөзек кашы кебек кызыбыз? – дип өстиләр. Кайчакта берәр карт Әлфиянең өстәле янына якынрак килеп утырса, икенчесе, көлеп: – Тукта әле, Котбетдин абзый, синең малаең юк, син читтәрәк торып торсаң да ярый, мин малайлы кеше, Әлфиягә мин якынрак утырыйм, язган булса, язга киленлеккә алырмын, – дип куя иде.

Әлфия, колхоз председателе Хәнәфи белән Сәлимнең сөйләшүен бер колагы белән тыңлый-тыңлый, зур кенәгәне алдына салып кулына каләм алган чакта, ишек ачылып, Газинур күренде. Ул һәрвакыттагы кебек шаугөр килеп керде, ишек төбеннән үк Әлфиягә шаян сүз әйтеп аны тәмам кызартты, председательгә кул бирде, ә Сәлимгә:

– Акт төзедеңме? – диде.

– Сабыр ит, Газинур, без әле сөйләшеп бетермәдек, – диде Хәнәфи, аны туктатып.

Газинур Әлфия өстәле янына утырды да, председательнең Сәлим белән сөйләшеп беткәнен көтә-көтә, тәмәке төрә башлады.

– Әлфия, – диде ул, кызга әкрен генә, – тартырга ярыймы, төтеннән гөлләрең гыйшык тоткан яшь кызлар кебек саргаймасмы?

– Китсәнә, Газинур абый, гел шаяртасың. Әнә тәмәке тартырга ярамый дип язып куелган ич.

– Мин ул язуыңны күрмим шул, күзлегемне өйдә онытып калдырганмын.

Газинур үзенең ни өчен чакырылганлыгын белми иде әле. Соңгы атнада ул гел кырда, атлар янында булды. Григорий Ивановичның һәм Бөгелмәдән махсус килгән

зоотехникларның ярдәме белән колхозның бүтән атларын йогышлы чирдән саклап калдылар. Авыру атлар да сәламәтләнеп киләләр иде инде. Бу турыдагы шау-шу да ничектер үзеннән-үзе басылды. Ләкин бүген үзен правлениегә чакыргач, бигрәк тә биредә Сәлимнең дә утыруын күргәч, Газинур бу мәсьәлә яңадан кузгала икән дип уйлап алды һәм, шул турыда кызыксынып, Хәнәфинең сүзләренә колак салды.

Хәнәфи Сабиров сөйләгән чакта еш кына хәрби сүзләр кыстыра. Кайчагында командовать итүдән дә тартынмый, әйттем – бетте! дип кырт кискән чаклары да булгалый. Ләкин күбрәк җитди, төпле сөйләшә, олыларга хөрмәт, ихтирам күрсәтә, үз тиңнәре белән, бигрәк тә яшьрәкләр белән эреләнми.

– Шулай, Сәлим туган, – диде Хәнәфи, егетнең саргылт күзләренә туры карап. – Правление сине ветфельдшерлыктан азат итәргә булды. Ни өчен икәнен үзең беләсең, үпкәләргә урын юк. Осечка булган икән, аны берничек тә яшереп булмый. Ләкин мин синең турыда күп уйладым. Синең киләчәктә дә ни алма, ни хөрмә булып калуыңны теләмим. Менә илебезнең социалистик төзелешләренә кешеләр сорап кәгазь килде. Әллә барасыңмы? – дип сорады һәм Сәлимнең йөзенә бәреп чыккан икеләнүне күреп өстәде: – Уйла! Син яшь кеше. Дөнья күреп тә кайтырсың. Күпкә түгел, бер елга. Ә бер елга, энә Газинур әйтмешли, куян тиресе дә түзә.

Хәнәфи җавап көтеп тынып калды. Газинур бернәрсә дә аңламады. Атлар турында бер сүз дә юк иде.

– Бик рәхәтләнеп барыр идем, Хәнәфи абый, – диде Сәлим, аңа карамаска тырышып, – бик рәхәтләнеп, ләкин син беләсең бит, минем... сәламәтлек шәп түгел... Шуның аркасында укудан да киттем, аннары мин...

– ...Миңнурыйга өйләнергә йөрим, – дип кыстырды Газинур тиз генә.

Хәнәфинең кара мыек астындагы иреннәре елмайгандай булды. Ләкин Газинурга бармак янады. Тик утыр, янәсе, синнән сорамыйлар.

– Моңарчы мин синең авыру икәнеңне белмидер идем, – диде Хәнәфи Сәлимгә. Газинур аның күзләрендә шаян чаткылар биешеп алуын күрде. – Нәрсә белән чирлисең соң, энем?

Сәлим, ни дип җавап бирергә дә белмичә кызарып, аска карап утырганда, яңадан Газинурның чәнечкеле тавышы ишетелде:

– Аның сырхавының исемен, Хәнәфи абый, Әлфия алдында әйтергә ярамый. Тышка чыгып сора.

Сәлимнең әйтерсең яңагына суктылар. Ул урыныннан сикереп торды. Йөзе комач кебек кызарды, салынкы иреннәре калтырый башлады, Газинурның аны мыскыл итүе, Әлфия алдында аның егетлеген юкка чыгарып ташлавы Сәлимне җир ярылса, җир тишегенә керердәй хәлгә китерде. Йөрәге ачудан ярылырдай булып типте. Ул Газинурны баскан җирендә үтерерлек сүз эзләде. Ләкин таба алмады.

– Д-д-дуңгыз көтүчесе! – диде ул, тотлыгып.

Газинур көлеп җибәрде.

– Туры сүздә оят юк, Сәлим. Булсын иде колхозның «чибәр маллары» күбрәк, Хәнәфи абый, ә? «Прогресс» колхозы алардан йөз мең доход ала! Колхозга йөз мең табыш китергән нәрсәдән мин нәҗес дип тартынып тормас идем.

Председатель көздән «Красногвардеец»та да «чибәр маллар» фермасы булдырачагын әйтте дә Сәлимгә борылды:

– Ярар, энем, хәзергә шуның белән сүзне тәмамлыйк. Иртәгә докторга күренеп кайтырсың. Әнә Әлфия язу бирер. Әгәр дә чынлап та строевой службага ярамыйсың икән, что ж, җибәрмәбез. Бездә халык бетмәгән.

Бу инде чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, Сәлимне тәмам юк итте. Ул беркемгә дә карамыйча, өстәл кырыендагы эшләпәсен дә алмыйча чыгып китте.

– Ну, хур иттең егетне, Газинур, – диде Хәнәфи, көлүеннән тыела алмыйча. – Җитмәсә, Әлфия алдында.

– Газинур абыйның шул инде, – диде Әлфия, кызарып. – Үзе яратмаган кешесен һәрвакыт кеше күзенә күренмәслек итә.

– Кара, кара, Хәнәфи абый, ничек яклый бу егетен, – диде Газинур, председательгә күз кысып. – Мә, алайса, Әлфиякәем, егетеңнең эшләпәсен илтеп бир. Әйт: башын югалтып йөрмәсен, кирәк булыр әле.

– Ярар, Газинур, – дип бүлдерде аны Хәнәфи, – инде синең белән сөйләшик, ни өчен чакыртканымны беләсеңме?

– Белүен белмим, Хәнәфи абый, ләкин сизенәм, – дип җавап бирде Газинур һәм көлемсерәп куйды.

– Сизенәсең? – Хәнәфи, башын кыйшайта төшеп, уң күзен кысты.

– Каядыр эшкә җибәрергә исәбең бар шикелле, Хәнәфи абый. Таш кисәргәме, урман кисәргәме? Әллә шахтага күмер чабаргамы? Шахтага булса, барыр идем мин. Әлфия, ничек әле шахтер көе? «Шахтер егет күмер чаба...»

«Чыннан да сизенгән бит, шельма!» дип эченнән сөенеп уйлап алды председатель. Дөресен әйткәндә, Хәнәфинең Газинурны колхоздан читкә җибәрәсе килми иде.

Яхшы эшләүчеләр колхозда да бик кирәк. Бу турыда ул Гали абзый белән дә киңәште. Ләкин Гали абзый читкә китүчеләр исемлегенә Газинурны үзе тәкъдим итте.

– Шәһәр күреп кайтса, бу егет колхозның тоткасы булачак, – диде.

Хәнәфи тырыш эшчеләр колхозга да бик кирәк дигәч, Гали абзый ашыкмый гына, һәр сүзен уйлап, җентекләп:

– Без, Хәнәфи дус, кешеләргә колхоз күзлегеннән генә түгел, дәүләт күзлегеннән дә карарга өйрәник, – диде. – Менә бер-ике елдан синең колхозыңа берничә механик яки электрик, яки бүтән һөнәр осталары кайтып төшсә, начар булачакмыни. Хәзер бит синең бөтен эшкә бер тимерчең бар. Ә колхозга кимендә механик кирәк. Ул чагында яңа урак машинасын көйләр өчен Бөгелмәгә барып слесарь эзләп йөрергә туры килмәс иде бит. Шулаймы? Ә урак машинасы колхозның гади бер эш коралы гына. Тиздән синең движогың, ашлык сугу машинаң, электростанцияң, радиоузелың, телефон узелың, тагын әллә нәрсәләрең булачак. Юк, Хәнәфи дус, һөнәргә өйрәнеп кайткан кешеләр бик кирәк. Киләчәктә алар колхозның төп әйдәүчеләре булачак. Перспективаңны югалтма, дус, алга карап эш ит!

Бу сүзләр белән Хәнәфи килешергә мәҗбүр булды.

– Дөрес сизенгәнсең, Газинур, Туган ил төзелешләренә бездән кешеләр сорыйлар, – диде Хәнәфи, егетнең көләч йөзеннән күзен алмыйча. Сәлим белән сөйләшүдән соң аның күңелендә утырып калган ямьсез юшкын әкренләп бетә башлады. – Ләкин шахтага түгел, таш кисәргә дә түгел. Урман кисәргә. Барасыңмы?

– Бармыйммы соң, Хәнәфи абый, – диде Газинур, уйлап та тормастан. – Тик бер нәрсә сорар идем, Хәнәфи абый: картлар, юлга чыкмас борын юлдаш сора, йорт алмас борын күрше сора, дигәннәр. Йортым бар, күршеләрем яхшы, юлдашларым кем булыр – шуны беләсем килә.

– Телең чыптадан булса, әллә кайчан тузып беткән булыр иде, Газинур, – диде Хәнәфи, кычкырып көлеп. – Гарәфи абзый, Һашим, Газзән барабыз дип әле яңа гына чыгып киттеләр.

– Гарәфи абзый белән Һашим булгач, мин калмыйм. Кайсы якка, кайчан китәргә?

– Уралга, Соликамск урманнарына. Атна-ун көндә юлга чыгарга.

– Шушылай тиз үкмени? – дип, бераз исәпкә калыбрак сорады Газинур. – Нигә көздән түгел? Урып-җыю вакыты якынлаша бит. Без китсәк, кыен булмасмы соң, Хәнәфи абый?

– Ротада бер отделение ким булса, билгеле, кыенга килә, Газинур. Әмма бурычны барыбер үти. Социалистик төзелешләргә булышмыйча ярамый бит. Әгәр колхоз үз ягын гына, завод үз ягын гына каерса, без ерак китә алмабыз. Шәһәр безгә нихәтле машина бирә. Әле кайчан гына сез Һашим белән җилгәргеч алып кайттыгыз. Бүген менә безгә яңа чәчкечләр кайткан дип хәбәр килде.

– Яңа чәчкечләр?!

– Әйе, якын көннәрдә тагын салам, печән турый торган станоклар кайтачак.

Газинур белән Хәнәфи шулай ипле генә сөйләшеп утырганда, Тавык Мортый килеп керде.

– Можномы, Хәнәфи абый? – диде ул һәм, алпан-тилпән атлап, председатель янына килде. Ул кызмача иде. Ике такта арасына салып изелгән шикелле тар йөзеннән тир ага, күлмәк изүен кендегенә кадәр ерып җибәргән, чалбары төшәм-төшәм дип тора, яланаягында чалшаеп беткән сандали.

– Хәнәфи абый, городка рабочийлар сорыйлар икән дип ишеттем. Мине җибәр! – Ул, кулларын йомарлап, күкрәген киереп басты. – Любой һөнәрне булдырам.

– Мин сине чакыртмадым бит, – диде Хәнәфи, кашларын җыерып. – Эчкәнсең икән, эш калдырып кытаклап йөрмә.

– Мин эчкәнме? Не верно! Минем йөрәгем яна, йөрәгем! – Ул, йөзен сытып, йодрыгы белән күкрәгенә суга башлады. – Йөрәгем... Нигә мине беркая да җибәрмисез? Што мин? Шадра Газинурны чакыртып, түргә утыртып сөйләшәләр, ә мине... ух!..

– Сабыр ит, синең чиратың да килеп җитәр әле. Ә хәзер кайтып йокла. Айныгач, ни өчен эшкә чыкмавың турында килеп әйтерсең.

– Миңа китәргә ярыймы, Хәнәфи абый? – дип сорады Газинур.

– Ярый, бар. Әтиең һәм туганнарың белән киңәш. Аннары миңа кереп соңгы сүзеңне әйтерсең.

Газинур тышка чыкканда, күк йөзен болытлар каплый башлаган иде. Ләкин, күңелендә артык якты булганга, Газинур төньяктан ургылып-ургылып килгән кара болытларга игътибар итмәде. Алда яңа шәһәрләр, заводлар... Газинур кебек гомерендә Бөгелмәдән башка шәһәр күрмәгән, бер генә тапкыр да поездга утырмаган егеткә моннан да кызыклырак, моннан да бәхетлерәк көннәр булырмыни?! Колхоз председателе үзе тәкъдим иткәч ничек бармаска. Нинди юләр бу Сәлим. Бүтән берәү булса, бар авыруын яшереп тә китәргә тырышыр иде. Ә ул...

Юньсезне син табакка төртсәң, ул тагаракка тартыр, дигәннәр. Нәкъ үзе! Әмма дә Газинур аны шәп сыптырды. Гомере буенча онытмас.

Кинәт Газинурның башына шикле бер уй төште. Бу сырхантай миннән ераграк карамыймы икән? Мин китәрмен, ә ул Миңнурый белән...

Газинур үзенең күңелендә бүтәннәргә карата инә очы хәтле дә кер булмаганга, башкаларның да күңеле шундый ук сафтыр дип йөри иде. Колхозга кергәннән соң, тормыштагы бөтен нәрсә ярыйсы туры, аңлаешлы булып киткән кебек, мәхәббәт тә, аныңча, шушындый туры, ачык булырга тиеш шикелле тоела иде. Ә аның көнләшү дигән көзге чебене дә бар икән әле.

«Тукта, чынлап сөяме соң бу татлы торма, әллә сөйгән булып кылана гынамы?» – дип, тагын да тирәнрәк хәвефкә төште Газинур. Ләкин, кичә Миңнурыйның күкрәгенә башын куеп торуларын, атлар авырган чакта Газинур өчен никадәр борчылуларын исенә төшергәч, аңа үзенең бу шикләнүләре бик әшәке булып тоелды. Ул, Миңнурыйны җәберсеткән кебек оялып, Гали абзый йортына таба карады. Тәрәзәләр ачык, тәрәзә төпләрендә чүмеч гөлләр. Әнә Миңнурый үзе дә. Ул ишегалдында бауга эленгән керләрне кочагына җыеп йөгереп йөри. Озын чәче үрелмәгән. Күрәсең, бик ашыгып чыккан. Көчле җил шул үрелмәгән чәчен, күлмәк итәген җилфердәтә.

Бер минуттан Миңнурый йөгереп кереп тә китте, һәм шуның артыннан ук яшен яшьнәп, бик каты күк күкрәп куйды. Газинур, аптырап, башын күтәрде. Бөтен күк йөзе күгелҗем кара болыт белән капланган. Һава тәмам караңгыланган.

Яңадан яшен яшьнәп, бик каты күк күкрәде. Нәрсәдер чатнап китте. «Кайдадыр яшен сукты», – дип уйлады Газинур һәм өермәләр бөтерелеп уйнаган киң урам буйлап ат абзарларына таба йөгерде.

Ул ат абзарлары ишегеннән кергәндә, тагын яшен яшьнәп китте. Уртада тар юл калдырып, ике якка һәр ат өчен аерым-аерым араннар тезелгән бик озын абзар эче кинәт яп-якты булып китте, сагаеп башларын күтәргән атлар, аргы очта кулына көрәк тотып баскан Сабир бабай һәм берничә хатын-кыз бер генә секундка күренеп калды. Шуның артыннан ук, таулар ишелгән сыман, тагын күк күкрәде. Газинур, башын иңнәренә батырып, ихтыярсыздан артка тайпылды. Яшен ат абзарын суккан кебек тоелды.

Бүтән атлардан аерып, такта белән бүленгән аранда торучы алмачуар айгыр, күк күкрәгән саен, ярсып дулый

һәм стенага беркетелгән тимер чылбырны өзәргә азаплана иде. Ул арада абзарның аргы башыннан Сабир бабай кемнәргәдер:

– Ишекләрне ябыгыз, ишекләрне! – дип кычкырды.

Тагын яшен яшьнәп, күк күкрәде. Ишек ябарга йөгергән хатын-кызларның берсе, кинәт илереп, юл уртасына чүгәләде. Бөтенләй якында гына нәрсәдер лап итеп килеп төште, күрәсең, давыл кайсыдыр өйнеңме, сарайныңмы түбәсен кубарып ташлады. Түбә саламнары урам буйлап бөтерелеп очарга тотынды.

Аннары абзар эче яңадан яп-якты булып китте. Ярыклардан, тишекләрдән күктәге сынгаланган яшен утының селкенеп торулары күренде. Абзар уртасында чүгәләгән хатын, яулыгы белән йөзен каплап, тагын да ныграк бөреште.

Газинур ишекләрне япты. Тышта котырып яңгыр ява иде. Яңгырдан урам аръягындагы өйләр түгел, утыз-кырык адымдагы янгын сарае да күренми. Ә тирә-яктагы таулардан урам уртасындагы чокырга ургылып-ургылып су ага.

Айгыр тимер чылбырны өзде булса кирәк, аяклары белән такталарга типкәли башлады. Ватылган такта кисәкләре абзар аръягына ук оча башладылар.

– Батыр чылбырны өзде! – дип кычкырды Газинур.

Йөгереп килеп җиткән Сабир бабай Газинурның дулаган ат янына керергә маташуын күреп аптырап калды.

– Кермә, тибеп үтерер! – дип кычкырды ул. – Кермә, башың ике түгел, Газинур.

Газинур, ишекне ачып, абзарга атылды. Күзләрен кан баскан, бөтен тәне калтыранган ат, үз янында кеше барлыгын күргәч, бер генә секундка тынып калды. Шул арада Газинур аның тимер чылбырыннан эләктереп өлгерде һәм, чылбырны алка аркылы үткәреп, ике кулы белән аңа асылынды. Бик кыска вакытка шашуыннан тынып калган ат, үзен яңадан чылбырга тагуларын сизгәч, бик яман ыңгырашып, киң күкрәге белән улакка китереп сукты, аннары арт аякларына басты. Йодрык сыярлык киерелгән танауларыннан атылып чыккан эссе Газинурның битенә бәрелде.

– Боргычны бир, Сабир бабай, боргычны! – дип кычкырды Газинур. – Боргычламасак, харап була.

Сабир бабай ишек башына кыстырып куелган боргычны, сузылып алып, Газинурга ташлады. Газинур аны эләктереп айгырның өске иренен боргычларга тотынды, Айгыр берничә тапкыр аны бәреп ташлый язды, ләкин Газинур бирешмәде. Ул ярсыган атны, ниһаять, җиңде.

Ат, коточкыч әрнүдән аңын җуйган кебек, кинәт тынычланып калды. Газинур улактан сикереп төште дә, маңгай тирен сөртеп, араннан чыкты.

– Янабыз! – дип кычкырды Сабир бабай.

Абзарның арткы ишеге ярыкларыннан ялкын күренде. Газинур ишеккә йөгерде, аны ачып җибәрүгә, тау итәгендә, колхоз амбарларыннан читтәрәк берьялгызы торган сарайның дөрләп яна башлавын күрде. Бу сарайда колхозның кышкы инвентарьлары һәм әле күптән түгел генә Газинур белән Һашим Бөгелмәдән алып кайткан яңа җилгәргеч тора иде.

Газинур яныннан, дилбегәсен баш өстендә болгый-болгый, насос арбасына аягүрә баскан һәм атын җан-фәрманга чаптырган этисе Гафиятулла бабай, аның артыннан сулы мичкә арбасына шулай ук аягүрә баскан, шулай ук дилбегәсен баш очында болгаган Халикъ үтеп киттеләр. Газинур ишек төбендәге Сабир бабайга: «Боргычны алырга онытма», – дип кычкырды да этисе белән энесе артыннан йөгерде. Сарыклар фермасыннан чыккан кыска буйлы Һашим, правление ягыннан күренгән Хәнәфи абзый, бригадир Габдулла һәм тагын бик күпләр шулай ук янгынга йөгерәләр иде.

Газинур белән Һашим килеп җиткәндә, сарайның түбәсе яна, Гафиятулла бабай насостан су сиптерә иде.

– Җилгәргеч яна! Һашим, җилгәргечне чыгарыйк! – дип кычкырды Газинур мичкә яныннан йөгереп үткән Һашимга һәм, этисенең арбасыннан балта алып, йозакны бәреп очырды. Аннары ишекне ачып җибәрде.

Ул арада башкалар да килеп җитте. Халыкның кайсы насоска тотынды, кайсы су сибә башлады.

– Егетләр, түбәне каерып ташлагыз, түбәне! Багорлар белән! – дип кычкырды Гафиятулла бабай. Хәзер аңа караву куркыныч иде: өсте-башы манма су, бүреге кайдадыр төшеп калган, йөзе чытылган, күзләре ялтырый. Бу инде кулын артына куеп, үз алдына сөйләнә-сөйләнә башын иеп атлаучы көчсез бер карт түгел, ә ярсыган батырны хәтерләткән бер кеше иде.

Газинур белән Һашим сарайга атылып керделәр. Ут инде бөтен почмакларга таралып өлгергән. Бер-бер өсле өелгән чаналар дөрләп яна. Ялкын телләре җилгәргечне дә ялыйлар. Яшен җилгәргечне суккан булса кирәк, аның такталары каерылып, чәрдәкләнеп беткән. Төтен. Эссе. Газинур, беләге белән йөзен каплап, эчкәрәк үтте дә җилгәргечкә ябышты. Һашим аңа булыша башлады. Тагын берничә егет сарайга йөгереп керде. Ләкин шул ук вакытта тыштан әллә ничә тавыш берьюлы:

– Чыгыгыз, түбә ишелә! – дип кычкырды.

Киемнәре өтелә башлаган Газинур белән Һашим башкалар артыннан йөгереп чыгуга, түбә ишелеп тә төште. Ут тагын да көчлерәк дуларга тотынды...

Соңыннан, янгын тәмам сүнеп һәм колхозчылар: «Хәерле каза булсын», – дип таралып беткәч, Газинур анда берүзе калды.

Әле күптәнме соң алар Һашим белән шул уенчык кебек зәңгәр җилгәргечне Бөгелмәдән алып кайттылар. Менә игеннәрне урып-җыйгач та, үзем беренче булып әйләндерәм бу җилгәргечне дип хыялланган иде Газинур. Нәрсә калды...

Давыл тынмаган, яңгыр һаман коя, яшен һаман яшьни, күк һаман күкри, ләкин Газинур боларның берсен дә тоймый, күрми, ишетми иде.

## 7

Яшенле-давыллы яңгыр әкрен генә үтеп китте. Соңгы күкрәү тавышы баш өстендә бераз гөрелдәп торды да, аннары, ташлы юлдан үтеп киткән арба тавышыдай, кайдадыр бик еракта, әллә Баулы, әллә Башкортстан җирләре өстендә күгелҗем рәшәгә кереп, бөтенләй тынды. Күк йөзе аязганнан-аяза барды. Салынкы соры болытлар, гүя артларына борылып карый-карый, ераклаша бардылар. Хәзер башыңны күтәреп күккә карасаң, ул чистарган, юылган кебек зәп-зәңгәр. Ә тирә-якта шундый тынлык, шундый тынычлык, әйтерсең табигать бик каты тартыштан соң арыган да хәзер, әкрен генә сулыш алып, хәл җыя. Шул ук вакытта бөтен нәрсәдә ниндидер үтә җиңеллек, үтә яктылык, үтә сафлык сизелеп тора. Һавада хуш исләр аңкый. Үләннәр, игеннәр, агач яфраклары, тагын да яшелләнә төшеп, кояшка каршы миллион тамчылар белән җемелдәп торалар.

Кояш баеп килә. Аның кыйгач нурлары кечкенә «Красногвардеец» колхозын буеннан-буена яктыртып, аңа кабатланмас бер ямь биргән. Әнә урам як бакчалары эченнән уенчык тартмалар шикелле генә күренгән ап-ак өйләр, әнә урам буйлап тезелеп киткән коеларның биек сиртмәләре, уйга чумгандай, тып-тын торалар, әнә авыл башында казармага охшаган озын-озын ферма биналары тагын да зуррак, мәһабәтрәк булып киткәннәр. Исаково очында хыялый бер капка сыман аллы-гөлле салават күпере күтәрелгән.

Ләкин давылдан соңгы тынлык озакка бармый. Актыккы күкрәү еракларда тынып өлгерер-өлгермәс борын

ук бөтен тереклек иясе кузгала, поскан җирләреннән чыга һәм яңадан ыгы-зыгылы, чыр-чулы, эшчән, күңелле тормыш башлана. Бу һәр җирдә шулай. «Красногвардеец»та да нәкъ шулай булды: Якты Күлдә, Туйралыда, Наратлыда әле яңгыр ява иде, ә «Красногвардеец»ның кояш нуры төшкән ишегалларына, урамына, урамны икегә ярып үткән, яңгыр сулары ташу сыман гөрләп агып торган чокыр буена ыштан балакларын сызганган бала-чагалар бәйдән ычкынган төсле йөгерешеп чыктылар. Председатель Хәнәфи белән бригадир Габдулла, атларга атланып, басуга игеннәрне карарга киттеләр. Колхозның май заводы гөрли башлады. Ак яулыклы, ак алъяпкычлы бер кыз, аягына ялтырап торган өр-яңа резина галош киеп, көянтә белән чишмәгә суга чыкты. Чишмәнең түбән ягында, күл сыман җәелгән сары күбекле яңгыр суында, каз-үрдәкләр каңгылдашып һәм бакылдашып йөзә. Ат абзарларының киң ишекләрен ачып җибәрделәр. Аннан бер җирән колын атылып чыкты, исе киткән сыман бераз карап торды да койрык чәнчеп уйнарга кереште. Аны чакырып әнкәсе кешнәде. Ул да булмады, шушы киң ачылган абзар ишеге турысында Сабир бабай белән Газинур күренде. Ишек төбендә бермәл сөйләшеп торганнан соң, алар абзар кырыендагы сулы кисмәк янына килделәр. Газинур урындык өстендәге яңгыр суын чүпрәк ураган кулы белән сыпырып алды да көлемсерәп куйды.

– Әйдүк, Сабир бабай, утырып җибәр түргә, тартыйк бергә, – диде. – Безнең йөрәкләр түгел, тәмәке янсын.

Шау-шулы, хәвеф-хәтәрле озын көннән соң алар икесе дә бик нык арыганнар иде. Бигрәк тә Сабир бабай йончыды. Газинур аны ял итәргә димләп карады. Карт кулын гына селекте.

– Хәнәфиләр кайтмый торып күзгә йокы керәмени. Үземә барасы калган... Игеннәр, атлар иминнәрме? Коточкыч давыл иде бит. Бер елны шундый давылдан соң игеннәр бөтенләй ятып калып череде, ә атларны өч көн эзләдек. Алар яңгыр уңаена киткәннәр дә киткәннәр...

– Борчылма, Сабир бабай. Без бер тәмәке тартканчы, Хәнәфи абый белән Габдулла абый кайтып та җитәрләр.

– Кайтуын мин дә беләм, кайтырлар. Хәере белән диген.

Сабир бабай ашыкмый гына тәмәке төрде һәм бала-чагалар кайнашкан сулы чокырга карап тора башлады. Моннан алты-җиде ел элек бу чокыр бөтенләй сай иде әле. Хәзер аның киңлеге өч-дүрт метрга, тирәнлеге ике-өч метрга җитеп килә. «Красногвардеец»ны чолгап ал-

ган таулардан төшә торган кар, яңгыр сулары аны елдан-ел тирәнәйтә баралар. «Су балчыкны түгел, таш-тауларны да җимерә ул» дип уйлый Сабир бабай, игеннәр, атлар турында борчылуын онытырга тырышып һәм «и гомерләр...» дигән шикелле әкрен генә башын чайкый.

Газинур да, тәмәке тарта-тарта, су тулган чокырга карый. Ләкин аны бөтенләй башка нәрсә кызыксындыра. Әнә кап-кара бер малай әнисенең кер уа торган тагарагын чыгарган да, аңа утырып, көймәдәге шикелле йөзмәкче була. Ләкин утырып өлгерми, тагарак әйләнеп китә, малай тагын суга чума. Газинур чын күңелдән рәхәтләнеп көлеп җибәрә.

– Тырыш, Әпкәли, тырыш, булдырасың!

Сабир бабай аның кычкыруына игътибар итми, үз алдына сөйләнеп, уйлавын дәвам итә:

– Эх, булсын иде, ичмасам, шул яңгыр суы хәтле генә үз инешебез, – ди ул сабыр, уйчан тавыш белән. – Терлекләр дә интекмәс иде, яшелчәләр дә суга тилмермәс иде, бала-чага да рәхәтләнер иде.

Ә Газинур һаман тагараклы малайны күзәтә.

– Әпкәли, бөтерчек бөрчә, тәки утырды бит! Тагаракта йөзә, шайтан таягы! – дип яңадан кычкыра ул һәм Сабир бабайга карап ала. – Кайгырма, бабай, менә бераз аякка гына басыйк, бу чокырга менә дигән буа буарбыз. Җәйнең-җәй буена суы кипмәс. Тирәсенә агачлар да утыртырбыз. Юкә агачлары! Юкә чәчәк атканда, исе бөтен колхозга җәелер.

Сабир бабайның җилдән киселеп, кибеп беткән җыерчыклы йөзенә кояшның соңгы нурлары төшә. Ул бераз читкәрәк елыша һәм әүвәлгечә уйчан тавыш белән кайтарып сорый:

– Буа дисеңме? Белмим шул, буа белән генә берәр нәрсә чыгармы монда? Тамырсыз агач үсмәгән шикелле, чишмәсез күл дә йә кибә, йә сасый. Шәһәрләрдә фонтаннардагы суны да һаман саен яңартып торалар бит. Ә менә агачларны дөрес әйтәсең. Агач җирне ныгыта ул. – Карт, нәрсәнедер хәтеренә төшерергә теләгән сыман, шактый озак вакыт үз алдына уйланып тора, аннары яңадан сүзен дәвам иттерә: – Без монда яңа кешеләр, бу җирләрнең борынгы тарихын белмибез. Әмма үзебезнең Шөгер – Азнакай тирәләрен яхшы беләм. Мин балачакта йөгереп-атлап чыгарлык ерганаклар хәзер кызыл балчыгы ыржаеп торган иләмсез зур чокыр булганнар. Җитмеш ел шул инде ул эшкә...

– Җитмеш елда күп сулар аккандыр, – дип җөпләп куя Газинур.

– Һи, акмаган кая! Сулар да акты, тирләр дә акты, кан белән күз яше дә акты, Газинур... Һай, ул үткәннәрне искә төшерсәң!

Газинур Сабир бабайның хәтерен калдырмаслык итеп, йомшак кына әйтеп сала:

– Аккан су кире кайтмый инде, Сабир бабай, үткәннәрне искә төшереп җаныңны борчыма. Киләчәккә кара да тагын җитмеш ел яшим әле дип гайрәтлән.

Сабир бабайның кипкән йөзе чак кына яктыра төшә. Ул кәкрәеп беткән бармаклары белән түгәрәк ак сакалын бөтергәли башлый.

– Киң күңелле җан син, Газинур, киң күңелле! Тагын җитмеш ел мин түгел, син дә, бәлкем, яши алмассың, улым.

Картның бу сүзләренә каршы Газинур кабынып, дәртләнеп китә. Башындагы кепкасын җилкә чокырына ук этеп куя. Киң маңгаена кара чәче сибелеп төшә. Күзләре уйнаклый башлый, йөзе нурланып китә.

– Юк, Сабир бабай, мин һич үлмәм шикелле. Мәңге яшәрмен кебек, – ди ул, тирән хис белән.

– Адәм баласы шулай инде ул, – ди карт уйчан гына. Аннары өстәп куя: – Ярый, Газинур, кузгалыйк.

Сабир бабай, урыныннан торып, абзар почмагына килде, кулын каш өстенә куеп, басу үренә карый башлады. Тау башындагы зират янында кемнәрдер күренгәндәй булды.

– Газинур, безнекеләр кайта түгелме? Кара әле, синең күзләрең үткенрәк.

– Әйе, безнекеләр кайта, – диде аның янына килеп баскан Газинур.

Кинәт Сабир бабай бик нык борчыла башлады, ул әле бер кулын, әле икенчесен каш өстенә куеп карый, гүя кайтучыларның йөзләренерактан ук күреп, барысын да алдан белергә тели. Башка вакытта атны куган өчен кешеләрне шелтәләргә яратучан бу карт хәзер председатель белән бригадирның атлатып кына килүләренә чын күңеленнән рәнҗи иде. Игеннәр ни хәлдә икән? Су басмаганмы? Боз сукмаганмы? Яңгыр арасында боз күренгәләде бит. Утлаудагы атлар таралышып бетмәгәнме? Алар арасында тагын берәр хәвеф-хәтәр юкмы? Аяк астыннан килеп чыккан бәла кебек, көтмәгәндә, колхозның өч яшь атының авыруы картны тәмам аптыраткан иде. Бу әшәке авыру башка атларга да йокмагае дип курка иде ул.

Ниһаять, председатель белән бригадир ферма янына килеп туктадылар. Аларның тыныч йөзен күргәч, карт-

ның эченә җылы йөгергәндәй булды. Шулай да сорамыйча түзмәде:

– Хәнәфи балам, нинди хәбәрләр алып кайттыгыз? Игеннәргә хәвеф-хәтәр тимәгәнме? Атлар бар да исәнме?

Председатель, иярдән төшеп, тезгенне Газинурга бирде.

– Обстановка куркыныч түгел, Сабир бабай. Атлар да, игеннәр дә үз урынында. Җил уңаена бодай әзрәк сөрлеккән сөрлегүен дә, күтәрелер әле.

Газинур койрыклары бәйләнгән, аяклары тез тиңентен пычракка буялган атларны абзарга таба алып китте.

– Газинур, – дип кычкырды Хәнәфи аның артыннан. – Иртәгә правлениегә кереп чык, яме. Теге мәсьәлә буенча доложить итәрсең.

– Була ул, – диде Газинур, артына борылмыйча гына.

Абзарда ул атларның иярләрен салдырды. Иярләрне сбруйлар сараена илтеп куйды, атларны аранга кертеп япты. Аннары кулына озын саплы себерке алып, аяк астына җыелган яңгыр суын себерә башлады. Эш көенә авыз эченнән җырлап та җибәрде. Сабир бабай, аның яныннан сүзсез генә узып, араннарның берсенә керде һәм төнгелеккә кибәк болгата башлады.

Аларның эшләре бары тик караңгы төшкәч кенә бетте, аннары ат караучылар, абзар ишегендәге аркылы агачка күкрәкләре белән ятып, әзрәк хәл алдылар.

– Ну, Сабир бабай, – диде Газинур, шаяртып, – яшеннән шүрлисең дә икән үзең. Котың тәмам очкан иде.

Сабир бабайның да хәзер кәефе яхшы. Карт кешегә күп кирәкмени: игеннәр зарарланмаган, атлар исән. Ул кеткелдәп көлә.

– Әллә булгандыр, әллә юк, хәтерләмим, – ди ул һәм кинәт бик җитди итеп әйтеп куя: – Ә син, Газинур, башсыз егет. Дулаган айгыр янына кереп харап була яздың бит. Мин сиңа ничә тапкыр кычкырдым, кермә дидем.

– Кермичә ярамый иде, – ди Газинур, акланырга тырышып. – Әгәр кереп айгырны тынычландырмаган булсам, үзен-үзе бетерә иде ул. Бу арада атлар белән болай да әллә нәрсәләр булып тора. Шуның өстенә үзебез дә куркып торсак... Менә җилгәргеч кызганыч, нихәтле тырыштык, коткара алмадык.

– Ярый, хәерле каза булсын. Кеше башы түгел. Председатель әйтә, быел ук яңасын булдырырбыз, ди. Страховка акчасы да бераз киләчәк. Безнең Әлфия шундый эшләрне тиз тотучан кыз. Менә синең кулларың ничек, бик каты сызламыймы? Пешкән тән бик әрнүчән була ул.

Газинур, чүпрәк белән ураган кулларын алга сузып, аларга карый да көлә.

– Минем кулларым, Сабир бабай, эт тиресе шикелле, иртән торганчы төзәлә алар.

Сыер абзарлары ягыннан моңарчы берөзлексез ишетелеп торган нечкә гөжләү кинәт тынды. Сыер савучы кызлар эшләрен бетереп кайтып киттеләр. Өйләрдә учакларга ягылган. Морҗалардан аксыл төтен күтәрелә.

Газинур Сабир бабайга председатель ни өчен чакырганлыгын әйтте. Шәһәрдән кәгазь килгән. Урман кисәргә колхоздан кешеләр сорыйлар. Газинур барырга вәгъдә биргән. Иртәгә исемлек төзиләр икән.

– Нишлим, Сабир бабай, барыйммы, юкмы? Хәнәфи абыйга вәгъдә бирүен бирдем, шулай да колхоздан бер дә китәсе килми. Син дөнья күргән кеше, киңәш ит әле миңа, Сабир бабай.

Газинурның киңәш соравы картның күңелен нечкәртеп җибәрде. Сүз җаеннан гына түгел, чын күңеленнән сорый бит. «Рәхмәт, улым, – дип уйлап ала карт. – Үз гомерендә Карпат тауларына менгән, Порт-Артурда сугышкан, нужа капчыгын күтәреп булса да, киң Россиянең буен буйлаган, иңен иңләгән бер картның яшьләргә бер-ике авыз киңәш бирерлек кенә тәҗрибәсе бар».

– Яшь вакытта, Газизнур улым, – диде ул, Газинурны тулы исеме белән бүген икенче тапкыр хөрмәтләп атап, – дөньяны бер күрү кирәк. Йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә, дигәннәр борынгылар. Мин мәслихәт күрәм.

Газинур картны игътибар белән тыңлады. Аның күз алдына ерак шәһәрләр, ерак урманнар килеп басты. Күңеле җилкенеп китте.

– Алай булгач, барам, – диде ул кыю гына. – Гали абзый янына кереп, тагын бер киңәшләшеп алам да барам. Әтинең күптән әйтеп куйган сүзе бар: дөнья күрмәк – ир кешенең бурычы.

– Дөрес сүз. Шулай да, Газинур, атаң сүзенә караганда да, минем сүзгә караганда да Әхмәтгали сүзенә күбрәк колак сал син. Без инде килде-китте кеше булып барабыз. Күбрәк өскә түгел, аска карыйбыз. Әйе. Шуңа күрә безнең сүзне тыңласаң, рәхмәт, тыңламасаң, үпкәбез юк дигәндәй. Ә Әхмәтгалинең сүзеннән чыкма. Еракка карап эш итә торган кеше ул.

Авылда утлар кабыздылар. Күктә эре-эре йолдызлар калыкты. Атлар әкрен генә пошкырып ашыйлар. Айгыр бертуктаусыз таптана, стенага беркетелгән тимер чылбыры чыңлап тора.

– Урта авылда этләр өрә башлады, – диде Газинур, көлеп, – әллә кайтып тамак ялгап килергәме икән? Әнкәй токмач пешерәм дигән иде.

– Бар, бар, – диде карт тиз генә. – Мин монда күзколак булып торырмын.

Газинур абзардан чыкты да, келәтләр каршында җыелган колхоздашлары янына туктап:

– Кайсыгызның тәмәке тартасы килә – рәхим итегез! – диде, янчыгын чыгарып.

Янчык, кулдан кулга күчеп, Газинурга бушап кайтты.

– Әттә генәсе! – диде ул, көлеп. – Туемда буран булмас, янчыкны ялтыраткансыз.

## 8

Газинур өйгә кайтып кергәндә, кайнар токмачны зур агач табак белән өстәлгә китереп куйганнар иде инде. Түрдә караңгы чырайлы Гафиятулла бабай, бөтен икмәкне күкрәгенә терәп, чалгы пычак белән телеп утыра. Яңгырда чыланган киемнәрен алмаштырганнан соң кигән ап-ак күлмәге аның чыраеның караңгылыгын тагын да ачыграк күрсәтә кебек. Гафиятулла бабайның сул ягында француз яулыгын ябынып утырган Шәмсинур җиңгинең дә озынча йөзе бүтән вакытлардагыча гамьсез түгел. Гомуми хәсрәт аңа да үзенең эзен салган. Газинур абыйсы Мисбах янына урындыкка килеп утырды.

Өй эче тып-тын. Картның кәефе юк чакта өйдә берәү дә кычкырып сөйләшми. Токмачны да сүзсез генә ашадылар. Тик Гафиятулла бабай гына, беркемгә дә мөрәҗәгать итмичә һәм беркемнән дә җавап көтмичә, үз алдына сукранып утырды. Мондый чакта аны борчымау яхшы. Аның холкын белгән уллары сүз катмадылар. Әмма карчыкның түземлеге җитмәде.

– Булды инде, атасы, сукранмасана, Алладан килгән каза бит, – диде.

– Һе, Алладан! – дип, берьюлы кызып китте карт. – Мин аны мулладан дип әйтәмме әллә? Таптың сүз! Колхоз милке өчен кем җавап бирә: минме, Алламы? Каныма тоз салган буласың тагы!

Гафиятулла бабай куе кашларын җыерды. Солдатта чакта Кавказ тауларында крушениегә эләккәндә ярылган, соңыннан яра эзе гомергә бетмәслек булып калган киң борынының эре яфраклары селкенергә тотынды.

Үз гомерендә башыннан бик күп газаплар кичергән, әллә ничә тапкыр үлемнән калган Гафиятулла бабайның шулай кинәттән күтәрелә торган гадәте бар иде. Әмма ул беркайчан да хатынына да, балаларына да кул тидермәде. Шулай да өйдәгеләр аңардан куркалар иде.

Бүген янгыннан соң картның кәефе аеруча начар булды. Ул әле һаман да утны ни өчен зурга җибәрмичә сүндерә алмавын аңлый алмый иде. Җитмәсә, председатель янына килеп зарланып йөргән булды тагы. Имеш, кемнеңдер сүзенә күңеле рәнҗегән. Дөрес әйткән ләбаса...

Аштан соң Гафиятулла бабай баш астына мендәр салды да сәкегә сузылды.

– Балалар, шауламагыз, кәефем юк. Чыгып торыгыз, булмаса, – диде.

Газинур үзенең читкә китәргә теләге барлыгы турында этисе белән яхшылап киңәшмәкче иде дә, картның кәефе юклыгын күргәч, соңыннан сөйләшергә булды.

Алар Мисбах белән ишегалдына чыктылар. Караңгы. Яңгыр арты булуга карамастан, һава җылы: җир рәхәтләнеп, изрәп ята шикелле. Лапаста сыер күши. Бозау ишегалдына ук чыгып яткан. Бозау янында, башын канат астына тыгып, ата каз йоклый.

– Авыр холыклы кеше безнең эткәй, – диде Мисбах, тирән генә көрсенеп. – Әйтерсең аны судка бирәләр. Берәү дә тиргәми ич аны. Бер елны Шөгердә яшен ике йортны сукты, ә былтыр кыр уртасында бер хатынны бәреп үтергән. Аңа кем гаепле? Картлык көнендә авырткан башына тимер тарак эзли.

Ул түмәр өстенә утырды. Газинур аның алдында аягүрә басып торды.

– Юк, абый, син этине белмисең, аның күңеле әйбәт, – диде ул, кесәсеннән тәмәке янчыгын чыгарып. – Каһәр суккан, беткән икән.

– Синең һәрвакыт шулай, – диде Мисбах сүрән генә. – Булды исә хәзер кешегә таратасың, ә аннары үзең интегеп йөрисең.

Газинур көлеп җибәрде.

– Саклап тотсаң, мең көнлек, сакламасаң, бер көнлек, димәкче буласыңдыр, абый. Әйеме? Беләм, саран ирдә мал тора. Чыгар янчыгыңны. Тартасы килә.

Мисбах тәмәке янчыгын кесәсеннән теләр-теләмәс кенә чыгарды. Тәмәке янчыкның төбендә генә иде.

– Һай, абый, монда бит бер төрерлек тә юк, – диде Газинур, янчыкны селкеп.

– Үзеңнеке булмаганга шулай дисең син. Безгә бик юмартланмаганда да ярый.

Шулай сөйләшә-сөйләшә тәмәке төрделәр. Аннары тәмләп суыра-суыра тарттылар. Бая, өйдән чыккач, караңгылык бик көчле сыман тоелган иде, күзләр күнеккәч, шактый ук якты булып китте. Хәзер инде күршеләрнең

каралтылары, коймалары гына түгел, хәтта казык башына кибәргә кидерелгән чүлмәкләр дә ап-ачык күренә иде.

Аргы башта кемдер «Хафизаләм иркәм» көенә гармун сыздырып җибәрде.

– Абый, – диде Газинур, тәмәкесен тартып бетергәч, – мин читкә китәргә уйлыйм бит. Хәнәфи абый, иртәгә кереп окончательно әйт, диде. Нишлим, барыйммы икән?

Мисбах туры җавап бирмәде. Ул башта нинди эшкә, хезмәт хакы күпме буласы, кием-салым бирәчәкләрме, юлга күпме акча тия, колхоздан тагын кемнәр бара дип төпченеп сораштырды. Газинур председательдән ишеткәннәрне сөйләп биргәч, ул бераз уйга калды.

– Алар менә әйткәннәрен алдан бирсеннәр иде. Югыйсә куянга койрык вәгъдә иткәннәр дә, ул әле дә койрыксыз, – диде Мисбах ахырда.

Газинур, бер карында ятмаган булсалар да, абыйсын ярата иде. Ләкин эченнән бервакытта да аның фикеренә кушылмый иде. «Единоличник син, абый», – ди торган иде ул аңа.

– Кызык кеше син, абый, – диде Газинур, чүгәләп. – Мин анда мал җыярга бармыйм лабаса. Элек заманда гына читкә китеп бәхет эзләгәннәр. Минем яңа җирләр, яңа кешеләр күрәсем килә. Акыл җыясым килә.

– Акча булса, акыл була, – диде Мисбах, урыныннан торып. – Син бит өйләнәсе кеше, өс-башыңны рәтләү ягын кара.

– Агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк димәкче буласыңдыр тагын. Юк, мин үзем дә чүпрәк яратмыйм, чүпрәк яраткан кызларны да сөймим. Ярый, абый, сау булып тор. Мин киттем.

Алар урамга чыктылар. Урам буенда, тоньк кына булып, яңгыр сулары ялтырый иде. Правлениедә ут бар. Чишмә башыннан челтерәп аккан су тавышы ишетелә.

– Кая, правлениегәме?

– Юк, Гали абзыйга кереп чыгам әле. Экстренный киңәшәсе бар.

– Юләр булма. Ул яңарак кына юлдан кайтты, йончыгандыр.

– Ул миңа кайчан керсәм дә ачуланмый. Озак утырмам.

Мисбах авылның бер башына – үз өенә таба китте, Газинур икенче якка – Гали абзыйларга таба атлады. Абыйсыннан аерылып егерме-утыз адым да китмәгәндер, Газинур урамны яңгыратып кычкырып җырлап җибәрде:

Беләзеккәең, һәй, бөгелмә,
Бөгелмәдән килгән түгелме?

«Һаман да акылга утырмый бу тинтәк малай», – дип уйлап алды кулларын артына куеп, башын бөгеп барган Мисбахетдин. Кече яшьтән үк олыларга охшарга тырышып үскән, хәзер инде тәмам шуңа күнегеп беткән Мисбах Газинурның һаман да әле иләс-миләслектән чыгып җитмәвен яратып бетерми иде. Ә Газинур тагын да кычкырыбрак җырлый бирде:

Сөям-сөям, дип әйтәсең,
Сөюләрең хәйлә түгелме...

Газинурның җыры ишетелгәч тә, Гали абзыйларның кечкенә өендә ачык тәрәзәнең ак пәрдәсе күтәрелде. Миңнурый тәрәзә янңагына сөялеп, озын керфекләрен түбән төшереп тыңлый башлады. Ул инде Газинурның читкә китәргә җыенуын да, правлениедә Сәлим белән бәрелешеп алуын да белә иде. Бу хәбәрне дус кызы Әлфиядән ишеткәч, Миңнурый башта аптырап калды, аннары Газинурга бик каты үпкәләде. Кич буе диярлек ул Газинурга әйтәсе шелтәләре турында уйлап, ачынып йөрде. Кем соң аңа Миңнурый? Хатыны түгел лә. Халык алдында аның исемен телгә алырга нинди хакы бар? (Әле күптән түгел генә атлар вакыйгасы уңае белән Газинурга бәйләп үз исемен дә ишеткәләгәндә, Миңнурый шыпырт кына поса яки ишетмәмешкә салына торган иде. Күрәсең, кызларның хәтер сандыгы сай икән, кай арада онытылып та өлгергән.) Ләкин Газинурның җырын ишеткәч, кызның дулаган йөрәге бик тиз сүрелде. «Нәрсәсе белән бу шадра минем күңелемне сихерләде соң?» – дип уйлады ул һәм татлы да, газаплы да итеп көрсенеп куйды. Газинур үзе: «Шадра – йөрәк яндыра», – ди. Әллә чыннан да бу дөрес сүзме икән. Алай дисәң, «Красногвардеец»та шадра егетләр бер генәмени! Нигә алары йөрәкне телгәләми?

Өйалдында Газинурның аяк тавышлары ишетелгәч, Миңнурый яңадан салкын, буйсынмас бер кыяфәткә керде. Хәзер ул яңадан чәнечкеле, усал Миңнурый иде.

Көр күңелле, шаян табигатьле Газинур да бу өйгә килеп кергәч, бик тиз үзгәреп китә торган иде. Бу юлы моның өчен җитди сәбәп тә бар. Конный двордагы сөйләшүдән соң Газинур Гали абзыйны беренче тапкыр күрә бит. Ул, ишек төбендә туктап, тартынып кына сорады:

– Гали абзый өйдәме?

Миңнурый өстәлдә сырлы бәләк белән кер тәгәрәтә иде. Ул Газинурга ачулы күзләре белән кырын карап алды да:

– Пычрак чабатаң белән идәнне таптама әле, – дип кычкырды.

Газинурның аяклары чыннан да пычранган иде. Ул аларны чистартып керер өчен ишекне ача гына башлаган иде, алгы як бүлмәдән Гали абзыйның калын тавышы ишетелде:

– Кем ул? Газинур, синме? Әйдүк, бу бүлмәгә уз.

Газинур бер Миңнурыйга, бер чабаталарына карап алды. Аннары, башын чайкап, көлемсерәп куйды да тышка чыкты. Бераздан ул яңадан әйләнеп керде, көлеп җибәрмәс өчен авызын учы белән каплап торган Миңнурый яныннан, каш сикертеп узып, аяк башларына гына баса-баса, алгы бүлмәгә узды.

Гали абзый өстәл янында утыра иде. Кулында ниндидер китап. Ак абажурлы җиделе лампа янып тора. Өстәл өсте дә, шүрлекләр дә китап белән тулган. Стенада зур карта.

Гали абзый үзе әчке күлмәктән генә. Башы яланбаш. Чәчен такыр итеп алдырган. Ак абажурлы лампаның йомшак яктысында ул ничектер яшәреп, матурланып киткән кук күренә.

Газинурны ул елмаеп, якты чырай белән каршы алды. Ачык чырай – такта чәй дигәндәй, Газинур берьюлы тартынуын онытты.

– Нәрсә, Миңнурый пычрак аяк белән ак өйгә кертмимени? Әйдә, утыр, – диде Гали абзый, урындык күрсәтеп.

– Зрә хәтәр, – диде Газинур, әкрен генә көлеп, – чебиле тавык кебек.

Ул зәңгәргә буяган артсыз урындыкка утырды, башыннан кепкасын салып, тезләренә куйды. Яңгырдан соң кепкасы әле рәтләп кибеп тә җитмәгән иде. Ул арада Миңнурый кереп Газинурның аяк астына чыпта җәйде.

– Кара аны, зур күз, идәнемне пычратсаң, икенче тапкыр бусагадан да атлатмам, – диде ул һәм башын күтәреп чыгып та китте.

Гали абзый белән Газинур бер-берсенә мәгънәле генә карашып алдылар. Аннары Гали абзый, китабын читкә куеп:

– Йә, Газинур, эшләр ничек? Колхозның сарае белән яңа җилгәргечен яндырдык диген, – диде.

Моны ул битәрләп тә, яманлап та әйтмәде кебек. Әмма Газинур колакларына кадәр кызарды.

– Яндырдык шул, – диде ул, авыр көрсенеп, чүпрәк белән бәйләнгән кулларын кепкасы астына яшерде. – Соңгы вакытта безнең колхозга бәла артыннан бәла явып кына тора. Шаккатарлык...

– Әйе шул. Ләкин гаҗәпләнерлек нәрсәсе юк моның, Газинур.

Гали абзый, урыныннан торып, ишекле-түрле йөренә башлады. Аягындагы йомшак чүәкләре идәндә лаштыр-лоштыр килде. Газинурга уң ягы белән борылганда, эчке күлмәгенең ачык изүеннән муенындагы яра җөе күренде. Бу дошман кылычының эзе иде.

– Яшеннән башкасы, – диде Гали абзый, һаман да йөренә биреп, – берсе дә очраклы хәл түгел. Бөгелмәгә барганда сөйләгән сүзләремне онытмадыңмы әле?

– Юк, онытмадым, Гали абзый.

– Менә шул көрәш хәзер дә дәвам итә. Дөрес, дошман хәзер кулына корал тотып ачыктан-ачык сугышмый. Корал тотып сугышуның барып чыкмавын күрде инде ул. Хәзер безнең арага кереп, тыштан колхоз яклы булган булып, эчтән бөтен көче белән колхозны җимерергә маташа.

Газинур Тавык Мортый турында сөйләп бирде һәм ахырдан ачу белән өстәп куйды:

– Сырланның үзен өзсәң дә, тамыры кала дип әйтәләр иде, шул икән алайса. Себергә киткән кулакларның калдыклары монда тәгәрмәчкә таяк тыкмакчы булалар.

– Бик дөрес, – диде Гали абзый. – Тормышның законы шундый, Газинур. Искелек көрәшсез генә китми, тигәнәктән яманябыша. Тавык Мортый кебекләр безнең канга күп тоз салачаклар әле. Шуңа күрә дә безгә гамьсез булырга ярамый.

Газинур кара күзләрен уйнатып алды.

– Аңарчы ул кысыр тавыкларның муеннарын борып, башларын канат асларына тыксак ничек булыр?

Гали абзый көлемсерәп куйды. Аңа егетнең йөрәклелеге ошады, әмма җавап биргәндә кызуламады.

– Ашыкма, Газинур, вакыты килгәч, барысы да эшләнер, – диде. – Хәзергә син ул Мортыйга күз-колак бул.

– Баягынак ул, эшкә җибәрүләрен сорап, Хәнәфи абый янына кергән иде. Шыларга тели булса кирәк.

– Булыр, булыр, – диде Гали абзый, үзе мәгънәле генә итеп Газинурга карады. Гомумән, ул Газинурны ярата, аны һаман күзәтә, әледән-әле үзе янына чакырып яки правлениедә, клубта, кырда, абзарда очратып, аның белән вакыт сыйдырганча сөйләшә, аңа үзенең киңәшләрен бирә иде.

Газинур үзе дә Гали абзыйның чын күңелдән яхшылык теләвен сизә. Көнбагыш кояшка гашыйк булып, аның артыннан көннең-көн буе башын бора биреп карап торган кебек, Газинур да һәрвакыт Гали абзыйга таба борылып-борылып карый, бер-бер эшкә тотынса, бу турыда Гали абзый нәрсә әйтер икән дип уйлап ала иде.

Сөйләшә-сөйләшә вакыт шактый үтте. Гали абзый янында Газинур таңга кадәр утырырга да риза иде. Ләкин юлдан кайткан авыру кешене озак борчырга Газинур яхшысынмады. Аннары Сабир бабай янына да барасы бар әле.

Ул үзенең ни өчен кергәнлеген әйтте.

– Соң, үзең ничек уйлыйсың, Газинур? Барырга теләгең бармы? – дип сорады Гали абзый.

– Теләгем бар гына дип әйтсәм, дөрес булмас, Гали абзый. Теләгем бик зур, – диде Газинур, – тик минем кебек коры җир көймәсе ни белә. Синең киңәшеңне ишетәсем килә минем. Сабир бабай да синең белән киңәшергә кушты.

– Ә син кая барачагыңны беләсеңме соң? – дип сорады Гали абзый.

– Урман кисәргә дигән иде Хәнәфи абый. Урал якларына. Әмма Урал кайда – белгән юк. Җырда гына ул якын.

Гали абзый, өстәл кырыеннан ак чыбык алып, картадан Свердловск тирәләрен күрсәтте. Газинурлар Соликамск леспромхозында эшләячәкләр икән. Гали абзый шул җирләр турында сөйләп бирде.

Иң ахырдан ул:

– Мин сиңа ул җирләрнең байлыгы турында да, Урал шәһәрләренең матурлыгы, заводларының зурлыгы турында да дөресен сөйләдем, – диде. – Ләкин син анда баргач, барысы да берьюлы ал да гөл булыр дип ялгыш уйлама. Юлыңда кыенлыклар күп очрар. Син алар алдында чигенмә, аларны җиңәргә тырыш. Син бит халык мәкальләренә оста кеше. Ир егетнең юлдашы – тәвәккәл дигәнне беләсең. Тәвәккәл бул, өйрән, укы. Анда, һичшиксез, нинди дә булса курслар булыр, һөнәр ал. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз. Вакытыңны әрәм итмә! Рус телен тырышып өйрән. Ул сиңа бик кирәк булачак.

Гали абзый яныннан Газинур бик соң чыгып китте, Галәк бабайлар йорты каршыннан узган чакта, ул беразга тукталды. Галәк бабай, кулына таягын тотып, бүрәнәләр өстенә утырган. Аның әйләнә-тирәсенә иңнәренә эти-әниләренең иске киемнәрен салган бала-чагалар чүмәшкәннәр дә, таң калып, бабайның авызына карап торалар. Ул аларга ерак үткәннәр – Ямәлкә патша турында сөйли. Сөйли-сөйли дә борынгы озын көйгә салып җырлап җибәрә:

Пугачау патша бар, диләр,
Пустау бишмәтләре тар, диләр,
Җаек та буе яу җирләре
Айкап та йөргән шул, диләр.

Пугачау патшаны күрсә идең,
Алларына буй бөгеп узса идең,
Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

Бу җырлар урам уртасында басып торган Газинурның күз алдына Бөгелмәдәге һәйкәл кырыенда яткан чуен туп көпшәсен китереп бастырдылар. Ә бүрәнәләр өстенә утырган Галәк бабай, берни сизмичә, һаман җырлый бирде. Күпме тыңлады Газинур аның шушындый җырларын! Күпме хисләр, күпме ашкынулар уятты бу җырлар аның яшь күңелендә! Хәзер ул юлга чыгарга әзерләнә. Ул инде яңадан Галәк бабайның хикмәтле әкиятләрен дә, моңлы җырларын да тиз генә тыңлый алмас. Аның каравы юеш үлән өстенә утырышып, авызларын яртылаш ачып, бабайның җырын йотлыгып тыңлаган малайларның яшь күңелләрендә никадәр яңа ашкыну, никадәр яңа омтылышлар уяныр!

Тормышның шушылай итеп төзелгән булуы, бернәрсәнең дә тукталып, бетеп калмавы, ә өзлексез дәвам итүе Газинурны аерата куандырды. Ул елмайды, күктә җемелдәгән Иләк йолдызларга карап, урам буйлап атлады. Ә Галәк бабай һаман җырлый бирде.

## 9

Яшенле яңгыр яуганның икенче көнендә Гафиятулла бабайларга Казаннан кунак кызлары килде. Кызларның берсе – Гөлләр исемлесе – Гафиятулла бабайның ерак кардәше, икенчесе Гөлләрнең дус кызы иде.

Аларны бик шатланып каршы алдылар.

– Өебез артык иркен түгел түгелен дә, күңел киң булгач, сыярбыз әле, үпкәләмәссез, – диде Гафиятулла бабай ачык йөз белән.

– Безгә авыл һавасыннан башка берни дә кирәкми, – диделәр кызлар.

– Безнең колхозның һавасы бик тәмле, – диде Шәмсинур җиңги, сүзгә кушылып. – Аннары сөтебез, йомыркабыз да, күмәчебез дә үзебезнеке, сатып алмаска. Бер дә борчылмагыз. Килүегез өчен бик рәхмәт. Колхоз тормышын карап китәрсез.

Гафиятулла бабайның кунак кызлары турындагы хәбәр минуты-сәгате белән бөтен колхозга таралды. Бу турыда Гали абзый да ишетте. Икенче көнне ул аларны урам буйлап узган чагында тәрәзәдән күреп тә калды. Кызларның берсе – кыска сары чәчле, икенчесе – озын кара толымлы. Алар, кулга-кул тотынышып, ниндидер күңел-

ле әйбер турында көлешә-көлешә сөйләшеп, урам уртасыннан баралар иде.

Башта Гали абзый алар белән Казан хәлләре турында гына гәпләшергә уйлаган иде. Казанны сагынган иде ул. Гел барырга дип җыена, әмма җае ничектер бер дә туры килми: әле тегесе, әле монысы килеп чыга да кала бирә. Ул Газинурның энесе Халикъ аркылы алардан үз янына кереп чыгуларын үтенде. Халикъ, Газинур кебек үк, Гали абзый өчен утка керергә әзер торган үткен малай булганлыктан, кызларны шул сәгатьтә үк диярлек алып та килде.

Ләкин сүз Казан хәлләре белән генә бетмәде, дөресрәге, шуның белән башланды гына. Кызларның сары чәчлесе – ул үзен Гөлләр дип таныштырды – инженер-электрик булырга укый икән, ә озын кара толымлысы – анысы Фатыйма исемле иде – артистка булырга әзерләнә. Моны белгәч, Гали абзыйның йөзе тагын да яктыра төште.

– Сез бит безгә бик кирәкле кешеләр, кызлар, – диде ул, җанланып китеп. – Казаннан ерак торабыз. Шәһәр кешеләре сирәк килә. Ә колхозчылар – бәлки, үзегез дә сизеп өлгергәнсездер инде – культурага бик нык сусый. Менә сез, Гөлләр, аларга колхоз электростанцияләре турында доклад сыман нәрсә ясый алмассызмы икән? Ә Фатыйма, бәлки, безгә үз һөнәрләреннән берәр нәрсә күрсәтер иде. – Ул кызларга үзенең сынаучан күзләре белән текәлеп карап торды да, – йә, ничек, кызлар, буламы? – дип сорады.

Кызлар бер-берсенә карашып алдылар да елмаеп куйдылар. Алар риза иде. Тик бер-ике көн вакыт сорадылар. Аннары Гөлләр, иллюстрация өчен «Красногвардеец»-ның үз елгасын тикшерсәң яхшы булыр иде, диде. Бәлки, якын киләчәктә «Красногвардеец» та электростанция корып җибәрер.

«Красногвардеец»ның үз елгасы дигән сүзне ишеткәч тә, Гали абзый көлемсерәп куйды. Аннары аның йөзе уйчанланып китте. «Красногвардеец» халкының су турында хыяллануы аңа бик яхшы билгеле иде. Ул киләчәктә колхозда сулыклар да, буалар да буласын белә, әмма хәзергә әле чишмә, кое сулары белән чикләнергә туры килә. Вакыты җитми яшен яшьнәми, диләр.

Кичкырын колхоз председателе Гали абзый киңәше буенча Газинурны правлениегә чакыртты.

– Газинур, сиңа боевое задание, – диде ул, кара мыегын бөтереп. – Кунак кызлары безнең «елгалар»ны карамакчылар. Син алар белән разведкага чыгарсың. Аңлашылдымы?

Газинур Хәнәфинең шаяртып сөйләвен шунда ук сизеп алды.

– Артыгы белән, Хәнәфи абый.

– Артыгы белән? – дип кайтарып сорады председатель. – Ә разведка нәрсә була?

– Кайткач, этидән сорармын әле.

Хәнәфи башын артка ташлап көлә башлады.

– Ах син, тел бистәсе! – диде ул, бармак янап. – Үзеңнән олыларны хитрит итмәкче буласыңмыни? Шагом марш!

Газинур кызлар белән кырга чыкты. «Красногвардеец» җирендә электростанция корырлык түгел, мал сугарырлык та су юк иде. Су бары тик күрше «Прогресс» колхозында гына бар. Ләкин Газинур кызларны туп-туры анда алып бармады. Кечкенә сай чишмәләрне күрсәтеп, кырлар буенча йөртте. Ул кызлар бик тиз арырлар да кайтыйк инде дип йөдәтерләр дип көткән иде. Ләкин ялгышты.

– Ах, биредә нинди күңелле, нинди иркен! – диде Фатыйма. – Мин Третьяков галереясында Шишкинның «Арыш басуы»на таң калып карап торганым бар. Ләкин биредә... Биредә мин тагын да көчлерәк дулкынланам шикелле, Газинур, – диде ул, егетнең кулыннан тотып. – Бу сезнең басулармы? Сез үстергән игеннәрме болар?

– Әйе, – диде Газинур, горурланып. – Безнең колхоз үстергән игеннәр!

Фатыйма, туктап, офыкка кадәр сузылып киткән басуга карап тора башлады. Игеннәре өлгереп килә торган басуның матурлыгын нәрсә белән чагыштырырга мөмкин? Бернәрсә белән дә, дип уйлады кыз. Ул үзенә башка, аның матурлыгы бүтән бер генә урында да кабатланмый. Урманнар ямьле, таулар ямьле, болыннар ямьле, әмма иген басуы барысыннан да ямьлерәк. Тегендә табигать күркәмлеге, табигать көче патша, биредә кеше хезмәтенең, меңләгән Газинурлар хезмәтенең тантанасы шаулый. Менә син еракка сузылган саен һаман тарая барган басу юлыннан атлыйсың. Тирә-ягыңда беркем дә юк. Тик мәһабәт диңгез булып, яшәү җыры җырлаган кебек, ике ягыңда арышлар гына дулкынлана. Алар шундый биек, синең башың гына күренә, кайчагында башың да күренми, ике стена арасыннан баргандай буласың. Шунда әгәр синең йөрәгең юл кырыендагы кантар кебек кибеп, катып бетмәгән булса, син шушы иген диңгезләрен үстерүче кешеләр турында, аларның хезмәтләренең гүзәллеге, олылыгы турында җырларсың. Бу алтын игеннәр табигать мәрхәмәте буенча гына үсмәгән бит, аларны кеше үстергән. Бу иксез-чиксез басуларны эшкәртү өчен ул нихәтле көч салган да нихәтле тир түккән!

Фатыйманың колакларында бу гаҗәеп җырның көе дә чыңлый башлагандай була, ул, аңа колак салып, кузгалмый тора. Газинур белән Гөлләр шактый алга киткәннәр. Аларның үз сүзләре сүз.

Бераздан Фатыйма аларны куып җитә, арыш башакларына бармак очлары белән кагыла-кагыла, янәшә бара башлый. Аннары кулларын җәеп иптәшләрен туктата.

– Чү, куркытмагыз, – ди ул пышылдап кына. – Әнә күрәсезме, юлда нинди матур кошчык йөри. И җаным, каурыйлары ямь-яшел. Былбылмы әллә, Газинур?

– Юк, солы чыпчыгы, – ди егет, көлемсерәп.

Болынлыкта Фатыйма чәчәкләр белән мавыга башлады. Бер чәчәк таба да: «Газинур, бу нинди чәчәк?» – дип сорый. Газинур аңа бу чәчәкләрнең җирле мәзәк исемнәрен әйтә: монысы бәрхет гөле, монысы көләч гөл. Менә бу сары чәчәкне давыл чәчәге диләр. Өзәргә ярамый, өзсәң, давыл чыга. Менә бу куе ал чәчәкне дегет чәчәге диләр. Өзеп алсаң, сабагы кулга ябыша. Монысы утчәчәк, янар чәчәк. Йөрәккә мең төрле шифасы бар. Фатыйма көлә, гаҗәпләнә. «Син ботаникмы әллә? Каян барысын да беләсең?» – ди. Юк, Газинур ботаник түгел, ул бу исемне дә белми, ул бары тик шул кырларда кечкенәдән аунап үскән малай гына. Гомер кичергән бабайлар ни белсәләр, аңа шуны сөйләгәннәр. Ә ул барысын да күңеленә бикләгән. Бал корты чәчәктән чәчәккә кунып ничек бал җыйса, Газинур да халыктан ишеткән сүзләрне шулай хәтер сандыгына җыйган.

Ниһаять, Газинур кызларны күрше «Прогресс» колхозына алып килде. «Красногвардеец»тан нибары берике чакрымда мул гына сулы елга ага иде. Гөлләр моны күргәч, ачылып, шатланып китте. Ул Газинурны кулыннан тотты, алар йөгереп елга ярына төштеләр. Фатыйма, чәчәкләрен кочаклап, тау башында берүзе калды.

## 10

«Красногвардеец»тан договор белән эшкә китүчеләр юлга әзерләнә башладылар. Гарәфи абзый, юлда чәй күп эчелә дип, тишек калай чәйнеген тимерчедән кургаш белән яматып алды, юлда аш күп ашала дип, ел саен кысыр кала торган симез сарыгын суйды; читтә йөргәндә хатын янда булмый дип, барлык ертык-тишекләрен яматты, өзелгән төймәләрен тактырды; мин киткәч, өйдәгеләргә кыен булмасын дип, кышлыкка утынын кисеп-ярып, әрдәнәгә өеп куйды; абзар-кураларын төзәтте, юлга, кул очында бераз акча да булсын дип, председательдән ат со-

рап, Бөгелмә базарына барып кайтты. Шул эшләр арасында бер атна вакыт үткәне сизелми дә калды. Ниһаять, Гарәфи абзый биленнән иртә-кич төшми торган алъяпкычын салып аны хатынына бирде. Шуннан ул, өйалдына чыгып, бакча кырындагы урындыкка утырды.

Урам буш, анда бары тик кара сыргалы ике кәҗә тәкәсе сикерә-сикерә уйный. Башта алар урамның теге ягында иде. Аннары, ялт иттереп, чокырга сикереп төштеләр, күз ачып йомганчы бу якка чыктылар. Бу кадәресенә Гарәфи абзыйның бер дә исе китмәде. Кәҗә тәкәләренең мутлыгы һәркемгә билгеле. Ләкин ул каһәр суккан нәрсәләр кое янындагы атлар эчерә торган озын улак белән генә дә чикләнеп калмадылар, ә кое бурасы өстенә сикереп менеп, шунда маңгайга-маңгай сөзешә башладылар.

Гарәфи абзый борчылып куйды.

– Һәй, юләрдән туган юләр нәрсәләр, коега егылып төшәсез ич! – дип кычкырды.

Кәҗә бәтиләре берни булмагандай кое өстеннән төштеләр дә сикерешә-сикерешә чабып киттеләр.

Якында гына кемнәрнеңдер сөйләшкән тавышлары ишетелде. Фермалар ягыннан урам бакчалары буйлап колхоз председателе Хәнәфи белән Гали абзый килә иде.

Гарәфи абзый, урыныннан торып, аларны аягүрә көтә башлады.

– Ни хәлләр бар, Гарәфи абзый, юлга чыгар алдыннан колхоз урамына карап утырасыңмы? – дип елмаеп сорады председатель.

– Әйе шул, – диде Гарәфи. – Күңелне аяздырыр өчен чыгып утырдым әле.

– Болытлыймыни? – дип сорады Гали абзый.

– Әзрәк болытлап тора шул.

Хәнәфи, Гарәфи абзыйга соңрак правлениегә керергә кушып, шунда ук китеп барды. Гали абзый Гарәфи янына утырды.

– Болытлап тора дисең, Гарәфи, – диде Гали абзый. – Димәк, күңел яңадан ерак җирләргә тарта?

Гарәфи әкрен генә көлеп алды.

– Чуттан төшеп калганчы, пример, бер әйләнеп кайтыйм әле, дидем. Югыйсә соңыннан карт дип эшкә дә алмый башларлар.

Гали абзый, фуражкасын салып, ак яулыгы белән такыр башын сөртте.

– Безгә картаерга иртәрәк әле, Гарәфи дус.

Гарәфинең кыска сары мыеклы йөзенә сагыш күләгәсе йөгерде.

– Анысы шулай да бит, Гали, еллар үтә... Сәламәтлек тә... Хәзер никадәр теләсәң дә, Кызыл Гвардиягә язылырга барган егет чакларны кайтарып алып булмый инде.

– Онытмыйсыңмыни әле ул заманнарны? – дип көлемсерәп куйды Гали абзый. – Врангельне Кара диңгезгә бәреп аткан көннәр хәтереңдәме?

– Хәтердә булмыйча. Онытырлык көннәр идемени алар, Гали!

Гали абзый Гарәфинең яшьлек дусты иде. Дөрес, алар бер авылда туып үсмәделәр. Гали абзыйның әти-әниләре, өйләнешкәч тә, эш эзләп читкә китеп барганнар, шахталардан шахталарга, приискалардан приискаларга күчеп йөргән чагында, кайдадыр ерак Себер рудникларының берсендә, семьялылар барагында аларның бердәнбер балалары Гали туган. Галинең бала чагы да, үсмер вакытлары да шушы баракларда, шахтерлар арасында үткән, ул кече яшьтән үк эшчеләрнең сыйнфый көрәшен үз күзе белән күреп килгән. 1912 елның 4 апрель вакыйгасы аның күңелендә гомергә онытылмаслык эз калдырган. Ленадагы алтын приискаларының хуҗалары булган Англия капиталистларының коточкыч изүләренә чыдый алмыйча баш күтәргән алты мең шахтер арасында Галинең әтисе Галиулла абзый да була, ә аңа ияреп Гали дә демонстрациягә бара. Эшчеләрнең кораллары булмый. Алар тыныч кына баралар, һәм шулай тыныч кына барган чагында аларга патша жандармнары ут ача. Кар өстендә биш йөз шахтерның үле һәм яралы гәүдәсе ятып кала. Гали башта бернәрсә дә аңламый. Ул әтисенең, күкрәген кулы белән тотып сөрлегүен, аннары кар өстенә авуын күрә. Халык йөгерешә башлый. Пулялар сызгыра. Гали әтисенең иңбашыннан селкетә.

– Әти, тизрәк тор, аталар! – дип кычкыра ул.

Ләкин әтисе тора алмый. Соңыннан аның үле гәүдәсен күтәреп алып кайталар. Төнлә унөч-ундүрт яшьлек Гали кесәсенә таш сала да бpraктан чыгып югала. Ул шахта түрәләре торган йорт тирәсендә бик озак йөри. Ахырда, сакчылар янынnan сиздермичә генә үтеп, тәрәзәләренә таш җибәрә...

Лена вакыйгасыннан соң Галинең әнисе туган авылы Сугышлыга кайта, шунда яши башлый.

Гарәфи исә Сугышлыда туа, аның бала чагы да, үсмер чаклары да шул тын авылда үтә. Алар бай да, үтә ярлы да булмыйлар. Аларның сыңар күзле бер атлары, кәҗә хәтле генә сыерлары, салам түбәле йортлары була. Әти-әниләре, апа-сеңелләре белән Гарәфи шул йортта тәрбия-

ләнә, үзенең бөтен киләчәген шул йортны ишәйтүгә багышларга уйлый.

Ләкин Ленадагы атулардан соң яңа бер көч белән кузгалып киткән революцион хәрәкәт дулкыннары тора-бара ерак Сугышлыга да килеп җитә.

Көннәрдән бер көнне Сугышлы кешеләре арасында Бөгелмәдә Кызыл Гвардия отрядлары төзелә дигән хәбәр тарала. Гали, бу турыда ишеткәч тә, Кызыл Гвардиягә язылырга була. Аңа ияреп, шактый вакыт икеләнгәннән соң, Гарәфи дә кузгала. Ләкин күңелендәге икеләнү тычкан кебек бертуктамый аның йөрәк читен кимерә. Гарәфи бара-бара да бер әйтеп куя икән:

– Әткәй карт белән әнкәй карчык күз алдымнан бер дә китми. Йөрәгемне өзәләр, – дип.

– Алай булгач, бар, кайт, – ди Гали, көлеп.

Гарәфи дәшмичә башын иеп бара. Аннары тагын әйтеп куя икән:

– Мин булмагач, аларның сукаларын кем сукалар.

Гали тагын, мыскыллап, аңа әйтә икән:

– Бар, кайт, алайса, – ди. – Мин синең өчен дә, үзем өчен дә буржуйларны кыйнармын.

Аларны отрядка алалар. Ләкин күп тә үтми, Гарәфи, ниндидер йогышлы чир белән авырып китеп, лазаретка эләгә, аннары аны авылына кайтарып җибәрәләр. Ә Гали Бөгелмәдә кала. Аның башыннан күп хәлләр уза, кулаклар фетнәсе вакытында аны бик каты кыйныйлар, ат койрыгына тагып йөртәләр. Авылда аны атканнар дип тә, асканнар дип тә сөйлиләр. Гарәфи аның белән яңадан байтак вакыт үткәннән соң гына, армиядә генә очраша. Алар бергәләп акларны Томскига кадәр куып баралар, аннары Врангельне, дөмбәсләп, Кара диңгезгә атып ташлыйлар. Гали инде командир була. Шуннан күп тә үтми, яраланган Гарәфине яңадан авылына кайтарып җибәрәләр. Алар Кырымның карасу биек чинарлары астында кочаклашып аерылалар.

– Илгә кайткач, кара, Гарәфи дус, колакларыңны йомып йөрмә, үзебезнең Советский власть өчен көчеңне кызганма. Бәлки, мине ат койрыгына таккан куштаннар, тиреләрен алмаштырып, әле дә шыпырт кына яталардыр анда. Очратсаң, солдатча эшләрен бетер, – ди икән Гали, үзе үк көрсенеп куя икән. – Юк, булдыра алмассың, юашрак кеше син, Гарәфи, йөгән белән әйдәсәң, калмыйсың, барасың, әмма тезгенеңне ычкындырсалар, сукыр тәкә кебек төртеләсең дә куясың, – ди.

Дөрес әйткән икән шул Гали. Гарәфи абзый, авылына кайткач, яңадан шул сыңар күзле атына, сукасына ябыш-

кан. Еллар үткән, Гарәфи берничә тапкыр читкә дә чыгып бәхет сынап караган. Аның белән бергә киткән Сугышлы егетләренең күбесе йә шахтада, йә рудникта, йә заводта урнашып калганнар. Ә Гарәфи тагын авылына кайткан. Көннәрнең берендә ул, Казаннан килгән бер уполномоченныйдан сорашып, Гали турында белешкән. Гали зур кеше. Казанда эшли икән, ләкин фронттагы яраларыннан соң сәламәтлеге бик шәптән түгел икән. Әллә кайларда, әллә нинди курортларда дәвалап караганнар – шифасы аз тигән. Врачлар аңа авылга кайтырга, борчылмыйча яшәргә кушалар икән.

Һәм шуннан соң күп тә үтми, илдә колхозлашулар башлангач, Гали абзый үзе дә Сугышлыга кайтып төшә. Гарәфи белән дә алар озак сөйләшәләр. Гарәфи тагын инә артындагы җеп шикелле, аңа тагыла.

– Әйдә, тезгенне сиңа бирдем, Гали, сиңа ышанам, – дип әйткән ул.

Колхозда Гарәфи абзый бик тырышып эшли, аның тормышы шактый түгәрәкләнә. Алтыпочмаклы өй салып җибәрә, каралтылар торгыза, өс-башын, өй җиһазларын өр-яңадан булдыра, балалары укырга керәләр. Шуның белән бергә Гарәфи үзенең дә эчтән яңаруын сизә. Аерым хуҗалык булып яшәгән чактагы өзлексез борчылулары, үзенең дә теңкәсенә тиеп беткән икеләнүләре, йоклаган чагында да җанын тындырмый торган иртәгәге көнгә булган ышанычсызлыгы бөтенләй юкка чыга. Ул җиңеләеп, яшәреп киткәндәй була. Колхоздашлары арасында аның хөрмәте арта, җыелышларда булса, аның киңәшләренә колак салалар.

Дөрес, еллар эзсез үтмәгәннәр. Гарәфи абзый да, бик үк картаймаса да, шактый олыгайган. Баш түбәсе пеләшләнгән, чигә чәченә чал кунган. Ул кулын артка куеп йөрергә күнегеп киткән. Шулай да бирешергә исәбе юк әле. Колхоздан эшчеләр сорап язу килгәнен ишеткәч, ул үзе председательгә барган, эшкә җибәрүләрен үтенгән...

Үткәннәрен искә төшереп, бакча алдындагы урындыкта кечкенә тынлыкка чумып барган урамга карап, әкрен генә сөйләшеп утырган бу ике кешенең тормыш юллары әнә шундый иде.

– Гали, – диде Гарәфи, хатирәләр кузгаткан күңел дулкынлануын басарга тырышып, – сәфәргә чыгар алдыннан шулай бер сөйләшсәң, күңелләр иркенәеп китә. Әйдә, булмаса, кереп берәр чынаяк чәй дә эчик. Парлап кунакка чакырып булмады, гаепләмәссең инде.

Гали абзыйның эреләнә, кыстата торган гадәте юк иде. Махсус рәвештә кунакка йөрергә яратмаса да, җае туры

килгәндә бер-ике чынаяк чәй эчүдән һичкайчан баш тартмады. Бу юлы да ул, җыелышка барыр алдыннан әзрәк ял итеп аласы булуга карамастан, каршы килмәде.

Алар Гарәфинең ак өенә керделәр. Өй эче якты, кызлар бүлмәсе кебек чиста иде. Стена буенда эреле-ваклы мендәрләр өелгән шарлы тимер кровать, каршы якта савыт-сабалар тутырылган пыяла шкаф, зур көзге, бер кечерәгрәк өстәл. Ак чыбыктан үрелгән этажеркада китаплар тезелгән. Тәрәзә төпләрен кургашын кәгазьгә төрелгән чүлмәкләргә утыртылган гөлләр бизәгән.

Гарәфинең хатыны Бибигайшә җиңги – өстенә эре-эре бизәкле күлмәк кигән, яулыгын киленнәрчә артка кысып бәйләгән җитез хатын – толымнарына үргән тәңкәләрен чылтырата-чылтырата табын әзерләргә кереште, кунак алып киләсе булгач алданрак әйтергә кирәк иде, дип, ирен җиңелчә генә шелтәләп алырга да өлгерде.

– Сез Гарәфигә ачуланмагыз, Гайшә, – диде Гали абзый, көлеп. – Мин үзем мәшәкатьләдем сезне. Сез пешергән коймак бик тәмле була иде, коймак ашыйсым килде дә кердем.

– Коймакка булгач, парлап киләләр, Гали абзый, – диде Бибигайшә җиңги, өстәлгә берсеннән-берсе тәмлерәк ашларын тезеп. Уңган хатын бервакытта да югалып калмый, һәр көтелмәгән кунакка аның сые әзер була. – Йә, рәхим итегез. Гали абзый, үзегез яраткан коймактан авыз итегез, – диде ул.

Гали абзый аның тәмле коймакларын мактый-мактый ашарга кереште.

– Ул хәтле күтәреп мактамасагыз да ярар инде, Гали абзый. – Бибигайшә җиңги, җиңелчә кызарып, Гали абзыйга чәй ясап бирде.

Гали абзый, куе итеп ясалган чәйне рәхмәт әйтеп алып, күңелле генә сөйләргә кереште:

– Менә Гарәфи картаям инде дигән була, Гайшә, ә үзе, киек каз кебек, әллә кайларга китәргә җыена.

– Без инде, Гали абзый, аның чуар йөрәклелегенә күнегеп беткән. Әйдә, йөрсен бераз, бездән чибәррәкләрне тапмаса, әйләнеп кайтыр әле.

Гайшә җиңги аска карап утырган иренә күз атып алды. Аның бу карашында ачулану да, сагышлану да бар иде. Күрәсең, Гарәфи абзыйның читкә китәргә теләве семья эчендә шома гына үтмәгән. Гали абзый сүзне җайсызрак башлап җибәрүе өчен үз-үзен орышып алды. Шуның өстенә ул бу җиңел сөякле хатынның вакыт-вакыт авыруы кузгалуын да белгәнгә күрә, аңа Бибигайшә җиңги хәтта кызганыч булып китте.

– Шәһәр күчтәнәчләре алып кайткач, пример, бездән дә әйбәтрәкләре булмас әле, – диде Гарәфи абзый, үзе кунагын кыстарга тотынды.

– Алдан кычкырган күкенең башы ярыла, алдан мактанма әле, – диде Бибигайшә җиңги, көлеп. – Ярар инде, ир кешенең теләгенә каршы килеп булмас. Барсын инде.

Шуннан соң мәҗлес яңадан күңелле төс алды һәм ахыргача шулай дәвам итте. Аннары Гали абзый Бибигайшә җиңгигә сый-хөрмәте өчен рәхмәтләр әйтеп, артык борчылмаска киңәш итеп чыгып китте.

Бибигайшә җиңги:

– Безне онытмагыз, кергәләп торыгыз, Гали абзый, – дип озатып калды.

Көтүдән кайткан терлекләрне абзарга япканнан соң, Гарәфи абзый яңадан бакча алдына чыгып утырды. Ни өчендер аның күңеле һаман тынычлана алмый иде.

Һава караңгыланып килә. Урамга куе күләгәләр сузылган. Фермалар ягыннан көчле гөрелте, көлгән, кычкырган тавышлар ишетелә. Бигрәк тә кызлар яңгыравыклы тавыш белән көләләр.

Коры чокырның аргы ягында Газинур күренде.

– Газинур, бире кил әле, – дип кычкырды Гарәфи абзый, утырган җиреннән кул болгап.

Газинур шунда ук аның янына килеп җитте. Ул якасы ачык ак күлмәктән, биленә каеш буган, аягында күн итек. Аны өстенә иске бишмәт киеп, алдына алъяпкыч ябып, аягына резина галош элгән килеш күрергә күнеккән Гарәфи абзый шаяртмыйча булдыра алмады.

– Газинур, туйга әзерләндеңме әллә, пример?

Газинур кара кашын биетеп куйды.

– Туйга бик әзерләнер идем дә, Гарәфи абзый, каз өмәләре вакыты җитмәгән шул. Бүген клубта кунак кызының докладывы була. Доклад тыңларга, үзең беләсең, атлар янында йөргән кием белән барып булмый. Докладтан соң уен булачак. Ат исе чыгып торса, кызлар яныннан таяр.

Гарәфи абзый, көлемсери төшеп, башын чайкады.

– Җавапны син таба беләсең, Газинур. Йә, ничек, пример, әйтик, юлга әзерме соң?

– Минем әзер булганга бишбылтыр инде, Гарәфи абзый, – дип, бер дә тоткарлыксыз җавап бирде Газинур, – аркага юл капчыгы асасы да эти-әни белән саубуллашасы. Аннары, даешь Урал!

Гарәфи абзый Газинурның шат, көләч, алсу йөзенә озак карап торды. Мөгаен, ул күптән түгел генә мунча кереп чыккандыр. Яңаклары алма кебек янып тора. Бер кара-

ганда, ул исерек тә кебек, бер караганда, бөтенләй аек. Ятим үскән, балачак иркәлеген татымаган, җиде-сигез яшеннән үк этисе белән көтү көтә башлаган, колхоз оешканга кадәр кышларын да кулакларда батрак булып эшләгән, алардан хәтсез күп кагылу-сугылуларны күргән бу яшь егеттә кайдан шулкадәр көр күңеллелек, кайдан шулхәтле үз-үзенә ышану? Менә Гарәфи булып Гарәфи читкә чыгып китәр алдыннан утырыр урын тапмыйча борчыла. Мактанудан түгел, Гарәфи бит Уралын да, Себерен дә, Кырымын да күргән кеше. Ә колхозыннан утызкырык чакрымнан да ары китмәгән Газинур ник бер генә хәвефләнсен, ичмасам. Була икән шундый кешеләр!

– Җиңелрәк карыйсың син тормышка, Газинур, җиңелрәк. Уй-сагышың юк синең, пример.

– Уй-сагыш ул, Гарәфи абзый, – диде Газинур шаян тавыш белән, – эшсез кешеләрдә генә була. Минем бүгенгәчә эшсез торганым булмады. Ни пычагыма уй-сагышның кирәге бар?

Уйлама, күңелем, эллә ни,
Уй бетерә бәндәне.

Гарәфи абзый ихтыярсыздан көлеп куйды.

– Диңгез сиңа, пример, һаман тубыктан икән әле, Газинур. Бер караганда, сокланам да сиңа, җиңел яшисең, матур яшисең. Дөньядан да курыкмыйсың, пример.

Газинур кинәт бик җитдиләнеп китте. Авыз эченнән көйләүдән туктады.

– Үзебезнең Совет дөньясыннан ни өчен куркырга, Гарәфи абзый? – дип сорады ул. – Менә иске заман булса, бәлки, куркыр идем. Ә хәзер миңа кая барсам да бер кояш.

– Шулай, шулай, – диде Гарәфи абзый, үзе, Газинур белән беренче танышкандай, аны җентекләп күзәтте. «Гали абзыең чәчкән орлыклар синең күңелеңдә дә яхшы шытып чыкканнар икән, егет», – дип уйлап алды ул.

Газинур кесәсеннән һәйбәт папирос кабы чыгарды, аны, кош күрсәтәм, карагыз, очмасын дигәндәй кыландырып, Гарәфи абзыйга сузды.

– Рәхим ит, Гарәфи абзый, Казан кызларының бүләге.

Гарәфи абзый, алтын язулы папиросны бармак очларында әйләндерә-әйләндерә, киез эшләпәле башын кыйшайтып, Газинурга текәлде.

Газинур, аның хәйләле карашын сизмичә, Гөлләр бүләк итеп биргән папирос кабына карап елмаеп тора. Берсеннән-берсе биегрәк боз таулары. Бер кеше атка атланган да, башлык колакларын җилдә туздырып, җан-фәрман

чапкан аргамакта каядыр бара. Кавказ диләр бу таулы җирләрне. Газинур Кавказ турында этисенең бетмәстөкәнмәс солдат хикәяләрен генә ишеткәне бар. Әмма ишетү – бер, үз күзең белән күрү икенче. Эх, әгәр дә Газинур шул карлы тау башларын якыннан торып бер күрсә иде! Анда, ди, тау башларында кар, түбәндә виноградлар, әфлисуннар үсә.

– Кара аны, Газинур, – дип шаяртты Гарәфи абзый, хуш исле папиросны суыра-суыра. – Пример, әйтәм, сурәтле папирос кабына Казан кызы каптырып куймасын үзеңне. Була ул андый хәлләр яшь чакларда.

Урамның аргы ягыннан ныгып бетмәгән яңгыравыклы тавыш: «Газ-и-нур-р абый!» – дип кычкырды, һәм бөтен «Красногвардеец» тирәләре күңелле яңгыраш белән «...нур...» дип кабатладылар.

– Халикъ пилмән ашарга чакыра, – диде Газинур, урыныннан торып.

Гарәфи абзый да аякка басты.

– Ярый, Газинур, – диде ул, – шулай алайса, иртәгә таң белән кузгалабыз. Һашимга, Газзәннәргә, клубта күрсәң, әйт әле. Озак йокламасыннар. Юл кешесенең юлда булганы яхшы.

– Була ул, Гарәфи абзый, бер дә борчылма.

Җил капка төбендә Газинурны энесе Халикъ каршы алды.

– Абый, – диде ул, бик зур сер итеп әйткән шикелле әкрен генә, – әйдә тизрәк. Кунак апалар гөбедә май язалар, ә майлары төшми. Әни көлә, апалар көлә. Кызык!

– Ә пилмән?

– Пилмән өлгермәгән әле, аны әле казанга да салмаганнар.

Халикъ абыйсын кызык карарга гына чакырган икән.

Газинур ишекне ачканда, Гөлләр җиз кыршаулы гөбедә тырышып-тырышып май яза иде. Гөбе эчендәге атлагыч бер югары күтәрелә, бер түбән төшә, аның саен кызның кояшта янган куллары да бер күтәрелә, бер түбән төшә. Кыска сары чәчләре тузгып маңгаена сибелә. Ул аларны кул аркасы белән артка таба сыпыра да тагын озын саплы атлагычка тотына. Фатыйма, кулына китап тотып, көлә-көлә аңа карап тора.

Газинурны күргәч, Гөлләр эшеннән туктады.

– Уф, арыдым, – диде ул, елмаеп, һәм сәке кырыена утырды. – Коточкыч хезмәт икән.

– Газинур, сиңа юлга май атлыйлар бит, – диде мич янында казан асып маташкан әнисе. – Ни гомер азапланалар, месскеннәр. Үзем генә языйм дим дә, бирмиләр.

– Бәлки, юлда Газинур безне бер исенә төшерер дип тырышкан идек тә, булдыра алмадык, – диде Гөлләр, Фатыймага карап алып. – Югыйсә китәр дә бөтенләй онытыр.

– Шундый изге теләктә булуыгыз өчен бик зур рәхмәт, алайса, – диде Газинур һәм, учларын бер-берсенә ышкып, атлагычка тотынды. – Карап карыйк әле, нигә чыгымлый икән ул.

Кызлар Газинурның эшен кызыксынып күзәтә башладылар. Ул, бер дә көч куймый, шаярып кына эшли кебек. Үзе:

– Күз тидерерсез, туры карамагыз, – дип көлә.

Ул арада пилмән дә өлгерде, май да язылып бетте. Кызлар, гаҗәпләнеп, гөбегә карадылар.

– Чү, Газинур, нишләттең син?

– Әфсен укыдым, – диде Газинур, көлеп. – Сере һәм догасы бар аның.

Пилмән ашаган чагында каядыр югалып торган Халикъ ишектән атылып керде дә, бөтен кешегә ишетелерлек итеп:

– Гали абый клубка китте! – дип кычкырды.

– Ут чыкканмыни, нигә шулхәтле акырасың, юләр, – диде әнисе, ачуланып.

Кызлар пилмәннәрен тиз-тиз ашап бетерделәр дә клубка җыена башладылар.

– Ашыкмагыз, хәзер чәй дә өлгертәм, – диде Шәмсинур түти, – безнең халык алай ашыгып җыела торганнардан түгел.

– Әни, син үзең генә ашыкмый торган кеше, – диде аңа каршы Халикъ, үзе, авызына пилмән артыннан пилмән тутыра-тутыра, аңлатып бирде: – Клубта инде утырыр урын да калмаган. Сабирҗан бабай белән Галәк бабай да анда инде. Ы... ы...

– Төелеп үләсең ич, кая бу кадәр кабаланасың, – диде Шәмсинур түти. – Сөякләре коелырга торган Галәк бабайга ни калган тагы анда?

Халикъ бу мәгънәсез сорауга җавап биреп тормады. Бүген ул аеруча шат иде. Чөнки бүгенге җыелышны әзерләшүдә аның да катнашы зур. Ул, Гали абзый кушуы буенча белдерү язып, аны правление ишегенә ябыштырып куйды. Аннары үзе кебек иптәшләре белән, өйдән өйгә кереп, колхозчыларга җыелыш буласын әйтеп йөрде. Гөлләр аңардан җыелыш башланыр алдыннан чертежларны, схемаларны, кечкенә электростанция макетын сәхнәгә чыгарып куюын үтенде. Халикъның түбәсе күккә тиде.

## 11

Зал чыннан да шыгрым тулган иде. Кызларны юл биреп алга уткәрделәр. Чабуыннан тартуларына карамастан, Газинур да аларга ияреп алга узды.

– Килдегезме, кызлар, – диде Гали абзый. Кунакларны сәхнәгә, кызыл комач япкан өстәл янына чакырды. Аның өстендә һәрвакыттагыча яшел гимнастерка, билендә каеш, аякларында күн итек иде. Күкрәгендә Кызыл Байрак ордены, тагын нindидер значок ялтырый.

Гали абзый, Хәнәфи һәм Гөлләр сәхнәгә менделәр. Фатыйма менмәде. Ул Гали абзый урындыгына утырды. Газинур Хәнәфидән бушап калган урындыкны эләктерергә ашыкты.

Халикъ сәхнәдә Гөлләр янында бөтерелде. Менә ул Гөлләрнең колагына нәрсәдер пышылдады, аннары сәхнә артына йөгереп чыкты, яңадан керде, алдан әзерләнгән кадакларга Гөлләрнең чертежларын элә башлады. Кечкенә өстәлгә өсте ак җәймә белән ябылган нindидер бер серле әйбер китереп куйды. Бу вакытта аның кояшта каралып беткән йөзе шундый тантаналы, шундый бәхетле бер төс алган иде, әйтерсең бүгенге кичәдә иң-иң кирәкле кеше ул, залда утыручылар барысы да аның сүзен тыңларга җыелганнар кебек.

«Кара, абыйсыннан алда тәбегә баса бит, кара бөрчә», – дип уйлады Газинур, үзе, артына борылып, күзләре белән Миңнурыйны эзләде. Бая ишектән кергән чагында аның чуар яулыгы күзгә чагылып калган иде, хәзер бер җирдә дә күренми. Кая китте икән?

– Иптәшләр, – диде Гали абзый, һәм шау-шу берьюлы басыла башлады. – Бүген безнең алдыбызда Гафиятулла бабайның, – ул алдагы рәтләрнең берсендә утырган Гафиятулла абзыйга карап алды, – Казаннан килгән кунак кызлары бар. Менә Гөлләр, – ул уң ягында утырган кызга башы белән изәде, – безгә колхоз электростанцияләре турында сөйләячәк, ә Фатыйма, – ул Галәк бабай белән Газинур уртасында, беренче рәттә утырган кызга ымлады, – сөекле шагыйребез Һади Такташның шигырьләрен укыячак. Шауламыйча, игътибар белән генә тыңлап утыруыгызны үтенәм. Сүз Гөлләр иптәшкә бирелә.

Гөлләр, чәнчә бармак юанлыгындагы чыбыкны ике кулы белән ике башыннан тотып, сәхнә кырыена килеп басты. Ул кыска җиңле ак күлмәктән, биек үкчәле ак туфлидән. Буе зифа, биле өзеп алырдай нечкә. Сары бөдрә чәчләре иңнәренә тиеп торалар.

– Иптәшләр, – диде ул сөйкемле ачык тавыш белән.

Утыручыларга бу гадәти сүз бик табигый, бик тыныч әйтелгән күк тоелды, Гөлләр исә бик каты дулкынлана иде. Ул авылда үзенең булачак диплом эшен аз-маз караштыргаларга гына исәпләгән иде. Гали абзыйның тәкъдименә ул ашыгыбрак ризалык бирде. Колхозчылар алдында чыгыш ясауның никадәр җаваплы бер эш булуы турында уйламаган иде ул. Шул турыда ныклап уйлый башлагач, төн йокылары качты. Ул бит бары тик студент-дипломник кына. Аның белеме дә төгәлләнмәгән әле. Ә колхозчылар өчен электростанцияләр кызыклы фән яңалыгы булудан күптән узган. Ул – алар өчен тормыш мәсьәләсе, ул – аларның иртәгәге көне. Менә шуңа күрә дә алар клубка шулай шыгрым тулганнар. Шуңа күрә дә йөзьяшәр Галәк бабай да мич башында кала алмаган, җыелышка килгән, уң кулын колагына куеп, докладчының һәр сүзен игътибар белән тыңларга әзер тора. Газинурны, аның кебек атлыгып, янып торган уннарча колхоз яшьләрен әйтмисең дә инде.

Гөлләр Совет хөкүмәтенең һәм Коммунистлар партиясенең киләчәктә авылларны электрлаштыру эшенә никадәр зур игътибар бирүе турында сөйләде дә докладының, иң авыр өлешенә – колхоз электростанциясенең ничек корылуына күчте. Әллә инде Гөлләр электричество белән һичбер танышлыклары булмаган кешеләргә дә шуны аңлаешлы итеп сөйләп бирә белгәнгәме, әллә «бу кызый менә нинди хикмәтләр сөйли, каян аңлап бетерәсең барысын да» дип, кешеләр үзләре аптырап калгангамы, – аны бүлдерми-нитми тыңладылар. «Мөгаен, бик начар сөйлим, берни дә аңлата алмыйм», – дип борчылды Гөлләр. Ул, дулкынланып, үзенең чертежларын, схемаларын, ак җәймә япкан, барысын да бик сәерсендергән әйбернең өстен ачып күрсәтте. Уенчык өйгә охшаган бу әйберне Гөлләр «макет» дип атады. Залдагылар бер кешедәй булып сәхнәгә таба сузылгач кына, ул җиңел сулап куйды. Аннары шундый электростанцияне салыр өчен күпме материал, күпме вакыт, күпме акча кирәклеген бәйнә-бәйнә төшендереп бирде. «Красногвардеец»ның үзендә электростанция салу мөмкинлегенә күчкәч, халыкның кызыксынуы тагын да арта төште.

– Электр чыгару өчен су кирәк, дидегез. Безнең чишмәләрнең суы чыпчыкка муеннан, каргага тездән, – дип кычкырдылар залдан.

Шуның артыннан ук шау-шу купты.

Гөлләр тавыш басылганны көтте дә бераз елмайган хәлдә:

– Тынычланыгыз, иптәшләр! Су бар, суны Газинур табып бирде, – диде.

Халык Газинурга үрелеп карый башлады. Почмакка посып утырган Тавык Мортый:

– Ачкан икән Казан каласын! – дип кычкыруга бөтен зал шаркылдап көлеп җибәрде.

Гали абзый халыкны көч-хәл белән тынычландыргач, Гөлләр сүзен дәвам иттерде:

– Дөрес, иптәшләр, сезнең үз җирегездә су юк, ләкин сезнең күршегездә – «Прогресс» колхозында су бар.

Тавык Мортыйның мыскыллы тавышы яңадан ишетелде:

– Яфановкада, иптәш докладчы, Зәй суы бар, Андреевкада – Дымка суы. Күрше районда – Ык. Анысы тагын да зуррак. Бәлкем, суны шуннан гына алырбыз, Газинур соравы, чуртан кушуы буенча, ә?

Бу юлы берәү дә көлмәде. Киресенчә, бөтен яктан Мортыйга ачулана башладылар. Галәк бабай таягына таянып урыныннан торды да Гөлләргә мөрәҗәгать итте:

– Сүзеңне бүлмә, кызым. Безнең арада акыл өләшкәндә пумала астында калган бер мескен җан иясе бар. Кушаматы – Тавык. Шуңа күрә көн элгәре кытаклый ул.

Галәк бабайга ду килеп кул чаптылар. Гөлләр, ап-ак сакаллы картның бу кадәр ачы телле булуына гаҗәпләнеп, сүзен дәвам иттерде. Бабайның үтергеч сүзләреннән соң әлеге Тавык кушаматлы кеше белән бәхәскә керүнең мәгънәсе калмады.

– «Прогресс»ның фермалары турысыннанрак, – диде Гөлләр, – өч йөз-дүрт йөз метр канау казыганда, сезнең үз җирегездә плотина эшләп булачак.

Бу фикер халыкка бик тиз барып җитте. Хәнәфи, Гали абзыйның колагына пышылдап:

– Разведка сведениеләре начар түгел бит, – диде. – Бу турыда чынлап уйлашырга да кирәк булыр.

– Уйлашырга кирәк, әлбәттә. Ләкин канау турында түгел. «Красногвардеец» белән «Прогресс»ка икесенә бер электростанция салу турында. Бу эш җиңелрәк тә, арзанрак та булачак.

Доклад һәм сораулар шактый озынга сузылды, Галәк бабай: «Электр йортыгызны миңа да күрсәтегез әле, балалар», – дип, сәхнәгә үк менде. Залдан аңа: «Яхшырак кара, Галәк бабай, электростанция салгач, сине анда главный итеп куярбыз», – дип кычкырдылар.

Сәгать уникенчегә киткәч, Гали абзый Гөлләрне кызганды булса кирәк, сорауларны туктатты.

– Гөлләр белән соңгы очрашуыбыз түгел, иптәшләр, ул бездә җәй буе торачак, – дигәч, халык тына калды.

Тәнәфестән соң сүз Фатыймага бирелде. Ул сәхнәгә чыкты да, тавыш басылганны көтеп, башын түбән иеп торды. Аннары Һади Такташның сугыш уты кабызырга маташучы «Англиянең мәгърур лордына» язган мәшһүр нотасын укырга кереште. Укыган саен аның тавышы көчәя, катылана барды.

Мин нотамны сиңа, «җәнап гали»,
Фәлән-төгән диеп башламыйм.
Мужик булып язам,
Йөрәктә дә
Англиягә ачу сакламыйм...

Шагыйрьнең нәфрәтле сүзләрен Фатыйма мөмкин кадәр көчлерәк пафос белән укырга тырышты. Аның тавышы тыңлаучыларның йөрәкләренә үтеп керерлек рәвештә яңгырадылар.

Сиңа каршы булган аэропланнар
Гади алюминнан коелыр.
Ләкин...
Шул тиеннәр биргән миллионнарны, –
Сугыш ачсаң, –
Сугыш сафында
Очратырсың әле тагын да.
Гаскәрләрең көчле,
Тик шулай да
Ул гаскәрләр безне җиңә алмас!

Фатыйма аеруча бер дәрт белән соңгы юлларны укыганда, клубка МТС тракторчысы Исхак Зәбиров килеп керде. Аңа берәү дә игътибар итмәде. Ул ишек яңагына сөялеп тыңлый башлады. Аннары, янындагы егетнең колагына иелеп:

– Кем бу? – дип сорады.

– Казан кызы.

Фатыйма укып бетерде. Аңа бик озак кул чаптылар. Аннары ул сөекле шагыйребезнең тагын бик күп шигырьләрен укыды. Тагын кул чаптылар. Газинур, сәхнәгә үк йөгереп менеп, чиксез дулкынланган тавыш белән: «Рәхмәт, Фатыйма, рәхмәт Такташ абыйга да!» – дип, кызның кулын кысты.

Кичә тәмам булгач та, картраклар тарала башлады, ә яшьләр уенга калды. Урындыклар тышка чыгарылды. Кызлар, су сибеп, идәнне себереп алдылар. Аннары клуб уртасына куелган ике урындыкка ике гармунчы килеп утырды һәм бию көен сыздырып җибәрделәр.

– Әйт шуны! – дип кычкырып, Газинур уртага сикерде, бармакларын шартлата-шартлата биеп тә китте. Ул әле бер кулын, әле икенче кулын баш артына куя, шул

уңайга көләч йөзен әле уңга, әле сулга бора. Ә аяклары әйтерсең идәнгә дә тимиләр – очалар гына.

Гөлләр каршында ул аеруча кыланып биеде. Яшьләр аны төрле яктан кыздырып тордылар. Гөлләр арыган иде, ләкин шундый ихлас күңел белән биеп чакыруны илтифатсыз калдырырга көче җитмәде. Ул кулларын киң җәеп, түгәрәк буйлап бер әйләнде дә уртага басып бии башлады. Газинур аңа сокланып карап торды. Гөлләр гүя биеми, ә иксез-чиксез зәңгәр күктә, кояш нурларында коенган ак күгәрчен кебек, дәртен тыя алмыйча, уйнап оча...

Гөлләр, Газинурның иңбашына кулын салып утырган Һашимны уртага чакырып алып, аның урынына утырды.

– Гөлләр, – диде Газинур, аның ялтырап торган күзләренә карап. – Димәк, безнең колхозда чынлап та электростанция корып була? Мин берүзем син әйткән теге өч йөз метрлы канауны казып бирер идем. Валлаһи газыйм менә.

Кыз, сулышын еш-еш алып:

– Син китәсең бит, – диде.

– Хәзер мин китмәскә дип тә торам әле. Үзем бармасам, Хәнәфи абый мине көчләп җибәрми.

Гөлләр аның колагына иелеп пышылдады:

– Юк, Газинур, син фикереңнән кире кайтма. Син анда монтерлык эшенә өйрәнергә тырыш.

Биюләр – җыр белән, җырлар биюләр белән алмашынды. Газинур яшьләр арасында Исаково кызларын да, күрше чуваш авылы Наратлы кызларын да күрде. Берберсеннән бер-ике километр җирдә генә яшәгән рус, татар, чуваш яшьләре клубтагы кичәләрдә һәрвакыт диярлек аралашып торалар, бергә уйныйлар, бергә бииләр иде.

Такта яручы Пашка белән Степан да монда. Степанның иңендә гармун. Ул уйнамаса да, «Красногвардеец» кызлары аңа аеруча сөйкемле карыйлар.

Менә бер чуваш кызы белән «Красногвардеец» егетен уртага алып, аларга парлап җырларга куштылар. Сары чәчле, кыр чәчәге кебек зәңгәр күзле чуваш кызы, бер дә тартынып тормастан, бик ягымлы тавыш белән татарча җырлап җибәрде:

Ал да була, гел дә була
Күгәрчен билләрендә.

Егет аңа кушылды:

Бул син батыр, бул көрәшче
СССР илләрендә.

Ишек төбендә, уенга катнашмыйча басып торган яшьләр арасында, Газинур Сәлимне күрде. Ул, ниндидер

көлке әйбер турында сөйләп, яшьләрнең игътибарын үзенә тартырга маташа иде. Кызларның берсе аны, кулыннан тотып, уенга сөйрәмәкче булды. Сәлим, кулын күкрәгенә куя-куя, уйнарга теләге юклыгын аңлатырга тотынды. «Назлыбикә», – диде Газинур эченнән.

Сәлим доктордан язу китергәндерме-юкмы, Газинур ул кадәресен тикшереп тормады. Ләкин китүчеләр исемлегендә ул да бар иде.

Фатыйманы уртага чакырдылар. Ул сүтелә башлаган кара толым очын үреп түгәрәк уртасында басып торган чагында, Исхак Зәбиров такта яручы Степанның баянын тартып алды да, аягүрә баскан килеш, дәрт белән сыздырып җибәрде. Бу әле күптән түгел генә татар композиторларының берсе тарафыннан язылган яңа бию көе иде. Фатыйма, бераз гаҗәпләнеп, тиз генә башын күтәрде, аксыл бөдрә чәчле, матур, таза егеткә сынап караганнан соң, гүя минем бу карашымны сизмәсеннәр дигәндәй, очып биеп китте.

Гөлләр почмакта басып торган кызларның пышылдауларын ишетте:

– И җаным, шул Исхакның гармун уйнаулары...

– Биючесе дә, гармунчысы да пар килгәннәр.

– Кем бу? – дип сорады Гөлләр Газинурдан.

Газинур, горурланып:

– Тракторист! – дип җавап бирде.

Кинәт Газинур юкка чыкты. Гөлләр, тәрәзә төбенә утырган Халикъны чакырып алып, Газинур кайда дип сорады. Абыйсының серен белгән хәйләкәр малай капчыкны төбеннән тотып селекмәде.

– Правлениегә кергәндер әле, – диде.

Бу вакытта Газинур, бакча рәшәткәсе аркылы сикереп төшеп, Миңнурыйның тәрәзәсен чиертә иде.

– Миңнурый, Миңнурый, – дип пышылдады ул.

Берничә чиерткәч тә Миңнурый тәрәзә янына килде, – күрәсең, ул көтеп торган. Ләкин йөзе ачулы, кашлары җыерылган.

– Ни кирәк сиңа, шар күз? Бар әнә, иреннәреңне турсайтып, кунак кызларына карап утыр.

Газинур әкрен генә көлеп җибәрде:

– Ачуланма, Миңнурый... Мәхәббәтем синдә генә.

Кызның тавышы тагын да рәхимсезләнә төште. Сүзләре боз кебек салкын иде.

– Тасма телләнмә әле. Яхшылыкта кит, югыйсә өстеңә кайнар су сибәчәкмен.

Газинур сөйли генә башлаган иде, Миңнурый авыз ачарга да ирек бирмәде:

– Кунак кызлары янында мөкиббән китеп утыра бит, әнекәем. Кыланышыннан гарьләнеп үләрсең. Бөтен дөньясын оныткан. Кунак кызы белән колактан-колакка сөйләшкән була.

Нәрсәгә соң Миңнурый бу кадәр ярсыган? «Мөгаен, сүз ирештергәннәрдер», – дип уйлап алды Газинур, үзе тәрәзә төбендәге тамчылы гөлне бер читкәрәк этеп куйды: ул аңа карарга җайсызлый иде. Миңнурый гөлне яңадан үз урынына утыртты.

– Кич буе, ичмасам, әйләнеп тә карамый...

– Карадым, син күренмәдең.

– Күренмәдем! Синең шардай күзләрең мине күрерлекмени. Мин бит инә очы кадәр генә, мине күрер өчен зур күрсәтә торган пыяла кирәк.

– Җитәр инде, Миңнурый. Бу ачулануларың белән дә йөрәкне теләсең.

– Булган ди синдә йөрәк. Бар, югал. Тәрәзәм төбендә өрәк кебек катып торма әле.

– Мин иртәгә китәм бит, Миңнурый, – диде Газинур әкрен генә.

– Китсәң, юл такыр.

Кинәт Миңнурый, куллары белән йөзен каплап, артка тайпылды.

– Миңнурый җаным, Миңнурый, – дип дәште Газинур.

Кыз җавап бирмәде.

Газинур тәрәзә төбендә тагын бераз басып торды да бакчадан урамга чыкты. Клубның ачык тәрәзәләреннән гармун чыңнары, тыпыр-тыпыр биюләр, кул чабулар, шат тавышлар ишетелә. Мәктәп почмагында кемнәрдер сөйләшеп тора. Газинур адымнарын әкренәйтте.

– Һашим бәгырем, онытмассыңмы?

– Юк, Әлфия җаным, онытмам.

Газинур кулларын чалбар кесәсенә тыкты да, Һашим белән Әлфиягә кызыгып, авыл буйлап фермаларга таба атлады. Аннары, бер көрсенеп алып, кычкырып җырлап җибәрде:

...Ут салалар, су салмыйлар
Янган йөрәкләремә.

...Икенче көнне, төш вакытларында, Газинурлар Бөгелмә вокзалында вагонга утырдылар. Газинур күңелсез иде. Гарәфи абзый да, Һашим да, Газзән дә, башкалар да моңа игътибар иттеләр. Газинур юл буе әллә нинди моңлы җырлар җырлап килде. Аның күңелсезлегенең сәбәбен иптәшләре төрлесе төрлечә юрады. «Туган-үскән җирдән чыгып киткәндә, һәркемгә шулай ямансу була ул», – диде аз сүзле Газзән. Гарәфи үзенчә нәтиҗә яса-

ды: «Әйттем бит, Газинур, пример, кунак кызы белән сак бул. Теге Казбек тавы буйлап чапкан атта йөрәгеңне алып китте, ахры, ул синең».

Газинур берсенә дә җавап бирмәде, акланган булып төрле уен-көлке сүзләр дә әйтмәде. Атта килгәндә, артка каерылып-каерылып карады. Вагонга кереп утыргач, ачык тәрәзә яныннан китмәде.

Перронда халык кайный. Кемнәрдер, соңга калам дип, акны-караны күрмичә йөгерә. Чәйнекләр шалтырый. Кемнәрдер саубуллаша, хат яз, онытма, диләр. Әнә алдарак берсе – ак чәчле карчык – күз яшьләрен кулъяулыгы белән сөртә. «Аерылулар шушы инде», – дип уйлап куйды Газинур һәм шунда, перронга күтәрелә торган баскычларда, аның күзләренә чуар яулык чагылып китте. Егет үз-үзен онытырлык дәрәҗәдә:

– Миңнурый! – дип кычкырып җибәрде, кешеләрне этә-төртә ишеккә ташланды.

Көрәк сакаллы бер рус карты аның артыннан:

– Вот, ошалелый! – дип башын селкеп калды.

Перрон уртасында кая барырга белмичә, як-ягына каранып торган Миңнурый янына Газинур, ук кебек атылып килеп, ике беләгеннән тотты, очкынланып торган кара күзләре белән аңа текәлеп карап:

– Миңнурый бәгырем! – диде.

– Газинур... – диде Миңнурый әкрен генә. – Уф, кичектем дип котым очты.

– Каян килеп чыктың? Ничек килеп җиттең, Миңнурый?

Кыз озын керфекләрен түбән төшерде. Ничек килеп җитте соң ул? Моның хәзер әһәмияте бармыни. Ул олы юлга кадәр өч километр чамасы җәяү йөгерде, аннары атка утырды, ат бик әкрен бара күк тоелгач, тагын җәяү, турыдан йөгерде, ә аннары аны автомобиль куып җитте...

– Ничек булса да килдем инде, – диде ул, чак-чак тынын алып. Хәзер бу алсуланган, чиксез дулкынланган Миңнурый кичәге салкын, чәнечкеле Миңнурыйга бер дә охшамаган иде. Сөйкемле, оялчан, матур Миңнурый. Ул Газинурга шундый өздереп карый, кулларын аның кулларыннан тартып алу түгел, үзе аңа ныграк сыена бара.

Чаң суктылар. Халык вагон ишекләренә ябырылды. Миңнурый куеныннан чиккән яулык чыгарып, оялып кына, Газинурга сузды.

– Мә, бүләгем булсын, Газинур.

– Миңамы? – дип шатланып сорады Газинур.

– Сиңа, – диде кыз әкрен генә. – Син бит минем... бер генәм. Онытма.

Газинур аны күкрәгенә кысты.

– Онытмам, бәгырем, онытмам!

Паровоз озын итеп кычкыртты. Аннары поезд әкрен генә кузгала башлады. Газинур вагон баскычына сикерде.

– Хуш, Миңнурый, хуш, акыллым. Хуш, гөләп чәчәгем!

Миңнурый, чуар яулыгын болгый-болгый, вагон белән янәшә йөгерә. Вагон тәгәрмәчләре кызурак әйләнә. Газинур яңакларында салкынча каты җилне тоя. Менә Миңнурый туктады. Ул һаман да әле яулыгын болгый. Әнә ул бик кечкенә инде. Ә вагон тәгәрмәчләре кызурак әйләнәләр. Миңнурый инде бөтенләй күренми дә. Поезд инде Бөгелмәнең соңгы йортлары яныннан чабып үтә. Алда очсыз-кырыйсыз киң кыр күренә.

– Хуш, Миңнурый, сау булыгыз, туган җирләрем! – дип, соңгы мәртәбә кычкыра Газинур һәм, тәгәрмәчләр тавышы кебек озын көйгә салып, җырлап җибәрә:

...Озакламый без кайтырбыз,<br>
Ай, кояшлар кебек әйләнеп.

## 12

Бер елга дип киткән Газинур ике елдан артык читтә йөрде. Караңгы төндә ат абзарлары алдына утырып сөйләшкәндә, йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә, дип әйткән иде Сабир бабай. Нинди хикмәтле, нинди матур сүзләр! Аларның чын мәгънәсен Газинур юлга чыккач кына аңлады.

Бөгелмәдән кузгалып киткәч тә, башта Газинурның уйлары Миңнурые турында гына булды. Сөйгәненең чуар яулыгы гына түгел, җырларга кушылып җырлана торган матур Бөгелмәнең биек-биек йортлары, завод трубалары, мәһабәт кыя сыман күтәрелгән элеваторы да – ул элеваторга Газинур никадәр ашлык ташыды! – күптән инде күздән югалуга карамастан, Газинур һаман да тәрәзә яныннан китмәде. Аңа ни өчендер киләсе станциядә Миңнурый яңадан күренер кебек тоела иде. Гүя аларның кайнар мәхәббәтләрен бер-берсеннән аерырлык көч тә, ара да дөньяда юк. Миңнурый – матур һәм чәнечкеле гөләп чәчәге – ул шундый кыз, ул бервакытта да, беркайчан да үзенең Газинурыннан аерылып калмас кебек. «Красногвардеец»тан Бөгелмәгә очып килеп җиткән кебек, алдагы станцияләрнең берсенә дә очып килеп җитәр шикелле. Ләкин станция артыннан станция үтте, ә ыгы-зыгы килеп торган перроннарда, Газинур никадәр генә йотлыгып караса да, Миңнурый күренмәде. Дөрес, берничә тап-

кыр ул алдана да язды – чуар яулыклы кызлар азмыни станцияләрдә! Ләкин, үзе алданса да, күңеле шатланды. Моннан соң Миңнурыйны исенә төшергән кечкенә генә нәрсәләр дә аның нечкә күңелен сөендерәчәк иде.

Поезд һаман алга бара. Ямь-яшел урманнардан дулкынланып торган алтын иген кырларына ыргылып чыга. Газинурның Миңнурый турындагы матур уйларына: «Менә кайда ул игеннәр! Монда колхозлар безнең «Красногвардеец» хәтле генә түгел икән!» – дигән яңа матур уйлар килеп кушыла иде. Авыллар, разъездлар, кечерәк станцияләр күренеп кала. Һәр җирдә яңа йортлар салалар, һәр җирдә, төзелешләр өстендә кызыл флаглар җилферди. Бу кызыл флаглар Газинурны станциядән станциягә озатып баралар. Ул, илдә барган төзелешләр турында әллә ничә кат ишеткән булса да, боларны үз күзе белән күргәннән соң: «Һай-һай, эшлиләр дә икән!» – дип куя иде. Ул арада җәйге тымызык җилдә җилфердәп торган чираттагы кызыл флагчык күздән югалуга, поезд матур болыннар, ямьле тугайлар буеннан бара башлый, зәңгәр тасма сыман вак-вак инешләр күренеп кала. Газинур яңадан үзенең Миңнурыен исенә төшерә, тавышын артык күтәрмичә, иреннәрен кәгазь сыярлык кына ачып, моңлы итеп җырлап җибәрә:

Минем исемдә син генә,
Бәгырем, белмисең генә.

Ләкин озак сагышлана, төшенкелеккә бирелә белми торган шат күңелле Газинур, бара торгач, яңадан үзенең асылына кайтты. Ике-өч сәгать үтүгә, аны бөтен вагон белә иде инде. Иптәшләре югары полкаларда тын гына ятып, колхоз эшләре, бала-чагалары турында үзара әкрен генә сөйләшеп барган арада, Газинурның шаян тавышы әле бер купеда, әле икенчесендә ишетелә иде. Әле ул вагонның аргы башында алар кебек үк договор белән эшкә баручы Норлат кызлары белән «Сарман»ны җырлый, әле кемнәр беләндер тамбурга чыгып тәмәке тарта, әле олырак юлчылар, аны үз яннарына утыртып, кайдан икәнлеген, кая баруын сораштыралар, Газинур үзе дә сораштыра. Кешеләр аның бөтен нәрсәне белергә теләвенә гаҗәпләнәләр. Шәл бөркәнгән бер татар карчыгы аның болай төпченүен ошатып та бетермәде булса кирәк:

– Белмәгәннең беләге тыныч, улым. Барысын белсәң, бик тиз картаерсың, – диде.

Газинур балаларча көлеп җибәрде.

– Юк, әбекәем, хәзер белмәгәннең түгел, белгәннең беләге тыныч. Беләге юан берне егар, белеме юан меңне

егар, ди безнең Галәк бабай. Сез аны белмисез инде. Йөз яшәгән карт ул!

Үз гомерендә бик күп җирләрдә булган, Уралны да белгән Гарәфи абзый Газинурның Бөгелмәдә аңа «ошалелый!» дип кычкырган көрәк сакаллы рус карты белән чәй эчеп утырганын күргәч, башын селкеп куйды:

– Һай-һай, җор! Һай-һай, су сөлеге бу Газинур! – диде бераз уйланып торгач, бөтенләй икенче тавыш белән сөйләп китте: – Үзебез турында, пример, берни әйтә алмыйм, бик кыенга туры килсә, сезонлы эшләрдә андый хәлләр булгалый, егетләр, борынны салындырып кую ихтималыбыз да бар. Әмма Газинур турында алдан әйтә алам: югалмас бу егет! Утта да янмас, суда да батмас! Күр, без вагонга утырганнан бирле яткан урыныбыздан кузгалганыбыз юк, авызыбызга йөзек капкан шикелле, һичкем белән сөйләшмибез, ә ул һаман кешеләр арасында.

Гарәфи абзый югары полкага менеп ятты. Аңа каршы мыштым Газзән яткан, өченче полкадан Һашим белән Сәлимнең башлары сузылган. Гарәфи абзый аларга күз кысып, елмаеп куйды:

– Куначага иртәрәк кунакладыгыз түгелме соң, егетләр? Безгә Газизҗан белән, пример, ярый, без – олы кешеләр, ә сез нәрсә, эреп аккан шикелле анда ятасыз? Вагон тулы кызлар. Безгә «Красногвардеец»тан гына килен алырга димәгән бит. Пример, әйтәм, бәлки, берәрегезнең бәхете шунда адашып йөри торган булса? Төшегез, хәзер үк төшегез! Түшәмгә төкереп ятмагыз әле. Төнлә дә йокларга өлгерерсез.

Ләкин төне буе йокламаган егетләр төшәргә ашыкмадылар.

– Их, булмаган нәрсәләр, – диде Гарәфи абзый, үзе, Газинурның аргы баштан ишетелгән җырына колак салып, өстәде: – Кешедән качмаган кешенең кеше белән сүзе була, ди. Яхшы сүз ишетә.

Вагон тәрәзәләреннән кояш нурлары бәреп керде. Югарыдан түбәнгә таба, бераз кыйгачлап, сизелер-сизелмәс кенә тибрәнеп торган алтын бау сузылды. Күзләренә кояш нурлары төшкән Газзән йөзен читкә борды. Һашим белән Сәлим дә башларын яшерделәр. Вагонның аргы башында Газинур «Нурия»не сузып җибәрде, аңа кызлар кушылды.

Юл борылып-борылып бара булса кирәк. Кояш нурлары инде икенче як тәрәзәдән керә. Ул да булмый, вагон эче караңгыланып китә. Гарәфи абзый баш астына куйган котомкасын җайлый да бүленгән сүзен дәвам иттерә:

– Кайчак, пример, мин үзем дә бу Газинурга аптырап куям. Аның күңелендә кешеләргә карата, нәрсә дип әйтим, яхшы теләкме, зур яратумы ята...

Һашим сүзне уенга борырга ашыкты:

– Вәсбия әби әйткән, ди, мин үлгәч, каберемне Газинурдан казытыгыз, дип. Дөресме икән?

– Ул кадәресен белмим, әмма ләкин, егетләр, оятны да күтәрә белергә кирәк, – диде Гарәфи абзый шелтәле тавыш белән. – Вәсбия әби ярым сукыр, ярым гарип, япаялгыз бер карчык. Дөрес, колхоз аны ташламый, ашарына-эчәренә биреп тора. Шулай да кешенең күңел дигәне дә бар бит әле. Җанлы кешенең сөйләшәсе дә, хәбәр ишетәсе дә килә, аннары теге-бу нәрсәгә мохтаҗ чагы да булгалый. Пример, мин үзем дә, гөнаһны яшереп булмый, аңа күрше булсам да, сирәк керә идем. Керсәм, исәнлек-саулык сорашудан узмый идем. Ә карчык кешенең исәнлек-саулыгы, сорамасаң да иләк кебек үтәдән-үтә күренеп тора. Ә Газинур, пример, кайчан карама Вәсбия әби янында, суын да китерә, утынын да ярып кертеп куя. Мичен дә төзәтеп бирә, ишек тупсасын да рәтли. Сөйләр сүзе дә бетми аның.

– Җитәр инде, Гарәфи абзый, шул Газинурны мактап авыз суларың корыды, – диде Сәлим. Мөмкин булса, ул Газинур турында бөтенләй сөйләтмәс иде, ләкин шул ук вакытта, юлга чыккач, иптәшләрен үзенә каршы куюдан да курка иде. Юл хәлен белеп булмый.

Газинур килде. Аның йөзе чак кына кызарган, кара күзләре уйнап ялтырый, күлмәк якасын ычкындырып җибәргән. Үзе яланбаш, чәчен машинка белән кыска итеп алдырган.

– Гомерең озын булыр әле, Газинур, синең турыда сөйләшеп тора идек, – диде Гарәфи, көлеп.

– Гайбәтемне сатасызмы?

Газинур ике кулын ике як полкага куеп күзен кыса төште дә Сәлим белән Һашимга карады.

– Тукта әле, егет, – диде Гарәфи абзый, кинәт башын сузып, – якынрак кил әле, сулышыңны миңа таба өр әле. Әйтәм, пример, бөтен вагонны яңгыратып җырлыйсың. Төшергәнсең бит, каһәр!

– Һич юк, Гарәфи абзый. Ярты чынаяктан да кимрәк иде, кече телгә дә тимәде. Дядя Митрофан сыйлады. Бездә, ди, русларда, сыйлап биргәннән баш тартмыйлар. Ә мин әйтәм, татарлар сыйлап биргәнне кире какмыйлар. Шуннан чынаякларны чәкештердек. Ул үзе, Гарәфи абзый, нәкъ без бара торган урманда эшли икән. Ялдан кайтып килүе. Туган авылымда булдым, ди.

– Тукта, тукта, – дип, Гарәфи абзый полкадан кабаланып төшә башлады. – Без бара торган леспромхоздан дисеңме? Рәтләп сөйләштеңме соң аның белән? Эшләр, пример, ничек анда? Ярарлыкмы?

– Урта бармак кебек, дип әйтә. Кияүне мактаган кебек мактый, безнекеннән дә әйбәт леспромхоз бөтен Уралда юк, ди.

– Сөйләсәң, сүзнең мае чыга, үзем барып сөйләшим әле, егетләр, – диде Гарәфи абзый һәм вагонның аргы башына китеп барды.

Газинур урмандагы эш турында Митрофан карттан ишеткәннәрен иптәшләренә сөйли башлады. Һашим белән Сәлим, кызыксынып, югарыдан башларын суздылар. Тик күзләрен йомып яткан Газзән генә сүзгә катышмады. Ул һаман тын тора, үзенең ниндидер бетмәс-төкәнмәс уйларын уйлый иде.

Газинур леспромхоздагы хәлләр турында үзе күреп белгән кеше кебек кызып, дәртләнеп сөйли иде. Ул әле барып та җиткәне юк, ә Соликамск аның өчен туган колхозы кебек үз булып әверелгән иде инде. Газинур аның нарат урманнарын, бөтен илгә атаклы урман кисүчеләрен мактый башлады:

– Урман кисүче Володя Бушуевның рәсемен Мәскәү газеталарында басып чыгарганнар. Яхшы эшләгәне өчен бүләк итеп алтын сәгать җибәргәннәр. Ә үзе, ди, дядя Митрофан әйтә, буйга-сынга баһадир түгел, синнән чак кына зуррак. Теләсәң, ди, син дә аның кебек атаклы урман кисүче була алачаксың, ди. Минем куллар кычытып тора әле. Җиңнәрне сызганып тотынсак, шәт, сынатмабыз, ә?

Кулларын баш астына тыгып яткан Газзән, беркемгә дә карамыйча, караңгы чырай белән:

– Чылбырлынымы? – дип сорады.

– Как же, чылбырсыз алтын сәгать буламыни, Газзән абый.

Газзән, Газинурның авызын яба алмавын күргәч, тагын да корырак тавыш белән:

– Алдан күп кычкырасың, башың авыртыр, – диде. – Ярты чынаяктан эрегәнсең.

Ләкин Газинур исерек түгел иде. Аны аракы исертмәгән, аны бүтән нәрсә «исерткән» иде.

Гомерендә беренче тапкыр поездга утырган, үзенең туган-үскән җирләреннән беренче тапкыр ераларга чыгып киткән бу егет туган илнең киңлеген дә үз күзе белән беренче тапкыр күрә һәм шунлыктан аның күңеле язгы Идел кебек дулкынланып ташый иде. Моңарчы ул

ничектер үзенең колхозы, аның көндәлек ыгы-зыгысы белән генә яшәде. Ә поездга утырганнан соң күпме җир үтте, күпме станцияләр, күпме шәһәрләр күрде. Ә алда яңа станцияләрнең, яңа шәһәрләрнең исәбе дә, хисабы да юк.

Беренче күргән нәрсә һәрвакыт яңа, үтә кызык була. Ләкин ул яңа, ул үтә кызык нәрсәләр бик күбәеп китсә, алар үзләренең күплекләре белән кешене басалар, тойгыларының үткенлеген киметәләр, ахыр килеп аның күңелендә гамьсезлек тудыралар. Ләкин Газинурның тынгысыз җаны бу гомуми кагыйдәгә дә сыярга теләми иде. Җил өреп торган ут һаман көчәя барган кебек, Газинурның күңеле дә, яңадан-яңа нәрсәләр күргән саен, һаман киңәя, зурая гына бара иде шикелле.

Гарәфи абзый да, хәтта бөтен юл буенча яткан җиреннән кузгалмыйча түшәмгә карап барган Газзән дә аңардан көләләр.

– Станция саен төшеп ни эзлисең, юләр, – диләр.

«Их, Гарәфи абзый, Гарәфи абзый! Син үзең бөтенесен күргәч тә, бүтәннәргә ул кызык түгел дип уйлыйсыңмы? Әллә, Сәлим белән Һашим менә синең кебек, тиле бозау шикелле койрык чәнчеп чапмыйлар дисеңме? Ләкин дә бит, Гарәфи абзый, Һашим белән Сәлим җидееллык мәктәп бетергән кешеләр, алар бит Казанда гына да әллә ничәшәр тапкыр булганнар. Ә Газинур Бөгелмәдән ары кая киткәне бар? Эзли, имеш! Нәрсә эзли соң Газинур? Гарәфи абзый, әйт әле, яз көне җылы туфракны тишеп чыккан яшь бодайлар нәрсә эзли? Нигә алар, бер-берсен узышып, көн-төн үсәләр, кояшка үреләләр? Аңлат шуны, Гарәфи абзый, әгәр шуны аңлатсаң, Газинур да сиңа үзенең күңелен аңлатыр».

Гарәфи абзыйның шаярып кына әйткән сүзләре Газинурның күңелендә әнә шундый катлаулы бер тойгы, җавап уятты. Ләкин ул боларны, әлбәттә, телдән әйтмәде, әйтергә җыенмады да. Ул үзенең бераз гаҗәпләнгән сыман дугаланып торган кара кашлары астындагы акыллы күзләре белән Гарәфи абзыйга текәп карады да нәкъ балаларча елмайды:

– Үзем дә белмим, ләкин чыгасы килгәч нишлим, Гарәфи абзый.

Поезд яңа зур станциягә килеп җитә иде.

– Кипяток... – диде Газзән, үзе яз көне беренче тапкыр өненнән чыга башлаган карт аю төсле ашыкмый гына полкадан төшә башлады.

– Үзем алып киләм! – диде Газинур һәм, Гарәфи абзыйның калай чәйнеген эләктереп, чыгып та китте.

## 13

Бригадир биек штабельләр арасында тирән уйга чумып утырган карт урманчы Карп Васильевич янына Газинурны алып килде.

– Саумы, Карп Васильевич? Менә сиңа яңа ярдәмче китердем, рәхим ит.

Бригадирның бу сүзләренә каршы урманчы борын эченнән нидер мыгырдап кына куйды. Газинур берни дә аңламады. Ул бу кешегә сәерсенеп карады. Картның кечерәк борыны өстендә нечкә кыршаулы күзлеге төшәмтөшәм дип кенә атланып тора. Сары мыегының чылгыйларын өскә таба бөтереп җибәргән, шундый ук сары сакалының очы да, чак кына бөтерелеп, өскә таба карап тора. Авызында кыска саплы кәкре трубка. Ул аны ешеш суыра, авызыннан көлтәләп чыккан төтенне, тынгысыз черкиләрне ачуланып куган кебек, кулы белән әледәнәле таратып тора. Кайдадыр якында гына тукран тукылдый. Күрәсең, ул да картның эчен пошыра, тавыш ишетелгән саен, аның мыек очлары селкенеп куялар. Газинур ни дип тә уйларга белмичә аптырап басып торганда, Карп Васильевич кинәт урыныннан күтәрелде.

– Менә нәрсә, хөрмәтле иптәш, – диде ул бригадирга һәм кулын селкеп куйды: – Миңа ярдәмче кирәкми. Шул!

Бригадир елмайды. Ул, күрәсең, картның холкын белә иде.

– Ни сөйлисең, Карп Васильевич. Сиңа берүзеңә кыен бит. Яшьләргә килгәндә, хәтерең калмасын. Яшь чак – яшел чак. Төрлесе була. Ярый, минем эшем күп, Карп Васильевич. Биргәндә алып кал, соңыннан сорап йөрсәң дә булмас. Ә иптәш Гафиятуллин начар егет түгел бугай.

– Башта алар берсе дә начар булмый, – диде карт, ләкин аның тавышында баягы кискенлек юк иде инде.

Ике ай буе Карп Васильевич яшь кенә бер егетне маркировкага – тамга салырга өйрәтте. Киләчәктә мастер итү турында хыялланды. Беренче өйрәнчеге маркировщик эшен ошатмыйча ташлап киткәннән соң, Карп Васильевич яңасын бик төпченеп сайлады. Егет юньле генә шикелле иде. Сәләте дә бар, тырыш та. Ә гомерен хезмәткә багышлаган, бөтен шатлыгын шул хезмәттән тапкан Карп Васильевич каршында бу сыйфатлар әһәмиятсез түгел иде. Ул өйрәнчегенең кечкенә генә уңышына да чын күңеленнән, аталарча шатланды, җыелышларда булсын, өендә булсын, бу турыда үзенә бертөрле горурлык белән сөйләп килде. Бала чагыннан ук урманда эшләп үскән, урман остасы булу өчен никадәр зур кыенлыклар аркылы үтәргә

кирәклеген бик яхшы белгән карт урманчы яшьләргә бу эшне бик аз вакыт эчендә үзләштерергә мөмкинлек булуына куанып бетә алмый иде. Ләкин аның шулай зур күреп, кадерләп өйрәткән егете бөтенләй көтмәгәндә һәм, күңел өчен генә булса да Карп Васильевич белән сөйләшмичә, икенче бер эшкә күчеп китте. Бу үз һөнәре белән горурланырга яраткан картны чиксез җәберсетте. Әлбәттә, яшь егеткә моторлы пычкы белән яки тракторда, автомашинада эшләве кулайрак, ләкин маркировканы да кем дә булса ясарга тиеш ләбаса. Юк, кем дә булса түгел, ә агачны бик яхшы таныган кеше ясарга тиеш. Чөнки маркировщикның тамгасыннан башка бер генә бүрәнә дә урманнан читкә китми. Киселгән агачның икенче гомер юлын билгеләүче дә, яңа тормышка аңа путевка бирүче дә ул!

Әгәр дә юньсез егет берни әйтми генә китеп барган булса, бер хәл иде әле. Ул чагында Карп Васильевичның күңеле, бәлки, бу хәтле кыйналмас та иде. Ул юньсез киткән вакытта: «Тамга салу эшмени ул», – дип мыскыл иткән бит әле. Моны инде карт урманчы һич тә күтәрә алмый иде. Чөнки хезмәт ул барыннан да югары, аны кимсетергә берәүнең дә хакы юк!

– Әйе, – диде урманчы бригадирга, – башта алар берсе дә начар түгел. Ә соңыннан... син күр дә мин күр.

– Җитте, җитте, Карп Васильевич. Яшь чак – яшел чак, дим бит. Ниләр булмый.

Бригадир анда-санда гына аударылмый калган наратлар белән чуарланган киң кисенте буйлап китеп барды. Карп Васильевич, Газинурга күтәрелеп тә карамыйча, яңадан агач төбенә утырды. Берничә минут алар икесе дә тын тордылар. «Җилле карт икән», – дип уйлап алды Газинур, аннары мастерның марля белән ураган кулына, аннары озын саплы маркировка чүкеченә күз төшереп, кызганган сыман, башын селкеп куйды.

– Кулың авырта, ахрысы, дядя Карп? Бир әле чүкечеңне, әзрәк сугып алыйм. Кайда, ничек сугарга?

Карп Васильевич Газинурга бер тапкыр күтәрелеп карады да читкә борылды.

– Әгәр дә бар кеше дә тамга суга белсә, мин аны авырткан кулым белән сугып та йөрмәс идем, – диде ул, шелтәләгән төслерәк итеп. – Аны сала белеп салырга кирәк. Бу утын яру түгел, егеткәй.

– Күрсәтеп бирсәң, дядя Карп, мин бик тиз отып алыр идем.

Картның күзләрендә кызыксыну чаткысы кабынгандай булды.

– Отып алыр идем дисеңме? – дип сорады ул.

– Әйе.

Шуннан соң гына Карп Васильевич Газинурны игътибар белән баштанаяк карап чыкты. Әмма урта буйлы, зур кара күзле гади авыл егете аның күңеленә ошап бетмәде, ахрысы, сүрән йөзе яктырмады. Ләкин Газинур, картның салкын карашын гүя сизмәгән кебек, үзенең яңадан-яңа сорауларын яудыра барды. Агачларның юан башларындагы тамгага кулы белән күрсәтеп:

– Дядя Карп, тамгадагы беренче хәреф нәрсәне аңлата? «Ш» белән янәшә ике шакмак тора, аннары цифр. Аларның хикмәте бармы?

Карт тамга чүкечен брезент курткасының кесәсенә тыгып куйды да Газинурга тагын бер тапкыр карап алды.

– Тукта әле, егет... – диде ул, җиңелчә ачуланып. – Нигә тигәнәк кебек ябышасың? Кем син? Кайдан килдең? Нинди һөнәрең бар?

Карп Васильевич, Газинурның үзе турындагы беркатлы хикәясен тыңлагач, күн кепкасын бармагы белән күтәреп, башын кашып куйды, кырыс карашы әз генә үзгәреп киткәндәй булды.

– Алай икән-н... – диде ул сузып кына һәм егеткә туры карап сорады: – Ә син, егетем, чынлап өйрәнергә телисеңме? Әллә тегеләй-болай гынамы?

– Чынлап телим! – диде Газинур. Аның бу кыска җавабында, бигрәк тә акыллы күз карашында теләк тә, кыюлык һәм нindидер зирәклек тә бар иде. Карп Васильевичның күңеле бөтенләй йомшарды.

– Алайса тыңла, егетем, – диде ул, кесәсеннән тамга чүкечен алып, калкып торган «Ш» хәрефенә бармагы белән төртеп күрсәтте: – Бу баш хәреф агачның сортиментын күрсәтә, ягъни бу агачтан нәрсә ясалачагын әйтә, «Ш» дигән икән, димәк, бу агач шпал ясарга китә. Аңладыңмы? Әгәр тамганың беренче хәрефе «А» булса, ул бүрәнәләр авиациягә китә. Ә хәрефтән соң куела торган квадратлар агачның сортын күрсәтә: бер квадрат – беренче сорт, ике – икенче, өч – өченче. Дүртенче сорт булмый. Нибары өч. Ә инде квадратлардан соң куела торган цифр агачның диаметрын, ягъни юанлыгын күрсәтә. Төшендеңме?

– Бераз төшендем шикелле, – диде Газинур. – Үземчә әйтеп карыйм әле, буталмадыммы икән.

Ул картның сөйләгәннәрен үзенчә кабатлап чыкты да, бераз көлемсери төшеп:

– Дөрес сөйләдемме? – дип сорады. Дөрес сөйләгәнен белә, шулай да моны картның үз авызыннан да ишетәсе килә иде аның.

«Үткен, шельма!» дип уйлап алды карт, ләкин мактаудан тыелып, сүзен дәвам иттерде:

– Ләкин монысы аның иң җиңеле. Монысын аның башына тай типмәгән һәр кеше аңлый ала. Тамга салучы агачларның сортларын таный белергә, аларны бутамаска тиеш. Югыйсә сиңа беренче сорт дип икенче сортны тыгарлар, ә син шап та шап – тамга сал. Юк, алай булмый ул, егетем. Агачны таный белү кыенрак. Моны бер утыруда төшендереп тә булмый. Бу – фән! Әйе. Ләкин теләгән кеше белә ала. Кеше акылы ирешә алмый торган бернәрсә дә юк. Шул, егетем, теләгең булса, өйрән – әкренләп барысын да төшендереп бирермен. Хәзер әйдә, агачларга тамга салыйк. Синең чүкеч тотканың бармы? Кадакны бер сугуда төбенә кадәр батыра аласыңмы? Бик яхшы, хәзер сынап карарсың. Тамганы да бер сугуда салырга кирәк: тамга ачык, туры булып, бүрәнә башының өске кырыена билгеле бер урынга төшсен. Менә болай.

Карт озын саплы чүкеч белән җиңелчә селтәнде дә бүрәнә башына шап итеп сукты.

– Күрдеңме, – диде ул, үз хезмәтеннән тәм тапкан бер тавыш белән, – тамга нинди ачык булып төште. Менә тагы. Күрдеңме? Менә тагы! Һоп! Күрдеңме, чүкеч бөтен йөзе белән ничек тип-тигез килеп төшә. Йә, хәзер син сәләтеңне күрсәт, егетем. Кабаланма. Чүкечне менә болай тот. Берәү дә анадан мастер булып тумый. Барысы да тырышлык белән күнегү аркасында килә.

Газинур, учларына төкереп, кулларын бер-берсенә ышкыды да чүкечне алды. Аннары уйнаган шикелле генә шап иттереп агачка сукты. Тамга ачык, тигез булып төште.

– Йә, йә, тагын берне! – диде карт, җанланып.

Газинур тагын сукты. Бу юлы да тамга ачык, матур булып төште. Карт, ике кулы белән тез башларына тотынып, бөтен гәүдәсе белән алга иелгән һәм, балык тотучы кебек муенын сузган килеш:

– Йә, йә, тагын берне! – дип кычкырып торды. Ул егетнең эшләвен ошатты булса кирәк, – теләсәң, булдырасың, – диде.

Урман кисүчеләр барагына Газинур күтәренке күңел белән кайтты. Ул эшеннән бик канәгать иде. Ә Карп Васильевич аңа барысыннан да бигрәк ошаган. Сәер, ләкин һәйбәт карт!

Газинур иптәшләреннән кайда эшләүләре турында сораштыра башлады. Һашим белән Сәлим автомашиналарга бүрәнә төяшкәннәр, Гарәфи белән Газзән ат белән эшләгәннәр икән...

– Йә, ничек урман эше, Газзән абый? – дип сорады Газинур бүтәннәргә караганда күңелсезрәк утырган колхоздашыннан.

«Красногвардеец»тан чыгып киткәннән бирле кырынмаган, йөзен саргылт сакал-мыек баса башлаган, артык аз сүзле Газзән кыска гына җавап бирде:

– Эш кодалый бару түгел, билгеле.

– Ә синең сразы буйлы ыштан киясең киләмени, Газзән абый? – Газинур кычкырып көлеп җибәрде, аннары җитди итеп өстәде: – Эх, Газзән абый, эш турында алай әйтергә ярыймыни!

Газзән белән сөйләшүе кыен иде. Ул куй, бызлап торма дигән шикелле кулын селтәде дә Газинурның сүзләренә бөтенләй җавап бирми башлады.

Баракта утыз-кырык кеше тора иде. Газинур алар белән танышырга ашыкты. Поездда очраган дядя Митрофан белән атаклы урман кисүче Владимир Бушуев та бу баракта торалар икән. Газинур бу турыда белгәч куанып китте.

– Дядя Митрофан, теге иң шәп стахановчыгызны күрсәтегез әле, – диде Газинур, Митрофан карт янына барып.

Карт куе кашлары астына яшеренгән кечкенә күзләрен барак буйлап йөртеп чыкты да:

– Күренми, кайтмаган әле, – диде.

Икенче көнне Газинур эштән тагын да күтәренкерәк күңел белән кайтты. Кич белән йокларга яткан чагында, Һашим белән Сәлимнең икесенә берьюлы сорау бирде:

– Егетләр, әйтегез, ботак нәрсә ул?

Һашим кычкырып көлә башлады.

– Исән торасыңмы, Газинур, ата казың күкәй саламы?

– Ачуы килмәгәндә, – диде Газинур, майкасын салып, кроватька сузылып ятты. Аның тәне кояшта янып көрән төскә кергән. Кулбашлары салыныбрак тора, күкрәге киң, мускуллары көчле. – Юк, Һашим, – диде ул кинәт җитди тавыш белән, – мин шаярмыйча сорыйм бит. Урманчы булгач, аны белергә кирәк. Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп, шулаймы, Гарәфи абзый?

– Шулай, шулай, бик дөрес әйтәсең, Газинур, – диде Гарәфи. Газета гына җәелгән өстәл янына килеп, лампаның куыгына өрде. Ут гөлт итеп сүнде. Барак эче дөм караңгы булып китте. Ләкин бераздан тәрәзә пыялалары әз генә аксылланды.

– Белмәсәгез, үзем әйтим. Ботаклар, – диде Газинур, Карп Васильевичтан ишеткән сүзләрне кабатлап, – үзагачның тумыштан килә торган кимчелеге.

Газинурны яратып бетермәгән, Әлфия алдында оятка калдыруын бер генә минутка да исеннән чыгармаган Сәлим үртәп көлүдән тыела алмады.

– Ботак агачның кимчелеге булса, кешенең аяк-кулы нәрсә була? Ни сөйләгәнеңне белмисең бит, мастер абзый.

– Агачның түгел, үзагачның, русча әйткәндә, древесинаның, – дип төзәтте Газинур. Ул Сәлимнең авызын капларлык бүтән сүзләрне дә тапкан булыр иде, ләкин бүген аның һич тә эрләшәсе килмәде.

– Бүрәнә аша бүре күрмә, калай әтәч! – диде Газзән, Сәлимне яклап. Кроватен шыгырдатып икенче ягына әйләнеп ятты, – йокла!

– Чү, Газзән абый, яшь мастерның сүзен тыңлыйк әле, – дип, Сәлим яңадан чәнчеп алды.

Газинур, иптәшләренең көлүенә карамыйча, караңгы түшәмгә текәлгән килеш, үз фикерен аңлатырга тотынды. Үзагачта ботаклар никадәр азрак булса, үзагачның кыйммәте шулкадәр югарырак икән. Аннары үзагачта ботакның кайда туры килүе дә – уртадамы, кырыйдамы – бик мөһим. Ләкин ботак үзагачның бердәнбер кимчелеге түгел. Үзагачның бүтән кимчелекләре дә шактый икән. Газинур үрелгән яки кәкрәйгән үзагачлар турында, ярык яки черек үзагачлар турында, үзәкләре зәңгәрләнә башлаган үзагачлар турында сөйләп китте. Хәзер инде берәү дә аңардан көлми иде. Хәтта Газзән дә башын аның ягына таба борды. Кайчак Газинур тукталып кала, бутала, күрәсең, бик күп нәрсә аның үзенә дә ачык түгел әле. Шулай да ул шушы берничә көнен әрәм үткәрмәгән, иптәшләренә билгеле булмаган әллә нихәтле яңалыкларны белеп өлгергән. Барыннан да бигрәк тыңлаучыларга аның яңаны тотып алырга, төшенергә ашкынуы тәэсир итте. Һашим белән Сәлим аңа беренче тапкыр эчләреннән кызыгып куйдылар. Гарәфи абзыйның да күңеле кытыкланды булса кирәк, яткач тарта торган гадәте булмаса да, торып тәмәке төрә башлады.

– Безнең мәрхүм әткәй әйтә торган иде, – диде Гарәфи абзый, тәмәкесен суыра-суыра, – алтынны тоткан таныр, дияр иде. Агач та, пример, шундый ук алтын. Без шул алтынны таптап йөрибез, әмма берни күрмибез. Күзләрне йомып йөргәч, шулай була икән ул. Мин бит элек тә урман эшендә аз-маз маташкалаган кеше, пример, оят булса да әйтим, Газинур минем авызымнан алып әйтте. Газинур түгел, мин сөйләргә тиеш идем сезгә бу сүзләрне. Егет син, Газинур!

Көтмәгәндә Гарәфи абзыйның Газинурны мактап куюы әңгәмәгә бөтенләй башка төс бирде. Караңгы баракта кол-

хоздашлар таң сызыла башлаганчы сөйләштеләр. Гарәфи абзый урман эшендә берни дә белмим дип тыйнакланган булса да, сөйләшә торгач, аның да теле ачылып китте. Ул урман кисүчеләргә файдалы булган бик күп нәрсәләр турында сөйләде.

Җанын ватылмый торган чуен тартма эченә бикләп куйган Газзән генә сүзгә катнашмады. Ул, яшелле-сарылы тавышлар чыгарып, күптән тегермән тарттыра иде.

Сөйләп арыгач, Гарәфи абзый да, аннан соң Сәлим дә йокыга киттеләр. Ә Газинур белән Һашим әле һаман хыялланып сөйләштеләр. Ләкин алар тиздән күңелсезлеккә тарачакларын башларына да китермәделәр.

Беркөнне кич белән бригадир аларның барысын да үз конторкасына алып керде дә вакытлыча, кышка кадәр, төрлесен төрле участокка җибәрергә мәҗбүр булганлыгын әйтте.

– Җәй көне, үзегез күрәсез, бездә эш аз. Безнең сезон кыш көне башлана. Кыш көне җаныгыз нихәтле теләсә, шулхәтле эш булачак. Тагын бер тапкыр әйтәм, егетләр, мин сезне вакытлыча гына күчерәм.

– Бишебезне бер урынгамы? – дип сорады Гарәфи абзый. – Без бер-беребездән аерылмаска теләр идек, иптәш бригадир.

– Юк шул, бишегезне биш урынга җибәрергә туры килә.

Бригадирның бу сүзләреннән соң, барысы да шаулаша башладылар. Иптәшләреннән һич тә аерылырга теләмәгән Газинур бигрәк тә кызды.

– Юк, начальник безгә үзе әйтте сез бергә эшләрсез, бергә торырсыз, диде. Без башта ук сөйләшеп куйган идек.

– Мин дә, иптәш Гафиятуллин, үз башым белән генә эшләмим. Мин дә начальникның боерыгын үтим.

Газинур аңа ышанмыйча карады.

– Начальник үзе куштымы?

– Алайса киттек, Газинур, – диде Гарәфи абзый, Газинурның җиңеннән тартып. – Начальство белән сүзгә килешү яхшы эш түгел. – Һәм кулларын аркасына куйган килеш, башын иеп баракларга таба юнәлде.

Газинур дары кебек кабынып китте. Аны бригадирның сүзләреннән битәр күпне күргән, тәҗрибәле Гарәфи абзыйның бригадир белән бик тиз килешүе, башын бөгеп, мескенләнеп китеп баруы гарьләндерде.

Аз гына вакыт эчендә Газинур урман эшен чын күңеленнән яратырга өлгерде. Гәрәбәдәй сары кәүсәле, иртәкич берөзлексез шаулап торган мәһабәт наратлар, әллә нинди җил-давылларга да бирешмәгән юан-юан агачлар-

ны егып баручы урман кисүчеләр, агач ташучы күңелле шоферлар, киемнәре дә, борыннары да майга буялып беткән тракторчылар, подстанциядә – урман шаулавы кебек тигез гөжләү белән әйләнеп торган дизельләр янында эшләүче җитди монтерлар, кепкаларының козырекларын артка әйләндереп кигән шаян слесарьлар Газинурның йөрәгенә кереп урнаштылар, бигрәк тә үзен чын күңелдән өйрәтә башлаган Карп Васильевичтан ул һич тә аерылырга теләми иде.

– Юк, мин моннан китмим! – дип кычкырды ул бригадирга, аннары иптәшләренә борылып өстәде: – Хәзер үк начальникның үзенә барам.

Газинур бүрәнәләр төяп узып баручы автомашиналарның берсенең кабина баскычына сикерде дә борылышта күздән дә югалды.

Леспромхоз начальнигы әле иртән иртә үк шәһәргә чыгып киткән, кайчан кайтасы да билгеле түгел икән. Контора кешеләре дуылдап килеп кергән егетнең сүзләрен сәерсенеп тыңладылар. Ләкин бу эштә начальникның үзеннән башка берәү дә ярдәм итә алмавын әйттеләр. Начальникның чыннан да шундый приказы булган икән.

Газинур урамга чыкты, кәефсезләнеп, бүрәнәләр өеме өстенә утырды. Күк йөзендә бер генә болыт та юк. Кайдадыр такта яралар, ахрысы, түгәрәк пычкы зырылдавы ишетелә. Бөтен поселок эчендә тәмле сагыз исе аңкый.

Газинур ашыкмыйча гына тәмәке төрде, зәңгәр тәмәке төтене аркылы поселок урамы буйлап карый-карый, күңелсез уйларга чумды. Әгәр чыннан да күчәргә туры килсә? Карп Васильевич ни әйтер? Элекке өйрәнчегеннән күңеле кыйналган кебек, Газинурга да рәнҗерме? Менә бит аяк астыннан килеп чыккан бәла нинди була ул. Эх!

Гарәфи абзыйны күз алдына китергәч, Газинурның күңеле тагын да ныграк борчыла башлады. Нишләп бу Гарәфи абзый шулкадәр йомшак? Еламаган балага имчәк бирмәүләре исеннән чыкканмы әллә. Үзең дауламагач, конечно, контора нәрсә язмас. Эх! Менә булсын иде биредә Гали абзый, менә юлын табар иде ул!

Гали абзый кебек кешеләр монда да бардыр ич! Әлбәттә, бар. Алар кайда юк?!

Газинур, кепкасын җилкә чокырына этеп, урыныннан сикереп торды да автомашиналар, чылбырлы тракторлесовозлар актарып бетергән киң урамның аргы башына таба йөгереп китте. Кикрикләрен канга батырып сугышып торган ике этәч, куркып, аның аяк астыннан икесе ике якка очты.

Леспромхозның партоешма секретаре урнашкан өр-яңа нарат йортка керер алдыннан Газинур бер генә минутка туктап калды. Ул үзенең өстен-башын какты, ычкынган якасын төймәләде. Аннары кыю рәвештә ишекне тартып ачты.

– Керергә рөхсәтме?

Өстәл артында утырган ак гимнастеркалы, кырык бишилле яшьләрдәге күзлекле бер кеше ягымлы тавыш белән:

– Рәхим итегез, ни йомыш? – диде.

Газинур аның чәчен машинкада алдырган киң маңгайлы башына, калын кара кашларына, ачык чыраена тагын бер карап алгач, әкрен генә:

– Миңа партоешма секретаре кирәк иде, – дип сорады.

– Мин булам, – диде өстәл артындагы кеше. – Рәхим итегез, утырыгыз.

Газинур икеләнеп калды: утырыргамы, юкмы? Гали абзый янына килеп кергәч, ул үзендә курку түгел, ә эчке каушау сизә торган иде. Ә биредә каушау да бар, ятсыну да.

Шулай да ул урындык читенә утырды, үзенең кемлеген дә әйтеп тормастан, зары турында кызып-кызып сөйләргә кереште. Секретарь аны бүлдермичә тыңлады, бары тик күзлеген салып, сул кулының ике бармагы белән күз төпләрен генә сыпырып алды. Аннары күзлеген яңадан киде. Дулкынланган Газинур аның күзләренең нинди төстә икәнен дә күрә алмады, әмма аларның үзен игътибар белән күзәтүен сизде һәм тотлыгып калды.

– Сөйләгез, сөйләгез, – диде секретарь.

– Мин инде әйтәсе сүземне әйттем, иптәш секретарь, – диде Газинур, кулындагы кепкасын бөтереп, – безне берберебездән аермагыз, безгә элекке урыныбызда эш табып бирегез. Нинди эш булса да ярый, без эштән баш тартмыйбыз. Агач кисәргә булса да, ат белән ташырга булса да, ботак чабарга булса да – барыбер.

– Сез партиялеме? – дип сорады ахырда секретарь.

Газинур кызарып җавап бирде:

– Юк, мин партиясез.

– Комсомолецмы?

– Түгел.

Газинур үзенең кемлеген сөйләгән чагында секретарь аңа тагын да текәлебрәк карый башлады. Ләкин аның бу төпченүле карашы Газинурга ошап бетмәде. «Алтын сәгать тапканмыни, әйләндереп-әйләндереп карый», – дип уйлап алды ул эченнән.

– Монда үзең килдеңме? Берәрсе өйрәтеп җибәрдеме? – дип сорады секретарь.

– Үзем килдем, беркем дә өйрәтеп җибәрмәде, – диде Газинур.

Секретарь урыныннан торды. Ул Газинурдан шактый озын, юан иде. Газинур аның янында үзен малай гына итеп сизде. Сөйләгән вакытта ничектер онытылган ятсынуы яңадан йөрәген салкынайтып җибәрде. Күңелендәге барысын да яхшылап сөйләп бирә алдымы соң ул? Бутамадымы? Татарча булса, буталмас иде, барысын да бәйнә-бәйнә төшендереп бирер иде. Русча менә кайчак кирәкле сүзне табып булмый.

Секретарь, өстәл артыннан чыгып, уң кулын Газинурның иңбашына куйды.

– Яхшы, иптәш Гафиятуллин, син хәзер бар, кайт. Үзең дә тыныч бул, иптәшләреңне дә тынычландыр. Начальник кайту белән үк, барысын да җайларбыз. Беркая да китмәссез.

...Ике ягына да мәһабәт наратлар үсеп торган олы урман юлы буйлап Газинур иптәшләре янына кайта. Аның итек үкчәләре машина тәгәрмәчләре астына түшәлгән һәм ике буразна кебек еракка-еракка сузылып киткән такталарга дөп-дөп баса. Ә йөрәгендә шундый зур шатлык, күңеле шундый якты, әйтерсең берүзе бөтен дөньяны кочаклаган. Кепкасын кулына тотып, адым уңаена селкәселкә бөтен тавышы белән кычкырып җырлый:

> Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
> Селкенмәгән агачлай калмасын...

Иптәшләре, барак каршындагы чирәмгә ятып, аны көтеп торалар иде. Караңгыланып килгән урман эченнән күтәренке җыр тавышы ишетелгәч, башларын күтәрделәр.

– Тәки үз дигәнен булдырган, ахрысы, – диде Гарәфи абзый, ябык йөзе яктырып китте.

Хәтта аз сүзле, һәрвакыт караңгы чырайлы Газзәннең дә йөзендә ниндидер җанлану сизелде.

Урман арасыннан җырлый-җырлый килеп чыккан Газинур, кулын болгап, еракган ук иптәшләренә кычкырды:

– Китмибез, калабыз!

## 14

Берничә ай вакыт үтте. Көзге салкын яңгырлар башланды. Көзнең беренче атналарында алтыннан койган шикелле сары яфраклары белән шыбырдап утырган ак каеннар, кызгылт яфраклы усаклар, өрәңгеләр хәзер көннән-көн шәрәләнә баралар. Бары тик наратлар, чыр-

шылар һәм ак чыршылар гына яшел ылысларын коймый, алар җәй көнендәгечә бизәнеп-ясанып утыралар, тик бераз карасулана гына төшкәннәр.

Урманда җәйге күңелле чыр-чулар да ишетелми. Сайрар кошлар күптән инде очып китте. Моннан бер атна элек Газинур урман эчендәге күлдә киек үрдәкләрнең ерак юлга чыгар алдыннан төркемгә тупланауына карап торды. Киек үрдәкләр әле бер төркемгә җыелалар, әле күл эченә таба йөзеп китәләр яки, муеннарын сузып, һавага күтәреләләр. «Болары егет-җиләннәре булса кирәк, сабан туендагыча, кая басарга белмичә ярсыйлар», – дип уйлады Газинур. Ул шулай уйларга гына өлгергән иде, яшел башлы ата үрдәк тирә-ягына бер каранып алды да шундый моңлы итеп кычкырып җибәрде, Газинурның күзләренә яшьләр килде. Бер минуттан үрдәкләр бөтенесе берьюлы һавага күтәрелделәр, күл өстендә әйләнә башладылар. «Туган җирләре белән саубуллашалар, – дип уйлады Газинур. – Кешеләр, туган җирдән туйган юк, туган илнең төтене дә тәмле, диләр. Сез, кошлар, андый нәрсәләрне белмисез инде. Шулай да...»

Үрдәкләр күл өстендә бер әйләнделәр дә, өчпочмак булып тезелеп, көньякка таба юл алдылар. Газинур алар күздән югалганчы карап торды, Миңнурыен юксынып, сагышланып куйды.

Ләкин куллары һәрвакыт эшкә кычытып торган Газинур, уй-сагышка чумып, озак йөри алмый иде. Леспромхоз тормышы аны көннән-көн күбрәк мавыктырды, ул анда һәр көн нинди дә булса бер яңалык ача барды, шуңа сабый баладай чын йөрәктән сөенде.

Ул арада салкын Урал кышы сәлам бирә башлады. Ул суыкка чыдый алмаган кошларны куып кына туктамады, урмандагы бөтен җәнлекләрне озын кышка тизрәк әзерләнергә мәҗбүр итте. Тиеннәр, иртәдән кичкә кадәр агач башларында сикерешеп, чикләвек җыюдан туктамадылар. Аю өнгә ятарга ашыкты. Бүреләрнең, төлкеләрнең йоннары куерды, саесканнар, ала каргалар, чәүкәләр, песнәкләр кешеләр тора торган урыннарга якынрак килделәр.

Иртән Газинур Карп Васильевич белән бергәләп эшкә бара. Берсе алданрак чыкса, икенчесе бераз көтеп тора. Күзлеген борын очына гына элгән Карп Васильевич картларча ашыкмыйча әкрен генә атлый, ә Газинурның күкрәгендә әйтерсең казан кайный, ул колын шикелле юргаларга гына тора. Делянка аңа сабан туе мәйданын хәтерләтә, ул анда көрәшкә катнашырга теләүче, ихтимал, сөйгән кызын да очратырга өметләнүче егет кебек

дулкынланып, ашкынып бара. Хәтта кайчакларда төнлә, кинәттән уянып киткәч тә, шушы гөрләп торган делянка аның күз алдына килеп татлы йокыларын качыра. Мондый вакытларда ул таңга кадәр уйланып ята, ә иртән гаҗәеп бер җиңеллек белән эшенә йөгерә.

Әле ерактан ук, урман шаулавына кушылып, үткен пычкыларның үзенә бертөрле моңлы көй белән зырылдаулары, агачларның гөрселдәп авулары, балта тавышлары, тракторларның гүләве, ат әйдәүчеләрнең һай-һулары ишетелә. Делянкага якынрак килгән саен, бу гомуми шаушу көчәя, зурая бара. Берничә минуттан, борылышны үткәч, бөтен делянка күренә башлый. Алда кара стена шикелле урман шаулап тора. Кулларына моторлы пычкылар яки урманчылар лучковая дип атап йөрткән гади кул пычкылары тоткан агач аударучылар, атакага барган шикелле, шул кара стенага таба һөҗүм итәләр. Иң хәтәр җилләргә дә бирешмичә, җәен-кышын шаулап торган мәһабәт наратлар, зифа ак чыршылар төпләренә зырылдап торган үткен пычкы баткач, калтыранып киткәндәй булалар, аннары ни булды дигән сыман бер генә секундка тынып калалар да әкрен генә авалар. Алар ауган урында һавага кар фонтаннары күтәрелә, кар бөртекләре, ап-ак парашют гөмбәзе шикелле кабарып, бераздан яңадан җиргә төшә башлый, урман кисүчеләрнең бүрекләренә, иңнәренә кунып ала-кола итә.

Агач аударучылардан илле метрлар чамасы арттарак ботак чабучылар эшли. Иртәнге кояш яктысында аларның балталары астыннан очкан ап-ак йомычкалар ялтйолт килеп тора. Ботак чабучылар үткән урында шәпшәрә бүрәнәләр, чыбык-чабык өемнәре генә кала. Чыбыкчабыкларны шунда ук бер читкә алып китеп, зур-зур учакларга ташлыйлар. Ылыслар дары кебек кабынып китәләр дә күзләрне чагылдыра торган көчле бер яктылык белән чытырдап яналар, ә чи ботаклардан исә саргылт куе төтен генә күтәрелә. Трактор һәм ат белән бүрәнә сөйрәүчеләр киселгән, чистартылган агачларны эшкәртү мәйданына ташып торалар. Эшкәртү мәйданы делянканың нәкъ урта бер җирендә. Биредә бүрәнәләргә разметка ясыйлар, аларны кискәлиләр, сортларга аералар, тамга салалар, аннары, эстакада янына килеп туктый торган автомашиналарга, тракторларга, атларга төяп, станциягә озата баралар.

Карп Васильевич белән Газинур делянканың нәкъ менә шушы үзәк мәйданында эшлиләр. Карп Васильевич, ботаклардан чистартылып, карда яткан озын-озын агачларны, сары метр белән тиз-тиз үлчәп, кечкенә балтасы белән

кирәк урыннарга киртек ясап бара. Аның артыннан ук эшкә керешкән пычкычылар, шул киртекләргә карап, бүрәнәне төрле озынлыктагы өлешләргә кисәләр.

Газинур Карп Васильевич белән янәшә эшли. Карт урманчы кул астында ул шактый гына тәҗрибә туплап өлгерде. Укымышы аз булса да, сизгер, җитез акылы аңа күп нәрсәне практикада бик тиз төшенергә мөмкинлек бирде. Дөрес, аның Карп Васильевичныкы кебек, үз-үзенә тулы ышанычы да, ныклыгы, тапкырлыгы да юк әле. Һәр өлкәдәге кебек, агачларның да кыйммәтле һәм кыйммәте азрак сортлары була. Разметка ясаучының бурычы – һәр киселгән агачтан кыйммәтле сортны күбрәк чыгарырга тырышу. Газинур моны, әлбәттә, белә, ләкин белү – бер, эшләү – башка. Шуңа күрә ул, ялгышмыйм дип, разметка ясаудан элек, кар өстендә яткан агачның бер башыннан икенче башына кат-кат үтә, чамалап үлчәп карый, кайчакта карга тезләнеп агачның аскы ягын капшый. Моңа аның шактый күп вакыты китә. Ләкин соңыннан, үзе разметка ясаган агачларның яхшы сыйфатлы шпал бүрәнәләре, телеграф баганалары, рудник стойкалары булып әверелүен күргәч, шуның өстенә Карп Васильевичтан да берәр җылы сүз ишетсә, аның күңеле язгы тургай кебек җырлый башлый. Ә инде әзер бүрәнәләргә тамга сугарга керешкәч, ул Карп Васильевич белән икесе өчен дә эшләп өлгерә. Аның күзе белән кулы бервакытта да ялгышмый.

Кайчакта Газинур тирләп-пешеп бетә дә бераз хәл алыр өчен биек эстакададан делянкага карап тора. Клеймо сабы белән бүреген күтәрә төшә, кызу маңгаена салкын җилнең килеп орыну рәхәтен тоя, ә ялтырап торган зур кара күзләре делянка буйлап йөгерәләр. Борчак чүмәләсе кочаклап китергән шикелле, ботаклар кочаклап килгән чая кызларга шаян сүзләр кычкыра, атта эшләүчеләр, трактористлар яки бүрәнә өючеләр белән әйтешеп ала, ләкин күп вакытта аның күзләре делянканың аргы башына – Володя Бушуев эшләгән почмакка төбәлгән була. Әнә ул, Володя Бушуев, бүреген бераз артка батырып, аксыл бөдрә чәчләре киң маңгаена төшкән хәлдә, мәйданда җиңгән батыр кебек, ашыкмыйча гына икенче агач янына килә. Үз-үзенә ышанган, зур тәҗрибәле кешеләрдә генә була торган бер җитез караш белән (нәкъ Карп Васильевич кебек) мәһабәт наратны «үлчәп» ала, җилнең көчен, юнәлешен, агачның кайсы якка таба авышып үскәнлеген билгели, аны үзенә кирәк булган урынга ничек итеп аудару турында уйлап куя. Моны ул берничә секунд эчендә эшли. Шуннан соң Володя үзенең ярдәмчесенә нидер әйтә

дә аларның моторлы пычкысы чыжылдый башлый. Күп тә үтми, зифа нарат, зәп-зәңгәр күк гөмбәзендә тотынырэйбер тапмыйча, ипле генә авып төшә.

Володя Бушуев аударган агачларның башлары барысы бер юнәлештә, трактор юлының ике ягына почмак ясап яталар. Шуңа күрә биек эстакада өстеннән караган Газинурга алар бик зур бер чыршы булып күренә. «Оста аудара бу Володя», – дип уйлап ала Газинур, чөнки агачларны бу рәвешчә аудару бүрәнә сөйрәтүчеләрнең эшен бермә-бер җиңеләйтүен ул белә иде инде.

Владимир Бушуев белән Газинур урманга килгән көннәрдә үк танышты. Бушуев – уртача буйлы, якты зәңгәр күзле, көләргә, җырларга, җиң сызганып, тирләп-пешеп эшләргә ярата торган киң күңелле рус егете. Үзенең атаклы урман кисүче булуына, даны леспромхоздан еракеракларда шаулавына карамастан, ул Газинур белән бер дә эреләнмичә сөйләште, аның беркатлы сорауларыннан башта эче катып көлде, ә аннары җитди итеп, түземлелек белән аңлатырга кереште. Газинур инде аның биографиясен дә читләтеп белеп алды. Ул урман кисүче малае икән, эти-әниләре хәзер дә исән, күрше участокта эшлиләр. Володя аларның төпчек уллары, ә Володяның абыйлары кайсы инженер, кайсы Кызыл Армия командиры. Володя үзе дә киләчәктә командир булырга хыяллана. Володяның Катя исемле сөйгән кызы да бар икән, биредә медпунктта эшли, тик хәзер вакытлыча Свердловскига киткән. Озакламыйча кайтырга тиеш.

Бераздан машиналар кайтып җитәргә тиеш, барлык әзер бүрәнәләргә маркировка ясап бетерергә кирәк. Газинур учларына төкерә дә яңадан тамга салырга керешә.

Участокта өстенә кыска тун, башына кеш мехыннан тегелгән бүрек кигән партоешма секретаре Павел Иванович Иванов күренде. Ул беркадәр вакыт Бушуев белән сөйләшеп торды, аның эшен күзәтте, ботак чистартучылар янына туктады, тракторчыларның эшенә җентекләп карап торды, аннары трактор өстенә менеп, кулы белән тирә-якка күрсәтә-күрсәтә нидер әйтте. Мөгаен, берәр киңәш биргәндер.

Павел Ивановичны монда көн саен күрергә мөмкин. Ял вакыты туры килсә, эшчеләр аны шунда ук сырып алалар, ул кар өстендә яткан берәр бүрәнә өстенә утырып, йә леспромхозның көндәлек эшләре турында, йә Советлар Союзындагы яңалыклар турында сөйләп китә. Ул һәрвакыт үзе белән карта йөртә, халыкара хәлләр турында сөйләгәндә, аны ике агач арасына беркетеп куеп, чыбык белән күрсәтә-күрсәтә, Европаның көньягында,

Австрия һәм Адриатика районында, шулай ук Европаның көнбатыш кырыенда, Испания һәм аның әйләнәсендәге сулар районында, Бөек Океанда, Кытай тирәсендә сугыш төеннәре бәйләнеп китүе турында; астыртын рәвештә, игълан ителмичә башланган Икенче империалистик сугышның Гибралтардан алып Шанхайга кадәр булган гаять зур мәйданда баруы турында аңлатып бирә иде. Эшчеләр аның шушындый кыска, җанлы әңгәмәләрен яраталар. Павел Иванович иң буталчык мәсьәләләр хакында да бик гади итеп, һәркем төшенерлек итеп сөйли белә иде.

Газинур Павел Ивановичны теге вакытта үзләрен коткарып калган өчен хөрмәт итә иде. Павел Иванович үзе дә аны онытмый. Бүген дә, участок буйлап килә-килә, эстакада турысына җиткәч, Газинур янына туктамыйча үтмәде. Кул биреп исәнләшкәч, Павел Иванович:

– Йә, иптәш Гафиятуллин, эшләр барамы? Иптәшләреңнең кәефләре ничек? – дип сорады.

– Ал да гөл, – дип, Газинур көлемсери төшеп җавап бирде. – Сезгә рәхмәт, Павел Иванович, ярдәм иттегез.

– Эшкә күнегәсеңме?

– Әкренләп күнегәм.

– Бик яхшы. Озакламыйча укуларны оештырып җибәрәбез. Сиңа да, иптәшләреңә дә укырга кирәк. Политтүгәрәккә йөрерсең, аннары рус телен өйрәнерсең. Буламы?

– Була, иптәш парторг.

Карп Васильевич белән бераз сөйләшкәч, Павел Иванович башка эшчеләр янына китеп барды. Менә бит нинди кеше ул. Әллә нәрсә әйтмәде дә, вәгъдә дә итмәде, ә күңелне яз кояшы кебек җылытып китте, Газинур беләгендә таулар актарырлык көч сизде. Ул кичкә кадәр баш күтәрми эшләде, бертуктаусыз диярлек җырлады.

Эш бетәр алдыннан Газинур янына Карп Васильевич килде. Газинур, маркировка ясауны тәмамлап, яңадан разметкага керешкән иде. Хәзер ул озын, кәкре агач янында уйланып басып тора иде.

– Нәрсә аптырадың, Газинур? – дип сорады карт.

– Менә бу кәкредән рәтле бернәрсә чыгара алмыйча башны кашып торам әле, Карп Васильевич. Алай кистерсәм дә вай, болай кистерсәм дә вай. Утынга гына тураттырсам – кызганыч. Икенче шундый агачның үскәнен кырык-илле ел көтәргә кирәк.

Карп Васильевичның күзләре бүрәнәнең буен буйлап өлгергәннәр иде инде. Ул көлемсерәп куйды, кыска бармаклы кулы белән сары мыегын бөтереп алды.

– Уең дөрес, дустым, – диде ул. – Разметка башлар алдыннан һәрвакыт шулай уйла. Чөнки кискән ябышмый. Ләкин аптырарга да ярамый. Менә бүрәнәнең юан башыннан зәңгәрләнгән урынын утынга кисеп ташлыйбыз, – Карп Васильевич бүрәнәнең юан башыннан бер метр чамасы калдырып, балтасы белән киртләп алды, – ә калганын берәр метрлык брусларга кистерәбез. Хәзер кара, нәрсә булды. Кәкрең турайды да китте. Төшендеңме?

Газинур картка рәхмәт әйтте, разметка ясап чыкты, аннары икенче бүрәнәгә юнәлде. Карп Васильевич аның эшен мыек чылгыен бөтерә-бөтерә күзәтеп торды. Ул бер әйткәнне тиз төшенеп алуы, иренми эшләве өчен Газинурны аерата ярата иде.

Эштән кайткан чакта, Газинур, караңгыланып килгән урман эчендә дөрләп янган учакларга күз ташлап:

– Урманда утынның кадере юк, диләр иде, дөрес икән. Көн саен нихәтле ботак яндыралар. Ә безнең якта әниләр казан аслыкка да аптырый, – диде.

Кулларын артына куеп барган Карп Васильевич җитди генә җавап бирде:

– Юк, Газинур, урманда утын күп булган өчен генә яндырмыйлар аларны. Урманда чүп-чар булмаска тиеш. Чүп-чарда агач өчен бик зарарлы кортлар, бөҗәкләр үрчи. Җәй көне янгын чыгуы да мөмкин.

– Соң, аларны яндырмыйча берәр нәрсә эшләтеп булмыймыни? – дип янә сорады Газинур.

Карт тиз генә җавап бирмәде. Мөгаен, бу турыда ул үзе дә күп уйлагандыр, башкалардан да бу сорауны күп ишеткәндер.

– Әйе, – диде ул әкрен генә, – бу ылыслы ботак-чатаклардан, тиешенчә эшкәрткәндә, уксус кислотасы, метил спирты, тагын бик күп файдалы химик әйберләр эшләргә мөмкин. Тик менә урман химикларының куллары гына җитешми...

– Ничек инде җитешми? Ялкауланалармы әллә? Тотарга да газетага язарга! Безнең районда колхозларга йөрми торган бер агроном бар иде, шуны газетага язгач, көн-төн колхозларда йөри башлады.

Карп Васильевич Газинурның беркатлылыгына елмайды:

– Яздылар инде, Газинур, – диде ул. – Бу турыда хәзер Мәскәүдә бик зур галимнәр баш вата. Җиңел мәсьәлә түгел ул.

Карт урманчының бу сүзләре Газинурның кызулыгын беркадәр сүрелдерде. Мәскәү белгәч, галимнәр баш ват-

кач, күрәсең, чыннан да җиңел эш түгелдер. Шулай да әйтмичә түзмәде:

– Алайса, ул галимнәргә хат язарга кирәк, тизрәк кыймылдасыннар. Югыйсә көн саен нихәтле ботак яндырабыз ич. Әрәм бит.

Алар кисентелек буйлап баралар иде. Хәзер монда бары тик яшь агачлар гына үсә. Аларның берничәсен трактор сындырып киткән. Карп Васильевич, шул сынган агачлар янында туктап, башын селкеп, юньсез тракторчыны әрли башлады.

– Чын урманчы, – диде ул, – урманны кисү турында гына түгел, аны үстерү турында да кайгыртырга тиеш. Бүгенге көн белән генә яшәп булмый, иртәгә, киләсе елга, йөз елга алга карарга кирәк.

Карт ауган яшь наратны торгыза башлады. Газинур аңа булышырга тотынды.

– Бу участокта, – диде Карп Васильевич, – мин хәтерлим, Володя Бушуев эшләгән иде. Ул агач кисеп ташлаудан элек, яшь агачларны сындырмас өчен, аны кая таба аудару турында да уйлый. – Менә, – карт кулын сузып яшь наратлар үсеп торган киң аланга күрсәтте, – берсен генә дә имгәттермәгән бит. Барлык урманчылар да шулай эшләргә тиеш, Газинур!

Карп Васильевичның бу сүзләре Газинурга көчле тәэсир ясады булса кирәк, ул тирән уйга чумып бара башлады. Әйе, йөз ел алга карап яшәве дә, эшләве дә күңелле.

Алар тау башына менделәр. Моннан тирә-як бик ерак күренә иде. Кышкы салкын җил аларның ияк очларыннан чеметте. Урманчылар икесе дә, бүрекләрен артка этеп, алга карап тора башладылар. Карп Васильевич, кулын сузып, еракта узып баручы хәтсез озын эшелонга күрсәтте:

– Әнә синең тамгаң сугылган агачлар илебез төзелешләренә китеп бара, Газинур. Хәерле юл теләр аларга. Менә күз алдыңа китер: илебезнең кайсыдыр бер шәһәрендә, әйтик, Москвадамы, Ленинградтамы, Киевтамы, Ташкенттамы, Казандамы яки бүтән бер шәһәрдәме, менә минем кебек бер карт мастер синең тамгаң салынган агачларны карап йөри ди. Ул бик таләпчән, аңа агачның иң шәбе кирәк, чөнки яхшы материалдан гына яхшы әйбер ясап була. Карт мастер, күзләрен кыса төшеп, син тамга салган агачка тын гына карап торыр да әйтер: «Барырлык!» Исеңдә тот, Газинур, карт эшчеләр мактауга юмарт түгел, ләкин әгәр алар «барырлык» ди икән, димәк, бик яхшы. Аңлыйсыңмы син шуны?

– Аңлыйм, – диде Газинур.

Күбәләк-күбәләк кар ява башлады. Газинур баракка карга батып кайтты. Ләкин аның күңеле күтәренке иде. Ул киемнәрен тиз генә салды да, мич тирәсенә кибәргә элеп, үзе эчке күлмәкчән килеш кроватена сикереп менеп, юрганына төренде.

– Туңдыңмы? – дип сорады каршы койкада утырган Гарәфи абзый.

– Җан туңмаса, Гарәфи абзый, тән туңмый, – дип көлеп җавап бирде Газинур.

Газинур үзенең «Красногвардеец» иптәшләрен көндез бик сирәк күрсә дә – алар дүртесе дә ат белән агач ташыйлар иде – кичләрен һәрвакыт бергә булалар, бергә ашарга йөриләр, клубка, киногa да бергә баралар. Аларның үзара сөйләшкән сүзләре нәрсә турында гына башланмасын, ахыр килеп, барыбер «Красногвардеец»ка кайта, шуның белән тәмамлана иде.

Колхозның кечкенә генә яңалыгы да аларга билгеле була иде. Чөнки аларның һәркайсы атна саен диярлек хат алып тора. Бигрәк тә Һашимга хатлар еш килә. Аның өзелеп сөйгән Әлфиясе колхоз хәлләре турында да бик юмарт яза, Һашим хатның ул урыннарын иптәшләренә дә кычкырып укый.

Газинурның исә хат ягыннан башта ук бәхете булмады. Дөрес, әти-әнисеннән, абыйсы Мисбахтан аңа хатлар килгәли, ә Миңнурый нигәдер бөтенләй эндәшми. Әллә онытты инде ул гөләп чәчәге? Әллә берәр сәбәп бармы? Газинур аңа әллә ничә хат язып җибәрде. Үзенең сөюләрен килештереп әйтер өчен җырлар да язды. Бик сагындым, бик саргайдым, әгәр сабырлык даруларын тапкан булсаң, миңа да җибәр, диде. Хатка каршы хат көтүен белдерде, мине онытма дип үтенде. Әмма Миңнурыйдан җавап хатлары барыбер килмәде. Иптәшләре кайчак Газинурны кызганалар, кайчак шаярталар: «Сиңа хат язарга вакыты бармы соң аның... берәрсенең куенында ак куян кебек йомылып ята торгандыр әле», – диләр иде. Бигрәк тә Сәлим әче телле булып китте. Ул, Газинурның гыйшкыннан көлеп, аның күзен ачырмый башлады. Киң күңелле Газинур исә аңа ачуланмый, Сәлимнең моны ниндидер явыз бер максат белән эшләвен башына китерми иде. Ул Сәлимнең Миңнурыйга тыныч карый алмаганлыгын белә, ләкин Миңнурыйның аңа бервакытта да чынлап күз салганы булмады бит. Әллә ялгышамы Газинур?

Бүген Газинур эштән кайтып кереп, кроватена утыргач, Гарәфи абзый:

– Йә, Газинур, сөенечкә ни бирәсең? – диде һәм тум-

бочка өстенә җәйгән газета астыннан берьюлы ике хат чыгарды.

Газинур, кулын сузып:

– Хатлар? Миңамы, Гарәфи абзый? – дип кычкырды.

– Юк, син вәгъдәңне башта әйт, аннары кулыңны сузарсың.

– Ни телисең, шуны алып бирәм, Гарәфи абзый. Бир тизрәк!

Булса була икән! Хатларның берсе Миңнурыйдан, икенчесе Гөлләрдән. Газинур иң элек Миңнурыйның хатын ачты, беренче юлларын укый башлауга, аның йөзе кояш нуры төшкән кебек балкырга тотынды.

Миңнурыйның хаты озын иде. Колхоз хәлләре турында шактый күп язган. Дәүләткә ашлык тапшыруны срогыннан алда үтәгән өчен колхоз председателе Хәнәфине патефон белән бүләкләүләрен әйткән. Монысы инде бишенче патефон. Хәнәфи көлә: «Мин патефоннан башка бүләк алмыйм», – ди. Колхозчыларның кәефләре бик күтәренке, хезмәт көненә җидешәр-сигезәр килодан да ким алмаячаклар. Гали абзый, Кавказдан дәваланып кайткач, яңадан элекке урынында эшли башлаган, Сабир бабай һаман шунда, атлары белән. Тавык Мортыйны кулга алганнар. Бөгелмәдә күрсәтмә суд булган. Теге вакытта атларны агулаучы шул Тавык Мортый булган икән...

– Ах, эт нәрсә! – дип кычкырып җибәрде Газинур.

– Ни булган? – дип сорады Гарәфи абзый.

– Без китәр алдыннан колхозның атлары авырган иде бит... Тавык Мортый эше булган.

– Ни сөйлисең!

– Менә Миңнурый язган...

Газинур хатның бу өлешен янә укып чыкты. Аның нәфрәтләнүенең чиге юк иде. Гарәфи абзый да исәпкә калды.

Газинур хатын укуны дәвам иттерде. Миңнурый үзе бик каты авырган, тимер юлда укуын ташлап, колхозга кайтырга мәҗбүр булган. Хәзер хәле әйбәтләнгән. Һашим белән Әлфия арасында хатлар туктамый, дигән. Һашим кайткач, туй итәргә вәгъдәләшкәннәр...

Быел көз авылда туйлар бик күп буласы икән. Егетҗилән, кыз-күлән бар да шашынып йөри. Әлфия инде мамык түшәкләр әзерли...

Газинур, хатны укуын бүлеп, баракның аргы башында домино уйнап утырган Һашимга кычкырды:

– Әй, кил әле, карсак, монда кил. Синең бөтен эч серләреңне сөйләп биргәннәр бит.

«...Ә син, Газинур җаным, кайчан кайтырсың икән?

Лимон кебек саргайтып бетерәсең үземне. Ялгыз башымны кая куярга белмичә йөрим. Бер ямь күземә күренми син булмагач. Син, бәлки, мине оныткансыңдыр да... Газинур бәгырем, өмет йолдызым, син дә кайт инде тизрәк...»

Сәлим турында берни язмаган. Хәтта аңа сәлам дә әйттермәгән.

Гөлләрнең Казаннан җибәргән кош теледәй хаты дусларча язылган иде. Газинур киткәч, колхозда күңелсез булып калуын, Фатыйма белән бик еш аны искә төшереп сөйләүләрен әйткән, Газинурдан биргән вәгъдәсен онытмавын, укуын, берәр һөнәргә өйрәнүен үтенгән.

Гөлләрнең хатында бернинди вәгъдәләр дә, Миңнурыйның хатындагыча кайнар мәхәббәт тә, тирән сагыну да юк иде, шулай булса да ул, еракта янган йолдыз кебек, Газинурны шатландыра, сөендерә, кайдадыр Казан шәһәрендә Гөлләрнең яшәве аның тормышына ямь өстенә ямь бирә иде кебек.

Һашим белән Сәлим, уеннарын ташлап, Газинур янына килделәр. Гарәфи абзый, аларга күз кысып:

– Егетнең бәхет капусы ачылды бит, берьюлы ике кыздан ике хат! – диде.

– Алайса, Газинур берьюлы ике куянның койрыгын тота, – дип чәнчеп алды Сәлим.

Кулларын чалбар кесәсенә тыккан кыска буйлы Һашим, елмаеп:

– Йә әле, Газинур, укып җибәр, минем турыда татлы торма нәрсә язган, – диде.

– Бәлки, Газинур хатны башыннан ук укыр? – диде Гарәфи абзый, аның сүзен куәтләп.

Газинур кара күзләрен уйнатып алды:

– Артыграк булмасмы икән, Гарәфи абзый. Һашим бит Әлфиянең хатларын берсен дә тулы килеш безгә укымый. Йә, ярар, тыңлагыз.

Газинур хатны яңадан укый башлагач, Сәлим шунда ук мич каршына китеп барды, тәмәке кабызды. Миңнурыйның Газинурга төбәп әйтелгән җылы сүзләрен ишеткәндә, аның йөзе караңгыланганнан-караңгылана барып, күзләре яшел тамчылар булып кечерәеп калды. Ләкин хатта Тавык Мортыйның исеме телгә алынгач, ул кинәт кенә Газинурга таба борылды, үлек кебек туп-туры карап тора башлады.

Газинур хатны укып бетергәч, Сәлим тиз генә иптәшләре янына килде һәм:

– Бу чынмы? – дип сорады, еш-еш сулап. – Безнең атларны Тавык Мортый агулаган булганмы?

– Миңнурый буш сүз язып тормас, – диде Гарәфи абзый. – Ә без менә үз арабызда сарык тиресе ябынып йөргән бүрене күрмәгәнбез.

– Ух, сволочь! – дип кычкырды Сәлим, йодрыгын күтәреп кемгәдер янап алды. – Ул кара җан аркасында бер гаепсез кешенең башын ашаулары мөмкин иде бит. Минем турыда нихәтле нахак сүз сөйләделәр...

Сәлим ике-өч минут буенча җилләнеп торды да, иптәшләренең үзеннән әкрен генә көлүләрен күргәч, яңадан мич каршына барып утырды. Ләкин бу юлы инде ул тәмәкесен баягы кебек өзек-өзек түгел, ә ашыкмыйча гына суырды. Барлык вак җанлы кешеләрнеке кебек Сәлимнең дә нәфрәте сай, тәмәке төтенедәй җиңел иде. Мондый кешеләр теләсә нинди факттан да аның шәхси ягын аерып алалар. Әгәр дә аларның үзләренә бернәрсә дә кагылмаса – алар канәгать. Әгәр дә инде шунда аларның аз гына хаклы булулары да күренсә, алар канәгать кенә түгел, алар инде шат. Сәлим белән дә нәкъ менә шундый хәл иде. Башта ул бик каты курыкты. Мортый эшенә бер-бер катнашы булганлыктан түгел, – бу яктан аның вөҗданы чиста иде, – ә вак-төяк гөнаһларының ачылуыннан курыкты. Андый-мондый хәлнең юклыгын белгәч, ул җиңел сулап куйды: хәзер Сәлимнең колхозда кайчандыр начар ветфельдшер булганлыгын бөтенләй онытачаклар, алай гына да түгел, ул әле, эшне яхшылап алып барганда, үткән көннәрнең каһарманы булып әверелүе дә бик мөмкин...

Әгәр дә иптәшләре Сәлимнең бу бозык уен белсәләр, алар аны кыйнап ташлаган булырлар иде. Кызганычка каршы, бозык уй һәрвакыт тирән яшерелгән була, аны белү түгел, сизүе дә кыен. Менә кеше терсәге белән тезенә таянып мич алдында утыра, ашыкмый гына тәмәке тарта, йөзенә ут яктысы төшкән, аның җаны да йөзе кебек үк якты шикелле тоела. Аның башында бик әшәке уйлар айкалуын берәү дә белми...

– Ә безнең мыштым кайда? – дип сорады Һашим кинәт.

Газзән баракта юк иде. Аңа нәрсәдер булды. Соңгы вакытта ул баракка гомумән бик соң кайта, еш кына исерек тә була иде. Аек чакта аның авызыннан сүзне аркан белән тартып та чыгарып булмаса, исергәч, ул күп һәм зарланып сөйли, каядыр китәргә җыенганлыгын әйтә.

Гарәфи абзый да, егетләр дә аны иптәшләрчә үгетләп карадылар. Ләкин Газзән аларны тыңларга да теләмәде: «Мин бәби түгел, миңа нәнкә кирәкми», – ди иде ул аларга каршы.

Газзән белән сүзләре күбрәк туры килә торган Сәлим:

– Контора тирәсендәдер әле. Ул бит чыннан да китәргә җыена, – диде.

Шул чакта, карга буялып, Газзән үзе дә кайтып керде. Ул карлы бүреген ишек төбендә салып, киез итегенә суга-суга какты да ашыкмый гына чишенә башлады. Аннары, дөрләп янган мич авызына каршы чүгәләп, тәмәке тартырга тотынды. Газинур сүзсез генә аны күзәтеп ятты. Газзәннең йөзе уйчан, үзе бераз борчылган да кебек. Нәрсә бар аның уенда? Нинди теләкләр белән яши бу кеше? Авылда чакта ул урта хәллеләрдән санала иде, Аларның бөтен нәсел-нәсәпләре мыштым, үзләре үтә саран. Колхозда Газзән үзенең бер ягы белән дә күзгә ташланмаска тырыша иде. Бер генә җыелышта да сүз алып сөйләмәде.

– Начальство күбрәк белә, без вак кешеләр, – ди торган иде ул, бик бәйләнә башласалар.

Газзән тәмәкесен тартып бетереп, үз кровате янына килеп утыргач, аңа Тавык Мортый турындагы хәбәрне әйттеләр. Моңа аның бер дә исе китмәде.

– Таш капчыкка утырасы килгәндер, – диде ул сүрән генә.

Газинур аның бу пошмаслыгына эченнән бик нык ачуланса да тыштан сиздермәде. Сүзне икенчегә борып:

– Газзән абый, безгә әйтмичә генә каядыр китәргә җыенасың дип ишеттем, дөресме? – дип сорады.

Газзән тиз генә җавап бирмәде. Ул Газинурга каш астыннан кырыс кына карап алды да өстәлгә таянды. Бары шуннан соң гына:

– Әйе, барып чыкса, шундый исәп юк түгел иде, – диде.

Газинур, башта ук аңа турыдан-туры бәрелергә батырчылык итмичә, аның кулыннан тотты:

– Ни сөйлисең син, Газзән абый?! Хәзер бит урманда эшнең иң кызу чагы башлана. Урак өсте. Быелга үткән елгыга караганда планны да ике өлеш арттырып биргәннәр.

Газзән, өстәлгә таянган килеш, һаман читкә карап торды. Газинур Һашимга, Сәлимгә, иң актыктан Гарәфи абзыйга күз төшерде: «Йә, сез ни дисез моңа?»

– Газинур дөрес әйтә, Газзән. Хәзер моннан китү килешеп бетмәс, – диде Гарәфи абзый.

Һашим да шуны якларга кереште. Сәлим сүзгә катнашмады.

Газзән үз алдына мыгырданды:

– План тулыр... Без монда төп көч түгел мичәүдә баручылар гына.

Газинур, бу сүзләрне ишеткәч, бер сикерүдә Газзән койкасы янына килде. Ул шундый каты сикерде, өстәлдәге лампа, чайкалып китеп, аз гына аумады.

– Сыер кебек дулама әле, – диде Газзән, кашларын җыерып.

– Мичәүдә баручылар дисеңме? Планны бездән башка да тутырырлар дисеңме? – дип буыла-буыла кычкырды Газинур. – Акылың алтын икән, Газзән абый! Кирәк вакытта үзебез барып сорадык, ә хәзер көн-төн эшли торган вакытта, кигәвеннәр тешләгән бозау кебек, койрыкны сырт буена!.. Бу ничек була инде, Газзән абый? – Газинур Гарәфи янына килде. – Син безнең арада олы кеше, колхоздан киткәндә Хәнәфи абый безгә синең сүзне тыңларга кушты. «Красногвардеец»ның йөзенә кызыллык китермәгез, диде. Газзән абый синең сүзеңне тыңларга тиеш. Син турысын өздереп әйт.

Гарәфи, башын күтәреп, бер Газинурга, бер Газзәнгә карады. Аның бу карашында Газинур ниндидер тартыну барлыгын сизде. Ул Газзәннең хәтерен калдырырга теләми иде булса кирәк. Газинур моның белән килешә алмады.

– Юк, Гарәфи абзый, син туры итеп әйт, боргаламыйча. Әгәр дә инде Газзән абый тыңламый икән, үз акылым акыл, ди икән, ул чагында китсен. Тик мин Газзән абыйдан мондый эшне көтмәгән идем. Ул Тавык Мортый түгел бит.

Газинурның бу сүзләренә каршы Газзән берничек тә җавап бирмәде.

## 15

Шулай да беркөнне эштән кайтуга, Газзәннең койкасын буш күргәч, Газинур бик нык күңелсезләнде, үзенең кровате янына килеп, чишенмичә-нитмичә ятты да, кулларын баш астына куеп, такта түшәмдәге бер ноктага карап тора башлады. Колхоздашының болай эшләвенә аның күңеле кыйнала иде. Дөрес, иртән эшкә киткәндә, Газзән барысы белән дә ике куллап саубуллашты, үзенең кая эшкә урнашуы турында бик тиз хәбәр итәргә булды. Ләкин аның болай җылы итеп саубуллашулары түгел, ә бәлки яңадан уйлар әле, китмәс әле, башына тай типмәгән бит дигән фикер Газинурны беркадәр өметләндергән иде. Хәзер ачык. Газзән киткән...

Газинур янына Володя Бушуев килеп утырды.

– Сагышланасыңмы әллә? – диде Володя. Аның зәңгәр күзләре үз итеп карыйлар иде. – Якташың ташлап киттемени?

– Китте шул! – диде Газинур, яткан җиреннән кузгалмыйча. – Җылы урын эзләп китте. Гарьлек! – Газинур торып утырды. – Белсәң иде, Володя иптәш, китүе белән ул мине җәберсетте! – Ул үзенең кабарып, җилдән, сал-

кыннан кызарып беткән зур учын күкрәгенә куйды. – Менә монда пычак кадаган кебек. Җитмәсә, безнең «Красногвардеец» кешесе... Кыйнап киткән булса, җиңелрәк булыр иде.

Володя аның иңбашына кулын салды:

– Кайгырма, Газинур, – диде ул йомшак кына. – Киткән артыннан китеп булмас. Безгә менә кичке буш вакытларны әрәм итмәү турында уйларга кирәк. Хәзер бит һәр җирдә уку елы башланды. Мин үзем урман техникумында читтән торып укыйм. Сиңа да, Газинур, укырга кирәк. Тырышсаң, булдырасың син.

Уку турында сүз чыгуга, Газинур бик шатланып китте. Бу турыда Павел Ивановичның да сөйләшкәнлеген әйтте.

– Мин монтерлыккамы, тимерчелеккәме укыр идем, Володя, – диде ул, хыялланып. – Колхозда электростанция салырга уйлыйбыз. – Газинур Гөлләрне күз алдына китерде: – Без аның урынын да билгеләдек инде.

– Бик яхшы, – диде Володя. – Минем электрик дусым бар. Миша Степановны беләсеңме? – Газинур белгәнлеген әйтеп башын иде. – Миша менә дигән электрик. Ул сине өйрәтер. Ләкин моннан тыш, Газинур, сиңа рус телен өйрәнергә кирәк. Турысын әйткәндә, русчаны син урман тракторы чыбык-чабыкны ваткан кебек ватасың. Аннары без сине политтүгәрәккә дә яздык. Тиздән безнең кызыл почмакка Катя килеп йөри башлаячак. Син аны белмисең әле, ул җәй буе шәһәрдә экзаменнар биреп йөрде. Тагын ике елдан врач буласы кеше. Ул ел саен бездә аз белемле кешеләрне укыта. Сине дә укытыр.

– Берүземнеме?

– Нишләп берүзеңне булсын. Синең кебек укырга теләүчеләр бездә байтак, Газинур.

Атна-ун көннән укулар башланды. Газинур иптәшләре белән бергә бик тырышып укырга йөрде. Хәзер Газинурның бер генә киче дә буш булмый иде. Ул йә Карп Васильевич янына, «урман дәресенә», йә Миша Степанов янына, «электр дәресенә», йә кызыл почмакка, Катя янына рус телен өйрәнергә, йә политграмота түгәрәгенә йөгерә. Бигрәк тә Катяның дәресләрен ул түземсезлек белән көтә иде. Кара болыт чәчле, бераз моңсу карый торган коңгырт күзле, елмайганда яңаклары чокырлана торган бу япь-яшь рус кызы аңа бер дә иренмичә рус телен өйрәтә, кайчагында аның берүзе өчен генә калып та берәр-икешәр сәгать утыра торган иде. Газинурның сүз запасы шактый, җөмләләр төзергә дә маһирлыгы бар, әмма басымнарны, родларны бар дип тә белми. Татарчага туры китереп, топор, пила, дерево кебек рус сүзләрен барысын да

«ул» дип җибәрә яки «он пошел» урынына «она пошел», яки киресенчә кулланулар аның телендә еш була иде. Катя аңа һәр мисалны иренмичә, аерата зур түземлелек белән аңлата, русча сөйләгәндә татарчаны «онытып» торырга куша иде. Газинурның җыр яратуын, җыр отарга сәләтле булуын сизеп алгач, Катя аңа төрле җырлар ятларга куша башлады. Кайчак алар дәрестән соң моңлы рус җырларын бергәләп җырлыйлар. Газинур җырны кайда ишетсә, шунда отып ала иде. Катяга ул һәр дәрескә бер җыр ятлап килергә сүз бирде. Кайчакта Катя аның отып килгән җырларын тыңлаганда эче катып көлә, моңсу коңгырт күзләре очкынланып китәләр иде.

Бүген дә уку китабы буенча бирелгән дәресне укыткannan, ике бит чамасы күчереп яздырганнан соң, Катя Газинурдан:

– Йә, Газинур, бүген нинди җыр өйрәндең? – дип сорады.

– Җыр – сабак түгел, аны булдырабыз, – диде Газинур, елмаеп. Аннары үзенең матур тавышы белән җырлап җибәрде:

Нас утро встречает прохладой,
Нас ветром встречает река...

Катяның ак йөзе җиңелчә кызарып китте: бу Володя Бушуевның яраткан җыры иде. Катя белән икәүдән-икәү генә калган чакларында ул һәрвакыт шушы җырны җырлый торган иде.

Кудрявая, что ж ты не рада
Веселому пенью гудка? –

дип әләктереп алды Катя. Газинур аңа кушылды. Кушымтаны да икәү бергә җырладылар.

Не спи, вставай, кудрявая,
В цехах звеня, –
Страна встает со славою
Навстречу дня.

Катя шатланып туя алмый: җыр Газинурның күңелен күтәреп кенә калмый, җыр аңа рус телен яратырга, рус сүзләрен дөрес әйтергә, сүз байлыгын арттырырга да бик зур ярдәм күрсәтә иде.

Беркөнне, дәрестән соң баракка кайткан чагында, Катя Газинурдан:

– Газинур, синең сөйгән кызыңның исеме ничек? – дип сорады.

Газинур шыгырдап торган кар өстеннән атлый-атлый аңа гаҗәпләнеп карады:

– Минем сөйгән кызымның барлыгын каян беләсең?

– Синең кебек җырчы егетләрнең сөйгән кызлары булмыйммы соң, – диде Катя, елмаеп. – Колхозыгызның бөтен кызлары сиңа гыйшык тотканнардыр әле.

Газинур, култык астындагы әлифбасын җайлабрак кыстырып:

– Юк, «Красногвардеец»та ул яктан минем базар әллә ни югары түгел иде, – диде. – Бездә барысы да җырлый белә, җырның ертыгы юк. Менә гармунчының базары төшми. Кызлар аңа чебен балга ябышкан кебек ябышалар.

– Хәйләлисеңдер, Газинур. Шулай да сөйгәнеңнең исемен әйт әле.

– Миңнурый, – диде Газинур.

– Миңнурый? Матур исем. Ә русча нәрсә дигән сүз?

Газинур русча аның мәгънәсен аңлата алмагач, Катя аны бераз шелтәләп тә алды.

– Ничек инде ул алай, Газинур, сөйгән кызың исеменең мәгънәсен белмисең?

– Аның мәгънәсе дә буламыни? – дип гаҗәпләнде Газинур. – Бездә мәгънәсен-ниен тикшереп тормыйлар: Миңнурый да Миңнурый дип йөртә бирәләр. Ә менә кушаматларының мәгънәсен беләм: берсе – гөләп чәчәге – цветок шиповника, икенчесе – татлы торма – сладкий редька.

– Сладкая, – дип төзәтте Катя һәм көлеп җибәрде. – О, ул үзе чәнечкеле, үзе татлымыни?

– Шундыйрак шул! – диде Газинур. Аның тавышында горурлану да, сагыш та яңгырады.

Тышта инде чын-чынлап Урал кышы иде. Аерата салкын төннәрдә агачлар шарт-шорт итә, әйтерсең мылтык аталар. Мондый төннәрдә бүреләр поселокка якын ук килеп улыйлар, ә иртән тагын каядыр посалар. Агачларның шәрә ботаклары ап-ак бәскә төренгән. Салкын күктә йолдызлар чекерәешеп тора. Бер кырыйда, урман эчләренә моңсу ак нурын сибеп, тулган ай әкрен генә йөзә. Мондый айлы кичләрдә, әгәр дә азрак җил дә булса, урман эче җанлы кебек тоела – бөтен җирдә күләгәләр уйный, серле авазлар ишетелә.

Баракка керер алдыннан Газинур бер генә минутка туктап калды. Ике нарат уртасыннан күренеп торган тулган айга текәлде. Бәлки, Миңнурый да айга карый торгандыр? Катя үзенең сораулары белән Газинурның яшь күңелен җилкендереп җибәрде. Ерак шул син, Миңнурый, ерак, кадерлем. Хатларың да бик сирәк килә. Көнаралаш язам дисең, ә Газинур нибары ике хатыңны алды.

Ара ерак шул, язган хатларың да тиз генә килеп җитә алмый.

Хатларның югалуына бер-бер кешенең катнашы барлыгын Газинур башына да китерә алмый иде. Әгәр хатларның леспромхозга кадәр килеп тә, шушында ерткаланып җилгә очырылуын яки учакка атылуын белгән булса, ул гаеплене яңаклап алудан да тукталып калмас иде. Ләкин ул үзенең беркатлылыгы белән берни дә күрми иде. Хатлар конторкага килә, аннан кем туры килсә, шул алып кайта да өләшә. Газинур үзе почтальон килә торган вакытларда конторкага барырга бер дә вакыт таба алмый иде.

Сәлимнән ул бөтенләй шикләнмәде. Газзән киткәннән соң, Газинур Сәлимне хәтта беркадәр якын күрә башлады. Ни әйтсәң дә, «Красногвардеец» егете бит, бергә үскән, бергә уйнаган, бер чишмәнең суын эчкән. Дөрес, биредә Сәлимнең колхозда чакта күзгә ташланмаган яңа сыйфатлары да әз-әзләп ачыла башлады. Ул еш кына аракы эчә, каядыр китеп карта уйный. Газинурның үз теле белән әйткәндә, «шахыр-махыр» да иткәли бугай. Беркөнне Газинур аның сандыгында «ат башы хәтле» яңа йозак күргәч, исәпкә калды: нәрсә яшерә Сәлим? Элек ул сандыгын иптәшләре алдында бер дә тартынмыйча ача торган иде. Анда аның кием-салымыннан, сандык капкачының эчке ягына ябыштырылган бизәкле открыткалардан башка берни дә юк иде. Хәзер ул сандыгын кеше юк чакта гына ача...

Газинур кайчан да булса Сәлим белән ныклап бәрелешеп аласын, йөрәгенең ерак-ерак почмагында хәзергә әле сәбәбе дә билгеле булмаган ачу төене төйнәлә башлавын сизә иде сизүен. Ләкин үзе үк моны күңеленнән куарга да тырыша иде.

Газинур тагын бер тапкыр тулган айга карап алды да, Миңнурыен сагынып тирән генә бер көрсенеп, баракка кереп китте.

## 16

Биек тау башыннан, атылган ук кебек очып, ике кеше чаңгыда төшә. Текә борылышларда алар, кар тузаны туздырып, бер генә секундка күренәләр дә тагын күздән югалалар, аннары тагын агачлар арасыннан очып чыгалар, тагын югалалар. Аларга борыла-сарыла төшәргә туры килә, чөнки аларның юлларында бик күп агачлар, ташлар бар.

Алданрак төшә торганы бөтен көченә оча. Аның өстендә ак свитер, куе зәңгәр чалбар, башында куян тиресеннән тегелгән озын колаклы бүрек. Көчле җил аның

муенына ураган шарфының очларын, бүрегенең озын колакларын артка каерган. Чаңгычы үзе алга иелгән, боҗралы таякларын карга да тидерми. Бу оста чаңгычының урман белән яхшы таныш булган кыю бер кыз икәнен күрү кыен түгел иде.

Арткарак калып төшә торган чаңгычы, соры костюмлы, аркасына ау мылтыгы аскан егет тыелыбрак шуа. Ул кызның секунд саен алмашынып торган һәр хәрәкәтен күзәтә. Аның карашында соклану да, борчылу да, кирәк була калса, ярдәмгә әзерлек тә бар. Чаңгылар аның ихтыярына тулысынча буйсына, текә борылышларны ул аеруча оста үтә. Әгәр теләсә, ул кызны әллә кайчан узып киткән булыр иде.

Еракта, ак җаймә шикелле җәелеп яткан киң күл өстендә, алар тын алалар, бераздан икенче тауга менәләр, тагын түбән төшеп китәләр. Күрәсең, алар икесе дә таудан шуарга, кош кебек очарга, урманның каршыга чабуын күрергә яраталар. Егетнең ау мылтыгы да ул-бу булмагае дип кенә алынган булса кирәк. Аларга бик күп куян, көртлек эзләре очрый, бер тапкыр алар хәтта поши эзен дә игътибарсыз үтеп киттеләр. Ниһаять, алар бер тау башында туктадылар. Тирә-якта урман кисүченең пычкысы тимәгән мәһабәт наратлар, карасу чыршылар, тирән бер тынлык саклап, селкенмичә торалар. Аларның киң тармаклы ботакларын кар баскан, ул кар бөртекләре кояш нурларында җем-җем итә. Бигрәк тә кышкы урманда каеннар матур. Аларның бәс белән уралган нечкә ботаклары ап-ак чәчәкле гөлләр төсле. Каеннар үзләре шундый нәфис, шундый сылу, шундый зифа, аларны кочып үбәсе килә. Һәм куян бүрекле кыз чыннан да аны бер кулы белән кочаклый, башын каенның ап-ак кәүсәсенә куя. Бер генә секундка озын коңгырт керфекләрен түбән төшерә. Шунда алсу ак йөзле бу кыз әкияттәге йоклап яткан урман чибәренә охшап китә. Егет аның янына килә, кыз озын керфекләрен күтәрә, елмая. Аның елмаюында да кояшта җемелдәгән яңа кар бөртегенең җемелдәве шикелле ниндидер кабатланмас бер матурлык бар. Егет аның кулыннан тота.

Алар текә яр кырыена киләләр. Түбәндә Кама елгасы. Хәзер ул калын боз астында, өстенә ап-ак юрган ябынган, яз көнендәгечә актарылып акмый, җәй көнендәгечә әкрен генә тирбәлдереп, исәпсез-хисапсыз салларны да мул суында агызып бармый. Ул калын боз астында, ләкин шулай да агудан туктамаган, бәхетләре ташып торган ике яшь күңел аның дулкыннарының тонык шаулавын ишетәләр кебек.

Газинур Володя белән Катяны (әйе, бу алар иде) беренче тапкыр икесен бергә нәкъ менә шунда, Каманың текә ярында күрде. Аның күзләре зур булып ачылды: аның карашында сөенү дә, көнләшү дә бар иде. Менә бит бәхетлеләрнең хәле!

Аучылар йөри торган киң чаңгылы Карп Васильевич исә, егет белән кызга тамчы да игътибар итмичә, үз юлыннан бара бирә. Аның бөтен гәүдәсе, хәтта кечкенә сакалы һәм борын очына элгән күзлеге дә алга омтылган кебек. Бил каешында аякларыннан аскан ике куян, бер көртлек селкенә.

Газинурның да бил каешында куян бар. Ләкин ул аудан бигрәк урман белән кызыксына шикелле. Ул кар өстендәге эзләргә түгел, тирә-ягына каранып бара. Авыз эченнән нидер көйли дә. Үзе нигәдер яланбаш, кара чәченә кар бөртекләре ябышкан.

Кайдадыр тукран агач кайрысына томшыгы белән бәрә. Берничә тапкыр бәрә дә туктый, аннары тагын тукылдарга керешә. Биек нарат башында, аучыларга мыскыллы карап, гөнҗәлә койрыклы тиен ботактан ботакка сикерә.

Газинур кинәт кычкырып җырлап җибәрә. Карп Васильевич шаккатып туктый, озак кына карап тора, аннары бармак яный: ух, юләр! Ауда җырлап йөриләрмени...

...Баракта Катяны көтәләр иде. Ул монда кич саен диярлек килә, эшчеләргә «Корыч ничек чыныкты» китабын кычкырып укый. Ул бик оста укый. Китапның күңелле урыннарын укыганда, аның үзенең дә йөзе шатлыктан балкый, тавышы ягымлылана, байларның, петлюрачыларның кабахәтлекләрен, ерткычлыкларын сурәтләгән урыннарын укыганда, аның тавышы кырыслана, чырае караңгылана, геройларның авыр кичерешләре турында укыганда, аның күзләре мөлдерәмә яшь белән тулы була. Урман кисүчеләр – картлары, яшьләре – аны тын да алмыйча тыңлыйлар. Катя белән бергә шатланалар, нәфрәтләнәләр, кайгыралар. Газинур һәрвакыт Катяга каршы утыра, малай чакта Галәк бабайның Ямәлкә патша турындагы тылсымлы әкиятләрен тыңлагандагы шикелле, китапның бер генә сүзен дә ычкындырмаска тырыша.

Катяга җылырак булсын өчен, мич кырыена ук елыштырылган өстәл янына Газинур бүген дә иң алдан килеп утырды. Урманда Катя белән Володяны күрүен исенә төшергәч: «Бүген Катя бик арыгандыр, килми калмагае», – дип борчылып куйган иде Газинур. Ләкин Катя

вакытында килеп җитте. Ул, өстәл тирәсенә утырышкан уннарча кешеләргә баш иеп:

– Исәнмесез, иптәшләр! – диде.

Дядя Митрофан аңа тунын салырга булышты, куян бүреген кулыннан алды.

– Кызлар артыннан ничек ухаживать итәргә яшьләр картлардан үрнәк алсыннар, – диде ул, барысын да көлдереп.

Өстенә аксыл көрән фуфайка кигән Катя, коңгырт чәчләрен төзәткәләп, өстәл янына утырды да китапның ак кәгазь кыстырган җирен ачты. Барысы да Катяның бүген аеруча шат күңелле, көләч йөзле булуына игътибар иттеләр. Ләкин Газинур гына моның чын сәбәбен белә иде.

– Иптәшләр, – диде Катя, – укуыбызны дәвам иттерәбез. Ләкин бүген мин сезгә күп укымам, нәкъ сәгать сигездә клубта кино башлана, ә аннары танцы була. Барыгыз да клубка рәхим итегез.

Катя үзенең моңсу, ләкин бүген үтә көчле ялтыраган күзләре белән халыкка тагын бер тапкыр карап алды да укый башлады.

«Бу зур, көчле кеше, нык большевик, мең тугыз йөз унбишенче елдан бирле РСДРП(б) члены, йөзе диңгез җилләре белән киселгән Балтыйк матросы Федор Жухрай үзенә сихерләнгән күзләр белән карап торучы яшь кочегарга тормышның каты хакыйкатен сөйләде.

– Мин, туган, үзем дә бала чакта менә синең шикелле идем, – диде ул. – Көчеңне кая куярга белмисең, эчеңдәге буйсынмас көч тышка бәреп чыга. Мин фәкыйрьлектә яшәдем. Кайчакларда тук, яхшы киенгән бай малайларына карыйсың да, аларга булган дошманлыктан йөрәгең яна. Мин еш кына аларны бик каты кыйный торган идем, ләкин моннан әтинең мине нык кына кыздыруыннан башка бернәрсә дә чыкмый иде. Ялгызың сугышып, тормышны икенче якка борып булмый. Синдә, Павлуша, эшчеләр файдасын күзәтүче яхшы кеше булу өчен кирәк булган бөтен нәрсә бар, тик син менә бик яшь әле һәм сыйнфый көрәшне бик аз аңлыйсың. Мин сиңа, туганкай, чын юлны сөйләп күрсәтермен, чөнки мин беләм: син эшлекле булачаксың. Юаш һәм ялагай кешеләрне яратмыйм мин. Хәзер бөтен җир йөзендә янгын башланды. Коллар баш күтәрде, алар иске тормышны диңгез төбенә батырырга тиешләр. Ләкин моның өчен аңа куенында назланучы балалар ярамый, моның өчен батыр егетләр кирәк, сугыш алдыннан тараканнар шикелле ярыкка качмыйча, шәфкатьсез сугыша торган нык халык кирәк».

Газинур, Катядан күзен алмыйча, терсәгенә таянып тыңлый. Ул әле күп кенә сүзләрнең мәгънәсен авыр төшенә, кайчагында гомумән аңлап та бетерми, җанытәне белән ярата башлаган Павка яки Жухрай матрос озаграк югалып торсалар, эче пошып:

– Павка белән Жухрай матрос кая киттеләр? – дип, Катяны бүлдереп сорап та куя иде. Мондый чакта аңа төрле яктан ачуланып кычкыралар, ә Катя ачуланмый, ул елмая гына. Китаптагы вакыйганы Газинур күптән инде үзенә яхшы таныш булган Бөгелмәгә күчереп куйган. Шуңа күрә китапта сөйләгәннәрне Бөгелмә урамнарындагы хәлләр итеп күз алдына китерә, аларны Гали абзыйлар, Бөгелмәнең туганнар каберендә күмелгән геройлар белән бәйли. Жухрайны ул Бөгелмә ревкомы членнары Петровская, Просвиркин иптәшләр белән бергә күмелгән билгесез матрос итеп исәпли.

Павка Корчагин матросны петлюрачылардан коткаргач, Газинур, чиксез шатланып:

– Молодец, Павка! – дип кычкырды. – Шулай кирәк, андый кеше өчен башың да жәл түгел.

Икенче көнне Газинур, бүрәнә төшереп, аягын имгәтте. Карп Васильевич шунда ук аны медпунктка озатты. Катя, ак халат киеп, чиста, иркен бүлмәдә берүзе утыра иде. Газинурның аксый-туксый килеп кергәнен күргәч, борчылып:

– Газинур, ни булды? – дип сорады.

– Таяк төште, – диде Газинур, шаяртып.

Яра шактый иде, ләкин Катя перевязка ясаганда, Газинур бер генә тапкыр да ыңгырашмады.

– Мин сиңа бюллетень язам, Газинур. Син берничә көн өйдә генә утыр, – диде Катя.

Газинур каршы килде:

– Кирәкми, мәшәкатьләнмәгез. Мин барыбер баракта ята торган түгел.

Бары тик Катя шелтәләгәннән соң гына, Газинур кәгазьне кулына алды һәм, уңайсызланып:

– Карп Васильевичка берүзенә кыен булачак бит, – диде. Аннары, башын күтәреп: – Катя иптәш, сез миңа, алайса, Островский китабын биреп торыгызчы. Бер җирдә минем шигем бар, үз күзем белән карыйсым килә, – диде.

Катя, гаҗәпләнеп:

– Нинди шик ул, Газинур? – дип сорады.

– Матрос Жухрайны эшчеләргә булышыр өчен Бөгелмәгә Ленин үзе җибәргән булган, аның пулеметы да булган. Сез нигәдер шул урынын укымадыгыз.

– Ни өчен алай дип уйлыйсың, Газинур?

– Миңа бу турыда Гали абзый сөйләгән иде. Жухрай матросның кабере дә Бөгелмәдә. Тик анда нигәдер исемен генә язмаганнар.

– Бөгелмәдә?

– Әйе, Бөгелмәнең шәһәр бакчасында. Безнең Гали абзый аны, Павка Корчагин кебек, үз күзе белән күргән. Жухрай матросны соңыннан аклар үтергәннәр...

Катя берни әйтмәде, ул Газинурга «Корыч ничек чыныкты» китабын биреп җибәрде һәм, ул чыгып киткәч, тәрәзәдән бик озак карап торды. Газинурның китапны шулкадәр үзенчә аңлавына ул таң калган иде.

Яңа ел алдыннан урман кисүчеләрнең зур җыелышы булды. Иң яхшы бригадага – Володя Бушуев бригадасына – Күчмә Кызыл Байрак тапшырылды. Володя Бушуев, кызыл комач белән ябылган президиум өстәле яныннан торып, уннарча кешеләрнең алкышлары астында байрак янына килде. Байракны тотып торучы икенче бригада җитәкчесенең кулын каты итеп кысты. Аннары байракны уң кулына алып, халыкка таба борылды да смирно басты. Якты электр утында байракның йолдызы, алтын чуклары, куе кызыл төстәге хәтфәсе җем-җем итеп торды. Володяның җилдән, кояштан каралган йөзе көләч, күзләре чак кына кысыла төшеп каядыр еракка-еракка карыйлар иде.

Алгы рәтләрнең берсендә Катя белән янәшә утырган Газинур, байрак тоткан Володяга сокланып карый-карый, Бушуев бригадасы членнарыннан да катырак итеп кул чапты. Моңарчы аның байрак тапшырганны бер дә күргәне булмады. «Красногвардеец»та андый хәлләр нигәдер юк иде. Байрак алырга хокуклы булу, байрак тотып, менә шулай халык алдында басып тору бәхетенә ирешү Газинурга бик зур, хәзергә әле аның көче җитмәслек бер эш булып тоела. Шулай да бүген ул аерата бәхетле, леспромхозның начальнигы үзенең докладында башка бик күп ударниклар белән бергә Газинур Гафиятуллинның да исемен мактап телгә алды. Газинур Катяга карап каш сикертте. Ул Газинурдан да бигрәк шатланган, алсу йөзендә нур балкый, ләкин моны берәүгә дә сиздермәскә тырыша.

Алкышлар тынгач, Володя байракны моннан соң беркемгә дә бирмәс өчен, тагын да тырышыбрак эшләячәкләрен әйтте. Аның тавышы көчле, нык иде.

Җыелыштан Газинур бәйрәмдәгедәй күтәренке күңел белән кайтырга чыкты. Әйтерсең аның үзенә байрак бирделәр, әйтерсең серле көзгедә аның иртәгәге гаҗәеп ма-

тур көнен күрсәттеләр дә: «Әйдә, оч, егет, шул яктылыкка таба!» – диделәр. Ул бөтен яшь йөрәге белән җилкенеп оча да башлаган иде. Кинәт исерек җыр ишетелде. Газинурның өстенә салкын су сипкәндәй булдылар, ул сискәнеп туктап калды, янындагы иптәшләреннән:

– Нинди ишәк болай акыра? – дип сорады.

– Мишка Карабаш, – дип җавап бирделәр аңа. – Байрак тәтемәгәнгә хәтере калган, ди.

Газинур бу кешене бик аз белә иде. Карабаш икенче участокта эшли, ерак баракта тора. Эш вакытында бөтенләй диярлек очрашырга туры килми. Җыелышта аның турында ипле сүз әйтмәделәр. Дөрес, элегрәк аны ударник дип йөриләр иде. Бер тапкыр стена газетасында да мактап яздылар. Соңыннан леспромхозда шундый хәбәр таралды: Мишка Карабаш өеннән телеграмма алган, имеш, әнисе үлем түшәгендә ята. Ул көннәрдә Мишка Карабаш чыннан да юкка чыгып торды. Яңадан леспромхозда күренә башлагач, хәл-әхвәл сорашучыларга:

– Әнине җирләдем, – дип кенә җавап бирә торган булды.

Шул вакыйгадан соң Мишка нигәдер лаякыл исерек йөри башлады. Күпләр, аны кызганып: «Акыллы гына егет иде, кайгыдан харап була», – дип борчылдылар. Үгетләп, оялтып карадылар. Аннары шелтәләп тә бактылар. Берсенең дә файдасы булмады. Карабаш һаман эчә бирде.

Бүген дә эчкән. Әнә ул үзе кебек берничә исерекбаш белән чаттан килеп тә чыкты. Сөзәргә әзерләнгән үгез шикелле, башын бөгеп алпан-тилпән атлый-атлый, Газинурлар төркеменә якынлашты да, биш адым кала туктап:

– Бушуевчылармы? – дип мыгырданып куйды, ирен почмакларын кыйшайтып, мыскыллы бер аваз чыгарды: – Хе!

Бушуев егетләреннән берсе түзмәде:

– Азрак салдыңмы әллә? – дип чәнчеп куйды.

Карабаш, аңа арты белән борылып, үз әшнәләренә өндәште:

– Карагыз, байрак йөртүчеләр, – диде һәм бормаландырып сүгенергә тотынды. – Чүпрәк алганнар да, фәләнтөгән, түбәләре күккә тигән. Ә безгә чүпрәк нәрсәгә? Безгә премиясе булсын! Акчасы. Шулаймы?

– Шулай булмыйча! – дип, тиз генә эләктереп алды Газинур. – Песинең буе җитмәгәч, ит сөрсегән, ди.

Бушуевчылар, кычкырып көлә-көлә, үз юлларына китеп бардылар. Мишка Карабаш, йодрыгы белән янап, юл уртасында сүгенеп калды.

Берничә көннән соң Володя Бушуевны, дядя Митрофанны һәм тагын берничә кешене шәһәргә, стахановчылар киңәшмәсенә җибәрделәр. Алар арасында Газинур да бар иде.

Китүчеләрне озатырга Гарәфи абзый белән Һашим да килде. Сәлим нигәдер күренмәде.

– Хәзер син, Газинур, дәрәҗәле кеше, – диде Гарәфи абзый, аңа хәерле юл теләп. – Халык арасында үзеңнең бәяңне төшермә. Сөйләгәннәрне әйбәтләп тыңла, кайткач, безгә дә җиткерерсең.

– Газзән абыйны очратсаң, сәлам әйт, – дип өстәде Һашим.

Газинур әле һаман да үзенең бәхетенә ышанып җитә алмый иде. Әйтүе генә җиңел бит, ул Володя Бушуевлар белән бергә, леспромхозның иң яхшы эшчеләренең берсе булып, киңәшмәгә бара. Юк, бу, мөгаен, бик матур бер төштер, менә ул уяныр да, барысы да бетәр. Ләкин башкалар белән бергә Павел Иванович та Газинурның кулын кыса, үзе елмаеп сорый:

– Йә, ничек, иптәш Гафиятуллин, шатмы?

Шәһәргә алар кич белән килеп җиттеләр. Поездда төшүгә, аларны машина көтеп тора иде инде. Шау-гөр килеп утырдылар да, Газинур якыннан әле моңарчы күрмәгән, ике ягында биек-биек таш йортлар тезелгән урамнар буйлап киттеләр. Күперләр, чатлар, мәйданнар, бакчалар артта калды.

– Ай-һай, мондагы ташпулатлар, – диде Газинур, йортларның зурлыгына гаҗәпләнеп. – Берсенә бер колхоз кереп утырыр.

Аларны шәһәрнең иң яхшы гостиницасына урнаштырдылар. Келәмнәр, ямь-яшел гөлләр, рәсемнәр, картиналар белән бизәлгән киң, якты баскычлар буенча өскә – бишенче катка күтәрелделәр. Яшь кенә бер кыз бүлмәне ачып бирде.

– Рәхим итегез, иптәшләр, – диде.

Газинур зур тәрәзә янына килде. Бер кулы белән шторны күтәреп, урамга карый башлады. Аның каршында, электр утларына чумып, төнге шәһәр җәелеп ята иде. «Ут диңгезе икән биредә, төнлә инә табарлык», – дип уйлап алды ул. Вакыт соң булуга карамастан, киң мәйдан аркылы бертуктаусыз диярлек машиналар, кешеләр узып торалар. Газинурның машиналарга да, кешеләргә дә мондый биек урыннан һичкайчан карап торганы юк иде. Мәзәгрәк икән. Бигрәк тә кешеләрнең аяк атлаулары.

Газинур үзенең көтү көткәндә биек усак башына менгән чагын исенә төшерде һәм ихтыярсыздан көлемсерәп куйды: «Күтәрелә бит Газинур абзагыз!»

Киңәшмә икенче көнне иртән башланды. Алар бөтен төркемнәре белән залга керделәр. Халык бик күп иде. Залы да урмандагы клуб хәтле генә түгел – мең кеше сыярлык!

Володя Бушуевны башкалар белән бергә президиумга сайладылар.

Газинур докладчыны бер сүзен дә ычкындырмыйча тыңларга тырышты. Ләкин докладчы урман эшенең киләчәге турында сөйләгәндә, Газинур шулхәтле хыялланып китте, зал тып-тын утырганда, берүзе кинәттән кул чаба башлады. Кайберәүләр аңа кырын карап алдылар, әмма күпчелек аңа иярде, берничә секундтан шундый көчле алкышлар давылы күтәрелде, Газинур инде беренче булып үзе кул чаба башлавына да ышанмый иде.

Тәнәфестән соң, атаклы стахановчылар берәм-берәм трибунага чыгып сөйли башлагач, Газинур тагын тып-тын калды. Аларның сүзләрендә Газинур өчен шулхәтле күп яңа нәрсә бар иде, ул аларны барысын да хәтерли алмам дип борчылып та куйды, Газинур бу киңәшмәдән кайткач үзенең һәм иптәшләренең эшенә бөтенләй башкача караячагын төшенде.

Төнлә, сиртмәле кроватьта, ак җәймәләр эчендә рәхәтләнеп ял иткәндә, ул Газзәнне исенә төшерде. Кайда икән ул? «Бәхетен» таптымы икән? «Юләр син, Газзән абый, безнең заманда бәхет эзләп чапмыйлар, тырышып эшләсәң, бәхет үзе синең янга килә».

Леспромхозга алар дүртенче көнне кайттылар. Газинур, юл киемен дә алмаштырмыйча, Карп Васильевич янына йөгерде.

– Йә, кайттыңмы, стахановчы? – дип, көләч йөз белән каршы алды аны карт урманчы.

– Кайттым, кайттым, Карп Васильевич. Иллә әйбәт булды да!

Алар өелеп бетмәгән штабель өстенә менеп утырдылар, Газинур үзенең күргәннәре-ишеткәннәре турында җанланып сөйләргә кереште.

## 17

Кадерле Миңнурыена җибәргән кош теледәй хатларында: «Договор срогын тутырам да бер көн тормый «Красногвардеец»ка кайтам», – дип яза иде Газинур. Ләкин ел үтте, Гарәфи абзый, Һашим һәм Сәлим кайтып киттеләр, ә үзенең колхозына, сөйгәненә бөтен җаны-тәне белән ашкынган Газинур һаман леспромхозда калды. Баштарак отпускка кайтам дип йөргән иде, соңыннан

ялын да биредә генә үткәрде. Әллә кай арада гына җәй үтеп, көз килеп җитте.

Беренче вакытларда китми торуының ачык сәбәбе дә бар иде – Карп Васильевич авырды.

Ләкин карт сәламәтләнгәч тә, сәбәпләр табылып торды. Рус телен яхшырак үзләштерергә, берәр һөнәргә өйрәнергә кирәк иде. Җәй көне Газинур слесарьлар, шоферлар, электриклар янында чыннан да күп чуалды. Шуның белән бергә Мисбахның киткән чакта әйткән сүзләре дә исеннән чыкмады: синең өйләнәсең бар бит, расход булачак. Әйе шул, өс-башыңны да әзрәк шомартмый ярамый. Миңнурыйга да тегесен-монысын алырга кирәк. Гомергә бер генә була торган яшьлек туен башкаларныкыннан ким итеп, йөзгә кызыллык китермәссең бит. Дөрес, мондый чакта, күңел киң, кесә тар, дип әйтәләр. Кыш буе туплаган маяның җитмәве дә мөмкин. Һашим белән Сәлим җитмәгәнен этиләреннән ала алалар, ә Газинурның андый таянычы юк, ул үзе этисенә кулыннан килгәнчә ярдәм итеп торырга тиеш. Димәк, бөтен мәшәкать аның үз башында.

Әйе, болар барысы да шулай, барысы да дөрес. Ләкин шулай булса да Газинурның леспромхозда тоткарлануының төп сәбәбе шушы гына түгел иде. Сагынулары никадәр генә көчле булмасын, Газинур хәзергә моннан китә алмавын аңлый иде. Күзгә күренми торган ниндидер бик нык җепләр аны леспромхозга бәйләп өлгергән иде инде. Ул леспромхоз өчен вөҗданы каршында җаваплы булганлыгын тою дәрәҗәсенә иреште. Ләкин йөрәкне авызлыклап кую да бик кыен иде. Аңа йозак салмассың бит, күкрәгеңнән суырып алып та ташламассың.

Хәзер инде Газинурның сагынулары бермә-бер артты: ул Миңнурыйны да, иптәшләрен дә сагына. Буш вакытларында бараклардан ераккарак китеп, көзнең салкын, зәңгәр күгеннән тезелешеп очкан кыр казларының моңлы тавышларын сәгатьләр буе ямансылап тыңлап утыра, яки кайда булса әкрен генә гөжләгән биек наратларның төбенә чалкан ятып, яки тынып-томрап аккан Каманың биек ярына басып, әкрен генә җырлап җибәрә торган булды:

> ...Сагынасыңмы дип сорыйсың,
> Сагынмаган кая ул.

Ул кайтыр көннәрен саный, бу газаплы көннәрнең кими баруына баладай шатлана иде. Тиздән, тиздән үзенең гөләп чәчәген, Миңнурыен күрәчәк, аның белән бергә булачак, күзләренә караячак. «Синең күзләр төпсез диң-

гез...» дип, әкрен генә җырлар ул аңа. Миңнурый, озын керфекләрен сирпеп карый-карый, назланып көләр...

Кайчагында Газинур Сәлимне исенә төшерә: егет күптән инде колхозда. Газинурның юклыгыннан файдаланып, Миңнурыйга сумала кебек ябышмыймы икән ул аяклы хәсрәт анда? Һәм көнчелек, әрсез тычкан кебек, Газинурның йөрәген кимерә башлый, аның өйгә кайту теләген тагын да көчәйтеп җибәрә. Мондый вакытларда ул хәтта ыңгырашып та куйгалый иде.

Беркөнне баракка партоешма секретаре Павел Иванович Иванов килеп керде. Аның башында киң кырлы эшләпә, өстендә җиңел соры плащ, аягында сазлыкларда киеп йөри торган озын кунычлы күн итек иде. Күрәсең, ул ерак участокларны әйләнеп кайта.

Павел Иванович эшләпәсе белән плащын салып ишек кырыендагы чөйгә элде дә өстәл янына килеп утырды.

Бу озын буйлы, такыр башлы, алтын күзлекле кешене җыелышларда, урман участокларында, баракларда көн саен күрергә күнеккән Газинур аңа бөтенләй диярлек ияләшеп беткән иде. Павел Иванович үзенең тышкы кыяфәте белән бөтенләй башка кеше булса да, аның акыллы күз карашында, кешегә булган җылы мөнәсәбәтендә, гадилегендә, Газинурның беренче әйдәүчесе, беренче укытучысы Гали абзыйга охшаган сыйфатлары күп иде. Газинур моны Павел Ивановичны һәр күргән саен сизә дә, ә хәзер икәүдән-икәү утырганда, моны аерата ачык күрде.

Газинурның чәе кайнаган иде. Ул өстәлгә ике стакан, ак күмәч, шикәр куйды да чәйнеген алып килде. Газинур шул «хатын-кыз эшләрен» башкарганда, Павел Иванович аны күзәтеп торды.

– Йә, Газинур, колхозга кайтабызмы? – диде Павел Иванович, балкашыгы белән үтә куе чәйне болгатып. Ул Газинурның өстәмә договор срогы да тулып килгәнлеген белә иде.

– Кайтасы килә, Павел Иванович, – диде Газинур. Аның тавышында тирән сагыну яңгырады. – Хәзер безнең колхозның эшләре бетеп килә инде. Озакламыйча анда туйлар башлана. Кайчакта берьюлы икешәр-өчәр туй була, бөтен колхоз бәйрәм итә. Ә яшь егетләр, яшь кызлар мондый чакларда чистый акылдан язалар...

– Синең анда кемнәрең бар? Хатының юк бугай?

– Әти карт бар, аннары...

– Сөйгән кызыңмы?

– Әйе, – диде Газинур, аның сөйкемле йөзе җиңелчә кызарды.

– Туйга көтәме? – Павел Иванович, стаканын иреннә-

ре янына күтәреп, Газинурга көлемсерәп карады. Газинур да елмайды.

– Алай ук өздереп сөйләшмәгән идек сөйләшүен дә, эшләр шуңа таба бара иде.

Парторг бер минут чамасы эндәшми торды. Кайчандыр ул да Газинур кебек янып торган яшь егет иде. Ул да үзенең сөйгән кызына өйләнергә җыена иде. Ул чакта Павка Иванов Урал елгалары буенда этисе белән бергә такта ярып йөри иде. Иртәгә туй дигәндә, жандармнар аны кулга алдылар, шуннан соң ул үзенең сөйгән Катюшасын яңадан беркайчан да күрә алмады. Ул, Павел Ивановичны эзләп, ерак Себергә киткән һәм кайдадыр очсыз-кырыйсыз Себер тайгасында аның эзләре мәңгегә күмелгән. Хәзер менә Павел Ивановичның чәчләренә чал төшкән, күз төпләре вак-вак җыерчыклар белән капланган, ә ул көннәрнең кайгысы һаман онытылмый...

Павел Иванович ун еллап вакыт үткәннән соң гына өйләнде. Аннары балалар туа башлады. Башта малай булды, аннары кыз бала. Кызына Павел Иванович үзенең беренче сөйгәненең исемен куштырды. Хатыны моңа каршы килмәде, ул бары тик, минем кызым да шундый саф йөрәкле булып үссен, диде.

1922 елда Гражданнар сугышыннан әйләнеп кайткач, Павел Иванович үзенең башына яңа зур хәсрәт төшкәнлеген белде: улы белән хатыны һәлак булганнар. Кечкенә Катюшаны балалар йортына биргәннәр. Ул аны бик озак эзләгәннән соң Уралдагы балалар йортларының берсеннән табып алды. Шуннан бирле алар гел бергә яшиләр иде.

Газинур, әлбәттә, бу турыда бернәрсә дә белми иде. Ул, парторгның чал төшкән чәченә, елмайган чагында чигәләрендә җыела торган вак җыерчыкларга карый-карый, бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлый иде.

– Ничек әйтәләр әле, Газинур, – диде Павел Иванович, егеткә бер җылы караш ташлап, – туй бәйрәмнәрнең бәйрәме диләрме әле?

– Белмим, Павел Иванович. Андый хикмәтле сүзне ишеткәнем юк.

– Алайса, китаптан укыганмындыр.

– Китапта булыр. Китапта һәрвакыт матур итеп язалар. Шаккатасың.

– Ә син, Газинур, китаплар укыйсыңмы?

Газинур комач кебек кызарды.

– Мин, Павел Иванович, күбрәк тыңлыйм, – диде ул оялып кына. – Кайчакта берәр калын китапны алып, шартлатып укып чыгасы килә дә, чабу җибәрми, грамота

аз. Юкаракларын аз-маз сукалый башладым. Ләкин анысы да кыен.

– Башта һәрнәрсә кыен була ул, Газинур, аннары күнегәсең.

Китаплар турында сөйләшә торгач, леспромхоз эшләренә күчтеләр. Павел Иванович алар әзерли торган агачларның кайларга китүе, агачның халык хуҗалыгында нинди урын тотуы турында сөйләде. Агачтан башка бер генә производство да эшли алмый икән.

– Без алга барган саен, – диде Павел Иванович, сүзен ашыкмыйча гына дәвам иттереп, – агач безгә күбрәк кирәк. Урманнар безнең илдә җитәрлек, ә менә белгечләр аз. Кыш көне бездә, үзең беләсең, сезон, җиң сызганып эшләр чак, ә без кешеләрне эшкә өйрәтеп вакыт үткәрәбез. Ел саен өйрәтәбез, ел саен өйрәткән берсе китеп тора. Сезончылык тез аска суга безнең, Газинур.

Газинур парторгның нәрсәгә ымлавын бик тиз сизенде, күңелсез генә елмаеп, җилкә чокырын кашып алды. Егетнең бу елмаюы, күңелендә туган көрәшне капларга тырышып, малайларча беркатлылык белән җилкә чокырын кашып алуы парторгка аның йөрәгендә нәрсәләр ташуы турында бик ачык сөйлиләр иде.

Газинур, йөзе кызара баруын сизеп:

– Мин уйлап карыйм әле, Павел Иванович, – дип мыгырданып куйды.

Парторг, аның хәленә кергәндәй:

– Уйла, Газинур, уйла, – диде. – Кыен мәсьәлә бирдем мин сиңа. Бу сөйләшүне соңыннан да күп тапкырлар исеңә төшерерсең. Туйдан башлады, тукмак белән бетерде, диярсең...

Беркөнне иртә белән Карп Васильевич Газинурны Мишка Карабаш бригадасына җибәрде.

Карабаш бригадасы иң ерак участокта эшли иде. Газинур анда барып җиткәнче, шактый вакыт үтте. Урман тын. Пычкы тавышлары да, агачларның гөрселдәп авулары да ишетелми. Газинур борчыла башлады. Бу ни бу? Әллә ялгыш икенче юлга кереп киттеме? Ләкин киң аланга чыккач, Газинур урман кисүчеләрнең аударылган агачлар өстенә утырышып тәмәке тартуларын күрде. Тәмәке төтеннәре нечкә зәңгәр җепләр булып әкрен генә һавага күтәрелә иде.

Якынрак килеп, утыручылар арасында Павел Ивановичны да күргәч, Газинур тагын да гаҗәпләнә төште. Парторгның йөзе ачулы. Мишка Карабаш һәм аның егетләре аска карап утыралар. Күрәсең, Газинур килер ал-

дыннан парторг белән карабашчылар арасында шактый кызу сүз булган.

Газинур сәлам бирде, ләкин аның сәламен алучы булмады.

Парторг кыю бер хәрәкәт белән урыныннан торды.

– Менә шулай, Карабаш, әгәр сез намуслы кеше булсагыз, суган сатып утырмагыз! Хәзер үк эшкә керешегез.

Карабаш бер читтәрәк яңа киселгән агач төбендә бөкрәеп утыра һәм мүкләнеп беткән ташка охшый иде. Кара чәче бүреге астыннан тузгып чыккан, күзләре тычканныкы кебек йөгерешеп торалар.

Павел Ивановичның сүзләрен ишеткәч, Карабаш селкенеп куйды, ләкин урыныннан кузгалмады.

– Сез, иптәш парторг, минем намусыма тими торыгыз, – диде ул, һаман аска караган килеш. – Мин, бәлкем, дөньяда иң намуслы кешемендер...

– Арттан санаганда...

Кемдер әкрен генә көлеп куйды, ләкин Карабашның авыр карашы астында шунда ук тынып та калды.

Павел Иванович, егетләргә карап:

– Ә сез, геройлар, нишләмәкче буласыз? – дип көлемсерәде. – Әллә сез дә кичкә кадәр учак янында җылынырга уйлыйсызмы? Бәлки, ботка да пешерә башларсыз?

Моңа да җавап бирүче булмады. Мишка Карабашның ачулы карашы бүрәнәгә чапкан үткен балтага тукталды. Аннары аның кан баскан күзләре парторгка текәлделәр.

Парторг кулына пычкы алды.

– Йә, кайсыгыз минем белән, – диде ул кыю гына. – Кемнең егәрлеге бетмәгән әле?

Газинур беренче булып кузгалмакчы иде дә, тыелып калды: ул урман кисүче түгел, белмәгән көйгә тыгылып, парторгны оятка калдыруы мөмкин.

Бая бригадирдан көлә башлаган яшь егет кинәт сикереп торды.

– Әйдәгез, егетләр, кәнительне бетерергә вакыт, – диде ул һәм, кулы белән иптәшләрен чакырып, кар ера-ера парторг белән янәшә атлады.

Алар артыннан башкалар да берәм-берәм кузгалдылар. Мишка Карабаш берүзе калды. Җыерылып төшкән кашлары астыннан ул аланда кайный башлаган эшне, киселгән наратларның гөрселдәп авуларын, ап-ак кар фонтаннарының югары күтәрелеп әкрен генә иңүләрен шактый озак күзәтте.

Газинур аңа карап торды-торды да, түзә алмыйча:

– Үрдәк бәбкәләре чыгарган тавык кебек яр буенда берүзең утырып калдың бит, абзый, – диде.

– Цыц! – дип акырды Карабаш.

Бер сәгать чамасы вакыт үткәч, Павел Иванович кайтып китте. Мишка Карабаш, аны туктатып:

– Шулай итеп, мине бөтен халык алдында хур итәргә булдыгызмы, парторг? – дип, сүзләрен теш арасыннан сыгып сорады.

– Сез үзегезне-үзегез хур итәсез, Карабаш. Күрәсезме, бригадагыз нинди әйбәт эшли?

Карабаш үзенекен алга сөрде.

– Миңа нишләргә кушасыз инде хәзер?

– Сезгәме? Күңелегез теләгәнчә агач төбенә утырып торырга, – дип көлемсерәде Павел Иванович. – Ә кич белән конторага керерсез. Артык сөйләшеп торуның кирәге юк. Барысы да ачык.

Көн урталарында каты буран күтәрелде. Урман мең төрле аваз чыгарып шаулый башлады, һава бик тиз караңгыланды. Барлык бригадалар да диярлек эшләрен туктатып, кайтып китәргә мәҗбүр булдылар.

Газинур баракка тәмам туңып, карга батып кайтып керде. Өс киемен чишенгәннән соң, дөрләп янган мич каршына килеп, җылынырга тотынды. Бераз хәл алгач, Карабаш бригадасында булган хәлләр турында сөйләргә кереште.

– Карабашка исең киткән! – дип бүлдерде аны олырак яшьләрдәге бер урман кисүче. – Безнең парторг эрерәк җәнлекне дә бәреп еккан кеше. – Һәм ул Гражданнар сугышы вакытында Ерак Көнчыгышта хәрәкәт иткән Павел Иванович отряды үзеннән ике өлеш артык булган япон гарнизонын ничек юк иткәнлеге, ә самурай полковнигын плен алганлыгы турында сөйләп бирде.

– Анысы шулаен шулай да, – дип, икенче бер урман кисүче сүзгә кушылды. – Карабашка җиңел карарга ярамый. Карабаш коточкыч кеше ул. Ул моны болай гына калдырмас. Баягынак миңа очраган иде, лаякыл исерек, ә тун астына балта яшергән.

Шулчак ишек ачылып китте, һәм баракка кулына Павел Ивановичның хәлсез гәүдәсен күтәргән дядя Митрофан килеп керде. Авыр-авыр атлап, баракның аргы башына узды да парторгны үзенең койкасына салды.

– Чиста сөлге...

– Кайсы дошман...

– Мишка Карабаш эше, – диде ишектән килеп кергән бер егет. – Ярый әле дядя Митрофан килеп өлгерде. Югыйсә...

Митрофан карт Газинурның кулыннан чиста сөлгене тартып алды да:

– Катяга йөгер. Күз ачып-йомганчы барып җит, – диде.

Газинур, башына бүреген дә кимичә, барактан йөгереп чыкты. Ул, чәнечкеле буранны да, көйдергеч салкынны да сизмичә, бөтен көченә йөгерде.

Яланбаш, агарынган йөзле Газинурны ишек төбендә күргәч тә, Катя куркып артка чигенде.

– Ни булды, Газинур? – дип, көч-хәл белән сорады ул.

– Бәла... Киенегез!

– Володяга бер-бер хәл булдымы әллә?

Газинур башын чайкады.

– Әтигәме? – дип, тагын әкренрәк тавыш белән сорады Катя.

Газинур башын түбән иде.

Мишка Карабашны шул ук көнне кулга алдылар. Тикшерү аның урман заводы хуҗасы малае икәнлеген, ялган исем белән йөрүен, ике тапкыр хөкемнән качканлыгын билгеләде. Әнисенең ялган авыруы турындагы телеграмма чынлыкта әтисенең кулга алынуын хәбәр иткән. Әтисенең яшерелгән алтыннары һәм башка күп кенә кыйммәтле әйберләре булган. Бу турыда әтисе белән Мишка гына белгәннәр. Менә шул алтыннар инде Мишка Карабашны акылдан яздырып йөрткән. Алтыннарны кулга төшерү өчен ул хәтта әтисен үтерергә дә маташкан. Ләкин карт көчле булган әле, бирешмәгән, ул үзе улын буып үтерә язган. Шуннан соң Мишка яхшы кеше исемен алырга тырышып йөри башлаган. «Рәтле кәгазьләр кулга төшерергә кирәк, – дип уйлаган ул. – Ударник грамотасы кулда булса, аннары эшнең җайлысын үзем дә табар идем. Ә эти дөмеккәч, алтыннарны сыпырам да заграницага таям».

Телеграмманы алгач, Мишка әтисе өчен түгел, алтыннар өчен курыккан. Әтисенең холкын яхшы белгәнгә, ул бик пошынган. Поездда өенә кайткан чагында, ул өч тәүлек буена авызына бер валчык аш капмаган, бер тамчы су эчмәгән, йокламаган, ябыгып беткән. Әтисенең бусагасыннан кергәндә, аның чырае төн кебек караңгы, үзе ерткыч кебек зәһәр булган. «Кичеккәнлеген» белгәч, Карабаш аю кебек үкереп җибәргән, беркем белән дә саубуллашмыйча, шул ук төндә китеп тә барган. Леспромхозга кайткач, ул эчә башлаган. Бетте баш, бетте дөнья, дигән...

Мишка Карабашның тарихы телләрдән телләргә күчеп, Газинурга да килеп җиткәч, ул гаҗәпләнүдән битәр ничектер үзенә карата да, башкаларга карата да таләпчәнрәк булып китте. «Дөнья бу, колакларны йомып йөргәнне яратмый. Бүре юк димә бүрек астында...» Шунда ук

парторг белән сөйләшүе исенә төште. Әле бүгенгә кадәр Павел Ивановичка җавап биргәне юк бит аның.

Кич белән Газинур парторгның квартирасына китте, Павел Иванович больницада ике атна чамасы яткач, яңадан леспромхозга кайткан, ләкин эшкә чыкканы юк иде әле.

Катя белән Павел Иванович чәй эчеп утыралар иде. Газинурны да табынга чакырдылар. Ул, парторгның башына уралган ак марлядан күзен алмыйча, өстәл янына килеп утырды. Ләкин ни дип сүз башларга да белмичә аптырап калды. Әмма Павел Ивановичның кәефе күтәренке иде. Катя да көләч. Газинур җиңел сулап куйды. Павел Ивановичның эш, укулар, колхоз хәлләре турындагы сорауларына уйнап-көлеп җавап бирә башлады.

– Әти, син аңардан сөйгән кызының кушаматларын сора әле, – дип, Катя утка май өстәде.

– Йә, йә, Газинур. Әйт әле. Тыңлыйк.

– Бездә, Павел Иванович, кушамат таксалар – гомерлеккә.

Миңнурыйның кушаматларын белгәч, Павел Иванович рәхәтләнеп көлде. Дөрес, ул башта ук Газинурның ниндидер җитди бер йомыш белән килүен сизенде сизенүен, ләкин сораулар биреп ашыктырмады. Ниһаять, Газинур үзе сүз башлады;

– Павел Иванович, – диде ул, бик җитди итеп, – барактагы сөйләшүебезне онытмадыгызмы әле?

– Юк, онытмадым, Газинур.

– Мин бит сезнең тәкъдимгә берничек тә җавап биргәнем юк әле. Бу көннәрдә бик күп уйландым... Тагын бер сезонга калырга булдым. Колхоз каршы килмәс дип уйлыйм...

– Ә туй? – дип бүлдерде Катя.

– Туй качмас, Катя Павловна. Чәчләр бәйләнгән булса, арадан җил дә үтмәс.

– Нәрсә дип әйтим сиңа, Газинур, – диде Павел Иванович, – дөрес уйлагансың, карарың дөрес. Беләм, бу уйга килү сиңа җиңел булмагандыр, ләкин... гомуми эш өчен үзеңнең шәхси омтылышыңны кирәк чакта җиңәргә өйрән.

Газинур бик тирән сулап куйды, әйтерсең ниндидер бик зур киртә аркылы атлап чыкты ул.

...Бу кыш ничектер бик тиз үтеп китте. Беркөнне шома саплы тамгасын бил каешына, ялтырап торган җыелма метрын күкрәк кесәсенә кыстырып, киселгән делянка буйлап барганда, Газинур әле яңа гына кардан ачылган

агач төбендә шәмәхә төсендәге нечкә умырзая чәчәген күреп туктады да иелеп өзеп алды.

– Малай, яз җиткән бит! – диде ул һәм тирә-ягына гаҗәпләнгән сыман карады.

Моннан әле берничә генә атна элек бу урында мәһабәт наратлар белән аралашып, өрәңгеләр, ак чыршылар шаулап үсеп утыра иде. Аннары бирегә үзенең моторлы пычкысы белән Володя Бушуев һәм аның иптәшләре килде... Хәзер монда яңадан тирән тынлык. Урман кисүчеләр моннан ерак киткәннәр. Агачлар булмагач, бу урында кар да тизрәк эрегән, кар китәр-китмәс беренче яз чәчәге – умырзая баш күтәргән.

Газинур, башын артка ташлап, күккә карады. Күк йөзе чиста, зәңгәр һәм Миңнурыйның бәйрәм косынкасы кебек җиңел иде. Газинурның кызу эш эчендә онытылып торган сагынулары тагын кузгалды. Ул яңадан умырзаяга карап:

– Малай, яз җиткән бит! – дип куйды.

Нәкъ шул чакта Павел Иванович килеп чыкты. Ул кулына умырзая чәчәге тотып исәпкә калган Газинурны ерактан ук күрде. Хәзер ничектер хәйләле дә, шаян да, мөлаем да елмаеп аңа якынлаша иде.

– Нихәл, Газинур, – диде ул, – умырзая таптыңмы? Яз җитте диген!

– Яз җиткән шул, Павел Иванович, ә мин менә шуңа гаҗәпләнеп торам әле.

– Күңелләрең дә җилкенә башладымы?

Газинур Павел Ивановичның тел төбен аңлап җиткермәде. Ул аның көләч йөзенә, аннары пиджак кесәсеннән чыгып торган «Правда» газетасына күз төшереп алды да: «Бригадаларда беседа үткәреп кайта», – дип, үзенчә уйлап куйды.

– Йә, күңелләрең җилкенәме, юкмы? – дип кайтарып сорады ул, Газинурның кулындагы чәчәккә башы белән ымлап. – Мин менә урманда әллә ничә җирдә умырзая күрдем, берсен дә өзмәдем, син менә берне күргәнсең, аны да өзгәнсең. Володя Бушуев синнән дә уздырып җибәргән – берүзе бер бәйләм җыйган.

Кинәт Газинур елмаеп куйды.

– Сез, Павел Иванович, безнең Хуҗа Насретдинчәрәк, ерактан урап әйтәсез икән. Берьюлы абайлый да алмадым.

Павел Иванович, бераз уйлап торгач:

– Әйе, Газинур, яз килде, – диде. – Сиңа да кайтырга вакыт. Югыйсә Миңнурыең көтә-көтә саргаеп беткәндер. Аны артык саргайтырга ярамас. Хәзер урманда эшнең азрак чагы. Бар, кайтып туй яса да, кышка, теләсәгез,

парлашып килегез. Икегезгә дә эш җитәчәк, – ул Газинурның нык иңбашына кулын салды. – Алтын чагың синең, Газинур. Анда сине ничек көткәнлекләрен мин бик яхшы күз алдыма китерәм. Ашык, дустым, яшьлек ике килми.

Шул көннән Газинур юлга әзерләнә башлады.

## 18

«Красногвардеец»ка Газинур көн урталарында кайтып төште. Май ае иде. «Алга» юлы буендагы тау башыннан үзәнлектә бик җайлы гына урнашкан колхозын күргәч, Газинур арбадан сикереп төште дә тау түбәсендә, җил двигателе янында туктап басып калды. Ул бер колхозына, бер двигательнең челтәрле башнясына, көмеш сыман канатларына карап ала. Анда, шәһәрләрдә генә түгел, ерак-ерак колхозларда да, «индустрия» чәчәк ата. Ул киткәндә, бу көмеш канатлы двигатель хыял гына иде бит!

Озак вакытлар читтә йөреп кайткан кешегә үз авылы гадәттә кечерәйгән, искергән, фәкыйрьләнгән күк тоела. Ул үзенең хыялында матурлап-пөхтәләп йөрткән авылын танымыйча, берничә минут аптыраштa калып тора. Ике елдан артык читтә йөреп кайткан Газинур да, үз колхозын беренче күргәч, гаҗәпләнеп куйды. Ләкин аның гаҗәпләнүе бөтенләй башка иде. Ул киткәндә шәп-шәрә диярлек булган йорт тирәләре хәзер инде яшеллеккә күмелеп баралар. Ихаталы бакчаларда тырыш куллар үстергән шомырт, чияләр, алмагачлар шау чәчәктә утыра. Бөтен үзәнлектән, бөркелеп-бөркелеп, тәмле чәчәк исләре килә.

Газинур, башын артка ташлап, мәһабәт двигательгә тагын бер мәртәбә карап ала, аннары аның сөенеч белән тулы күзләре инде салынып беткән май заводының яңа бинасына текәлә, яңа сыер абзарлары, терлек каралтылары буеннан йөгереп үтә, аннан яңа амбарларга, тугым бөгү мастерскоена, аннары тагын да ераккарак омтылып, каршы яктагы тау башында олы кыя сыман торган ябык ындырга, аның янындагы тегермән бинасына, ул киткәндә салына гына башлаган амбарлар тирәсендәге әллә нихәтле бүтән биналарга барып тукталалар. Чү, кайдандыр Газинурга бик яхшы таныш булган озын-озын зырылдау тавышы ишетелә. Зырылдау бер нечкәргәндәй була, бер тагын да калыная төшә. Тукта, бу түгәрәк пычкы тавышы ич! Колхозда түгәрәк пычкы! Әллә үзләре такта да яралармы? Ул пычкыны нәрсә белән әйләндерәләр? Әллә движоклары да бармы? Бар шул, әнә аның үзенә бертөрле

калын тавышы яңгырый! Нигә, нигә соң бу турыда хатка язмаганнар иде?!

Газинур үз йортына карый. Туган йорты булмаса да, торган йорты. Аны да танырлык түгел. Аның каршында да бакча үскән, яфраклардан хәтта тәрәзәләр дә күренми.

Урам уртасында, яшь чирәмдә каз бәбкәләре йөри. Ак яулыгын артка кысып бәйләгән, ак алъяпкычлы бер кыз, сиртмәле коедан су ала-ала, правление ишеге төбенә баскан шундый ук ак алъяпкычлы, ак яулыклы икенче бер кызга кул болгый. Кемнәр икән? Правление ишеге төбендәгесе Әлфия түгелме икән?

Исаково очыннан, фаралары белән кояшта җемелдәп, йөк машинасы төшеп килә. Правление ишеге төбендәге кыз аңа таба борылып карый да ялт иттереп ишектән кереп югала. Газинур көлемсери, күзләре белән Миңнурыйның тәрәзәсен эзли башлый: әнә ул, ап-ак пәрдәсе һәрвакыттагыча төшерелгән.

Миңнурый, Миңнурый! Гөләп чәчәгем! Сизәсеңме, бәхетең нинди якын синең! Газинур түзми, киң күкрәге белән туган колхозының тәмле һавасын киерелеп сулый да ачык, күңелле тавыш белән җырлап җибәрә:

Өстемдәге күлмәгемнең
Якаларын кем уйган,
Исемең матур, кемнәр куйган,
Сине күреп кем туйган.

Һәм җырын бетерер-бетермәс, бөтен көче белән таудан түбәнгә омтылып, яшь колын кебек сикерә-сикерә авылга таба йөгерә башлый.

Алдан хәбәр итмәгәнгә, Газинурны өендә берәү дә көтми иде. Бөгелмәдән ул очраклы олауга утырып кайтты.

Газинур, җил капканы ачып, ишегалдына йөгереп килеп керде. Ишегалдының яртысын диярлек биләп алган бакчада әтисен күрде. Гафиятулла бабай, май ае булуга карамастан, башына колакчын бүреген, өстенә иске тужуркасын киеп, биленә алъяпкыч элгән, һәрвакыттагыча үзалдына сөйләнә-сөйләнә, тимер көрәк белән карлыган куаклары төпләрен йомшартып йөри.

Газинур, бер кулы белән читәнгә тотынып бөтен гәүдәсе белән алга омтылган килеш, берничә секунд урыныннан кузгала алмыйча әтисенә карап торды. Гомер буе кулы эштән бушамаган, ару-талуны белмәгән кадерле әтисенә карата аның күңелендә чиксез зур уллык мәхәббәте ташыды. Кинәт, нәкъ сабый чагындагыча:

– Әтием! – дип кычкырып җибәрде, күз ачып йомганчы тәбәнәк читән аша сикереп, әтисенә каршы йөгерде. Һич тә көтмәгәндә, уйламаганда улын күргән Гафиятулла бабайның кулыннан көрәге төшеп китте. Ул, бер сүз әйтә алмыйча, баскан урынында катты да калды. Нәрсәдер аның бугазыннан кыскандай булды, ул авызын ачты. Сирәк керфекләре еш-еш селкенделәр, тез буыннары калтырап китте.

– Газизнурым! – диде ул ахырда, калтыранган ике кулын алга сузып. – Улым, синме бу? Сине күрәмме, балакаем?!

Газинур аның кочагына ташланды, башын әтисенең күкрәгенә куйды. Әтисе аның маңгаеннан үпте, кабарып беткән зур кулы белән җиткән чәченнән сыйпады, үзе һаман бер үк сүзләрне кабатлады:

– Газизнурым... Сине дә күрер көннәрем бар икән! Газизнурым!

Газинурның энесе Халикъ өйдә пәке белән нидер юнып утыра иде. Ишектән килеп кергән абыйсын күргәч, урыннан сикереп торды да:

– Әни, абый кайткан! – дип кычкырып, Газинурның муенына килеп асылынды.

Кече казан яныннан, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, Шәмсинур җиңги аптырап килеп чыкты, ике кулын сузып, Газинур белән күреште.

Халикъны шунда ук Мисбахларга йөгерттеләр. Өйдә булсалар, парлап килсеннәр, дип әйттерделәр. Ул арада Газинурның кайтуын ишеткән күрше-күлән дә керә башлады. Иң элек Галәк бабай белән Сабир бабай килеп җиттеләр. Галәк бабай озын ак күлмәк өстеннән җиңсез казаки кигән, аягына каталар элгән, башында кырпулы бүрек. Ул һаман шундый ук, бер дә үзгәрмәгән төсле. Сабир бабай исә шактый бирешкән, сакал-мыегы тәмам агарган, гәүдәсе дә бөкрәя төшкән.

– Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр күрешә килер, – диде Галәк бабай, исәнлек-саулык сораша-сораша.

– Балакаем, наныем, исән-сау кайттыңмы? – дип, Сабир бабай да ике кулын сузды.

Картлар артыннан ук хатыны Мәйсәрә белән Мисбахетдин килеп җитте.

– Абый! – дип, Газинур Мисбахны кочаклап үпте. – Исән-сау тордыңмы? Мәйсәрә апа исәнме?

Мәйсәрә йөкле иде. Үзенең шундый хәленнән бераз уңайсызланып булса кирәк, кызарып куйды. Газинур аның тартынып кына сузган кулын кысты.

– Барыгыз да исән-саумы, Мәйсәрә апа, балалар?

Газинур «апа» дигәч, Мәйсәрә тагын да кызара төште, кыз чагында Газинур аңа исеме белән генә дәшә торган иде.

– Ул хәтле картайтмасаң да ярар инде, – диде ул, кече якка, Шәмсинур җиңги янына уза-уза.

Газинурның кайчан кайтасын белмәсәләр дә, көтеп торганнар икән. Шәмсинур җиңгинең атланмае, каймагы, юкә балы, каклаган ите, чәкчәге – барысы да табынга тезелде. Коймак та өлгерде. Газинур алып кайткан шәһәр күчтәнәчләрен дә табынга куйдылар. Гафиятулла бабай Шәмсинур җиңги белән пышылдап сөйләшкәннән соң, өстәлгә әчетелгән бал да килеп утырды. Галәк бабай белән Сабир бабай, бер-берсенә карашып, сакалларын сыпырып алдылар.

Чәй һәм бал эчә-эчә барысы да – картлары, яшьләре – астыртын гына Газинурга күз төшергәләп торды. Чын икән, йөргән таш шомара икән. Газинур моннан ике ел элек колхоздан киткәндәгечә түгел. Өс-баш та яхшы ук ыспайланган, урман һавасы да бик килешкән, ахрысы, яңаклары бодай кабартмасыдай күпереп, алсуланып тора. Ләкин Газинурның үзгәрүе киемендә, йөзендә генә түгел, аның үзгәрүе күз карашында да, сүзләрне ашыкмыйча, төпле итеп сөйләвендә дә (аңа шәһәр турында, эшләгән эше турында хәтсез күп сораулар яудырдылар, ул аларның берсен дә җавапсыз калдырмады), үз-үзен тотуында да сизелә иде.

– Яшь чагында дөнья күрү – ир егетнең бурычы, диләр иде борынгы картлар, – дип, Галәк бабай биш бармагына күтәргән тәлинкәсенә өф итеп өрә-өрә сөйләп китте. – Инде исән-сау кайтуыңа бик шөкер. Хәзер әти-әниең исән чагында үзеңне башлы-күзле иткәндә дә ярар иде, Газинур.

Сабир бабай да кордашының сүзләрен җөпләп торды. Янәсе, вакыт бик җиткән, яшьлекнең кадерен белергә кирәк, әгәр мәслихәт күрсәләр, ул үзе яучы булып барырга әзер.

Газинур бу сүзләре өчен картларга рәхмәт әйтеп тә, ачуланып та утырды. Миңнурыйны күрмичә торып бу турыда һич тә сөйләшәсе килми иде аның. Ул сүзне колхоз хәлләренә күчерергә теләде, ләкин, картлар алдында әдәп саклап, аларның сүзләрен бүлдермәде. Сөйләшә торгач, картлар үзләре үк колхоз хәлләренә күчтеләр.

Сабир бабай, Газинур алып кайткан күчтәнәчләрдән авыз итеп:

– Сагынгансың инде, Газинур, колхозыбызны, – дип әйтеп куйды. – Туган җирләр сагындыра ул. Мин шулай

Карпатта йөргәндә, шәрә муенлы бөркетләр генә куна торган таш өстенә утыра идем дә, күңелләр бик ямансылый башлагач, әкрен генә җырлап җибәрә торган идем.

– Туган җирдән туйган юк, кем, Сабир, – дип, Гафиятулла бабай үзенең Кавказда хезмәт итүләрен искә төшереп алды. Аннары кар түбәле Кавказ тауларыннан төшеп, яңадан «Красногвардеец»ка кайтты. – Колхозыбызның хәле, улым, – диде ул, кечкенә сакалын бармаклары белән аралаштыргалап, – ярыйсы, әйе. Язгы чәчүне алдарак тәгәлләдек. Апрельнең ничәнче числосында әле, картлар, чәчүгә төштек?.. Элекке заманда бу вакытта Ялачич бояры да кузгалмый иде әле.

Галәк бабай һаман да таза, тигез тешләре белән гәрәбәдәй конфетны тешләп чәен эчкәч:

– Уҗымнар да бик яхшы күтәрелеп килә, – диде. – Кичә генә Хәнәфи белән бөтен кырларны атта әйләнеп кайттык. Хәнәфигә дә әйттем, күз генә тимәсен, быел уҗымнар да, сабан ашлыгы да бик әйбәт өметләр тудыра, дидем. Яңгырлар да явып алды.

– Ветрянканы күргәнсеңдер инде, Газинур, – дип, Сабир бабай үз шатлыгын бүлешергә ашыкты. – Җилне таки эшкә җиктек бит. Кайчан телибез, шунда абзарларга су бирә. Элеккеге заманда мондый хәлләр әкиятләрдә генә булган. Терлекләрне сугара-сугара нихәтле җәфа чиккәнне син үзең дә онытмагансыңдыр әле. Ә хәзер берәр яшьрәк егетне тауга йөгертәм дә су дип кычкырам, шуннан улакларга көмештәй саф су чылтырап ага. Хайваннарның җаннары нихәтле тели, шулхәтле ага башлый.

– Үткән правлениедә электростанция салдыру турында сүз булган, – диде Гафиятулла бабай. – Гөлләр дә килеп киткән иде. Хәзер ул инде инженер, бик зур урында эшли.

Гөлләр турында ишеткәч, Газинур сөенеп куйды. Гөлләр аңа монтерлыкка өйрәнергә кушкан иде. Хәзер Газинур бу эш белән беркадәр таныш. Аның сандык төбендә инструментлары да бар. Колхозда электростанция генә салсыннар, ул һичшиксез анда күчәчәк.

– Сабирҗан тимерченең малае Сөләйман правлениедә радио ясаган, – дип өстәде Галәк бабай. – Кеше дигәннең акылы! Үз түреңдә утырып, мең чакрымнардагы кешенең тавышын ишетә...

Газинур сүз арасында Гали абзый турында сорап куйды, районда эшли икән. Сәламәтлеге яхшырган. Озакламыйча ялга кайтачак икән.

Бал Галәк бабайның башына шактый йөгерде, ахрысы. Аның сүз янчыгы бөтенләй чишелеп китте, берәүгә дә сөйләргә ирек бирми башлады.

– Газинур улым, урманда нинди җырлар җырлый идегез? – дип сорады. – Бер җырлап картларның күңелен күрмәссеңме?

Җыр дигәндә инде Газинурның капчыгы буш түгел. Рөхсәт сорагандай, әтисе белән абыйсына бер карап алды да җырлап та җибәрде.

Галәк бабай аны башын иеп тыңлап утырды да, Газинур җырлап бетергәч, әйтә куйды:

– Яңа җырлар икән. Без яшь чакларда андый җырлар юк иде. Безнең җырлар башка иде. Ишеткәнегез бармы лашманчылар турында? Күптән булган хәл инде ул. Петр патша заманында. Петр патша кораблар ясаткан, шуңа бөтен ил белән урман кискәннәр. Безнең бабайлар мари урманнарында лашман куганнар. Минем үземә дә Севастополь сугышы елларында лашманда булырга туры килде. Безнең заманда да ул бик авыр хезмәт иде, бабайлар заманында лашман эше каторгадан да авыррак булган. Әле дә оныта алмыйм аларның бер җырын...

Галәк бабай бераз уйланып торды да, күзләрен йомып, әкрен генә җырлап җибәрде:

Бәрәңге урманы агачы.
Тарталмыйлар лашман атлары,
Шул агачлар килеп төшкәч,
Юкка чыга адәм башлары.
Ступай, кычкыра
Имән кисмәгә,
Яна йөрәгем
Аракы эчмәгә.

Йөз яшьлек картның инде дерелдәп торган иреннәреннән чыккан бу халык хәсрәтенең ачы моңы табындашларга бик көчле тәэсир итте. Ә Галәк бабай, бераз тын торгач, шундый ук озын, моңлы көйгә икенче бер җырны башлады. Бу шул заманнарның бәете иде.

Саңгыз дигән урманда күп түгелде күз яшем,
Аккош очып җитмәс җирдә калды бәнем газиз башым.
Кара Ширмә буенда үрдәк йөрер тезелеп,
Лашманчылар кайтканнан соң, әнкәм йөрер тилмереп.

– Менә, Газинур улым, – диде Галәк бабай бераздан. – Элекке заманда халык нинди җырлар җырлаган. Яңа урманнарда син инде аларны ишетмәгәнсең. Менә мин сиңа карыйм да сөенәм. Синең җырың да, тормышың да башка. Кара, кадерен бел боларның, Газинур улым. Мин, карт юләр, кайчакта сез яшьләргә иске җырларны юри

җырлап куям. Бүгенге тормышларның кайдан килгәнен онытмагыз, дим.

Чәйләр, баллар эчелеп, юл чәенә килгән кунаклар рәхмәтләр әйтә-әйтә таралгач, Газинур правлениегә чапты. Ул ишекне ачып кергәндә, Әлфия берүзе счет төймәләре салып утыра иде.

– Әлфия, колхозның доходын миллионга җиткердеңме инде, – дип, Газинур өстәл янына атлады.

Әлфия, көтмәгәндә, үз алдында шәһәрчә киенгән Газинурны күргәч, шатланып кычкырып, урыныннан торды:

– Әнием, Газинур абый кайткан!

Газинур аның кулын ике кулы белән кысып селкәселкә:

– Менә, туеңа кайтып җитәрмен дип әйткән идем бит, кайттым. Йә, кайчан туең була, Әлфия? Үзең шундый чибәрләнгәнсең, күзем генә тимәсен.

– Китсәнә, Газинур абый, син һаман шундый ук шаян икәнсең әле.

– Әлфиянең туе булганга бишбылтыр инде, соңга калдың, егетем, – дип, икенче бүлмәдән кара мыегын борабора, Хәнәфи килеп чыкты. – Аның инде хәзер синең кебек егет малае бар. Саумы, Газинур?

Газинур, кызарып киткән Әлфиягә шаян караш ташлап, Хәнәфигә омтылды.

– Хәнәфи абый, саумы!

Алар кул кысышып күрештеләр, аннары Хәнәфи, Газинурның иңбашына кулын куеп:

– О-һо! Егеткә шәһәр икмәге килешкән икән, – диде.

– Урман һавасы диген, Хәнәфи абый, – дип төзәтте Газинур.

– Ярый, урман һавасы булсын. Әлфия, ничек, өйләндерергә ярыймы, юкмы егетне?

– Миңнурыйны суган кебек саргайтып бетерде инде.

– Синең кебек саргайган булса, бигайбә, Әлфия.

– Менә күрерсең әле, – диде Әлфия мәгънәле генә. – Чит җирләрдә бик күп йөрсәң...

– Һай, усаллангансың, Әлфия, болай усал түгел идең бит. Киявең кем? Йә, нигә аска карыйсың? Хәнәфи абый, күр, кияүгә чыгарга оялмаган, киявенең исемен әйтергә ояла.

– Ник оялыйм... Синең җан дустың инде...

– Карсак Һашиммы? Йә, ярый, ярый, Әлфия, кызарма, күгәрчен сөтеңне күбрәк әзерләп куй, кунакка килермен.

Бу көнне Газинур колхозның бөтен хуҗалыгын йөреп, карап чыкты, Һашимны, Сәлимне күрде, Газзән янына да кергән иде, өйдә туры китерә алмады. Шуннан туптуры Гарәфи абзыйларга юнәлде.

– Озакладың син, Газинур, – диде Гарәфи абзый, егетне баштанаяк карап чыккач. – Һашим кайтып чеби чыгарырга да өлгерде инде монда.

– Эшне ташлап китәсе килмәде, – диде Газинур төпле генә.

– Эш ул, Газинур, беркайчан да бетәсе түгел. Ничек соң? Без киткәч, күп үзгәрешләр булдымы? Павел Иванович, Бушуев, Карп Васильевичлар исән-сау калдылармы? Теге куян бүрекле кыз андамы әле?

Газинур Гарәфи абзыйга күзләрен кыса төшеп карады. Гарәфи абзыйның маңгай өстендәге чәче коелып беткән булса да, яңаклары күпереп тора.

– Һәммәсе исән-сау калдылар, сәлам әйттеләр. Бүтәннәре турында иркенләбрәк сөйләшеп утырырбыз әле, Гарәфи абзый. Аяк өстән генә сөйләп бетерерлек түгел.

Гарәфи абзый белән сөйләшкәннән соң, Газинур ындырга менде, аннары, председатель Хәнәфи белән бергә тарантаска утырып, басуга китте. Чаптар һаман шундый ук ут, элдереп алырга гына тора.

Караңгы төшкәндә, басудан әйләнеп кайттылар. Газинур хәзергә атлар тирәсендә эшләргә булды. Хәнәфи каршы килмәде.

– Эшлә, туган, югыйсә Сабир бабайга кыенга килгәли, – диде ул.

Газинур Сабир бабай янына ашыкты.

– Күрәм, йөрәгең элеккеге кебек үк тынгысыз икән, – диде себерке сабына таянган Сабир бабай.

– Бөкрене кабер генә төзәтә, – диде Газинур, көлеп. – Эх, беләмсең син, Сабир бабай, мин ничек сагындым колхозыбызны. Юк, моннан соң беркая да китмим!

– Ник алай? Начармы әллә анда?

Газинурның күзләрендә гаҗәпләнүгә охшаган бер нәрсә ялтырап китте.

– Минем алай дигәнем юк, Сабир бабай. Анда начар түгел, анда бик яхшы. Кешеләре дә бик әйбәт. Ләкин үз колхозыбызны шәһәр кебек итәргә кирәк. Электр станциясен салып җибәрү белән, күп нәрсә үзгәрәчәк. Мин электр эшенә бераз өйрәнеп кайттым.

– Анда һөнәр дә өйрәттеләрмени, Газинур?

– Өйрәттеләр... – Газинурның күз алдына аксыл бөдрә чәчле Володя Бушуев, моңсу күзле Катя, Карп Васильевич, партоешма секретаре Павел Иванович килеп бастылар. Ул стахановчылар киңәшмәсен хәтерләде һәм сулышын киң алып кабатлады: – Күп нәрсәгә өйрәттеләр. Хәзер безнең илебездә эш белмәгән кеше булмаска тиеш, Сабир бабай. Тормыш шулай куша, югыйсә сөяленә басам, ди.

– Һа, кара син аны, акыллы сүз бит бу, Газинур.

Газинур бөтен җирдә булды, бөтенесен күрде, тик Миңнурый янында гына булмады. Ләкин Миңнурый турында читләтеп кенә сүз чыкса да, аның колаклары үрә торды. Әлфиянең кинаяле сүзләреннән соң ул шунда ук Миңнурый янына кермәкче иде дә, имеш-мимешләргә юл куймас өчен, үзен тыйды. Ул Халикъны чакырып алды:

– Йә әле, әйтеп бир әле, разбойник, Миңнурый апаң ничек тора? Нинди егетләр белән йөри? – дип турыдан-туры сорады.

Халикъ, әлбәттә, колхоз кызларының, шул җөмләдән Миңнурыйның да яшерен серләрен белә иде. Ләкин ул, абыйсы кебек хәйләкәр булганга, сер капчыгын берьюлы чишеп куймады.

– Миңнурый апага яучылар йөри дә, ул аларны кире борып җибәрә. Мине күрсә, Газинур абыеңнан хатлар юкмы, дип аптыратып бетерә, кайчак кәнфит тә бирә. Каенем, җаным, кил, яныма утыр, бер үбим әле үзеңне, дип шаярта. Үзе үпми. Гөләп чәчәге кебек чәнечкеле ул.

– Әле дә гөләп чәчәге дип йөртәләрме үзен?

– Хәзер күбрәк кычыткан диләр.

Газинур кычкырып көлеп җибәрде, ләкин йөрәге тынычланмады.

Караңгы төшү белән, аңа дус-ишләре җыелды һәм алар байтак вакыт җырлап утырдылар. Газинур бүтәннәргә чокырны тутырып салганда, үзенең чокырын йә сикертеп үтте, йә аракы урынына, йөзен юри чытып, су эчте. Аның бөтен уйлары Миңнурый янында иде.

– Клубта бүген берни дә юкмыни? – дип сорады ул иптәшләреннән.

Кичә клубта кино күрсәткәннәр, аннан элек доклад булган, ә бүген берни дә юк.

Сәлим почмакта утыра, сүзгә катнашмыйча, бертуктаусыз аракы чөмерә. Аңа: «Аша, исерерсең», – диләр, ул ашамлыкларны кулы белән читкә этә дә тагын стаканны ала. Стакан аркылы Газинурга карый. Берничә тапкыр аларның күз карашлары очрашты: мондый чакта әйтерсең кылычка кылыч бәрелеп утлар чәчри иде.

Кинәт Сәлим урыныннан торды, ике кулы белән ашъяулыкны йомарлап, аны өстәлдәге барлык савыт-саба, ашамлыклар, шешәләр белән бергә үзенә тартты. Табындагылар әллә ничә авыздан: «Сәлим, бу нишләвең, юләрләнмә!» – дип кычкыра башладылар. Ләкин ул берәүне дә тыңламады, күрмәде. Пыялаланган күзләре белән каядыр еракка караган килеш, буылып-буылып сөйләргә тотынды:

– Газинур... Нигә син кайттың? Тагын юлыма аркылы төшәсеңме? Юк, не позволю! Лучше сандыгыңны ач, күрсәт урман кызыңны! Әллә, чәчәген өзгәч, урманда ташлап калдырдыңмы? Миңнурый бар дисеңме? Юк, Миңнурый барыбер сиңа булмаячак. Бул... – Сәлимнең теле көрмәкләнә башлады. Ул, чайкалып китеп, лап итеп урынына утырды. Нечкә, ямьсез тавыш белән җырлый башлады: – Асылъяр, кенәри, бергә булырбыз әле...

Өстәлнең икенче башында утырган Газинур агарынып китте, колакларына ышанмады. Ул, иптәшләрен этә-төртә, Сәлим янына килде.

– Ни сөйлисең син?! – дип, исерек булмаса да, Сәлимнең якасыннан алды.

Ләкин теге йоклый иде инде. Газинур аны сәке кырыена төртте дә үзе шунда ук, ишегалдына чыгып, түмәргә утырды.

Карасу күктә түм-түгәрәк ай йөзә. Йолдызлар җемелди, ә арырак кырыйларына ай нуры төшкән болыт кисәкләре күренә, һава җылы, пырылдый-пырылдый коңгызлар оча. Өйдән җыр, гармун тавышы ишетелә. Һашим «Хафизаләм иркәм» көенә җырлый...

Газинур тирән сулап куйды.

– Шулай... «Чит җирләрдә озак йөрсәң...» Хәзер аңлыйм, Әлфия, кем бакчасына таяк атканыңны.

Моннан чирек сәгать кенә элек Газинурның бөтен уйлары Миңнурый белән бергә иде, йөрәге бары тик аны күрү бәхете белән генә тулы иде. Ә хәзер... Нәрсә калды хәзер?..

Аның янына малай сыман гына буйлы Һашим килеп басты.

– Газинур, ник безне ташлап чыгып киттең? Сәлимгә хәтерең калдымы? Аның сүзләре яңа түгел бит...

Һашим тәмәке кабызды, янчыгын Газинурга сузды.

– Тарт, дустым, күңелеңә җиңелрәк булыр, – диде ул, Газинурның иңбашына кулын куеп.

Газинур, зур күзләрен караңгыда ялтыратып, аңа бер күтәрелеп карады да башын түбән иде.

– Газинур, – диде Һашим, аның янына утырып. – Син мине дус дип саныйсыңмы әле? Мин сине элеккечә дус күрәм. Хәтерлисеңме, Бөгелмәнең таш юлын салганда, ничек эшләдек? Кышын Бөгелмәдән кайтканда, чана артыннан йөгерткәнемне дә хәтерлисеңме?

Газинур аңа карап алды.

– Чанада шаярып барганда, башымны вата язганыңны да онытмыйм. Әле булса эзе бар.

– Алайса, дуслыгыбызга да ышанасың?

Газинур бер кулы белән аны кочаклап алды.

– Рәхмәт, – диде Һашим, – хәзер син монда утырма. Мәҗлесне үзем түгәрәкләрмен, сине Миңнурый тилмереп көтә. Бар.

– Ә Сәлим?! – дип, Газинур үзе дә сизмәстән сорап куйды.

– Бар, бар, ул турыда соңыннан. Сукыр чебен күзгә кермәсә, аны сукыр да димәсләр иде.

Бер секунд эчендә Газинурның бөтен көче үзенә кайтты. Ул, читән аша сикереп, шунда ук күздән юк булды. Һашим бераз басып торды да җыр, гармун тавышы яңгырап торган өйгә кереп китте.

Газинур караңгыда мәче кебек үткен күрә, очар карлыгач кебек, тавыш-тынсыз йөри белә иде. Ул, бер генә Сарбайны да борчымыйча, бәрәңге бакчалары аркылы үтте дә бөтенләй икенче яктан, Исаково ягыннан посып килеп Миңнурыйның тәрәзәсен чиертте. Тәрәзә пәрдәсенең кырые шунда ук күтәрелде, эчтән әкрен генә:

– Ишек бикләнмәгән, – дигән тавыш ишетелде.

Газинур йорт кырыеннан, куе күләгәгә сыенып, баскычка менде. Өйалды караңгы иде. Кинәт Газинурның муенына ялангач кайнар куллар сарылды.

– Газинур, җаным...

Караңгыда Газинур Миңнурыйның йөзен күрә алмады. Тик эссе сулышын гына тойды. Аннары аның битләренә кызның хуш исле чәчләре орынды. Газинур аны бөтен көче белән кочаклап алды...

– Миңнурый, бәгърем, чү, ник елыйсың? – дип пышылдады ул.

Миңнурый, аның кулыннан тотып, өйгә кертте. Өй эчендә ут яндырылмаган булса да, тәрәзәдән төшкән ай нурыннан шактый якты иде. Миңнурый тәрәзә пәрдәсен яхшылап корды да ут кабызды. Бер кулы белән асылма лампага тотынган килеш, сөйкемле һәм назлы күзләре белән Газинурга карады. Миңнурый буйга шактый тартылган, җитмәсә, биек үкчәле туфли кигән. Ул хәзер инде юан тормага охшамый, биле нечкә, буе зифа, коңгырт чәч толымнары билен узган, очлары элеккечә бераз сүтелеп тора.

Миңнурый очып килеп Газинур янына утырды, сөйгәненең кулларыннан тотты.

– Бер елга дип китүләрең шушы булдымыни, Газинур? Һашимнарның кайтканына да ни гомер узды инде.

Миңнурыйның бу сүзләрендә ике ел буенча җыйналган чиксез сагынулары да, йокысыз төннәрдә мендәр читен тешләп яшерен елауларның ачы ләззәте дә, шелтә дә, үпкә дә, инде бәхеткә ирешүдән, өметләренең юкка чыкмавыннан туган шатлык та бар иде.

Шулкадәр тирән мәхәббәт һәм сабый бала кебек иркәләнү белән әйтелгән бу сүзләргә ни дип җавап бирергә? Бу яшь кызның чылтырап аккан чишмә суы кебек саф, җәйге таң кебек гүзәл тойгылары алдында нинди сүзләр белән акланырга? Бармы соң андый сүзләр? Газинур аларны белми дә, белсә дә Миңнурый алдында аларны әйтер өчен теле әйләнмәс иде.

– Газинур, мин бит синең тау башында җырлаган җырыңны ишеттем, – диде Миңнурый әкрен генә, гүя шул җырны яңадан тыңлаган кебек, тирән ләззәткә чумып, күзләрен йомды. Газинурның көтмәгәндә еракта ишетелгән җыры яшь кыз йөрәгендә нинди зур шатлык катыш тетрәү уятуы турында Миңнурый бер сүз дә әйтмәде.

Газинур исә аңардан күзләрен ала алмыйча, аңа берсүзсез карап торды: җырларда сагынып җырланган, тавышы кошлар сайравында гына ишетелгән ерактагы Миңнурый чыннан да үземе соң бу?

Миңнурый тиз генә урыныннан торды, ни өчен икәнен үзе дә белмичә, икенче якка юнәлде. Газинур аны куып җитеп иңнәренә аллы-гөлле ефәк яулык салды.

– Бүләгем булсын, Миңнурый...

– Рәхмәт, Газинур.

Миңнурый керфекләрен түбән төшерде. Кулын дулкынланып торган калку күкрәгенә куйды. Аннары, озын керфекләрен яңадан күтәреп, нурлы күзләре белән Газинурына карады. Ул чиксез бәхетле иде. Сәлимнәрнең теңкәгә тигән чаклары, Газинур турындагы төрле имеш-мимешләр, хәтта үзенең ике ел буена кичергән сагышлары да бу минуттагы зур бәхете алдында бик кечкенә булып калдылар. Ул Газинурга булган үпкәләрен дә, ачулануларын да, чәнечкеләрен дә онытты. Аның карашы гүя: «Мин гөләп чәчәге, ләкин синең өчен минем инәләрем юк», – дип әйтә иде.

Миңнурый Газинурның кочагына ташланды, кайнар иреннәрен сөйгәненең иреннәренә якын ук китереп сөйли башлады:

– Газинур, сиңа, бәлки, төрле сүз ирештерерләр... Ышанма аларга, мин сине генә сөям, син минем бер генәм, гомерлек ярым...

## 19

Ындыр табагы өстендә кичке җылы аяз күктә күгәрченнәр оча. Кайчакта алар, рәт-рәт тезелгән, алтыннан койган сыман сап-сары салам эскертләренә килеп куналар да, борчылып, ябык ындырга карыйлар. Анда алар-

ның оялары. Ләкин күгәрченнәр ояларына керә алмыйлар. Ябык ындыр эчендә, тирә-яктагы бөтен әйберләрне дер селкетеп, сугу машинасы үкерә, җилгәргеч зырылдый, кешеләр кайнаша. Биек, озын сарайның бер башыннан көлтә төягән арбалар кереп тора, икенче башыннан ашлык төягән олаулар, автомашиналар чыгып китәләр. Тик сугу машинасы эштән туктагач кына, күгәрченнәр үз ояларына курыкмыйча очып керәләр, йомшак тузан белән капланган ояларына кунаклап гөрләшә башлыйлар. Ләкин хәзер кич якынлашуга да карамастан, ябык ындыр эчендәге сугу машинасының туктарга исәбе юк. Күгәрченнәр сарайга түгәрәк күзләре белән бераз карап торалар да яңадан һавага күтәреләләр, ябык ындыр түбәсенә кунмакчы булып түбәнәяләр, ләкин аның тере нәрсә кебек дерелдәп торуын күргәч, кунарга батырчылык итмичә, яңадан югары күтәреләләр, колхоз ягына таба очып китәләр. Батып барган кояш нурлары күк күгәрченнәрнең канат асларындагы ак йоннарын яктыртa, ә ак күгәрченнәр, кыйгач борылганда, көмеш нурда коенган сыман, бөтен каурыйлары белән ялтырап китәләр.

Күгәрченнәр – мул тормыш билгесе. Элекке заманда, ачлык елларында, алар бөтенләй күренмиләр иде. Ә хәзер һәр колхоз өстендә бу гүзәл, затлы кошлар төркем-төркем булып очалар, түбә кыекларында, сарай түбәләрендә гөрлиләр. Бигрәк тә алар колхозның ындыр табаклары тирәсендә күп. Биредә аларга берәү дә тими, алар кешеләргә шулхәтле ияләшкәннәр, чебиләр кебек, аяк астында чуалалар, бер дә курыкмыйлар.

Дәүләткә ашлык ташучы олаулар Бөгелмәдән кайттылар. Газинур алдагы Малина исемле җирән кашка атның арбасыннан сикереп төште дә гөрләп торган ябык ындыр эченә йөгереп керде. Аның кара күзләре ашлык сугучы уннарча хатын-кызлар арасыннан Миңнурыйны эзләде. Ак җиңсәле Миңнурый, тузан кунган кызыл яулыгын күзләренә кадәр үк төшереп, ажгырып торган барабанга көлтә биреп тора иде.

Ул баулары киселгән көлтәләрне күз иярмәс җитез бер хәрәкәт белән эләктереп ала да барабан алдына сала. Җилкенеп, уйнап, сөеп эшли Миңнурый. Газинур аның эшен күргән саен сөенеп, куанып бетә алмый.

Миңнурый да Газинурны күрде:

– Шадрам кайткан икән, – диде, көлеп. – Нигә бик тиз кайттың, юлда түгеп калдырмадыңмы?

– Бөгелмә элеваторын безгә якынрак күчереп куйганнар, – диде Газинур, барысына да ишеттерергә тыры-

шып. – Әкрен кыймылдыйсыз, кызлар. Менә соңгы капчыкларны алабыз!

Газинур биш потлы капчыкны җилкәсенә уйнап кына күтәрде дә арбасына таба йөгереп китте. Аннары тагын йөгереп кайтты, коточкыч гөрелтедән сөйләшүе кыен булса да, җаен туры китереп берәр шаян сүз әйтеп яки мәгънәле итеп карап, күзен кысып, кашын сикертеп, башын чайкап кызларны көлдерде, аннары яңа авыр капчыкны иңенә ташлап, арбасына йөгерде. Киләп ураган кебек беренче караңгыдан икенче караңгыга кадәр, ә кайчакта төне буенча да Бөгелмә белән «Красногвардеец» арасында олаулар белән йөргән Газинур, аяктан егылырлык булып арыганда да, сер бирергә яратмый иде. Бигрәк тә үзенең гөләп чәчәге алдында сынатасы килми иде аның. Миңнурыйның теленә эләксәң, сөйгәнем дип тормас!

Ике дистәгә якын олауга капчыклар төялеп беткәч, Хәнәфи аларны тагын бер кат санап чыкты да, кечкенә блокнотына билге ясап, кулын күтәрде:

– Хәерле юл, егетләр. Озак тоткарланмагыз. «Заря»лылар, «Тигез басулар» уздыралар, – дип кыздырып алды, ләкин үзе мыек астыннан елмаеп куйды, – уздырмый торсыннар!

«Красногвардеец»тан Бөгелмәгә унсигез километр, барып кайту белән – утыз алты. Кояш баер алдыннан чыгып киткән олаучылар төнлә генә кайтачаклар. Ләкин бу берәүне дә хәзер борчымый. Мондый кызу эш өстендә колхоз төнен көнгә ялгап эшләргә күнеккән. Шулай да бер-берсен яраткан яшь йөрәкләр күреп сөйләшер өчен вакытын да, җаен да табалар.

Газинурлар бик соң кайттылар. Арыган атларны алмаштырып, яңаларын җиктеләр. Сугу машинасының ремене бушаган иде. Шуннан файдаланып, Миңнурый Газинурның арбасы янына килде. Башка олаулар төялеп бетмәгән иде әле. Газинур Миңнурыйның кулыннан тотты да, алар салам эскертләре арасына кереп киттеләр. Миңнурый йомшак саламга утырды, башыннан тузанлы яулыгын алды. Караңгыда аның йөзе яхшылап күренми, тик ак тешләре белән күзләре генә ялтырый иде.

Газинур, Миңнурый янына, хуш исле салам өстенә чүгәләп:

– Бик арыдыңмы? – дип сорады.

– Арыдым, беләкләремне күтәрер хәлем юк, – диде Миңнурый, серен яшермичә, шунда ук көлеп җибәрде. – Туебызга кадәр хәл керер әле, иеме?

– Ә туйны кайчан ясыйбыз соң, Миңнурый? Кайчан кавышабыз?

Миңнурый, арыган кулларын баш артына куйган килеш, көлеп:

– Кызыл кар яугач, – диде.

Олаучылардан кемдер сызгырды.

– Мине чакыралар, – диде Газинур, Миңнурыйның кулын кысты. – Саргайтып бетерәсең бит, җаным!

– Син мине ике ел саргайттың, мин алай да түздем. Син берничә атна көтәргә теләмисең.

– Димәк, урып-җыюлар беткәч тә?

– Кызыл кар яугач, дим ич.

Яңадан сызгырдылар.

– Киттем! – диде Газинур һәм, Миңнурыйның битеннән үбеп, йөгереп китеп тә барды. Миңнурый, бәхетле елмаеп, аның артыннан карап торды да әкрен генә күзләрен йомды. Шунда ук аның күңеленә «Күзем йомсам, күз алдымда...» дигән җыр килде. Ул елмайды, яңагын йомшак саламга куйды.

Шулай ул нибары ике-өч минуттан да кимрәк ятты. Ләкин шул ике-өч минут эчендә ул җылы, йомшак суга чумган кебек, татлы йокыга талырга да, хәтта төш күрергә дә өлгерде. Имеш, алар Газинур белән самолетта очалар. Аннан аларга Татарстан, күрше Башкортстан җирләре генә түгел, бөтен Советлар Союзы күренә, имеш. Бөтен җирдә, илнең иңеннән-иңенә, буеннан-буена сузылган кырларда кешеләр уңыш җыялар, һәр җирдә алтын көшелләр өелгән.

Кайдандыр җыр яңгырый. Шат күңелле җыр. Гармун да уйныйлар...

Миңнурый күзләрен ача, урыныннан сикереп тора. Тәне җиңеләйгән, ул әле һаман оча кебек. Йокысы тәмам ачылган, күңеле әлеге гаҗәеп төштәгечә биеккә-биеккә очу тәэсиреннән канатланган, ә олы юлдан олауда барган Газинурның күңелле җыры ишетелә:

...Юл бирегез, икмәк төяп
Кызыл обозлар бара.

Сугу машинасы гөрли башлады. Миңнурый яулыгын бәйли-бәйли ындырга йөгерде.

Иртә белән әле яңа гына Бөгелмәдән кайткан Газинурны председатель янына чакырдылар.

– Олауны Вәлиәхмәткә тапшыр, – диде Хәнәфи, – ә үзең движок янына позициягә урнаш. Николай Михайловичка ярдәмче итеп билгелим үзеңне.

Газинур, шатлыгын яшерә алмыйча:

– Минеме? Машинист ярдәмчесе итепме? – дип кайтарып сорады.

– Леспромхозда алган белемеңне күрсәтергә вакыт.

Хәнәфи кырт борылды да үлчәүләр янына китте. Кызлар көшелдән капчыкларга чиләк белән ашлык тутыралар иде.

Газинурны машинист ярдәмчесе итеп күчерү турындагы хәбәр бик тиз арада бөтен ындырга таралды. Миңнурыйның, бер генә күзе белән булса да, «шадрасына» карыйсы килде: нишли икән ул юләр анда. Ләкин барабан комсыз, машина яныннан китү түгел, тузгып чыккан чәчен яулык астына кыстырырга да вакыты юк Миңнурыйның. Ул, кыен булса да, төшке аш вакытын көтте. Ашарга кайтышлый, белмәмешкә салынып, керосин, май исләре бөркелеп торган машиналар бүлегенең ишеген ачты. Машина артыннан җиңнәрен сызганган, йөзе майга буялган Газинур килеп чыкты.

– Әбәү, мунча пәрие, нишләп йөрисең син монда, – диде Миңнурый, Газинурның монда йөрүенә гаҗәпләнгәндәй булып. – Николай Михайлович күрсә, чыбыклар әле үзеңне.

Газинур кызга каш сикертеп куйды.

– Бәлки, башта мин синең үзеңне кычыткан белән сыйлап алырмын. Машиналар бүлегенә чит кешегә кереп йөрергә ярамавын оныттыңмыни?

– Һай, нинди усал машинист, – дип, Миңнурый пырхылдап көлеп җибәрде. – Соң син бу агрегатның нәрсә икәнен беләсеңме әзрәк?

– Белмәсәм, монда куймаслар иде, Миңнурый җан!

Газинур, Миңнурый янына ук килеп, шаян тавыш белән әкрен генә җырлап җибәрде:

Агыйдел алкынына,
Басма су салкынына;
Килмә янга, кабынырсың
Йөрәгем ялкынына.

Миңнурый тиз генә тирә-ягына каранып алып, кешекара күренмәгәч, Газинурга шаянлык белән җавап кайтарды:

Ал биргәннәргә – ал бирәм,
Гел биреп тормыйм әле;
Гөрбияннарга – гөрбиян,
Сер биреп тормыйм әле.

Газинур кочып алырга дип кулын сузган гына иде, Миңнурый ялт итеп читкә тайпылды, аннары назланып бармак яный-яный юк булды.

Миңнурый туй кызыл кар яугач булыр дип шаярткан булса да, алар ак кар яуганны да көтмәделәр. Урып-җыю

эшләре бераз иркенәя төшкәч тә, аларның туйлары булды. Кызыл туй ясадылар. Иртән Газинур, правление атын – ак бәкәлле чем-кара Чаптарны тарантаска җигеп, Миңнурыйларның капкалары төбенә килеп туктады. Миңнурый киенеп-ясанып көтеп тора иде инде. Ат килеп туктагач, өстенә кыска жакет, башына озын чуклы ак шәл, аягына өр-яңа галош белән биек үкчәле туфли кигән Миңнурый, Гали абзыйның хатыны Галимә апа һәм Әлфия өйдән чыктылар. Миңнурый тарантаска утыруга, бер урында сабырсызланып биеп торган Чаптар кузгалып та китте. Галимә җиңги белән Әлфия аларның артыннан хәерле юл теләп, кул болгап калдылар.

Су алырга чыккан күрше хатын, кул болгап торучы Галимә апа белән Әлфия янына килеп:

– Ахирәт, кемнәрне болай озаттыгыз? Бөгелмәдән кунак килгән идеме әллә? – дип сорады.

– Юк, – диде Галимә җиңги, яшен сөртеп алып, – Газинур белән Миңнурый Бөгелмәгә язылышырга киттеләр.

Кичен Гафиятулла абзыйның өе кунаклар белән тулды. Түрдә, иң мактаулы урында, Гали абзый белән Галимә апа, колхоз председателе Хәнәфи, алар белән янәшә яшь кияү белән яшь килен – Газинур һәм Миңнурый, аннары Сабир бабай белән Галәк бабай, бригадир Габдулла, Гарәфи абзый белән Бибигайшә җиңги, Һашим белән Әлфия һәм башка кунаклар утырганнар иде. Сакал-мыекны төзәттергән Гафиятулла бабай, өстенә чиккән якалы ак күлмәк кигән Мисбах, Шәмсинур җиңги кунакларга хөрмәт күрсәтү өчен аяк өстән тордылар.

Мәҗлесне ачып җибәрергә вакыт иде инде. Гали абзый, елмаеп:

– Туйны безнең колхозыбызның иң карт кешесе Галәк бабай ачсын, – диде. – Картларга хөрмәт.

Түрдә тулган ай кебек балкып утырган түгәрәк ак сакаллы Галәк бабай тамагын кырып алды.

– Үз гомеремдә, – диде ул, сакалын сыпырып, – туйларның зурысын да, кечкенәсен дә, күңеллесен дә, даулысын да күп күрдем. Кияү егет тә, башкода да булдым, кыз да урлаштым... Шулай бервакытны... ярый, анысы хәзергә торып торсын, соңыннан сөйләрмен. Әйе, күп нәрсә күрдем. Әмма ләкин кызыл туйда утырганым булмады. Инде кызыл туйда утыру бәхетенә дә ирештем. Шаять, монысы соңгысы булмас. Ягез, җәмәгать, табынны күтәрмик, кызыл туй котлы булсын. Яшьләргә тигез гомер телик! – Галәк бабай тамырлары беленеп торган ябык көрән кулы белән бер стакан мөлдерәмә тулы балны алды да:

Җырларга кушсаң, җырлармын,
Гөрләргә кушсаң, гөрләрмен,
Килгән кодаларның хакы өчен
Җырлау түгел, егылып үләрмен, их!

Ул стаканны төбенә кадәр эчеп җибәрде, аннары, кызыл башлы сөлге белән сакал-мыегын сөртеп:

– Галәк бабагызда дәрт бетмәгән әле, – диде.

Кунаклар көлеп җибәрделәр. Шау-шу күтәрелде. Яңа котлаулар, тигез, бәхетле гомер теләүләр башланды. Гали абзый белән Хәнәфи дә берничә сүз әйттеләр. Алар яшьләргә, колхоз өчен көчне кызганмый эшләгез, алма кебек балалар үстерегез, диделәр. Газинур белән Миңнурый аска карап утырдылар. Аның каравы, картлар китеп, табынга үз тиңнәре – яшьләр җыелгач, аларның шат көлүләре, парлап җырлаулары, тыпыр-тыпыр биюләре бер генә минутка да тынмады. Берсеннән-берсе уздырып биеделәр, берсеннән-берсе уздырып җырладылар.

Туйга Сәлимне дә чакырганнар иде. Бөтен өметләре юкка чыккан, көнләшүдән үз-үзен кая куярга белми йөргән Сәлим, тыштан бер дә исе китмәгән кешегә салынып, туйга килде. Ләкин аның эчкә баткан күзләренең карасуланып китүенә караган һәр кешегә аның йөрәгендә нинди ялкын дөрләвен, күңелендә нинди давыл ярсуын белүе кыен түгел иде. Ул бөтен кешедән күбрәк эчте, бөтен кешедән күбрәк җырлады, күбрәк көлде. Бизгәк белән авырган кебек янган күзләре бер генә минутка да ак күгәрчен кебек Миңнурыйдан китмәде. Газинур да, аннан бигрәк Миңнурый да моны сизеп тордылар, ләкин күрмәмешкә салындылар, чөнки алар икесе дә бүген бик бәхетле иде.

Газинурның кияү егете һәм табынны алып баручы Һашим, әледән-әле Сәлим янына килеп, аның колагына нидер пышылдады. Ул Сәлим үткән мәҗлестәге кебек тавыш-гауга чыгарып туйның ямен җибәрер дип курка иде. Ләкин бүген Сәлимгә аракы тәэсир итмәде.

– Һашим, аракыга су кушып бирәсеңме әллә син? – дип кычкырды ул һәр рюмкадан соң. – Кызганма син Газинурның малын, – һәм шунда ук яшь кияүгә борылып, – кара аны, Газинур, Миңнурыйның кадерен бел! – дип кычкырды. – Бүтән андыйны таба алмассың!

Аннары Сәлим җырларга тотынды. Ул стенага сөялеп, күзләрен йомып, бөтен мәҗлесне онытып җырлады. Аның артык кычкырмыйча, моңлы итеп җырлавы йөрәгенең никадәр сыкравын бик яхшы әйтеп бирә иде. Тавышы да бүген бүтән чактагы кебек ямьсез түгел иде.

Алма сатучылар килгән,
Алдым ящигы белән.
Яр булмаслыгын да белдем,
Сөйдем яшьлегем белән.

Ак өемә элеп куйдым
Алмалы паласымны.
Өзелеп сөйдем, белеп сөйдем
Аерылып каласымны.

Чылтырап аккан чишмәдә
Бармы яулык юганың?
Җаның теләп сөйгән ярның
Онытыласы юк аның.

Кече якта кемдер көрсенеп куйды, кызганган тавыш белән:

– Әй бичара, нигә бу кадәр өзгәләнә, авылда кыз беткәнмени? – диде.

Газинурның кара күзләре уйнаклый башлады, сулышы ешайды. Миңнурый аның кулын кысты. Үз җырыннан үзе елый башлаган Сәлимне иптәшләре алып чыгып киттеләр. Ә аннары, гүя барысына да җавап биргән кебек, Миңнурый җырлап җибәрде:

Самоварың җиз генә,
Кайнаулары тиз генә.
Матур да күп, чибәр дә күп,
Җан сөйгәнем бер генә.

Сәлимнең егет горурлыгын югалтып малай кебек үкереп елавы Газинурның күңелендә бик ямьсез тойгы уятты. «Яңгыр астында калган көчек кебек шыңшып утырганчы муенга элмәк салалар аны, хәчтерүш!» – дип уйлап алды ул. Тик Миңнурый җырлый башлагач кына, аның күңеле ачылып китте һәм Миңнурыйга кушылып җырлап җибәрде:

Безнең басу – такыр басу,
Тотыйк төлкеләр булса.
Алдашмабыз, ташлашмабыз,
Алда гомерләр булса.

Мәҗлес бик соң таралды. Өйдә Газинур белән Миңнурый гына калды. Көләч йөзле, кара күзләре ялтырап торган, бәхетле һәм чиксез шат Газинур, ике кулын алга сузып, үзенең гөләп чәчәген чакырды. Миңнурый, башын кыңгыр салып, шаянлык белән тулы күзләрен сирпеп аңа карады, аннары кинәт бит очларына ялкын капкандай булды, ул, йөгереп килеп, ике кулын Газинурның кулларына куйды.

– Ак күгәрченем, без бергә! – диде Газинур, Миңнурыйны кочагына тартып.

## 20

Гафиятулла бабайның өе кечкенә булганлыктан, Газинур, өйләнгәч тә, озакламыйча, эти-әнисенең ризалыгын алып, башка чыкты. Уң яктагы күршеләренең өе хуҗалары читкә киткәнлектән бушап тора иде. Шул йортны сатып алдылар.

– Иллә шәп ташпулат та соң безнең йорт! – диде Газинур, кечкенә тәрәзәле, тыштан да, эчтән дә кызыл балчык белән сыланган тәбәнәк өйнең ишеген ачып. – Төкле аягың белән, Газинур иптәш, – диде ул үз-үзенә.

Борынгы йола буенча, әтисе биреп җибәргән бербөтен ипине өстәл өстенә куйды. Миңнурый исә, каенатасының кечкенә булса да кеше җылысы кунган өеннән, бигрәк тә Гали абзыйларның якты, җыйнак, авылча бай йортыннан соң буш өйгә килеп кергәч, ишек төбендә баскан килеш туктап калды. Аның йөзендә ниндидер аптыраш иде.

Шат һәм көләч Миңнурыйның кинәт болай сагышка чумуын күргәч, Газинур хатыны янына килде, аның иңбашыннан йомшак кына кочып алды.

– Әллә инде ямансылый башладың, Миңнурый җаным, – диде ул иркә тавыш белән. – Безнең тәрәзәбезнең кечкенәлегенә, гөләп чәчәгем, исең китмәсен, ул зур дөньяга карый. – Газинур көлемсерәп куйды. – Галәк бабай әйтә: карчыганың оясы түгел, үзе матур, ди. Колхозның эшләре уң булса, бер-ике елдан менә дигән алтыпочмаклы, зур тәрәзәле йорт салырбыз.

Миңнурый Газинурга күтәрелеп карады. Аның кечкенә кара күзләре елмая иде. Бары тик шул кечкенә күзләрнең түрендә генә, кайдадыр бик еракта, үтеп киткән яңгырның офыктагы болытлары кебек, моңсулык шәүләсе калган иде.

– Их син, минем кыю карчыгам, – диде ул, ярым мыскыллап, шунда ук җиңнәрен сызгана башлады. – Чиләкләр ал да суга йөгер. Аннары завхоздан бераз акбур сора. Өйне яхшылап акшарламыйча, юмыйча кермибез.

– Баш өсте, гөләбем, йөгерәм! – диде Газинур, үзе чиләкләр шылтыратып коега чапты. Урамда аның кемгәдер: «Яңа йорт котлау мәҗлесенә рәхим итегез!» – дип шаярып кычкырган тавышы ишетелде.

Миңнурый Газинурның бу «кунакчыллыгыннан» ихтыярсыз елмаеп куйды. Газинурның нәкъ менә шушы балалардай беркатлылыгы, дөньяда хәсрәт уты йотмыйча, җиңел яшәве, төшенкелекне белмәве аңа барысыннан да бигрәк ошый иде бит.

Миңнурый ятимлектә үсте, аның үз өе, үз почмагы булмады. Ләкин кош та үзенә оя кора, Миңнурый да үзенә оя кирәклеген аңлый иде. Ул әзер йортка тап булырмын дип бервакытта да хыялланмады. Барысын да үз кул көче белән тудырырга әзерләнде. Кайчак ул сагышлана, әмма аның сагышы иртәнге чык кебек тиз оча иде. Тормыш аны куркытмый, кыенлыклар алдында чигенергә уйламый иде ул. Кайда гына булмасын, ни генә эшләмәсен, Газинур кебек, теленнән җыры төшмәде.

Газинур су алып кайтты. Миңнурый өстенә иске кара күлмәк кигән, башына иске яулык япкан, яланаяк. Бик тырышып өй эчендәге тузаннарны, пәрәвез ояларын себереп йөри.

– Син кемне өй котларга чакырдың? – дип сорады ул Газинурдан. – Башта өйне кеше керерлек итәргә кирәк ләбаса.

Җәйге көн озын, әмма өйне эчтән-тыштан агарта, анналары тәрәзәләрне, идәннәрне юа торгач, кич тә килеп җитте. Бу көнне Газинур белән Миңнурый өйалдында гына йокладылар. Икенче көнне Газинур иртән иртә үк атлар янына китте. Өйгә төш вакытында гына кайтты.

Миңнурый, тәрәзәдән башын сузып:

– Алъяпкычыңны салып, аякларыңны сөртеп, кулларыңны юып кер, сабын белән су әнә ишегалдында, сөлге дә шунда, – дип кычкырды.

Газинур аның кушканнарын төгәл үтәп, ниһаять, өй эченә кергәч, ишек төбендә таң калып туктады. Ап-ак өй эче аслы-өсле кызыл башлы сөлгеләр белән бизәлгән, бер як стенага ак бөрешле ашъяулык элеп куелган. Идән сары гәрәбәдәй ялтырый, урын-җир әйбәт итеп җыелган, ак мендәрләр кабарып тора, түрдәге көзге башына да сөлге эленгән, көзге астында яңа авылны күрсәткән зур плакат, тәрәзә төпләрендә песи яфрагы, ал кына гөлләре, тамчылы гөлләр, алар ышыгында җиңел ак пәрдәләр күренә. Киҗеле ашъяулык япкан өстәлдә, бизәкле поднос өстендә, самовар шаулый. Ә Миңнурый үзе мич кырыена баскан да, кулларын бөеренә куеп, елмаеп тора.

– Чү, мин ялгыш килеп кермәдемме? Бу шадра Газинур өе буламы? – дип сорады Газинур, көлеп.

– Әйдә, әйдә, мутланма әле, күзләреңне дә май ашаган мәче кебек елтыратма, – диде Миңнурый.

– Уңган хатын кар өстендә казан кайната, дип сөйлиләр иде, иллә дөрес икән, – диде Газинур һәм, Миңнурый янына килеп, аның уң битеннән үбеп алды.

Кыш җитте. Бөтен җир ап-ак карга күмелде. Гамьсез балалар чана, чаңгы шуалар. Ә олылар иртәдән кичкә кадәр кырда кар тота. Газинур белән Миңнурый да кар тотарга йөриләр. Газинурның өстендә сырган телогрейка, сырган чалбар, аягында киез итек, бүреген, көязләндереп, кыңгыр салып кигән, бүтәннәр кебек колакларын төшереп бәйләмәгән. Бияләйләрен билбавына кыстырган, яланкул эшли. Аның дәртле һай-һулары, шаян җырлары бер генә минутка да тынмый.

– Гарәфи абзый, артта каласыз! – дип кычкыра ул бер якка.

– Кызлар, кәҗә! – дип кычкыра икенче якка.

– Гөлназира җаным, булачак киявеңә түшәк әзерләмисең, җәһәтрәк кыймылда! – дип шаярта арттарак калган бер кызны.

Менә Газинур, беразга гына эштән туктап, көрәк сабын култык астына терәп, кырга карап тора. Кыр буйлап җәяүле буран себерә, әйтерсең күзгә күренми чапкан ак аргамакның яллары дулкынлана. Газинур шул күзгә күренмәгән ак аргамакның җилдә тузгыган ялларына карап җырлап җибәрә, җырлый-җырлый хатын-кызлар арасыннан Миңнурыйны күзләре белән эзли.

Миңнурый йөкле. Кыр эшләренә аны берәү дә җибәрми, бригадир Габдулла хәтта ачуланып та алды:

– Синең аркаңда, Миңнурый, мин халыктан сүз ишетәм. Кызлар күземне ачырмый, йөкле хатыннарны кырга чыгармасаң, колхозда кеше беткәнмени, диләр. Мин сиңа ничә әйттем, ә син һаман үзсүзләнәсең. Газинурың кайда, син шунда, што аны берәрсе алып китәр дип куркасыңмы?

Кайтыр алдыннан Газинур Миңнурый янына килә, көрәген кулыннан ала, берәүгә дә ишеттермәслек итеп әкрен генә әйтә:

– Син бераз саграк булыр идең, Миңнурый. Сиңа авыр күтәрергә ярамый бит.

– Нишләп авыр күтәрим. Кар авыр буламыни, – ди Миңнурый, җил кискән иреннәре белән елмаеп.

Өйгә кайтып ашаган-эчкәннән соң бераз ял иткәч, алар клубка китәләр. Газинур бер почмакка утырып газеталар караштыра, Миңнурый кычкырып уку оештыра. Аратирә Газинур Миңнурыйга күтәрелеп карап ала. Бик кыска гына вакытка – Миңнурый ноктадан соң тын алган чагында – аларның күзләре очраша. Берничә айдан аларның беренче балалары туарга тиеш. Беренче бала! Бу турыда уйлаганда нинди генә ата-ананың күңеле сөенми дә, йөрәге яшерен борчылудан сызланмый! Шушын-

дый минутларда яңа туган балаларның бишекләренә бомба ташларга әзерләнүче фашистларга – сугыш уты кабызучыларга – нинди көйдергеч нәфрәт кабынмый да нинди ярсу тумый?! Фашистлар ачыктан-ачык сугыш әзерлиләр. Испанияне канга батырдылар. Хәзер герман фашистлары котырына, самурайлар кылыч уйната, ак финнар кыбырҗый. Шулай ук алар безнең илгә каршы да сугыш башларлармы икәнни? Безне, тыныч хезмәтебездән аерып, кулга корал тотарга мәҗбүр итәрләрме икәнни?

Клубка бармаган кичләрендә Газинур белән Миңнурый китап укыйлар. Күбесенчә Миңнурый укый, Газинур, бер кулын иягенә куеп, зур күзләрен кая булса мич почмагына терәп, хәрәкәтсез тыңлап утыра. Аның күз алдына куян тиресеннән тегелгән озын колаклы бүрек киеп йөргән Катя килеп баса, Катяның җылы мичкә аркасын сөяп китап укулары исенә төшә...

Беркөнне Миңнурый Газинурга «Галиябану» китабын укыды. Аны ул яттан диярлек белә иде, чөнки үзешчән түгәрәккә катнашып, әллә ничә тапкыр сәхнәдә Галиябану ролен уйнаганы бар иде.

Газинур да бу пьесаны яхшы белә, ә «Галиябану» көе – аның яраткан көе. Ләкин кабаттан тыңларга яки карарга туры килгәндә, Газинур һәрвакыт бик каты дулкынлана. Бу юлы да шулай булды. Башта ул тып-тын утырды, аннары түзмәде, Миңнурыйны бүлдереп:

– Ну бу куштан Исмәгыйльне! Әгәр мин бар чакка туры килгән булса, билләһи газыйм, муенын өзеп, башын култык астына кыстырып җибәргән булыр идем, – диде.

– Әтәчләнми генә утыр әле, яме, – диде Миңнурый. Ул укыган чакта бүлдерүне яратмый иде.

Газинур яңадан терсәгенә таянып, күзләрен мич почмагына текәп тыңлый башлады. Ләкин бераздан сүз кыстырмый түзмәде:

– Ә Галиябану колхоз кызы булса, менә дигән кеше булыр иде, иеме, Миңнурый?

– Ие, – диде Миңнурый, үчекләп.

– Бәдри абзый да, акчага кызыгып, кызын әрәм итмәс иде. Кызганам мин аларны, бигрәк караңгы тормышта яшәгәннәр.

– Тыңлыйсыңмы, юкмы тик кенә! – дип ачуланды Миңнурый.

– Бетте, бетте, җаным, бир йөзегеңне, авызыма кабам.

Китапның ахырын укыганда, Газинурның күзеннән яшь атылып чыкты. Ул урыныннан торды да, пиджагын җилкәсенә элеп, яланбаш килеш чыгып китте.

– Кая болай чыгасың, тиле. Салкын тидерәсең ич! – дип кычкырды Миңнурый аның артыннан.

Биш-ун минут вакыт үткәч, Газинур яңадан өйгә керде. Миңнурый аны әрләргә тотынды. Газинур каршы җавап бирмәде. Ул хатыны янына килде дә аны иңеннән кочып янына утыртты.

Күп кирәкмени ирен яратучы яшь хатынга! Иренең иркәләп бер кочуы аның бөтен ачуын юкка чыгара.

– Син бигрәк йомшак күңелле кеше икәнсең, Газинур.

– Кешеләрне кызганам. Гомерләре әрәм үткән.

Алар байтак вакыт эндәшми тордылар, аннары Миңнурый, Газинурны авыр уйлардан аерыр өчен:

– Газинур, син улмы, кызмы телисең? – дип сорады. Үзе күз кырые белән генә иренә карап алды.

Газинур баш бармагы белән аның борын очына басты.

– Хәзер кыз да, малай да кирәк. Элекке заманда гына, иманага җир артсын дип, малай теләгәннәр. Кызларга кимсетеп Артыкбикә дип исем биргәннәр. Хәзер безнең колхозыбызның мәңгегә беркетелгән җире бар. Кем туса да, бәхете көтеп тора.

– Шулай да ирләр нигәдер күбрәк малай булсын дип телиләр, – диде Миңнурый.

– Анысы билгеле инде, – диде Газинур, көлеп, – малай туса – әтисенә, кыз туса – әнисенә булышчы.

Колхоз җыелышы кичкә билгеләнгән иде. Язгы чәчүгә әзерлек мәсьәләсе барлык кешеләрне дә дулкынландырганлыктан, «Красногвардеец»ның кечкенә клубы җыелыш башланганчы ук шыгрым тулды. Газинур белән Миңнурый үзләре кебек шаян, сүзчән яшьләр арасында, урта бер җирдә утырганнар иде. Сабир бабай гына монда ничектер адашып эләккән. Сәламәт, алсу йөзләр арасында аның ак сакаллы җыерчыклы йөзе әллә кайдан аерылып тора.

Хәнәфи президиум сайларга тәкъдим иткәч, залдан һәрвакыт сайланыла торган кешеләрнең – правление членнарының, укытучы, председатель һәм бригадирның исемнәрен кычкыра башладылар. Кинәт Гарәфи абзый аякка басты, бераз көтә төшкәч:

– Мин, җәмәгать, президиумга Газинурны тәкъдим итәр идем, – диде.

Бөтен яктан хуплаган тавышлар ишетелде:

– Дөрес!.. Газинурны языгыз!..

Газинурны әйтерсең алмаштырып куйдылар. Ул бөрешеп, оялып, аска карап утырды. Гомерендә беренче тапкыр президиумга сайлыйлар иде аны. Җитмәсә, җыелышы нинди тагын – яше-карты агылып килгән.

Исемлекне тавышка куйганнан соң, Хәнәфи:

– Президиум членнары, урыннарыгызга рәхим итегез, – диде.

Газинур урыныннан торды да шунда ук кире утырды. Миңнурый, шәл почмагы белән авызын каплап, пырхылдап көлеп җибәрде, терсәге белән Газинурга төртеп:

– Бар инде, – диде. – Әллә миннән башка куркасыңмы?

Газинурның уң ягында утырган Сабир бабай егетнең хәлен яхшырак төшенде булса кирәк.

– Халык үзе чакыра икән, аптырамый бар, улым, – диде.

Газинур торып киткәч, Сабир бабай, Миңнурыйга таба иелеп:

– Менә бабай әйткән иде диярсең, килен, заманы килер, доклад та чыгып сөйләр әле безнең Газинур, – диде.

Миңнурый ире өчен күңеленнән горурланса да, гадәтенчә шаяртып җавап кайтарды:

– Минем шадрам да доклад ясый башласа, кемнәр генә тыңлап утырыр икән?

Хәтере калган Сабир бабайның ни дип әйтүен Миңнурый ишетмәде. Аның бөтен игътибары ирендә иде. Җидееллык мәктәпне тәмамлаган, беркадәр вакыт шәһәрдә дә яшәгән Миңнурый җәмәгать эшләре мәсьәләсендә үзен иреннән тәҗрибәлерәк саный иде. Ул Газинур тыйнаклык күрсәтеп арткы урындыкка утырыр дип көтте. Ләкин Газинур Хәнәфи белән янәшә утырды, шунда ук председательнең колагынаниндидер көлке сүз пышылдады булса кирәк, тегенең мыеклары селкенеп куйды. Миңнурый, шаккатып, хәтта кулларын чабып алды: менә сиңа пәрәмәч!

Докладны тыңлаганда да Миңнурый иреннән күзен алмады. Аның күңелендә шатлык белән бергә борчылу артканнан-артты: Газинур, бер-бер мәгънәсез сүз әйтеп, үзен бөтен халык алдында гомергә хур итәр төсле тоелды аңа. Ә ул ирен җитди кеше итеп санауларын, аның һәрвакыт президиумга сайланыла торган хөрмәтле кешеләр исәбендә генә булуын, сүз сораса, Гали абзый яки укытучы кебек җитди итеп сөйләвен генә тели иде.

Чыгыш ясаучылар, гадәттәгечә, атлар турында, орлык, инвентарь, агрономия чаралары, МТС турында сөйләделәр. Җыелыш шактый сүлпән бара иде. Дөрес, председательне, бригадир Габдулланы бераз тәнкыйтьләп алдылар. Яңа завхоз Сәлим Салмановка да өстән генә эләкте.

Миңнурый аны күзләре белән эзләде, Сәлим беренче рәттә, картлар арасында, президиумга яны белән борылып эре генә утыра. Гүя ул бер күзе белән президиумны,

икенчесе белән залда утыручыларны күзәтә. Соры якалы тунының төймәләрен ычкындырып җибәргән, майдан ялтырап торган аксыл чәчен шома итеп артка тараган. Шуңа күрә башы кеп-кечкенә булып калган.

«Менә куркә!» – дип уйлап алды Миңнурый һәм чак кына кычкырып җибәрмәде: председатель Газинурга сүз бирде. Миңнурый шунда ук барысын да онытты. Аның йөрәгендә бары бер нәрсә – борчылу гына калды. Менә ул Газинур җиденче күктән егылып төшәчәк куркыныч минут. Моңарчы Газинур җыелышларда бервакытта да чыгып сөйләмәде, күп булса, утырган җиреннән бер-ике авыз сүз кычкырды. Миңнурый Газинур бу юлы да шулай эшләр дип уйлаган иде. Ләкин бөтенләй көтелмәгән бер хәл булып алды.

Газинур трибунага чыкты. Елмайды, оялып кына башын кашып куйды, тагын елмайды. Залда көлгән тавышлар ишетелде. Миңнурый эсселе-суыклы булып китте.

Ул арада Сәлим үзенең нечкә тавышы белән:

– Бетердеңме? – дип чәнчеп алырга да өлгерде.

– Менә башлыйм әле, башлагач ничек тә бетерермен, – диде Газинур тыныч кына.

Залда яңадан көлгән тавышлар ишетелде.

Миңнурый үз-үзен өзгәләргә җитешкән иде: җитди кешеләр шулай сүз башлыйлармыни!

Кинәт Газинур кызып сөйләп китте:

– Менә сез, картлар, әйтергә яратасыз: «Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың», – дисез. Шулаймы, Галәк бабай? – Ул беренче рәттә утырган ил картына мөрәҗәгать итте.

Галәк бабай, бер кулы белән озын таягына тотынып, икенче кулын, яхшырак ишетелсен дип, колагына куйган иде:

– Дөрес, улым, бик дөрес.

– Ләкин бу мәкаль искергән инде, бабай.

Галәк бабай, аптырап:

– Нәрсә әйтәсең? – дип сузып сорады.

– Искергән, дим, бу мәкаль. Хәзер яхшы уңыш аласың килсә, чәчүгә кыштан ук әзерләнергә кирәк. Ә кышны без ничек үткәрдек? Барыбыз да хатыннарыбызның җылы куенына иртәрәк кереп ятарга ашыктык шул.

Бу сүзләрдән соң Миңнурый иренен тешләде, колак очларына кадәр кызарды. «Менә өйгә генә кайт, шадра шайтан, күрсәтермен мин сиңа җылы куен!»

– Агроөйрәнүләр бөтенләй диярлек булмады. Димәк, быел да колхоз кырларында искечә эшләргә уйлыйбыз. Ә инвентарь белән эш ничек? Завхоз үзе әнә яңа тун кигән,

өстеннән шабыр тир акса да, тунын салмый утыра, ә сабаннар, чәчкечләр, урак машиналары кар астында ята. Безнең завхоз иптәш Салманов аларның кар астында тутыгып эштән чыгуы турында уйлап та карамый. Ә тимерчелек ни хәлдә? Бөтен эшне бер кешегә аударганбыз да тынычланганбыз. Болай булса, ремонт көзгә кадәр дә бетмәячәк. Сез дә, Хәнәфи абый, дилбегәне йомшартказсыз, Габдулла да тискәре якка карый. Ә соңыннан, уңмаган кызның туендагыча, ыгы-зыгы кубар, тегесе әзер түгел дә, монысы әзер түгел. Уңмаган кызны мондый чакта ахирәтләре коткара: берсе – күлмәк, берсе – яулык, берсе читек бирә. Ә безне кем коткарыр?

– Һай, тирәннән сөрдерә бит, килен, – диде Сабир бабай, сөенечен яшерә алмыйча.

– Әйтмә инде, бабай! – дип бүлдерде Миңнурый аны. – Мондый тирәнлекне – ташка үлчим.

Чынында исә Миңнурый Газинурның иплән сөйләп китүенә, кешеләрне тыңлата алуына бик шат иде, ләкин мин-минлеге хәтта үз алдында да моны танырга ирек бирми иде.

– Куй әле, килен, тузга язмаганны сөйләмә, – диде Сабир бабай һәм, Газинур сөйләп бетерүгә, беренче булып аякка басты.

– Газинур бик дөрес сүзләр әйтте, иптәш колхозчылар. Тимерчелек ат абзарлары янында гына. Көн саен күреп торабыз. Сөләйман берүзе кыштырдый анда. Ярдәм кирәк аңа, җәмәгать. Мин Сөләйманга булышчы итеп Газинурны билгелик дип әйтер идем. Леспромхозда чакта ул тимерчелек эшенә аз-маз өйрәнгән. Ашлык сукканда движок янында да начар эшләмәде. Тагын бер тапкыр егетлеген күрсәтсен. Атларны аңардан башка да карарбыз.

Сабир бабайның тәкъдимен раслап кул чаптылар.

Өенә кайткач, Газинур кровать астыннан агач сандыгын чыгарды да леспромхоздан алып кайткан инструментларын карый башлады.

Миңнурый, иңнәренә җылы шәл салып, аңа каршы утырган, чәнечкеләрен тирән батырмыйча гына ирен шаярта. Ул инде клубта инәләр өстендә утырганын оныткан. Аның куркуы хәзер эчке канәгатьләнү тойгысы белән алмашынган, аңа инде бүтән бернәрсә дә кирәкми.

Икенче көнне Газинур таң атар-атмас ук тимерчелеккә килде. Сөләйман юк иде әле. Газинур алачыкның бикләнмәгән ишеген тартып ачты, алачык эченә күз салды. Бөтен җирдә чүп-чар ауный, инструментлар чәчелеп ята.

– Тимерче ачуланса ачуланыр, шулай да бераз тәртипкә китерим әле бу чәүкә оясын, – диде Газинур үзүзенә.

Айлар буенча өелгән чүп-чарны чыгарып ташлагач, җир идәнне яхшылап себерде, чәчелеп яткан инструментларны тәртипләп тезеп куйды, учакны кабызып җибәрде.

Тимерче, алачык ишегеннән атлап:

– Кем монда шаяра? – дип кычкырды.

– Хәерле иртә, Сөләйман абзый, – диде Газинур аңа каршы.

– Пумушник әллә килеп тә җиткәнме?

– Йокыдан чүмәлә өеп булмас, Сөләйман абзый.

– Ә үзең кичә, безнең колхозчылар хатыннарының җылы куеннарына иртәрәк ятарга ашыгалар, дидең.

– Минем хатын керпе кебек чәнечкеле шул, Сөләйман абзый. Күп йоклатмый.

Тимерче елмайгандай итте дә, күн алъяпкычын биленә бәйләп, кырыс кына:

– Ярар, башлыйк. Эш вакытында ләчтит сатуны яратмыйм. Бүген сабаннардан тотынабыз. Әнә теге төрәннәрнең пычакларын алып кил әле.

Газинурның алачыкны тәртипкә китерүеннән ул канәгать идеме, юкмы – әйтүе кыен. Һәрхәлдә, Сөләйман берни булмагандай эшкә кереште.

Газинур төрән пычакларын алып килде. Тимерче аларны кулында әйләндереп карады да берсе артыннан икенчесен учакка тыкты. Газинур өрдерергә кереште. Пычаклар кызып җиткәч, Сөләйман озын саплы келәшчә белән аларның берсен эләктереп алып сандалга салды да бәләкәй чүкечен чыңлатып суга да башлады. Газинур дәү чүкеч белән тимерче күрсәткән урынга кайрылып-кайрылып бәрергә тотынды.

Газинурга бер генә нәрсә ошамады: тимерче эндәшмичә, шаяртмыйча, җырламыйча эшли. Газинур аны җанландырып җибәрергә тырышып караса да, берни чыкмады. Тимерченең иреннәре ачылмадылар. Тик төшке ашка туктар алдыннан гына:

– Синең, Газинур, бүген кулларың түгел, телең авыртачак, – диде. – Күп сөйлисең.

«Мыштым Газзәнне сиңа ярдәмче итеп бирәсе иде. Менә пар килер идегез», – дип уйлады Газинур, ләкин телдән башкача әйтте:

– Ни дип, Сөләйман абзый, сүз кушмый эшләргә, без мәчеттә утырмыйбыз ла.

Тимерче кулын селтәде дә ашарга китеп барды.

## 21

«Красногвардеец» кырларында язгы чәчү гөрли. Председатель Хәнәфи колхозның иң яхшы атларын, иң яхшы сабанчыларын, иң яхшы чәчүчеләрен кырга чыгарды. «Урта кулка» сабанчыларның һай-һуларыннан, кычкырып җырлауларыннан яңгырап торды. Хәзер колхозның үзәк хезмәт мәйданы, иң күңелле урыны биредә иде. Председательне дә бары тик биредә генә табарга мөмкин. Ул, Чаптарны тарантаска җигеп, киң кыр буйлап сабанчыларның әле бер төркеменә, әле икенчесенә, әле чәчүчеләр янына ашыга. Чаптар юл сайлап тормый, ул кырлар буйлап турыдан йөрергә күнеккән ат. Тарантас түренә утырып, «Красногвардеец»ның калкулыктагы кырлары буйлап барган Хәнәфигә үз колхозының басуы гына түгел, тирә-як колхозларның чәчүлекләре дә ап-ачык күренә. «Заря», «Прогресс», «Тигез басу» кырларында тракторлар эшли. Хәнәфи аларга озак карап бара. Шәп нәрсә ул трактор дигәнең. Әле кичә генә алар «Красногвардеец» кырларын шаулаталар иде, бүген әнә кайда. Тракторчыларның бригадиры Исхак Зәбиров, Хәнәфи белән саубуллашканда:

– Урып-җыюга кадәр, Хәнәфи абзый, – диде. – Чәчүне кызу тоттың.

– Койрыкларың бар әле, – дип көлемсерәде Хәнәфи. – Синең тракторларың бөтен җиргә дә керә алмый бит.

Хәнәфи шул турыда уйлый-уйлый тирә-яктагы авылларга күз төшерә – алар да «Красногвардеец» кырыннан ап-ачык күренәләр. Әнә Петровкада яңа мәктәп салдыралар, Наратлы авылына өч йөк машинасы бер-бер артлы кереп бара, Бөрәшәүдә янгын каланчасы күтәргәннәр, Ивановканың силос башнялары калкып чыккан...

Биектә-биектә, зәңгәр күк йөзендә, тургай сайрый. Хәнәфи, башын күтәреп, аның гаҗәеп матур җырына колак сала. Шул чакта Чаптар кешнәп җибәрә. Уйлары бүленгән Хәнәфи тирә-ягына карана. Урман буенда чәчү машиналары эшли. Хәнәфи атын шунда таба бора.

Алдагы чәчкеч артына баскан Газинур, корыч сотникларга алтын бодай агуын күзәтеп, бөртекләрне куллары белән тигезли. Гүя бодай бөртекләрен җылы кара туфракка озата, аларның исән-сау шытып чыгып, ямь-яшел диңгез булып дулкынлануларын тели. Хәзергә аның артында кара туфрак тасмалары гына сузылып калса да, аңа бодай шаулый күк тоела.

– Буламы, яшь егетләр, яшь кызлар?! – дип кычкырды Хәнәфи, үзе тарантастан төшеп, чәчкечләргә ияреп бара башлады.

– Була! – дип, яшьләр бердәм җавап бирделәр.

Хәнәфи Газинур янына килде:

– Йә, эшләр ничек, Газинур?

– Ал да гөл, Хәнәфи абзый. Орлык чиста, эре. Менә дигән кондиция!

Газинурның соңгы сүзеннән Хәнәфи көлеп куйды. Аннары, мыегын борып:

– Ә сөенчегә нәрсәң бар, мут егет, йә әле, чиш янчыгыңны! – диде.

Газинурның күзләре шар булды. Кичә Миңнурыйны, Газинур кырда чакта, Бөгелмәгә бала тудыру йортына озатканнар иде. Бүген иртән аның сәламәт котылуы турында колхозга телефоннан шалтыратканнар.

– Нәрсә, шатланмыйсыңмы әллә? – диде Хәнәфи, бер сүз әйтә алмый торган Газинурга карап. – Кызың бар, юләр!

– Кызым? – дип, Газинур тыны кысылып кычкырды. – Ә әнисе ничек, әнисе исән-саумы, Хәнәфи абзый?

Баланы алар бераз соңрак көтәләр иде. Ни булды икән? Миңнурый бер-бер авыр әйбер күтәрмәдеме икән?

– Борчылма, – диде Хәнәфи, – хатының да сәламәт, balaң да сәламәт.

Хәнәфи икенче чәчкечкә таба китте, ә Газинур, шатлыгына чыдый алмый, орлык китерүче кызга кул болгап:

– Нәсимә, кызым бар, кызым! – дип кычкырды.

Миңнурыйны алты көннән соң Гафиятулла бабай белән Мәйсәрә апа алып кайтты. Кыр эшләре бетеп җитмәгәнгә, Газинур үзе бара алмады. Өенә ул бары тик караңгы төшкәч кенә кайтты. Ишектән атылып керүгә, шатлыктан ярсыган тавыш белән:

– Кая минем кызым! – дип кычкырды, үзе кемдер, әтисе булса кирәк ясап биргән сиртмәле бишеккә таба юнәлде.

Миңнурый аның юлына аркылы төште:

– Чү, өстең салкын, балага салкын тидерерсең. Чишен башта.

Газинур Миңнурыйны кочаклап үпте дә, тиз-тиз өстенбашын чишенеп, яңадан бишеккә омтылды. Миңнурый тагын аны балага якын җибәрмәде:

– Юк, элек кулларыңны ю, аннары мичкә терәп җылыт!

Газинур бер сүз әйтми хатынының кушканнарын эшләде. Ул кулларын юып ак сөлгегә сөртте дә кайнар мичкә терәде.

Миңнурый бишек янында баскан килеш баланы тирбәтә. Йөкле вакытта гәүдәсе юанайганга зифалыгын

җуйган Миңнурый хәзер яңадан кыз вакыттагы кебек чибәрләнгән. Газинур аңа сөеп карап торды да, бер сүз әйтми аның янына килеп, иңнәреннән кочаклады. Аннары тирән хөрмәт, олылау һәм ихтирам белән беренче тапкыр:

– Әнисе! – диде.

– Менә тора-тора төрҗәгун! – дип, иркәләнеп көлеп җибәрде Миңнурый. – Кайтып керүенә бер гомер үтте, хәл сорашу юк, исәнме юк – әнисе!

– Йә әле, кызымны күрсәт инде, – диде Газинур, уңайсызланып.

– Кызым, кызым, дип өзгәләнәсең, ә үзең бишек тә әзерләп куя белмәгәнсең.

Газинур, аптырап, кулларын җәеп җибәрде:

– И-и! Искә дә килмәгән бит, шайтанны!

– Әй, минем хәсрәтем! – диде Миңнурый, саклык белән генә баланың битен ачты. Бала, күзләрен йомып, әкрен генә мышнап йоклый иде.

– Нинди нәни! Чыпчык баласы хәтле генә! – дип пышылдады Газинур, иелеп баланың җылы маңгаеннан үпте. Бала, тынычсызланып, башын боргалап алды.

Миңнурый, бәхетле елмайган килеш:

– Үпкәнне яратмый ул, бик назлы, – диде.

Газинур балага текәлеп карап торды да:

– Үземә охшый икән, – дип куйды, – ух син, күк күгәрченем минем, сандугачым, былбылым.

Миңнурый баланың битен япты.

– Җитәр, – диде ул шаян гына, – югыйсә балага бөтен яраткан кошларыңның исемнәре белән дәшә башларсың тагы.

– Ә исемен ничек куштырабыз? – дип сорады кинәт Газинур.

– Син яраткан исемне, – диде Миңнурый, – синең кызың.

Балага Сәмига дип исем бирделәр.

Хәзер инде Газинур, эштән кайткан саен баласын кулына алып сөймичә, өстәл янына утырмый. Вакыты булганда ул аны сәгатьләр буенча иркәләргә әзер. Ул балаларга карата бик күп такмаклар белә, шуларны әле берни дә аңламаган кызына бертуктаусыз кабатлый иде:

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Бәбкәенә бүләккә.

Шундый бәхетле минутларның берсендә, бер дә көтмәгәндә, аларга районнан сабан туена кайткан Гали аб-

зый килеп керде. Газинур белән Миңнурый аны ачык йөз белән балалардай сөенеп каршы алдылар. Миңнурый шунда ук самовар куеп җибәрде. Гали абзыйдан исәнлек-саулык сораша-сораша өстәл әзерләде.

Гали абзыйның өстендә кара костюм (элек ул күбрәк күгелҗем йон гимнастерка кия торган иде), аягында ботинка. Йөзе бераз түгәрәкләнә төшкән, яңакларында алсулык та бар. Бритва белән кырдырган башының маңгай өсте ялтырап, чигә тирәләре күгелҗемләнеп тора.

Ул кесәсеннән тәмәке савытын чыгарды. Ләкин бишеккә күз төшереп алгач, кесәсенә кире тыкты.

– Ярамый икән, өйдә кечкенә бар, – диде ул, елмаеп. – Йә әле, күрсәтегез батыр кызыгызны. Исеме ничек, Сәмигамы?

Миңнурый, җиңелчә кызарып, бишектән баласын алып килде. Гали абзый, бармагын баланың нәни ияк астына куеп, иренен чупылдатып алды. Бала елмайган сыман авызын ачты да кинәт елап җибәрде.

– Әттә-тә, батыр кыз, – диде Гали абзый, – кунак абыйга ачуланырга ярыймы соң?

– Бир әле Сәмигамны, – диде Газинур, кызын кулына алып, очындыра-очындыра такмаклый башлады:

Үч-үч, үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки,
Үсәр әле, зур булыр,
Бигрәк матур кыз булыр.

Бала шунда ук елавыннан туктады.

– Харап инде, әтисе иркәләдеме, җан рәхәте килә. Әти кызы булыр, ахрысы, – диде Миңнурый.

Чәй эчкәндә, Гали абзый, аларның икесенә берьюлы карап:

– Йә, ничек торасыз? – дип, тормышлары турында сораштыра башлады, Газинур белән Миңнурый, бер-берсенә карашып алып, икесе дә көлеп җибәрделәр:

– Күгәрченнәр кебек гөрләшеп торабыз.

Бу гомуми сүзләр генә Гали абзыйны канәгатьләндермәде. Ул җентекләп сораштыра башлады. Колхозда ничек эшләүләрен дә, өйдә үзара ничек торуларын да белеште.

– Мин Хәнәфи белән сөйләштем. Колхозда икегез дә яхшы эшлисез, ди. Монысы иң әһәмиятлесе. Монысы өчен мин икегезне дә мактыйм, икегез өчен дә куанам. – Гали абзый бераз эндәшми торды, инде суына башлаган чәен, Миңнурыйдан кайнарлаттырып, бер-ике йотым эчте дә сүзен дәвам иттерде: – Мин сезнең үз кешегез... Минем

сезгә туры итеп, каты итеп әйтергә хакым бар. Күрәм, Миңнурый кулыннан килгәннең барысын да эшләгән, өй эчегез чиста, гөлләр дә бар, сөлгеләр дә. Менә сәгатегезне күрмим. Шүрлегегездә китапларыгыз да аз. Ишегалдыгыз да бөтен яктан ачык...

– Газинур менә... – дип сүзгә кушылды Миңнурый. – Колхоз дисә – үлә, өй эшенә бер дә күңел бирми.

– Тукта әле, әнисе, – диде Газинур әкрен генә, – менә, яхшымы, яманмы, өй алдык, сыер алдык. Болар бит барысы да бер ел эчендә. Менә быел тагын колхозның игене уңып, хезмәт көненә былтыргы кебек җидешәр-сигезәр килодан бүлик – өй эчен дә аллы-гөлле итәрбез. Бөгелмә кибетендә күреп кайттым – менә дигән шарлы тимер кроватьлар бар. Гарәфи абзыйларныкы кебек. – Ул бераз уйлап торды да, көтмәгәндә: – Ну кроватьтан бигрәк радиоприемник алыр идем әле, – диде.

Миңнурый, хәйран калып, кулларын ботына сукты. Гали абзый да көлемсерәп куйды, тавышындагы катылык та бетте. Ул инде бөтенләй икенче төрле итеп сүзен очлады:

– Сез мине ялгыш аңлый күрмәгез: үз оягызга, әрләән кебек, бөтен нәрсәне ташыгыз димим. Газинур дөрес әйтә, колхозда булса – колхозчының өендә дә була. Шулай да читтән килгән бер кеше өегезгә керсә, аптырап калырлык булмасын. Культуралы итеп тора башларга бик вакыт. Моңа сезнең мөмкинлегегез дә бар. Төшендегезме?

– Бераз гына, – диде Газинур, елмаеп. Шуннан ул, сүзне бик оста гына итеп икенчегә борып җибәреп, Гали абзыйдан Авыл хуҗалыгы күргәзмәсе турында сораштыра башлады. Аннары сүз үзеннән-үзе колхозда электростанция салуга күчте, шунда гүя сүз арасында гына, гүя гади бер танышы турында сорагандай гына Газинур Гөлләр турында сорап куйды. Казанга барганда Гали абзый, янәсе, аны күрмәгәнме.

Гөлләр исемен ишеткәч, Миңнурый иренә усал карап алды. Ул моннан өч ел диярлек элек клубта Газинурның Гөлләргә сокланып карап утыруларын, аның белән колактан-колакка сөйләшүләрен, кара-каршы биюләрен әле дә оныта алмый иде.

– Гөлләр дисә, үзәкләре өзелә, – диде ул, үпкәле тавыш белән. – Казанда аны эзләп йөрергә Гали абзыйның вакыты күп ди.

– Көнләшә дә беләсеңмени, Миңнурый? – дип сорады Гали абзый, шаяртып.

Миңнурый өчен Газинур җавап бирде:

– Коточкыч көнче, Гали абзый.

– Әбәү, синең кай җиреңне көнләшим?

Кемдер ишек дөбердәтте, ул да булмады, бүлмәгә яңгырга чыланган Һашим килеп керде. Кунак барын күргәч, бераз каушый төшебрәк ишек төбендә туктап калды.

– Саумы, Гали абзый!

– Исәнме, Һашим! Яңгыр явамы әллә?

– Чиләкләп коя. Бәйрәмнең бөтен ямен җуя.

– Әйдүк, Һашим, өстәл янына уз, чәй ясап бирәм, – диде Миңнурый.

– Рәхмәт, чәй эчеп тормыйм. Мин ашыгыч йомыш белән кергән идем.

– Кемгә, миңамы? – диде Газинур, урыныннан торып.

– Юк, Миңнурыйга... Бүген клубта безнең үзешчән түгәрәк «Галиябану»ны күрсәтмәкче иде дә Галиябануны уйнаучы кызыбыз авырып китте. Менә хәзер нишләргә белми аптырап торабыз. Иптәшләр Миңнурыйга җибәрделәр. Кыз чакта ул Галиябануны бик оста уйный торган иде.

– И-и, тапкансың, Һашим, искә төшерер чакларны... Хәзер минем нәни балам бар. Аны кайда калдырыйм? Ул бит минут саен уяна.

– Ул турыда без уйлаштык. Гөлҗиһан әбине китерәбез.

– Кит, кит, Һашим! Гөлҗиһан әбигә бала ышанаммы соң?! Ул үз балаларын да карый белмәде. Безнең Сәмига бик елак кыз. Әтисеннән башка беркемне дә тыңламый.

Һашим, ни дияргә белмичә, әле Миңнурыйга, әле Гали абзыйга, әле Газинурга карый иде. Ә Гали абзый идән уртасында баскан килеш, кулына кепкасын алып, китәргә җыена, нигәдер көлемсери. Мөгаен, нишләрләр икән бу ике юләр, дип уйлый торгандыр.

– Нигә Әлфия уйнамый? – дип сорады Миңнурый,

– Карчык ролен уйный ул. Карчык булырга бик ярата. – Һашим, өметен тәмам өзәргә теләмичә, тагын Миңнурыйга карады: – Әтисеннән башка беркемне дә тыңламыймыни?

– Юк шул... әти кызы ич ул.

Газинур көлеп куйды.

– Һашим дус, буең кыска, акылың тагын да кыскарак. Син мине юкә чөй белән чөйләмичә тор әле. Тел очында ни торганны сизәм: хатыныңны театр уйнарга җибәреп, үзең балага нәнки булып кал, дисең. Шулаймы?.. Эшләрең шәп, Газинур, моннан да ары шәп булмый да.

Бу сүзләрне Газинур шундый эчкерсез беркатлылык белән әйтте, өйдәгеләр барысы да шаркылдап көлеп җи-

бәрделәр. Бала, куркып уянып, кычкырып елый башлады.

– Чыннан да эшләрең шәп түгел икән, Газинур, – диде Гали абзый, Һашимга борылып. – Тиз башланамы соң спектаклегез?

– Клубта халык шыгрым тулган да бит...

– Ә Хәлилне кем уйный? – дип сорады Газинур кинәт.

– Сәлим.

– Ә?!

Газинур кулын селтәп алды:

– Юк, башка бер кеше булса, бәлки, нәнки булып калырга да риза булыр идем. Ә Сәлим булгач... ник дөнья җимерелми!..

Газинурның ни өчен каршы килүе барысына аңлашыла иде. Сәлим әле булса Миңнурыйны оныта алмый. Ул һаман да әле өйләнмәгән, чынмы, ялганмы: «Миңнурый булмагач, бүтәнне алмыйм», – дип әйтә, имеш.

Гали абзый ишек янына килде, кепкасын киде.

– Ярый, Миңнурый, хуш булып торыгыз. Иртәгә Галимә апагыз үзебезгә дәшәр. Ә син, Һашим, башыңны имә. «Красногвардеец» хатын-кызлары кызарып утырмасалар, Галиябану ролен үзем уйнармын. Яшь чакта минем дә уйнаганым бар.

Бу сүзләре белән Һашимны гына түгел, Газинур белән Миңнурыйны да аптырашка калдырып, Гали абзый чыгып та китте. Бер минут чамасы ни әйтергә белми торгач, Һашим тирән генә көрсенеп куйды:

– Нишлибез инде?

Миңнурый сүзсез генә киенә башлады.

– Син кая? – дип сорады Газинур, гаҗәпләнеп.

– Театр уйнарга, – диде Миңнурый салкын гына.

– Ә бала?

Газинур, ике кулы белән башын кысып, урындыкка утырды.

– Һашим, син бар, без хәзер килеп җитәбез, – диде Миңнурый.

Һашим шунда ук атылып чыгып та китте. Миңнурый Газинур янына килде, аның кара чәчләреннән сыйпап, янына утырды.

– Син дә көнче икәнсең, Газинур, – диде ул әкрен генә. – Иптәшләрнең хәленә керергә кирәк ләбаса. Театр уйнаудан ни була? Мин бит барыбер синнән башка беркемне дә яратмыйм, яратмам да!

Газинур башын күтәрде, гаҗәпләнеп хатынына карады:

– Ә үзең көнче түгелмени? Әле генә Гөлләр өчен күзләреңнән миңа нинди уклар аттың. Ә минем Гөлләр

белән театр уйнаганым юк. Әгәр уйнасам, син нишләр идең икән?

– Кайсыгыз яхшырак уйный дип карап утырыр идем.

– Утырыр идеңме икән, чәченә барыпябышыр идеңме икән?

Миңнурый кашларын җыерды, бик җитди итеп җавап бирде:

– Син мине ул хәтле тиле дип уйлама әле, Газинур. Әйдә киен, киттек. Гали абзый да килеп җитәр.

Газинур бераз уйланып утырды да:

– Эх, беткән баш беткән! – дип урыныннан торды. – Ә Гали абзый безне шәп итте, йомшак тотып, каты җиргә утыртты.

– Шул кирәк безгә! – диде Миңнурый.

...Гали абзый алдагы рәтләрнең берсенә килеп утыруга, пәрдәне ачып та җибәрделәр. Ләкин «Галиябану»ны чын профессиональ артистлар уйнаганын да, театр турында һични белмәгән авыл яшьләре уйнаганын да әллә ничә тапкыр күреп, элегрәк елларда авыл сәхнәсендә үзе дә уйнап йөргәләгән Гали абзый, сәхнәгә күз салудан бигрәк, Газинурны эзләде. Әнә алгы рәттә утыра икән. Кулында ак юрганга төргән бала. Еламасын өчен әкрен генә тирбәтеп тора. Ә зур кара күзләре очкын белән тулы.

– Молодец, – диде Гали абзый эченнән һәм сәхнәгә борылды. Анда, авыл урамында, егетләр, гармунга кушылып, Галиябану көенә җырлыйлар, Галиябану – Миңнурый, тәрәзә яңагына сөялеп, аларга карап тора...

## 22

Шулай матур яшиләр иде алар. Әгәр фашистлар сугыш ачмаган булса, алар, туган «Красногвардеец»ның бәрәкәтле кырларында дәрт белән эшләп, бүген дә шулай тыныч, бәхетле гомер кичерерләр иде. Алар үз колхозларының тагын ике-өч елдан соң да, биш-ун елдан соң да нинди булачагын күз алларына бик ачык китерәләр иде: ул чагында инде «Красногвардеец»ның үз электростанциясе күптән салынып беткән булачак, бөтен эшкә электр җигелгән, кырларның уңышы ике-өч тапкыр арткан, арышларның, бодайларның, тарыларның, бәрәңгеләрнең сортлары яхшырган, терлекләрнең дә, атларның да нәселләре үзгәргән, кошчылык фермалары гөрләп тора, авыл башында, тау итәгендә, тау араларында җиләк-җимеш, алма-чия бакчалары шаулап үсә, һәр өйдә радио сөйли, яңа мәктәп, хата-лаборатория, уку йорты, балалар бакча-

сы йорты, яңа клуб. Телисең икән, кинога бар, телисең икән, лекция тыңла, телисең икән, үзешчән түгәрәгенең постановкасын кара. Колхоз председателе Хәнәфи дә, әй, Әптери малай, май заводына йөгер әле, фәлән матур апаны казлар фермасыннан тиз генә чакырып кил әле, дип тормас, ә телефон трубкасын алыр да, центральный, тимерчелек мастерскоен... Тегермәнне... Сепараторныйдан Миңнурыйны... электростанция, монтер Газинурны... дип, кабинетыннан чыкмыйча гына кирәкле эшләре турында сөйләшеп алыр, күрсәтмәләрен бирер...

Кыш көне Газинур бик ныклап укырга әзерләнә иде. Колхоз председателе Хәнәфи аны Бөгелмәгә терлекчеләр курсына җибәрергә вәгъдә итте. Ләкин 1939 һәм 1940 елларның кышы хәвефле булды. Ил өстендә күптән җыелып килгән давылның беренче яшене яшьнәде: Америка, Англия империалистларының котыртуы буенча Финляндия сугыш ачты. «Красногвардеец»ның өч егете – Газинур, Мисбах һәм Газзән Кызыл Армия сафына чакырылды. Алар өчесе бер көнне киттеләр, бер отделениегә туры килделәр. Сугышка да бергә керергә җыенганнар иде, ләкин аларга сугышка керергә туры килмәде. Хәтта фронтка да барып җитмәделәр, аларны ярты юлдан – Вологдадан кире кайтардылар. Кызыл Армиянең көчен үз сыртларында татый башлаган ак финнар бик тиз сугышны туктатуны сорадылар.

Ай ярымнан соң, яңадан колхозга кайткач, Мисбах белән Газзән солдат киемнәрен, шунда ук үзләренең тумыштан ияләшкән, шуңа күрә тәнгә якынрак та, җылырак та булып тоелган үз киемнәренә алмаштырдылар. Газинур исә, колхозга кайткач та, солдат киемнәреннән аерылырга теләмәде. Салкынрак көннәрдә – шинельдән, көннәр җылыта башлагач, гимнастеркадан, билен каеш белән буган, башына йолдызлы шлем кигән килеш йөрде. Шушы килеш ул, Бөгелмәгә барып, рәсемгә дә төшеп кайтты.

– Кара әле, әнисе, Газинур солдатны! – диде ул Миңнурыйга, ярты открытка зурлыгындагы, осталыгы бик таман булган фотограф төшергән рәсемне сузып.

Миңнурый, ялтыравыклы юка кәгазьне кулына алып, аңа озак кына карап торды. Газинур аягүрә басып төшкән. Уң кулы белән өстәл кырыена таянган, сул кулының бармакларын җиңелчә генә бөккән. Башында йолдызлы буденовка, өстендә гимнастерка, билендә киң каеш, каешына ат куган чыбыгын кыстырган. Ләкин Миңнурыйга аның киеме түгел, йөзе кадерле. Кара күзләре каядыр еракка карый һәм ниндидер бик мавыктыргыч, бүтәннәр күрми торган бернәрсәне күрә кебек. Кара кыйгач каш-

лары, гаҗәпләнгән сыман, азрак өскә күтәрелгән. Бераз калынрак иреннәре чак кына ачылган...

– Нәкъ үзең инде, – диде Миңнурый. – Суйган да каплаган, – диде Газинур.

Миңнурый гадәтенчә көлемсерәп куйды, үзенә хас шаянлык белән:

– Иреннәреңне кыса төшсәң, чыбыгыңны алып ташласаң, үземә охшамас дип курыктыңмы? Аннары, кесәләреңә шулхәтле нәрсә тутырдың? Рәсемгә төшәргә баруыңны алдан әйтсәң, ичмасам, гимнастеркаңны әйбәтләп үтүкләп биргән булыр идем, – диде.

Кызыл Армиядә аз гына булып кайтканнан соң, Газинурның тышкы киемендә генә түгел, холкында да күп кенә яңа үзгәрешләр сизелә башлады. Дөрес, ул әле һаман да әүвәлге кебек шук, шаян, җырчы, ләкин шул ук вакытта аңарда инде яшьлекнең юләр җиңеллеге, беркатлы гамьсезлеге бетә төшкән. Хәзер аның йөрәгендә гүя күзгә күренми торган ниндидер бер пружина эшли башлаган, бу пружина аның барлык рухи көчен бер учка җыя кебек. Күз алдын каплап торган алсу пәрдә дә ачылды шикелле, әйләнә-тирәдәге тормыш, кешеләр, аларның үзара мөнәсәбәтләре, эшләре хәзер элеккечә гади булып күренми иде инде аңа. Ул аларның катлаулылыгын күрә, иске белән яңа арасында барган өзлексез көрәшне күрә. Дөрес, тормыш арбасында Газинурның бервакытта да түләүсез юлаучы булганы юк иде, ләкин ул күбрәк гамьсез яшәде, тормыш сикәлтәләрен, урамдагы яңгыр сулары тулган чокырларны уйнап-көлеп аркылы чыккан кебек, бик җиңел үтте. Билгеле, уйласаң, тормышның уйларлыгы бар иде.

Финляндия вакыйгасыннан соң ул сугыш куркынычына реальрәк карый башлады. Шулай да дошманнар хәзер Кызыл Армиянең көчен тагын бер тапкыр күрделәр – моннан соң алар ут белән җиңел шаярмаслар дип уйлый иде. Латвия, Литва, Эстония һәм Бессарабиянең Советлар Союзына кушылуы аның күңелен тагын да күтәрә төште, аңа болар барысы да сугыш куркынычын бик еракка этәргән кебек тоелды. Шуңа күрә газиз туган илебездә яңадан сугыш башланган көнне дә аның бөтен уе тыныч хезмәткә төбәлгән иде.

Кичтән бригадир Габдулла, правлениедә Газинур белән Мисбахка наряд биреп:

– Иртәгә сез ике сабан белән «Йөрәк»кә барырсыз, – диде.

«Йөрәк» дип «Красногвардеец»та урман эчендәге, йөрәккә охшаган кечкенә генә бер аланга әйтәләр иде.

Бу аланга колхоз орлыклык өчен көздән яңа сорт арыш чәчәргә исәпли иде.

Газинур белән Мисбах «Йөрәк»кә таң беленә башлагач ук киттеләр. Ә кояш тәртә буе күтәрелгәндә, алар байтак җирне сөреп тә өлгергәннәр иде.

Газинур беренче сабан белән алдан бара. Ул бер кулы белән ике төрәнле сабанның шомарып беткән тоткычыннан кыскан, икенче кулы белән дилбегәсен тотып, атларын әйди. Ул олы тояклы булганы өчен Чабата дип йөртелгән туры ат белән Малина исемле җирән кашка байталны җиккән. Симез, олы атлар сабанны җилтерәтеп кенә алып баралар. Җир дә йомшак. Көзгедәй ялтырап торган төрәннәр кара карга канаты шикелле чемкара, симез туфракны уйнап кына актаралар. Газинур әле сызгырып куя, әле, атларын иркәләп, аларга ягымлы сүзләр кычкыра, әле бөтен кырны яңгыратып кычкырып җырлап җибәрә. Башындагы шлемын артка этәргән, кояшта уңарга өлгергән гимнастеркасының якасын ычкындырган. Озынча йөзеннән тир ага. Ул туфраклы кулы белән уң яңагын сыпырып алган булса кирәк, бармак эзләре сузылып калган.

Мисбахетдин шактый артта калып атлый. Хуҗа ашыкмагач, атлары да теләр-теләмәс кенә кыймылдыйлар. Мисбах аларга кычкырмый, тик ара-тирә арт саннары өстендә чыбыркысын гына шартлатып ала. Шуннан атлар бераз кызулата төшәләр дә, яңадан онытылып, ашыкмыйча гына үз җайларына бара бирәләр.

Мисбах эш вакытында бөтенләй диярлек кычкырып җырламый, бик җырлыйсы килсә, авыз эченнән генә нидер көйләгән була.

Сабан артыннан ул әйдәүче булып түгел, ә күләгә шикелле, мәҗбүри рәвештә тагылып бара кебек. Ләкин аның турында ялкау дип тә, эш сөйми дип тә әйтеп булмый. Ул беркайчан да бүтәннәрдән ким эшләми, әпентөпен дә эшләми, шул ук вакытта уздырмый да. Ул бер яктан да гаепләп булмый торган урта кул кеше иде. Янып, җилкенеп эшләргә яраткан Газинур кайчакта, ярым шаяртып, ярым җитди итеп:

– Абый, телисеңме, мин сиңа үз йөрәгемнән очкын алып бирәм, – дип әйтә иде. Мисбах Газинурны яратканга, бигрәк тә Газинурның мыскыл итү өчен түгел, ә эчкерсез йөрәктән әйткәнлеген яхшы белгәнгә, аңа һич тә ачуланмый, тик түбәнчелек күрсәткәндәй, чикләвек төсле коңгырт күзләре белән елмая гына иде.

Газинур, җир башына барып җитеп, атларын туктатты, сабан төрәннәрен калак белән чистартырга кереште.

Бу эшне дә ул эленке-салынкы гына эшләми, ә үзенчә ниндидер тәм, шигърият белән эшли. Аның кечкенә агач калагы тиз-тиз хәрәкәтләнә, ә төрәнгә ябышкан туфрак төерләре әллә кая очалар.

Төрәннәрен чистартып бетергәч, Газинур сынын турайтты, уң кулын бөеренә куеп, әле җирнең яртысына гына җитеп килгән Мисбахетдинга таба борылды.

– Абый, ташбака кебек кыймылдыйсың, буксирга алам үзеңне! – дип, урманда чакта еш әйтелә торган «буксир» сүзен кыстырып кычкырды. Аннары атларының камыт асларын карап, муеннарыннан, арт саннарыннан сыйпаштырып алды да: – Әйдә әле, малкайларым! – дип, Мисбахетдинның килеп җитүен дә көтмичә, тагын кузгалып китте. Тагын аның дәртле җыры алан буйлап яңгырады:

Кырда ускән җитеннәрнең
Матур була чәчәге.
Матур колхозның бу көне,
Күңелле киләчәге.

Газинур үз тавышына үзе сокланып җырлый торган кеше түгел иде. Шулай да бу минутта ни өчендер аңа кушылып бөтен тирә-як җырлый кебек тоелды. Үткен төрәннәр актарган чем-кара туфрак та, «Йөрәк»не урап алган ямьле урман да, андагы кош-кортлар да, фирәзәдәй зәңгәр күк тә, шул аяз, якты күк йөзендә көлеп торучы кояш та – барысы да, барысы да аңа кушылалар кебек.

«Спасс сыртына якынлашып килгән ак күлмәкле, ак яулыклы бер хатын күренде. Ул бер кулы белән баласын җитәкләгән, икенче кулына шакмаклы кызыл ашъяулыкка төргән төенчек тоткан.

Бу иртән ашамый-эчмичә китеп барган Газинур белән Мисбахка төшке аш алып килүче Миңнурый иде.

Миңнурый килеп җиткәч, сабанчылар атларын туармыйча гына солыга куйдылар, үзләре, агач күләгәсенә утырышып, катык белән кайнар бәрәңге ашый башладылар. Аш янында да Газинур тавыш-тынсыз утырмады. Миңнурыйны көлдереп, әллә нихәтле шаян сүзләр сөйләде. Аннары, атлар солыларын ашап бетергәнче, кызын муенына атландырып, урманга кереп китте.

Инде ике яшь тулып, өченчегә киткән Сәмига әтисенең муенында үзен бик рәхәт сизде булса кирәк, кычкырып, кайбер авазларын йота-йота җырлап җибәрде:

Әйт әле, күбәяк,
Сөйләшик билгәяп...

Урман һавасы саф, бераз салкынча, хуш исле. Агач араларында әллә нихәтле ал, кызыл чәчәкләр. Үлән котырып үскән – Сәмиганың ал бантиклы башы гына күренә.

– Әтием, әтием, кара, мин кызыл чәчәк таптым, – дип кычкырып җибәрде ул һәм җете кызыл чәчәк алдында кулларын чаба-чаба сикергәләп биергә тотынды. Аннары аның күзе икенче чәчәккә кунган ак күбәләккә төште булса кирәк, ул тагын көчлерәк шатланып: – Әтием, әтием, миңа күбәяк килде, миңа күбәяк килде! – дип кычкыра башлады.

Газинур чәчәкләрдән таҗ ясап кызының башына киертте.

Менә алар тагын сабан сөрәләр. Миңнурый белән Сәмига чәчәкләрен күтәреп кайтып киттеләр. Кайтып киттеләр, әмма сабан артыннан барган Газинурның күз алдыннан башына чәчәк таҗы кигән, түгәрәк алсу йөзле кызы китмәде. Газинур аның киләчәге турында уйлый башлады. Сәмига, үсеп җиткәч, кем булыр: врачмы, агрономмы, зоотехникмы? Кем булса да булыр, хәзер аңарга укыр өчен бөтен юллар ачык, бөтен мөмкинлекләр бар. Ә Мөдәрриснең – хәзер аның улы да бар инде – инженер-электрик булуын теләр иде. Чөнки колхозның үз инженеры булырга тиеш ләбаса...

«Йөрәк»нең әле яртысы да сукаланмаган иде. Ә кояш чамадан тыш кыздыра башлады. Атлар тиргә батты, алар, кигәвен-черкиләрдән арыныр өчен, башларын, койрыкларын бертуктаусыз селкәләр. Газинур шешәгә салып алып килгән ачы исле карболканы аларның тиреләренә кош канаты белән сөртеп карады, файдасы аз булды.

– Газинур, кайтыйк булмаса, тәмам теңкәгә тиделәр, эшнең дә рәте юк, – диде Мисбахетдин. Газинур каршы килмәде.

Алар сабаннарын арбага салдылар да кайтырга да чыктылар. Атлар, гүя арыганлыкларын онытып, өйгә бик җәһәт атладылар.

Колхоз нибары ике-ике ярым километр ераклыкта иде. Зиратны узып, ындыр турысына җиткәч, бөтен «Красногвардеец» уч төбендәге кебек күренде. Колхозда ниндидер гадәттән тыш бер хәл бар, ахрысы, правление янына халык җыелган. Әнә тагын кемнәрдер йөгерә. Хатын-кызлар. Әнә урам уртасында озын ак күлмәк өстеннән җиңсез камзул кигән, кулына таяк тоткан Галәк бабай да бара...

Аякларын арба кырыеннан салындырып утырган Газинур, кулын каш өстенә куеп, алга омтылып карады да, борчылган тавыш белән:

– Абый, авылда бер-бер хәвеф-хәтәр булганмы әллә? Бөтен колхоз купкан бит, – диде.

Мисбах та авылга карый башлады. Шик юк, анда нидер бар. Әнә яңадан-яңа кешеләр правлениегә таба йөгерәләр.

Газинур белән Мисбах, ни дип юрарга да белмичә, атларын кызулаттылар, бераздан конный дворга килеп тә җиттеләр. Ат абзарлары ишеге төбендә аптыраган кыяфәттә Сабир бабай басып тора иде.

– Ни бар, Сабир бабай, нигә халык җыелган? – дип, арбага аягүрә баскан Газинур кычкырып сорады.

Сабир бабай калтыранган тавыш белән җавап бирде:

– Ишетмәдегезмени әле, балалар?! Сугыш!.. Гитлер, йөзе кара, безгә каршы сугыш башлаган... Халык митингка җыела...

Газинур бер секунд чамасы тын калып басып торды. Ул ихтыярсыздан тирә-ягына каранып алды: ремонттан чыккан жнейкалар, арбалар, сабаннар, туарылмаган атлар, тап-такыр ишегалды... Монда бөтен нәрсә хезмәт турында гына сөйли. Нигә ул сугыш? Кемгә кирәк? Кайда? Кемнәр ачкан аны?

Газинур арбадан сикереп төште дә митингка йөгерде. Хәнәфи абый, ниндидер биек әйбергә басып, кулларын болгый-болгый сөйли иде.

Мисбахетдин атларын туара башлады. Сабир бабай, аның алдына килеп, ничектер артык йомшак тавыш белән:

– Мисбахетдин улым... Син дә халык янына бар... Атларны үзем туарырмын, – диде.

Газинурга, Мисбахка һәм Газзәнгә военкоматтан инде повестка да килеп җиткәнлеге турында берьюлы әйтергә картның теле әйләнмәде.

## 23

Китәр вакытлар җиткән иде инде.

Өстенә искерә төшкән язгы пальто, аягына тула оек белән резина галош кигән Газинур, Миңнурыйның ике беләгеннән тотып, соңгы мәртәбә аның кадерле күзләренә текәлеп карады. Миңнурый гаҗәеп зур түземлелек күрсәтә иде. Йокысыз үткән төн аның матур йөзенә тирән кайгы эзен салса да, анда син киткәч, ике кечкенә бала белән мин берүзем нишләрмен, көнемне ничек үткәрермен дип аптырап өметсезлеккә төшү дә, тетрәү дә юк иде. Ул бер генә тапкыр да еламады. Тик менә хәзер, китәр минутта, Газинур аның ике беләгеннән тотып күзләренә текәлгәч кенә, аның озын керфекләре дерелдәп китте.

– Хуш, Миңнурый җаным, – диде Газинур әкрен генә. – Хуш, бәгырем. Әгәр кыерсыткан чакларым булган булса, кичер...

Миңнурый аны, ике кулы белән муеныннан кочаклап, кат-кат үбә башлады.

Кроватьларында уйнап утырган Сәмига белән Мөдәррис этиләре белән әниләренә гаҗәпләнеп карап тордылар. Нәни балалар берни дә аңламыйлар иде.

– Кирәкми, Миңнурый, кирәкми, бәгырем, елама. Дошманны җиңәрбез дә әйләнеп тә кайтырбыз, – диде Газинур. Аннары балалары янына килде, икесен ике кулына алды. – Зур үс, кызым, син дә, улым, зур үс, – диде ул, әле берсен, әле икенчесен үбә-үбә. – Тәти булыгыз, еламагыз.

Күз яшьләрен сөртеп, үзен яңадан кулга алырга өлгергән Миңнурый, Газинурның иңбашына кулын куеп:

– Үзеңне сакла, – диде. – Безнең өчен кайгырма. Колхоз безне ташламас. Балалар өчен дә борчылма. Мин аларны тәрбияләрмен. Без иртә-кич синең җиңеп кайтуыңны көтәрбез...

Газинур балаларын кроватьларына бастырды.

– Мин эткәйләргә күрешергә керим, Миңнурый. Син олаулар янына бара тор, – диде ул. Ишек тоткасына бер кулы белән тотынгач, туктап калды, артына борылды, зур кара күзләре белән моңаеп басып торган хатынына, балаларына карады. Аннары, йөгереп килеп, өчесен дә тагын тиз-тиз үпте дә, ишек башындагы чөйдән шлемын эләктереп, атылып чыгып та китте.

Ишегалдының уртасына җиткәч, Газинур авыр сулыйсулый туктады. Правление ягыннан гармун тавышы, кемнәрнеңдер җырлавы, халык гөрләве ишетелә. Урам уртасыннан үзенең кардәшләре белән Газзән үтеп бара.

Газинур урамга чыкмыйча гына, ишегаллары аркылы үтеп, этисенең өенә керде. Мисбах анда иде инде.

Сәкедә табын әзерләнгән. Сөйләшмичә генә берәр чынаяк чәй эчтеләр. Аннары Гафиятулла бабай табынны җыярга кушты. Шакмаклы ашъяулык өстендә, тәлинкәдә, телем-телем киселгән икмәк һәм тоз савыты гына калды. Менә табынны җыеп йөргән Шәмсинур җиңги дә сәке читенә килеп утырды. Ата-баба йоласы буенча бераз тынга калып утырдылар. Аннары картлар дога кылды. Шуннан соң Гафиятулла бабай дулкынланган тавыш белән соңгы сүзләрен әйтте:

– Сез туган илебезне сакларга китәсез, улларым. Батыр булыгыз. Батыр егет – яу күрке, диләр иде борынгылар... – Ул бераз эндәшми торды да өстәде: – Сез инде

хәзер ил хезмәтчеләре – бөтен халыкның күзе, өмете сездә. Семьяларыгыз, бала-чагаларыгыз турында борчылып, башыгызны кайгыга салмагыз. Без монда күмәкләшеп яшәрбез. Дошманны җиңеп, исән-сау кайтыгыз. Миннән теләк шул, балалар.

Гафиятулла карт күзләренә тыгылган яшьләрен кызыл кулъяулыгы белән сөртеп алды. Газинур белән Мисбах табындагы икмәкне сындырып кабып, бармакларын тозга тидереп яладылар да картлар белән саубуллаша башладылар...

Фронтка китүчеләрне озатыр өчен бөтен колхоз правление йорты янына җыйналган иде. Бер якта хатын-кызлар, алар белән янәшә «Красногвардеец»ның уйчан йөзле, урта яшьтәге ирләре баскан. Председатель Хәнәфи дә алар арасында. Икенче якта бүген-иртәгә повестка көтеп торган яшьләр тупланган. Сәлим гармун уйный, Һашим, Зәки, Бари, кулларын иңбашларына куеп, кычкырып җырлыйлар.

Урта бер җирдә «Красногвардеец»ның хөрмәтле картлары җыелган. Иң алда, таягына таянып, күлмәге тезләренә җиткән, аягына җылы каталар, башына түбәтәй кигән ап-ак сакаллы Галәк бабай басып тора.

Фронтка китүчеләрне Бөгелмәгә илтеп кайтыр өчен атлар килде. Тарантасларга колхозның иң яхшы атлары җигелгән иде.

Бераздан, үзенең җил капкасын ачып, Гафиятулла бабай урамга чыкты. Менә ул, озын гәүдәсен бөкрәйтә төшеп, ике улының ике беләгеннән тотып урам буйлап әкрен генә атлап килә. Өстендә кыска җиңле казаки. Ак күлмәгенең җиңнәре һәм итәге казаки астыннан күренеп тора. Аның иңнәрен авыр кайгы баскан. Ул бик авыр атлый. Менә ел ярым эчендә икенче тапкыр инде ул берьюлы ике улын сугышка озата.

Халык аны, тынып, хөрмәт белән каршы алды.

– Хәнәфи туган, – диде Гафиятулла бабай, председатель алдында туктап. – Менә ике улым... Икесен дә үз кулым белән илгә тапшырам. Балаларыма актыккы сүзем шул: явыз дошманны җиңеп кайтсыннар!

Хәнәфи йомшак күңелле кеше түгел. Ләкин бу минутта аңа да сүз табуы кыен булып китте.

– Рәхмәт, Гафиятулла абзый, рәхмәт, – диде ул, дулкынланып. – Бик зур сүзләр әйттең. Солдат өчен ата сүзе – командирның приказы кебек үк – изге. Газинур белән Мисбах аны җиргә салып таптамаслар.

– Ватаны юк – җыры юк сандугач ул, дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар иде, – диде Гафиятулла абзый,

ике кулын сузып. – Сандугач – җыры белән, ил азатлыгы белән матур.

Хәнәфи, аның ике кулын кысып:

– Рәхмәт, рәхмәт, Гафиятулла абзый! – дип кабатлады.

Гафиятулла абзый картлар янына китте, аннары, тарантаслар янына килеп, утырып китүчеләргә йомшак булсын өчен, печәннәрен кабарта башлады. Моны ул, гадәтенчә, үзалдына сөйләнә-сөйләнә эшләде. Хатын-кызлар, аңа карый-карый, күз яшьләрен сөртеп алдылар. Ирләрнең чырайлары тагын да уйчанланды.

Ат башында баручы малайлар кузлага менеп утырдылар. Гармун көчлерәк ярсый башлады. Газинур, яшьләр янына килеп, гармунга кушылып бер җыр җырлады:

Мылтык тоткан кулларымның
Көче бетмәс көрәштә;
Җанымны да кызганмамын
Илем өчен көрәштә.

Хәнәфи сәгатенә карап алды.

– Егетләр, юл кешеләренең юлда булганы яхшы, – диде тарантас өстенә менеп.

Тыныч вакытта аның сүзенә һәрвакыт колак салып килгән халык бу дәһшәтле көндә председательгә тагын да якынрак килде. Аның тыныч, ышанычлы тавышы һәркемгә көч бирә иде.

– Җәмәгать, – диде Хәнәфи үзенең ачык тавышы белән, – без бүген үзебезнең иң яхшы егетләребезне озатабыз. Иртәгә, бәлки, бүтәннәребезне дә чакырырлар. Ләкин колхоз эше туктамаска тиеш. Китүчеләрнең урынын буш калдырмас өчен без икеләтә-өчләтә көч куеп эшләргә тиешбез. Озакламый урып-җыю башланачак. Мин безнең хатын-кызларыбызга, кадерле картларыбызга мөрәҗәгать итәм: барыгыз да эшкә! Аптырарга, куркырга урын юк, Кызыл Армия дошманнарны каршы ала белер. Ә китүчеләргә сүзебез шул: сез анда «Красногвардеец»-ның данына тап төшермәгез!..

Икенче тарантаска Газинур сикереп менде. Аның йөзе җитди, күзләре үткен карыйлар иде.

– Колхоздашларым! – диде ул. Аның болай дип сүз башлавында җитлеккәнлеге дә, колхозына һәм халкына булган тирән мәхәббәте дә ташый иде. – Ил картлары, абыйлар һәм апалар! Яшьтәшләрем! Явыз дошман безнең туган илебезгә һөҗүм иткән. Ул безнең авылларыбызны, шәһәрләребезне яндыра, кешеләребезне, балаларыбызны үтерә. Ул, бәлки, безнең «Красногвардеец»ка да килермен дип уйлый торгандыр. Юк! Бу байлыкларны без, –

ул бөтен «Красногвардеец»ны кочкандай кулларын җәеп җибәрде, – фашистлар килеп таласын өчен торгызмадык. Без корал тота беләбез. Ә корал тота белгән – сөяленә бастырмас! Сез шулай дип әйтә идегез безгә, ил картлары! Без сезнең сүзләрегезне йөрәкләребезгә салып алып китәбез. Иптәшләр! Күңелегез тыныч булсын, «Красногвардеец» егетләре йөзгә кызыллык китермәсләр!

Газинур тарантаска ничек тиз сикереп менгән булса, шулай тиз төште дә. Төшү белән картлар төркеменә атлады, алар белән ике куллап саубуллаша башлады. Иң элек ул Галәк бабайның карт кулларын кысты:

– Хуш, Галәк бабай, исән-сау яшә.

– Хуш, Газинур улым, хуш! Исән-сау йөреп, җиңүче булып кайтыгыз. Безнең эткәйләр әйтә торган иде: «Ат – аенда, ир елында сыналыр». Бик зур сынауга барасыз, батыр булып кайтыгыз.

Атлар кузгала башлады, Газинур Хәнәфи янына омтылды. Хәнәфи аны күкрәгенә кысып, аркасыннан сөйде:

– Хуш, Газинур, хуш! Красногвардеецларча кыйнагыз дошманны.

Бер генә минутка да Газинурдан күзен алмаган Сәлим, ниһаять, бер җайлырак вакыт туры китереп, аның янына килде. Ул аска карый, тартына. Элекке һавалануыннан бернәрсә дә калмаган. Муенына аскан гармунының телләрен тавыш чыгармыйча тибрәтеп, күтәрелеп карамыйча сөйли башлады:

– Газинур, – диде ул, – мин сиңа карата... күп әшәкелек эшләдем. Урманда да, колхозда да... Син мине дошманың дип санап китә торгансыңдыр... Кыйнарсың дип тә көткән идем...

Бу сүзләрдән Газинурның көлеп җибәрәсе килде. Ләкин көлү түгел, елмаймады да. Үзен бер читтә көтеп торган Миңнурыйга карап алды да китә-китә әйтеп ташлады:

– Узган эшкә – салават, Сәлим. Киләчәктә болай булмассың дип ышанам.

Газинур йөгереп китеп баргач, Сәлим урам уртасында берүзе аска карап басып торды. Газинурның ашыгып әйткән сүзләре аңарда нинди тойгылар уятуын ул хәзергә үзе дә белми иде әле: аның елыйсы да, сүгенәсе дә килә иде. Аннары ул башын күтәрде, бөтен көче белән тартып, гармунын сыздырып җибәрде. Шунда ук кемнәрдер аның гармунына кушылып җырлый да башладылар.

Халык авыл очына кадәр озата барды. Басу капкасына җиткәч, озатучылар туктады. Газинур белән Мисбах,

Гафиятулла бабайның ике ягына басып, соңгы тапкыр аның белән күрештеләр.

– Әткәй, безнең өчен борчылма, башлар исән булса, кайтырбыз. Киленнәреңне ярдәмеңнән ташлама, – диделәр. Аннары хатыннары белән саубуллаштылар.

Сөекле һәм гүзәл Миңнурый! Ул бу соңгы минутта да үз-үзен нык тота. Газзәннең хатыны иренең муенына сарылып үкереп елаган чагында, Миңнурый күз яшьләрен дә күрсәтми иде.

– Мин сиңа ышанам, Газинур җаным, – диде ул әкрен генә.

Атлар Исаково үренә менәләр инде. Газинур, яңадан тарантаска басып, туктап калган колхоздашларына, этиәниләренә, хатыны, балаларына ерактан кул болгап, соңгы сәламен җибәргәндәй, сузып кычкырды:

– Хушыгыз! Ху-шы-гыз! Без кайтырбыз!

## Икенче бүлек

### 1

Газинурның күзенә йокы кермәде. Ул, югары сәкедә кырын ятып, кызыл вагонның кечкенә тәрәзәсеннән карап, тирән уйларга чумды. Күз алдына биленә патронташлар ураган, гранаталар таккан матрос килеп басты. Тачанкада Гали абзый, аяксыз пулеметчы җилеп үтеп киттеләр. «Менә без дә сугышка барабыз. Абыйларның данын саклый алырбызмы?»

Газинур белән янәшә уйчан йөзле Мисбах, караңгы чырайлы Газзән, кулларын баш асларына куеп, түшәмгә карап яталар. Алар да йокламыйлар.

Әкрен генә таң атты. Кояш чыкты. Кемдер гармун уйнап җибәрде. Кемдер Газинурга таныш булмаган борынгы солдат җырын башлады.

Поезд урман эченнән ыргылып чыга. Кечкенә тәрәзәдән иртәнге кояшның алтын нурлары сибелгән иген кырлары күренә башлый. Өлгереп килгән игеннәр әкрен генә дулкынлана, һәм гармун, җыр тавышлары арасында Газинурга бодай шаулавы ишетелгәндәй була. Бодай шаулавы! Кайберәүләр, бәлки, аны гомерләре буенча ишеткәннәре юктыр. Ә кырда, табигать кочагында үскән Газинур, бодай камыллары төбендә ятып, тук башакларның бер-берсенә әкрен генә ышкылып, гөжләп шаулауларын бик күп тыңлаганы бар. Башакларның гөжләве көннән-көн үзгәрә бара. Бары тик Газинур кебек җырчы егет кенә аларның үзгәреп торган нечкә музыкасын сизә, күңеленә бикли ала. Бодайлар өлгергәндә аларның гөжләвендә ниндидер үтенү, чакыру моңы була, алар гүя, тизрәк урып алыгыз безне, югыйсә алтын бөртекләребез әрәм була, дип әйтәләр.

Ләкин хәзер җыр, музыка, тәгәрмәч тавышлары арасыннан ишетелгән башаклар моңы аерата тирән, аерата сагышлы. Алар гүя, без өлгердек инде, безне ташлап кая китәсез, җир уллары? Китмәгез, җыегыз безне, без сезнең намуслы хезмәтегезнең гүзәл җимеше бит, дип тилмерәләр.

Газинурның күңеле сүз белән аңлатуы кыен булган сызлану белән тулып ташый: ул инде башаклар чакырган җиргә бара алмый, ул китә, китә...

Юл уңга борыла башлый. Хәзер Газинур эшелонның иң арттагы вагоннарын да, паровозны да күрә. Состав «Красногвардеец» урамыннан да озынрак булыр, һәр вагонда тыныч хезмәтләреннән аерылган, әле кичә генә югары уңыш алу яки нормасын арттырып үтәү турында гына уйлаган ничәмә-ничә дистә кеше утырган. Ә артта очсыз-кырыйсыз иген кырлары кала. Кемнәр җыяр ул игеннәрне, кемнәр сугар да, кемнәр җилгәрер аларны?! Кемнәр аларны дәүләт амбарларына ташыр?!

Газинур Миңнурыйны исенә төшерә. Миңнурый янына Әлфия килеп баса. Алар тирәсенә «Красногвардеец»-ның башка хатын-кызлары җыела. Шунда ук Хәнәфи, бригадир Габдулла, этисе, Сабир бабай, энесе Халикъ һәм тагын бик күпләр. Юк, алар бу байлыкны әрәмгә җибәрмәсләр. Ләкин шулай да аларга кыен булачак. Газинур моны йөрәге белән сизә, эченнән көрсенеп куя. Аның көрсенүен көчәйткәндәй, паровозның еш-еш пышылдавы, тәгәрмәчләрнең кызу-кызу тукылдаулары ишетелә. Күрәсең, юл үргә менә. Өстәвенә тышта җил дә кузгалган: паровозның куе төтене әле бер якка, әле икенче якка авыша.

Гармунчы Газинурга таныш булган дәртле көйне – «Өч танкист»ны уйный иде. Ул җыр Газинурга Соликамскиның шаулап торган урманнарын, Володя Бушуевны, Катяны, Карп Васильевичны, Павел Иванович Ивановны исенә төшерә. Әле һаман да шунда эшлиләрме икән алар? Володя белән Катя өйләнештеләрме икән? Бәлки, алар да, Газинур кебек, туган илне сакларга бара торганнардыр. Газинур баштарак аларга хатлар язгалады, алар да җавап бирделәр. Аннары язышу үзеннән-үзе тукталды. Гаеп Газинурда булды бугай. Ул хат язарга яратмый иде.

Кем белә, тыныч хезмәттә очрашкач, фронтта да очрашырлар, бәлки. Тау тау белән очрашмаса да, кеше кеше белән очраша.

Газзән белән Мисбах һаман да әле, кулларын баш асларына куйган килеш, сүзсез яталар. Мөгаен, алар өйдә калган хатыннары, бала-чагалары турында уйлыйлардыр. Газинур да Миңнурый белән балаларын онытмый, шулай да ул инде гел алар турында гына уйлый алмый. Гали абзый юл аягы итеп бик дөрес итте: хәзер үзеңнән дә көчлерәк булырга кирәк.

Газинур, уйга чумган Мисбах белән Газзәнгә карап:

– Абзыкайларым, күзләрегез белән түшәм такталарын тишәсез ич. Иртә ямансылыйсыз. Әле окопта да уйла-

нырга өлгерерсез. Солдат көр күңелле булырга тиеш. Хәтерлисезме комиссарыбызның Финляндиягә барганда әйткән сүзләрен?

– Анысы шулай да бит, – диде Мисбах, – безнең кул мылтык тотып үскәнмени? Безнең кул сабан белән көрәккә, сәнәк белән балтага күнеккән.

Газинур яткан җиреннән күтәрелә төште.

– Абый, мескенләнмә, – диде ул кызу гына, – сөялле кул барысына да бик тиз күнегә.

Кинәт эшелон туктады. Газинур тәрәзәдән карады: станция түгел, бик матур алан икән. Газинур идәнгә сикереп төште.

– Чыкма, утыра алмый калырсың! – дип кычкырды Мисбах аңа.

Ләкин Газинур үзе кебек җитез солдатлар белән бергә алан буйлап йөгерә иде инде. Каен аралары хуш исле ал, кызыл чәчәкләр белән тулган. Газинур, иң матурын өзеп, шлемына кыстырды. Шунда ук:

– По вагонам! – дигән тавыш ишетелде. Газинур тагын бер чәчәкне өзде дә, йөгерергә җайлы булсын дип, галошларын кулына алып, оекчан килеш кенә вагонга таба чапты.

Эшелон буферларын чыңлатып кузгалган иде инде. Башта Газинур ачык ишектән галошларын эчкә ташлады. Аннары солдатлар аның үзен кулыннан тартып алдылар.

Бу кыска туктау бөтен вагонны җанландырып җибәрде. Солдатлар барысы да, хәтта Газзән белән Мисбах кебек түшәмгә карап ятып баручылар да, урыннарыннан тордылар.

Йөзе алсуланган, күзләре ялтырый башлаган Газинур гармунчы егет янына килеп басты. Ул Газинурга күптән таныш булган МТС бригадиры Исхак Зәбиров иде.

– Якташ, даешь бию көен! – диде Газинур, үзе бармакларын шартлатып куйды. Зәбиров аңа көлемсерәп карады да «Әпипә»не уйный башлады. Газинур тагын бармакларын шартлатты, вагонның тузанлы идәнен йон оеклары белән тыпырдата-тыпырдата биеп тә китте.

Бригадирга аның ашкынып биюе ошады булса кирәк, ул тагын да кызурак, дәртлерәк уйный башлады. Газинур да аның саен ярсыбрак биеде. Солдатлар, кул чабып, аңа куәт бирә башладылар. Кайберләре аякларын дөбердәтергә тотынды. Аерылышу аркасында ямансылап уйчанланган йөзләр яктырды.

Бию беткәч, Зәбиров гармунын иңеннән алмыйча гына аяк өсте басты да тирләп-пешкән, күзләре ут кебек уйнап торган Газинурның иңбашына кулын куйды:

– «Красногвардеец» егете бит әле син?

– Әйе, «Красногвардеец»тан! – дип, горурланып җавап бирде Газинур.

– Клубыгызда булганым бар... Сезнең яшьләрегез биергә оста. Бигрәк тә кызларыгыз.

Газинур, Зәбировның Фатыйма биегәндә гармун уйнавын исенә төшереп, мәгънәле генә көлемсерәп куйды: янәсе, беләбез кайсы матур турында әйткәнеңне. Ләкин Зәбиров сүзне икенчегә борды:

– Җырлый да беләсеңме?

Газинур сәкедән аякларын салындырып утырган Мисбах белән Газзәнгә күз кысып алды:

– Җыр янчыгым колхозда онытылып калмаган булса, беләдер идем!

Зәбиров соңгы вакытларда Бөгелмәдә чыккан яңа бер көйне сыздырып җибәрде. Газинур бөтен күкрәге белән һава сулады да, үзе белән янәшә баскан «Алга», «Тигез басу» егетләрен ашкындырып, ачык, моңлы тавыш белән башлап җибәрде:

Җилләр исә, җилләр исә,
Кем туктатыр җил көчен?

Җырның калган яртысын уннарча тавышлар эләктереп алды:

Егет җанын кызганырмы
Туган-үскән ил өчен?

Эшелоннар вак станцияләрдә туктап та тормыйлар. Зур станцияләрдә дә бик азга гына туктыйлар. Паровоз су ала да тагын кузгалып китә. Зур станцияләрнең һәрберсендә хәрби кешеләр кайный, солдатлар төялгән кызыл вагоннар күренеп кала. «Бөтен Советлар Союзы халкы күтәрелә», – дип уйлый яңадан югарыга менеп яткан Газинур.

Төнлә Казан янындагы Юдино станциясен үтеп киттеләр – Казанга кереп тә тормадылар. Солдатлар арасында: «Безне Мәскәүгә алып баралар», – дип сөйли башладылар. Ләкин, күп тә үтмәде, аларны, кайдадыр Муром тирәсендә туктатып, эшелоннардан төшерделәр. Аннары мунчага алып бардылар, кием бирделәр. Газинур, үзенең йон оекларын, иске пальтосын салып, өр-яңа солдат киемен киде дә, кесәсендәге көзге кисәген чыгарып, үз-үзен карарга тотынды.

– Исәнме-саумы, Газинур солдат, кәеф-хәтерләрең ничегрәк? – дип көлемсерәп күзен кысты.

Икенче көнне төнлә алар чыннан да Мәскәүдә иделәр. Эшелон туктауга Газинур вагоннан сикереп төште дә үтеп баручы фонарьлы тимерьюлчыдан:

– Мәскәү кайда? – дип сорады.

Фонарьлы кеше караңгыда Газинурның йөзен күрмәде, шуңа күрә, бу сорауга игътибар бирмичә:

– Син басып торган җирдә, – дип узып китте.

Станция – кемдер аны Лихоборы диде – солдатлар төялгән эшелоннар белән тулган иде. Танклар, туплар, автомашиналар төялгән платформалар күренә. Янәшә юлдан бронепоезд үтеп бара.

Бронепоездның шау-шуы тынгач, Газинур үзе белән янәшә басып торган солдаттан:

– Иптәш Васильев, Кремль кай турыда, белмисеңме? – дип сорады.

– Әнә шул якта, моннан күренми ул, – диде солдат, кулы белән караңгыда изәп алып.

Газинур солдат күрсәткән якка таба йотлыгып карады, Мәскәүнең утлары сүндерелгән, барысын да куе караңгылык йоткан иде. Тик тимер юл буендагы дүртәр-бишәр катлы йортлар гына чак-чак күренә.

Газинурга ямансу булып китте. Гомерендә бер тапкыр башкалага кил дә Кремльне ерактан гына булса да күрми кит, имеш. Ярый ла таң атканчы аларны бирелә тотсалар. Кая, тоталармы соң мондый вакытта.

Кичә политрук беседа үткәргәндә, фашистлар безнең күп кенә җирләрне басып алганнар, бик каты сугышлар бара, дип сөйләде бит.

Күп тә үтмәде, эшелон чыннан да урыныннан кузгалды.

– Бөтенләй китүебезме? – дип сорады Газинур бер иптәшеннән. Теге иңбашларын гына җыерып куйды. Аңа әйтеп тормаганнар лабаса.

Ләкин озакламыйча эшелон яңадан туктады, ә паровоз китеп барды. Газинур, ераклаша барган паровоз тавышына колак салып, эченнән сөенеп куйды: «Болай булгач, таңга кадәр торабыз әле».

Газинурны дневальный итеп билгеләделәр. Солдатлар яткач, ул, су сибеп, вагон идәнен әйбәтләп себереп чыкты, аннары, ишек яңагына сөялеп, тышка карап тора башлады. Җәйге төн төнмени ул. Әнә яктыра да инде.

Газинур янына шинелен җилкәсенә салган Зәбиров килеп басты. Күн тужуркасын салгач, ул ничектер башкаларга охшап киткән, бүтәннәрдән элеккеге кебек аерылып тормый. Тик нык ияге, карчыганыкы төсле үткен күзләре, каты иреннәре элеккечә аның көчле ихтыяры турында сөйлиләр. Әмма иртәнге тонык яктылыкта Исхакның йөзе уйчан күренде.

– Әнә Авыл хуҗалыгы күргәзмәсе. Мин былтыр күргәзмәгә катнашкан идем. Безнең Татарстан павильоны әнә тегендәрәк, – диде ул, кулы белән станция аръягына күрсәтеп.

– Без һаман да Мәскәү янындамыни? – дип, беркадәр гаҗәпләнү белән сорады Газинур.

– Әйе, безне Окружной юл буенча күчереп йөрттеләр.

– Кремль кай турыда?

Зәбиров вагоннан сузылып карады да:

– Әнә шул турыда булырга тиеш, – диде.

Газинур вагоннан сикереп төште дә, бераз читкә китеп, карап тора башлады. Хәзер Мәскәүнең биек ташпулатлары ап-ачык күренә иде. Кинәт Газинур чиксез шат тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Кремль! Кремль!

Мөгаен, ул, бередәге исәпсез-хисапсыз манараларның берсен күреп, аны Кремль дип уйлагандыр, чөнки моннан Кремльне күрү мөмкин түгел иде.

Берничә сәгатьтән эшелон кузгалып китте һәм бу юлы озак туктамады. Башта ачык вагон ишегеннән зәңгәр буяулы, террасалы җиңел йортлар, нарат урманы эчендәге җыйнак дачалар күренеп барды, аннары поезд киң кырларга чыкты.

Газинур, дежурдан бушап, югары сәкегә менеп, йокларга ятты. Төшендә ул яңадан Кремльне күрде. Имеш, ул Кызыл мәйдан буйлап үтә. Әнә, нәкъ рәсемдәге шикелле, Ленин Мавзолее, әнә Кремль сарае башында кызыл флаг җилферди. Ул да булмый, мәйдан кызыл байраклар күтәргән халык белән тула. Беренче май бәйрәме, имеш. Халык ура кычкыра, Газинур да бөтен тавышы белән ура кычкыра, имеш...

Аны Мисбах төрткәләп уятты:

– Газинур, сугышка керәсеңме әллә? Ура кычкырасың.

Газинур күзләрен ачты, беркадәр вакыт берни аңламыйча абыйсына карап торды. Аннары аңына килде.

Бер зур гына станциядә эшелон ярты тәүлек чамасы туктап торды. Ул арада янәшә юлларга яңадан-яңа эшелоннар килеп туктады. Аларның һәрберсе солдатлар белән шыгрым тулган иде.

Кулына котелок тотып платформа буйлап йөгереп барган Газинур яңа килеп туктаган кызыл вагоннарның берсеннән сикереп төшкән Сәлим белән очрашты.

– И-и-и! – дип кычкырып җибәрде Газинур. – Син дә кузгалдыңмыни, Сәлим? Менә әйбәт. Бер якка барабыз икән. Мидхәт белән Һашим кайда?

Сәлим көрсенеп җавап бирде:

– Аерылдык. Мин берүзем. Алар миннән Бөгелмәдә калдылар әле. Мисбах абый белән Газзән абый синең беләнме?

– Без бергә. Әнә тегендәрәк безнең вагон. Паровоздан өченче.

– Кая алып баралар икән, Газинур, ишетмәдеңме?

– Ленинградка да диләр, Петрозаводскига да диләр. Дөресен белү кыен.

– Ну кызу тоталар. Курьерскийда барган кебек барабыз. Сугышка да поезд белән үк барып керербезме икән?!

Вагон ишекләре төбенә баскан дежурныйлар: «По вагонам!» – дип кычкыра башладылар.

– Безнекеләр, – диде Газинур, ашыгып, һәм Сәлимне кочаклады. – Хуш! Башлар исән булса, тагын очрашырбыз әле. Кайгырма.

Газинур үз вагонына таба йөгереп китте.

– Мисбах абый белән Газзән абыйга сәлам әйт, – дип кычкырды бик каты әсәрләнгән Сәлим.

Вагоннар буферларын дөбердәтеп кузгалдылар. Ачык ишек төбенә баскан Газинур кул болгады. Бу минутта Сәлимгә булган элекке ачулары тәмам онытылган, ә Сәлим аңа ничектер якынаеп, туганлашып киткән кебек иде. «Хәзер без икебез дә солдат», – дип уйлап алды Газинур.

Борынгы рус шәһәрләре Ярославльне, аннары Вологданы үтеп киттеләр. Солдатлар арасында «Петрозаводскига, ак финнарга каршы илтәләр» дигән хәбәр таралды...

## 2

Петрозаводск шәһәрендә аларны чынлап та эшелоннан төшерделәр. Стройга тезелер алдыннан «Красногвардеец» егетләре бер тирәгәрәк җыелды.

– Их, Советлар Союзының киңлеге! – диде Газинур. – Күпме вакыт киләбез, һаман очы-кырые юк. Нинди тинтәк дошман шундый җирне алам дип сугыш башлаган!..

Газзән дә, Мисбах та, бер сүз әйтмичә, тәрәзә пыялалары челпәрәмә килгән, түбәсе убылып төшкән, тәрәзә турыларында стенасы кара корымга буялган кызыл таш йортка карап торалар иде.

– Бирегә ташлый икән... – диде Мисбах әкрен генә.

Бу аның сугыш хәрабәләрен беренче күрүе иде. Моңарчы алар тимер юл кырыйларында, урман эчләрендә бомба чокырларын гына күрделәр, ләкин алар, әллә ачык урында булгангамы, әллә поезд бик кызу үтеп киткәнгәме, бу хәтле күңелне шомландырмыйлар иде.

– Карагыз, арткы як стенасы бөтенләй юк! – дип пышылдады Мисбах яңадан. – Нихәтле кеше харап булгандыр монда, нихәтле кеше квартирасыз калган.

Аңа җавап бирергә өлгермәделәр, сафка тезелергә команда булды. Аннары аларны шәһәр кырыйларыннан казармага алып киттеләр. Юлда тагын җимерелгән, янган, ишелгән йортлар очрады. Аяк астында пыяла ватыклары кыштырдады.

Колонна як-ягында кораллы часовойлар басып торган зур таш капкадан киң ишегалдына килеп керде. Бу казарма ишегалды иде.

Солдатларны шунда ук бүлмәләргә урнаштырдылар. Бөтен бүлмәләрнең ишекләре ачык, идәннәрдә кәгазь кисәкләре ауный, күрәсең, моннан күптән түгел бик ашыгып чыгып киткәннәр.

«Безне дә монда озак тотмаслар», – дип уйлады Газинур. Ләкин солдат бер сәгатькәме, ике сәгатькәме туктый, кайда, күпмегә туктаса – шул урын аның туган йорты булып китә. Ул анда нәрсә барын белергә, үзенә кирәк булганча җайларга тиеш. Солдатның нянькалары юк.

Бу сүзләрне Газинур, Финляндия кампаниясенә барганда өлкән командирдан ишетеп, чыкмаган мыегына урап куйган иде. Хәзер алар яңадан аның исенә төште.

Казармага килеп урнашканнан соң бер сәгать тә үтмәгәндер, Газинур инде аның барлык почмакларында булырга, әллә никадәр яңа нәрсәләр, яңа танышлар табарга өлгергән иде. Кара кашлы, кара күзле, гаҗәеп җиңел сөякле, сүзчән һәм җырчы егетне солдатлар да беренче күрүдән үк үз иттеләр. Бик күпләр аңа, бер ротага эләксәк шәп булыр иде, дип тә әйткәләделәр. Чөнки мондый күңелле, «душа» кешеләр белән походта да, окопта да, сугышта да җиңелрәк. Мондый кешеләргә үзеңә ышанган кебек ышанырга мөмкин.

Фронт моннан бик үк ерак түгел, диләр. Финнар белән немецлар безнекеләрне һаман кысрыклыйлар, ди. Аларның танклары, туплары, самолетлары бик күп. Хәзергә әле аларга каршы безнең пограничниклар гына сугыша. Кызыл Армиянең төп көчләре килеп җитмәгән әле.

Петрозаводск өстендә дошман самолетлары оча. Кайдадыр, шәһәр бакчасында урнаштырылган зенит туплары, биек йортлар түбәсендәге зенит пулеметлары ярсып-ярсып аталар. Тәрәзә пыялалары берөзлексез чыңлап тора.

Озакламыйча построение була, диләр, таралышмаска кушалар. Маршевый роталарга бүләләр, бүген төнлә үк фронтка да озаталар, имеш. Шушы хәбәрләр турында сөйләшеп, Мисбах белән Газзән ишегалдындагы бүрәнәләр

өстендә нәкъ авылдагыча тәмәке тартып утыралар. Икесенең дә йөзләре җитди, борчылулы. Икесе дә күбрәк җиргә, итек башларына карыйлар.

– Теге вакытта ярты юлдан кайткан идек, – диде Газзән, Финляндия кампаниясен исенә төшереп. – Бу юлы җәһәннәмнең авызына килеп кердек бугай. Башлар исән каламы, юкмы. – Бераз эндәшми торгач, беркатлы гына итеп өстәде: – Обозга эләгәсе иде.

– Бәлки, санитар итәрләр, – диде Мисбах. – Теге вакытта без өчебез дә санитар идек ич. Безнең военный билетларда да шулай дип язылган...

Казарманың ишегалды аркылы штаб урнашкан яңа флигельгә кулларына кәгазьләр тоткан командирлар һәм писарьлар бертуктаусыз кереп-чыгып йөри. Кайчак өсләренә хәрби кием кигән хатын-кызлар да күренгәли. Газзән, аларга караңгы чырай белән карап:

– Туже сугышка баралар, – диде. Ләкин ул моны яманлапмы, яхшы дип санап әйттеме – аңлавы читен иде.

– Врачлар яки сестралардыр, – диде Мисбах. Аның күңелендә ниндидер тынычлану хисе туды: хатын-кызлар да баргач, ул сугыш дигәнең әллә ни куркыныч булмаска тиеш.

– Врачлар катушка күтәреп йөрмиләр, – диде Газзән, мыскыллап, аннары башын күтәреп һавага карый башлады. Күк йөзе чалт аяз – нәкъ «Урта Кулка»да бодай кыры өстендәге шикелле. Шундый чалт аяз күктән бомбалар явуына ышануы да кыен.

Мисбах һаман да җиргә карап тора. Таш арасыннан чыккан аксыл үлән сабагы буйлап, нәкъ «Красногвардеец»тагыча, бер кырмыска күтәрелә. Икенчесе үзеннән зур үлән сабагын өстери. Өченчесе килеп аңа булыша. «Тормыш сугыш дип тормый, үзенчә бара бирә. Менә итек белән басып сытарлар дип тормый кырмыска, үз эшен эшли», – дип уйлап алды Мисбах, тәмәке төпчеген ташлап, аны олтаны белән ташка ышкыды.

– Газинурга әйтәсе иде, кирәкле кешесен күрмәсме, – диде Газзән, яңадан карашын җиргә төбәп. Ул бервакытта да үз уен тулы килеш әйтеп бетерми. Ләкин Мисбах аның тел төбе кая барганын аңларга күнеккән иде.

Кайдадыр икенче катта гармун уйнап җибәрделәр – теге МТС бригадиры Зәбиров уйный булса кирәк. Гаҗәп кешеләр бар дөньяда. Борчылу юк, сагышлану юк, уйлану юк – гармун да бию, җыр да көй. Бу кешеләр сугышка да шулай җырлап барерләрме икән?

Ачык тәрәзәләрдән көчле җыр ишетелә. Хор арасыннан, тургай шикелле каядыр өскә ыргылып, Газинурның

ачык, моңлы тавышы яңгырый. Мисбах колакларын үрә торгыза, МТС бригадирының гармун уйнавы ул хәтле гаҗәп эш түгел әле, ул орденлы, аңа шулай килешә дә кебек. Ә Газинур... Бер ана карынында ятмасалар да, бер өндә, бергә үскән Газинурны Мисбах никадәр аз белгән икән! «Красногвардеец»та артык күзгә ташланмаган никадәр бүтән сыйфатлары бар икән аның. Соликамск буенча Газинурны күбрәк белгән Газзәннең исә моңа артык исе китмәде. Ул инде Газинурның «хикмәтләрен» күргәләгән иде.

– Әнә безнең тилебез дә җырлый бит, – диде Мисбах, яшьләрнең шаянлыгын ошатып бетермәгән картлар кебек. – Аңа бирсәдә дә, колхоздагы кебек, диңгез тубыктан. Әти турында да, хатыны белән балалары турында да уйламый, ахрысы.

– Минзәлә шулпасын эчмәгән әле ул, – диде Газзән, аннары Сәлим турында сорап куйды: – Бирсәдә күренми. Әллә егетне турыдан позициягә җибәрделәрме икән?

– Булса да булыр. Дөньяның купкан чагы, – дип җавап бирде Мисбах.

Ике колхоздаш шулай сөйләшеп торган арада, Газинур парадный ишек төбенә чыкты, биек таш баскычта туктады. Аның карашы каядыр еракка төбәлгәнгә, ул баскыч янындагы бүрәнәләр өстендә утырган Мисбах белән Газзәнне күрмәде, ә тегеләр шунда ук аны күреп алдылар. Газинур билен киң каеш белән нык итеп кыскан, киң күкрәге калкып тора, гимнастеркасында бер генә җыерчык та юк, җеп шикелле генә калдырып ак яка теккән, обмоткасын тезенең яртысына җиткереп ураган, ботинкаларын кайдадыр чистарткан, ялт-йолт итеп торалар, пилоткасын әзрәк каш өстенә төшереп кыйшайтыбрак кигән.

– Түбәң күккә тимәсен! – дип кычкырды Газзән астан.

Газинур аларны күреп алды, таш баскычлардан йөгереп төшә-төшә үк:

– Сез нәрсә, бүтәннәрдән аерылып, тавыклар кебек, үзегез генә кояшта кызынасыз? – дип кычкырды. – Газзән абый кырынмаган да. Обозга алсыннар дип, картрак күренергә тырышасыңмы? Булмый, өмет тә итмә. Сиңа йә пулемет, йә чабагач сабы – ПТР тоттырачаклар.

– Шаярма әле, Газинур, – диде Газзән. – Утыр, сүз бар.

Газинур бүрәнә өстенә утырды. Газзән обозга әләгү турында бая Мисбахка сөйләгәннәрен кабатлады. Газинур башта аны елмаеп тыңлап торды, аннары елмаюы очты, кара кашлары җыерыла башлады. – Конешно, –

дип сүзен дәвам итте Газзән, бераз юргаларга керешеп, – коралны яхшы белсәк, солдат һөнәренә өйрәнгән булсак, эш башкача булыр иде. Югыйсә Мисбах белән без...

– Абый, ә син ничек уйлыйсың? – дип сорады Газинур эндәшми утырган Мисбахтан.

Мисбах уйланып кына җавап бирде:

– Өйрәтсәләр, әлбәттә, яхшы булыр иде дә, көннәре нинди бит, өйрәтеп торыр чакмыни...

– Шулай шул, абый, – дип, Газинур Мисбахның сүзен раслады, аның урман чикләвеге кебек түгәрәк күзләренә карады: алар алдашмыйлар иде. – Бераз гына булса да мылтык тота beләбез бит. Мирный вакыттагыча иркенләп өйрәтеп тормаслар. Хәзер дошманны кыйнарга кирәк.

Газзән утырган урынында кыбырҗып куйды.

– Кара, Газинур, – диде ул саңгырау тавыш белән, – сугышка керми торып, бик батыраеп китмә әле.

Шәһәрдә кинәт тревога башланды: паровозлар, сиреналар үкерергә тотынды. Ишегалды берьюлы бушады, Газзән белән Мисбах та якындагы базга гаҗәеп бер җитезлек белән сикерделәр. Тик Газинур гына, баскан урыннан кузгалмыйча, пилоткасын артка этте дә, каш өстенә кулын куеп, зәңгәр күккә карый башлады. Ләкин анда берни күренми, самолетлар кайдадыр читтәрәк гүли. Ара-тирә, җир селкетеп, көчле гөрселдәүләр яңгырый – станцияне бомбага тоталар, ахрысы.

Кинәт казарманың биек бинасы артыннан, шактый түбән очып, моторларын үкертеп, бер немец бомбардировщигы атылып чыкты да аргы якка омтылды. Аның кара күләгәсе ишегалдыннан шуып үтүгә, бомбардировщикны куып килүче кызыл канатлы безнең истребитель күренде. Немец бомбардировщигы үкчәсенә басуларын сизде, ахрысы, кинәт, текә борылыш ясап, борыны белән күккә күтәрелде. Шунда гаҗәп бер хәл булды. Истребитель, күз ачып-йомганчы өскә чыгып, үлем элмәге ясады да, карчыга югарыдан козгынга ташланган шикелле, немец бомбардировщигы өстенә омтылды, аның бензин бакларына пулеметтан бәреп, чәнчелдереп тә ташлады. Фашист самолеты, артыннан озын төтен койрыгы калдырып, кайдадыр казармалар артына җиргә бәрелеп шартлады.

Һава сугышын үз-үзен онытып күзәтеп торган Газинур кинәт бөтен тавышы белән кычкырып җибәрде:

– Чәнчелдерде! Чәнчелдерде!

Ләкин аның тавышын берәү дә ишетмәде бугай, чөнки бомбалар ярылуыннан, зениткалар тавышыннан тирә-як һаман да әле гөрселдәп тора иде.

– Базга!

Газинур колагы төбендә үк яңгыраган бу ачулы сүзгә борылып карауга, янында хатын-кыз командирның басып торганын күрде. Командирның пилоткасы астыннан озын коңгырт чәчләре чыгып тора иде.

– Базга, нишләп катып торасың, – дип кабатлады командир.

Газинур исә, шатлыгын яшерә алмыйча:

– Фашистны бәреп төшерделәр! Нәкъ карчыга сыман типте! – диде һәм базга сикерде.

Тревога беткәннән соң, Газинур, фашист самолетының кайда төшкәнлеген белергә, үзенә ачуланган хатын-кыз командирны тагын бер тапкыр күрергә теләп, баздан беренче булып сикереп чыкты.

Фашист самолетының язмышын Газинур бик тиз белде, ул казармалар янында гына төшкән, очучыларыннан берсе дә исән калмаган, барысы да дөмеккәннәр. Ә хатын-кыз командирны Газинур тиз генә таба алмады. «Менә, ай күрде, кояш алды», – дип гаҗәпләнде ул. Ашханәдә тәмле шулпа ашаганда, бу турыда Мисбах белән Газзәнгә дә сөйләп бирде.

– Кайдадыр күргәнем дә бар иде кебек үзен, тик исемә генә төшерә алмыйм, – диде.

Бу хәбәргә Газинурдан да бигрәк Газзән шатланды. Ләкин ул хәйләкәр иде. Мәсьәләне уенга салып, Мисбахка мәгънәле итеп күз кысты:

– Һай, мескен Миңнурый!

Газинур, сүзне икенчегә борып, истребительдә утырган очучы турында сөйли башлады. Нинди оста итеп мәтәлдерде! Димәк, гитлерчыларны үкертеп-үкертеп кыйнап була!

Хатын-кыз командирны Газинур ашханәдән чыгып килгәндә күрде һәм кинәт шаккатып туктап калды. Бу Катя, Соликамскида урман кискәндә үзен русча укыткан, куян тиресеннән тегелгән озын колаклы ак бүрек киеп, кызыл почмакка килеп йөри торган Катя иде.

– Катя... – диде Газинур.

Ашыгып барган Катя, үз исемен ишеткәч, кинәт туктады, атлыгып торган яшь кызылармеецка текәлеп карады. Ул байтак вакыт танымыйча торды.

– Чү, Газинур, син түгелме?

– Нәкъ үзе... Әле яңа гына килеп төштек. Бая ишегалдында мин дә сезне танымадым.

Шушындый көтелмәгән очрашу вакытында була торганча, алар бер-берсенә сорау яудыра башладылар, Газинурны аеруча Карп Васильевич, Павел Иванович, Володя Бушуевлар кызыксындырды. Катя бу якларга үзе ничек килеп эләкте икән?

Екатерина Павловна хәрби госпитальдә эшли икән. Шәһәргә ул дару алыр өчен килгән, бер уңайдан госпиталь начальнигы санитарлар алып кайтуны да аңа йөкләгән. Аңа кичә үк кешеләр бирергә вәгъдә иткәннәр, ләкин вәгъдә иткән кешеләрен үзләре үк фронтка озатканнар. Бүген, ниһаять, аңа исемлек биргәннәр. Ул сумкасын тиз генә ачып исемлекне алды да укый башлады.

– Элек санитар булып эшләгәнең юк идеме, Газинур?

Газинур Финляндия кампаниясенә барганда санитар итеп билгеләнгән булганлыгын әйтте.

– Гафиятуллин... Менә синең фамилияң дә бар икән. Алай булгач, мин сине үзем белән алып китәм. Санитар итеп. Бар, тиз генә әзерлән.

Газинур биредә үзенең абыйсы белән бер колхоздашы барлыгын әйтте. Катя аларның фамилияләрен сорады. Исемлектә алар да бар иде.

Тагын бер сәгатьтән алар, унбишләп кызылармеец, ачык машинага утырып, гаҗәп матур нарат урманы эченнән сузылган олы юлдан баралар иде инде. Арттан тагы бер көймәле машина килә. Аның өсте дә, Газинурлар утырган машинаның кабинасы кебек, яшел ботаклар белән маскировкаланган.

Юлга чыгар алдыннан Газзән Газинурның кулын кысып рәхмәт әйтте: «Егет икәнсең», – диде. Ул санитарлыкка эләгүне Газинур аркасында гына булган эш дип уйлый иде. Газинур көлеп җибәрде, кулын селекте, ләкин аңлатып торуны кирәк тапмады.

Бушуева икенче машинаның кабинасында бара иде.

Газинур леспромхоздан киткәннән соң, Екатерина Павловна әле тагын ел ярым чамасы анда эшли. Өйләнешәләр. Ләкин, күп тә үтми, Володя Бушуевны армиягә алалар һәм пехота училищесына укырга җибәрәләр. Ул Фин кампаниясенә катнаша, җиңел генә яралана. 1940 елның җәендә Екатерина Павловна аның янына – Петрозаводскига килә, госпитальдә эшли башлый. Иртәгә сугыш дигән көнне алар квартираларының Онега күленә караган ачык верандасында ак чыбыктан үрелгән креслода Володя белән икәү кара-каршы утыралар, отпуск алып, Соликамскига кайтып килү турында хыялланалар. Анннары аларга Володяның иптәшләре – командирлар кунакка килә. Төнлә, иртәнге дүртләрдә, телефон шалтырый. Володя трубканы алып тыңлый да, йоклап яткан Екатерина Павловнаны уятмаска тырышып, тиз-тиз киенә башлый.

Екатерина Павловна үзе уяна һәм, куркып:

– Володя, син кая җыенасың? – дип сорый.

– Чакыралар, Катюша, – ди Володя, ишеккә юнәлә, аннары нәрсәдер исенә төшергән сыман кире борыла, йөгереп килеп Екатерина Павловнаны үбә. Шуннан соң Екатерина Павловна аны яңадан күрә алмый. Володя үзенең часте белән фронтка чыгып китә. Шул ук көнне Екатерина Павловна да кыр госпиталенә билгеләнә...

Газинур, әлбәттә, бу турыда бернәрсә дә белми иде. Ул үзеннән соң булган хәлләр турында иркенләбрәк сорашырга бик теләсә дә, хәзергә бу мөмкин түгел иде. Аның каравы ул үзе сугышчыларга Катя турында бөтен белгәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде, аның кешелекле, кече күңелле булуын мактады. Ул үзенең сөйгәне турында сөйләгән кебек эчке дулкынлану белән сөйләде. Бу хәл солдатларга аның адресына чәнечкеле сүзләр ташлап алырга да юл ачты. Газинур җавапка сүз эзләп берәүнең дә кесәсенә кермәде, аның теле җитәрлек йөгерек иде. Шул ук вакытта аның үткен кара күзләре урманны күзәтүдән дә туктамады.

– Менә первосортный урман кайда икән! Безнең Дымск урманнары да, Баулы урманнары да, Липовка урманнары да түгел икән. Соликамск урманнары да моңар тормый. Карагыз наратларның кәүсәләренә, алтын бит болар!

Алар Суоярви шәһәренә килеп җиткәндә, әле һаман да якты иде. Идел буйларыннан ерак төньякка беренче килгән сугышчылар биредә төннәрнең бөтенләй диярлек булмавына гаҗәпләнеп бетә алмадылар. Бу турыда алар озак итеп, сәерсенеп сөйләделәр.

Машиналар шәһәр кырыендагы алтышар почмаклы, икешәр катлы агач йортлар алдына килеп туктадылар. Капка башында кызыл хач билгесе төшерелгән ак флаг җилферди иде.

Шофер, кабинасыннан чыгып:

– Килеп җиттек, егетләр, төшегез, – диде.

– Фронт еракмы? – дип сорады кемдер.

Урман эченнән тонык кына гөрселдәгән туплар тавышы ишетелә иде. Шофер, берни әйтми, тавыш ишетелгән якка башын изәп куйды. Аның бу сүзсез җавабын барысы да бик ачык аңладылар.

## 3

Кыр госпитале бер ишегалды әйләнәсенә төзелгән икешәр катлы, алтышар почмаклы өч йортта урнашкан иде. Икесендә яралылар ята, берсендә госпиталь персоналы һәм госпитальнең канцеляриясе урнашкан. Ишегалдындагы бер катлы шактый зур флигельдә приемный

покой. Алгы сызыктан яралыларны алып килгән автомашиналар, санитар повозкалар шул флигель каршына килеп туктыйлар. Алар килеп туктауга, флигельдән ак халатлы санитарлар белән санитаркалар йөгереп чыгып, яралыларны, машинадан сак кына төшереп, приемныйга ташый башлыйлар.

Күп вакытта машиналар яртылаш ватылган, чәрдәкләнгән килеш кайталар. Пыялалары челпәрәмә килгән кабинадан шоферның бинт белән уралган канлы башы күренә. Ул, кулларын руль тәгәрмәченә куеп, күзләрен йомып утыра. Еш кына яралылар белән бергә шоферны да приемныйга алып китәләр.

Приемныйның бөтен бүлмәләре яралылар белән тулган. Яралыларның кайсыберләре әкрен генә ыңгыраша, кайсыберләре ишегалдының иң ерак почмакларына да ишетелерлек итеп әрнеп кычкыралар, ярдәм сорыйлар. Күпләре инде, кычкырудан, газаплanудан арып, газета ябыштырылган түшәмгә хәрәкәтсез күзләре белән тын гына карап яталар. Кем белә, бәлки, алар түшәмне дә күрмиләрдер, бары тик күзләрен йомарга көчләре җитмәгәнгә яки күзләре мәңгегә йомылудан курыкканга гына шулай тукталган караш белән текәлеп карап яталардыр.

Флигельнең такта белән бүленгән икенче яртысында врачлар операция өстәле яныннан көн-төн китмичә эшлиләр. Бары тик санитарлар бер яралыны алып китеп, икенчесен операция өстәленә куйган арада гына алар, кул юарга, резина перчаткаларын алмаштырырга дип, баскан урыннарыннан кузгалалар. Аларның барысы да диярлек сүзсез эшли, тик ара-тирәниндидер инструмент исемнәрен генә телгә алалар. Күп вакытта хәтта инструмент исемнәрен дә әйтмиләр – ак халатлы, ак яулыклы, йөзләренә дә ак маска бәйләгән сестралар, хирургның җиңелчә баш хәрәкәтен күреп, аңа ялтырап торган кирәкле инструментны сузалар.

Ярдәм күрсәтелгән яралыларны санитарлар шунда ук әлеге икешәр катлы йортларга алып китәләр. Бу йортларда приемныйдагы кебек ыгы-зыгы юк. Яралылар, озак газаптан соң беренче тапкыр тынычланып, ап-ак кроватьларда яталар. Сестралар, ак күләгәләр шикелле, тавышсыз йөриләр, салкынча кулларын яралыларның кайнар маңгайларына куялар, ул-бу кирәкмиме, дип сорыйлар, мендәрләрен, юрганнарын төзәтәләр, солдат йөрәген эретә торган ягымлы сүзләр әйтәләр.

Газинурның моңарчы госпитальдә түгел, Бөгелмә больницасында да булганы юк иде. Шуңа күрә яралыларның ыңгырашулары, хәтсез күп канлы чүпрәкләр аның нечкә

йөрәгенә гаҗәп көчле тәэсир итте, ул госпитальгә килгәннең беренче көннәрендә тирән аптырашта калып йөрде. Сугышта булган, аны үз күзләре белән күргән кешеләр госпиталь тормышы турында бөтенләй башкача уйлыйлар. Газинур исә фронтта булмыйча торып госпитальгә эләкте, сугышны аның эчендә торып түгел, аның артында торып, эшләгән нәтиҗәсе буенча күрде: күпме кан коела!

Кайчандыр сукса тимер өзәрлек егетләр булып та, хәзер ыңгырашып яткан яралыларны Газинур чын күңеленнән кызганды, мөмкин булса, аларга үз сулышын өзеп бирергә әзер иде. Ләкин яралылар аның кызгануын яратмыйлар. Алар бары тик дошманны бик аз кыйнап калулары өчен генә үкенәләр. Шуннан соң Газинурга, саутаза егеткә, Ватан өчен йөрәк каннарын кызганмаган яралылар арасында чабып йөрү ничектер оят булып тоела башлады. Күңелендә үз-үзеннән канәгатьсезлек туды. Хәзер инде ул Катяны очратуга шатланмый, ә үкенә иде.

Екатерина Павловна Бушуева Газинурны үз янына алды. Ул госпитальнең аптека начальнигы булып эшли иде. Аптека ике катлы йортларның берсендә, түбәнге катта, икесе шактый зур, берсе кечкенәрәк өч бүлмәдә урнашкан. Екатерина Павловна һәм аның ярдәмчеләре – Нина белән Галя исемле яшь кенә ике кыз – көннәр буе шуннан чыкмый эшлиләр. Әледән-әле аларга сестралар йөгереп килә, ниндидер язулар күрсәтәләр, Екатерина Павловна яки кызларның берсе аларга йә шунда ук дарулар бирәләр, яки язуларын алып калалар да бераздан килергә кушалар. Ак пыяла шкафларда, шүрлекләрдә – күрәсең, монда элек тә аптека булган – төрле шешәләр, банкалар, коробкалар тезелгән. Бөтен нәрсә үтә чиста ялтырый, ә бүлмәдә, куе урман эчендәге кебек, тирән тынлык. Тик ара-тирә генә кызлар бер-берсенә сүз кушышып алалар яки пыяла савытлар чыңлап куя. Өстәлдәге бәләкәй көмеш үлчәүләрдә, колбаларда тәрәзәдән төшкән кояш нурлары чагылып уйный, зәңгәр ялкынлы спиртовкалар янып тора.

Аптеканың бөтен хуҗалык эшләре, бөтен вак-төяк йомышлары, аның сотрудниклары турында кайгырту – барысы да Газинур карамагына күчте. Ул, башка санитарлар кебек үк, өстенә ак халат киде, алар кебек үк, көндәлек эшләргә чумды. Базадан медикаментлар китерсәләр, ул аларны йөгерә-йөгерә «складка» – кечкенә бүлмәгә ташыды, ящикларны ачып, андагы әйберләрне тиешле урыннарына – пыяла шкафларга, шүрлекләргә тезде, суга йөгерде, идәннәрне себерде, чүп-чарларны чы-

гарып ташлады, Екатерина Павловна яки кызлар кая җибәрсәләр, шунда чапты, кайчакларда яралыларны ташышырга да булышты. Ишегалдында һава һөҗүменнән сакланыр өчен тирән баз казыды, базның өстен элек бүрәнәләр, аннары таш һәм туфрак белән япты. Ат белән дә еш кына йөрде. Ләкин аның җилкенеп торган йөрәгенә болар гына аз иде. Екатерина Павловна яки кызлардан һаман саен: «Миңа йомышыгыз юкмы?» – дип сорап торды.

Кызлар аны үз эшләренә тарттылар. Ул көмеш үлчәүдә дарулар үлчәде, җиз киледә порошоклар төйде, зәңгәр ялкынлы спиртовкада су җылытты, ак эмаль тазларда шешәләр юды... Бер төшендереп биргән нәрсәне Газинур бик тиз отып ала, соңыннан бер дә онытмый, бутамый иде. Екатерина Павловна, аның тырышлыгын электән дә яхшы белгәнгә, хәзер бу өлгерлеге өчен аны тагын да көчлерәк ярата башлады. Элек Катя, эшкә күмелеп, ашарга да, эчәргә дә оныта иде. Хәзер Газинур үзенә сиздерми генә аны өзлексез кайгыртып тора. Әгәр Екатерина Павловна ашханәгә вакытында бара алмый калса яки кая булса китеп барса, Газинур аның ашын алып кайта. Шунлыктан Екатерина Павловна көннең яки төннең кайсы гына вакытында кайтып кермәсен – аны кайнар аш, кайнар чәй көтә. Үзе чәй яратканлыктан, Газинур Екатерина Павловнаны гына түгел, Нина белән Галяны да чәй эчәргә өйрәтте.

Аптеканың үзенчә тын, салкынча бүлмәләре, Газинур аяк басканнан соң, ничектер үзләренең элекке кырыслыкларын югалтып, гади, җайлы бүлмәләргә әверелделәр. Кайчакта Газинур, эшләргә комачауламыйча, йә татарча, йә русча җырлап җибәрә, шаян сүз әйтеп ташлый, барысын да елмаерга мәҗбүр итә.

Шаянрак табигатьле Нина Газинурдан татарча өйрәтүен үтенә башлады. Газинур аңа биш сүз өйрәтте. Нина аның артыннан татар сүзләренең басымнарын боза-боза кабатлап бара: «Газинур, шадрам, мин сине яратам». Барысы да, бу сүзләрнең русча мәгънәсен белгәнлектән (Газинур үзе үк әйтте), рәхәтләнеп көләләр.

Әгәр Газинур берәр җиргә китеп барса яки озаграк кайтмаса, аптекада хәтта күңелсез булып та китә торган иде.

Мисбах белән Газзәнне Газинур сирәк күрә иде. Мисбахны перевязочныйга, Газзәнне яралыларны ташып торырга куйдылар. Аларның хезмәте Газинурныкына караганда, әлбәттә, күп өлеш авыррак иде. Кайбер көннәрдә алар сабан сөргәндәгедән, ашлык суккандагыдан да ким

арымыйлар. Ләкин кече яшьтән авыр эшкә күнеккән бу кешеләр бервакытта да хезмәт авырлыгыннан зарланмадылар. Аннары биредә, шулхәтле яралылар арасында, саутаза килеш зарлану оят та, хурлык та булыр иде.

Алар үзләре инде икешәр хат – берсен юлдан, берсен госпитальгә урнашкач язган булсалар да, «Красногвардеец»тан берсе дә хат алганы юк иде әле. Үзара очрашсалар, аларның сүзләре һаман да шул ерак-еракларда торып калган колхозлары турында була иде. Эшләр зурга китте. Мөгаен, Хәнәфи абзыйларны да армиягә чакырганнардыр инде. Урып-җыю эшләре ничек бара торгандыр? Барысы да хатын-кызлар, карт-корылар белән балачагалар кулына калды бит.

Дошман госпитальнең урынын сизеп алды булса кирәк, көн саен һава һөҗүме башланды. Инде ике тапкыр янгын да булып алды – хәзергә ул хәтле зыянлы түгел, ярдәмче сарайлар гына янды. Ә фронтта, яралыларның сөйләүләренә караганда, хәлләр бик нык кискенләшкән. Безнекеләр яңа рубежга чигенгәннәр. Хәзер еракгагы туп тавышлары госпитальдән дә бик ачык ишетелеп тора. Яралылар тагын да күбрәк килә башлады. Газинур алар арасында тирән борчылу белән йөрде, аларның авыр яралардан газап чиккән йөзләренә әрнеп карады, ул алар арасыннан үзе белән бергә килгән таныш иптәшләрен эзләде. Ләкин байтак вакыт беркемне дә очратмады. Карелия фронтында бер генә госпиталь, бер генә юнәлеш булмавын белсә дә, күңеленнән үзен тынычландырып: «Юк, алар әле сугышка керергә өлгермәгәннәрдер», – дип уйлады.

Ләкин беркөнне Мисбах, аны ишегалдында очратып:

– Безнең Исаково егетен китерделәр бит, – диде. – Ветфельдшер Гөргөри Ивановичның улы.

– Кайда? – дип, агарынып сорады Газинур. Аның күз алдына тәбәнәк кенә буйлы, мөлаем гына карт килеп басты. «Ул әле берни белми бит...»

– Первый корпуска илтеп куйдык. Операция ясадылар. Бер кулын өздергән. Хәле начар...

Менә ак халатлы Газинур иреннәре көеп беткән, күз төпләре каралган Исаково егетенең баш очында утыра. Алар илдән бергә чыктылар, фронтка бер эшелонда килделәр. Газинурның сугышны күргәне дә юк әле, ә ул инде, ут эчендә булып, дошманның бугазын чәйнәп, яраланган килеш ята... Нәрсә дип сорашырга аңардан? Хәлең ничек, дипме? Тәмәке кирәкмиме? Врачлар, сестралар күрмәгәндә, бераз «күгәрчен сөте» китерим, дип әйтергәме? Газинур боларны күз ачып йомганчы эшләячәк. Ләкин болар иң

әһәмиятлесеме? Әгәр Газинур фронт турында сораштыра башласа: «Нигә үзең бармыйсың, бүтәннәр артына яшеренеп тормыйсыңмы син, чибәр егет?» – дип әйтмәсме?

Мондый фикер Исаково егетенең уенда да юк иде, әлбәттә. Киресенчә, ул ак халатлы кешеләргә Газинурга аңлашылмый торган ниндидер тирән бер хөрмәт белән карый, үзен һич тә батыр итеп күрсәтергә теләмичә, масаймыйча, сугыш хәлләре турында сөйли. Анда да үзе турында түгел, ә бүтәннәр турында.

– Син эшелондагы ике орденлы гармунчы егетне, МТС бригадиры Зәбировны хәтерлисеңме? – диде ул, сыңар кулын баш астына тыгып. – Гайрәтле егет булып чыкты ул... Безнең помкомвзвод иде. Ләкин без аны искечә «бригадир» дип йөртә идек. Ул элек тә сугышта булган икән – Халхин-Голда катнашкан. Бер орденын да шунда алган, икенчесен МТСта биргәннәр... Әйе, утырабыз шулай окопта. Фин танклары килә. Җир тетри... Ә танклар артында фин автоматчылары... Безнең туплар, ПТРлар танкларга бәрә. Элек берсен, аннары икенчесен яндыралар. Ә бүтәннәре һаман килә. Гөберле чылбырлары белән безне бөтен окопларыбыз белән бергә асларына сөйриләр шикелле. Чәчләр үрә тора, малай. Тупларыбыз атудан туктады. Танклар окоплар алдында ук. Шуннан, син күр дә мин күр, безнең помкомвзвод – бригадир, ике кулына берәр граната алып, окобыннан чыкты да алдан килүче танкка каршы шуышып та китте. Без әле ни булганын да яхшылап белмибез. Танк якын гына. Бригадир, яткан җиреннән бераз күтәрелә төшеп, граната томырды. Нәкъ башнясына тегенең! Танк үкереп җибәрде. Ләкин туктамады. Без уйлыйбыз: помкомвзвод хәзер икенче гранатасын томыра инде. Юк! Бригадир аякка басты! Гранатасын сул кулы белән күкрәгенә кысып, чайкала-чайкала танкка каршы атлап китте, ә уң кулы, күрәсең, яраланган – бау кебек селкенеп бара. Моны күргәч, безнең бөтен рота, таң калып, атудан туктады. Кеше үлемгә бара ич! Тагын дүрт-биш адым. Танк аны изәчәк, үзе дә шартлаячак. Ләкин шунда безнең бер ПТРыбыз атып җибәрде. Танк шып итеп туктады...

– Бригадир исән калдымы? – дип сорады тыны кысылган Газинур.

– Ул биредә... Безне бер машинада алып килделәр... Их, туганкай, – диде яралы, яңадан фронт хәлләренә күчеп, – әгәр син анда эшләр ничек булганын белсәң иде! Урман яна... Җир яна. Фронт, җилгәргеч иләге кебек, як-якка чайкала: әле алар атакага килә, әле без контратакага күтәреләбез...

– Җилгәргеч иләге кебекме? – дип кайтарып сорады Газинур.

– Әйе. Окоплар әллә ничәшәр тапкыр кулдан-кулга күчә.

Бу көтелмәгән охшату Газинурга ерак үткәннәрне хәтерләтте. Колхозның беренче җилгәргече, Газинурның шатлыгы, аннары җилгәргечнең яшен сугып януы, Газинурның аның бөгәрләнеп беткән тимер сыны алдында басып торулары аның миеннән яшен тизлеге белән үттеләр, һәм ул тирән көрсенеп куйды. Эх, ерак калды инде «Красногвардеец».

Газинур Сәлим турында да сораштырды:

– Безнең колхозның Сәлим Салманов дигән егетен очратмадыңмы? Эшелоннары безнең арттан киләдер иде. Әллә кайда гына юкка чыктылар.

– Нинди Салманов?

– Безнең элекке ветфельдшер. Григорий Иванович аны яхшы беләдер иде.

– Юк, очратмадым. Анда, туганкай, шундый чаклар була, очратсаң да танымый калуың бик мөмкин.

Газинур Исаково егетенә папирос бирде, тагын килергә вәгъдә итеп, МТС бригадиры Исхак Зәбировны эзләргә чапты. Ләкин ул аны күрә алмады. Бригадирны станциягә алып киткәннәр иде инде.

## 4

Яралылар тагын да күбәйде. Дошман авиациясе безнең складларны өрөзлексез бомбага тотып торганлыктан, медикаментлар җитешми башлады. Екатерина Павловна, дарулар артыннан чаба-чаба, аяктан егыла язды. Бу көннәрдә ул бик нык ябыкты, аның гәүдәсе күләгә кебек булып калды. Хезмәттәге борчылулар өстенә бу көннәрдә аның җан газабы да артты. Володядан һаман һичбер хәбәр юк иде, Екатерина Павловна аның турында әллә нәрсәләр уйлап бетерде, урынына ятса, бәгыре өзгәләнүгә түзә алмыйча, мендәр читен тешләп елаган чаклары да була иде.

Бүген иртән иртә үк ул базага китте. Аннан кичкә таба бөтенләй ватылып, алҗып кайтты. Машина буш иде. Екатерина Павловна кабинадан төште дә туп-туры госпиталь начальнигы янына керде. Үзенең буш кул белән кайтканлыгын әйтте.

Чәченә чал кергән олы яшьләрдәге начальник, уйга чумып, бераз эндәшми торды да икеләнергә урын калдырмыйча:

– Табарга кирәк! – диде. – Без яралыларны ярдәмгә мохтаҗ килеш калдыра алмыйбыз. Алар Ватан алдында үзләренең бурычларын үтәделәр. Аларны коткару – безнең бурыч. Мин үзем дә бу эшкә керешәчәкмен. Ләкин миңа гына ышанмагыз. Мөмкин булган бөтен чараларны күрегез, Екатерина Павловна.

– Аңлыйм, – диде Бушуева әкрен генә һәм боерыкны үтәр өчен чыгып китте.

Аптекага кайткач, ул, хәлсезләнеп, урындыкка утырды, тәрәзә төбенә таянды. Икенче кулы белән башыннан пилоткасын тартып алды. Йөзе ябыкканга, аның коңгырт чәчләре тагын да куерак булып күренә, тәүлек буенча күктән югалмый торган кояшның нурларында алтын сыман елкылдый иде.

Нина белән Галя аның янына килделәр.

– Зинһар, Газинурны тиз генә эзләп табыгыз, – диде Екатерина Павловна кызларга арыган тавыш белән, үзе шунда ук күзләрен йомды.

Газинур бик тиз килеп җитте.

– Тыңлыйм, Катя Павловна, – диде ул. «Екатерина» дип әйтергә аның теле әйләнми иде. Җырларга кереп җырланган, Газинур өчен гомердә онытылмаслык матур истәлекләр белән бәйләнгән «Катя»ны «Екатерина» белән алмаштыруларына ул бер дә риза түгел иде. Аның болай эндәшүеннән кызлар көлә, Екатерина Павловна үзе дә елмая. Ләкин бүген берәү дә көлмәде.

Газинур килеп кергәч, Екатерина Павловна тиз генә урыныннан торды.

– Газинур, сөеклем, – диде ул, – безнең медикаментларыбыз бетеп бара. Базада берни дә юк – аны яндырганнар... – Екатерина Павловна тирән генә сулыш алды. – Моннан унбиш-егерме километрда, урман эчендәге бер карел авылында, күрше армия госпитале урнашкан. Штабта телефон аркылы сөйләштек. Алар бар кадәр даруларын биреп торырга булдылар. Ләкин алар икенче урынга күченә башлаганнар икән. Шуңа күрә анда бик тиз барып җитәргә кирәк. Син хәзер Николай белән шул авылга бар. Николай юлны белә. Менә сиңа язу, кемгә кирәк – күрсәтерсең. Буш кул белән кайтма. Мин үзем яңадан базага китәм.

Газинур зур кара күзләре белән Екатерина Павловнага текәлеп карап тора. Бу күзләрдә кушканны үтәргә әзер булудан башка берни дә юк иде.

– Барам, буш кайтмам! – диде Газинур, ак халатын салып, почмакка сөялгән винтовкасын эләктерде дә шофер янына йөгерде. Николай – киң җилкәле, йөзе кояшта янып беткән кадровик – аны көтеп тора иде инде.

Машина казылып беткән ишегалдыннан, әле бер якка, әле икенче якка янтая-янтая, урамга, таш юлга чыкты. Озакламыйча Суоярвиның тузанга күмелгән урамнары артта калды. Аннары машина олы юлдан урман эченә – тар юлга борылды.

Көн аяз иде. Юл буйлап үскән агачларның күләгәләре юл аркылы сузылган. Хуш исле җиләс җил исеп тора. Әледән-әле машиналар, олаулар очрый – тирә-якта безнең частьларның тыллары урнашкан. Ләкин җиде-сигез километр киткәч, тыллар бетте, автомобильләр дә, атлылар да, җәяүлеләр дә күренми башлады.

Николай машинасын куа. Аның йөзе кырыс, күзләре, кысылып, як-ягына караналар. Мондый кара урман эчендәге гаскәр йөрми торган юлларда дошманның һавадан ташланган вак диверсия группалары хәрәкәт итүчән була. Николай финнарның тактикаларын бик яхшы белә. Урманда алар вак-вак төркемнәр булып йөриләр, аерым кешеләргә, олауларга, машиналарга һөҗүм итәләр. Ләкин хәзергә әле урман тыныч.

– Екатерина Павловна, күченә башлаганнар, дип әйттеме? – дип сорады Николай.

– Әйе. Кичекмәсәк ярар иде.

Николай машинаның тизлеген арттырды. Байтак вакыт сөйләшмичә бардылар. Ләкин Газинурга сөйләшмичә бару кыен иде.

– Николай, син үзең кайсы якныкы? – дип сорады ул.

Көчле кулларын руль тәгәрмәченә салып, аны бер дә көч куймыйча гына әйләндерә-әйләндерә йөрергә яраткан Николай хәзер рульне нык итеп кыскан. Ул озак җавап бирмәде. Аннары:

– Ерак Көнчыгыштан. Комсомольск шәһәрен беләсеңме? – диде.

– Яшьләр шәһәренме?

Яшьләр шәһәре! Бүтән вакыт булса, Николай ул шәһәрне ничек салулары турында җәелеп сөйләр иде. Кеше аяк басмаган тайганы штурмладылар бит алар! Ничәмә-ничә мең куб метр туфрак актарып чыгарды Николайның экскаваторы!

Юл түбән таба төшә башлады. Урман сирәкләнде, аннары бөтенләй юлдан чигенде. Яктырып китте. Бераздан ялтырап елга күренде.

– Күпер...

Күпер төбендә Николай машинаны туктатты. Аннары, кабинадан төшеп, күперне тикшереп карадылар. Күпер төзек иде.

Машина яңадан тигез юл буйлап очты. Урман бер

якыная, бер ерагая. Урман ерагайган минутларда Николайның киеренкелеге дә кими. Ул сөйләшергә дә каршы түгел.

– Ә үзең кайдан, Газинур?

Газинурны армиядә дә күбрәк исеме белән генә йөртәләр иде. Бик сирәк, рәсми вакытларда гына, аңа фамилиясе белән мөрәҗәгать итәләр, ә күпләр аның фамилиясен белми дә иде.

– Татарстанның Бөгелмә районыннан, «Красногвардеец» колхозыннан.

– Колхозыгызның исеме яхшы икән.

– Ул үзе дә начар түгел! Районда һәрвакыт алдан бара иде.

– Колхозда кем булып эшләдең? Фельдшер булыпмы?

Газинур елмаеп куйды. Келт итеп Сәлим исенә төште. Кайда икән ул «ат докторы»? Исәнме икән?

– Юк, ветфельдшер бездә башка кеше иде, – диде Газинур, – мин колхозчы булып эшләдем. Имгәнгән атларны дәвалауны искә алмаганда, медицина белән алыш-бирешем булмады.

– Кара син! Ә мин сине медик дип торам тагы.

Шуннан соң Николай яңадан байтак вакыт эндәшми барды. Урман тагын юлны ике яктан кысты, ә еракта ул бөтенләй бергә кушылган сыман иде.

Газинур күз кырые белән генә Николайга карап алды. Николайның уң кул аркасына күк тушь белән «1913» дип язылган. Димәк, ул Газинурның яшьтәше, икесе дә бер елда туганнар. Октябрь революциясе вакытында аларга нибары өч-дүрт яшь булган. Гражданнар сугышында өлкән абыйлары пулемет сөйрәп йөргәндә дә алар шар гына сукканнар. Ә хәзер – солдатлар!

Җилеп барган машина яңадан урманны ике якка аерып ташлагандай булды – тирә-як тагын яктырып китте. Тирә-як яктыру белән, Николайның да йөзе ачылды.

– Екатерина Павловна белән сез элек тә танышлар идегезме? – диде ул. – Ире бармы аның?

Николайның тавышында үтә кызыксыну яңгырагандай булды.

– Кызганычка каршы, ире бар шул, бик әйбәт, син бераз соңлагансың, – диде Газинур, көлеп. – Мин алар белән Соликамскида, леспромхозда эшләдем. Аның ире – Володя Бушуев – иң яхшы урман кисүче иде.

– Ә хәзер кайда ул?

– Биредә, сугыша. Екатерина Павловна аның өчен бик борчыла. Яңа яралыларны китергән саен, үз-үзен белештермичә йөгереп чыга.

– Ул чагында аңлашыла, – диде Николай, – югыйсә мин аны артык йомшак бер кеше дип уйлый идем. Ә соңга калу турында син юкны сөйлисең. Минем үземнең сөйгән кызым бар – берәүгә дә алмаштырырлык түгел.

Көтмәгәндә тау битендә зур авыл күренде. Ерактан караганда ул бөтенләй буп-буш шикелле иде.

– Китеп өлгергәннәрме әллә? – дип борчылды Газинур.

Машина басу капкасыннан авылга керде. Кырыйдагы урамнарда бер генә җан иясе дә юк, күрәсең, барысы да эвакуацияләнгәннәр. Газинурның да, Николайның да борчылуы бермә-бер артты. Ләкин Николай машинаны туктатмады. Авыл уртасында больница бар. Әгәр булсалар – шунда булырга тиешләр.

Больница каршында, агачлар арасында, чыннан да йөк машинасы тора иде. Николай үз машинасын аның янында туктатуга, каршы як йорттан юан гына бер капитан йөгереп чыкты.

– Ниһаять! – диде ул, Газинур сузган язуны укыгач. – Без инде сезне бер сәгать көтеп торабыз. Хәзер китә идек. Авыл буш, бездән башка беркем дә юк. Әле күптән түгел генә авыл өстендә тегеләрнең самолетлары тилгән кебек очып йөрде. Кайтканда сак булыгыз. Машина күрсәләр, эзәрлекләп җанны алалар.

Йөкне бер машинадан икенчесенә күчерү озак вакыт алмады. Шуннан соң саубуллаштылар да ике машина ике якка китеп тә барды.

Газинур спидометрга күз төшерде. Спидометрның стрелкасы иң актык чиктә дерелдәп тора. Шулай да аңа алар бик әкрен баралар кебек тоелды.

– Коля, ку, дускай, аргамагыңны!

Юлның яртысыннан күбрәген үтеп, Суоярвига якынлашканда, һавада мотор тавышы ишетелде. Газинур самолетларның кайсы якныкы икәнен мотор тавышлары буенча аерырга күнекмәгән иде әле.

– «Мессер»! – диде Николай. Йөрешен бераз киметә төшкән машина яңадан котырып чаба, чокырлы урыннарда чамадан тыш каты сикерә башлады. Николайның кашлары җыерылды, үзе бөтен гәүдәсе белән алга омтылды. Самолет һөҗүменә беренче эләгүе түгел иде аның.

Тар юлның ике ягында да су белән тулы чокыр сузыла. Беркая борылыр урын юк. Фашист инде артка төшеп килә. Ул пулеметтан ут ачты, пуляларның юлга кадалулары ап-ачык күренә, пуля тигән агач ботаклары кителеп төшәләр.

Самолет тавышы якынайганнан-якынайды. Менә уң як фара челпәрәмә килеп очып китте. Шул ук секундта Николай тормозны үзенә тартты. Машина кинәт туктатудан чак кына мәтәлчек атып китмәде. Газинур маңгае белән винтовкасына шундый каты бәрелде, күзләреннән утлар чәчрәде.

Самолет машина өстеннән узып китте. Николай кабинадан аңа ачулы күзләре белән карап алды да яңадан кузгалды. Ләкин «мессер» бераз югалып торды да, яңадан килеп чыгып, кабаттан эзәрлекли башлады. Николай машинасын яңадан бөтен тизлегенә куды, аннары, самолет килеп җитте дигәндә генә, яңадан кырт итеп туктатты. Ләкин шыбырдап яуган пуляларның берсе кабина пыяласын ватты, пыяла кисәкләре Николайның битләренә, күзләренә кадалды. Ул куллары белән йөзен каплауга, бармак араларыннан кан күренде. Газинурның куллары белән сул колагы гына җиңелчә тырналган иде.

– Коля!.. – диде ул, куркып.

Николай, берни әйтмичә, руль өстенә капланды.

Газинур кабинадан сикереп төште дә кузовка менде. Ящикны ачып, һавага карый-карый, марля, мамык алды. Аннары тиз генә Николайның башын бәйләде.

– Тәмәке! – диде Николай.

Газинур аңа папирос каптырды, ут кабызды. Николайның канлы куллары калтырый иде.

– Хәзер тагын килеп җитәчәк, кабахәт...

Ләкин һава тын. Бернинди гөрелте дә ишетелми. Күрәсең, фашист, эшләрен бетердем дип уйлап, китеп барды.

Газинур аптырашта иде. Инде нишләргә? Машинаны ташлап, Николайны җитәкләп китәргәме? Ә медикаментлар? Әллә Николайны машинада калдырып, бөтен көченә йөгерергәме? Юк, монысы ярамый. Кара урман эчендә кем булмас.

Газинур шулай аптырап торган арада, Николай руль тәгәрмәчен, рычагларны кулы белән капшап чыкты:

– Мотор төзекме?

– Белмим шул. Мин бернәрсә дә аңламыйм бит, Коля.

– Өстән генә кара. Капотта пуля эзләре бармы? Ватык җире булса, күрерсең.

Газинур, капотны карагач, ул-бу юклыгын әйтте.

– Ә машина ничек тора?

– Алгы тәгәрмәчләре чак кына канауга төшмәгән. Юлга аркылы диярлек.

Николай машинаны алып барачагын әйткәч, Газинур ышанмыйчарак торды.

– Буш кул белән кайтып булмый ич. Син миңа кайчан уңга, кайчан сулга барырга кирәклеген әйтерсең. Мин юлны күз алдыма китерәм. Тик син уң белән сулны гына бутама.

Иң кыены машинаны юлга турылап кую булды. Николай моны бик зур саклык белән эшләде. Ниһаять, машина юл уртасына басты.

– Ничек?

– Кыл уртада.

Машина әкрен генә кузгалып китте. Газинур әле «уңгарак», әле «сулгарак» дип юл күрсәтеп барды. Николай, руль артында әүвәлгечә туры утырып, күрми торган күзләре белән алга карап барды. Аның бөтен нервысы киерелгән, ул хәтта беркадәр вакытка яраларының сызлавын да онытты.

Шулай алар госпитальгә килеп җиттеләр. Көтә-көтә борчылып беткән Екатерина Павловна аларны капка төбендә каршы алды. Ул ерактан ук машинадагы ящикларны күрде, ләкин машинаның бик әкрен килүе аны куркытты. Ватык кабина эчендә йөзе-башы марля белән уралган шоферны күргәч, аның куркуы тагын да артты. Машина туктады.

– Алып кайттык! – диде Газинур, машинаның ишеген ачып, үзе Николайга төшәргә булыша башлады.

## 5

Икенче көнне иртә белән Газинур бик озак вакыт кичәге хәлләр тәэсире астында йөрде. Ажгырып килгән дошман танкысына каршы күкрәгенә граната кысып атлаучы МТС бригадиры Исхак Зәбиров бер генә минутка да аның күз алдыннан китмәде. Зәбиров белән янәшә шофер Николай басып торды. Әле кичә генә Николай белән Газинур бер госпитальдә эшлиләр иде, әле кичә генә алар бер кабинада утырып бардылар. Николай гади бер рус егете иде. Әгәр кичә иртән, Николай шундый батырлыкка сәләтле, дисәләр, Газинур бик үк ышанмаган да булыр иде. Ләкин Николай, Газинур белән янәшә утырган хәлендә, яраларының коточкыч сызлавына, якты дөньяны гомергә югалту куркынычы бәгырен телгәләүгә карамастан, канга һәм тиргә батып, бернәрсә дә күрмичә, күзләре бәйләнгән килеш, бары тик «уңга-сулга» дигән сүзләргә ияреп кенә, ун километр буенча базлы-сазлы юлдан машинасын алып килде.

Бу гади кешеләргә кайдан шулкадәр көч, түземлек, батырлык килгән? Газинур алар кебек була алыр идеме?

Юк, мөгаен, була алмастыр. Ул бит, Николай яралангач, күзле булып та, ни эшләргә белмичә аптырап калды. Алар кебек булыр өчен аңа әле бик күп, бик күп чыныгырга кирәк шул! Карчыганың канаты очканда ныгый. Газинур әле яңа оча гына башлады. Чыныгыр өчен бик күп очарга кирәк шул.

Ләкин бу көнне шундый кызу вакыйгалар башланды, Газинурның хискә бирелергә түгел, ашханәгә барып кайтырга да вакыты калмады.

Берничә атна буенча барган бик каты сугышлардан соң сан ягыннан бик күп өстен булган берләшкән фин һәм немец-фашист гаскәрләре, бу участокта фронтны өзеп, кызу рәвештә, Суоярвига һәм Карелиянең башкаласы – Петрозаводск шәһәренә таба килә башлаганнар. Госпитальдә шул хәбәрне алырга гына өлгергәннәр иде, дошман самолетлары килеп чыкты. Алар, узышлый госпитальгә берничә бомба ташлап, тимер юл станциясен бомбага тотарга киттеләр.

Тагын бер сәгатьтән госпитальгә ашыгыч рәвештә икенче урынга күчү турында приказ алынды. Ыгы-зыгы башланды. Беренче чиратта яралыларны ташырга керештеләр. Яралылар төялгән санитар автобуслар, йөк машиналары, атлар бер-бер артлы станциягә юнәлделәр. Җиңелрәк яралылар үз аяклары белән китте. Аларны сестралар озата барды. Ә алгы сызыктан яңадан-яңа яралылар килеп торды. Ашыгыч операциягә мохтаҗ булганнарын, машинадан төшереп, тиз-тиз санобработка ясап, шунда ук операция өстәлләренә салдылар.

Соңгы берничә көн эчендә дошман авиациясе тимер юл станциясен өзлексез рәвештә бомбага тотканлыктан, яралыларны вакытында эвакуацияләргә мөмкинлек булмады. Шуңа күрә госпитальдә яралылар шактый күп җыйналган иде. Хәзер тимер юлны төзәтеп өлгергәннәр. Эшелон инде станциядә тора. Ләкин һәр минут саен дошман самолетлары килеп чыгуы мөмкин. Бу турыда госпиталь җитәкчеләре генә түгел, яралылар да белә. Үзләре кузгала алмаган авыр яралылар тешләрен кысып көтеп торалар. Әгәр яннарыннан ак халатлы берәр кеше йөгереп үтеп китсә, алар аның артыннан озак карап калалар. Алар: «Башта мине алып китегез», – дип ялвармыйлар, тавыш кубармыйлар, әмма күзләрендә бары тик шул бер үтенеч кенә. Аларны барысыннан бигрәк үзләренең бернәрсә дә эшли алмаулары, язмышны кул кушырып көтеп торырга мәҗбүр булулары газаплый.

Газинур яралыларны носилка белән машинага ташыша иде. Алгы сызыктан, әле яңа гына килеп туктаган маши-

наларның берсе яныннан узганда, аны бер яралы туктатты.

– Иптәш санитар, сездә Бушуева дигән врач юкмы?

– Бар, – диде Газинур.

– Аңа лейтенант Бушуевтан сәлам. Ул соңгы группа белән безнең чигенүне капларга калды. Мин яраланганда исән иде әле. Хәзер белмим...

– Туктагыз, мин Катя Павловнаны чакырып киләм, хәзер, – диде Газинур.

Ләкин госпиталь начальнигы машиналарны шунда ук станциягә борып җибәрде.

– Тиз, тиз булыгыз! – диде ул шоферларга.

Машиналар киткән генә иде, Газинурны эзләп Нина килде, аны Екатерина Павловна янына чакырды.

Газинур килеп кергәндә, Екатерина Павловна белән Галя медикаментларны ящикларга төйиләр иде. Екатерина Павловнаның йөзендә арыганлык, тирән кайгы беленеп тора. Әле тыныч елларда, булачак сугышлар турында сүз чыкканда, Владимир еш кына: «Дошман бары тик безнең мәетләребез аша гына алга үтәчәк. Без исән чакта аңа юл булмас», – дип сөйли торган иде. Госпиталь начальнигы фронтның өзелүе турында әйткәч, Екатерина Павловнаның күз аллары караңгыланып китте. «Володя юк инде», – дип уйлап алды ул, күз яшьләрен бүтәннәргә күрсәтмәс өчен, йөзен читкә борды.

Ләкин кайгыга бирелеп, каушап торыр чакмыни! Хәзер үк аптеканы станциягә күчерә башларга кирәк. Медикаментлар күз карасы кебек кадерле. Бер генә метр бинтны да, бер генә кисәк мамыкны да ташлап калдырырга ярамый. Ә дарулар турында әйтеп тә торасы юк. Ләкин аларны ничек күчерергә? Эшелон, ичмасам, станциягә дә килеп җитә алмаган, ул шәһәрдән берничә километр читтә туктаган.

Николай исән булса, эш башкача торыр иде. Аның машинасы аптекага махсус рәвештә беркетелгән иде. Инде ул юк, аны яралылар белән бергә алып киттеләр. Машинасы да бик нык зарарланган. Машинаны караган шоферлар башларын гына чайкадылар.

– Газинур, – диде Бушуева, озын керфекләрен күтәреп. – Без дә хәзер күчә башлыйбыз. Машинабыз юк, ә әйберләребез, үзең күрәсең, җыя торгач, күп. Госпиталь начальнигы безгә... ат бирергә булды. Син шул атны тиз генә табып ал.

– Була ул, – диде Газинур беркадәр ваемсызрак тавыш белән. Ләкин үзе бер ат белән генә монда әллә ни кырып булмасын бик яхшы төшенде.

– Барыгыз, Газинур, – диде Екатерина Павловна, үзе кызларга борылып өстәде: – Зинһар, яхшырак төягез, юлда ватылырлык булмасын. Юл начар.

Газинур ни өчендер китми тора иде. Шкафтан ниндидер сыекча тутырылган зур пыяла савытны кулына алган Екатерина Павловна, аңа иңбашы аркылы карап:

– Газинур, берәр сүзең бармы әллә? – дип сорады.

– Әйе, Катя Павловна... Володя сезгә сәлам әйтеп җибәргән.

– Володя?! – Екатерина Павловна шатланып кычкырып җибәрде. Ул хәтта чайкалып китте, кулындагы пыяла савыты төшә язды. – Кайда ул? Исәнме? Кем аркылы әйттергән? Кайда ул кеше? Нигә миңа башта ук килеп әйтмәдең?

Газинур яралы сөйләгәннәрне кабатлап бирде, ләкин Екатерина Павловнаны борчымас өчен, Володяның соңгы группа белән безнең частьларның чигенүен капларга калуы турында бер сүз дә әйтмәде.

Екатерина Павловна, сөенеч белән тулы күзләрен Газинурга текәп:

– Рәхмәт сиңа, – диде, әйтерсең бу сәламне алгы сызыктан Газинур үзе алып килгән иде.

Газинур ашыгып чыгып китте.

Кызлар аптеканың барлык медикаментларын ящикларга, капчыкларга тутырдылар. Екатерина Павловна төеннәрне санап чыкты, блокнотына теркәп куйды. Ул арада Газинур йөгереп килеп керде.

– Булды, – диде ул шаян тавыш белән. – Ат та, машиналар да.

– Машиналар? – дип гаҗәпләнеп сорады Бушуева.

– Әйе, машиналар. Безнең бабайлар: йөз сум акчаң булганчы йөз дустың булсын, диләр, Катя Павловна. Минем йөз сум акчам юк, йөз дустым бар, – диде Газинур, аннары: – Кайсы ящикларны чыгара башларга мөмкин? – дип сорады.

Госпитальнең барлык шоферлары Газинурның дуслары иде. Ул үзенең үтенечен сөйләп биргәч, аларның берсе дә каршы килмәде. Аптека ящиклары һәм капчыклары яралылар белән бергә аларның аяк очларында, баш асларында эшелонга китә торды. Ә санитар машиналарга куярга мөмкин булмаганнарын Газинур үзе ат белән ташыды. Шулай итеп, аптека госпитальнең бүтән бүлекләренә караганда иң беренче булып эшелонга күченде.

Үз эшен бетергәннән соң да Газинур тынычланып калмады. Ул башкаларга булыша башлады. Госпитальдә калган соңгы врач белән соңгы сестраны, алар белән кал-

ган берничә санитарны алып кайтыр өчен дә госпиталь начальнигы аны җибәрде.

– Гафиятуллин, бер аягың – анда, бер аягың монда булсын! – диде ул, борчылып, зәңгәр күккә карады.

Газинур шофер янына кабинага утыргач, алар китеп тә бардылар. Озакламыйча машина госпиталь капкасыннан килеп керде. Шул ук минутта диярлек һавада мотор тавышлары ишетелде. Шофер машинаны йорт ышыгына яшерде. Аннары Газинур белән, машинадан төшеп, базга йөгерделәр.

Бомбаларның берсе әле күптән түгел генә операционный булган флигель янына төшеп ярылды. Икенчесе беренче корпусны актарып ташлады. Калганнары кайдадыр читтә ярылдылар.

Колаклары тонган, өсләренә туфрак коелган Газинур белән шофер баздан чыкканда, госпитальнең барлык бинаЛары диярлек дөрләп яна иде. Дошман фугас бомбалардан тыш бик күп яндыргыч бомбалар да ташлаган икән.

Шофер машинасын коткарырга ташланды. Газинур ут диңгезе уртасыннан флигельгә таба йөгерде. Икенче яктан яланбаш, йөзе канга баткан бер санитар йөгереп чыкты.

– Врач белән сестра флигельдә калдылар! – дип кычкырды ул. – Операционныйда!

Флигельгә ишектән керергә мөмкин түгел иде инде. Кемдер – Газинур күреп тә өлгермәде – ватык тәрәзәдән эчкә кереп китте. Аның артыннан ук Газинур да тәрәзә аркылы эчкә керде. Бүлмәләр төтен белән тулы иде. Газинур операционныйга таба барганда, аның каршысына врачның гәүдәсен күтәреп килгән Газзән очрады.

– Анда сестра Тамара белән малай калды! – дип кычкырды ул, туктамыйча гына.

Газинур операционныйга йөгереп керде. Өстәл янында, идәндә, кулларын җәеп, кан эчендә сестра ята. Өстәлдә унике-унөч яшьлек малай ыңгыраша.

Газинур малайны кулына алды. Килеп җиткән икенче бер санитар сестраны күтәрде. Ялкын инде эчкә үрли. Обойлар, түшәмгә ябыштырылган газеталар яна...

Машина, ут өермәсе эченнән чыгып, киң юлга борылды. Газинур кулларына карап алды. Алар канга буялып беткәннәр. Күрәсең, тәрәзәдән кергәндә, пыяла ватыкларына кискән.

Шофер машинасын бөтен көченә куды. Берәү дә сөйләшмәде. Барысы эшелон турында гына уйлады: андамы, китеп бармаганмы?

Станция яныннан үттеләр. Анда бөтен биналар янып, җимерелеп, җир белән тигезләнеп беткән. Юлларда калган ялгыз-ярым вагоннар, паровозлар гына әле һаман да яналар, станция биналарының, пакгаузларының калдыклары да төтенли. Рельслар тимерчыбык кебек бөгәрләнеп бетканнәр. Бөтен җирдә яңа бомба чокырлары.

Машина борылышны үтеп, алда эшелон күренгәч, кешеләр җиңел сулап куйдылар. Машинага каршы еракган ук: «Тамара, Тамара!» – дип, ике кызның йөгереп килгәне күренде. Газинур машинада Тамараның хәрәкәтсез яткан гәүдәсенә карап алды да, машина туктар-туктамас борын ук сикереп төшеп, госпиталь начальнигына каршы йөгерде...

Озакламыйча эшелон кузгалып та китте. Юл коточкыч иде. Дошман самолетлары, эшелонны ике тапкыр куып җитеп, бомбага тоттылар. Иң арттагы вагоннарның берсе – азык-төлек вагоны яна башлады. Аны юлда ташлап калдырдылар.

Екатерина Павловна үзен нык тота, бомбалар төшкәндә, башкалар кебек, йөзен куллары белән каплап, бөтен гәүдәсе белән калтыранмый. Ә Нина белән Галя, мескеннәр, тәмам агарынганнар, бер-берсен кочаклап утыралар, самолет тавышы ишетсәләр, шулай кочаклашкан килеш йөзләре белән капчыкларга капланалар.

Газинур, үзенең ерак колхозын, Миңнурыен, балаларын исенә төшереп, әкрен генә җырлый иде.

– Җитәр, Газинур! – дип кычкырды кызларның берсе. – Зинһар, күңелгә шом салма, болай да чәчләр үрә тора.

Газинур аларны көлдерергә, күңелләрен күтәрергә тырышты. Ләкин башка вакытта көләргә дә, җырларга да, сүз әйтешергә дә яраткан кызлар бу юлы берни тыңларга теләмәделәр.

Бер урында эшелон шактый озак туктап торды. Алда станцияне бомбага тотканнар, тимер юл да ватылган, диделәр. Биредә тыныч. Юлдан йөз-ике йөз метрларда поселок күренә. Поселок яна, ләкин янгынны берәү дә сүндерми. Гомумән, поселокта бер кеше дә юк бугай, киткәннәр.

Газинур вагоннан сикереп төште. Күрше вагон ишегеннән Мисбах белән Газзән карап торалар иде.

– Сүндерүче дә юк бит! – диде Мисбах, яна торган йортларга ымлап. Аның тавышы әрнүле иде.

– Абый, – диде кинәт Газинур, – янган икмәк исе килә түгелме?

– Әнә кибет яна, – диде Мисбах, кулын алга сузып.

– Кибет? Бәлки, анда берәр нәрсә бардыр? Яралыларга безнең бернәрсәбез дә калмады бугай!

– Начальниклар бу турыда синнән яхшырак беләләр. Кирәк булса, кушарлар әле, – диде Газзән.

– Әй, кушып торганны көтсәң...

Газинур кибеткә таба йөгереп китте. Мисбах аңа нидер кычкырды, ләкин ул аны ишетмәде.

Кибетнең ватык тәрәзәсеннән Газинур эчкә карады. Идән уртасында зур гына ящик тора. Шүрлекләрдә дә ниләрдер бар.

«Кара, никадәр әйберне ташлап киткәннәр!» – дип ачынып уйлады Газинур. Идән уртасындагы ящикта шоколад плиткалары иде. Газинур, иелеп, ящикны күтәрмәкче булды, ләкин ящик ишелеп төште, күрәсең, аны ватык булганга ташлап калдырганнар да. Шүрлекләрдә печеньелар, конфетлар, папирослар, галантерия әйберләре тулып ята.

Газинур күп уйлап тормады, гимнастеркасын салып, якасын бау белән бәйләде дә шоколад плиткаларын тутыра башлады.

– Газинур, нәрсә алып кайтасың? – дип ачуланып сорады Екатерина Павловна.

– Шоколад! Авыр яралыларга безнең бернәрсәбез дә калмады бит – хәзер шоколад белән сыйлыйбыз. Анда әле печеньелар да бар. Аларын да алып кайтырга кирәк. Дошманга калганчы үзебезнекеләр ашасын.

Газинур шоколад тутырган гимнастеркасын вагонга ташлады да тагын йөгереп китте.

Эшелон буйлап үтеп барган комиссар Екатерина Павловнадан:

– Нәрсә ташый ул? – дип сорады.

– Шоколад китерде. Авыр яралыларга өләшербез дип әйтә.

– Шоколад?

Комиссар, мәсьәләгә бик тиз төшенеп, күрше вагоннар янында басып торган санитарларга:

– Ә сез, егетләр, нәрсә карап торасыз. Йә әле, йөгерегез! – дип кычкырды.

## 6

Бер тәүлек чамасы туктап-туктап барганнан соң, эшелон кечкенә бер разъездда бөтенләй туктады. Тимер юлның ике ягында да гаҗәеп матур каен урманы шаулый иде. Газинур урманда күп йөрде, күп яшәде, әмма каен урманындагы кебек матурлыкны һичкайда күрмәде.

Каеннарның ак мәрмәр кебек кәүсәләре тирә-якны яктыртып җибәргәннәр, алардан гаҗәеп бер җиңеллек, пакьлек бөркелеп тора кебек. Бигрәк тә ут эченнән килгәннән соң, ак каеннар Газинурга көчле тәэсир ясады. Ул, гаҗәпләнеп, тирә-ягына каранды. Тимерьюлчының йорты тирәсендә гамьсез тавыклар йөри, бераз арырак, ак тартмалар кебек, умарта оялары күренә. Әгәр дә разъездга килеп туктаган бу кызыл эшелон, аннан ашыгып-ашыгып төшкән хәрби кешеләр булмаса, кайдадыр якында гына канлы сугыш баруын да күз алдына китермәс идең. Чөнки биредә бөтен нәрсә тынычлык, тынлык һәм яшәүгә омтыла иде.

Тимер юлдан бер-ике километрда, урман аланында, госпиталь вакытлы чатырлар корып җибәрде, яңадан аның кызыл хачлы ак флагы җилферди башлады. Берничә сәгатьтән соң госпиталь яңа яралыларны кабул итәргә тотынды. Яңадан, Суоярвидагы шикелле, госпитальнең көндәлек киеренке тормышы башланды.

Бер айдан артык вакыт үтте. Ак төннәр, исәпсез күп черкиләр кимеде, хәзер төннәр озайганнан-озая, караңгыланганнан-караңгылана бара. Яңгырлы-болытлы төннәрдә инде ике чатыр арасында да адашырга мөмкин: күзгә төртсәң, күренми.

Көз сулышы бөдрә каеннарга да орынды. Каеннарның яфраклары саргая башлады, һава шактый сизелерлек салкынайды. Күп тә үтмәс, озын, салкын Карелия кышы килеп җитәр. Хәзер инде һәркемгә ачык: сугыш озакка сузылачак, кышка әзерләнергә кирәк. Ләкин шушы көннәрдә фронттан күңелне күтәрә торган яхшы хәбәрләр килә башлады. Безнекеләр дошманның алга килүен бөтен фронт буйлап туктатканнар, ә кайбер участокларда контрһөҗүмгә дә күчкәннәр. Рәсми сводкаларда бу турыда берни дә әйтмиләр, хәтта Карелия фронтын күп вакытта телгә дә алмыйлар. Бу хәбәрне, һәрвакыттагыча, яралылар алып килде. Аларның кайсы кемгә бу шатлыклы хәбәрне беренче булып сөйләгәндер, берәү дә белми, әмма ул минуты, секунды белән бөтен госпитальгә таралды.

Екатерина Павловна Бушуева бу турыда «соңгы хәбәрләр капчыгы» Газинурдан ишетте. Газинур, чатырның асылма ишеген кайтарып керә-керә үк, күңелле тавыш белән кычкырды:

– Катя Павловна, кызлар! Безнекеләр һөҗүм итә, ак финнар табан ялтырата!

Өстәл артында нидер язып утырган Екатерина Павловна, һәрвакыттагыча дарулар әзерләү белән мәшгуль

булган Нина белән Галя урыннарыннан сикереп тордылар.

– Бу турыда сводкада юк әле, миңа яралылар сөйләде. Ак финнарны кызган табага бастырганнар! – дип аңлатып бирде Газинур. Аның зур кара күзләре ялтырый, әйтерсең ул үзе дә дошманны куып бара иде.

Нина белән Галя шатлыкларыннан бер-берсенең муенына атылдылар, ә Екатерина Павловна, күзләрен зур итеп ачып, каядыр еракка карый, гүя ул ут һәм төтен эченнән алга барган үзенең Володясын күрә иде. Газинур Володяның соңгы группа белән безнекеләрнең чигенүен капларга калганлыгын әле бүгенгәчә аңа әйткәне юк иде, Екатерина Павловна аны исән дип уйлый, көтә, аның белән яши, ә Володя, бәлки, күптән инде... Нигә соң Газинур аңа ул чакта ук әйтмәде. Ә хәзер әйтсә, Екатерина Павловна ышанмас, табигый, Володя юк инде, аның үлемен миннән генә яшерәләр, дип уйлаячак. «Менә бит ничек була ул...» – дип эченнән сызланды Газинур. Ул, Екатерина Павловна кебек үк, түземсезлек белән Володядан хат көтте, ләкин хат һаман юк иде...

Екатерина Павловна моңсу гына елмайды:

– Рәхмәт, Газинур, син һәрвакыт безгә яхшы хәбәрләр китерәсең! – диде.

Газинурга шулкадәр авыр булды, ул, бер-бер нәрсә сиздереп куймас өчен, тиз генә чатырдан чыгып китте.

Озакламый ул яңадан кайтты, мич ягып җибәрде.

Менә Газинур мич алдында, тумран өстендә утыра. Мич авызыннан төшкән дерелдәвек яктылык аның йөзен кызарткан. Ул уйчан, бу юлы аның кара кашлары гаҗәпләнгән сыман югары күтәрелмәгән, ә җыерылып бергә кушылганнар.

Кызлар озын өстәлдә, җиделе лампа яктысында, үз эшләре белән мәшгуль, Екатерина Павловна кечкенә өстәл янында нидер язып утыра. Чатырның түбәсендә яңгыр шыбырдый, яхшылап тартылмаган почмакны җил шапылдата. Чатыр эчендә тынлык, кызлар да нигәдер гадәттәгечә сайрашмыйлар, тын гына эшлиләр. Шулай бер сәгать чамасы узгандыр. Аннары Екатерина Павловна урыныннан торды, кызлар янына килде.

– Булдымы, акыллыларым? – дип сорады. Ул кызлардан өч-дүрт яшькә өлкәнрәк булса да, ак халат кигән килеш алар белән янәшә басканда, барысы да мединституттан килгән практикантлар булып күренәләр, арада аларның кайсы олырак икәнен дә аеруы кыен.

– Булды, Екатерина Павловна, – диде Нина, урыныннан торып. Галя да өстәл яныннан китте. Газинур бүгенгә

аларның эшләре беткәнлеген аңлады. Әчпошыргыч тынлыктан туеп та, эш вакытында бер генә шаян сүз әйтергә кыймаган Газинур берьюлы җанланып китте. Ул, утка караган килеш, кинәт үзалдына көлеп җибәрде.

– Газинур, әллә Миңнурыеңны исеңә төшердеңме? – дип, иптәшләренә күз кысып сорады Галя.

Алар барысы да Газинурның өйләнү тарихын беләләр. Ул аларга хатынының ничек итеп элекке ухажеры белән театр уйнавын да, үзенең бала күтәреп театр карап утыруларын да – берсен дә калдырмый сөйләп биргән иде. Кызлар ул чакта күзләреннән яшь чыкканчы көлделәр, шул турыда бик озак бәхәсләштеләр. Газинурны көнләшә белмәүдә гаепләделәр. Нина аңа кара мавр турында сөйләп бирде. Газинур аны күзләрен зур итеп ачып тыңлап торды да ахырда:

– Ул кара гарәп дигәнегез кайсы илдә яшәгән? – дип сорады. Маврның чит илдә моннан бик күп еллар элек яшәгәнлеген белгәч, сызгырып җибәрде.

– Мин колхозда шундый бер әкәмәт тип булганмы дип гаҗәпләнеп торам тагы. Заграницада ни булмас. Анда Гитлерлар да, Чемберлиннар да бар. Кара гарәп бер кешене суйган, ә болары меңәрләп суялар.

Газинур башын күтәрде. Екатерина Павловна ягына карап алып, башын чайкады.

– Юк, Галочка, Миңнурыйны тулган айга караганда гына исемә төшерәм. Бездә, сагынганда айга кара, айда очрашыр күзебез, дип җырлыйлар.

– Очрашамы соң?

– Кайчагында очраша.

– Ой, алдыйсың! Хәзер ни өчен көлеп куйдың? Ялганламый гына әйт әле.

– Галәк бабайның бер хикәятен исемә төшердем. Тыңласаң, сиңа сөйләп бирәм. Ул сиңа кирәк булачак.

– Нигә?

– Менә тыңлагач күрерсең. Галәк бабай безнең колхозның иң карт кешесе. Аңа инде йөз яшь бардыр. Мәктәп бусагасына утырып, әкият сөйләргә ярата торган иде ул. Ә без, малай-шалай, әтиләрнең бишмәтләрен киеп, аның аяклары янына, җиргә чүгәләп утыра идек тә, авызына карап, тын да алмыйча тыңлыйдыр идек. Беркөнне ул безгә бер-берсен яраткан егет белән кыз турында сөйләде. Элекке заманда безнең татарларда егет белән кыз бер-берсен күреп сөйләшә дә алмаганнар, очраша да алмаганнар. Хатлар язышу турында әйтеп тә торасы юк – берәү дә укый-яза белмәгән. Ләкин егетләр-кызлар барыбер бер-берсен яратышканнар, бер-берсенең мәхәббәтләрен бе-

лешкәннәр. Таңчулпан белән Кәрим дә бер-берсен сөйгәннәр, ләкин ата-аналары аларны кавыштырырга теләмәгәннәр, чөнки Кәрим бик ярлы булган. Ата-аналары Таңчулпанны бер ишанга сатканнар. Таңчулпанны алып киткәннәр. Кәрим авылда булмаган, аны лашманга озаткан булганнар. Ләкин ул моны барыбер белгән, ишанны кара урманда куып җитеп, Таңчулпанны коткарган.

– Ничек белгән ул?

– Болай белгән: бер-берсен яраткан кешеләрнең йөрәкләреннән йөрәкләренә күзгә күренми торган җепләр сузыла икән. Әгәр яратышучыларның берсе ямансылый, йә сагышлана башласа... – Газинур күз кырыйлары белән Екатерина Павловнага карап алды. Бушуева, өстәл янына баскан килеш, аны тыңлап тора иде. – Әйе, яратышучыларның берсе ямансылый яки сагышлана башласа, йөрәкләрдән йөрәкләргә сузылган күзгә күренми торган нечкә җепләр скрипка кыллары кебек чыңлый, моңлана башлыйлар, үзәкне өзәләр, күңелсезләндерәләр, көчне суыралар... Менә шуның өчен, Галочка, әгәр сөйгән егетең көчле булсын дисәң, дошманнарны җиңсен дисәң, һичкайчан ямансылама. Чөнки синең ямансылавың аңа барыбер билгеле булачак...

– Ой, Газинур, син көнчыгыш хакиме икәнсең бит! – дип кычкырды Галя.

Екатерина Павловна тиз генә Газинур янына килде. Ул шактый дулкынланган иде.

– Газинур, син бу экиятне үзең уйлап чыгардыңмы әллә?

– Юк, Катя Павловна. Мин аны чыннан да Галәк бабайдан бер ишеткән идем. Мин аңардан бик күп экият ишеттем. Мин кечкенәдән экият тыңларга ярата идем. Тик оста итеп сөйләргә генә өйрәнеп булмады.

– Газинур, – диде кинәт Бушуева, аның иңбашына кулын куеп, – син бу экиятең белән минем бөтен йөрәгемне актарып ташладың бит.

Екатерина Павловна, ике кулы белән ике битен кысып, чайкала-чайкала өстәле янына китте. Газинур урыныннан сикереп торды, бер Екатерина Павловнага, бер тынып калган кызларга карады.

– Зинһар, гафу итегез, Катя Павловна, мин тилене. Җыен тузга язмаганны сөйлим шунда, – диде ул әкрен генә.

Бушуева тиз генә аңа таба борылды.

– Юк, Газинур, син тиле түгел. Син әле нинди әйбәт егет икәнлегеңне үзең дә белмисең! Сабак бирүең өчен рәхмәт!

Мичтә һаман коры утын дөрләп яна, җил чатыр брезентын лапылдата. Чиксез уңайсызланган Газинур, башын түбән иеп, чатыр уртасында басып тора, ә ак халатлы ике кыз аңа сокланып карыйлар.

Икенче көнне Газинур иртәдән үк җырлап йөри башлады. Ә төш вакытында Екатерина Павловнаның чатырына янып-пешеп йөгереп керде дә, аның бик бирелеп эшләп утыруына карамастан, беренче тапкыр аны эшеннән бүлдерде.

– Катя Павловна, – диде ул, шатлыктан тотлыгып, – сезгә хат! Володядан!

Бушуеваның йөзе ак халаты кебек агарынды. Ул, урындыгын аударып, урыныннан торды. Бер кулы белән күкрәгенә тотынды, икенчесен алга сузды.

– Володядан?! Кая, бир тизрәк!

Газинур аңа өчпочмаклы хат бирде. Екатерина Павловнаның куллары калтырый иде. Газинур аңа сулыш алмыйча карап торды – ул бит хатта ни язылганын белми иде.

Хатны укыган саен Екатерина Павловнаның сагышлы йөзе яктыра, нурлана барды. Әгәр Газинур үз-үзенә читтән карый алган булса, ул үз йөзенең дә яктыра, нурлана барганын күрер иде.

– Володя исән, – диде Бушуева, хатны укып бетергәннән соң. – Унга якын хат яздым, дигән, ә мин берсен дә алмадым. Минем өчен борчыла...

– Кайда ул? – дип сорады Газинур.

– Масельская юнәлешендә дигән...

## 7

Урманнар, сазлар, таулар, исәпсез-хисапсыз күлләр, елгалар белән капланган Карелия җире сугыш операцияләре алып бару өчен иң кыен урыннарның берсе санала. Ул Баренц диңгезеннән алып Ладога күленә кадәр сузыла, бу йөзләрчә километр арада гаскәр йөрерлек яхшы юллар да, танклар, артиллерия һәм авиация катнашы белән киң күләмдә сугыш операцияләрен җәелдерер өчен зур мәйданнар да бик аз. Төньякның бердәнбер тормыш артериясе булып Киров тимер юлы сузыла. Ул Беломорск, Лоухи, Кандалакша аркылы төньякның башкаласы Мурманскига – төньякта бердәнбер булган, ел әйләнәсендә туңмый торган порт шәһәренә бара.

Немецларның һәм финнарның берләшкән төньяк группа гаскәрләренең төп бурычы әнә шул Киров магистрален кисү, Мурманск шәһәрен алу булса, аларның көньяк-

тагы гаскәрләре Ленинградны ерактан урау максатын үтиләр иде. Совет командованиесе сугышның башыннан ук гитлерчыларның стратегик планнарын сизеп алды, куркыныч янаган барлык әһәмиятле урыннарга вакытында гаскәр туплады. Ставканың боерыгын үтәп, төнге караңгылыкта гаскәрләр ашыгыч рәвештә бер урыннан икенче урынга күченде. Алар артыннан санитар частьлар да кузгалды.

Екатерина Павловнаның чиксез зур шатлыгына каршы, аларның кыр госпитален Масельская юнәлешенә – Сегежа шәһәренә күчерделәр. Хәзер Екатерина Павловна Володяга якынрак булам дип куанды. Юлда килгән чакта Газинур аңа Володяның соңгы группа белән безнең гаскәрләрнең чигенүен капларга калганлыгын сөйләде. Екатерина Павловна, Володядан инде хат килгән булуга карамастан, бик каты дулкынланды. Ул Володя хезмәт иткән дивизиянең медсанбатына күчү турында хыялланырга тотынды.

Сегежа – кечкенә генә эшче шәһәрчек. Сугышка кадәр анда кәгазь комбинаты эшләгән. Хәзер комбинат эвакуацияләнгән, заводның буш корпуслары, күккә сузылган төтенсез трубалары гына калган, шәһәрдә гражданский халык бөтенләй диярлек күренми. Чүлмәк түбәле, балконлы, тәрәзә яңаклары, болдырлары матурлап, сырлап эшләнгән, бер-берсенә бик охшаган, тәртип белән салынган йортларның күбесе буш, ә кайберләренә хәрби кешеләр урнашкан. Шәһәрнең урта бер җирендә киң мәйданга каршы мәһабәт Культура сарае тора. Кайчандыр бу Культура сарае шәһәрнең шаулап торган бер урыны булган. Хәзер анда госпиталь урнашкан иде.

Газинур, Культура сараен, торак йортларны туйганчы карап йөргәннән соң, башын чайкап:

– Кешеләр матур яшәгәннәрдер монда! – диде. – Мин квартираларга кердем, һәрберсе өчәр бүлмәле. Кухнялары аерым. Мичләре ак чынаяктан, балконнары менә дигән, тәрәзәләре зур, идәннәре буяулы... Белмим, алар моннан ничек киткәннәрдер, әмма минем, ул буш квартираларда йөргәндә, күзләремә яшьләр килде. Кызганыч!

Фронтта безнең гаскәрләрнең контрһөҗүме дәвам итә иде әле. Беркөнне госпиталь начальнигы бер төркем санитарларны, терелеп килүче яралылар белән алмаштырып, фронтка җибәрү турында армия штабыннан приказ алды. Ул бик озак уйланып торды, аннары рядовой составның исемлеген сорады. Кемнәрне җибәрергә? Бүлек начальникларын да чакыртты. Башкалар белән бергә Екатерина Павловна да килде.

Екатерина Павловна киткәннән соң ярты сәгатьләп вакыт үткәч, зур тазда төрле шешәләр юып торган Газинур янына Мисбах йөгереп килеп керде. Ул бик каты борчылган иде.

– Ни булды, абый? – дип сорады Газинур.

Мисбах, өстәл янында эшләүче кызларга карап, әкрен генә:

– Әйдә, чыгыйк әле, – диде.

Бүлмәдән чыгып, утын сарайларына таба бер ун адымнар киткәч, Мисбах ашыгып сөйли башлады:

– Санитарларны алгы сызыкка озатмакчылар икән... Исемлектә бер мин генә. Син дә, Газзән дә юк...

Газинур, кара кашларын җыерып, нидер уйлап, алга карады. Аның күзләренә комбинатның төтенсез трубалары чалынды. Шул трубаларга тиеп, күктә тау-тау соры болытлар актарылып йөзә иде.

– Мин синнән калмыйм, абый, – диде Газинур нык итеп. – Кая барсак та, бергә барыйк.

Бераздан китүчеләрне кызыл почмакка җыеп, госпиталь начальнигының приказын укыдылар. Ахырдан госпиталь начальнигы үзе:

– Миңа, бәлки, үтенечләрегез бардыр? – дип сорады. – Әйтегез, мин сезне тыңлыйм.

Газинур мөрәҗәгать итәргә рөхсәт сорады.

– Иптәш начальник, – диде ул, рөхсәт алгач, – исемлектә минем абыем Билалетдиновның фамилиясе бар. Минем фамилиям юк. Мин абыйдан калмыйм. Безгә фронтка абый белән бергә барырга рөхсәт итегез.

Барысы да аңа борылып карадылар. Бераз тузгый төшеп, ак халатының чабуларын очындырып йөрергә яраткан шаян Газинур үзенең яңа гимнастеркасын киеп, ак яка тегеп, билен каеш белән нык итеп кыскан килеш смирно баскан, калкурак зур кара күзләре белән начальникка керфек какмый карап тора.

Начальник Екатерина Павловнаның Газинурны калдыру турында никадәр үтенеп сорауларын исенә төшерде, гаҗәпләнеп, санитарга карады. Кайчандыр, Гражданнар сугышы елларында, үзенең дә шулай өлкән командиры алдында басып торуын, менә бу кара күзле егет кебек үк, атлыгып, үзен алгы сызыкка җибәрүен үтенгәнен хәтерләде. Ул көрсенеп алды:

– Екатерина Павловна белән сөйләшегез. Әгәр ул каршы килмәсә, мин сезгә рөхсәт итәм, иптәш Гафиятуллин, – диде.

Әзерләнү өчен бары бер сәгать вакыт бар иде. Газинур Екатерина Павловна янына йөгереп керде. Бүлмәдә ул юк иде.

– Кызлар, Катя Павловна кайда? – диде ул, бик ашыгып. – Мин китәм!

Кызлар берни аңламадылар.

– Кая китәсең, Кемьгамы, Беломорскигамы? – дип сорады Нина.

– Юк, алгы сызыкка...

Екатерина Павловна ашыгып килеп керде. Госпиталь начальнигы аның белән сөйләшергә өлгергән иде инде.

– Китәсеңмени? – дип сорады ул.

Газинур, беренче тапкыр аның алдында смирно басып, сынын турайтты.

– Гафу итегез, иптәш военврач, мин, тәртипне бозып, сездән рөхсәт алмыйча, начальникка бардым. Мин абыйдан кала алмыйм. Колхоздан бергә киттек, сугышка да бергә керик.

Екатерина Павловна, аскы иренен тешләп, бераз эндәшми торды. Нина белән Галя, эшләрен бүлеп, Газинур янына килделәр.

– Нигә безне ташлап китәсең, Газинур? – диде Нина.

– Син исемлектә юк идең ич! Екатерина Павловна синең өчен начальник белән, беләсеңме, күпме даулашкан? – диде Галя.

Газинур Бушуевага хөрмәт белән карады.

– Гафу итегез... Бүтәнчә булдыра алмадым... Мин бит абыйдан калмас өчен генә болай эшләмим.

– Юк, син дөрес эшләгәнсең, – диде Екатерина Павловна. – Син бит үзең, бөркет баласы, канатлары ныгыгач, оясында утыра алмый, очып китә, дигән идең. Уңыш телим, Газинур, исән бул, – ул, нәкъ бертуган энесе белән саубуллашкан кебек, Газинур белән саубуллашты. – Хуш, Газинур. Володяны күрсәң, сәлам әйт. Мөмкин булса, йөрәк җепләре турындагы әкиятеңне аңа да сөйлә. Мин онытмыйм.

Газинур бик дулкынланып җавап бирде:

– Мин дә сезне онытмам! Сугыш беткәч, мин сезгә кунакка, ә Нина белән Галяның туена барачакмын, ярыймы, кызлар?

Газинур, барысының кулларын каты итеп кысып, чыгып китте. Бу вакытта аның зур кара күзләре яшь белән мөлдерәмә тулы иде.

Китүчеләрне ишегалдында сафка тезделәр.

Газинур госпитальдә калучы Газзән белән ике куллап саубуллашты да абыйсы янына, икенче рәткә килеп басты.

Хезмәттән буш булган сестралар, санитарлар, врачлар аларны озатырга чыкканнар иде. Екатерина Павловна,

Нина һәм Галя да биредә иде. Госпиталь комиссары, әйбәт хезмәт иткән өчен китүчеләргә рәхмәт әйтеп, фронтта да батыр сугышчы булырга, дошманны рәхимсез рәвештә кыйнарга чакырды. Аннары команда булды һәм строй кузгалып китте.

Берничә сәгатьтән алар, Масельская станциясенә ярты километр чамасы җитмичә, тимер юл өеме өстендә вагоннан да төштеләр. Поезд шунда ук, арты белән чигенеп, кайтып та китте. Караңгыда бернәрсә дә күренми, тик шау-шудан, кораллар, котелоклар чыңлавыннан гына монда бик күп кеше төшкәнлеген белеп була иде. Ләкин бераздан алар да, поезд кебек, каядыр караңгыда юк булдылар.

Санитарлар командасын дамба янында сафка тезделәр, алып килүче командир кешеләрне кулы белән берәм-берәм санап чыкты, бер-береннән калышмаска кушып, команданы үз артыннан алып китте.

Башта алар чокырлы-чакырлы җирләрдән бардылар. Аяк астында су чыпылдады, түмгәкләргә сөртенделәр. Аннары юлга чыктылар. Караңгыда водокачка, җимерек йортлар беленер-беленмәс кенә күренеп калды! Тик бер генә җирдә бер генә ут булсын. Әйтерсең бөтенесе үлгән. Бераздан алар урман эченнән бара башладылар. Хәзер алгы сызыктагы пулемет, автомат тавышлары торган саен ешрак ишетелә иде. Караңгы урман өстендә көчле яңгыраш айкала. Еракта, мөгаен, фронт буйлаптыр, тезмә-тезмә булып ракеталар оча, тагын да ерактарак, төнге яшен сыман, дошман тупларының ялкыннары уйный.

Алар шактый озак бардылар. Яңгыр яумаса да, күк йөзе тоташ болыт белән капланган иде. Болытлар агач башларына сыдырылып кына узалар шикелле. Гүя җил түгел, шул болытлар агач башларын төрле тавышлар чыгартып чайкалдыралар.

Каршыдан искән салкын җилдә көз сулышы бар. Шулай да солдатлар тирләп-пешеп беттеләр, Газинур, пилоткасын салып, яланбаш атлый иде. Команданы алып баручы командир аны күреп алды.

– Монысы тагын нәрсә?! – дип ачуланды ул. – Әллә яңадан госпитальгә кайтырга телисеңме? Хәзер үк ки!

Караңгыда Газинурның кызаруын берәү дә күрмәде. Ләкин ул үзе яңакларының бик озак кызып торуын сизеп барды.

Аларны ниндидер юеш, салкын землянкаларга урнаштырдылар, иртәгә кадәр ял итәргә мөмкин, диделәр. Землянкага кергәч тә, Газинур, кесәсеннән шәм кисәге алып, шырпы сызды. Караңгылык почмакларга посты.

Стена буйлап чыршы ылыслары түшәлгән озын сәке сузыла. Идән такталары астында, баскан саен, су лыччылдый, терлек абзарларындагы шикелле. Тар тәрәзә турысында өстәл булган, ләкин кемнәрдер аның такталарын каерып алып киткәннәр, бары тик җиргә кагылган ике аягы гына тырпаеп калган. Газинур шул казык-аякларның берсенә шәм кисәген утыртты да иңнәреннән капчыгын салып сәке өстенә ташлады. Аннары, бүтән сугышчылар белән бергә идән уртасында икеләнеп басып торган Мисбахетдингә карап:

– Абый, нәрсә уйга калдың, – диде, – бүгеннән безнең туган йорт шушы землянка була инде. Әйдә, иркенләп урнаш, иртәгә, бәлки, бусы да булмас, ачык окопта кунарга туры килер.

Солдатлар, капчыкларын салып, сәке кырыена утырыштылар, тәмәке төрә башладылар. Аннары алгы сызык турында, ак финнар турында бераз сөйләшеп алдылар.

Масельская юнәлешендә фин гаскәрләре тора икән. 1939–1940 еллар сугышына катнашкан солдатлар шюцкорчыларның коточкыч кансызлыгы турында, «кукушка»лар, фин «кавалериясе» – чаңгы батальоннары турында, дошманның урманда оста итеп сугыша белүе турында сөйләделәр.

Иягендә яра эзе беленеп торган бер солдатка бу сүзләр бик үк ошап бетмәде, ахрысы. Башта ул кыска тамыр трубкасын ачуланып суыра-суыра сөйләгән бер солдатның йөзенә сынаулы карашын юнәлтеп утырды. Барысы да сөйләп бетергәч, ул чак кына көлемсерәде дә:

– Алайса, безнең эшләр ташка үлчим булып чыга, – диде. – Маннергеймчылар тегендиләр дә, маннергеймчылар мондый... Ә мин сезгә әйтәм: шайтан сурәттәге кебек куркыныч түгел. Кырыгынчы елда Выборг янында без аларга күрсәттек күрмешләрен, алар шундук икенче җыр җырлый башладылар. Бу юлы да өлешләренә төшкән көмешләрен алачаклар.

– Хак сүзгә җавап юк, – диде Газинур һәм беренче булып сәкегә сузылып ятты. – Солдат йокысы, дуслар, кадерле йокы. Вакыт бар чакта йоклап калыйк, соңыннан теләсәк тә йоклап булмас. Ә чыршы ылыслары мамык түшәктән дә йомшаграк.

Газинур әкрен генә җырлап җибәрде:

Аклы ситсы күлмәгемне
Кисәм, каралыр микән,
Искән җилгә сәлам әйтсәм,
Алып баралыр микән?

– Нәрсә син, Газинур, җырлар чакмыни, – диде Мисбах күңелсез генә. Ул әле һаман да үзенең госпитальдән китүенә ышанып җитә алмый иде. Ничектер бер дә көтмәгәндә-уйламаганда булды бит.

– Абый, без җырламый, кем җырласын? Синең дә әвенең янмасын әле. Башлар сау булса, югалмабыз, дип әйтеп әйткән, ди, бер батыр солдат.

Мисбах озак эндәшмәде. Газинур, яшь бала кебек мышнап, әкрен генә йоклый да башлады. Шәм дә сүнде. Караңгылык яңадан, почмаклардан чыгып, бөтен землянка эчен тутырды. «Нәкъ кабер, – дип уйлап алды Мисбах. – Эх, кайларда гына ятмый икән адәм башлары...» Мисбах үзенең хатынын, балаларын күз алдына китерде, үзен кош та очып җитмәс ерак җирдә дип хис итте. Ярый әле Газинур биредә. Мисбахның күңелендә туганлык хисе ташыды. Ул караңгыда, кулы белән капшап, Газинурның шинелен рәтли. Газинурны госпитальдә калдыралар иде бит, ул абыйсыннан аерылмас өчен – Мисбах шулай уйлый иде – монда килде. Әгәр киресенчә булса, Газинурны җибәреп, Мисбахны калдырган булсалар, ул чагында Мисбах Газинур кебек эшләр идеме?..

Кайдадыр якында гына снаряд төшеп ярылды. Җир селкенеп китте. Түшәмнән шыбырдап ком коелды. Мисбах сискәнеп куйды, ни уйлаганын берьюлы онытты. Ул, яткан җиреннән күтәрелә төшеп, яңа снаряд килеп төшкәнен сагаеп көтә башлады. Ләкин бүтән шартлау ишетелмәде.

– Ят, абый, йокла, монысы күктән төшкән карга тизәге кебек кенә, – диде Газинур һәм яңадан әкрен генә мышнарга тотынды.

«Их, нинди кеше син, Газинур?! Күңелең ташмы әллә синең югыйсә? Кешечә борчыла да белмисең бит син...» – дип көрсенде Мисбах.

Шул турыда уйлый-уйлый йокыга киткәнен дә сизми калды.

Иртән, көн яктысында, землянкадан чыккач, солдатлар тирә-якларына беркадәр вакыт гаҗәпләнеп карап тордылар. Урман боз суккан бодай кыры кебек: бер генә сәламәт агач та юк, барысының башлары өзелеп, кәүсәләре янып, күмерләнеп, сынып, чәрдәкләнеп беткән. Бөтен җирдә кап-кара снаряд чокырлары җәйрәп тора, күбесенә яшел су тулган.

– Һай-һай каты бәрә икән монда! – диде бер солдат.

– Бомба беләнме, снаряд беләнме? – дип сорады икенчесе. – Урманны чисти кисәүгә әйләндергән бит.

Мисбах белән Газинур, бер читкә китеп, мүкле таш

өстенә утырдылар да озак кына тәмәке тарттылар. «Красногвардеец»ны искә төшерделәр. Элек тә хатлар бик озак килә иде, хәзер, адрес алмашынгач, тагын да озаграк йөрер инде.

– Алгы сызыкка моннан биш километр бар икән, – диде Газинур. – Без икенче эшелонда кунганбыз.

– Икенче эшелонга да нык эләгә икән, – диде Мисбах, күмерләнеп беткән агачларга тагын бер карап. – Бүген үк алгы сызыкка алып китәрләрме икән?

Газинур көлеп җибәрде:

– Хәзер икенче эшелонда ятарга да ризамы, абый?

– Юк, нигә алай дисең, – диде Мисбах уйчан гына. – Безнең белән бергә килгәннәр инде... Без башкалардан кай ягыбыз белән артык.

Мисбахның бу сүзләрен ишеткәч, Газинурның йөзе балкып китте:

– Дөрес әйтәсең, абый. Бик дөрес!

Иртәнге аш өчен кухняга барып кайткан Газинур яңа хәбәр китерде.

– Абый, Сәлим дә безнең полкта икән. Үзен күрмәдем күрүен, белгән кешеләр әйтте. Хозротада ездовой булып хезмәт итә икән.

– Китсәнә, безнең ветфельдшер Сәлимме? Кая соң, еракмы? Күрәсе иде бит, малай.

– Каядыр китеп барган. Тиз кайтмас диләр.

– Китсә, кайтыр әле. Безнең полкта дисең алайса. Газзән генә аерылып калды.

Ул арада сафка тезелергә команда булды. Газинур белән Мисбах котелокларын тиз-тиз бушаттылар да, кашыкларын итек кунычына кыстырып, командир янына йөгерделәр. Пополнение булып килүчеләр ике йөздән артык иде.

Газинур белән Мисбах сафның урта бер җиренә туры килделәр. «Смирно!» командасы бирелгәч, саф алдына бер төркем командирлар килеп туктады. Аннары «Вольно» командасы булды. Командирларның берсе – уртачарак буйлы, калын иренле бер капитан:

– Пулеметчылар бармы? – дип сорады. Биш-алты кеше тавыш бирде. Аларны шунда ук аерып алдылар.

– Артиллеристлар? – дип сорады озын кара мыеклы икенче бер командир.

Артиллеристлар унбишләп кеше иде. Берсе, бөтенләй артиллерист булмаса да, үзен артиллерист дип атады. Мисбах аны белә, ул аларның госпиталеннән иде. «Кара син аны, артиллерист дигән була, ә үзе мылтык та тота белми торгандыр әле», – дип уйлады Мисбах. Ул түзем-

сезлек белән пехота командирының чыгуын көтте. Пехота-матушкага теләүчеләр бармы, дисәләр, мине языгыз, Мисбахетдин Билалетдиновны, аннары... дип чәчрәп әйтергә әзерләнде.

Строй алдына күзләре уйнаклап торган, озын, сыгылма гәүдәле, кыска кара мыеклы өлкән лейтенант чыкты. Ул, нечкә иреннәре белән елмаеп, шаян тавыш белән:

– Йә, бөркетләр, кайсыгыз разведчик булырга тели? – дип сорады. Ул бүтәннәр кебек «фәләннәр бармы?» дип сорамады, ә «кемнәр разведчик булырга тели?» диде.

Строй бер минутка тынып калды.

– Теләүчеләр юкмыни? – диде разведка командиры, үзе тагын да көчлерәк елмайды. Газинур урыныннан кузгалып алды. Мисбах, бүтәннәргә сиздерми генә, аның җиң очыннан тартып куйды. «Монысы иң хәтәре! Селкенми тор!» – дип пышылдады ул Газинурга.

Разведка командиры, солдатларның күзләренә карыйкарый, сафның бер башыннан икенчесенә таба килә. Кайчакта ул берәрсе алдында туктый, бер-ике сүз әйтә, фамилиясен сорый, яңадан кузгалып китә.

Мисбах, тынын да алмыйча, бездән тизрәк үтеп китсен иде, дип көтеп торды. Ул арада разведка командиры саф уртасына җитте. Шунда Мисбах өчен аяз көндә күк күкрәгән шикелле көтелмәгән бер хәл булып алды. Аның белән янәшә басып торган Газинур, урыныннан кузгалмыйча гына:

– Иптәш командир, безне, абый белән икебезне, разведкага языгыз, – диде. – Гафиятуллин Газинур, Билалетдинов Мисбахетдин.

Мисбах, авызын яртылаш ачып, шаккатып калды. Нидер әйтергә теләде, ләкин өянәге тоткан кебек, авызыннан бер сүз дә чыгара алмады. Ә Газинурның күзләре ялтырый, командирга туры, кыю карыйлар иде.

Разведка командиры, күзләрен кыса төшеп, егеткә бераз текәлеп карап торды да:

– Ә син ак финнардан курыкмыйсыңмы? – дип сорады.

Газинур күңелле итеп җавап бирде:

– Нигә алардан куркырга, иптәш командир? Мунча пәриләре түгелдер әле. Аннары, разведчик күбрәк төнлә йөри. Караңгыда, безнең күрше Исаково руслары әйтә, барлык мәче дә соры була, ди.

Гафиятуллин белән Билалетдиновны разведкага яздылар.

## 8

Газинурлар алгы сызыкка килгәннән соң, ун көнләп вакыт үтте. Безнең гаскәрләр контрһөҗүмнән туктаганнар иде инде. Яңа солдатлар – алар разведкада бишәү иде – отделениеләргә беркетелделәр. Газинур белән Мисбах үзләрен бер отделениегә куюны сорадылар. Взвод командиры аларны сержант Морозов отделениесенә билгеләде.

Яңа килүчеләрне баштарак аерым өйрәттеләр, килгән көннәре белән үк заданиегә алып бармадылар. Аларны төз атарга, граната ташларга, тимерчыбык кисәргә, пычрак җирдән түш белән шуышырга, суга керергә, карта, компас белән эш итәргә, дошманны күзәтергә, дошманга ничек якынлашырга, ничек һөҗүм итәргә, соңыннан ничек кайтырга, йолдызларга, агач башларына яки агач төпләренә карап урманда йөри белергә, кул сугышына, пычак белән сугыша белергә, – кыскасы, разведчик өчен нәрсә кирәк булса, шуларның барысына да өйрәнергә мәҗбүр иттеләр. Ләкин вакыт чамадан тыш кысынкы булганга, аларны иртәдән кичкә, кичтән таңга кадәр йөгерттеләр. Арыган, пычранып, тирләп беткән иптәшләренә карап, Газинур еш кына:

– Ну, егетләр, госпитальдә җыйган майларыгыз эриме? – дип шаярта иде.

Җил өреп торган утлы күмер кызганнан-кыза барган кебек, Газинур да, кыенлыклар арта барган саен, үзен көчлерәк, дәртлерәк сизә иде. Бу чамадан тыш авыр солдат хезмәтен дә ул ничектер җиңел итеп, уйнап-көлеп башкара иде. Моңарчы урманда эшләү, фин кампаниясе вакытында колакларын йомып утырмау, ниһаять, табигый зирәк акылы, кыю, батыр йөрәге, талымсыз холкы аңа бик нык ярдәм итте. Ул күңел төшенкелеген белмәде. Мисбах исә еш кына сыкрана: «Ну, энекәш, башны харап иттең, ахрысы», – дип, Газинурга үпкәсен белдерә иде. Мондый чакларда Газинур көлә:

– Абый җаным, ялан-ялан майлы ботка булмый, егылмас борын елама әле. Монысы аның сөте генә, каймагы соңыннан, – ди торган иде.

Мисбах кулын селти, тәмәке төпчеген иреннәре пешкәнче суыра, урман чикләвегедәй күзләрен кысып, снаряд кыйпылчыклары сындыргалап бетергән нарат кәүсәләренә яки җәйрәп торган снаряд чокырларына карый да, башын чайкап, тирән үпкә белән әйтә:

– Ярар инде, хәерле булсын, Газинур. Карама көленә утырттың. Көтмәгән идем мондый эшеңне. Мин разведка кешесемени?!

Разведвзвод берничә тапкыр заданиегә барып кайтты. Разведчиклар күбрәк төнлә китәләр дә таң алдыннан арып-талып, пычракка буялып кайталар. Кайчакта алар шау-шулы, күңелле булалар, кайчакта чырайлары Карелия туфрагы төсле кара була: сөйләшмиләр, көлмиләр, тизрәк сәкегә менеп яталар, ләкин берсе дә йокламый, кулларын баш асларына куеп, караңгы түшәмгә карап, хәрәкәтсез яталар, нindидер уйлар уйлыйлар. Яңа килүчеләргә алар үлемне кичкән, нindидер серле, аңлашылмый торган кешеләр булып күренәләр. Шулай да алар күбрәк шат, шаян кыяфәт белән кайтып керәләр, нигәдер кыен, куркыныч хәлләр турында түгел, ә разведкада булган төрле мәзәкләрне искә төшерәләр, бер-берсен җиңелчә генә үртәп көләләр. Ә аннары... Аннары алар җырлый башлыйлар.

Газинур үз гомерендә шактый күп җырлар җырлаган, ишеткән кеше, әмма разведчиклар шикелле йөрәкләрне айкап, үзәкләрне өздереп җырлаганны моңарчы күргәне дә, ишеткәне дә юк иде. Җырны күбрәк сержант Морозов башлап җибәрә. Аның тавышы артык көчле дә түгел, ләкин аңарда урман шаулавы кебек нindидер үзенә бертөрле моң бар.

Газинур сержант Морозовның парторг икәнлеген, Дон елгасы буенда туып үскәнлеген, ә аннары Ростов-Дон заводларының берсендә тимерче булып эшләгәнлеген, армиягә әле сугыш башланганчы ук алынганлыгын белә иде. Газинур абыйсы Мисбах белән «Красногвардеец»та, урман эчендәге «Йөрәк»тә җир сөргән, кызын муенына атландырып чәчәкләр җыйган чагында Морозов инде илебез чиген бозып кергән дошманнарга каршы сугыша башлаган булган. Бу хәл үзе генә дә Газинур каршында Морозовның бәясен югары күтәрде, ул кайчан да булса аның белән якыннан дуслашырга хыяллана иде.

Кичә разведвзвод заданиедән үзенең тәҗрибәле ике разведчигын югалтып кайтты. Эшнең ничек булуы турында яңа солдатларга берәү дә сөйләмәде.

Разведчикларның нindидер язылмаган законнары, традицияләре бар иде. Яңа килүчеләргә алар өстән, олылар балаларга караган кебек, бераз көлемсери төшеп карыйлар. Алар белән үзләренең шатлыкларын да, кайгыларын да бүлешмиләр, шул ук вакытта аларның үткен күзләре яңа килүчеләрне, рәт чыгармы болардан, юкмы дигән кебек, бертуктаусыз сыныйлар. Взводның составы һаман алмашынып тора: берәүләр яралана, икенчеләр үлеп кала, әмма аның традициясе үзгәрми. Бүген исән булган разведчикларның күбесе үз вакытында шушын-

дый ук сынауларны башыннан кичергән. Яңа кешене разведчиклар үз семьяларына бары тик сугышта сыналганнан соң гына кабул итәләр.

Газинур моны беренче көннән үк сизеп алды, сугышчан заданиегә үзен тизрәк алып баруларын үтенә башлады. Взвод командиры кече лейтенант Григорьян, кара бөдрә чәчле, тышкы кыяфәте белән дә, кызу холкы белән дә карчыгага охшаган әрмән егете аңа бары тик:

– Вакыты килеп җитмичә, күке дә кычкырмый. Ашыкма! – диде.

Ул Газинурга тагын нидер әйтергә җыенган иде дә, ашыгыч рәвештә полк штабына чакырдылар. Анда ул караңгы чырай белән китте. «Яралanучылар турында сорашып, майор теңкәгә тиячәк», – дип уйлады ул. Штаб начальнигы, инде чәченә чал төшә башлаган капитан, гүя аның өс-башын тикшергән кебек баштанаяк карап алды да:

– Хуҗа янына киттек! – диде.

«Хуҗа» – полк командиры, чандыр йөзле, озын буйлы майор Кремнев – Григорьянга кулын сузды:

– Йә, Арагац бөркете, «Кыяр»да эшләр ничек? Финнарда нинди яңалык бар? – дип сорады.

Кайчандыр янып торган, ләкин соңыннан сүнгән Арагац тавы – Григорьянның туган җире, ә «Кыяр» Масельская янында дошман урнашкан иң югары биеклекнең солдатлар телендәге исеме иде. Кыяр кебек озынча булганлыгы өчен аңа шул исемне биргәннәр. Бу биеклектән безнең позицияләр ап-ачык күренеп тора. Аны алу өчен полк батальоннары бик озак сугыштылар. Бер тапкыр алганнар да иде. Ләкин финнар, көчләрен туплап өлгереп, безнекеләрне яңадан бәреп чыгардылар. Шулай да командование полк позицияләре «өстендә» финнарның «кунаклап утыруы» белән һич тә килешә алмый иде.

– Менә нәрсә, Григорьян, – диде майор Кремнев, разведчикның докладын тыңлагач, – син миңа бу каһәр суккан «Кыяр»дан теләсә ничек булса да «тел» алып кайт. Аңлыйсыңмы, теләсә ничек булса да! Мин ул «Мономах бүреген» баш түбәмдә артык йөртә алмыйм. Аңлашыламы?

Кызу табигатьле, көчен кая куярга белми торган Григорьян үз взводына күтәренке күңел белән кайтты.

– Әй, Арагац бөркетләре! – дип кычкырды ул үзенең разведчикларына. – Җитәр, түшәмгә карап, күз нурларыгызны бетермәгез. Безнең урамда да бәйрәм булыр. Сержант Морозовны минем янга, ә калганнарга – әзерләнергә!

Разведчиклар өермәдәй сикереп тордылар. Кая китте аларның сүрәнлекләре, кая китте аларның ару-талулары!

Кече лейтенант, үз землянкасына кайтып, разведка планын төзергә кереште. Дөресрәге, аның планы башында күптән төзелгән иде. Хәзер аны кәгазьгә генә төшерәсе бар иде.

Ишек шакыдылар.

– Да, да! – диде Григорьян, картадан башын күтәрмичә.

Тәбәнәк буйлы, киң җилкәле, саргылт кашлы, соры күзле, кыска сары мыеклы, зур куллы, өстенә сырма кигән, билен каеш белән буган, бер ягына пистолет кобурасы, икенче ягына фин хәнҗәре таккан, бүреген кыңгыр салып кигән сержант Морозов килеп керде.

Григорьян аны үз янына чакырды, һичбер кереш ясап тормастан:

– Яңалардан кемнәрне алырга мөмкин? – дип сорады.

Сержант Морозовның да җавабы, күрәсең, әзер иде:

– Гафиятуллин белән Билалетдиновны, – диде.

Григорьян кара күзләрен уйнатып куйды:

– Син моны уйлап әйтәсеңме? Гафиятуллин яңа гына дежурдан кайтты түгелме?

– Так точно, – диде сержант Морозов. – Ләкин разведчикка батальонда дежурить итү ул – бер көнлек ял йортына барып кайту дигән сүз.

Григорьян урыныннан торды. Ул озын, зифа буйлы иде. Аның сүзе, хәрәкәте, карашы, буе-сыны ни өчендер бу кешене чакматашка охшаттыралар. Гүя аңа кагылып кара, бөтен җиреннән очкыннар чәчрәр. Авыррак сөякле сержант Морозов янында аның бу сыйфатлары күзгә аеруча нык бәрелә иде.

– Ял йорты? – дип кайтарып сорады ул тиз генә. – Андый сүзләрне оныт син хәзер, сержант! Барлык дошманнарны кырып бетермичә, безгә ял юк.

– Ә кырып бетергәч? – дип сорады сержант, көлемсерәп.

– Аннары иң яхшы санаторийларда ял итәрбез. Мин сезне барыгызны да Арагацка алып барырмын. Севан күленә ала балыклар тотарга менәрбез.

Сержант яңадан көлемсерәп куйды. Григорьяннан исә очкыннар чәчрәп киткәндәй булды.

– Нәрсә башыңны чайкыйсың? Әллә шулай булмас дисеңме?

– Сугыштан соң да безнең эшебез күп булачак, – диде Морозов сабыр гына.

Григорьян үзенең ярдәмчесенә туры итеп карап алды.

– Синең йөрәгең, сержант, Севан суыннан да салкынрак, ахрысы. Хыялланырга яратмыйсың. Җитәр, эшкә якынрак килик. Аларның кайсын «тел» алу группасына билгелибез?

Сержант бу сорауларга да икеләнмичә җавап бирде:

– Минемчә, Гафиятуллинны. Ул җитезрәк тә, кыюрак та күренә. Билалетдиновны – каплау группасына.

Григорьян белән Морозов бу сүзләрне сөйләп утырган вакытта, Газинур, котелогын тезләре өстенә куеп, кайнар шулпа ашый һәм кайсы кырынып, кайсы коралын чистартып торган разведчикларга Хуҗа Насретдинның коега төшкән айны ничек итеп яңадан күккә мендереп куюы турында сөйли иде. Мисбах аның янында, сәке кырыенда утыра, шуышып йөргәндә өзелеп төшкән төймәсен тага.

Сержант Морозов килеп керде.

– Гафиятуллин, Билалетдинов, взвод командирына! – дип кычкырды.

Газинур ашап бетермәгән шулпасы белән котелогын тимер мич өстенә куйды да гимнастеркасын төзәткәләп алды. «Әллә...» – дип уйлады ул, йөрәге ешрак тибәргә тотынды.

Тышка чыгып, землянка яныннан бераз киткәч, Мисбах Газинурны җиңеннән тартып туктатты.

– Газинур, – диде ул әкрен генә, тирә-ягына каранып. – Әллә безне дә тегендә алып баралармы? Иптәшләр баядан бирле әзерләнәләр.

Газинур бер караштa Мисбахны баштанаяк күздән кичерде:

– Безнең кай җиребез башкалардан ким соң, абый? Монда безне көненә өч тапкыр шулпа белән ботка ашап, землянка саклап ятарга китермәгәннәрдер.

Ботаклары җиргә таба тартылып торган карасу чыршыларның түбәләренә тияр-тимәс кенә булып көзге авыр болытлар агыла. Тышта җылы, тын, бераз бөркү.

– Анысы дөрес тә... – диде Мисбах, шул карасу-яшел чыршылар өстеннән күзен йөртеп. – Өйрәнүләр азрак булды менә.

– Кайгырма, абый, сугыша-сугыша өйрәнербез. Хуҗа Насретдин гына бит суга керми йөзәргә өйрәнмәкче булган.

Алар, взвод командиры землянкасының ишеген кагып, керергә рөхсәт сорадылар. Эчкә кергәч, смирно бастылар – Газинур бераз алдарак, Мисбах аның җилкәсе ышыгындарак иде.

Григорьян урыныннан торды да карчыганыкы төсле үткен күзләре белән егетләрне баштанаяк үлчәп алды,

аннары аларга якын ук килеп, йөзләренә текәлде. Яңа разведчикларны беренче тапкыр сугышчан заданиегә алып барганда, ул һәрвакыт шулай итә торган иде. Кайчакта яңа солдатка шулай карап тора-тора да, берни аңлатмыйча: «Барыгыз, кайтыгыз!» – дип борып та җибәрә иде. Моны ул күңеле шикләнгән чакларда шулай эшли торган иде. Ләкин Газинурның зур кара күзләре аңа кыю карыйлар, иңбашларын арткарак киергән, күкрәге алга чыгып тора. Мисбахның урман чикләвегедәй коңгырт күзләре дә алдашмыйлар шикелле. Тик кулларының салынып торулары гына Григорьянга бераз ошап бетмәде. Шулай да ул аны кире борып җибәрмәде.

– Мин сезне разведкага билгеләдем, – диде ул үзенең әрмән акценты белән. – «Тел» алырга барабыз. Гафиятуллин, сез «тел» алу группасында, Билалетдинов – каплау группасында. Аңлашылдымы?

– Так точно, – диде Газинур.

Бераз соңгарак калып Мисбах та шуны кабатлады.

– Сез беренче тапкыр заданиегә барасыз, – диде Григорьян. – Мин сезгә разведчикның төп законын әйтим: кыю, тапкыр, җитез булыгыз. Куелган бурычны үтәми кайтмаска. Сугышта иптәшең турында онытмаска, һәрвакыт аңа ярдәмгә килергә. Менә шул. Мин сезгә ышанам. Ләкин ул ышанычны сугышта акларга кирәк. Ә заданиенең планы турында бераз соңрак барыгызны да бергә җыеп сөйләрмен...

Григорьян, каядыр бик ашыккан сыман, ишекле-түрле бер әйләнде дә яңадан сугышчылар алдына килеп басты:

– Сержант Морозов миңа сезне бертуган диде. Нигә сезнең фамилияләрегез ике төрле?

Газинур кыска гына аңлатып бирде.

– Шулаймыни? – диде Григорьян. Аның кара күзләрендә очкын ялтырады. – Минем дә бер карында ятмаган, ләкин бик яраткан абыем бар. Үги әнинең улы. Тик без икебез ике җирдә сугышабыз – абый Кара диңгездә, ә мин менә Карелия сазларында.

Болытлар бераз тарала төшкән. Алар арасыннан кояш күренә. Ул инде шактый түбәнәйгән. Җәй көне күктән һич тә китәргә теләмәгән кояш хәзер, салкынга түзә алмаган кебек, тизрәк төнге бишегенә ятарга ашыга иде.

Алгы сызыкта гадәттәге атышлар бара. Бер як та артык кызмый. Финнар, гомумән, соңгы вакытта нигәдер артык «юашланып» киттеләр. Ни өчен? Хикмәт нәрсәдә? Бу сорауларны өлкән командирлар да, гади сугышчылар да үз-үзләренә бирәләр, җавап эзлиләр иде. Алынасы «тел» әнә шул сорауга да җавап бирергә тиеш иде.

## 9

Разведкага әзерлек эшләре беткәндә, караңгы төшеп килә иде инде. Өсләренә сырма гына кигән унбиш разведчик сафка тезелеп басып торалар. Уң флангта сержант Морозов. Кече лейтенант Григорьян сафка соңгы тапкыр күз йөртте дә команда бирде. Разведчиклар киек казлар кебек бер-бер артлы тезелеп кузгалып киттеләр.

Алгы кырыйда пехотачыларның траншеяларыннан финнар ягына карап тордылар. «Кыяр» караңгыда кара болыт кебек кенә күренә. Финнарның позицияләре тимер юл дамбасының аргы ягында. Аннан ара-тирә автоматлардан аталар, ак ракеталар чөяләр.

Бер читтәрәк Григорьян пехота командиры белән сөйләшә. Пехота командирының тавышы Газинурга таныш кебек тоела. Кайдадыр бер ишеткән иде кебек ул бу тавышны. Ул аны күрер өчен башын да сузды, ләкин караңгыда берни күрә алмады. Ул арада саперлар килде.

– Йә, Арагац бөркетләре, – диде Григорьян үзенең разведчикларына, – киттек.

Разведчиклар траншеялардан чыга башладылар. Саперлар алдан китте. Алар разведчикларны мина кыры аркылы чыгарып җибәрделәр. Тимер юл кырыена җиткәч, җиргә ятып тыңлап тордылар. Аларны болытлар арасыннан чыккан ай борчыды. Разведчикларның кайсыдыр аңа хәтта йодрыгы белән янап та алды.

Байтак вакыт дамба кырые буйлап бардылар. Аннары сукмак сулга борылды, тимер юл да уңда калды.

Кинәт финнар минометлардан ут ачты. Разведчиклар йөгерә башладылар. Беренче тапкыр ут астына эләккән Мисбах аптырап калды. Ул иелеп йөгерергә кирәклеген белсә дә, уклау йоткан кебек туп-туры йөгерә иде. Кемдер аның аркасына төртте, шуннан ул иелеп йөгерә башлады.

Миномет уты астыннан чыкканнан соң, Григорьян разведчикларны туктатты. Финнар хәзер икенче җиргә аталар иде. Димәк, белеп түгел, ә ул-бу юкмы дип шикләнеп кенә аталар. Әйдә атсыннар! Шау-шу вакытында баруы җайлырак.

Өч-дүрт метр киңлегендәге елга янына килеп чыктылар. Кемнәрдер елга аркылы ике рельс салган. Разведчиклар шул тимер басма турысында, куаклар арасына ятып, озак кына күзәтеп тордылар. Аннары бер разведчик басма аркылы чыгып китте дә, тавыш-тынсыз гына барып, аргы яктагы куаклар арасына ятты. Яңадан хәрәкәт бетте. Яңадан тынлык. Тик җилнең әкрен генә

сызгыруы ишетелә дә кайдадыр еракта фин часовое автоматтан атып куя. Миномет уты күптән инде тынды. Җиргә яткан разведчикларга караңгы «Кыяр» күренә. Ул аларның өстендә асылынып торган шикелле. «Әллә шул тау башына менеп «тел» алыргамы?» – дип уйлады Мисбах, борчылып. Ләкин алгы кырыйдагы траншеялардан чыгып киткәннән соң шулкадәр озак вакыт иркен йөрергә мөмкин булуы аны беркадәр тынычландырды. Чөнки алгы сызыкны ул бөтенләй башкача күз алдына китерә иде: окоптан башыңны суздыңмы – беттең!

Пышылдап кына әйтелгән команда ишетелде. Разведчиклар бер-бер артлы елга аръягына чыга башладылар. Авыррак сөякле Мисбах, басма аркылы чыкканда, суга егылып төшә язды. Ярый әле арттан килүче сержант Морозовның көчле куллары аны вакытында тотып калдылар.

Менә алар яңадан кара урман эченнән сак кына баралар. Финнарга кадәр дүрт йөз-биш йөз метрдан да артык түгел дип кисәттеләр. Бу битараф җирдә аларның засадалары булуы мөмкин. Григорьян разведчикларга ике күзләрен дүрт итеп карап барырга кушты.

Унбиш-егерме минуттан алар ярым җимерек землянка янында туплandылар. Биредә Григорьян разведчикларга бераз көтәргә кушты. Финнар якын, ләкин операцияне башлап җибәрергә иртәрәк әле. Төн уртасын көтәргә кирәк. Бу вакытта аларның күбесе йоклый.

Юлда килгәндә эссе иде, тик тора башлагач салкынайтты.

Газинур белән Мисбах землянка кырыенда җиргә чүгәләп утыралар иде.

– Нигәдер эчем бик поша, – дип пышылдады Мисбах.

– Борчылма, абый, – диде Газинур йомшак кына. – Без үзебез генә түгел, иптәшләр белән бергә ич.

Григорьян белән Морозов якыннан караганда тагын да биегрәк күренгән, өстендә агачлар үсеп торган караңгы «Кыяр»га таба киттеләр. Бераздан алар әйләнеп тә кайттылар. Аннары Григорьян хәрәкәт итә башларга боерык бирде.

Иң алдан Григорьян белән биш кеше китте. Аннары тагын биш кеше. Алар белән бергә Газинур да китте. Киткән чакта Мисбахның кулын кысты. Иң арттан Мисбахлар группасы кузгалды. Бу группаны сержант Морозов алып барды.

Айны болытлар каплады. Дөм караңгы. Шулай да, түбәннән караганда, күк яктысында биеклекнең түбә сызыгын шактый ачык күрергә мөмкин. «Биек икән,

каһәр! Өскә аварга тора», – дип, тагын бер тапкыр уйлап алды Мисбах.

Биеклек итәгендә финнар, агачларны кисеп, бер-берсе өстенә аударып, кеше үтә алмаслык завал ясаганнар. Шул завал янында сержант Морозов каплау группасын туктатты.

– Минем кулым турысына кара, – диде ул, һәр сугышчының колагына пышылдап, – әнә завал арасыннан тар гына сукмак сузыла, күрәсеңме? Финнар сукмагы. Нык күзәтегез. Безнекеләр сулданрак барачаклар.

Кайдадыр югарыда финнарның мыдыр-мыдыр сөйләшүләре ишетелә. Мисбахның йөрәге сикереп-сикереп кага. Ни әйтсәң дә, бу аның беренче разведкасы, беренче тапкыр дошманга шулай якын килүе. Ул тирә-ягына карап ала, Газинур күренми. Әллә кереп тә киттеләрме икән?

Финнар нидер сизенделәр булса кирәк, һавага ракета чөйделәр. Аның яктысында бөтен биеклек күренде: завал шактый киң икән, завал артында чәнечкеле тимерчыбык...

Мисбах карап та бетерә алмады, әллә ничә җирдән пулеметлар ата башлады. Яктырткыч пулялар өере Мисбахның баш очыннан гына выжлап узды. Шуның артыннан ук миналар төшеп ярыла башлады. Кинәт Мисбахның аякларына тимер таяк белән китереп суккандай булдылар. Ул әһ итеп куйды, ихтыярсыздан кычкырып җибәрмәс өчен иренен тешләп, башын күтәрде. Коточкыч әрнүдән аның күзләре атылып чыгардай булган иде.

Болытлар арасыннан ай күренде. Тирә-як яп-якты булып китте. Сулдарак кемнәрдер завал эченә кереп бара иде. Мисбах алар арасында Газинурны шәйләде, үзе дә сизмәстән кул изәде. Янәсе, монда кил, мин яраландым. Газинур аның кул изәвен күрдеме, юкмы – туктамады, иптәшләре артыннан йөгереп китте.

Мисбахның тыны кысылды. Ул Газинур минем янга килер, яраларын бәйләп, үз ягыбызга алып китәр дип көткән иде. Ә ул...

Финнар һаман аталар иде. Мисбах кулын сузып әледән-әле аякларын капшап ала: итек эчләре лачма кан!

Аның янына бер разведчик шуышып килде.

– Кай җирең? – дип сорады ул, пышылдап кына.

– Аякларым, иптәш Антонов. Ай каты авырта.

– Сержант миңа сине алып чыгарга кушты. Аланның теге ягына шуышырга кирәк. Анда яраңны бәйләрмен.

Ул күнегелгән бер хәрәкәт белән Мисбахны аркасына салды да шуыша да башлады. Утыз-кырык адымнар кит-

теләр. Кинәт аларның баш өстендә пулялар сызгырырга тотынды. Ул да булмады, Мисбах Антоновның җиргә сыенып тын калуын сизде.

– Иптәш Антонов, иптәш Антонов, – дип пышылдады ул, борчылып.

Антонов җавап бирмәде. Ул үлгән иде.

Мисбах бөтенләй аптырап калды, йөрәге ярылырдай типте. Куркудан һәм әрнүдән зур булып ачылган күзләре белән тирә-ягына каранды – беркем дә юк! Тагын бер тапкыр Антоновны җилкәсеннән селкеп карады. Башын капшады – җылы кан. «Минем аркамда харап булды», – дип уйлады Мисбах, коты чыгып.

Бераздан Мисбах Антоновның гәүдәсен сержант кушкан якка таба сөйрәргә маташа башлады, – ул сержант Морозовның ярдәмгә киләсенә ышана иде, – ләкин булдыра алмады. Шуннан соң Мисбах иптәшенең автоматын алып үз муенына такты. Бик зур кыенлык белән генә аны аркасына этте, канлы аякларын өстерәп, Морозовлар калган якка таба шуышырга тотынды. Бераз шуышкач, аның хәле бетте. Ул йөзтүбән капланды. Күзеннән яшь бәреп чыкты. Башын күтәрде. Тыңлап торды. Берәү дә атмый. Газинурлар кайда? Нишләделәр? «Тел» ала алдылармы? Кем аны килеп коткарыр? Бу сораулар берсе артыннан берсе өелеп киләләр.

Күпмедер вакыттан соң йөзтүбән яткан Мисбахның колагына аяк тавышлары ишетелгәндәй булды. Ул башын күтәрде, якыннан гына кемнәрнеңдер йөгереп үтеп киткәнен күрде. Шул ук вакытта яңадан финнар ата башлады, аларга каршы аткан автомат чиратлары да ишетелде. Сержант Морозов группасы эзәрлекләп килүче финнарга каршы сугыш башлады, ахрысы.

Граната шартлаулары яңгырады. Эшләр гранатага ук барып җитте инде дип тагын да катырак борчылды Мисбах. Шунда ул, яралы булса да, иптәшләрен ташлап китәргә хакы юклыгын, әгәр дә ташлап китсә, намусына гомер буе юып ала алмаслык тап төшерүен бик яхшы аңлады. Ул, терсәкләренә таянып, иренен тешләп, яңадан шуыша башлады. Кинәт якында гына финча сөйләшкән тавышлар ишетелде. Мисбах башын күтәреп карауга, үзеннән унбиш-егерме адымда агачлар арасында ике финны күрде. Берсенең кулында кул пулеметы. «Морозовның тылына төшмәкчеләр...» – дип уйлап алды Мисбах, үзе автоматын финнарга төзәп атып җибәрде. Финнар икесе дә җиргә ауды.

Шуның артыннан ук урманда өч тапкыр сызгырып җибәрделәр. Бу каплау группасына чигенә башлау ту-

рында шартлы сигнал иде. Димәк, «тел» алу группасы финнар оясыннан чыккан инде.

Атышлар икенче якка авыша башлады. Аннары бөтенләй тынды. Бу хәл Мисбахны шатландырды да, шомландырды да: ялгышып, бөтенләй башка якка шуышмаганмы соң ул? Йолдызларга карый – йолдызларны болыт каплаган, айга карый – кирәк чакта ул да күренми. Ә урмандагы агач башлары түп-түгәрәк.

Мисбах алан кырыена шуышып килде. Каплау группасыннан берәү дә аны куып җитмәде. Әллә тавыш салыргамы? Юк, тавышны финнар ишетәчәк. Алар кулына эләккәнче шушында үлү артыграк.

Бераз гына яктыра башлады. Хәзер инде берәү дә Мисбахны коткарырга килә алмас. Көндез монда йөрергә мөмкин түгел. Ә киләсе төнгә чаклы ул үзе түзә алмаячак. Мисбахның күз алдына ерак «Красногвардеец», хатыны, балалары, карт әтисе белән әнисе, аларны озата чыккан колхоздашлары килеп басты. Берәү дә Мисбахның хәлен белми бит. Башлар исән булса, кайтырбыз, диде ул киткән чакта. Менә ул солдат башлары кайларда ята.

Мисбахның күңелендә Газинурга карата авыр рәнҗү, үпкә ташый башлады. Энекәш! Абыйсының яралганын белде, ә туктап ярдәм итмәде. Ташлап китте! Ташлап!

Ул үзе яралганнан соң хәлләр никадәр чуалып китүен белми иде. Сержант Морозов, яралы Билалетдиновның дошман кулына эләгүеннән куркып, Антоновка аны алдан билгеләнгән юнәлеш белән алып чыгарга кушты. Ул тәҗрибәле разведчикка тулысынча ышанды. Автомат тавышын ишеткәч, Морозов Антонов ата дип уйлады. Аннары ул үзе яраланды. Исән разведчиклар аны күтәреп алып чыкмакчы булдылар, ләкин Морозов риза булмады: ул чагында финнар аларны бик тиз куып җитәчәкләр. Ул ике разведчикка, дошманны алдап, атыша-атыша икенче юнәлештә чигенергә кушты. Үзе элек билгеләнгән маршрут белән шуышырга булды. Аның көче бар иде әле. Әгәр финнар белән очрашырга туры килсә, терелләй бирелмәячәк...

Антоновның үле гәүдәсен күргәч, Морозовның йөрәге жу итеп китте. Билалетдинов дошман кулына эләктеме әллә?! Ләкин алга таба бераз шуышкач, Билалетдиновны да күрде. Шуннан, маңгай тирен кул аркасы белән сыпырып, җиңел сулап куйды.

– Билалетдинов, бу синме? – диде ул. – Бөтенләй яктырткачы аланның теге ягына чыгып яшеренергә кирәк. Аланны финнар һәрвакыт ут астында тота.

– Бүтәннәр кайда? – дип сорады Мисбах.

– Русаков белән Понамаренко дошманны, үз артларыннан ияртеп, икенче якка алып киттеләр. Әгәр алар шулай итмәгән булсалар, безне күптән куып җиткән булырлар иде.

Ихтыяр көче йомшарып киткән Мисбахка пышылдап әйтелгән бу сүзләр бик көчле тәэсир итте. Күзләренә яшь килде.

– Хәлең ничек?

– Начар, иптәш сержант... Мин инде беттем дип уйлаган идем.

Морозовның башы белән аягы яраланган. Иртәнге яшькелт рәшәдә Мисбах аның канга буялган, бик нык суырылган йөзен күрде.

– Алай уйларга иртәрәк әле, – диде сержант. – Әйдә, мин сине аргы якка чыгарып куйыйм. Аннары Антоновны килеп алырмын.

– Сез үзегез дә яралы ич...

– Күп сөйләшмә!

Ул Билалетдиновны аркасына салды да көч-хәл белән генә шуышып китте. Мисбахның яралы аяклары җирдән сөйрәлде. Ул, кычкырып җибәрмәс өчен, иреннәрен тешләде. Шул ук вакытта көченнән килгән хәтле куллары белән сержантка булышты.

Аланны чыгып, Мисбахетдинны куе куаклар арасына яшергәч, сержант Морозов Антоновның мәетен алырга дип китте һәм яңадан әйләнеп кайтмады. Финнар аланга минометтан ут ачтылар. Сержант, күрәсең, шунда һәлак булды.

Мисбах аны бик озак көтте. Аның киеме тәмам чыланган иде. Ул туңа башлады. Тешләре шакылдарга тотынды. Ул яңадан тирән үпкә белән Газинурны исенә төшерде. Русаковлар, аны коткарыр өчен, дошманны икенче якка алып киттеләр. Антонов белән сержант Морозов, аны коткарып, үзләре һәлак булды. Әгәр алар булмаса, Мисбах хәзер шушы ышык урында ятар идеме?.. Менә бит бөтенләй ят кешеләр Мисбахка гомер буе онытмаслык яхшылыклар эшләделәр, ә энекәше, ичмасам, янына да туктамады!

Биредә күпме ятканлыгын Мисбах белми иде, ләкин аңа шушы куаклар арасында мәңге ята кебек тоела. Аннары саташа башлады, ахрысы, «Кыяр», юк, «Кыяр» түгел, ә әкияттәге Каф тавы урыныннан кубып аны куа килә, имеш. Мисбах коты очып кычкырып җибәрде.

Бу тавышны бер төркем сугышчылар белән бергә яралыларны эзләп килүче Газинур ишетте. Ул туктады, са-

гаеп тыңлап торды, аннары куаклар арасына ташланды. Анда ул чалкан яткан Мисбахны күрде, аның янына тезләнде.

– Абый, абый, – диде ул, пышылдап кына.

– Газинур... – дип дәште Мисбах, саташаммы әллә дип уйлап, яңадан күзләрен йомды.

– Абый! – Газинур, Мисбахның хәлсез гәүдәсен күтәреп, башын тезе өстенә куйды. – Абый!..

Мисбах аңга килде, бик озак Газинурга карап торды. Аннары, агарган иреннәрен чак кыймылдатып:

– Бу синме, Газинур? – дип сорады.

– Мин, абый, мин.

Мисбах елап җибәрде. Аннары яшь аралаш:

– Сержант... шунда... Аны коткарыгыз... – диде. Мисбах яңадан һушыннан язды. Шуннан соң нәрсә булганлыгы турында һични белми иде. Ул һушына килгәндә, Газинур аны, ике тәгәрмәчле арбага салып, урман буйлап алып бара иде.

– Мин кайда? – дип сорады Мисбах.

Газинур, бер кулы белән арбага тотынган килеш, аңа иелде:

– Син үз ягыбызда инде, абый. Хәзер машинага салып медсанбатка озатабыз.

Машина куе агачлар арасында көтеп тора иде. Санитарлар алданрак килгән икенче бер арбадан кемнедер күтәреп алып машинага кертәләр.

Газинур атын туктатты, абыйсы янына килеп басты.

– Хуш, абый, – диде ул, күз яшьләрен сөртеп. – Инде синең урыныңа да мин калдым. Икебез өчен дә сугышачакмын. Аккан каныңны җирдә калдырмам, абый.

– Сержант Морозовны таптыгызмы, Газинур?

– Таптык. Әнә аны да машинага салалар.

– Ә «тел»?

– Алдык. Үзем беренче булып сыртына атландым. Эһ дияргә дә өлгермәде... Командир рәхмәт тә әйтте. Абый... мин сержант белән саубуллашыйм әле.

Газинур Морозов янына йөгерде. Аны, арбадан төшереп, машина янына алып килгәннәр. Ул носилкада ята, күзләре йомык, зур куллары, хәлсезләнеп, гәүдәсе буена сузылган.

Газинур, аның шул зур кулына җиңелчә кагылып:

– Хуш, иптәш сержант, – диде. – Тизрәк терел.

Морозов эндәшмәде, күзен дә ачмады. Ул арада санитарлар Мисбахны да алып килделәр. Газинур яралыларны машина эченә кертеп куярга булыша башлады. Аннары соңгы тапкыр абыйсы белән саубуллашты.

– Хуш, абый, тизрәк терел, – диде ул, Мисбахның кайнар маңгаеннан үпте. – Катя Павловналарны күрсәң, сәлам әйт.

– Хуш, Газинур, хуш, җаным... башыңны сакла...

Машина юл сикәлтәләрендә чайкала-чайкала кузгалып китте. Менә ул ераклаша, менә ул борылышта күздән дә югалды. Ә Газинур һаман да баскан урыннан кузгала алмый тора. Аның күңелендә шундый бер тойгы: әйтерсең машина Мисбах белән Морозовны гына түгел, Газинурның йөрәген дә суырып алып китте.

Газинур башын күтәрә, күктә авыр соры болытлар агыла. Ара-тирә яңгыр катыш кар бөртекләре оча, йөзьеллык наратлар, үч алырга чакыргандай, ачулы шаулыйлар.

## 10

Вакытның чабып баруын бернәрсә дә туктата алмый. Гүя кичә генә әле Газинурның башы өстендә Карелиянең урманнары шаулый иде, гүя кичә генә әле ул, тирән кайгыга чумып, Мисбах белән Морозовны салган машинаны озатып тора иде. Ә аннан бирле ике ел вакыт узган инде! Җитмәсә, нинди еллар әле!

Кремневның полкы әле җирле сугышлар алып барды, әле оборонада утырды, әле аны тылга ялга чыгардылар. Берничә тапкыр дивизия бөтен составы белән яңа урынга күченде, аннары аны эшелоннарга төяделәр дә каядыр көньяк-көнчыгышка таба алып киттеләр.

– Кая алып баралар? – дип сорадылар солдатлар. – Сталинградкамы?

Барысының да хәлиткеч сугыш төенләнгән җиргә – Сталинградка эләгәсе килә иде. Ләкин аларны Калинин өлкәсенең тәмам ватылып беткән кечкенә бер станциясендә вагоннардан төшерделәр. Бу Төньяк-Көнбатыш фронт иде. Эшелоннардан төшүгә, дивизия сугыша да башлады. Гитлерчылар чигенәләр иде. Юл буйларында җимерелгән яки качып барганда ташлап калдырылган исәпсез-хисапсыз машиналар, туплар, хәрби җиһазлар аунап ята.

Сугышчылар көн-төн бардылар. Бары тик кыска ял вакытларында гына Газинур, кайда булса юл кырыенда утырып, фронт газетасына күз төшерергә вакыт таба иде. Совинформбюро сводкасы өстеннән күзләрен тиз-тиз йөгертеп, шатлыгын яшерә алмыйча:

– «Киев юнәлешендә... Запорожье һәм Мелитополь юнәлешләрендә... Павлоград юнәлешендә... Брянск юнәлешендә... Харьковтан көньяк-көнбатыштарак... Прилу-

ки юнәлешендә... Рославль юнәлешендә...» – дип укый иде ул.

Көн саен яңадан-яңа юнәлешләр турында хәбәр итеп торалар. Совет Армиясе аерым участокларда гына түгел, бик зур совет-герман фронтының буеннан-буена диярлек һөҗүм итә.

– Менә кайда ул безнең көч! – дип сөйли иде Газинур үзенең иптәшләренә. – Сталинград белән Курскидан соң гитлерчылар кая карарга да белмиләр. Сүнде аларның шәмнәре! Ә безнең көчебез көн саен арта. Вакыт та безнең файдага эшли. Без үзебез дә кырык беренче елдагылар түгел!

Бу ике ел эчендә Газинур үзенең полкташ иптәшләре белән бергә, автоматын күкрәгенә асып, солдат бүреген егетләрчә кыңгыр салып, шинель чабуларын бил каешына кыстырып, очсыз-кырыйсыз фронт юлларыннан күпме атлады! Ул үзе кебек чая иптәшләре белән яна торган авылларга бәреп керде, шәһәр урамнарында сугышты. Көзге, язгы җилләр аның йөгергән чакта канатлар кебек җилпенгән плащ-палаткасын артка каерды, җәйге эссе кояш аның йөзен кара-көрән төскә кертте, пилоткасын, тир тозыннан чыланып беткән гимнастеркасын уңдырды. Салкын окопларда, ачык кырларда, яңгырда, буранда кунган, муеныннан суга кереп елгалар, сазлар кичкән, елгыр чаңгыларда йөргән вакытлары да, карга күмелеп йоклаган чаклары да күп булды аның. Яраланып кар өстенә дә егылды, артыннан канлы эз калдырып камышлар арасыннан шуышырга туры килгән көннәре дә бар иде. Госпитальдәге сөйкемле сестраларның йомшак кулларын да күрде, операция газапларын да, сәламәтләнү шатлыгын да кичерде. Ниләр, ниләр генә үтмәде Газинур солдат башыннан! Тик бер генә үкенече булды аның: госпитальдән соң яңадан фронтка кайткач, разведкага эләгә алмады. Госпитальдә аның уң аягының мина өзгәләгән бармакларын кисеп ташладылар. Хәзер ул, әүвәлге кебек, кыр кәҗәседәй җитез йөгерә алмый иде инде. Шуннан ул пулеметчы булып китте. Хәзер ул, станоклы пулеметның сырлы көпшәсеннән сыйпап, еш кына:

– «Максимка» нәкъ минем хатыным төсле хәтәр: бер үкерә башласа, берәүне дә якын китерми, – дия торган иде. Монысы, әлбәттә, Газинурның гадәттәге шаяруы иде. Ләкин бу беркатлы шаяру астында гаять зур бер нәрсә ята иде: ул үзен кайчандыр Гали абзый сөйләгән аяксыз пулеметчыга, Лениннан килгән, куркынычлы фронт көннәрендә дә Газинурның күңеленнән чыкмый торган батыр матроска якынайган, хәтта алар белән бер үк саф-

та тора кебек хис итте. Бу хәл авыр минутларда аңа яңа көч, яңа дәрт бирде.

Ә кыен чаклар бу ике ел эчендә аз булмады. Ул чигенүнең газаплы көннәрен дә, яна торган авылларны һәм шәһәрләрне дә, юл чатында моңаеп басып калган карткорыларны да, елап калган бала-чагаларны да байтак күрде. Бик күп якын дусларын югалтты, кайберләрен ул үз кулы белән җирләде, кайберләренең сөякләрен дә таба алмады, кайберләреннән вакытлыча аерылды. Күпләре белән яңадан очрашты. Карелия фронтында беренче тапкыр разведкага барган чагында алгы сызык траншеясында төнлә ишетелеп калган таныш сыман тавыш чыннан да таныш булып чыкты. Күп тә үтмәде, шул ук траншеяда, бу юлы инде көндез, Газинур Володя Бушуев белән очрашты. Ә бер елдан соң дивизия медсанбатына Екатерина Павловна күчеп килде. Газинурның абыйсын үлемнән коткарган кыска сары мыеклы Морозов, госпитальдә дәваланганнан соң, яңадан полкка кайтты, хәзер Газинур белән бергә бер пульротада хезмәт итә иде. Иске командиры – Арагац бөркете өлкән лейтенант Григорьян белән Газинур шулай ук еш очраша иде. Ул һаман дошманның алгы сызыгын айкап йөри, әллә нинди хәтәр бәрелешләргә катнашуына да карамастан, бер генә тапкыр да яраланмаган иде. Госпитальдән кайткач, разведчиклар арасында Газинур үзенең якташы – МТС бригадиры старшина Зәбировны да очратты. Аңа ул аеруча шатланды, чөнки госпитальдә аны күрә алмагач, гомумән, кайчан да булса бер күрүгә өметен өзгән иде...

1943 елның көзендә Н нчы дивизия полклары, чигенүче дошманны эзәрлекли-эзәрлекли, Старая Русса белән Великие Луки арасында Ловать елгасына килеп чыктылар. Биредә аларның алга барулары вакытлыча тукталды.

Вак таулар, урманнар, сазлыклар арасыннан борылып-борылып аккан елгадан Газинур каскасы белән су чүмереп алды да, ике куллап тотып, аякларын киереп баскан килеш эчә башлады. Каска кырыеннан аккан су тамчылары күкрәгендәге автоматына тамып торды.

Эчеп туйгач, Газинур юеш каскасын яңадан башына киде, Ловать аръягына карап тора башлады. Ул тирләгән, ярсыган иде.

– Иптәш командир, бер уңайдан Ловать аша да сикерәбезме? – дип кычкырды ул, күзләрен уйнатып.

Елганы кичәргә приказ юк иде. Елга аръягында дошман алдан бик көчле оборона корылмалары әзерләгән, яңа көчләр китереп өлгергән иде.

– Ашыкма, ефрейтор, – диде командир. – Берәр юләр фриц пуля белән башыңны ватмас борын, окоп казы.

Газинур маңгай тирен җиң очы белән сыпырды да Ловать аръягында, урман-сазлар арасына поскан дошманга тагын бер карап алды.

– Ничего, анда да барып җитәрбез әле! – диде ул ачу белән. – Ловать та, сазлар да фрицларны коткара алмас. Бүген булмаса, иртәгә муеннарын борырбыз. Монысы көн кебек ачык.

Газинур пулемет өчен окоп казый башлаган иптәшләре янына килде, кулына тимер көрәк алды.

Шул көннән полк оборонага күчте. Солдатлар өчен яңа тормыш башланды. Яңадан алар кулларына тимер көрәкләр, балталар алдылар, дошманның артиллерия, миномет уты астында дзотлар, блиндажлар, землянкалар әзерләделәр, траншеялар казыдылар, траншея казырга мөмкин булмаган сазлы урыннарда, крепость стеналарына охшатып, валлар күтәрделәр.

Беркөнне, фортификацион эшләр кызып кына барганда, таң алдыннан полк разведчиклары «тел» алып кайттылар. Бу иртәнге караңгы сәгатьтә валны ныгытырга чыккан сугышчылар иң алдан кызу-кызу атлап кайтучы өлкән лейтенант Григорьянны, аның артыннан автоматын әзер тотып фрицны җитәкләгән старшина Зәбировны күрделәр. Бүтән разведчиклар, эштән кайтучылар кебек, бераз артка калыбрак атлыйлар. Алар барысы да юеш халатлардан, башлыкларын артка ташлаганнар, үзләре арыганнар, тирләгәннәр. Күзләре яулык белән бәйләнгән әсир абына-сөртенә килә, тәмам бөкрәйгән, әйтерсең җебегән тавыкмыни.

Разведчиклар үтеп киткәч, ачык позициягә куелган станоклы пулемет янында постта торучы солдат, муенына автомат аскан өлкән сержантка карап, әкрен генә әйтә куйды:

– Һай үткен дә соң безнең разведчиклар, исең китәр. Җир астыннан ут йөртәләр. Өлкән лейтенант Григорьян – чын бөркет. Старшина Зәбиров та аннан калышмый. Ефрейтор Гафиятуллин сөйләде, ул – кырык беренче елда ук граната белән танк шартлаткан егет...

Солдатның акценты аның рус түгеллеген, ашыгып, йотлыгып, дулкынланып сөйләве аның яшь икәнлеген күрсәтә иде.

– Беләм... Бергә булдык, – диде өлкән сержант. Аның тавышы салмак һәм тыныч иде.

– Сез дә старшина Зәбиров белән бергә булдыгызмыни? Өлкән лейтенант Григорьянны да электән беләдер идегезме? – дип, түземсезлек белән сорады яшь солдат.

– Кайчандыр мин аның ярдәмчесе идем, – диде өлкән сержант. – Старшина урынында...

– «Тел» алырга да йөрдегезме?

– Булды...

Яктыра башлады. Өлкән сержант Морозов пулеметны дзотка кертеп куярга кушты. Ул төне буена бер генә минут та йокламады. Алгы сызыкта разведка хәрәкәт иткәндә, аның күзенә йокы керми иде. Разведкага киткән чагында, өлкән лейтенант Григорьян үзе аның янына килде, әгәр сизә калсалар, ут белән булышлык күрсәтү турында Морозов белән сүз куешты. Мондый эшләрдә ул бары тик үзенең элекке ярдәмчесенә генә ышана иде.

Разведка исән-сау әйләнеп кайткач, өлкән сержант тынычланып йокларга ятты. Йоклап торып юынырга гына өлгергән иде, аны гвардия капитаны Ермилов янына чакырдылар. Морозов пилоткасын, гимнастеркасын төзәткәләп алды да рота командирының землянкасына йөгерде. Землянкада йөзе кояшта каралган, болай да ак кашлары тагын да агара төшкән пульрота командиры гвардия капитаны Ермиловтан башка тагын полк командиры майор Кремнев та бар иде. Морозов килеп кергәндә, алар, өстәлгә иелеп, картага карап торалар иде.

Морозов, хәрби тәртип буенча, үзенең килгәнлеген әйтте. Гвардия капитаны башын күтәреп аңа карады. Кечкенә тәрәзәдән кергән кояш яктысы бер генә секундка аның йөзенә төште. Өлкән сержант гвардия капитанының куе ак кашлары артына тирән яшеренгән зәңгәрсу күзләрен күреп алды. Бу акыллы, юаш күзләр Морозовта бүген ни өчендер озаграк тукталдылар кебек. «Мөһим эш бар, ахрысы... Майор да бирердә», – дип уйлап алды өлкән сержант.

Майор, сүнгән трубкасын авызына кабып, һаман да картага карап тора иде. Менә ул, кулына карандаш алып, бер урында билге ясады. Морозов картадан ерак иде, майорның нинди билге ясавын ачык кына күрә алмады, тик кул хәрәкәтенә караганда, майор пулемет билгесе ясады шикелле.

– Менә шунда! – диде Кремнев.

Гвардия капитаны тиз генә картага карап алды. Шул чакта өлкән сержант тагын бер тапкыр бик кыска вакытка гына аның зәңгәрсу күзләрен күреп алды. Әйе, алар гадәттәгечә түгел иде.

Дзот амбразурасына куелган пулемет янында яки беренче линия траншеясында торучы гади солдатка фронт яки армия масштабындагы хәлләр түгел, үз дивизиясендәге, үз полкындагы хәлләр дә тулысынча билгеле бул-

мый. Шуңа күрә өлкән сержант якын көннәрдә фронтның бу участогында да зур вакыйгалар башланачагын, күрше Калинин фронтының – дивизия ике фронт ялгамында тора иде – һөҗүмгә күчәчәген, ә гитлерчыларның контрчаралар күреп, совет гаскәренең һөҗүмен өзәр өчен, төрле участокларда демонстратив «һөҗүмнәр» әзерләвен белми иде. Ул бары тик дошманның алгы сызыгындагы хәлләрне генә күргәли. Шулай булса да, тәҗрибәле солдат, элекке разведчик, бик вак, күп вакытта бүтәннәрнең күзләренә дә чалынмый торган билгеләрдән үз алдындагы дошманның «сулышын», «уйларын» сизенә иде. Моннан бер өч атна элек солдатлар арасында немецлар һөҗүмгә күчә, имеш, дип хәбәрләр йөри башлагач, өлкән сержант Морозов политбеседа вакытында аларга туп-туры әйтте:

– Әлбәттә, безгә уяу булырга кирәк, ләкин иртәгә, яки берсекөнгә, яки бер атнадан гитлерчылар һөҗүмгә күчәр дип уйламыйм. Фриц үзен тыныч тота, авыз гармунында күңелле көйләр уйный. Ни өчен? Чөнки бүтән барлык участокларда Совет Армиясе гитлерчыларның арт сабакларын укыта, ә биредә әлегә тыныч. Ә фриц үзенең ахмак башы белән, монда иртәгә дә тыныч булыр, дип уйлый. Шуңа күрә ул шатлана, күңелле көйләр уйный. Ә һөҗүм алдыннан ул кабалана, әчегән камыр кебек кыбырҗый башлый, гармуны көзге яңгыр астында калган эт баласы кебек шыңшырга тотына.

Ә соңгы ике көн эчендә өлкән сержант Морозов гитлерчыларның алгы сызыгына аеруча игътибар белән карый башлады: ул анда бинокль, стереотруба, перископ пыялалары ялтыравын гадәттәгедән күбрәк күрде, схемасына дошманның яңа ут нокталарын теркәде. Ә төнлә фрицның гармуны эт баласы кебек шыңшый башлавын ишетте. Ә иртән үзенең ярдәмчесенә – балык кебек елдам, үзе дә ничектер балыкка охшаганрак кызылармеец Мостафинга:

– Йә, Абдул, патроннарны күбрәк әзерлә, – диде.

Бераз соңрак, вал өстеннән дошман позицияләрен күзәткән чагында, Морозов янында каядыр бик ашыгып барган өлкән лейтенант Григорьян туктады.

– Йә, Арагац бөркете, – диде ул аңа иске гадәте буенча, – нинди яңалыклар бар?

Морозов аңа үзенең күзәтүләре, нәтиҗәләре турында сөйләп бирде. Григорьян үзе белән бергә туктаган киң җилкәле, үткен карашлы старшина Зәбировка карап күз кысты:

– Менә ул разведка мәктәбен үткән солдат! Молодец, өлкән сержант. Разведчик исемен югары тотасың.

– Гитлерчылар шушы көннәрдә өннәреннән чыгар дип

уйлыйм, – диде Морозов, – сезнеңчә ничек, иптәш өлкән лейтенант?

– Өлкән сержант ялгышмый, – диде Григорьян һәм тиз генә китеп барды.

Хәзер, смирно басып, сугышчан боерык көтеп торганда, өлкән сержант тагын бер тапкыр шул турыда уйлап алды.

Авыр көрәшләрдә үткән сугыш еллары өлкән сержант Морозов өчен эзсез генә узмадылар. Алар аның холкындагы киң күңелле кешеләргә хас гамьсезлекне, юашлыкны бетереп кенә калмады, тышкы кыяфәтен дә алмаштырды. Дөрес, ул әүвәлгечә калынрак иренле, саргылт кашлы, йомшак соры күзле, кыска сары мыеклы гади рус егете иде. Ләкин бу гади рус егетенең уң яңагында чигәсеннән алып авыз турысына кадәр тирән яра эзе сузыла. Шуңа күрә, аңа сул яктан караганда, ул эштән арып горн янында басып торган шат күңелле тимерчене хәтерләтсә, уң ягыннан караганда, бу авыр сөякле кешедә дошманнарына иксез-чиксез нәфрәт ташыганын, аның теләсә нинди куркыныч заданиегә дә уйлап та тормастан барачагын бик ачык күрергә мөмкин иде.

– Өлкән сержант Морозов, – диде Ермилов, пулеметчыга туры карап, – сугышчан приказны тыңлагыз, иртәгә иртән гитлерчылар безнең участокта һөҗүмгә күчәргә маташачак дигән мәгълүматлар бар. Сезнең пулеметыгызны кинжальный ут алып бару өчен билгеләдем. Төнлә безнең траншеялар алдында позициягә урнашырсыз.

Морозов керфеген дә селкетмичә җавап бирде:

– Тыңлыйм, иптәш гвардия капитаны!

– Барыгыз, әзерләнегез.

Морозов, кулын чигәсеннән төшермичә борылып, ишеккә таба атлады. Гвардия капитаны белән майор Кремнев аның артыннан карап калдылар. Башларыннан күп нәрсәләр кичергән, сугышның беренче көненнән үк өзлексез бәрелешләрдә катнашып килгән бу ике офицер кинжальный ут алып барырга билгеләнгән расчетка нинди куркыныч янавын бик яхшы беләләр иде. Кинжальный пулемет актыккы минутта, дошман тезмәләре бөтенләй якын килгәч кенә ут ача. Аның уты дошман өчен искиткеч куркыныч, ул аның тезмәләрен чалгы белән чапкандай кырып сала. Пулемет атудан туктамый торып, дошман алга бару түгел, башын да күтәрә алмый. Шуңа күрә дошман да аңа каршы үзенең бөтен ут көчен юнәлтә, аны беренче чиратта юк итәргә тырыша. Кинжальный ут алып бару өчен билгеләнгән пулеметны саклау эше аеруча җентекләүне сорый. Майор Кремнев шул турыда гвардия капитанына күрсәтмәләр бирергә тотынды.

## 11

Морозов землянкага ашыгып керде, караңгы сәкедә үзалдына җырлап яткан Мостафинга:

– Абдул, пулеметны тиз генә алып кер әле... Чистартырга кирәк! – дип кычкырды.

Аларның пулеметлары болай да чиста иде. Өлкән сержант моны яңадан карап чыгарга куша икән, димәк, кызу эш булачак. Командирын ярты сүздән аңларга күнеккән елдам Мостафин, күз ачып йомганчы сәкедән төшеп, землянкадан чыгып та китте. Берничә минуттан ул станоклы пулеметны сөйрәп кертте. Морозов идәнгә плащ-палатка җәйгән иде. Алар, шул плащ-палатка өстенә тезләнеп, пулеметны сүтә башладылар. Мостафин шунда ук авыз эченнән көйләргә кереште – дулкынланган чагында ул һәрвакыт шулай берүзе генә аңлый торган сүзсез җырны суза торган иде. Морозов исә кычкырып җырларга һәвәс булса да, авыз эченнән, эчне пошыра торган итеп көйләүне яратмый иде. Бу юлы да ул, ризасызлыгын белдереп, кашларын җыерды.

Мостафин шунда ук көйләүдән туктады:

– Иптәш өлкән сержант, сезнең йөрәгегездә бер-бер сагыш бармы әллә, гел нидер уйлыйсыз? Безнең «Тукай» колхозында шундый бер уйлы кеше бар иде. Соңыннан суга батып үлде.

Морозов, пулемет кисәкләрен чүпрәк белән тиз-тиз чистарткан Мостафинга астан гына карап алгач, ирексездән елмаеп куйды:

– Минем гомердә суга батасым юк, Абдул. Ул яктан хәвефләнмә. Мин Донда тудым, Донда үстем, кирәк булса, су өстендә йоклый да алам.

Мостафин җиңел генә сызгырып җибәрде: сөйләп тор, янәсе! Ул үзе йөзә белми иде. Бала чакта бер тапкыр баткан да булган. Чаршауга салып ике сәгать селеккәч кенә һушына килгән. Шуннан соң авылда аңа «үлемнән калган» дип кушамат биргәннәр.

Мостафин шул турыда әйтергә дип авызын ачкан гына иде, өлкән сержант аны сабыр гына бүлдерде:

– Тукта әле, Абдул... – диде һәм рота командирыннан әле яңа гына алган боерык турында сөйләп бирде. – Заданиегә икәү генә барабыз. Башкаларга анда эш юк.

Мостафинның йөрәге кызурак тибә башлады. Кинжальный ут алып бару билгеле инде... Хәтәр. Моңарчы аның бер тапкыр да андый ут алып барганы юк иде.

Морозов, аның кабынып китүен күреп, мыек астыннан көлемсерәп куйды:

– Бәлки, миңа сине түгел, икенче номерны алып барырга кирәктер, Абдул? Аның нервлары ныграк бугай.

Мостафинның сәламәт алсу йөзе башта агарынып китте, аннары куе кызыл төскә керде, яңакларында ак тимгелләр күренде. Күз каралары караңгыдагы чаткылар төсле ялтырый башладылар.

– Иптәш командир, сез миңа ышанып бетмисезме әллә? – дип сорады ул, ярсып.

Морозов аңа каты итеп карады, ләкин аның карашында кимсетү юк иде.

– Ох, үпкәчел халык! – диде ул, башын чайкап. – Чак кына бернәрсә булдымы – хәзер дары кебек кабыналар. Ә пулеметчы үзен кулда тота белергә тиеш. Менә болай! – Ул каты йомарлаган дәү кулын югары күтәрде. – Тегендә тынычрак бул, – дип, Морозов алгы сызыкка таба башы белән ымлап күрсәтте, – шаярттым мин сине, Абдул. Төшендеңме?

– Гафу итегез, – диде Мостафин, – төшенүен төшендем дә, шаяртуыгыз бик каты.

Өлкән сержант иңбашларын селкеп куйды. – Мин, Абдул, йомшаклыкны гомумән яратмыйм.

Шул чакта ишек шакыдылар. Ике сугышчы – кече сержант белән ефрейтор килеп керде. Кече сержант озын буйлы, кәкре борынлы, нечкә иренле, ефрейтор исә уртачарак буйлы, калкып торган зур кара күзле, чак кына шадрарак бер егет. Болар икенче пулемет расчетының төзәүчесе Константин Стариков белән аның ярдәмчесе Газинур Гафиятуллин иде.

– Узыгыз, иптәшләр, утырыгыз, – диде Морозов. – Мин хәзер эшемне бетерәм. Сез рекомендация өченме?

– Әйе, иптәш өлкән сержант, коммунист булып сугышырга теләк бар, – диде Стариков.

Морозов пулеметының йозагын җыеп бетереп оясына куйды, аның ничек эшләвен тикшереп, гашеткаларга басты. Чалт-чолт иткән тавышлар ишетелде. Бары тик пулеметның тоткарлыксыз эшләвенә ышангач кына, өлкән сержант идәннән торды:

– Дөрес уйлагансыз, иптәшләр. Хәзер икегезгә дә язып бирәм.

Мостафин белән Газинур үзара бераз сөйләшеп алдылар. Ләкин Газинур бүген гадәтенчә шаяртмый, көлдерми, аның сөйкемле йөзе җитди. Ул инде Морозовның кая җыенуын белә. Шуңа күрә Мостафин белән анымоны сөйләшкән чагында да ул әледән-әле өлкән сержантка күз төшерә. Гөнаһны яшерәсе юк, үзенә шундый бурыч йөкләтелмәгәнгә беркадәр көнләшеп тә куя

иде. Ләкин бу кызыгу күңеле вакчыллыктан түгел, ә бары тик сокланудан, үзенең дә шундый буласы килгәнлектән. Әйе, Морозов кебек батыр пулеметчы булу – аның күптәнге хыялы. Тикмәгә генә гвардия капитаны Ермилов кинжальный ут өчен Морозовны сайлап алмаган бит.

– Илдән хатлар аласыңмы, Газинур? Ни язалар, исәнсаулармы? – дип сорады Мостафин. Шунда Газинур Мостафинга да турырак карады, аның бу сорауны ни өчен биргәнлеген аңлады. Мостафин да Морозов белән бергә барачак бит. Ни генә булса да, алар янәшә булачаклар. Газинурның күңелендә аңа карата якты хисләр туды. Бу япь-яшь комсомолец егетне аның кочасы килде, ләкин солдатка үзенең хисләрен тышка чыгару килешми, аннары мондый нечкәлек Габдулланың хәтерен калдыруы да мөмкин. Газинур әкрен генә елмайды:

– Хатлардан өзелмим, малай, гөләп чәчәгем яудырып кына тора, – диде.

Чыннан да, Миңнурыйдан хатлар еш килеп тора иде. Күп вакытта хат почмакларында җырлар да була. Ул җырларны соңыннан Газинур бөтен иптәшләренә җырлап йөри. Аның өеннән хат алуын расчеты гына түгел, взводы гына да түгел, бөтен рота, хәтта бөтен батальон белә иде. Мисбах, Куйбышев госпиталендә бик озак ятканнан соң, агач аяк белән «Красногвардеец»ка кайтып төшкән, Газзәннең үлү хәбәре килгән. Ул аз сүзле, караңгы чырайлы кешене Газинур бик үк яратып бетермәсә дә, аның үлү хәбәрен ишеткәч, күзләренә яшь килде. Ул, траншеяга сөялеп, бик озак уйланып торды. «Туфрагың җиңел булсын, Газзән абый», – диде.

Хат саен Газинур Гали абзый турында сораштырып яза иде. Кайда ул, нишли, исәнме? Иң элек Миңнурый аның да фронтка киткәнлеге турында язды. Аннары хатларының берсендә: «Гали абзыйның хәбәрләре килеп тора», – дип белдерде. Тагын бер хатында: «Гали абзый Сталинградта сугышам дип язган иде», – дип хәбәр итте. Аннары ул яраланган, госпитальдән бер хаты килгән. Шуннан соң Газинур аның турында һични белми иде. Әллә инде бик еракка киткән, хат язарга вакыты юк, әллә яраларының авырлыгына түзә алмыйча үлеп калдымы. Юк, никадәр генә уйламасын, Газинур Гали абзыеның үлүенә ышана алмый иде. Газзәннең үлүенә, колхоздашларыннан тагын берничә кешенең үлүенә ул берьюлы ышанды, әмма Гали абзыйның үлүенә, үзенең кайчан да булса бер үләсенә ышана алмаган кебек, ышана алмый иде ул. Аныңча, Гали абзый кебек кешеләрне үлем ала

алмый, үлем алар алдында көчсез. Аны бит кулаклар өйрәнмәгән яшь ат койрыгына такканнар, аклар үлем эшелонына ташлаганнар, ул Сталинград дәһшәтен дә күргән, әмма үлем аны ала алмаган. Юк, ул исән булырга тиеш. Сугыштан соң, фашистларны турап салганнан соң, Газинур аның белән чәй эчә-эчә сөйләшеп утырыр әле.

Партиягә керү фикеренә килгәч, Газинур Гали абзый турында тагын да күбрәк уйлый башлады. Үзенең барлык адымын, эшен Гали абзый үлчәве белән үлчәү гадәте фронтта да дәвам итә иде. Ул еш кына: «Минем бу эшемә Гали абзый ничек карар иде, яхшы табар идеме?» – дип, үз-үзенә сораулар бирә иде. Газинурның партиягә керү теләгенә ул ничек карар? «Сиңа иртәрәк әле, Газинур, политик белемеңне бераз арттыра төш», – дип әйтмәс идеме? Юк, әгәр дә Газинурның фронтта һаман «сабак» укуын белсә, каршы сүз әйтмәс иде бугай.

– Ә миңа нигәдер күптән хат килгәне юк, – диде Мостафин, сагышланып.

– Син борчылма, Апуш, солдат хатларының юлы озын. Килер әле. Бәлки, бүгенге почтада ук булыр.

– Үзем дә шулай дип торам әле. Минем бит бердәнбер якын кешем – әни карчык. Бүтән беркемем дә юк. Син ул яктан бәхетле, Газинур. Синең хатының да, балаларың да бар. Әтиең дә бар...

– Әйе, ул яктан мин бәхетле, малай, – диде Газинур.

Морозов, кулларын чүпрәккә сөртә-сөртә, өстәл янына килде, Мостафин пулеметны алып чыкты.

– Йә, эшләр ничек, иптәшләр? – диде Морозов, сәке кырыена утырып. Газинур белән Стариков, гимнастерка кесәләреннән дүрткә бөкләнгән дәфтәр битләре чыгарып, өстәлгә куйдылар, – алгы сызыкта кәгазь кадерле иде.

– Эшләр, – диде Газинур, көлемсери төшеп, – нәкъ сабан туендагыча.

Морозовның йөзендә берьюлы ике төрле билге күренде: йөзенең бер яртысы әкрен генә елмая, икенче яртысы җитди һәм кырыс иде.

– Ялгышмасам, сабан туе – яз бәйрәме. Хәзер көз, – диде Морозов, үзе тәрәзә төбендәге кара савытын сузылып алды.

– Бик дөрес, иптәш өлкән сержант, көз, – диде Газинур шаян тавыш белән, – ләкин кырык беренче елның да, кырык икенче елның да көзе түгел, ә кырык өченче елның көзе! Дошман өчен ул чыннан да көз, ә безнең өчен ул – яз башы. Гитлерчылар бөтен фронт буйлап тәгәриләр, Курск дугасындагы кыңгыраулары гына шалтырый, һөҗүм итеп маташкан чакларында да алар күбрәк артла-

рына карыйлар. Фрицның җаны хәзер куянныкы кебек, яфрак селкенгән саен калтырый.

– Син бу турыда сугышчыларга да сөйлисеңме, Гафиятуллин? – дип сорады Морозов.

Газинур өчен Стариков җавап бирде:

– Сөйләмәгән кая, агитатор итеп билгеләгәннән бирле, буш минут тапкан саен, солдатларга лекция укый.

Газинур чак кына кызарды.

– Лекциягә, конечно, көчем җитми, ә болай үзем белгәннәрне сөйләштергәлим, – диде ул җитди итеп.

Сары бөдрә чәчләрен пилоткасы эченә яшерә-яшерә, Стариков тагын сүзгә кушылды:

– Иптәш парторг алдында тыйнакланма әле, Газинур, Александр Матросов турындагы беседаңны бөтен кеше ошатты.

– Анысы башка, Костя. Матросов турында бүтәнчә сөйләп булмый. Андый геройлар бит безнең илдә генә бар, фрицлардан андый батыр чыга алмый.

– Ни өчен? – дип кызыксынды Морозов.

Газинур, бу турыда күп уйлаган булса кирәк, җавапны тотлыкмыйча бирде:

– Ни өчен икәнлеге үзеннән-үзе билгеле инде аның, иптәш парторг. Матросов – совет сугышчысы, ул үз илен яклап сугышты. Ә фриц нәрсә? Аның алдында пулемет, артында пулемет, кем өчен, ни өчен утка керә – пычагым да белми. Кыскасы, эше ташка үлчим аның. – Газинур бераз эндәшми торды, аннары өстәде: – Ә бер сүз белән әйткәндә, иптәш өлкән сержант, фрицның җаны өтек, ә Матросовның җаны олы, кояш кебек.

– Ни өчен алай? – дип сорады Морозов.

Газинур бераз уйланып торды да ерактан уратып җавап бирде:

– Билгеле инде, анадан бар кеше дә күлмәксез туа, иптәш өлкән сержант. Аңа нинди күлмәк киертү – өлкәннәр эше. Кешене яхшы итәргә дә мөмкин, юлбасар итәргә дә була. Матросовны Коммунистлар партиясе тәрбияләп үстергән, аның җанын олы иткән. Ә фрицны кем әвәләгән? Тинтәк Гитлер! Минемчә, тамыры шунда, иптәш өлкән сержант. Дөресме?

– Дөрес! – диде парторг.

Морозов рекомендация язарга кереште. Стариков белән Газинур аның кулыннан күзләрен алмадылар. Авыр хезмәткә күнеккән сөялле шул кул аларга дөньяда иң зур ышаныч кәгазен – аларны бөек Коммунистлар партиясенә тәкъдим итеп, рекомендация яза иде.

Язып бетергәч, Морозов ашыкмый гына урыныннан торды. Стариков белән Гафиятуллин да аякка бастылар.

– Сезнең белән иркенләбрәк сөйләшергә исәп бар иде дә, иптәшләр, вакытым тар. Мин сезнең моңарчы ничек сугышканыгызны беләм. Коммунист булгач, тагын да яхшырак сугышырсыз дип ышанам. Коммунистларга ротадагы, батальондагы солдатлар гына түгел, бөтен дөнья карый. Дуслар да, дошманнар да.

Газинурның сулышы ешайды.

– Вөҗданыгыз тыныч булсын, иптәш парторг, – диде ул, – без туган илебез өчен көчебезне кызганмабыз.

– Ышанычыгызны акларбыз, иптәш өлкән сержант, – дип кушылды Стариков.

Морозов аларның кулларын кысты.

Аз гына яңгыр сибәли иде. Күк йөзен соры болытлар каплаган. Немец артиллериясе якындагы фанера заводына ата. Төтен арасыннан заводның ватык корпуслары, әлегәчә ничектер ишелми калган озын трубасы күренә.

Алгы сызыкта исә үзенә бертөрле тынлык: немецлар да атмый, безнекеләр дә атмый.

Вал буйлап ашыгып барган чакта, Гафиятуллин белән Стариковны өстенә кыска бекешка кигән майор Кремнев туктатты. Ул бер төркем командирлар белән сөйләшеп тора иде. Сүзен бүлеп, пулеметчылардан:

– Сез нишләп йөрисез? Нигә үз урыныгызда түгел? – дип сорады. Майор алгы сызыктагы тәртипсезлекне, солдатларның кирәксезгә аннан ары, моннан бире йөрүләрен яратмый иде.

Пулеметчылар кайда булганлыкларын әйттеләр. Полк командирының кырыс йөзе йомшарды.

– Добро, – диде ул, үзенең һәрвакыт әйтә торган сүзен кабатлап. – Кайтыгыз. Әзер һәм сак булыгыз.

Пулеметчылар честь бирделәр дә вал буйлап китеп бардылар, аларның пулеметлары флангта тора иде.

## 12

Икенче рекомендацияне Газинурга өлкән лейтенант Григорьян бирде. Өченчесен дә ул пульротада ук таба алган булыр иде. Әгәр сораса, гвардия капитаны Ермилов та, расчет командиры өлкән сержант Степашкин да каршы килмәсләр иде. Ләкин өченче рекомендацияне Газинурның үзен әле сугышка кадәр үк белгән кешедән – Владимир Бушуевтан аласы килде.

Командирыннан рөхсәт сорап, Газинур шунда ук капитан Бушуев ротасына китте.

– Озак торма... Үзең күрәсең, эшләр ничек куера, – диде Степашкин.

– Күз ачып йомганчы кайтам, иптәш өлкән сержант.

Бу вакытта сугышка керер алдыннан була торган күтәренке-борчылулы бер халәт Газинурны чолгап алырга өлгергән иде инде. Мондый минутларда кешенең уйлары да, тойгылары да, искә төшерүләре дә ничектер үзенә бертөрле – үтә пакь, үтә кадерле була, алар күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә. Ләкин Газинурның күңелендә сугыш алдындагы гадәти киеренкелек кенә түгел. Ул бүгеннән тормышында ниндидер яңа чор башлангычын сизә, әйтерсең ул яңа баскычка күтәреләчәк. Ул күптән, авылда чагында ук инде, коммунист булу турында хыялланды, озак еллар буенча шуңа җаны-тәне белән әзерләнде, һәм менә ул көн килеп җитү алдында. Газинурның күкрәк кесәсендә ике коммунистның рекомендациясе ята. Өченчесе өчен ул ашыга-ашыга бара. Ни әйтер Бушуев? Шикләнмәсме? Ышанырмы?

Газинурның күз алдына госпитальдә дәваланып, полкка кайтканнан соң, капитан Бушуев белән очрашуы килеп басты.

Пыскак яңгыр явып торган көзге төн иде. Полк икенче эшелоннан алгы сызыкка күчә башлады. Шинель чабуларын бил каешларына кыстырган солдатлар, тездән пычрак ерып, олы юлга чыктылар. Газинур, станоклы пулеметның хоботын муенына атландырып, юл кырыеннан барды. Кычкырып сөйләшүләр, тәмәке тартулар тыелган иде. Тик рота старшинасы Михноның гына көйгә салыбрак кычкырган командасы ара-тирә ишетелгәләде.

– Подтянись!.. Принять в право!

Колонна әкрен генә уңга тайпылды, юл буйлап фаралары сүндерелгән автомобиль үтеп китте. Караңгы иде, ләкин солдатлар кем машинасы икәнен таныдылар:

– Генерал бара, – диде кемдер.

Газинур генералны бер дә күргәне юк иде.

– Костя, ниндирәк безнең генерал? – дип сорады ул Стариковтан.

Стариков җавап бирергә өлгермәде, шул ук Михноның:

– Разговоры! – дигән тавышы ишетелде.

Төн таңга авыша башлаганда, алар алгы сызыктагы землянкаларда урнаштылар. Аннан әле элекке хуҗалары чыгып та өлгермәгән иде. Газинур хәтсез арыган булса да, алгы сызык солдатлары белән сөйләшми түзә алмады. Ул алардан дошман турында, алгы сызыктагы тормыш турында сораштырды. Алгы сызыктагылар икенче эшелондагы хәлләр белән кызыксындылар.

– Андамы?.. Анда ял йортындагыдан да әйбәтрәк! – диде Газинур, күзен дә йоммыйча.

Солдатларның берсе, аның артык мактап җибәрүенә эче пошып булса кирәк:

– Ә син, энекәш, үзең ял йортында булганың бармы соң? – дип сорады.

– Хатыным булган иде, – диде Газинур.

Сукыр лампа яктысында Ермилов белән сөйләшеп утырган бер өлкән лейтенант тиз генә урыныннан торды да Газинур янына килде.

– Таныш тавыш, – диде.

Караңгы булуга карамастан, Газинур Бушуевны шунда ук танып алды.

– Иптәш Володя... иптәш Бушуев... иптәш командир... – диде ул, урыныннан тиз генә күтәрелеп. Ул тагын нәрсәдер әйтергә теләде, ләкин бик каты дулкынланганлыктан, сүз таба алмады.

– Тукта, тукта, – диде Бушуев, фуражкасын артка этеп. – Бу син... син түгелме, Газинур?

– Әйе, нәкъ үзе...

Ике бертуган очрашкан кебек, алар кочаклаштылар, Бушуев аны рус гадәте буенча өч тапкыр үпте, ә Газинур шул ук вакытта, татар гадәте буенча, аның аркасыннан какты.

– Исән-сау йөрисеңме, Газинур?

– Ремонтка кереп чыгарга туры килде килүен, ләкин болай бирешмибез, – диде Газинур.

Хәзер ул очрашуга күп айлар үтте инде, ләкин бүген, рекомендация сорап Бушуев янына барган чагында, Газинур яңадан, ул вакыттагы кебек, күңеле нечкәрүен, йөрәге сулыгып тибүен, ә яңакларында Бушуев үпкән чагындагы каты төкләрнең җиңелчә генә чәнчүен тойды.

Дивизия медсанбатында эшләүче Екатерина Павловна да полкка килгән чакларында Газинурны онытмый иде. Әйтерсең Газинур аларның бертуган энеләре. Ә чынлап карасак, ул бит аларга беркем дә түгел. Кайчандыр бер урында бергә эшләгән кешеләр азмыни дөньяда. Бер җае туры килгәндә, андый кешеләр белән, иске танышбелешләрне искә төшереп, бер-ике сәгать гәпләшеп утырырга мөмкин. Икенче очрашканда инде аягөсте генә сөйләшелә, ә өченчесендә баш кагып кына үтәсең. Ләкин бу гади рус кешеләренең күңеле киңлегенә, Володя белән Катяның аңа, Газинурга, гади бер иске таныш итеп кенә карамыйча, ничектер башкачарак, туганнарча каравына Газинур гаҗәпләнә дә, сөенә дә иде. Әйе, дип уйлый иде ул, күңел күзе якын күрмәсә, маңгай күзе якын итми...

Муенына автомат тагып килгән Газинурны үз ротасы территориясендә күргәч, Бушуев шатланып каршы алды. Ничек торуы, хатыны, бала-чагалары турында сораштыра-сораштыра, землянкасына алып керде, Газинур йомышын әйтте. Бушуев туктады, бик җитдиләнеп китеп, Газинурга туры итеп карады. Егетнең йөзе кояшта янган, калку күзләре якты, кыю. Җыйнак гәүдәсендә, хәтта күкрәгенә таккан автоматын ышаныч белән тоткан кулында да күпне күргән солдатларга гына хас бернәрсә бар. Әйе, бу Соликамск урманнарында бил каешына озын саплы тамга кыстырып бөтерелеп йөргән беркатлы Газинур түгел инде.

Бушуев ординарецына чәй әзерләргә кушты.

– Татар чәй ярата, Митя, исеңдә тот, – диде Бушуев ординарецына. – Кайчан да булса сиңа татар кунакка килсә, син аңа аракы куйма, чәй куй. Газинур, ничек әйтәдер идең әле чәй турында?

– Ачык чырай – такта чәй, иптәш капитан, – диде Газинур, көлемсерәп.

– Ишеттеңме, Митя? Синең такта чәең бар бугай, кызганма. Газинур чәеннән Казан каласы күренгәнне яратмый. Шулаймы, Газинур? Мин синең леспромхоздагы сүзләреңне һаман онытмыйм әле.

Бушуев рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аның белән бергә Митя да, почмакта колагына телефон трубкасы элеп утырган элемтәче дә көлеп җибәрделәр. Элемтәченең көлүен кайдадыр бүтән землянкаларда, колакларына шулай ук телефон трубкасы тагып утырган бүтән элемтәчеләр дә ишетте.

Газинур Бушуевка карады. Бу – Соликамск урманнарында кулына моторлы пычкы тотып, юан-юан агачларны егып баручы Володя да, түгел дә кебек. Өстендәге киеме, хәрәкәтләре, хәтта күз карашлары да үзгәргән аның. Тик кашларын җыерганда, маңгаен урталай яра торган сызык белән ап-ак тешләре генә әүвәлгечә калганнар.

Бушуев, кулларын артына куеп, землянка буйлап бер әйләнде дә рекомендация язарга утырды. Аны берничә тапкыр бүлдерделәр: әле комбат, әле полк командиры шалтыратты.

Газинур, Митя китереп куйган чәйгә кагылмыйча, капитанның язып бетерүен көтте.

Аңа эссе булып китте. Ул шинель каптырмаларын ычкындырып җибәрде. Күкрәгендә «Батырлык өчен» медале тоныкына ялтырап китте. Бу медальне аңа «Кыяр»дан «тел» алганда күрсәткән кыюлыгы өчен биргәннәр иде.

Ниһаять, Бушуев урыныннан торды.

– Яхшы коммунист булуыңны телим, – диде ул, аңа кадерле кәгазьне сузып. – Мин синең ничек эшләвеңне, ничек сугышуыңны беләм. Катя да синең турыда мактап кына сөйли. Ләкин бернәрсәне исеңдә тот, Газинур: син коммунист булгач, синең тормышыңда тышкы яктан һичнинди үзгәреш булмас. Син шушындый ук пулеметчы булып калырсың. Ләкин сиңа иптәшләрең гади пулеметчы итеп карамаслар, ә коммунист пулеметчы итеп карарлар. Моңарчы син үзең өчен, күп дигәндә отделениең өчен җаваплы идең, хәзер инде син рота, батальон өчен, ә тагын да тулырак итеп әйткәндә, бөтен Совет Армиясе өчен җаваплы. Ләкин син җаваплылыктан курыкма, син ул җаваплылыкны үзең теләп, аңлап аласың. Төшенәсеңме минем сүзләремне, Газинур?

«Морозов та нәкъ шушыларны сөйләде бит», – дип уйлап алды Газинур.

– Әйе, төшенәм, иптәш капитан.

Бу минутта Газинурның күңеле язгы таң кебек аяз һәм саф иде. Ул үзендә, яз көне беренче тапкыр кырга чыгып, беренче буразнаны сызгандагы кебек көчле җилкенү тойды. Менә шулай, бер дә туктамыйча, еракка-еракка барыр иде ул, һич тә арымас иде. Аның авыл урамындагыча күкрәк киереп кычкырып җырлыйсы килде, ләкин алгы сызыкта кычкырып җырлау тыелган иде. Ул, тар сукмактан атлый-атлый, авыз эченнән көйли башлады:

Орленок, орленок, взлети выше солнца
И степи кругом огляди...

Газинур үз блиндажына кайтты, расчет командиры өлкән сержант Степашкинга күренде. Степашкин озын борынлы, олырак яшьләрдәге бер кеше иде. Сугышка кадәр ул Мордовиядә умартачы булган, аның бөтен сөйләгәне бал кортлары турында гына иде. Газинур еш кына:

– Берлинга барып җиткәнче, өлкән сержант безне барыбызны да умартачы итә, – дип шаярта торган иде, Степашкин бу шаяртуга ачуланмый, үзалдына әкрен генә көлә, башын чайкый:

– Сине, ефрейтор, Берлинга хәтле түгел, дөнья кырыена барып җиткәнче өйрәтсәң дә, синнән умартачы чыгачак түгел. Тынгысыз кеше син. Ә бал кортлары күп такылдаучыларны яратмый.

Газинур килеп кергәндә, өлкән сержант старшина Зәбиров белән сөйләшеп утыра иде. Газинур разведчикның мондый киеренке вакытта биредә утыруына шактый гаҗәпләнде.

– Нихәл, Бөгелмә малае, – диде ул, Газинурга кулын сузып. – Ни эшләр каерып йөрисең?

Газинур үзенең кайдан кайтканлыгын әйтте.

– О, бу начар эш түгел! – диде старшина.

Өлкән сержант пулемет янына чыгып китте. Зәбиров сәкегә сузылды.

– «Тел» алып кайткансыз икән, – диде Газинур.

– Әйе, – диде Зәбиров теләр-теләмәс кенә, бераз эндәшми торгач өстәде: – Кара әле, Газинур, әйдә татарча бер җырлап алыйк. Нигәдер күңел ямансылый бүген.

Газинур аның янына сәкегә сузылып ятты.

– Ләкин кыска көйгә җырлама, борынгырак бер көйгә башла.

– Ярар, борынгысы кирәк булса, борынгысын да табабыз, – дип, Газинур «Агым су» көенә җырлап та җибәрде:

Аккошлар очар, әй, күл күреп,
Былбыл кошлар очар, гөл күреп.
Кына гөлгә кунган былбыл коштай
Сайрашырбыз микән бер күреп.
    Агым су, ак болытлар йөзәдер,
    Яшь күңелемне өзәдер...
Сандугачлар сайрый, әй, җир-су кипкәч,
Озак килми алар, бер киткәч.
«Онытмам» дип ник әйтәсең,
Бәлки, онытырсың, без киткәч.
    Агым су тулып таша, яз булса,
    Кайгырмыймын, кара каш булса.

Җырның соңгы ике юлын Газинур үзе генә җырлады. Зәбиров ни өчендер җырдан туктады, торып утырды.

– Ошамадымы әллә? – дип сорады Газинур, уңайсызланып.

– Юк, ошады. Юк, матур җырлыйсың икән. Кинәт старшинаның кашлары җыерылды, күзләре кечерәйде, сулышы ешайды. Ул, кулын йомарлап, маңгаена куйды.

Газинур моны күреп шаккатты.

– Ни булды, Исхак? – дип сорады ул әкрен генә.

– Мин аны ак күгәрчен итеп сөйдем, ә ул... козгын булган, – диде Зәбиров караңгы тавыш белән.

– Сөйгән кызың кияүгә чыкканмы әллә? – дип тиз генә сорап куйды Газинур. Аның күз алдына Бөгелмәнең шәһәр бакчасы коймасы янында башын кыңгыр салып, нечкә билен ак пластмасса билбау белән кыскан, үтә ак куллы, сары чәчле кыз килеп басты.

– Кияүгә чыкса гына бер хәл иде... – диде старшина, авыр сулап, – кияүгә чыккан өчен мин аны, бәлки, гафу да итәр идем... Ә ул, кара җан, начаррагын эшләгән...

Бөтен ил, бер кешедәй булып, дошманга каршы көрәшкән чагында, ул... үз кесәсе турында кайгыртырга керешкән... Ух, кара елан! – дип кычкырды старшина. – Аркама пычак кадаса, җиңелрәк булыр иде... Ничек мин аның шундый икәнен алдан күрмәгәнмен!

Газинур, старшинаның авыр кайгысын таратыр өчен, сүзне уенга борып җибәрергә ашыкты:

– Мәхәббәтнең күзе йомык, ди. Күрмәсәң дә гаҗәп түгел. Ләкин юкка кайгырма, иптәш старшина. Баш сау булса, кызлар табылыр. Кура җиләк кебек менә дигәннәре пешеп җитәр.

Старшина урыныннан торды, пилоткасын киде. Уенкөлкегә салырлык эш түгел иде бу.

– Китим, югыйсә өлкән лейтенантка кирәк булуым бар, – диде ул кискен генә. – Ә син, Газинур, уяу бул, иптәшләреңә дә әйт. Гитлерчылар кортланалар. Аңладыңмы? Ярый, исән бул. Кара, минем серне бүтәннәргә сөйләмә.

Зәбиров кызу гына чыгып китте. Арысландай көчле бу егетне Газинур чын күңелдән кызганды.

«Әйе, канга тоз салучылар да була шул дөньяда», – диде ул үз-үзенә. Миңнурыйның һичкайчан шушындый булмаячагына сөенеп, пулемет каршында дежурда торучы Стариков янына китте. Аны алмаштырыр вакыт җиткән иде инде.

– Кайттыңмы? – дип сорады Стариков. – Булдымы?

– Булды! – диде Газинур. – Әйбәт кеше ул, капитан Бушуев, Костя. Чәй белән дә сыйлады.

– Чәй белән сыйлаган һәр кеше әйбәт сиңа, – дип шаяртмакчы булды Стариков.

Газинур, алда җәелеп яткан сугыш кырына тар амбразурадан карап:

– Юк, туган, – диде. – Күңеле яхшы кешенең генә чәе тәмле була. Биредә нинди яңалыклар? Фрицлар ягында ул-бу сизелмиме?

– Хәзергә тып-тын утыралар. Еракта мотор гүләве ишетелгәли. Танклар түгелме икән?

– Старшина Зәбиров та кисәтеп китте әле, – диде Газинур.

Газинур пулемет янында берүзе калды. Тар амбразурадан еракта, офык буенда, берничә йолдыз җемелдәгәне күренә. Ракета чөелгәндә, алар тоныкланалар, аннары беразга бөтенләй югалалар да яңадан әүвәлгедән дә көчлерәк булып җемелди башлыйлар. Ләкин Газинур аларга, колхозда төнге юлдан буш арбага кырын ятып баргандагы кебек, озаклап карап тора алмый. Ул аларга

бары бер генә тапкыр күз ташлый да яңадан караңгы сугыш кырын күзәтергә тотына. Ике фронт арасындагы снарядлар актарып бетергән, тутыккан тимерчыбыклар белән уралган, надолблар тырпаеп торган, миналар белән тутырылган сазлы болынлык Газинурга бик яхшы таныш. Бүген анда бар кешедән алда Морозов белән Мостафин утыралар. Алар шулай ук төнге серле һәм шомлы тынлыкка колак салып торалардыр.

Газинур алар яшеренгән окопны күзләре белән эзләде, ләкин таба алмады. Аңа бераз ямансу булып китте. Беркадәр вакыттан соң дзотка ике кеше килеп керде.

Аларның берсе расчет командиры өлкән сержант Степашкин иде. Газинур аны аягын лышкылдатып атлавыннан ук танып алды. Икенчесен ул караңгыда күрә алмады, ләкин тавышын ишеткәч, анысын да шунда ук таныды: бу полк парторгы лейтенант Соловеев иде. Аның күкрәктән чыккан тавышында Газинур һәрвакыт ниндидер үзенә генә хас җылылык сизә иде. Сугышчылар белән Соловеев ашыкмыйча, тыныч кына сөйләшә, аңарда ясалма пафос та, гади булып күренергә тырышып кылану да юк.

Соловеев – инде олы яшьләрдәге, тормышның ачысын-төчесен күргән киң күңелле авыл кешесе. Армиягә аны 1942 елның башында алганнар. Җәй көне, дивизия полклары каты сугышлар белән чигенгән вакытта, Соловеев үзенең ротасы белән ике тәүлек буенча кичүне саклаган. Рота бөтенләй һәлак булган, Соловеев станоклы пулемет янында берүзе калган, патроннары беткәнче атышкан. Кулбашы һәм аягы яраланган килеш, пулеметын сөйри-сөйри, елга буена шуышкан, актык көче белән елганы йөзеп чыккан...

Елга аръягында ул күперне шартлатырга тиеш булган саперның күпер төбендә үлеп ятканын күрә. Шуннан ул күпергә шуышып китә, үле саперның салкын кулыннан бикфорд шнурын каерып ала, ут кабыза. Күпердән чигенергә аның вакыты да, көче дә булмый инде. Ул, күзләрен зур итеп ачып, шартлаткычка таба үрмәләгән ялкынга карап тора башлый...

Тормышта могҗизалар булмый, диләр. Ләкин Соловеев исән кала. Шартлатылган күпер янына яңадан килгән совет сугышчылары аны елга ярында, туфракка ярталаш күмелеп, һушсыз яткан хәлендә табалар. Ул бер тәүлектән соң санитар машинада барган чагында гына һушына килә.

Соловеевны рота командиры чагында күреп белгән яки аның ротасында хезмәт иткән сугышчылар аның батыр-

лыгы, куркусызлыгы, тыйнаклыгы турында гаҗәп хәлләр сөйлиләр. Соловеев әле дә буш вакытларында үзенең элекке ротасына барырга, үткәннәрне искә төшереп, озаклап сөйләшеп утырырга ярата икән.

Армиягә кадәр Андрей Андреевич Соловеев Чувашстан республикасында райком инструкторы булып эшләгән. Әйтүенә караганда, ул Бөгелмәдә дә күп тапкырлар булган, хәтта яшь чагында Бөгелмә тавындагы даганда да атынган, имеш. Газинур шуңа аны якташы кебек күрә иде. Кайчагында алар чувашча сөйләшеп тә алгалыйлар. Соловеев, үзе рус булса да, чувашча оста белә иде.

Газинур Соловеевның сөйләшкәндә, кеше күзенә карап тора торган гадәте барлыгын беренче очрашканда ук сизеп алган иде. Ул гүя синең сүзләреңне ишетү белән генә канәгатьләнмичә, җаныңда ниләр барлыгын да күрергә тели кебек.

Соловеев Газинур белән исәнләште дә, амбразура өстәленә таянып, хәзер тып-тын яткан сугыш кырына карап тора башлады. Аннары янәшә килеп баскан Степашкиннан:

– Кайда? – дип сорады.

Ул кем яки нәрсә турында соравын ачык итеп әйтмәсә дә, Газинур аның тавышындагы тирән борчылудан сүз Морозов турында барганлыгын аңлады.

– Әнә шушы турыда, – дип, Степашкин кулы белән күрсәтте.

Немецлар ягында ракета чөйделәр. Аның тоныкяктысы беразга блиндаж эченә дә төште. Газинур Соловеевның йөзен күреп калды: «Морозов турында кайгыра», – дип уйлады Газинур.

## 13

Гитлерчыларның һөҗүме җиде сәгать егерме өч минутта башланырга тиеш иде. Безнең командование, бу турыда алдан белгәнлектән, немецларның һөҗүме башланудан берничә минут элек, артиллериядән көчле ут ачты. Гитлерчылар аптырап калдылар. Аларның артиллериясе билгеләнгән вакытта ут ача алмады. Бары тик унбиш-егерме минут үткәннән соң гына, ягъни һөҗүмнең иң мөһим бер моментын – көтелмәгәнлек моментын югалткач кына, алар аңга килделәр, берьюлы бик күп туплардан, миномётлардан ут ачтылар, һавада аларның самолетлары күренде. Җир һәм күк үкерергә, ыңгырашырга тотынды. Ул арада безнең истребительләр дә килеп җитте,

кайдадыр югарыда, җирне каплаган кара төтен өстендә, беркемгә дә күренмәгән һава сугышлары башланып китте. Андагы сугышның никадәр кызу икәнлеге турында яна-яна җиргә килеп төшкән самолетлар гына сөйли иде.

Стариков белән Гафиятуллин хәтта янып төшә торган самолетларны да күрә алмыйлар. Алар утырган калын дзотның тар амбразурасыннан сугыш кырының бик кечкенә бер өлеше генә күренә. Әнә позицияләр алдында туфрак стенасы күтәрелгән. Ул стена, кара болыт кебек, бертуктаусыз ишелеп тора, ләкин яңадан-яңа снарядлар, бомбалар һавага элеккесеннән дә көчлерәк кара фонтаннар аталар.

Газинур шул фонтаннарга карый, аның тешләре кысылган, кара кашлары җыерылган, зур күзләре ялт-йолт килеп торалар. Аңа дзот эчендә тик утыруы кыен, куллары кая куярга белми.

– Костя, кара, кара! – дип кычкырды ул кинәт. Аңа һавага күтәрелгән куе туфрак һәм төтен эчендә пулемет тәгәрмәче күренгәндәй булды. Ул йодрыгы белән амбразура өстәленә суга башлады, аннары, амбразурадан атылып чыгарга теләгәндәй, бөтен гәүдәсе белән алга ыргылды.

– Тыныч бул, Газинур, – дип кычкырды Стариков, Газинурны, бил каешыннан эләктереп, бик вакытлы тартып алды. Чөнки нәкъ шул вакытта йодрык зурлыгындагы кыйпылчык, амбразураны ныгыткан зур ташка бәрелеп, очкыннар чәчрәтте дә, рикошет ясап, икенче якка, пулемет көпшәсенә тиде.

Гитлерчыларның артиллерия уты озак үкерде, ул инде һичкайчан туктамас кебек тоелганга, кинәт тирә-як тыптын булып китте.

Бер минуттан соң яңадан бөтен нәрсә үкерә башлады. Болын буйлап, артларыннан кара эзләр калдырып, танклар килә иде. Танклар артыннан немец пехотасы да күренде. Фрицлар, бөтен буйларына басып, акырыша-акырыша йөгерәләр, автоматлардан аталар, ләкин аларның акырулары да, автомат чиратлары да танклар һәм артиллерия гөрелтесе эчендә югала, алар үзләре дә катыргы солдатларга, юк, катыргы солдатларга түгел, ә арт аякларына баскан күселәргә охшыйлар иде.

Танклар тирәсендә безнең снарядлар күпләп ярыла. Кайчак танклар бөтенләй күздән югалалар, ләкин күп тә үтми, алар снарядлар күтәргән туфрак, төтен эченнән яңадан ыргылып чыгалар, туктап та тормыйча аталар. Снарядлар ярылуы тагын да ешая. Танклар алдында тоташ ут стенасы күтәрелә. Ул да булмый, танкларның берсе һавага ялкын атып яна башлый. Икенчесе дә туктап кала.

Биредә танклар йөри ала торган урын тар булганлыктан, башкалары да ут капчыгына эләгәләр.

Ләкин пулемет гашеткаларына ябышкан Стариков белән кулына лента тоткан Газинурның игътибарын танклар түгел, ә алар артыннан килүче пехота тарткан иде. Аларның пулеметлары флангта, пехотага каршы беренче булып, ут ачарга тиеш. Ләкин гитлерчылар яхшылап күренми. Сугыш кыры өстендә айкалган төтен барысын да каплаган. Аннан, җәһәннәмнән ычкынгандай, аерым фрицлар гына йөгереп чыгалар.

– Костя, башла... – диде Газинур кысылган тавыш белән.

Стариков егермегә кадәр санады да гашеткаларга басты. Пулемет бөтен сыны белән селкенеп тыкылдарга тотынды. Дзот эчендә аның үкерүе аеруча көчле иде. Газинур, лентаны турылый-турылый, нәрсәдер кычкырды, ләкин аның тавышы Стариковка ишетелмәде.

Пулемет беренче лентаны бик тиз йотты да туктады. Газинур, күз ачып йомганчы, икенче лентаны тыкты. Пулемет яңадан котырынып ата башлады, яңадан өстәлгә буш гильзалар коелырга тотынды. Газинур аларны җиңе белән идәнгә сыпырып төшерә торды.

Немец танкларының берничәсе, безнең артиллериянең ут киртәсен узып, тимерчыбыклар янына ук килеп җитте. Артиллеристлар, үзебезнекеләргә тидермәс өчен, аларга атудан туктарга мәҗбүр булдылар. Хәзер танкларга каршы пехота сафларында урнашкан җиңел туплар белән танк мылтыклары гына ата иде. Немец пехотасын шулай ук танклардан аерып булмады. Алар саранча көтүе шикелле ябырылып килә бирделәр. Аларның байтагы ава барды, ләкин калганнары һаман киләләр иде.

Стариков пулеметының кожухында озак атудан су кайный башлады. Шулай да ул бер генә минутка да атудан туктамады.

Фашист танкларының берсе флангтан атучы пулеметны күрде, ахрысы, аңа таба борыла башлады.

– Костя, кара, пантера безгә борыла! – дип кычкырды Газинур. Стариков Газинурның бу сүзләрен дә ишетмәде. Аның йөзеннән тир ага, каскасы күзләренә үк төшкән иде.

Кинәт пулемет туктады.

– Лента! – дип кычкырды Стариков карлыккан тавыш белән.

Газинур, үзләренә төбәлгән танк тубы көпшәсеннән күзен алмыйча, лента киертте, шул ук секундта туп авызыннан ыргылып чыккан кыска ялкынны күрде. Ул инс-

тинкт белән артка тайпылды, кулындагы лента төшеп китте. Газинур, йөрәге тибүдән туктаган хәлдә, снаряд ярылуын көтте. Нигәдер снаряд бик озак ярылмый иде. Әйе, бик озак, көтеп торырга көч җитмәслек дәрәҗәдә озак ярылмый иде ул. Газинур түзмәде, күзләрен ачты. Күрәсең, беренче снаряд тимичә үтеп киткән. Ләкин икенчесе дзотның почмагына китереп бәрде. Дзот, урыныннан кузгалгандай, селкенеп китте, түшәм бүрәнәләре арасыннан ком коелды. «Өченчесе нәкъ амбразурага бәрәчәк, пулеметны яшерергә кирәк» дигән уй яшен тизлеге белән Газинурның башыннан үтеп китте. Ләкин шушы бик кыска вакыт эчендә сугыш кырында нindидер зур үзгәрешләр булып алды, ахрысы. «Пантера»ның башнясы кубып очты. Немец пехотасы шулай ук артына карамыйча кача башлады.

– Морозов кыздыра! – дип шатланып кычкырды Газинур.

Морозовның пулеметы фашистлар, флангтагы пулеметлар уты астыннан чыгып, безнең траншеяларга ыргылырга хәзерләнгән иң кискен минутта ут ачты. Аның уты шулхәтле көтелмәгән һәм көчле булды: фрицларның алгы сафлары тәмам кырылып бетте. Исән калганнары кирегә борылдылар, ләкин аларга чигенергә дә урын юк иде. Кире борылган фрицларга аларның үз пулеметлары ут ачты. Котлары очкан Гитлер солдатлары, кая тыгылырга белмичә, яңадан алга ташландылар, яңадан Морозовның пулемет уты астына эләктеләр. Берничә минуттан гитлерчылар икенче тапкыр чигенә башладылар. Яңадан аларга үз пулеметлары ут ачты. Шулай ике ут арасында, акылдан язган кешеләр кебек, айкалып-чайкалып йөгергән немец солдатлары тәмам кырылып бетте.

Пехотадан аерылган танклар үзләре генә озак сугыша алмады. Алар шулай ук Ловать аръягына чигенделәр. Ләкин берсе, китәргә теләмичә, йөз сиксән градуска борылды, ватылган надолблар арасыннан үтеп, туп-туры Морозов окобына таба омтылды. Бер генә секундка окоптан Морозовның канлы башы күренде. Ул танк астына граната ташлады да шунда ук окопка яшеренде. Ләкин немец танкысы, үлем ачысы белән дошманына ташлана торган яралы ерткыч кебек, коточкыч сикереш ясады, окоп өстендә ажгырынып әйләнеп, аны җир белән тигезли башлады. Шунда ук бронебойщикларның берсе аның бензин багын шартлатты. Танк дары кебек кабынып китте.

Тыны кысылып, немец танкысын күзәтеп торган Газинур катып калды. Мөгаен, бу минутта аның гына түгел, бүтән бик күпләрнең дә тыннары кысылган булгандыр.

– Морозов өчен! – дип кычкырды Стариков ачы тавыш белән. Бер генә секундка туктап торган пулемет яңадан үкереп атарга тотынды.

Гитлерчыларның беренче, аннары икенче, өченче, дүртенче атакалары кире кайтарылды. Төн буе сугыш кырыннан яралы немецларның ыңгырашулары, елаулары, ярдәм сорап кычкырулары ишетелеп торды. Аларны килеп җыймадылар. Алар инде беркемгә дә кирәк түгел иде. Кем өчен, ни өчен үлә иде алар биредә? Бәлки, шушы соңгы сулышларында алар егерме икенче июнь көнне безнең илебезгә аяк баскан минутларын каһәрләгәннәрдер?

Сержант Морозов белән кече сержант Мостафинның үле гәүдәләрен янган танк астыннан сугыш тынгач та казып алдылар. Таң белән аларны алгы кырыйдан ерак түгел бер әрәмәлектә җирләделәр.

Пулеметчыларны икесен бер кабергә янәшә салдылар. Алар, тормыштагы кебек үлгәч тә бергә иде. Газинур аларның кулларын күкрәкләренә кушырып куйды да йөзләренә карап торды. Аларның йөзләре тыныч, гүя эштән соң бик нык арып, дөньяларын онытып йоклыйлар. Газинурның кайнар яше Морозовның салкын кулына тамды.

– Хушыгыз, туганнар, – диде ул әкрен генә. Кабер башында аларның пулеметы тора иде. Ул бик аз зарарланган. Ә кабер әйләнәсенә майор Кремнев, гвардия капитаны Ермилов, полк парторгы Соловеев һәм дежурдан азат булган пулеметчылар басканнар. Фуражкасын кулына тоткан полк командиры, кабергә караган килеш, мәрхүмнәр белән саубуллашты.

Аннары парторг Соловеев сөйли башлады. Аның йөзендә тирән кайгы, сүзләре дә авыр, кайгылы иде.

– Иптәшләр, – диде Соловеев әкрен генә, – без үзебезнең иң яхшы дусларыбызны җирлибез. Бу кабердә коммунист Морозов белән комсомолец Мостафин ята. Алар Ватан өчен үзләренең газиз гомерләрен кызганмадылар. Алар соңгы сулышларына кадәр сугыштылар. Тыныч йоклагыз, кадерле дуслар. Без, фашизмны юк итмичә, кулыбыздан коралыбызны төшермәбез.

Ул бер уч туфрак алып кабергә салды. Майор Кремнев, гвардия капитаны Ермилов шулай ук кабергә учлап туфрак салдылар. Бик тиз арада кабер өеме калыкты, саубуллашу салюты яңгырады.

Газинур яшь белән тулы күзләрен ятим калган пулеметтан алмады.

– Костя, – дип пышылдады Газинур, күзләре белән пулеметка күрсәтеп, Стариков шунда ук аның ни әйтергә теләвен аңлады, ризалыгын белдереп баш иде. Аннары,

майор Кремневка мөрәҗәгать итеп, Морозовның пулеметын үзләренә бирүен үтенде.

– Әле кичә генә иптәш Морозов ефрейтор Гафиятуллин белән миңа партиягә керү өчен рекомендация бирде. Ул безгә коммунистларча сугышырга васыять итте. Аның пулеметы һәрвакыт шушы васыятьне безнең исебезгә төшереп торыр.

Газинур, Стариков белән янәшә басып, сүзсез генә честь бирде.

– Морозовның пулеметын алу нинди җаваплылык өстәгәнен беләсезме соң? – дип сорады полк командиры, һәр сүзенә басым ясап. Аңа ике пар коңгырт һәм кара күзләр, кыю, намуслы күзләр карый иде.

– Беләбез, – диделәр сугышчылар.

Кремнев бераз эндәшми торды.

– Яхшы, өлкән сержант Морозовның пулеметын, төзәткәч, сезгә бирерләр. Ләкин моның белән сез үзегезгә бик зур өстәмә җаваплылык аласыз.

Ике пар күз аңа, керфекләрен дә селкетмичә, һаман да туры, кыю карап тордылар.

Сугышчылар таралды. Күктә авыр болытлар салмак кына йөзде. Әрәмәлектә сызгырып йөргән җил яңа кабер өстенә алтын яфраклар сибә башлады.

## 14

Икенче көнне иртән гитлерчыларның артиллериясе яңадан котырына башлады. Полк позицияләре өстендә яңадан ут үкерде. Бигрәк тә танклар үтә алырлык урынны саклаучы беренче батальонга кыен иде. Калын вал, траншеялар берничә урыннан инде җимерелгән, кайбер ут нокталары юк ителгән иде. Икенче рота командирының күзәтү пункты өстенә авиабомба төшеп, блиндажны актарып ташлады. Блиндажда утыручыларның берсе дә исән калмады. Ә яңадан-яңа снарядлар һаман явып кына торды. Аларның үкерүе астында яралыларның ярдәм сорап ыңгырашулары да, аерым команда тавышлары, сүгенүләр дә ишетелми иде.

Беренче батальонның уң флангысындагы калын дзотта, тыштагы үкерүгә колак салып, пулеметчылар тын гына утыралар иде. Җир әкрен генә селкенә, калтырана. Дзотның калын түшәме, стеналары шулай ук урыннарыннан кузгалгандай булалар. Сугышчылар караңгыда моны күрмиләр, ләкин, борчылып, әледән-әле түшәмгә карап алалар. Түшәм бүрәнәләре арасыннан каскаларга ком коелып тора.

Артиллерия налеты туктау белән, бер секунд кичекмичә, пулеметына тотынырга мөмкин булсын өчен, амбразурага иң якын почмакта чүгәләп утырган Газинурга түшәмнән ком коелуы ерак Соликамскины, Карп Васильевич өстәлендәге ком сәгатен хәтерләтте. Газинур, Карп Васильевичларга килеп чыккан чакларда, шул ком сәгатенә озак-озак карап тора торган иде. Стенадагы сәгатьтә вакытның үтүен күз белән күреп булмый. Ә нечкә трубка белән бергә тоташтырылган ике пыяла шардан торган ком сәгатендә вакытның узуын бик яхшы күрәсең. Бер шардан икенче шарга нечкә генә, тегәрҗеп калынлыгы гына булып, ком ага. Хәзер дә җир, урыныннан убылып, караңгы упкынга очарга торган бер минутта, күктән чинап төшкән бомбаларның һәр секунд саен дзотны актарып ташлавын тының кысылып көтеп торганда, түшәмнән башны авырттырмыйча, кайчак әкренрәк, кайчак көчлерәк коелып торган ком ничектер бик еракта булса да, тормышның туктамаганлыгын, аның һаман дәвам иткәнлеген белдереп тора иде кебек.

Караңгы дзот эче ачы төтен белән тулган, сулыш алуы читен, күзләрне яшь томалый, иркенгә чыгасы, саф һава сулыйсы килә. Ләкин Газинур да, башкалар да урыннарыннан кузгалмыйлар. Алар, хәтта үләргә туры килсә дә, приказ булмыйча торып, моннан китәчәк түгелләр. Шулай да аларга кыен. Алар берөзлексез тәмәке тарталар. Тәмәке утлары, елтыр-елтыр килеп, әле анда, әле монда күренә.

Бүген гитлерчыларның артподготовкасы озаккарак сузылды. Күрәсең, кичә авызлары пешкәч, бүген аеруча тырышкан булалар. Дзот түшәме менә-менә ишелеп төшәр шикелле. Ком да көчлерәк ага. Озакламыйча иң кискен минут башланачак: гитлерчылар атакага күтәреләчәк.

Газинур белән янәшә утырган Стариков, караңгыда кармалап, аның кулын тотты да каты итеп кысты. Газинур икенче кулын Стариковның кулы өстенә куйды, шулай ук каты итеп кысты. Сугышчан дуслыкның бу сүзсез билгесе «без утка да, суга да бергә керербез, без мәңгегә бергә» дигән изге ант шикелле, аларның күңелләрен ышаныч белән тутырды.

Кинәт дзот, урыныннан кубып, башта каядыр югары очкан кебек булды, аннары түбәнгә ыргылды, нәрсәгәдер бик каты бәрелде. Дзотның уң як почмагы җиргә утырды. Нәрсәдер (түшәм бүрәнәләре булса кирәк) чатнап сынды. Амбразураны каплый торган корыч калкан, чыңлап, идәнгә очты, дзот эченә көчле һава дулкыны белән бергә төтен, тузан бәреп керде, шунда ук дзот өстенә тау

ишелеп төшкәндәй булды. Яңадан нәрсәдер бик каты шартлады, уң як почмак тагын да ныграк утырды.

«Бомба төште!» – Бу уй берьюлы барлык миләрдән яшен тизлеге белән үтеп китте.

Дзот эчендә үлем тынлыгы урнашты. Менә шунда сугышчылар түшәмнән ком коелуы тукталуын сизделәр. Юк, ком коелуы түгел, ә вакыт, тормыш, яшәү туктагандай булды. Ләкин ике-өч секунд та үтмәгәндер, шушы коточкыч авыр тынлык эчендә яралының ачы тавыш белән ыңгырашуы ишетелде:

– А-а-а!

Яраланучының кем булуын караңгыда белүе кыен иде. Ләкин аның тавышы сугышчыларны уятып җибәргәндәй булды, һәммәсе урыннарыннан сикереп тордылар, кесәләреннән шырпы эзли башладылар. Кинәт дзот ишеге төбендә кесә фонаре кабынып китте. Пулеметчылар, гаҗәпләнеп, утка таба борылдылар. Ләкин уттан алда торганнары фонарьны кем яндыруын күрә алмады, – ут аларның күзләрен чагылдырды. Арттарак һәм кырыйдарак торучылар кулына фонарь тоткан кешенең хатын-кыз врач икәнен күрделәр. Аның матур озынча йөзе агарган, нечкә иреннәре нык кысылган иде. Кайчан, ничек ул дзотка килеп кергән – берәү дә белми калды.

Хатын берничә адым алга атлады, идәндә бөгәрләнеп яткан сугышчыга иелде. Хәзер инде Газинур да аны яхшылап күрә иде. Аның күзләре зур булып ачылды. Ул чак кына кычкырып җибәрмәде. Бу Екатерина Павловна Бушуева иде.

Отделение командиры өлкән сержант Степашкин амбразурага, аннары ишеккә ташланды. Ишекне тартып ачып җибәрде. Дзоттан тышка алып чыга торган тар юлны туфрак баскан иде. Сугышчыларның кайсыдыр:

– Күмелеп калдык! Томаландык! – дип кычкырды.

Өлкән сержант, аңа таба тиз генә борылып:

– Тыныңны чыгарма! Паникага бирелмәскә! – дип кычкырды, врач янына тезләнде. – Кай җире, иптәш военврач?

Екатерина Павловна эндәшмәде. Ул ак марля белән яралының башын урый иде.

– Үз эшегездә булыгыз, – диде ул аннары.

Газинур сукыр лампага ут кабызды. Аңа ком тулганлыктан, ут чатыр-чотыр килә башлады, кечерәйгәннән-кечерәеп, ахырда бөтенләй сүнде.

– Идәнгә куй, – диде Степашкин.

Газинур, лампаны идәнгә куеп, яңадан шырпы сызды. Идәндә лампаның сары теле бераз зурая төште.

– Стариков, Гафиятуллин, Иванов... – дип команда бирергә тотынды өлкән сержант: – Ишек юлын баскан туфракны көрәкләр белән чистартыгыз. Туфракны эчкә ташларга. Калганнарга амбразураны чистартырга. Тиз булыгыз. Гитлерчылар хәзер атакага килә башларлар.

Газинур ишек төбенә атылды, юлны баскан туфракны тимер көрәк белән казырга тотынды.

«Фриц безне кабергә тыктым дип уйламасын, без, җир астыннан чыгып та, аның бугазына ябышырбыз әле!» – дип уйлады ул, туфракны ярсып ташлый-ташлый.

– Тукта, – диде Степашкин, бер аягы белән тезләнеп, туфракка колагын куеп тыңлый башлады. Ләкин бернәрсә дә ишетмәде булса кирәк.

– Гафиятуллин, йә әле, син дә тыңла. Синең колак үткенрәк.

Өлкән сержантның бу сүзләреннән соң, яралы янына тезләнгән врачның башын күтәреп борылып каравына берәү дә игътибар итмәде. Барысын да ишек кызыксындыра иде. Газинур, тезләнгән җиреннән күтәрелеп, башын селекте.

– Берни ишетелми. Тәгаен бөтен юлны баскан.

Ишек төбе тар булганга, анда берьюлы берничә кеше эшли алмый иде. Өлкән сержант берәмләп эшләргә, еш-рак алмашып торырга кушты.

– Бир миңа көрәкне, Газинур, – диде Стариков, аның кулыннан тимер көрәкне алып.

Тирләп-пешеп беткән, һава азлыктан сулышын бик авырлык белән алган Газинур стена буена чүгәләде. Шунда аның янына Екатерина Павловна килде.

– Газинур, бу синме? – диде ул әкрен генә.

– Сез ничек бирегә килеп эләктегез, Екатерина Павловна? – дип сорады Газинур, борчылып.

– Санбатка йомыш белән килгән идем. Бер уңайдан Володяны да күреп китим дидем. Кичә аны яраланган, дип сөйләделәр.

Екатерина Павловна бераз эндәшми торды. Газинур бу минутта аның кем турында уйлавын бик ачык төшенде.

– Сез борчылмагыз, – диде ул.

– Үзем өчен борчылмыйм. Аның өчен...

Екатерина Павловна тирән генә көрсенеп куйды. Бу көрсенүдән Газинурның да күңелләре нечкәреп китте. Бәлки, Миңнурый да, Газинур өчен борчылып, шулай офтана торгандыр. Ләкин Газинур, бүтәннәр турында онытып, үз кайгысына чума торган кеше түгел иде. Ул кесә фонаре яктысында бигрәк сагышлы булып күренгән. Екатерина Павловнага тагын бер карап алды да, аны авыр

уйлардан ничек тә аерыр өчен, үзенең беркатлылыгы белән:

– Екатерина Павловна, минем абыйны хәтерлисезме? – диде.

– Билалетдиновнымы?

– Әйе.

– Хәтерлим. Кайда ул, исәнме? Син аны яраланган дигән идең шикелле?

– Әйе, аягын кистереп, өйгә кайткан. Хәзер колхозда эшли. Сезгә сәлам язган.

– Рәхмәт, сәламәт булсын.

– Минем кечкенә улым тәпи йөри башлаган. Мин аны күргәнем дә юк әле, мин киткәч туган. Хәзер тәрәзә өлгесе биеклеге була инде, ди. Аның буен тегәрҗеп белән үлчәп, конвертка салып җибәрсеннәр дип яздым әле. Озакламый килеп тә җитәр. Әнисе миңа охшый дип юмалаган була. Солдатның күңелен күтәрә торгандыр инде. Хатыннар салпы якка салам кыстырырга бик оста була бит.

Бушуева ирексездән елмаеп куйды.

Ишек төбендәге сугышчылар шаулаша башладылар. Газинур алар янына атылды, кайсыныңдыр кулыннан тимер көрәкне тартып алып, кызып-кызып казырга тотынды.

Екатерина Павловна яралы янына килде, фонаре белән аның йөзен яктыртты. Каратутлы матур йөз иде. Ләкин коточкыч әрнү аның ириннәрен кара көйдереп өлгергән. Дөресрәге, кычкырмас өчен, ул үзе аскы иренен тешләгән, тешләре астыннан ияге буйлап нечкә генә кан юлы сузылган. Ә күзләре врачка ничектер инәлеп, ялварып карыйлар иде шикелле.

– Бераз гына түз, акыллым, – диде Катя, – хәзер юлны казып бетерәләр.

Сугышчы берни әйтмәде. Ул әкрен генә күзләрен йомды. Бу аның соңгы сулышы иде.

## 15

Гитлерчыларның кысрыклавы көчәйгәннән-көчәя барган чагында, гвардия капитаны Ермилов беренче укчы рота командиры капитан Бушуевның күзәтү пунктына килде. Бу вакытта полкның бөтен ут көче сугышка кертелгән иде инде. Немецлар шулай ук барлык коралларыннан аталар. Сугыш кырын кара төтен чолгап алган, җир селкенә, актарыла, үкерә, ыңгыраша, чиный. Бомбалар, миналар, снарядлар шулкадәр еш ява, аларның шарт-

лаулары тоташ бер гүләүгә охшый. Монда һичкем һичнәрсә белми кебек. Алай гына да түгел, бу котырынган ут һәм тимер өермәсенә кемнең дә булса җитәкчелек итүе, бу коточкыч давылның кемнеңдер ихтыярына буйсынуы акылга сыймаслык бернәрсә кебек тоела. Шулай да аңа җитәкчелек итәләр. Иң алда, ярым җимерек күзәтү пунктында, каскаларына, иңбашларына соры тузан кунган кырыс йөзле ике капитан – Ермилов белән Бушуев – янәшә басып торалар. Икенче күзәтү пунктында утырган полк командиры майор Кремневның да үткен күзләре стереотруба аркылы сугыш кырына төбәлгән. Кайдадыр бераз арттарак кулына телефон трубкасын кысып тоткан, әледән-әле кул сәгатенә күз төшереп торган дивизия командиры – олы яшьләрдәге генерал да сугыш турында уйлый. Аның киң маңгаена тирән сызыклар чыккан, кашлары җыерылган. Чал кергән куе кашлары астындагы соры күзләрендә дивизия алып барган сугышның бөтен киеренкелеге чагылган төсле. Аңа әледән-әле шалтыратып торалар, ул кыска, ачык боерыклар бирә, кайчагында кемнәрнедер орышып та ала, ачулана да. Ләкин бер генә секундка да йөзенә аптырау билгесе чыкмый, иң киеренке минутларда да күзләрендәге чаткылар сүнми. Гүя аңа күп нәрсә билгеле, тик ул хәзергә әйтми генә. Гүя ул, шаулап, асты-өскә килеп торган ачык диңгездә берничә көн буенча үкергән штормның инде соңгы – тугызынчы валы үтеп киткәнлеген берүзенә генә мәгълүм булган билгеләрдән сизеп ала торган карт диңгезче кебек, әле һаман да үкереп торган дошман утының инде иң югары ноктасына җитеп кире кайта башлавын күреп тора. Менә ул урыныннан күтәрелде, сәгатенә күз төшерде, җитез бер хәрәкәт белән трубканы колагына куеп:

– Кремнев, обстановка? – диде.

Аңа полк командирының ерак тавышы җавап бирде:

– Дошман пехотасын җиргә кыстым. Танкларга каршы ут сугышы алып барам. Дүрт танк яна.

– Ә нигә тавышың күңелсез? – дип сорады генерал кинәт. Полк командиры бу сәер сорауны аңлап җиткермәде булса кирәк. Бу минутта Кремневның чырае нинди төскә керүен күз алдына китереп, генерал көлемсерәп куйды: – Ә гитлерчылар ничек сугыша? – дип сорады. – Артларына карап сугышалар дисеңме? Шул шул! Үкчәләренә басарга әзер бул!

Бу юлы майор Кремневның шат тавышы ишетелде:

– Есть! Аңладым.

Ике өлкән командир телефоннан сөйләшкән һәм сугышның яңа этабын хәзерләгән вакытта, капитаннар әле

һаман да шул ук күзәтү пунктында басып торалар, һәркайсы үз подразделениесенә җитәкчелек итә иде.

Капитан Бушуев кабаланмыйча, кыска, кискен командалар бирә. Аның бөтен ротасы кул астында, аңа сугышка җитәкчелек итүе җиңелрәк. Гвардия капитаны Ермиловның исә пулеметлары төрле роталарга сибелгән. Ул аларны күрми, расчетлар белән хәтта телефон элемтәсе дә юк. Ләкин шулай да гвардия капитаны коточкыч сугыш гөрелтесе эчендә үз пулеметларының таныш такылдавын ишетә. Алар һәммәсе эштә. Тик уң флангтагы өлкән сержант Степашкин пулеметы гына нигәдер атмый. Гвардия капитаны анда үзенең йомышчысын йөгертте. Бераздан йомышчы әйләнеп тә кайтты. Ул дзот янына авиабомба төшкәнлеген, дзотның тәмам томаланганлыгын әйтте. Пулеметчылар, мөгаен, барысы да һәлак булгандыр.

Ермилов күз кырые белән генә Бушуевка карап алды. Нидер әйтергә теләде, ләкин нык кысылган иреннәре ачылмады. Ул Екатерина Павловнаның нәкъ шул дзотка кереп киткәнлеген үз күзе белән күрде. Дөресрәге, кинәт ут астында аптырап калган врачны ул үзе шул дзотка кертеп җибәрде.

Ермилов яңадан Бушуевка карап алды. Ул биноклен күзләренә күтәргән, алгы сызык янында дошманның җиргә кысрыкланган автоматчыларына, надолблар каршында үкергән танкларына игътибар итмичә, броняларына солдатлар утыртып, уйсулыктан үкерә-үкерә килгән үзйөрешле орудиеләргә карый иде.

– Десант... Артиллеристларга сигнал! – дип кычкырды ул, артына борылмыйча. Шунда ук үзйөрешле орудиеләр килгән якка таба ике яшел ракета очты.

Гвардия капитаны да үзенең пулеметчыларына ракеталар белән сигнал бирде. Шунда ул уң флангтагы пулемет турында уйлап алды: «Әгәр ул булса, бу десантны сыпырып кына алыр иде».

Элемтәче Бушуевка телефон трубкасын сузды:

– Майор Кремнев.

Бушуев, окоп төбенә чүгәләп, бер колагына телефон трубкасын куеп, икенчесен учы белән каплап, дошманның танк десанты төшерергә әзерләнүе турында хәбәр итте. Полк командиры, аны бүлдермичә тыңлагач, көлемсерәп:

– Тавышың ник күңелсез? – дип сорады.

Бушуев, аның әкрен генә көлүен ишеткәч, тагын да катырак гаҗәпләнде. Кинәт телефон трубкасы кызып киткәндәй булды. Нәрсә бу? Нинди көлү?

Бөтенләй янәшә генә диярлек снаряд килеп төште. Капитан, трубканы кулыннан ычкындырмыйча, туфракка төртелде, шунда ук өстенә ком өеме ишелеп төшүен тойды.

– Бушуев, Бушуев! – дип борчылып кычкырды Кремнев. – Тереме? Туфрак кына? Сабан туена әзерлән! Сабан туена дим! Аңладыңмы?

– Аңладым, – диде Бушуев.

Гвардия капитаны Ермилов китеп барган иде инде. Бу вакытта ул, снаряд тиеп ишелгән вал кырыенда, пулеметчылар взводының командиры – яшь кенә лейтенант белән янәшә яткан килеш, пулеметчыларга яңа цельләр күрсәтә иде. Артиллеристлар, минометчылар, пулеметчылар тупланган ут белән дошман десантының зур өлешен килеп җитмәс борын ук таркатып бетерделәр. Ләкин алда яткан гитлерчылар, безнең утның десантка каршы юнәлдерелүе сәбәпле, беркадәр йомшаруыннан файдаланып, атакага күтәрелделәр. Менә шул кискен моментта моңарчы тынып торган уң флангтагы пулемет ут ачты. Ул гитлерчыларның флангысына бәргәнгә, аның уты аеруча аяусыз иде. Гвардия капитанының кырыс йөзе күз ачып йомганчы яктырып китте. Ул, шатланып:

– Степашкин эшкә керешге! Егет! – дип кычкырды.

– Үлгәннәр терелдеме әллә? – диде лейтенант.

– Юк, безне үтерүе җиңел түгел! – диде гвардия капитаны һәм Бушуев турында уйлап алды. Бәхете бар икән!

Әйе, бу, чыннан да, өлкән сержант Степашкинның пулеметы иде. Җир астында күмелеп калган пулеметчылар, озак көрәшә торгач, ниһаять, үзләренә юл ачтылар. Өлкән сержант пулеметны ачык позициягә чыгарырга боерык бирде, үзе беренче булып тышка омтылды. Аның артыннан Стариков белән Гафиятуллин пулеметны сөйрәп йөгереп чыктылар. Бу вакытта бөтен җирдә аталар, мина, снаряд шартлаулары, пулемет, автомат чиратлары – барысы бергә кушылган иде.

Пулеметны ачык позициягә урнаштырып өлгергәннәр генә иде, дошманның пехотасы атакага күтәрелде. Өлкән сержант команда бирде. Пулемет, җир астында үзен озак вакыт эшсез ябып тотулары өчен ачуланган сыман, ярсып тыкылдарга керешге. Стариков бөтен лента беткәнче атты. Аннары Газинур икенчесен куйды:

– Кыздыр, Костя, кыздыр! – дип кычкырды.

Гитлерчылар, тимерчыбык киртәсе янына ук килеп җитеп, яңадан җиргә ятарга мәҗбүр булдылар. Шул чакта болытлар арасыннан, карчыгалар кебек, күз иярмәс тизлек белән атылып, безнең кызыл йолдызлы штурмовиклар

килеп чыкты. Гитлерчылар өстеннән түбән генә очып, аларга кургаш яңгыры коеп үттеләр.

Акылдан язган немецлар, икенче тапкыр әйләнеп килү өчен, яңадан һавага омтылган штурмовикларга башларын күтәреп карый-карый табан ялтырата башладылар.

– Куптылар! Аля-ля-ля! – дип кычкырды кемдер.

Өлкән сержант Степашкин вал өстенә сикереп менде һәм:

– Чигенүче дошманга... – дип команда бирде.

Стариков, команданың ахырын көтмичә үк, ут ачты. Газинур башын күтәреп караганда, өлкән сержант вал өстендә юк иде инде. Патрон ташучы кызылармеец, шуышып килеп, Степашкинның үлгәнлеген хәбәр итте.

Ләкин патрон ташучы бик ачык әйтсә дә, аның сүзләре әле яңа гына бер үлемне җиңеп, җир астыннан чыккан Стариков белән Гафиятуллинның аңына тиз генә барып җитмәде.

– Йөрәгенә пуля тигән...

Кинәт Стариков нәрсә булганын төшенде, бер генә секундка аның бармакларының ныклыгы югалды, пулемет, тезгене йомшарган чаптар ат шикелле, кинәт тотлыга башлады. Икенче секундта инде Костя үзен кулга алып өлгерде, пулемет яңадан бөтен көченә үкерергә тотынды.

– Лейтенантка әйтегез... – дип кычкырды ул, атудан туктамыйча, – команданы мин алам. Ефрейтор Гафиятуллин – минем урынга! Иванов – икенче номер.

Снарядлар һәм миналар ярылуыннан тетрәп торган алгы сызык буйлап өстенә офицер шинеле кигән урта буйлы бер кеше йөри. Ул дзотларга, блиндажларга керә, ут позицияләрендә, күзәтү пунктларында туктый, траншеяларга, аралашу юлларына килеп чыга. Һәр җирдә, вакыты сыйдырган кадәренчә, солдатлар, офицерлар белән сөйләшә, киңәшләр бирә, ә бүтәннәр сөйләгәндә бүлдермичә, зур игътибар белән тыңлый. Әгәр ату тавышларыннан авыздан чыккан сүз ишетелерлек булмаса, сугышчының иңенә кулын сала, аның белән бергә котырынган ут давылына тыныч кына карап тора.

Бу кеше һәр җитди сугыш алдыннан, теләсә нинди шартларда, төнлә һәм көндез, сугышчылар арасында бөтен кыенлыкларны бергә кичерешеп йөргәнлектән, ул кая гына барып чыкса да, көтелмәгән кунак булмый. Һәр җирдә аны үз итеп каршы алалар.

Бу кеше командалар да бирми, ачуланмый да, әмма ул булып киткән урында сугышчыларның күңелләрендә яңа ышаныч, яңа ашкыну туа.

Бу кеше – полк парторгы Соловеев. Ул Газинурлар

расчеты янында туктаганда, актыккы немец танклары һәм үзйөрешле орудиеләре чигенә башлаганнар иде инде. Парторг, Газинурның пулеметы янына тезләнеп, төрлесе төрле җирдә, төрле хәлдә дөрләп яна торган немец танкларына карап торды.

Газинур, атудан туктап, кулы белән каскасын күтәреп куйды:

– Бүген яңадан килеп маташмаячаклар, иптәш парторг, – диде ул көр тавыш белән. – Туйдырганчы «сыйладык...».

– Юк, Газинур, – диде парторг, аны бүлдереп, – аларның килүен көтеп утыру безнең эш түгел. Аларны куарга, тын алырга ирек бирмичә куарга кирәк.

– Приказ гына булсын, иптәш парторг, – дип җавап бирде Газинур. – Күптән көтәбез. Куарга дигәндә, безнең бил буган!

Шул чакта алгы сызык буйлап, башка барлык тавышларны күмеп, бер көчле тавыш яңгырады:

– Атакага!

– Атакага!

Кемдер вал өстенә сикереп менде, автоматын болгап:

– Ватан өчен! Ура! – дип кычкырды.

Меңнәрчә кешеләр аның көчле тавышын эләктереп алдылар.

– Ура!

– Ура-а-а!..

Стариковның пулеметы атакага баручыларга беркадәр вакыт урыныннан торып ут белән булышты. Аннары, лейтенантның позицияне алмаштыру турындагы сигналын күреп алып, Стариков яңа команда бирде:

– Дуслар, алга!

Газинур, атудан туктап, кул сырты белән маңгай тирен сыпырып алды да, Иванов белән икәү, пулеметны сөйрәп, Стариков артыннан йөгерделәр.

Алар пехотачыларны куып җиттеләр. Стариков, калкурак бер урынга күрсәтеп, пулеметны урнаштырырга кушты. Яңадан пулеметына ябышкан Газинур качып баручы фашистларның яшел аркаларын күрде. Ул аларга терәп аткан кебек ата башлады:

– Морозов өчен, өлкән сержант өчен! – дип кычкырды. Ул яраланган, ләкин кайда, кайчан – үзе дә белми. Каскасы астыннан кан ага, кан аның бөтен битен буяган. Ләкин ул моны сизми, нәфрәт белән тулы күзләрен гитлерчылардан алмыйча, һаман ата. Кинәт фашистлар җиргә сеңгән кебек юкка чыктылар. Газинур да атудан туктады. Күз күреме җиткән бөтен кыр буйлап безнекеләр атакага баралар. Ә иң алда... Ә иң алда өч пехотачы йөгерә. Менә

аларның берсе егылды. Аннары ул нидер кычкырды булса кирәк. Калган икесе кире борылды, егылган иптәшләрен тиз генә күтәрделәр дә яңадан өчәү йөгерә башладылар. Газинур алар янында миналар ярылуын, пулемет чиратлары күтәргән тузаннарны күрде. Ә өч билгесез дус, үлемсезләр кебек, һаман алга бардылар. Әйтерсең аларны мина кыйпылчыклары да, пулялар да туктата алмый иде.

Стариков, позицияне алмаштырырга кушып, команда бирде. Гафиятуллин белән Иванов, пулеметны борып, яңадан сөйрәп киттеләр. Газинур өч дустан күзен алмады. Алар һаман янәшә йөгерәләр, тирә-якларында һаман пулялар сызгыра, миналар ярыла.

Яңа позициядән ут ачкан чагында да Газинур аларны күрде.

– Нинди батыр егетләр! – диде ул, ләкин аның тавышы үзенә генә ишетелде.

Өч дус, дошманның тимерчыбыкларын үтеп, өчесе берьюлы гранаталар ыргытып, траншеяга сикерделәр...

## 16

Газинур караңгы, сасы немец блиндажы эченнән чыкты да, көзге салкынча һаваны бөтен күкрәге белән сулап, якында гына аунап яткан «юнкерс» койрыгына барып утырды. «Кайда соң синең баш-аягың, – дип эченнән генә үртәп куйды Газинур. – Кәлтә еланныкы кебек койрыгың гына калган ич, хәсрәт».

Газинур яньчелеп, янып, каралып беткән тимер-томыр өеменә тагын бер тапкыр карап алды да теш арасыннан черт итеп төкерде һәм шунда ук бу турыда онытты, чөнки аның күңеле бүтән уйлар, бүтән хисләр белән тулды.

Бу юлы алар гитлерчыларның атакаларын кире кайтарып кына калмадылар. Үзләре контратакага күтәрелделәр, фрицларның үкчәләренә басып, «җилкәләренә атланып», аларның траншеяларына бәреп керделәр.

Гитлерчылар, үзләренең җайлы позицияләрен яңадан кайтарып алу өчен, ике көн буенча бертуктаусыз атакалап тордылар. Өченче көнне алар, көймәләре комга утырган шикелле, тынып калдылар.

– Булды бу, – диде Газинур, пулемет көпшәсен сыйпап, – фриц барабанын кагып бетерде, егетләр. Хәзер эшкә тотынырга кирәк.

Ул, нәкъ колхоздагыча, учларына төкереп, кулына тимер көрәк алды. Башкалар да көрәкләргә сузылдылар. Төннең-төн буенча алар бер генә минут та ял итмичә эшләделәр: траншеяларны тирәнәйттеләр, ут нокталарын,

блиндажларны ныгыттылар, амбразуралары көнчыгышка каратып ясалган дошман дзотларын үзгәртеп, көнбатышка таба атар өчен яраклаштырдылар. Бу чиксез авыр эш иде. Солдат тормышы, гомумән, тоташ авыр хезмәт ул. Төне буенча авыр ломнар, тимер көрәкләр белән җир казыган, күтәрә алмаслык булып сызлаган куллар таң туугa яңадан автоматларга, пулеметларга, минометларга тотынырга тиешләр иде.

Газинурның күңелендәге сугыш ярсуы басылып бетмәгән иде әле, шуңа күрә аның нечкә хисле йөрәге сугыштан соң һәр солдат йөрәгендә табигый рәвештә туа торган үткен сагышны – һәлак булган яки яраланган иптәшләрен сагыну сагышын сизми иде әле. Бу сагыш аның йөрәгенә бераз соңрак килеп кагылыр. Хәзер ул бары тик җиңү шатлыгына исергән иде.

Актарылып, асты өскә килеп беткән җирдә, җимерелгән, шартлатылган блиндажлар, землянкалар да, яндырылган, ватылган туплар, танклар, автомашиналар, поход кухнялары да аның шатлыгын җуя алмый иде. Әйләнә-тирә аңа якты булып, ышанычлы, өметле булып күренә. Ул үзе дә, ихтыярсыздан елмаеп:

– Җиңүчеләрнең күз карашы якты була дип сөйлиләр иде, дөрес икән! – дип куя иде.

Кухнядан аш алып кайтучы Иванов, Газинур яныннан үтеп, блиндажга кереп китте. Тәмле шулпа исе Газинурның борынын кытыклап калды. Ул урыныннан торды, дошман ягына күз кысты: эшләр шулай, янәсе, фриц әфәнде, бәйрәм безнең урамда!

Газинур блиндажга керде. Иванов котелокларны өстәлгә тезеп куйган. Иске гадәт буенча ул тулы расчетка алып кайткан. Алты котелок. Иң кырыйда өлкән сержант Степашкинның «А.С.» хәрефләре уелган яшел котелогы тора.

Дүрт котелокның хуҗасы, котелокларын алып, итле шулпаны ашый да башладылар. Ике котелок өстәлдә торып калды. Аларга бирәү дә сузылмады. Бу ятим котелокларга күз төшергәч, Газинурның йөрәге кинәт жу итеп китте. Кулындагы кашыгы чак идәнгә төшмәде. Ул авыр сулап алды, ашын ашап бетермичә, башын игән хәлдә, блиндаждан чыгып китте.

Менә ул яңадан «юнкерс»ның иске чиләк кебек яньчелеп беткән койрыгы өстендә утыра. Көзге аяз көн, күк йөзе, күл өсте кебек, зәп-зәңгәр, тик бик еракта, нәкъ яз башындагы шикелле, кардай ак бөдрә болыт кисәге йөзә. Һава җылы, хәтта кыздыра да. Берничә минуттан Газинур үзенең аркасында да күңелне тынычландыра торган

җылылык тоя башлады. Көтүче малай булып йөргән чакларында, күңеле ямансылап китсә, ул нәкъ менә шулай берәр ышык җиргә – кояш җылысына утыра да болында ялкау гына йөргән сыерларга, кәҗәләргә, сарыкларга тын гына карап тора торган иде. Тукта, блиндаждан башын иеп, күзләре мөлдерәмә яшь белән тулы килеш чыгып киткән Газинур нигә болай кинәттән генә малай чакларын исенә төшерде соң? Ул күптән үткән гамьсез чакларның кырыс солдат тормышына, иң якын иптәшләрен югалткан солдат йөрәгендәге тирән хисләргә нинди катнашы бар?

Яз башы иде. Беркөнне көтү артыннан йөргән Газинур кыр уртасында, кар суы җыелган зур чокырда, кыр казы күрде. Ул бичара нигәдер моңлы итеп кычкыра, башын күтәреп, дусларын эзләгән сыман, зәңгәр һавага карый, аннары бераз йөзеп китә, тагын моңлы итеп кычкыра, тагын очсыз-кырыйсыз күккә карый. Өч көн ул шулай сагышланып йөрде. «Адашкан, мескенем», – дип уйлады Газинур. Ул суга икмәк валчыклары сипте, ләкин кыр казы аларга борылып та карамады. Дүртенче көнне ул суы кими башлаган чокырны тагын бер әйләнде дә моңлы итеп кычкырып очып та китте. Аның тавышы шундый моңлы иде, Газинурның үзәге өзелгәндәй булды, күзләреннән яшь бәреп чыкты. Ә тагын берничә көннән Газинур чокырның аргы ягында, юеш туфрак өстендә канатларын җәеп яткан иkенче бер казны күрде. Ул үле иде...

Газинур ул чакта озак елады. Аннары аның күз яшьләрен язгы җылы җилләр киптерде, ә менә йөрәгендә калган сагышны һичнинди җилләр дә, давыллар да киптерә алмаган. Хәзер, ниндидер ерак охшашлар нәтиҗәсендә ул сагыш яңадан өскә калыккан икән, димәк, ул аның күңеленең тирән бер почмагында һаман яшәп килгән.

Газинур тәмәке кабызды, төтен аркылы карап тора башлады. Алгы кырыйда эш кайный. Солдатлар күтәренке күңел белән эшлиләр. Тик кайберләре генә басынкы күренә. Менә олырак яшьләрдәге, сары мыеклы бер солдат, тимер көрәкне ике кулы белән тотып, аның сабына карап тора. Анда кемнеңдер исеме яки исем-фамилиясенең баш хәрефләре уелган булса кирәк. Солдатның кулбашлары кинәт бик авыр йөк баскан шикелле түбән иелде. Ләкин моны бары тик Газинур гына күрде, ул гына солдат йөрәгендәге сагышны – сугышчан дустын югалту кайгысын аңлады.

Газинур тирән сулап куйды, марля белән уралган маңгаен учы белән каплап, тезенә таянды, нәрсәдер әйтәсе

килде, ләкин әйтмәде. Бар менә шундый хисләр, алар турында матур сүзләр эзләп, мин фәлән, мин төгән дип әйтеп тормыйлар. Ул үзеннән-үзе билгеле, ул – кешенең канында, йөрәк тибешендә, ул – кешенең һәрбер сулышында.

Кемнеңдер аяк тавышын ишетеп, Газинур артына борылды. Почтальон икән.

– Гафиятуллин, нәрсә уйга калдың? – дип кычкырды ул шаян тавыш белән: – Йә әле, биеп җибәр, Миңнурыеңнан хат бар.

Газинур урыныннан сикереп торды:

– Кая, кая, бир тизрәк, туган!

Почтальон хатны тоттырды да китеп тә барды. Газинур шунда ук конвертны ертты. Зәңгәр конверт эченнән, хат белән бергә, бер саплам тегәрҗеп килеп чыкты. Газинурның авызы ерылды. Ул тирә-ягына каранды, әле бик ерак китеп өлгермәгән почтальонны күрде.

– Әй, әй, почтальон иптәш! – дип кычкырды ул, почтальон янына йөгереп. – Тукта әле, бер генә минутка тукта. Менә тегәрҗеп... Күрәсеңме... Конвертка салып җибәргәннәр... Миңнурый җибәргән... Мин үзем, җибәрегез, дип язган идем. Һе... Кара син аны!

Берни аңламыйча карап торган почтальон каршында Газинур бер саплам тегәрҗепне, ике очыннан тотып, астан өскә таба сузды.

– Күрәсеңме, туганкай, нинди булган. Кая әле, бир әле карабиныңны... – Газинур җепне карабин өстенә куеп үлчәде дә тагын да көчлерәк шатланып сөйли башлады: – Иһи, кая үрелә, тишек борын! Карабин буе. Гвардейский солдат булып килә бит, ә!

Почтальон аның бәйләнешсез сүзләрен бераз төшенә башлады.

– Малаеңның буен үлчәп җибәргәннәрме әллә? – дип сорады ул, көлеп.

– Кәнишне, малайның! Монысы минем төпчек малай. Күргәнем дә юк әле. Мин солдатка киткәч туган. Һе, кара син аны, карабин буе!

– Йә, ярый, ефрейтор, – диде почтальон, кулы белән сумкасына сугып алды. – Монда, брат, бер сиңа гына түгел, бүтәннәргә дә шатлык бар! Киттем.

– Шатландыр, җаным, кешеләрне шатландыр, – диде Газинур, почтальонның кулын кысып. – Рәхмәт, туган, хезмәтең матур синең.

Почтальон бу көтелмәгән мактаудан башын югары күтәреп китеп барды. Газинур яңадан «юнкерс» койрыгына килеп утырды, хатны укый башлады.

«Хат башы, языгыз каршы...» дип башланган иде ул. Почмакларында җырлар да бар иде. Сул як почмакка Миңнурый:

Иртән торсам, кояш көтәм,
Кич булды исә, ай көтәм;
Кояш белән ай көткән күк,
Бәгърем, синнән хат көтәм, –

дип, уң як почмакка:

Мин иркәмә хатлар язам,
Җавапсыз калмыйм бер дә;
Ул – фронтта, ә мин – тылда,
Йөрәкләр тибә бергә, –

дип язган иде. Хатның кырыйларына буяу карандашлары белән чәчәкләр эшләнгән. «Сәмигам төшергән!..» дип куанды Газинур һәм хатны укый башлады.

*«...Газинур, йөрәгем! Син анда, ут эчендә, безнең турыда борчыла торгансыңдыр инде. Без һәммәбез дә исәнсаулар. Зинһар, дип әйтәм, борчылма. Сәмигаң белән Мөдәррисеңне күрсәң танымас идең: шундый зур, акыллы булдылар. Беркөнне Сәмига сине төшендә күргән. Уянгач, кайда минем әтием, ул кайткан ич, дип елый башлады. Берәр шинельле кеше күрсә: «Әтием кайта, әтием кайта!» – дип шатлана, урамга йөгерә. Коймак пешерсәм: «Монысын әтиемә калдырам, ул коймак ярата», – ди. Хәзер ул өстәл башында, ирennәрен бөрештерәбөрештерә, сиңа хат язган була. Мөдәррис китап караштырып утыра. «Әни, нигә монда танк төшермәгәннәр», – ди. Төпчегебез бишектә йоклый. Син аның буен үлчәп җибәр дигәнсең, җибәрәм. Каян шундый нәрсәләр уйлап табасың, Газинур? Синең хатыңны алганнан бирле, Сәмига белән Мөдәррис көн саен Әнвәрнең буен үлчиләр: бер кәтүк җебемне әрәм итеп бетерделәр. Бүген алар, мин эштән кайтып керүгә, яныма йөгереп килделәр дә: «Әни, әни, Әнвәр бүген зур үсте... Әткәйгә тизрәк хат яз», – дип биешә башладылар. Мин аларга карыйм да куанып туя алмыйм, бөтен арыганнарым онытыла. Колхозда ир-ат булмагач, эш бик күп, Газинур. Мине транспорт бригадасының бригадиры итеп куйдылар. Безне, коммунистларны, иң җаваплы участокларга беркеттеләр. Көнне төнгә ялгап, Бөгелмәгә ашлык ташыйбыз. Заданиене тутырдык инде. Хәзер фронт фондына өстәмә ашлык ташыйбыз. Колхозчылар үзләреннән арткан бөтен ашлыкларын дәүләткә бирәләр. Мин дә, Газинур, егерме биш пот бирдем.*

*Әти ындырда эшли. Карт кешенең авырган чаклары да булгалый. Бу ике ел эчендә ул бик биреште, Газинур.*

*Сине теленнән төшерми. Шул Газинурымның кайтканын күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем, ди. Мисбах абыйны, госпитальдән кайткач, завхоз иттек. Ул безгә һәрвакыт килеп йөри, балалар белән сөйләшеп утыра. Синең турыда гел мактап сөйли. Сабир бабай белән Галәк бабай, мине күргән саен: «Миңнурый килен, Газинурыбыздан хат-хәбәр юкмы?» – дип сорашалар. Медаль алуыңны ишеткәч, Сабир бабай балаларга күчтәнәч алып килде. Балаларны башыннан сөеп: «Әтиегез кебек батыр булыгыз, медальне бик зур батырлык күрсәткән кешегә генә бирәләр», – дип сөйләде. Яхшы карт ул, балалар да аны бик ярата. Гарәфи абый да сине гел сораштыра. Ул бригадир булып эшли. Бик тырыша, кешеләргә дә бик ягымлы. Үзең беләсең, элек аны кайбер кешеләр бик үк яратып та бетермиләр иде. Сугыш еллары аны бик нык үзгәртте. Әлфия ике эш алып бара: хисапчы да, звеновод та. Аның карсак Һашимыннан хатлар еш килеп тора, бүләк тә алган, тик нинди бүләк икәнен генә язмаган. Хәнәфи абзыйның, партизан булып йөрим, дигән бер хаты килде. Гали абзыйның хатлары нигәдер килми тора. Барыбыз да бик борчылабыз. Картлар әйтә: «Аны бик зур эшкә җибәргәннәрдер, хат язарга вакыты юктыр аның. Югыйсә үзе исән-сау булырга тиеш». Без дә шулай уйлыйбыз.*

*Газинур җаным, колхоздашларым турында иренмичә генә яз дигәнсең. Иренәмме соң! Үткән ай башларында Гандалибә әби үлде. Гарәфи абзыйның хатыны Бибигайшә апа ир бала тапты. «Алга»ның Галим абзый кызы Сания безгә укытучы булып килде. Гыйльфан Рәшидәсенең туе булды, армиядән яраланып кайткан комбайн Мортазага кияүгә чыкты... Күрәсең, сугыш дип тормыш туктамый, туйлар да була, балалар да туа. Эх, Газинур, әгәр син кайтып төшсәң, колхоздашларыңны таный алмас идең. Элек ишегалларыннан чыкмый торган җитмеш-сиксән яшьлек карчыкларга кадәр, барысы да фронтка булсын дип, тырышып эшлиләр. Фронтовикларга дип атап, кем оекбаш, кем җылы бияләй бәйли, кайсы сандык төпләрендә яткан, ирләренең яки балаларының төсе итеп саклаган иң кадерле, иң кыйммәтле әйберләрен фронт фондына китереп бирәләр. Безнең әти белән әни дә өлешсез калмадылар... Яшьләрне әйтмисең дә инде. Без, иртә торсак та, кич ятсак та, сезнең турыда гына уйлыйбыз. Сезнең турыда уйлап эшкә тотынабыз, сезнең турыда уйлап эшлибез, сезнең турыда уйлап, эштән кайтабыз. Без бөтен көчебезне җиңү өчен бирәбез, Газинур...*

*...Газинур бәгырем, язарга онытканмын. Колхозыбызда күңелсез хәл булып алды әле. Колхоз атларын имгәткән өчен төрмәгә утыртылган теге Тавык Мортыйны хәтерлисеңме? Шул имгәк бер дә бер көнне колхозыбызга кайтты бит. Кайтуы белән армиядә булдым, ранен булдым дип кукраеп йөри башлады. Теге, башымны нахакка ашаган идегез, ди. Үземнең честныйлыгымны күрсәттем, утка кердем, канымны да, җанымны да кызганмадым, ди. Ә үзе, бер кеше кырыкка ярылырдай кызу эш вакытында, колхоздан тегесен-монысын даулый. Фронтовикларны санламыйсыз дип, председателебезне кыйнамакчы булган, халык кул тидертмәде. Шуннан ары ул, үч итеп, төнлә колхоз амбарына ут төртмәкче булган. Шырпы сызган чагында эләктереп алдык үзен. Мылтыктан атып та карады, барыбер кача алмады. Суд булды. Судта ул бандитның барлык ялганнары ачылды. Фронтта бөтенләй булмаган икән, яраланмаган да. Үзенең дус-ишләре кулын сындырганнар. Колхозга ялган документлар белән кайткан... Атарга дип хөкем иттеләр...»*

– Эткә – эт үлеме! – диде Газинур, кашларын җыерып, үзе гитлерчылар ягына карап торды. Менә бит кемнәр аларны анда көткәннәр. Әгәр фашистлар «Красногвардеец»ка кадәр үк барып җитсәләр, шул адәм актыгы Мортыйларны йә староста, йә полицай итеп куярлар иде. Газинур, кулын йомарлап, тез башына сукты. Аның ирексездән туган бу хәрәкәтендә шулхәтле нәфрәт, шулхәтле ачу тупланган иде, бер түгел, унлап Мортыйлар аңа каршы килсәләр дә, ул аларны пран-заран китереп ташлар иде.

Газинур яңадан хатка текәлде. Миңнурый инде бүтән нәрсәләр турында яза иде. Кара болыт үтеп киткәннән соң, күк йөзе аяза барган кебек, Газинурның да күңел күге әкренләп аяза барды. Ул елмая башлады, ә инде Галәк бабайның яшьләр бригадасына башлык итеп куелганлыгы турында укыганда, чын күңеленнән көлеп җибәрде.

Ахырда Миңнурый яңадан үзе турында, балалары турында язган иде. Хатның бу юлларын укыганда, Газинур тәмам эреп киткәндәй булды. Ул хәтта янына килеп баскан өлкән лейтенант Григорьянны да күрми торды. Хатын укып бетергәч, яңадан тегәрҗепне кулына алды, аны ике очыннан тотып яктыга күтәрде, башын әзрәк кыйшайтып, карап тора башлады.

– Кара син аны, ә? Сугыш дип аптырамый бит. Әллә энисе колагыннан тартып үстерәме икән үзен? Һай, егет, һай, герой!

Газинурның йөзендә, зур кара күзләрендә балкыган бәхет нурын күреп, Григорьян түзмәде, кычкырып көлеп җибәрде. Ул өйләнмәгән егет, ата кешенең шулкадәр тирән шатлык белән хат укуын, ниндидер тегәрҗепкә сихерләнгәндәй карап торуын аңлап җитми иде.

– Син нәрсә, дус кеше, нинди тегәрҗепләр белән маташасың? – диде ул. – Кулга инә белән җеп алырга иртәрәк бугай әле.

Газинур утырган җиреннән сикереп торды.

– Юк, белмәдегез, иптәш өлкән лейтенант, – диде ул, елмаеп. – Әнисе төпчек малайның буен тегәрҗеп белән үлчәп җибәргән. Менә карагыз, карабин буе инде, иптәш өлкән лейтенант. Тагын берничә елдан, сезнеңчә әйткәндә, Арагац бөркете була инде бу.

Григорьян кычкырып көлә башлады. Аның пешкән слива кебек күзләре очкынланып китте.

– Шундый йомшак күңелле ата булырсың дип һич тә уйламыйдыр идем, Газинур, – диде ул.

– Менә өйләнеп карагыз әле, иптәш өлкән лейтенант, аннары башкача сайрарсыз.

Кинәт Григорьян көлүдән туктады.

– Башта сугышны бетерәсе бар әле, Газинур, – диде ул кырыс кына. – Безнең өчен берәү дә сугышмаячак. Дошман ягында нинди яңалыклар?

Газинур хатын тиз генә кесәсенә тыкты.

– Әйдәгез траншеяга.

Алар аралашу юлыннан алгы траншеяга үттеләр. Түбәндә урнашкан немец позицияләре моннан яхшы күренә иде.

– Янган танктан ике бармак уңдарак, ике йөз метр арырак немецлар дзот казыйлар, – диде Газинур.

Григорьян, биноклен күтәреп карады.

– Дөрес.

– Башы сынган агачтан өч бармак сулдарак, йөз илле метр арырак – пулемет точкасы.

Григорьян, күзләреннән биноклен алмыйча:

– Кайдан килгән анда пулемет точкасы? Мин берни дә күрмим, – диде.

– Төнлә ул пулемет атты. Лентага ялгышлык белән яктырткыч пуля эләккән булган, шуның буенча мин аның урынын билгеләдем.

Григорьян Газинурның әйткәннәрен картасына төшерде дә, дошманны өзлексез күзәтергә кушып, китеп барды. Ләкин берничә адым атлагач, кире борылды, Газинурның аркасыннан кагып:

– Димәк, Арагац бөркете, ә? – диде.

– Әйе, иптәш өлкән лейтенант, Арагац бөркете!

## 17

Буш минут килеп чыккан саен, Газинур фронтта да рус телен өйрәнүне дәвам иттерде. Кайчандыр Соликамск урманнарында сөйкемле рус кызы Катя тарафыннан аның күңелендә рус теленә карата кабызылган кайнар мәхәббәт сүнмәде, киресенчә, еллар үткән саен, тормышны тирәнрәк төшенә барган саен көчәя генә барды. Хәзер аңа сержант Стариков булыша иде. Газинурның карап укуы белән сөйләшүе ярыйсы булса да, язуда аның хаталары шактый иде әле. Костя аңа рус теленең грамматикасын, имля кагыйдәләрен өйрәтте, диктант яздырды. Аларның төп дәреслекләре «Пехотаның сугышчан уставы» булды. Ләкин бүген Стариков диктант өчен икенче бер әйбер әзерләп куйган иде. Сәкегә кырын ятып, ул кечкенә өстәл янында утырган, язган чакта, гүя кулына булышкан сыман, иреннәрен дә кыймылдатып торган Газинурга карап алаала, басымнарны, авазларны мөмкин кадәр ачыграк чыгарырга тырышып, кычкырып әйтеп тора.

– ...Оно пылало так ярко, как солнце, и ярче солнца, – дип язды Газинур, – и весь лес замолчал, освещенный этим факелом великой любви к людям, а тьма разлетелась от света его и там, глубоко в лесу, дрожащая, пала в гнилой зев болота. Люди же, измученные, стали как камни.

– Идем! – крикнул Данко и бросился вперед на свое место, высоко держа горячее сердце и освещая им путь людям*.

Соңгы җөмләне әйткән чагында, Стариков урыныннан торды, кулын, Данко кебек, югары күтәрде. Аның тавышы дулкынланган, бөтен гәүдәсе алга омтылган иде. Кинәт аңа үзе дә, Газинур да, меңләгән бүтән совет солдатлары да кыю Данкога бер карында яткан игезәкләрдәй охшыйлар кебек тоелды. Совет сугышчылары да фашизм караңгылыгы баскан дөньяга яктылык илтүчеләр бит.

– Яздыңмы? – дип сорады Стариков бераздан. – Эндәш билгесе!

Газинурның да йөзе, Данко йөрәгенең яктысы төшкән кебек, тантаналы, нурлы иде. Менә ул башын күтәрде,

---

*...Йөрәк кояш кебек, хәтта кояштан да яктырак булып балкый һәм адәм балаларына чиксез мәхәббәт нуры чәчүче факел яктысында бөтен урман тып-тын булып кала, ә караңгылык, челпәрәмә килеп калтыранып, каядыр урман эчендә, черек сазлык авызына егылып төшә. Кешеләр исә, тәмам таңга калып, таш кебек каталар.

– Әйдәгез! – дип кычкыра Данко һәм, үзенең яна торган йөрәген югары күтәреп, аның нуры белән кешеләрнең юлын яктыртып, алга, үзенең урынына йөгереп барып баса (М.Горький, «Изергиль карчык»).

ялтырап торган зур кара күзләре белән дустына карап, дулкынланган тавыш белән:

– Менә кеше булган, ичмасам. Әкияткә дә охшамаган, – диде.

– Данко, әлбәттә, экият герое, – диде Стариков, – ләкин Данко кебек батыр кешеләр безнең илебездә күп. Николай Гастелло, Зоя Космодемьянская, Лиза Чайкина, Александр Матросов... Алар – меңнәр, Газинур. Безнең Морозов та, Мостафин да, безнең командирыбыз өлкән сержант Степашкин да шундый иделәр.

Газинур артык бер сүз дә әйтмәде. Бары тик көләч йөзе кырысланды, каш араларына тирән сызык чыкты.

– Мә, тикшер, Костя, – диде ул әкрен генә. – Хаталарым күп булса, яңадан биш тапкыр күчереп язармын.

Стариков, Газинурның кулыннан каләмен алып, диктантны тикшереп чыкты. Хаталар бар, ләкин элеккедән аз иде. Стариков Газинурны хәтта мактап та алды.

– Син мине мактама, туган, – диде ул сүрән генә. – Мин серкәсе су күтәрми торганнардан түгел. Минем йонны кирегә сыпырырга да ярый.

Газинур диктантын күчереп яза башлады. Стариков киенергә тотынды.

– Позицияне карап керим әле, – диде ул.

– Костя, син ул китабыңны миңа биреп торсаңчы, – диде Газинур, – мин аны тагын бер укыр идем.

Стариков аңа кечкенә генә китапны тоттырды да чыгып китте. Газинур, диктантын күчереп бетереп, Горькийның китабын укырга керешкән генә иде, полк парторгы Соловеевның йомышчысы килеп, Газинурны парторг янына чакырды. Газинур дәфтәре белән каләмен противогазына тыкты да тиз генә урыныннан торды, өстен-башын рәткә китерә башлады. Сакал-мыекны иртән үк кырган иде, ак яка текте, итеген чистартты.

– Генерал янына барасыңмы әллә, ефрейтор? – дип сорады землянкага килеп кергән солдатларның берсе. – Бигрәк ясанасың.

– Юк, генерал янына түгел, парторг янына, җаным, – диде Газинур. Бу аның, коммунист булганнан соң, парторг янына беренче тапкыр баруы иде. Элек ул Соловеев янына ничек туры килсә, шулай чабадыр иде, ә хәзер алай итә алмады. Парторг, бәлки, берни әйтмәс тә, шулай да Газинур аның янына алама көенчә бара алмый инде.

Парторг тора торган землянканың ишеге төбендә Газинур кинәт туктады. «Ярамаган бер-бер эш эшләп ташладыммы әллә? Нигә чакыра?» – дип уйлады ул, шикләнеп. Тәне эсселәнеп китте, кулы якасына сузылды, – ул

яканы ачык йөртергә ярата иде. Ләкин кулы, бугазына җитмичә, тукталып калды.

Ишекне ачып, керергә рөхсәт сорады.

– Әйдүк, әйдүк, – диде Соловеев ачык чырай белән. Ул шомартылмаган такталардан ясалган кечкенә генә өстәл янында нидер язып утыра иде. Кәгазьләрен бер читкә этәреп, Газинурга урын күрсәтте. Газинур урындык итеп куелган бүкән өстенә утырды.

Землянканың кечкенә тәрәзәсеннән кояш нуры кергән иде. Шул чәчүрем тасма киңлегендәге кояш нуры бөтен землянка эчен үзгәртеп җибәргән. Стенага эленеп куелган автомат та, парторгның каскасы белән шинеле дә сугыш заманыннан бик еракгагы әйберләр кебек, истәлекләр кебек кенә күренәләр. Ә тимер мич өстендә кайнап торган калай чәйнек исә Газинурга леспромхоз тулай торагын хәтерләтә. Соловеев үзе дә, нәкъ өйдәгечә, якасын ычкындырып җибәргән килеш утыра. Әллә кояш нуры яктыртканга, әллә гомумән кәефе шәп булганга, йөзе дә көләч. Газинур беренче тапкыр аның ап-ак сәламәт тешләренә, көлемсерәп караган күзләренә игътибар итте. Моңарчы ул парторгны күбрәк җитди кыяфәттә күрергә күнеккәнгә, парторг «өйдә» дә шундыйдыр дип уйлый торган иде. Соловеевның бер елмаеп җибәрүе Газинурның барлык элекке уйларын юкка чыгарып ташлады.

Соловеев, ике кулын ике тезенә куеп, гадәтенчә, Газинурның күзләренә карап, бераз карлыкканрак тавыш белән:

– Йә, Гафиятуллин, эшләр ничек, барамы? – дип сорады. – Илдән хатлар аласыңмы? Колхозда барысы да исән-саулармы?

– «Красногвардеец»тамы? Барысы да исән-саулар.

– Кайдан шундый исем таптыгыз колхозыгызга?

– Анысы аның, иптәш парторг, үзе бер тарих. – Һәм Газинур Гали абзый турында сөйләп бирде.

– Алай икән, – диде парторг һәм уйга чумды.

Соловеев, кесәсеннән чылбырлы көмеш сәгатен чыгарып, колагына куеп тыңлап карады. Әгәр дә Газинур бу сәгатьнең тарихы белән кызыксынган булса, Соловеев аңа Сиваш сугышлары турында, шул сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен командарм үз кулы белән бүләк иткән шушы көмеш сәгать турында сөйләгән булыр иде.

– Расчетыңда эшләр ничек? Матчастьны, тактиканы яхшы өйрәнәсезме?

Газинур кыска гына итеп сөйләп бирде.

Соловеев инде Газинурның ак якасын да, йөзенең чисталыгын, киеменең пөхтәлеген дә күрергә, күңеленнән:

«Молодец, шулай кирәк», – дип уйлап алырга өлгергән иде.

– Бик яхшы, – диде Соловеев. – Һөҗүм тәҗрибәсен күбрәк өйрәнегез. Кызыл Армия бөтен җирдә һөҗүм итә. Без дә оборонада озак ятмабыз. Беседалар үткәргәндә дә шуны истә тотарга кирәк. Ничә беседа үткәрдең?

– Бу атнада өч беседа үткәрдем, иптәш парторг. Яңа килгән иптәшләргә безнең частьның геройлары кече сержант Иван Фетисов, снайпер Балтабаев турында сөйләдем. Икенче тапкырында пулеметыбызның тарихы белән таныштырдым. Бездә бит хәзер герой Морозовның пулеметы. Аннары дисциплина турында булды. Сводкаларны көн саен укыйбыз.

Соловеев блокнотына берничә җөмлә язып куйды:

– Ә «Боевой листогы»гыз кайчан чыга? – дип сорады.

– Стариков дежурдан бушагач эшләп бетерә. Обедка элеп куябыз.

– Син үзең берәр нәрсә яздыңмы?

Газинур кызарды.

– Юк, язмадым, иптәш парторг, – диде ул әкрен генә. – Грамота ягым минем шәптән түгел бит, иптәш лейтенант. Сөйләргә дисәң, булдырам, әмма яза башласам, көймәм комга терәлә. Ә безнең отделениедә егетләр грамотныйлар. Стариков тугыз класс бетергән. Иванов – җидене, Сергеев – алтыны, миңа, агитатор кешегә, үзем дә беләм, мәкалә язмау бер дә килешми. Ләкин агачны яшьтән бөкмәсәң, картайгач, кыенга килә икән шул.

Соловеев, Газинурның бу эчкерсез сүзләрен тыңлыйтыңлый, үзенең малай чакларын исенә төшереп алды. Поп батрагының җиденче баласы – Андрейка, исерек дьяконнан сабак укырга түгел, сүгенергә генә өйрәнде, сабак укыйсы урында дьяконның сыер, ат абзарларын чистартып вакытын үткәрде. Тик Кызыл Армия сафына алынгач кына, ул чын-чынлап укырга-язарга, тормышны аңларга өйрәнде. Газинурга шул турыда кыска гына сөйләп:

– Юк, Газинур, рус телен олыгайгач та өйрәнергә кирәк, – диде.

– Мин өйрәнәм, иптәш парторг. Стариков белән көн саен диярлек сабак укыйбыз.

– Стариков булышамы соң?

– Бүтән кеше бертуган энесенә дә Стариков миңа булышкан кебек булышмас, иптәш лейтенант.

Соловеев бераз уйга калып торды. Аннары башын күтәреп, Газинурның күзләренә гадәтенчә туры карап сорады:

– Стариковны сугышчан листокның редакторы итеп билгеләсәк, ничек булыр? Степашкин урынына.

– Бик яхшы булыр, иптәш парторг. Стариковның белеме дә, грамотасы да зур. Сугыш беткәч, ул укытучы булырга хыяллана. Аннары ул шигырь дә чыгара белә. Берничәсен безгә укып күрсәтте. Нәкъ китаптагыча, Пушкин шигыреннән бер дә ким түгел!

Соловеев Газинурның кояш белән гади лампаны янәшә куеп болай беркатлы чагыштыруына көлемсерәмичә булдыра алмады.

– Ә сиңа, Гафиятуллин, тагын нинди йөкләмә бирергә? Ничек уйлыйсың? Әллә булган кадәресе дә җитеп торырмы?

– Берәр кечерәгрәк йөкләмә булганда, каршы килмәс идем, иптәш парторг.

– Кечерәгрәк йөкләмә? – дип кайтарып сорады Соловеев. – Юк, Гафиятуллин, партия эшендә кечкенә йөкләмәләр булмый. Сиңа кечкенә эш бирергә уйламыйм да. Син – коммунист, агитатор. Мин синең бер мәкаләңне язып куйган идем: «Йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып керә». Бик дөрес сүзләр. Син йөрәктән алып сөйли беләсең. Шуңа күрә солдатлар да сине яратып тыңлыйлар.

Газинур, Соловеевның тел төбен берьюлы төшенеп җитә алмаганлыктан, тын да алмыйча утырды. Ни әйтмәкче була парторг? Боларны ул Газинурны юмалау өчен тикмәгә генә сөйләми, әлбәттә.

Бер минуттан Соловеев үзе барысын да әйтеп бирде:

– Беренче батальонда русча начар төшенә торган күп кенә татар, башкорт сугышчылары бар, – диде ул. – Тагын татарча белә, ләкин русча начар төшенә торган берничә чуваш, казах, бер үзбәк бар. Партбюро сине алар арасында да агитатор итеп билгеләргә карар чыгарды. Син үзең моңа ничек карыйсың?

Газинурның маңгае тирләп китте. Ул кул аркасы белән киң маңгаен сыпырып алды.

– Партия кушкан эшкә мин риза, иптәш лейтенант, – диде ул һәм бераз уйлап торгач өстәде: – Үзара сөйләшкән чакларда бу турыда егетләр миңа әйткәннәре дә бар иде барын. Кайчакта аларның бергә җыелып җырлыйсылары да килә. Безнең халык җыр ярата бит, ә гармун булса, аңа ашарга да кирәкми.

– Бигрәк тә яхшы. Син үзең шәп җырчы, ә гармунны табарбыз.

Газинурның йөзе яктырып китте.

– Минвзводта Буранбаев дигән башкорт егете бар. Яз көне, камыштан курай ясап, солдатларны таң калдырган

иде... Гармунда да бик оста уйныйм дип әйтә. Аннары старшина Зәбиров та гармунда шәп уйный. Тик аның вакыты гына булмас. Разведчик.

Соловеев дәфтәренә Буранбаев белән Зәбировның фамилияләрен язып куйды. Аннары, башын күтәреп:

– Яхшы. Ул чагында шулай итәбез: беренче беседаны Александр Матросов турында үткәрерсең. Икенчесендә татар халкының фронтовик татарларга язган хатын укырсың. Татар халкының хаты хәзер кулымда юк әле, ә Матросов турындагы материалларны бирә алам.

– Кирәкми, – диде Газинур. – Матросов турында минем материалларым бар, мин бит үзебезнекеләргә бер тапкыр аның турында сөйләгән идем инде.

## 18

Фронт өстен айлы, йолдызлы сентябрь төне каплаган. Йолдызлар шундый күп, әйтерсең берсе өстенә берсе каткат өелешеп беткәннәр. Якынраклары эрерәк булып, егерме тиен көмеш акча зурлыгындагы асылташлар кебек, ераграклары инә очыдай чак-чак күренеп җемелдиләр. Гүя сугыш күптән беткән, бар да тыныч, бар да әүвәлгечә. Ләкин бу – Калинин өлкәсендәге гади фронт төне, автоматлардан, пулеметлардан аталар, минометлар, төш күреп уянган ялкау этләр кебек, өзек-өзек өреп алалар, кайчак артиллерия дә ут ача. Йолдызлы күк йөзе буйлап, бик югарыдан, төнге бомбардировщиклар үтеп китә. Аларның басынкы гүләүләре дулкын-дулкын булып килә, кайдадыр еракта, көнбатышта югала. Ә ракеталар төннеңтөн буенча берөзлексез янып тора. Аларның топаз муенсага охшаган озын тезмәсе фронт буйлап бик еракка сузылып китә. Ракеталарның аксыл-яшел яктысында тәбәнәк үрләр, сазлыклар, урманнар, чәнечкеле тимерчыбык челтәрләре, кара валлар, җимерек машина, туп, танк калдыклары чагылып китә. Свастикалы бер немец танкысы аеруча ачык күренә, чөнки ул алгы сызык янында ук шартлатылган. Ул хәзер бөтенләй кәкрәеп, җиргә сеңеп бара: тиздән сазлык аны бөтенләй йотачак. Танк белән бергә аның эчендә калган фриц мәетләре дә упкын төбенә китәчәк.

Калын вал кырыена сөялеп, шул күренешләргә тын гына карап баручы Газинур, солдат хезмәтеннән кабарып, каешланып беткән киң учын, дустының иңбашына салган кебек, янындагы пулемет көпшәсенә куйган. Тимер салкын һәм дымлы. Газинурның бармаклары кечкенә генә җиз этикетканы капшый. Ракета яктысында

андагы язуны укырга да мөмкин: «Пулемет Героя Советского Союза старшего сержанта Морозова...»

Газинур, өлкән сержант турында уйлап, күккә карап алды. Таң йолдызы калыкмаган әле. Ләкин вакыт соң инде. Бер генә секундка Газинурның күңеленә балалары килде. Сәмигасы да, Мөдәррисе дә, Әнвәре дә йоклый торганнардыр инде. Әниләре, бәлки, ындырдан кайтып, аш пешереп йөри торгандыр...

Башка вакыт булса, Газинур алар турында бик озак уйланыр иде. Бүген полк парторгыннан шундый җаваплы йөкләмә алганнан соң, Газинур бары тик Александр Матросов турында гына уйларга тырышты.

Бөек герой бер генә минутка да аның күңеленнән китмәде. Бу турыда ул көндез, парторг яныннан кайткач, үзенең дусты Костя Стариков белән дә сөйләшеп алды. Стариков аңа Горькийның тагын бер китабын бирде, менә бу юллардан файдалан дип, астына кызыл карандаш белән сызылган урынны күрсәтте: «Син үлдең!.. Шулай да булсын! Ләкин кыю, көчле рухлыларның җырларында азатлыкка, яктылыкка горур чакыручы җанлы үрнәк булырсың син!»

Бу юллар Газинурга бик ошады, ул, аларның тирән мәгънәсен гади телгә күчереп, үзенчә гәүдәләндерү чараларын эзли башлады. Матросов турында күбрәк уйланган саен, ул аның күз алдына лачын кебек кыю, тирән акыллы, туган иле, дус-ишләре өчен утка да, суга да керергә әзер торучы, олы җанлы, киң күңелле бер кеше булып килеп баса иде. Солдат юллары аларны очраштырмавы бик кызганыч. Югыйсә янәшә торып диярлек сугыштылар. Чернушки авылы Газинурлар хәзер тора торган позицияләрдән ерак түгел, күрше генә. Хәер, очрашмасалар да, бер шинель астында ятып, бер тәмәкене икегә бүлеп тартмасалар да, Газинур Александрны үзенең иң якын, иң кадерле дусты, туганы, коралдашы итеп саный иде. Моңа, бәлки, Газинур белән Саша биографиясендәге уртак урыннарның да беркадәр тәэсире булгандыр. Алар икесе дә ачы ятимлекне татып, ана иркәләвен күрмичә үскәннәр. Баланың анага булган чиксез зур, кадерле, изге мәхәббәте аларның күңелләрендә сакланып калган. Алар, нечкә күңелле, саф вөҗданлы кешеләр булганлыктан, йөрәкләрендәге бу олы мәхәббәтне вак-вак өлешләргә бүлгәләп, әрәм-шәрәм итеп, җилгә очырмаганнар. Дөрес, Газинурның сөйгән семьясы бар, ә Матросов үзенең олы мәхәббәтен, сөйгән кызы белән дә уртаклашырга өлгермичә, тамчысын да калдырмыйча анабыз Ватанга биргән...

Сугыш кырында үлеп калу гаҗәп хәл түгел, Газинур һәлак булган кешеләрне күп күрде. Алар арасында батыр йөрәклеләре, дошманга каршы арысландай сугышканнары булган кебек, үлемнән курыкканнары да бар иде. Газинур үзе белән эшелонда бергә килгән бер егетне хәтерләде. Телеграф баганасы шикелле озын буйлы бу саламторхан, фронтка килеп җитмәс борын ук, җебеп төште. Ул, тезләрен кочаклап, сәгатьләр буе йә бер ноктага карап тора, йә, һичбер сәбәпсез-нисез, язмышыннан зарланырга тотына иде.

– Безнең башлар беткән инде, – дип шыңшыды ул юл буе. Позициягә килеп кергәч, беренче снаряд тетеп ташлады үзен. Үлемнән соң берәүгә дә хөкем юк югын, шулай да Матросовның үлемен куркаклар үлеме белән янәшә кую, батырның якты истәлеген мәсхәрә итү булыр иде. Куркак, үзенең мескен җанын саклап, үлемнән качам дигән минутта үлә. Матросов исә, ут чәчеп торган амбразурага күкрәге белән килеп капланганчы ук, үзенең үләчәген белгән. Ул үлемгә белә торып, аңлы рәвештә каршы барган. Матросовның бөек батырлыгы кайда һәм кайчан башланган? Үлем ачысы белән амбразурага ташланган минуттамы, йә булмаса элегрәк, патроннары, гранаталары бетеп, снаряд чокырында яткандамы? Бу сорауга ачык җавап табу Газинур өчен бик мөһим иде. Чөнки ул үлемен сизгән аюның да сөңгегә каршы килүен, кайбер кешеләрнең дә үлем ачысы белән шаккатыргыч эшләр эшләп ташлавын белә иде. «Юк, – дип уйлады Газинур, – болар берсе дә батырлык түгел әле. Батырлык ул – Матросовча, аңлы рәвештә эшләнергә, кешенең күңелендәге, тәрбиясендәге, тормышындагы иң-иң яхшы сыйфатларның сөземтәсе булырга тиеш. Кеше үзенең берничә минутта башкарыла торган батырлыгын бик озак, бөтен гомере буенча хәзерләргә тиеш. Шунда гына аның батырлыгы, Данко йөрәгенең яктысы шикелле, мәңге онытылмаслык нур чәчәчәк, шунда гына аның батырлыгы кыю, көчле рухларның җырларында азатлыкка, яктылыкка чакыручы җанлы үрнәк булып калачак».

Матросов снаряд чокырында башын күтәрми, тын гына ятса, бәлки, исән дә калган булыр иде. Ләкин әгәр дә Матросов снаряд чокырында тын гына ятып, иптәшләренең берәм-берәм үлүләренә тыныч кына карый алса, ул бөек Коммунистлар партиясе тәрбияләп үстергән герой да булмас иде. Аның күңелендә бөтен гомере буенча тупланган олы, саф мәхәббәт – Ватанны ярату, сугышчан дуслыкка турылыклы булу – нәкъ менә шушы хәлиткеч минутта ташкын булып атылып чыга да.

Әлбәттә, Матросов турында төрлечә сөйләргә мөмкин. Ләкин Газинур иртәгә булачак әңгәмәсендә нәкъ менә югарыдагыча сөйләргә теләр иде. Аныңча, Матросов батырлыгының мәгънәсе дә әнә шунда. Ә инде Матросовның Чернушки авылы янында дошман амбразурасын күкрәге белән каплау факты турында ишетмәгән, белмәгән сугышчыны көндез кулына шәм тотып эзләсәң дә таба алмассың. Юк, әгәр көче җитсә, булдыра алса, Газинур Матросов турында ишеткәч күңелендә туган якты, тирән уйларны сөйләргә теләр иде. Әмма күңелдәгене ничек итеп тел белән сөйләп бирергә? Бармы соң күңелдәге асыл тойгыларны, җәүһәрләрне җуиммыйча аңлатып бирә ала торган зур сүзләр? Бәлки, бардыр. Ләкин андый сүзләрне шагыйрьләр генә белсә белер. Ә Газинур шагыйрь түгел. Ул хәтта, әгәр Стариковны искә алмаганда, тере шагыйрьне күргәне дә юк. Менә җыр белән булса, бәлки...

Бер секундтан инде Газинурның колагында ниндидер гаҗәеп дәрәҗәдә таныш, шул ук вакытта моңарчы берәү дә җырламаган, берәү дә чыгармаган бер көй чыңлый башлый. Ул көй, бер яктан, Галәк бабай җырлаган борынгы бәетләрне хәтерләтә, ләкин бәетләрдәге кебек тирән моң, сагыш, күз яше булып түгел, ә кояш нуры кебек дәртле, якты, язгы тамчылардагы кебек яшәү матурлыгы булып яңгырый. Ул көйнең сүзләре дә юк әле. Анда бары тик язгы гөрләвекләр тавышы, җирнең кышкы йокыдан уянуы, яшәрүе, киң Иделнең салмак агымы, бодай кырларының дулкыннары, кешене бөек батырлыкларга ашкындыра торган зур сөюнең ялкыны гына бар. Күңелендә туып килгән шул гаҗәеп көйгә колак салган саен, Газинур үзе дә аның булуына, яңгыравына ышана башлый...

Шагыйрь күңелендә яңа җырның, композитор күңелендә яңа көйнең иң беренче тапкыр ничек туа башлавын Газинур белми иде. Бәлки, чын шагыйрьләр белән композиторларның күңелендә дә яңа җыр, яңа көй нәкъ менә шулай туа торгандыр...

Газинур вакыт үткәнен дә сизми. Көнчыгышта таңның беренче, әле оялчан яктысы сызылып китә. Нәкъ менә шул чакта Газинурның үткен күзләре дошман ягыннан үрмәләп килгән гитлерчылар төркемен күрә. Алар күп түгел. Ун-унбиш кеше. Разведка. Газинур пулеметына ябыша, берничә минут көтә.

Алгы сызык өстендә иртәнге тирән тынлык. Бәлки, дошман разведкасын бүтән күзәтчеләр дә күреп алганнардыр, алар да, Газинур кебек үк, бераз якынрак килсеннәр дип, көтә торганнардыр.

Газинур гашеткаларга басты. Пулемет, уянып киткәндәй, бер дерелдәп алды да, ярсый-ярсый тыкылдарга тотынды. Гитлерчылар ыгы-зыгы килә башлады. Аларның икесе яраланды булса кирәк, калганнары, аларны сөйрәп, бик тиз үз якларына, караңгыга чигенделәр.

Бу хәл алгы сызыктагы солдатлар өчен бик гади бер вакыйга булганлыктан, Газинурны да бик аз дулкынландырды. Ул, постын Стариковка тапшырып, йокларга китте. Төшендә танк өстендә бара, имеш. Танк ике яклап янган Берлин урамына бәреп керә, имеш. Газинур танк өстендә аягүрә баскан, җилфердәп торган Кызыл байракның сабыннан кысып тоткан. Бу байрак кайчандыр леспромхозда атаклы стахановчы Володя Бушуевка бирелгән байрак, имеш. Ул да булмый, Газинур Идел ярында, биек наратлар төбендә утыра, имеш, ниндидер бик матур җыр җырлый. Җыры да, сүзләре дә, наратлар шаулавы кебек, бик таныш, имеш. Чү, бу бит Саша турындагы, Александр Матросов турындагы җыр...

## 19

Соловеев сүзендә торды. Ул үзе, дивизия политбүлегенә барып, гармун алып кайтты. Газинур шатлыгыннан чак кына биеп җибәрмәде. Ул шунда ук минвзводка, миналар ташучы башкорт егете Буранбаев янына йөгерде.

– Буранбай, бие! – дип, ул ерактан ук кычкырды. – Иптәш Соловеев гармун алып кайткан!

Блиндаж ишеге төбендә батальон миномётының зур балыкка охшаган миналарын чүпрәк белән чистартып утырган кечкенә кара күзле, киң яңаклы Буранбаев урыныннан сикереп торды.

– Нәмә һөйләйһең һин, Газинур, – диде ул, аның гадәттә йокымсырабрак торган киң йөзе тулган ай кебек яктырып китте. – Алдамайһыңмы?

– Әгәр алдасам, җир йотсын, – диде Газинур, шаян көлеп. Аннары җитди итеп өстәде. – Алдамыйм, Буранбай.

Газинур Буранбаевның исемен дә белә иде. Әллә нинди борынгы, әйтергә авыр исем: Котлыкыям. Шуңа күрә ул аны үзенә ошаган «Буранбай» исеме белән генә йөртә иде. Буранбайның дулкынлануын, юка ированнәренең чак кына тартылып куюын күргәч, Газинурның шатлыгы тагын да арта төште.

– Ниндәй гармун? Тальянмы? Баянмы? Тизрәк уйнап карыйһы ие.

Гармунның тальян икәнен белгәч, Буранбайның түбәсе күккә тиде.

– Тальян гармун! – дип кычкырды ул, кечкенә кара күзләре сөенеченнән, ут яктысы йоккан кара мәрҗәннәр кебек, ялтырап китте. – Һай, рәхмәт Соловеев иптәшкә, һай, рәхмәт парторгка! Һугыш башыннан тикле уйнаганым юк ие. Бер тапкыр, фронттан күсенгәндә, тальян тавышын ишеткәс, полный ход менән барган эшелоннан һикереп төштем. Аннары көне буе эшелон артыннан кудым. Көскә наряд менән котылдым, трибуналга бирүләре дә мөмкин ие.

Газинур көлеп җибәрде, аннары дусларча якын күреп әйтте:

– Ярый, Буранбай, яшь чакта ниләр булмый, шулаймы? Бүген кич безнең землянкада татар, башкорт сугышчыларының беседасын уздырабыз. Сиңа әйттеләрме?

– Командир әйтте... Һине агитатор иткәндәр дип ишеттем. Дөресме шул һүз?

– Дөрес, – диде Газинур. – Синең яныңа килүем дә шуның өчен әле, Буранбай. Булыш син миңа, туган?!

Чын күңелдән әйтелгән бу үтенечне ишеткәч, Буранбай аптырый төшеп калды.

– Нимә менән һиңа булыша алам, Газинур?

– Гармуның белән, Буранбай туган, – диде Газинур. – Тальян гармуның белән. – Һәм бераз уйлап торгач, серен бүлешкән кебек, әкрен генә сорады: – Буранбай, син көйне тиз ота беләсеңме? Мин яңа көйгә җырласам, син минем арттан ук ота аласыңмы?

– Миналар шартлавы колагымды сукраклатып бетермәгән булһа, мин көйде иллә тиз отадыр инем. Нindәй көй һуң ул, Газинур?

– Менә тыңла. – Газинур борын эченнән көйләп тә күрсәтте.

– Тагын бер тапкыр көйлә әле, – диде Буранбай. Газинурның көйләвен бик зур игътибар белән, башын кыйшайта төшеп тыңлады. – Бераз бәет көенә охшаган икән, – диде аннары.

– Әйе, ләкин бераз гына шул. Менә кара. – Газинур көйнең яңа, бәет көеннән аерыла торган урыннарына басым ясап көйләп бирде. – Менә болары бәет көендә юк. Бәет ул көз көне ага торган караңгы чырайлы, кайгыхәсрәтле Идел шикелле. Ә минем көй язгы Иделдәй. Анда май ташкыннары... Син, дустым, аның менә шул якларын яхшырак чыгарырга тырыш. Йөрәккә үтеп керсен. Ләкин йөрәккә кереп, боз булып ятмасын, ә язгы тургай кебек сайрасын. Ярыймы? Булдырасыңмы?

Газинур, бөтен гәүдәсе белән омтылып, Буранбайның кечкенә кара күзләренә карады. Әгәр дә Буранбай риза булмаса, ул аның ризалыгын көч белән тартып алырга да әзер иде. Минометчы көлемсерәп куйды.

– Һин, Газинур, гыйшык утында янган кыздай, әйтмәс сүзде әйттерәһен, – диде. – Ярар, Газинур, тырышырмын. Һин миңа бик авыр эш йөкләдең, шулай да тырышырмын. – Ул бераз уйлап торды, кечкенә кара күзләрендә үз бәясен бик яхшы белә торган авыл гармунчыларына гына хас мутлык та бераз чагылды. – Әгәр насар уйнаһам, гармунсы Буранбай юк булһын. Тик гармуныңды миңа алданрак биреп тор, бармакларымды бераз йомшартаем.

...Кич белән пулеметчыларның иркен землянкасында сугышчылар җыела башлады. Иң алдан, билгеле, тальян гармунын култык астына кыстырып, Буранбай килеп җитте.

– Сыздыр әле, Буранбай, безнең туган як көйләрен! «Шөгер көе»н, «Нурия»не, – диде Газинур, Буранбай янына, сәкегә утырып.

Буранбай чокырланып торган киң ияген гармун өстенә куеп, башын кыңгыр сала төшеп, кыска, юан бармакларын гармун телләре өстеннән йөгертеп узды. Авыр солдат хезмәтеннән катып беткән бу кыска, юан бармаклар астыннан нинди генә көй чыга алыр икән дип гаҗәпләнеп утырган Газинур, гармунның беренче чыңнарын ишеткәч үк, аның кем кулында икәнен бик яхшы сизде. Менә Буранбай, кискен бер аккорд белән, «Сакмар су»ны сыздырып җибәрде, аның юан бармаклары астыннан йөрәкнең иң нечкә кылларын тибрәтә торган моңлы тавышлар агыла башлады. Газинурның йөрәге тибүдән туктагандай булды, ул көч-хәл белән тын алды.

Чакырылган сугышчылар барысы да үз вакытында килерләрме дип Газинур бик нык борчылган иде. Чөнки солдат вакыты бик кысынкы, ул, авылдагыча, сызылып таңнар атканчы утыра алмый. Ләкин Газинурның борчылуы бушка булган икән. Әллә нишләде бу гармун. Аның тавышы землянкаларга, блиндажларга, ут позицияләренә барып керде, туган көйләрен ишеткән татар, башкорт сугышчылары, ашый торган ашларын ташлап, эшли торган эшләрен тиз-тиз төгәлләп, баллы урынга җыела торган умарта кортларыдай, гармун тавышы яңгыраган урынга – пулеметчылар землянкасына йөгерделәр. Землянка шыгрым тулды. Алдан килгән урын өчен дигәндәй, алдан килүчеләр плащ-палаткалар җәелгән сәкегә менеп, аякларын бөкләп утырдылар, кичегә төшкәннәре стена

буена, идәнгә чүгәләделәр. Алар арасында казах, үзбәк, чуваш егетләре дә бар иде.

Буранбай берсен берсенә ялгап, «Сакмар»ны, үзенең иң яраткан җыры «Буранбай»ны, «Шөгер»не, «Зөлхиҗә»не, «Нурия»не, «Галиябану»ны, «Ямьле Агыйдел буйлары»н сыздырды. Сугышчылар арасында матур тавышлы, җырга оста егетләр аз түгел иде. Алар шунда ук гармунга кушылып, кайда булса болынлыкта яки сабан туенда, кулларын бер-берсенең иңбашларына салып җырлаучы авыл егетләре кебек, җырлый да башладылар.

Алма булса, шундый булсын,
Берсен бишкә бүләрлек.
Дустың булса, шундый булсын,
Үзең өчен үләрлек.

Ишектән яңадан-яңа сугышчылар керә торды. Алар арасында кызыксынып килгән берничә татар офицеры да бар иде. Аларга сәкедә урын бирделәр. Офицерларны күргәч, Газинур шактый каушады. Солдатлар аның үз тиңнәре – ничек сөйләсәң дә, гаеп итмәсләр, ә офицерлар... Алар нигә килгәннәр? Билгеле инде, алар рус телен начар белүчеләр рәтенә керми. Аларны монда бары тик гармун тавышы гына китергән. Старшина Зәбировны да монда шул ук гармун тарткан булса кирәк, югыйсә ул русчаны су кебек эчә. Газинур аңа карап алды. Зәбиров, башын кагып, елмаеп куйды. Бу юлы аның чырае ул чактагы кебек караңгы түгел. Кулларын чалбар кесәсенә тыккан килеш, ишек яңагына сөялгән дә көлемсерәп тора. Бөтен күкрәге орден-медальләр белән тулы – генерал!

Җыр тынган арада, солдатларның берсе, старшинага мөрәҗәгать итеп:

– Ә разведчик нишләп авызына йөзек яшереп тора. Йә, әйттереп бир әле берне, иптәш разведчик, күрсәт егетлегеңне! – диде.

Зәбиров кыстата торганнардан түгел иде. Шулай аягүрә баскан килеш, гармунчыга кушылып, җырлый да башлады:

Батыр егет килә ат өстендә,
Аты уйнаклый авызын тартканда...

– Һай, рәхмәт, разведчик! Егет икәнсең. Мең яшә, – диде баягы солдат.

Ишектән Соловеев килеп керде, алга үтеп, офицерлар белән кул биреп күреште дә беррәттән утырды. Буранбай уйнаудан туктады.

– О-о, бөтен бер батальон җыелган икән биредә! – диде парторг, сугышчыларга күз йөртеп. – Йә, ничек, күңелегез булдымы?

Ул тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайды, барысына да ничектер күңелле булып китте.

– Булды, булды, – диделәр сугышчылар, шатланышып.

– Гармун өчен, иптәш парторг, сезгә бик зур рәхмәт, – диде Буранбай, урыныннан торып. – Май бәйрәме шикелле булды әле бу.

Соловеев Газинур белән пышылдашып нидер сөйләшеп алды да урыныннан торды.

– Башлыйк, иптәшләр, – диде ул, партбюро карары турында кыска гына сөйләп, русча начар белүче татар, башкорт сугышчылары арасында эшләү өчен ефрейтор Газинур Гафиятуллинның агитатор итеп билгеләнгәнлеген әйтте. – Ә хәзер, – диде ул, чыгышын тәмамлап, – сүзне агитатор иптәш Гафиятуллинга бирик. Ул сезгә ана телегездә Кызыл Армиянең данлы сугышчысы Александр Матросов турында сөйләячәк.

Газинур үз янында утырган Буранбайга карап алды, тартынып кына тамагын кырды. Бу кадәр күп халык алдында аның беркайчан да сөйләгәне юк иде әле.

– Иптәшләр, – диде ул татарча, акыллы йөзе кызарып китте, – мин сезгә рус халкының батыр улы Александр Матросов турында сөйләмәкче булам... Сез инде, иптәшләр, аның турында күп ишеткәнсез, беләсез. Шуңа күрә мин күп сөйләмим, әгәр рөхсәт итсәгез, мин аның турында бераз җырлап бирер идем...

Берәүне дә сискәндермичә, берәүне дә борылып карарга мәҗбүр итмичә, таң сызылган кебек әкрен генә сызылып, Буранбайның тальяны чыңлый башлады. Аңа, таң атуына кояш нурлары килеп тоташкан кебек, бик табигый булып, Газинурның күкрәктән чыккан моңлы тавышы кушылды:

Тарих мең дә тугыз йөз дә
Кырык өченче ел эчендә...

Бик күпләргә кечкенәдән үк таныш булган, йөрәкләренә мәңге онытылмаслык булып сеңеп калган бу борынгы таныш көй, таныш сүзләрнең беренче юллары тыңлаучыларның колакларын торгызды. Бу көйнең башында ук нindидер үзенә бертөрле яңалык бар иде. Ул көй бик таныш та, таныш түгел дә шикелле. Озак еллар читтә йөреп, туган йортына беренче тапкыр аяк баскан, инде буйга җитеп килгән сөекле баласын таный алмыйча аптырап торган атаның гаҗәпләнүе төсле иде бу. Сугышчылар бер-берләренә карашып алдылар.

Александр Матросов һәлак булды
Чернушки авылы читендә, –

дип, Газинур халык арасында туган, халыкның тирән моңын саф килеш саклый белгән җырчылар шикелле, иреннәрен кәгазь сыйдырырлык кына итеп ачып, җырын дәвам итте. Ләкин авыр, кайгылы хәбәрне белдергән бу соңгы ике юлда, элекке бәетләрдәгечә күз яше түгел, үлемгә буйсыну түгел, ә үлемне җиңәчәк дәртле көч тә яңгырады.

Соловеев татар телен төшенмәгәнлектән, Газинурның кинәт җырга күчүенә башта беркадәр гаҗәпләнеп торды. Бәлки, үзенә бертөрле кереш кенәдер. Ләкин җыр һаман дәвам итә, бу таныш булмаган җыр, аның Буранбай гармуны телләре астыннан чыккан гаҗәеп гүзәл агылышлары тора-бара Соловеевка да тәэсир итә, аны да үз эченә тартып ала башлады. Ул тонык кына яктылык сирпелгән солдат йөзләренең җитдилеген, күзләренең ялтырап еракка карауларын, маңгайларындагы текә сызыкларны, разведчик Зәбировның, уң кулын кобурасына салып, алга омтылып торуын күреп алды. Димәк, Матросов турындагы беседа күптән инде башланган.

Газинур кәгазьгә карамыйча җырлады. Аның алдан уйланган, ятлаган өч-дүрт строфасы гына бар иде. Ә калган куплетлары җыр дәвамында үзеннән-үзе туа бардылар.

Атакага барган чакта
Ут чәчри күземнән,
Туган илен саклаганда,
Солдат курыкмый үлемнән.
Куркак үлә, батыр кала,
Батырларга үлем юк...

Бу шундый бер җыр иде, мондый җыр бары тик бик якын, бик кадерле кеше турында гына туа, бер генә тапкыр җырлана. Менә Буранбайның гармуны чыңлый, Газинурның күңелендә яшен тизлеге белән яңадан-яңа куплетлар туа, аннары теленә күчә, ләкин әгәр дә Газинурны бүлдереп, аңа яңабаштан җырлап күрсәт, дисәләр, ул, һичшиксез, моны кабатлый алмас иде. Бу Газинурның Матросов турындагы йөрәк җыры, күңел хисләре иде.

Ничәмә-ничә гасырлар яшәгән, үзенең азатлыгы, бәйсезлеге өчен явыз ханнарга, патшаларга, канечкеч байларга, алпавытларга каршы көрәшкән халык «Ир егет үзе өчен туа, ил өчен үлә» дигән. «Ат – аенда, ир елында сыналыр» дигән ул аннары, һәм, үзенең газиз улларының батырлыгына куанып, «Батыр егет – яу күрке» дип аңлаткан. Александр Матросов менә шундый булган. Ул туган иле өчен чәчәктәй яшь гомерен кызганмаган. Ул Ватанга гомерен биргән, ләкин ул үлмәгән. Ул безнең белән, без-

нең арада, безнең беренче ротада бара. Бер көн килер, ил безгә әйтер: егетләр, дияр, оборонада күп яттыгыз, дошманны алга җибәрмәдегез, рәхмәт, әмма җиңү өчен алга барырга кирәк. Башкалар күптән инде алга бара, инде сез дә кузгалыгыз, дияр, һәр карышы изге булып саналган туган туфрагыбызны дошманнан чистартыгыз... Һәм кузгалырбыз без, дуслар, ташкындай ыргылырбыз без, дуслар, язгы Иделдәй! Фашизмның тамырын корытмыйча, кулыбыздан коралыбызны ташламабыз...

Менә шулай җырлады Газинур. Аның җыры беткәч, һәммәсе бер минут чамасы тын тордылар. Кешеләр әле җырның көчле тәэсиреннән арынып җитмәгәннәр иде.

Бераздан олырак яшьләрдәге, кыска кара мыеклы бер сугышчы, урыныннан кузгала төшеп:

– Яхшы сүзне мең кат тыңласаң да ялыктырмый, рәхмәт сиңа, иптәш агитатор, рәхмәт яхшы сүзеңә, – диде. Аның шулай әйтүе булды, бөтен землянка эче көчле алкышлар белән тулды.

Шул вакыйгадан соң ике-өч көн үткәч, һич тә көтмәгәндә, Газинур берүзе землянкада өенә хат язып утырган чагында, Сәлим йөгереп килеп керде. Газинур аның белән полклар күченгән чагында берничә тапкыр очрашкан иде. Газинур аны, колачын җәеп, сөенеп каршы алды. Абыйсы белән Газзәннән аерылганнан соң, Сәлим Газинур өчен бердәнбер «Красногвардеец» егете булып калды.

– Нинди җилләр ташлады, Сәлим? Исән-сау гына йөрисеңме? Колхоздан хатлар аласыңмы? Ни язалар? Әйдә утыр. Менә бирегә.

Бу кадәр ачык чырай белән каршы алудан шактый уңайсызланган Сәлим сәке кырыена гына утырды, землянка эченә күз йөртеп чыкты. Аның карашы стенага ябыштырылган плакатка тукталды. Бу – хәрби ант иде. Сәлим, эченә салкын йөгергән шикелле, кинәт сискәнеп китте. Газинур моны сизеп алды, Сәлимгә якынрак елышып, туганнарча итеп:

– Әллә сәламәтлек шәп түгелме, Сәлим? – дип сорады.

Сәлим шинель каптырмасын ычкындырды. Ул, күрәсең, берничә көн кырынмаган, йөзе ямьсез, күзләрендә – курку, керләнеп беткән сул кулы әкрен генә калтырый. Газинур, электән дә аның сәламәтлеккә туймаганлыгын белгәнгә, хәзер хәтта кызганып ук куйды.

– Эш сәламәтлектә түгел, Газинур абый, – диде Сәлим, гомерендә беренче тапкыр Газинурга «абый» дип дәшеп. – Ничек дип башларга да аптырыйм... Әйтергә телем

әйләнми. Сине безнең агай-эне арасында агитатор итеп билгеләгәннәр дип ишетеп килдем әле...

Газинур үзенең полкка катнашы булмыйча, батальон күләмендә генә агитатор икәнлеген әйтергә теләде, ләкин Сәлимнең авыр сулавы, күзләренең, коты алынган кешенеке кебек, як-якка каравы аны сагаерга мәҗбүр итте.

– Көч-хәл белән таптым үзеңне. Командир бер генә сәгатькә җибәрде. – Кинәт Сәлим Газинурның кулына ябышты, үтә ялварган тавыш белән кычкырып җибәрде: – Газинур абый, коткар мине! Башымны харап итәләр... Ике банка консерв өчен... Зинһар, полк командиры белән сөйләш. Трибуналга бирмәсен... Һичбер гаебем юк...

Газинурның көләч йөзе караңгыланды, ул, чирканган сыман, Сәлимнең кулын этәрде, коры тавыш белән:

– Яхшылап сөйлә! – диде.

– Төнлә, складтан продукт алып кайтканда булды... Юл бик начар иде. Төшеп калган, ахрысы. Командир ышанмый...

Калтыранган нечкә тавыш белән әйтелгән бу сүзләрне тыңлап утыруы Газинурга бик авыр иде. «Әгәр маңгаеңа берне кундырсам, башкачарак сөйләр иде сөйләвен, ләкин кулны пычратасы килми», – дип уйлап алды ул.

– Нибары шул гынамы? Яшермисеңме?

– Икмәктер, кояштыр, Газинур абый... – Ул яңадан Газинурның кулыннан тотты, инәлеп ялвара башлады. – Син, Газинур абый, агитатор кеше, партияле, синең сүзгә колак салырлар... Зинһар, башымны харап иттермә. Колхоздагы эшем турында да әйт. Тырышып эшләдем бит мин анда...

Газинур Сәлимнең барысын да ачып салмавын яхшы аңлый иде. Ләкин ни өчен Сәлим турыдан-туры командирларга, политрукларга сөйләнә торган сүзләрне Газинурга килеп сөйли? Моңа аның нинди нигезе бар? Нәрсәгә исәп тота?

Сәлим, Газинурның чырае караңгыланганнан-караңгылана баруын күреп, актыккы өметен юкка чыгармас өчен, тагын да кызганычрак тавыш белән инәлә башлады:

– Газинур абый, без бит бер авылда туып, бер чишмәнең суын эчеп үскән кешеләр. Бер колхоз кешеләре... Зинһар, дип әйтәм... Әти-әни хакы өчен...

Газинур урыныннан торды. Аның йөзе җитди, кырыс иде. Ул кулы белән стенадагы хәрби антка күрсәтте.

– Укыганың бармы?

– Укыдым, – диде Сәлим, урыныннан торып.

– Кул да куйдыңмы?

– Куйдым.

– Тагын бер тапкыр укы. Менә бу җирен.

Сәлим, каршылык күрсәтергә батырчылык итмичә, плакат янына килде.

– Укы!

– «Әгәр явыз ният белән бу тантаналы антымны бозсам...»

Сәлим тотлыгып калды. Йөзеннән елгалап тир ага башлады.

– Укы, укы, – диде Газинур.

– «...мин Совет законының каты җәзасына...»

– Йә, йә, ахыргача укы.

– «...бөтен хезмәт ияләренең нәфрәтенә һәм җирәнүенә...»

Сәлим, башын иеп, борынын лышкылдата башлады. Газинур кулларын йомарлап идән буйлап бер әйләнде дә Сәлим каршында туктады. Аның күңелендә шулхәтле ачы нәфрәт ташый иде, ул, үз-үзен көч-хәл белән кулга алып:

– Җебегән тавыкка охшыйсың бит, Сәлим, – диде. – Әгәр бу эшең турында колхозга язып җибәрсәләр...

Сәлим куркынып артка чигенде, кулын күкрәгенә куйды. Хәзер ул Газинурга өмет белән түгел, коты очып карый, Газинурның берсеннән-берсе аяусызрак сүзләрен ишеткән саен, арты белән ишеккә таба чигенә иде.

– Сәлим, мин синең сүзләреңә ышанмыйм. Син дөресен сөйләмисең. Командирларыңны да алдарга маташасың. Хәтерлисеңме, Галәк бабай безгә ничек сөйлидер иде. «Туры сөйләгән котылыр, кыңгыр сөйләгән тотылыр». Оныттыңмы әллә? Онытма. Куян йөрәк булма, ир бул! Кайт та командирыңа барысын да ачыктан-ачык сөйләп бир. Бернәрсәне дә яшермә. Гаебең өчен гадел җәза сора. Ә мин... солдат хакына кул сузган җинаятьчене яклап командирга сүз әйтә алмыйм. Мин синең өчен хурланам, Сәлим!

Сәлим акны-караны күрмичә чыгып киткәннән соң, Газинур землянка эчендә бик озак арлы-бирле йөренде. Яза башлаган хатын дәвам иттерергә кулы күтәрелмәде. «Безнең «Красногвардеец»та шундый җан көеге үсәр дип кем ышаныр. Тавык Мортый аңлашыла. Анысы совет властеның кан дошманы. Бөтен нәсел-нәсәпләре кәкре куллы иде. Ә Сәлим... Совет мәктәбендә укыган, колхозда үскән егет...» Газинур беркайчан да аңа зур өметләр багламады, әмма бу кадәр түбәнлеккә төшәр дип тә уйламаган иде. Ләкин хәзер, Сәлимнең барлык эшләрен бер җепкә тезеп, леспромхоздагы зур йозаклы сандыгын күз

алдына китергәч, Сәлимнең упкын янына килеп чыгуына артык гаҗәпләнмәде, үз-үзен тынычландыру өчен, «Куе суның акканы яхшы» дип куйды.

Ләкин җан тынычлыгы аңа кайтмады. Иптәшләре ефрейторның кәефе кырылуын бик тиз күреп алдылар. Эченә сер җыярга яратмаганга, ул шунда ук бу турыда сөйләп тә бирде. Ул моны «Хәрби ант» турында беседа дип атамады, ләкин бу Газинур үткәргән беседаларның иң әйбәтләреннән берсе иде.

## 20

Менә ничәнче тәүлек инде, кайдадыр көньякта, бер генә минутка да туктамыйча, көн-төн туплар гөрселди. Бу гөрселдәү, тау яңгырашы кебек, көчәйгәннән-көчәя бара, әйтерсең бөтен нәрсәне үз эченә йотып алырга тели. Көндезләрен күктә, урман өстендә, куе төтен болыты айкала, төннәрендә куе кызыл шәүләләр уйный. Аларга хәтта еракта караву да куркыныч, гүя күк йөзенә ут капкан, ул коточкыч рәвештә үкереп яна.

Анда бик каты һөҗүм сугышлары бара. Бары тик озак вакытка исәпләнеп эшләнгән куәтле оборона полосасын өзгән чагында гына, шундый көчле канонада яңгырап тора. Тәҗрибәле солдатлар моны бик яхшы беләләр. Оборона полосасын өзгәннән соң, дошманны куып барганда, андый көчле атышлар булмый инде.

Окопларда, траншеяларда, ут позицияләрендә – маскировкаланган миномётлар, туплар янында торучы солдатлар еракта килгән шушы көчле гөрселдәүгә колак салып, озак-озак тыңлап торалар да үзара сөйләшеп алалар:

– Шәп дөмбәслиләр!
– Снарядларны санап тормыйлар.
– Кайда икән?
– Великие Луки тирәсендә.
– Невель янында түгелме икән?
– Калинин фронты һөҗүм итә.
– Кузгалдылар бит.
– Болай булса, егетләр, без дә озакламабыз.

Бу сүзләрне олырак яшьләрдәге бер солдат әйтте. Ул, беренче язгы күкрәүне ишеткәннән соң күңеле кырларга ашкынган колхозчы кебек, соры солдат бүреген артка этеп, мыекларын сыпырып алды, өстенә маскировка өчен ятьмә корылган авыр тубына күз төшерде.

Пулеметчылар землянкасы янында дежурдан бушаган бер төркем сугышчылар җыелган.

– Безнең агитатор кайда икән, сводканы тыңлыйсы иде бит, – диде түземсезрәк солдатларның берсе. Ул шулай ук ерактан ишетелгән гөрселдәүләргә колак сала, тавыш килгән якка таба башы белән изәп, – шәп сукалыйлар бит! – дип раслап куя.

Бу канонада немецларныкы булу мөмкинлеге турында инде берәү дә уйламый. Дошманның үз өстенлеге белән масайган чаклары күптән үтте инде. Хәзер бәйрәм безнең урамда. Моны һәр солдат белә, күрә, ишетә иде.

Батальон штабыннан сузылган аралашу юлы буйлап, бик ашыгып, Газинур кайтып килә. Ул башка сугышчылардан үзенең бер ягы белән дә аерылмый. Аның башында шундый ук гади солдат бүреге, өстендә бер чабуы көя төшкән шинель, билендә, брезент капчыкта гранаталар, таушалмасын өчен эченә резина куйган погоннарында тар гына берәр кызыл сызык – ефрейтор билгесе. Ләкин шул ук вакытта ул гади солдат та түгел. Кайда гына булмасын – пехотачылар янындамы, минометчылар, пулеметчылар, пэтээрчылар янындамы – һәр җирдә аңа иптәш агитатор дип мөрәҗәгать итәләр, аңардан соңгы хәбәрләрне сорыйлар, аның белән киңәшәләр, кайгы-шатлыкларын уртаклашалар, илдән килгән хатларны да аңа укыйлар. Газинур бары тик үз расчетында һәм русча начар белгән татар-башкорт сугышчылары арасында эшләү өчен генә агитатор итеп билгеләнгән булуга карамастан, аны ничектер батальон күләмендәге барлык подразделениеләрдә дә агитатор дип исәплиләр иде. Газинур үзе дә агитатор булуы белән эченнән бик нык горурлана, ләкин кайчакта аптырап та калгалый: тукта, бу хөрмәтле, олы исем белән аңа дәшәләрме соң? Ул шундый зур исемне күтәрү дәрәҗәсенә кайчан, ничек ирешә соң? Кем аны шулай үстерде?

– Иптәш агитатор, нинди яңа хәбәрләр? – дип, бик ашыгып барган Газинурны бер пехотачы туктатты.

– Яхшы хәбәрләр, иптәш, яхшы хәбәрләр! – диде ул көләч йөз белән. Еракта һаман да көчле канонада ишетелә. Газинур йөзен тавыш килгән якка бора, күктә уйнаган ялкыннарга карый. – Безнең күршеләр һөҗүмгә күчкәннәр!

Газинур пулеметчылар землянкасына йөгереп керде. Аны күптән көтеп торган сугышчылар шунда ук сырып алдылар. Ул өстәл янына, яктыга узды, чишенеп тә тормыйча, аягүрә баскан килеш, Верховный Башкомандующийның приказын укый башлады:

– «Армия генералы Еременкога... Армия генералы Соколовскийга... Калинин фронты гаскәрләре, дүрт

көнлек бик каты сугышлардан соң, дошманның көчле ныгытылган полосасын өзделәр...»

Газинурдан күзләрен алмыйча тыңлап утырган пулеметчылар шатланып кычкырыша башладылар. Газинур тавыш басылганны көтте дә укуын дәвам итте:

– «...Һәм Смоленскига бару юлында немецларның мөһим терәк пункты – Духовщина шәһәрен штурм белән алдылар».

Кемдер өстәмә шәм яндырды. Землянка яктырып китте, Газинур тагын да күтәренкерәк тавыш белән укырга керешге:

– «Көнбатыш фронты гаскәрләре, каты сугышлардан соң, дошманның каршылыгын сындырдылар һәм Смоленск янында немец оборонасының мөһим терәк пункты – Ярцево шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар...»

Газинур укып бетергәннән соң, солдатлар бик озак, дулкынланып, сөйләшеп утырдылар. Арада элек Духовщина янында сугышкан кешеләр дә бар булып чыкты. Алар истәлекләрен уртаклаша башладылар, ә сержант Стариков, иптәшләренә карап:

– Хәзер гитлерчыларның безнең участокта ни өчен һөҗүм итеп маташулары да аңлашыла, – диде. – Дөресрәге, алар монда демонстрация генә ясаганнар.

– Әйе, – диде Газинур, – кәкре атып, туры тидермәкче, чыпчык биреп, каз алмакчы булганнар. Ләкин хәзер заманалар башка. Без хәзер дошманның бияләй эчендә бармак кыймылдатуын да беләбез. Шулаймы, иптәшләр, ә?

Газинурга постка барырга вакыт иде. Ул иптәшләре белән тагын бераз сөйләшеп утырды да пулемет янына чыгып китте. Ике сәгать буенча ул запас ут позициясеннән дошман ягын күзәтте. Алгы сызык бүген аеруча тыныч иде. Немецлар тыннарын да чыгармыйча утыралар, хәтта ракеталары да теләр-теләмәс кенә оча. Кинәт Газинур ерактагы гөрселдәүләрнең тынганлыгына игътибар итте. Тукта, кайчан булды соң бу? Әллә Газинурның колаклары чукракландымы? Ул хәтта бармагы белән колак эчләрен дә казып алды. Юк, колакларда һичбер гаеп юк. Күккә карады – кызыл шәүләләр сүнгән, анда йолдызлар җемелди, яңа ай калыккан.

– Димәк, алга баралар инде, – диде Газинур, дошманны куып баручы солдатларны күз алдына китереп. Язгы җил искәндәге кебек, йөрәге җилкенеп китте. Үзенең дә тизрәк кузгаласы килде. Ул күптән инде үзен һәм расчетын һөҗүм сугышларына әзерли иде. Хәзер инде күп көтәсе дә калмады. Бәлки, бер атнадан, күп булса, атна ярымнан биредә дә кайнар көннәр башланыр.

Алмаш килде, Газинур ял итәргә китте.

– Егетләр, яңа ай чалкан ятып туган, көннәр аязга китәчәк, – диде ул, землянкага кергәч. Аның тавышы көр яңгырады. – Бу безнең өчен бик кулай буласы. Көннәр коры чакта дошманны кууы күңеллерәк.

– Башта аны өненнән чыгарасы бар, – диде кемдер.

Газинур, шинелен сала-сала, җавап бирде:

– Монысы «сугыш алласының» эте инде. Безнең артиллерия хәзер теләсә нинди аюны да өненнән чыгарырга сәләтле. Ишеттегез бит, дүрт көн буенча ничек җырлады ул. Тәгаен, бик күп гитлерчылар чалбарларын буяганнардыр...

Газинур мич янына килеп чүгәләде, мичкә утын өстәде, кулларын җылытты, аннары беркемгә дә мөрәҗәгать итмичә сөйли башлады.

– Бүген төн бик матур. Яратам мин айлы-йолдызлы төннәрне, күк йөзе энҗе белән чиккән кара хәтфә кәләпүшкә охшый.

Газинур ашыкмый гына тәмәке төрә башлады. Почмактан кемнеңдер басынкы көлүе ишетелде.

– Иптәш ефрейтор, сез элек метеорология бюросында эшләмәдегезме? Һавалар торышын һәрвакыт алдан әйтеп бирә беләсез.

– Юк, иптәш Данилов, – диде Газинур, аңа таба борылып, – һавалар бюросы белән алыш-бирешем булмады. Хәтта аның барлыгын да белмидер идем. Әмма картлардан күп нәрсәләр ишеттем. «Красногвардеец»та чакта шулай көне буе кырда яки ындырда эшлибез дә, караңгы төшкәч, йокларга таралышыр алдыннан, фермалар алдына чыгып утырабыз. Безнең колхозда ферма алды – иң күңелле урын. Шунда инде ат караучы Сабирҗан бабаймы яки Галәк бабаймы, яңа туган нечкә ай урагына карап ала да: «Оланнар, көннәр аязга китәр, карагыз, ай, мунча ләүкәсендәге шикелле, чалкан яткан», – ди иде. Шуннан барыбыз да беравык тын гына утырабыз, тәмәке көйрәтәбез. Ә кырлардан үзәнлеккә ургылып-ургылып арыш исе килә – безнең кырлар калкулыкта тора, ә колхозыбыз – үзәнлектә. – Газинур бүтәннәрнең дә үзен тыңлаганын сизеп ала, озын сәкедән башларын күтәргән сугышчыларның барысына да мөрәҗәгать итеп сөйли башлый: – Иснәгәнегез бармы сезнең, егетләр, өлгереп килгән игеннәрнең хуш исен? Хәзер мин, йөгереп барып, шул арыш исен иснәр өчен, яшел болында тәгәрәп-тәгәрәп бер аунар өчен ярты гомеремне бирер идем...

Өстәл янында, «молния» яктысында, строевой записка язып утырган рота старшинасы Михно, башын күтәреп, күгәрчен гөрелдәве кебек йомшак тавыш белән:

– Колхозыгызны һәрвакыт мактап сөйлисең, ефрейтор, сорарга рөхсәт ит, зурмы соң колхозыгыз? – диде.

Бу турыда Газинур бик күп сөйләгәнлектән, солдатлар «Красногвардеец» хәлләрен бик яхшы беләләр иде. Хәтта үз колхозлары турында сөйләгәндә, безнең үз «Красногвардеец»ыбыз дип, илдән сәлам хатлар килсә, «Красногвардеец»тан күңелле хәбәр алдым әле... дип сөйли торганнар иде. Тик старшина Михно гына «Красногвардеец»ны танырга теләми, анда масштаб юк, анда социалистик агрегатларга мәйдан тар дигән була. Әлбәттә, зур колхоз – әйбәт нәрсә ул. Халык гомер-гомердән зурлыкны, киңлекне ярата. Ләкин «Красногвардеец»ка да кырык дүрт хуҗалык булып кына яшәргә димәгән ич.

Газинур старшина Михноның сугышка кадәр Украинада шактый зур колхозның председателе булып эшләгәнлеген, кечкенә колхозларга кимсетеп каравын белә, шуңа күрә туры җавап бирмәскә тырыша. Ләкин старшина, «Красногвардеец»ның хуҗалыгын үз ротасының хуҗалыгын белгән кебек яхшы белсә дә, аның ничә гектар җире барлыгын Газинурның үзеннән әйттертә, Газинур «Красногвардеец»ның 800 гектар җире бар дигәч, үтә гаҗәпләнгән булып, кашларын күтәрә.

– Бөтен чәчү әйләнешенәме? – дип сорый ул, чак кына көлемсерәп, аннары сөйләп китә: – Авыз суларыңны корытып нәрсәсен мактыйсың соң син аның? Исеменме? Исеме, әлбәттә, яхшы. «Красногвардеец» – теләсә нинди колхозга да ярый торган исем. Менә мин үз колхозымны алып әйтәм: безнең алты мең гектар җиребез бар иде. Бөтен эшне машина белән күтәрә идек. Ә сигез йөзне басуларга бүлгәч, нәрсә кала? Кульъяулыгы! – Старшина, кесәсеннән кульъяулыгы чыгарып, моның әһәмияте юк дигәндәй, селкеп тә алды. – Комбайнга түгел, тракторга да әйләнер урын юк ич анда.

Михноның бу сүзләрен Газинур әллә ничә тапкыр ишеткән булса да, алар аны үртәмиләр иде. Ул көлеп җавап бирде:

– Алып батыр да, иптәш старшина, анадан туган чагында бәләкәй генә булган. Ә тора-бара чабатасына җыелган туфракны селеккәндә дә таулар өелгән. Менә фашизмның тамырын корытыйк, аннары колхозларны үстерү эшенә җиң сызганып керешербез. Менә күр дә тор, сезнең колхозны социалистик ярышка чакырырбыз, иптәш старшина.

– Котелогың буш түгел синең, ефрейтор. – Старшина башын артка ташлап көлеп җибәрде. – Юкка гына агитатор итеп билгеләмәгәннәр үзеңне. Кичә өченче рота

старшинасы Сибгатуллинны күрдем, син аларга Матросов турында җыр белән доклад сөйләгәнсең икән. Хәйран калып мактый.

Шул сүзләрдән соң, старшина, өстәл яныннан торып, солдатларның берсе каршына килде дә аның күтәргән шинель якасын үз кулы белән төшереп куйды.

– Актыккы мәртәбә кисәтәм, иптәш сугышчы. Форманы бозасы булма! Кара аны!

Старшина чыгып китте. Землянкада беркадәр вакытка күңелсез тынлык урнашып калды. Газинур: «Иртәгә сугышчының тышкы кыяфәте турында беседа үткәрергә кирәк», – дип уйлап алды, аннары, аякларын сәкедән салындырган килеш, чалкан ятты да әкрен генә җырлап җибәрде.

Җыр Газинурның күз алдына Миңнурыйны китереп бастырды. «Кыендыр сезгә, күз нурларым, анда, кыендыр. Канатым гына юк, очып барып булышыр идем... Их, тизрәк кайтасы иде туган-үскән җирләргә, эшлисе иде, Миңнурый, киң кырларда җиңнәрне сызганып, якаларны чишеп! Колхоз бик күп атларын армиягә биргән. Ләкин Батыр бар. Үтәсе иде, Миңнурый, шул алмачуар чаптарга утырып Бөгелмә юлларыннан! Күрәсе иде кырларда алтын бодайлар чайкалуын, ишетәсе иде жнейкалар, комбайннар тавышын!..»

– Иптәш ефрейтор, күңеллерәкне җырлагыз әле, – диде бер солдат. – Сагыш ансыз да безнең йөрәкләрдә җитәрлек.

– Күңеллесен дә җырлыйбыз, иптәш, – диде Газинур һәм шушы араларда гына чыккан яңа җырны башлады, ләкин үзе һаман да Миңнурые турында уйлады.

По дороге пыльной, что легла под уклон,
Шел широкой рысью наш лихой эскадрон.

Землянкадагы барлык солдатлар хор белән күтәреп алдылар:

Эх! Видим, у дороги девка краса,
Чудо коса, море глаза.
Да! Улыбнулась улыбкой простой,
Нам помахала рукой.

Ротада яхшы җырчы булса – бәхет ул, җыр солдатның авыр тормышын җиңеләйтә, күңелен күтәрә, дәртләндерә, моңландыра. Шуңа күрә сугышчыларның җырчыга мәхәббәтләре дә аерата зур була: сугышчан иптәшләре Газинурны бетмәс-төкәнмәс энергиясе, шат күңеллелеге өчен генә түгел, матур җырлары өчен дә яраталар иде. Ул, күпме теләсәләр, шулхәтле җырларга әзер иде.

Иртән Газинурны рота командиры янына чакырдылар. Ул шунда ук барып та җитте. Гвардия капитаны зур бакыр чәйнектән чәй эчеп утыра иде.

– Йә, эшләр ничек, иптәш ефрейтор? – дип сорады ул.

– Алып мактарлык, салып таптарлык түгел, иптәш гвардия капитаны, – дип җавап бирде Газинур.

– Шулаймы?.. – Ермилов, иреннәрен пешерә-пешерә, калай кружкадан берничә йотым чәй эчте дә зәңгәрсу күзләре белән ефрейторга карап алды. Сугышчылар, бербер җитди нәрсә булса, аның шулай озаграк карап тору гадәтен белеп алганнар иде инде. Газинур сагайды.

– Менә нәрсә, ефрейтор, юлга әзерлән. Укырга барасың, – диде ул кискен итеп. Газинурның аңламый торуын күргәч, шундый ук кырыс тавыш белән өстәде: – Полк мәктәбенә, кече командирлыкка укырга.

– Ә кем сугышачак? – дип, үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде Газинур. – Безнең расчет болай да тулы түгел...

– Приказны тикшереп тормыйлар, иптәш Гафиятуллин, – дип бүлдерде гвардия капитаны.

Газинур тирән сулый-сулый капитанга бераз карап торды да, ярсуын басып:

– Есть! – диде. – Китәргә рөхсәт итегез.

– Барыгыз.

Гвардия капитаны корырак, хискә бирелүне яратмый торган кеше иде. Аннары ул солдатны укырга җибәрү – сугышчан бурычны үтәргә җибәрү белән бер дип саный иде. Ә сугышчан бурычны үтәргә җибәргәндә, билгеле, күңел нечкәрүләргә урын юк. Ләкин әгәр дә ул, кешене гомерендә беренче тапкыр мәктәпкә җибәрүен белгән булса, Газинурга әйтер өчен җылырак сүзләр дә таба алган булыр иде.

## 21

Болай булыр дип Газинур һич тә уйламаган иде. Кичкырын ул, барлык иптәшләре белән саубуллашып, землянкадан чыкты. Аның өстендә шинель, аркасында барлык солдат кирәк-яракларын тутырган юка гына юл капчыгы, кулбашында автомат, Стариков аны бераз озатырга булды.

Алар, бер-берсенең йөзенә карарга батырчылык итмичә, сүзсез генә атладылар. Аерылышу аларның икесенә дә авыр иде, ләкин ни хәл итәсең. Аерылышырга туры килә. Хәер, бу вакытлыча гына. Алар бит барыбер бер полкта булачаклар.

Землянкалар, ут позицияләре яныннан сузылган сукмак буйлап бара-бара кырга чыктылар. Юл чатында янып беткән автомашинаның тимерләре өстенә утырдылар. Газинур белән бергә укырга китүчеләр әле килеп җитмәгәннәр иде.

– Төрик берәрне, – диде Газинур, каядыр икенче якка карап.

Стариков тәмәке янчыгын землянкада онытып калдырган. Газинурның алюминий тәмәке савыты, гадәттәгечә, буш иде. Кесә төпләрен актара торгач, икесенә бер төрерлек тәмәке җыелды. Тәмәкене Стариков төрде дә кабызмыйча Газинурга сузды.

– Башлап син суыр, Газинур, син китәсе кеше, юл аягы булсын, – диде.

Газинур тәмәкене, уч эченә яшереп, берничә суырды да Стариковка бирде. Костя, берничә суыргач, тагын Газинурга бирде. Шулай алар иреннәре пешкәнче тарттылар. Аннары ерак кызыл офыкка тын гына карап утырдылар. Снарядлар, бомбалар актарып, яралап бетергән хәсрәтле җир өстенә әкрен-әкрен генә караңгылык пәрдәсе сарыла иде. Кайдадыр алгы сызыкта, койрыклы йолдыз кебек, ак ракета күтәрелде. Моннан, ерактан, аңа туптуры карарга да мөмкин, аның яктысы ул хәтле көчле түгел, күзләрне чагылдырмый. Үзәнлектә, сыек төтен шикелле, кичке томан йөзә.

Стариков тирән генә көрсенеп куйды. Газинур да көрсенде.

– Нәрсәдер сиңа бүләк итәсе килә, Газинур, – диде сержант, – ләкин солдатның нинди кыйммәтле бүләге бар?.. – Ул үзенең кыр сумкасын актарды, аннан кечкенә генә бер китап чыгарды. – Менә бу китап... нибары биш тиен тора. Шулай да аны сиңа бүләк итәсем килә, Газинур. Мә, истәлек итеп сакла.

Күңелләре нечкәреп киткән Газинур, китапны алып, Стариковның кулын кысты.

– Рәхмәт, дустым, рәхмәт. – Караңгы булуга карамастан китапның тышлыгындагы язуны укыды: М.Горький. Слава храбрым. Шушы китаптамы әле лачын белән Данко турында язылган?

– Әйе, шушы китапта.

Газинур бераз эндәшми торды, аннары, тиз генә кесәсен капшап, алюминий портсигарын чыгарды.

– Минем дә, Костя, кыйммәтле бүләгем юк. Бездә дөя дә бүләк, төймә дә бүләк, диләр. Мә, төсем итеп сакла.

– Рәхмәт, – диде Стариков, бәреп төшерелгән самолет алюминиеннан ясалган тәмәке савытын алып. Аның капкачына штык очы белән «Газинур» дип язылган иде.

– Берлинга кадәр бергә барырбыз дигән идем, менә аерылырга да туры килә, – диде Газинур, уйчан гына. – Дуслардан аерылып китүе кыен.

Стариков Гафиятуллинның иңбашына кулын куйды:

– Борчылма, Газинур. Син дусларсыз тормассың. Тиздән яңа дусларың булыр.

– Монысын дөрес әйтәсең, Костя, – диде Газинур. – Кайда барсам, шунда якын дуслар табам. Ләкин иске дуслардан аерылуы авыр... Менә хәзер мин, гомеремдә беренче тапкыр, чын мәктәпкә барам. Әллә ничек, ышанасы да килми, ышанмаска да мөмкин түгел.

Стариков итек башы белән туфракны казый башлады, бер табан җирдән зур гына ике осколок чыкты.

– Монда, Газинур, һичнинди гаҗәп нәрсә юк, – диде Костя, тимер кисәкләрен янәшә китереп.

Моңарчы тын торган алгы сызыкта берьюлы унлап ракета һавага чөелде, ике яктан да пулеметлар атышып алдылар. Стариков, борчылып, урыныннан торды. Аңа кайтырга вакыт иде. Төнгә каршы фриц сугыш башламый башлавын, шулай да сак булган яхшы. Аннары Газинурның юлдашлары да килеп җиттеләр. Алар унлап кеше иде.

Стариков белән Газинур кочаклашып үбештеләр. Стариков, дустының ике кулыннан кысып:

– Йә, туганкай, отлично укы. Ә аннары кайт, бергәләп Берлинга барачакбыз, – диде.

– Аңарчы, бәлки, сине лейтенантлар курсына җибәрерләр, – диде Газинур.

– Барыбер бергә булырбыз! – диде Стариков һәм, соңгы тапкыр дустының кулын кысып, озата килүчеләр белән бергә кайтып китте. Кинәт Газинур аның артыннан кычкырды, аннары, Костя янына йөгереп барып, дулкынлана-дулкынлана сөйли башлады.

– Костя, әгәр башласагыз... Мин килеп җитәчәкмен... Бернигә карамыйча...

Стариков, бик җитди итеп:

– Ташла бу тиле уеңны, Газинур, – диде. – Син укырга тиеш, укырга! Хуш!

Газинур, Стариков күздән югалганчы, артыннан карап торды. Аның күзләрендә яшь иде.

– Бертуганыңмы әллә? – дип сорады кемдер.

– Туганымнан да якынрак, – дип җавап бирде Газинур.

Кузгалып киттеләр. Караңгыда Газинур юлдашларының йөзләрен күрә алмады, бары тик буй-сыннарын гына абайлады, тавышларын ишетте. Киң җилкәле, сөйлә-

веннән украин егете икәнлеге беленеп торган бер сугышчы, башын чайкап:

– Гаҗәп заманалар, – диде, – сугышта укырга җибәрәләр, һич тә уйламаган идем. 1939 елда шахтада эшләгәндә дә мине укырга җибәрмәкчеләр иде. Бармадым. Забойны ташлыйсы килмәде...

– Ә биредә шатланып барасыңмы? – дип чәнчеп алды мыскыллы тавыш.

– Телеңә тилчә! – дип кычкырды украин егете. – Мине кырык беренче елда ук укырга җибәрмәкчеләр иде. Кырык икенче елда генерал тагын ике тапкыр чакыртты. Үтенеп сорагач, калдырды, ә бу юлы... Бу юлы ул инде миннән сорап та тормады. Приказ – вәссәлам!

Күк йөзен болыт каплаган. Тик анда бер, монда бер ялгыз йолдыз җемелди. Алгы сызыкка сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек төяп баручы машиналар, бер-берсенә бәрелмәс өчен, берөзлексез сигнал биреп узалар. Машиналар колоннасыннан соң, бер рота чамасы сугышчылар очрады.

– Бөгелмә егетләре бармы? – дип сорады Газинур.

– Бар, җанашың сәлам әйтте, – дип җавап бирде кемдер, көлеп.

Пехотачылар да узып китте. Аннары караңгыдан утларын сүндереп барган автоколонна килеп чыкты. Тагын пехотачылар очрады. Җиңел машина җил кебек выжлап үтеп китте.

Сәгать ярымнар чамасы баргач, тау астында эт өргән тавыш ишетелде, аннары этәч кычкырды. Газинур, үзе белән янәшә баручы украин егетенең янтавына төртеп:

– Ишетәсеңме, этәч кычкыра! – диде.

– Кычкырса соң? – дип гаҗәпләнде теге. – Могҗиза түгелдер. Аның уставында шулай язылган.

– Сугыш башыннан бирле ишеткәнем юк иде! – дип пышылдады Газинур, юлдашының шаяртуына карамыйча.

– Авыл кешесе икәнсең, – диде украин егете.

– Колхозныкы, – дип төзәтте Газинур.

Кырыйдагы йортлар күренде.

Бу авылда дивизия штабы урнашкан иде. Газинурлар килеп җиткәндә, штабтан ерак түгел бер йорт янында алар кебек укырга баручылар байтак җыйналган иде.

Политотдел землянкалары янында Газинур көтмәгәндә Соловеев белән очрашты. Соловеев инде барысын да белә, шуңа күрә Газинурның монда йөрүенә бер дә гаҗәпләнмәде.

– Димәк, укырга барасың, Газинур? – диде ул. – Тырышып укы!

– Бер дә уйламаганда булган хәл бу, иптәш парторг, – диде Газинур, чын күңеленнән, – сугышасы, дошманны ныграк кыйныйсы урында укырга җибәрәләр. Төшенеп җитмим.

– Бер сине генә җибәрмиләр бит. Син канәгать түгелме әллә?

Газинур, Соловеевның хуп күрмәвен сизеп, каушап китте.

– Канәгать түгел дип... Коммунист булганнан соң, мин әле бер эш тә күрсәтергә өлгермәдем бит, иптәш парторг. Иптәшләрнең әллә ни уйлаулары бар лабаса.

Соловеев аның күзләренә туп-туры карады:

– Юк, Газинур, иптәшләрең синең турында начар уйламаслар. Командование сине укырга җибәрергә кирәк таба. Бу атакага барырга дигән приказ шикелле үк.

– Аңлыйм мин моны, иптәш парторг. Шулай да...

– Аңласаң, җиткән. Калганын оныт. Укуда вакытыңны әрәм итмә. Анысы менә бик мөһим, һәр минут, һәр сәгать кадерле.

Бераздан соң аларның барысын да, сафка тезеп, икенче бер авылга алып киттеләр.

Көзге төннәр озын. Полк мәктәбе урнашкан авылга барып кергәндә дә караңгы иде әле. Солдатларны кайчандыр рәшәткә белән әйләндереп алынган булган, хәзер исә капка баганалары гына тырпаеп калган ялгыз бер йортка керттеләр.

Бу йортта элек балалар укыган. Хәзер, ике яклап, ике катлы сәкеләр тезелгән. Сәкеләр шәп-шәрә. Уртада өстәл өстендә шәм кисәге яна. Группаны алып килгән командир, шул өстәл янына утырып, исемлекне барлап алды да, иртәгә кадәр ял итегез дип, чыгып китте.

Ялангач сәкеләргә менеп яткач та, солдатлар әле бик озак сөйләшеп яттылар. Аннары берәм-берәм йокыга киттеләр. Газинурның да күзләре йомылды. «Аны әйт, моны әйт, Газинур абыегыз – курсант!» дип елмайды ул һәм шулай елмайган килеш йокыга да китте.

## 22

Иртән Газинур «Подъем!» дигән ачы тавышка күзен ачты. Бу гади сүзнең мәгънәсе аның аңына тиз генә барып җитмәде. Алгы сызыкта ул бары тик: «Коралга!» – дигән команданы гына ишетергә күнеккән иде. Бу команда нинди генә хәлдә булмасын, солдатны күз ачып йомганчы аякка бастыра, барлык арыганнарын онытты-

ра. Бу команда Газинурның канына шулкадәр тирән сеңгән иде, ул ук кебек атылып урыныннан торды, шинелен, противогазын киде, патронташын такты. Башкалар да нәкъ шуны эшләделәр.

Ишек төбендә өстенә сырма кигән, киң җилкәле, усал карашлы старшина, кулларын артына куеп, басып тора иде.

– Шинельләрне кимәскә! Физзарядкага гимнастеркадан гына чыгарга! – дип кычкырды ул.

Шуннан соң гына солдатларның кайсыдыр аңына килде булса кирәк, шинелен салып атты.

– Кеше телен бөтенләй онытa язгансыз, – диде старшина.

Физзарядканы йорт артындагы кайчандыр балалар волейбол уйнап йөргән зур мәйданда үткәрделәр. Шушы беренче зарядкадан соң ук курсантлар бу старшина аларның «каннарына тоз салачагын» бик яхшы төшенделәр. Ул аларны унбиш минут буенча йөгертте, аннары, күлмәкләрен салдырып, салкын су белән билләренә кадәр яхшылап юынырга мәҗбүр итте.

– Сабынны кызганмагыз, мәктәп начальнигы килеп караганда, яшел кыяр шикелле чип-чиста булыгыз, – диде ул. – Колак эчләрегезне яхшылап юыгыз, үзем тикшерәчәкмен.

Һәм чыннан да тикшерде бит. Берәүне дә мактамады, әмма өч солдатны яңадан юынырга куды, сакал-мыекларыҗитә төшкәннәргә биш минут эчендә кырынырга кушты. Газинурга да эләкте.

– Биредә алгы сызык түгел, иптәш курсант, – диде старшина. – Сакалыгыздагы һәр төк өчен җавап бирәчәксез.

– Иптәш старшина, – диде Газинур, аның зур кара күзләре уйнаклап китте: – Миңа көн саен кырынуның расчеты бер дә юк бит. Кырынсам, бөтен шадраларым ялтырап тора. Ә монда медсанбат якын диләр.

Старшина, сары кашларын җыерып, Газинурга карады, ачулы тавыш белән:

– Фамилиягез ничек? – дип сорады.

– Ефрейтор Гафиятуллин.

– Ефрейтор икәнегезне күрәм! – дип кырт кисте старшина. – Истә тотарга киңәш итәм: монда сез – курсант! Ә күп сөйләгән өчен чираттан тыш наряд!

Старшина хром итекләрен шыгырдатып борылды да ашыгып китеп барды. Старшина ишектән чыккач, кемдер:

– Йә, ефрейтор-курсант, хәзер бу старшинаның кемлеген белдеңме? – диде.

Йөзенә сабын күбеге сөрткән Газинур, бритвасын бил каешына ышкый-ышкый:

– Борчылма, иптәш курсант, ул минем иң якын дустым булачак. Без үзебез дә яшь чакта сикереп сугарга ярата торган идек, – диде.

Газинурның күршесе, төнлә бергә килгән украин егете Ильченко – куе кара кашлы, киң маңгайлы егет – ак якасын тегеп бетереп, гимнастеркасын киде. Аның бөтен күкрәге диярлек орденнар һәм медальләр белән тулган иде. Төнлә боларның берсен дә күрә алмаган Газинур аңа сокланып карады.

– Кече сержант, Берлинга кадәр барып җитсәң, орденнарыңны кая тагып бетерерсең икән? Күкрәгең нәкъ генералныкы шикелле.

Ильченко киң каеш белән билен кысты, гимнастеркасының җыерчыкларын сыпыргалады, бары шуннан соң гына:

– Юк нәрсә белән башыңны ватма әле, энекәш, – диде. – Акылың алтын икән, бүтән җирдә кирәк булыр.

Газинур тел очында гына әйләнгән шаян бер сүзне әйтмәкче иде дә, Ильченконың күз карашындагы үтә җитдилекне күреп, артык эндәшмәде. Газинур, әлбәттә, теге вакытта атакага иң алдан баручы өч дусның берсе нәкъ менә шушы кеше икәнен белми иде. Әмма белгән булса, моңа һич тә гаҗәпләнмәс иде.

Иртәнге ашка строй белән алып бардылар. Алар озын сарайларда, берәр тактадан гына ясалган тар өстәлләрдә алюминий табаклардан ашадылар. Шул уңай белән курсантларның кайсыдыр шаяртып та алды:

– Котелокның кадере бетте, дуслар! – дип кычкырды ул. – Алгы сызыкта башым югалса да, котелогым югалмасын дип йөри идек, инде нәкъ киресен әйтер заманнар килеп җитте.

Озын өстәлнең икенче башыннан Газинурның шаян тавышы әләктереп алды:

– Әмма, егетләр, солдат шулпасы котелоктан ашаганда гына тәмле икән.

Кайтканда да строй белән алып кайттылар. Ашханәдән чыгып бераз киткәч тә, старшина:

– Запевай! – дип кычкырды.

Строй һаман бара бирде, ләкин берәү дә җыр башламады. Старшина тагын бер тапкыр үзенең боерыгын кабатлады, ләкин строй һаман тын гына бара бирде.

– На месте! Раз, два, три... – дип команда бирде старшина. Ул, стройны биш минутлар чамасы бер урында биеткәч кенә, яңадан кузгалырга команда бирде. Ничек-

тер җыр башларга батырчылык итми барган Газинур, берәү дә җыр башламагач, кинәт яңгыравык көчле тавыш белән җырлап җибәрде:

Ходу, ходу, братцы,
Смело на врагов,
Перед нами город
В тысячу домов. Эх!

Старшинаның йөзе яктырып китте. Ул җыр башлаучы табылуына шатланды. Строй җырны күтәреп алды:

Надо его взять,
Родине отдать.
Перед нами город
В тысячу домов.

Газинур, җырлый-җырлый, тирә-ягына күз йөртеп барды. Кайчандыр авыл шактый зур, бай булган. Йорт алларында да, йорт артларында да бакчалар үскән. Мөгаен, яз көннәрендә, алмагачлар, чияләр, шомыртлар чәчәк атканда, бакчалар ак катык шикелле булгандыр, ә урамнарда иснәп туя алмаслык хуш исләр йөзгәндер. Кешеләрнең бу авылда рәхәт яшәгәнлекләрен, кичләрен чуар киемле кызларның әйлән-бәйлән уйнаганлыгын, сандугачлар сайравы шикелле күңелле итеп җырлар җырлап йөргәнлекләрен күз алдына китерүе кыен түгел иде. Хәзер исә авылның яртыдан күп өлеше янып беткән, – кайчандыр бакча эчендәге җыйнак йортлар урынында морҗалар гына калган. Күп кенә урыннарда яңа бомба чокырлары күренә. Фашист самолетлары монда еш булгалый, ахрысы. Җил двигателенең тимер канатлары җирдә ауный, челтәрле манарасы бер якка кыйшайган. Бакчалар тәмам кырылып беткән, алар мәет чыккан кайгылы өй эчен хәтерләтәләр. Кайчандыр мәктәп каршында йөз яшәгән агач үсеп торган. Хәзер аның нинди агач икәнен дә әйтүе кыен, кәүсәсе күмерләнеп беткән. Әйтерсең аны кайдандыр җир астыннан ташка әверелә башлаган хәлендә казып чыгарганнар да фашистларның коточкыч эшләренә кара һәйкәл итеп утыртканнар.

Мәктәптән ерак түгел бер җирдә, тау астында, медсанбатның кызыл хачлы ак флагы күренеп калды. «Екатерина Павловна якын гына икән, җаен табып бер барып чыгам әле», – дип уйлап алды Газинур, хәзер аңа бу эш бик гади булып тоелды. Бер авылда тор да, күрмә, имеш. Ләкин күп тә үтмәде, Газинур бу уеның хата икәнлеген аңлады.

Мәктәпкә кайткач та, биш-ун минуттан соң аларны кабаттан сафка тезделәр. Роталарга, взводларга, отделе-

ниеләргә бүлү башланды. Взвод һәм рота командирлары бар да офицерлар. Ә отделение командирларын курсантларның үз araларыннан билгеләделәр. Газинур Ильченко отделениесенә эләкте. Взвод командиры олы яшьләрдәге кече лейтенант иде. Рота командиры күптән түгел генә госпитальдән кайткан, әле һаман да бер аягына аксый төшеп йөргән капитан. Газинур аны элек күргәләгәне бар иде, ул икенче батальонда рота командиры иде.

Старшина одеяллар, ак җәймәләр, түшәк тышлыклары өләште. Саламны кырдан алып кайтырга кушты.

Урын-җирләр отделениеләп җыештырылганнан соң, казармага – хәзер мәктәпне шулай атый башладылар – яңадан старшина килеп керде. Ул һәркемгә үз урыны турысына басарга команда бирде дә, һәр урын-җирне җентекләп карый-карый, казарманың бер башыннан икенче башына үтте. Бик күпләргә урыннарын яңадан җыярга кушты.

Газинур, үз урынына күз кырые белән карап алып, старшина бәйләнә инде, дип көтте. Ләкин старшина урынны капшап карады да, берни әйтмичә, үтеп китте.

Төшке аштан соң, взвод командирлары взводларын мәктәп янындагы мәйданга строевой занятиегә алып чыктылар. Строевойдан соң тактика, политзанятие, уставны өйрәнү дәресләре булды. Инде караңгы төшкәч, авылның икенче башына, мунчага алып киттеләр...

Бары тик төнге унбердә генә отбой булды. Алгы сызык шартларына күнеккән солдатларга бу кискен үзгәреш бөтенләй диярлек сәер тоелды. Бер көн эчендә аларга шулхәтле күп яңа нәрсәләр сөйләделәр, аларның моны миләренә сеңдерергә вакытлары да, рухи әзерлекләре дә юк иде.

Ак җәймәле йомшак түшәккә сузылып яткан Газинур, шаяртып:

– Башым тубал булды, егетләр, – диде.

Сугыш башланганнан соң, әгәр госпиталь көннәрен искә алмаганда, бу аның беренче тапкыр шулай туган өйдәгечә чишенеп, рәхәтләнеп сузылып ятуы иде.

– Әгәр көн саен безгә болай сабак укытсалар, өч айдан йә генерал булабыз, йә башларыбыз куык кебек шартлый, – диде ул, тыела алмыйча.

– Разговоры! – дип кычкырды әллә кайдан гына килеп чыккан старшина. – Кем сөйли анда. Замри!

«Зәһәр икән», – дип уйлап алды Газинур, аннары, күзләрен йомып, йомшак түшәктә буыннарын шыгырдатканчы киерелде. Аның һичкайчан авырганы юк иде. Әмма бармаклары өзелеп төшкән уң аягы, артык күп

йөрелгәнгә, хәзер әкрен генә сулкылдап сызлый. Ләкин Газинур мондый вак-төякләргә генә игътибар итә торганнардан түгел. Ул, елмаеп, башын чайкап алды. «Гаҗәп эшләр була икән бу дөньяда, – дип уйлады ул, – өйдәгеләр, безнең Газинур сугышта, пулялар астында, юеш окопта ята инде дип уйлыйлар. Ә Газинур кызлар түшәгедәй ак түшәктә рәхәтләнә...»

Йокларга күптән вакыт, ләкин, күңеле дулкынланганлыктан, Газинурның күзенә йокы кермәде. Ул алгы сызыкта калган иптәшләрен – Костя Стариковны, Ивановны, Григорьянны, Зәбировны исенә төшерде. Нишлиләр икән хәзер алар? Иванов постта булырга тиеш. Костя, ихтимал, аның янына килгәндер, ара-тирә ракеталар яктырткан битараф җиргә карый торганнардыр. Уйлыйлармы икән алар Газинур турында? Китүе өчен ачуланмыйлармы икән? «Безгә гел һөҗүм турында сөйли иде, ә үзе яфрак астына шылды» дип яманламыйлармы икән?

Кемдер ишекне ачып керде. «Тагын шул тынгысыз старшина... Әллә нарядка уятырга килгәнме? Газинур онытмаган лабаса...» дип уйлады һәм күзен ачты. Старшина түгел, рота командиры икән. Ул казарма буйлап әкрен генә үтте дә, кул сәгатенә карап алып, чыгып китте. «Нигә йокламый икән ул? Эче пошамы әллә?» – дип уйлап алды Газинур.

Дневальный өстәлендәге фонарьның тонык яктысы төшкән түшәмнән электр арматурасы асылынып тора... Газинур аңа берничә секунд карап ятты: «Биредә электростанция булган икән», – дип уйлады, шунда кылт итеп Гөлләр исенә төште. Бу көтелмәгән хәтерләүдән Газинур хәтта елмаеп куйды. Кайда икән ул сөйкемле кыз? Аның укуын тәмамлап, Казанда инженер булып эшләвен Газинур сугышка кадәр үк ишеткән иде. Ләкин, урман эшеннән кайткач, күрәсе бик килгән булса да, күрә алмады. Шулай да Гөлләр аның күңелендә ниндидер бик яхшы, бик якты бер хис калдырган иде. Була бит менә шундый кызлар: син аңа гыйшык та тотмыйсың, аның белән театрга да йөрмисең, ләкин бер күреп сөйләшкәч, син инде аны беркайчан да оныта алмыйсың, ул синең йөрәгеңә үзенә генә хас булган ниндидер бер яхшы ягы белән кереп урнашып кала, син кая барсаң да, ни генә эшләсәң дә, ул синең хәтереңнән чыкмый, синең барлык эшләреңнең сүзсез шаһиты булып, тын гына, комачауламыйча гына тора бирә. Аны синең күңелеңнән берәү дә, хәтта өзелеп сөйгән ярыңның кайнар һәм көнче мәхәббәте дә куа алмый. Нәрсә соң бу? Госпитальдә ятканда Газинур үзе ке-

бек яралылардан: «Ир белән хатын-кыз арасында дуслык була алмый, ул йә мәхәббәткә әверелә, йә этле-мәчеле булып китәләр», – дип ишеткән иде. Буш нәрсә сөйләгәннәр икән. «Ир белән хатын-кыз арасында да чын дуслык була шул, – дип уйлады Газинур. – Әгәр дуслык булмаса, ни өчен мин аның исемен еллар буенча йөрәгемдә йөртер идем?»

Шул уйлар эчендә Газинур йокыга китте. Кинәт:

– Подъем!.. Тревога! – дигән команда ишетелде. Ул бик тиз күзләрен ачты, одеялын өстеннән ташлап, чалбарына үрелде. Башкалар да, сикерешеп торып, киенә башладылар.

Газинур бик ашыгып киенсә дә уздыра алмады. Тәртип белән куелмаган чалбар-гимнастеркаларын кигәндә буталып бетте. Дөрес, гимнастерка урынына чалбарын кимәде киюен, шулай да уң аягын сул балагына тыгып җибәрде.

Иң беренче булып отделение командиры Ильченко киенеп бетте һәм, отделениесенә построениегә чыгарга кушып, үзе ишеккә таба йөгерде. Бераздан Газинур да тышка йөгерде. Караңгы иде. Үзләре күренмәгән отделение командирларының:

– Беренче взводның беренче отделениесе...

– Икенче взводның беренче отделениесе... – дигән тавышлары гына ишетелде.

Газинур Ильченко тавышы яңгыраган якка таба йөгерде.

Бөтен рота чыгып сафка басканнан соң, бер кулына кесә фонаре, икенче кулына сәгать тотып торган рота командиры старшинага:

– Кереп тикшерегез, – диде, үзе сафка тезелгән сугышчыларга карады: – Унбиш минут киендегез, иптәш курсантлар! Начар, бик начар!

Ул арада старшина, кемнеңдер төшеп калган чалбар ременен күтәреп чыгып, рота командирына күрсәтте.

Газинур чалбар ременен тиз генә капшап карады: юк, аның ремене биләндә.

– Кемнең ремене? – дип сорады рота командиры.

Берәү дә дәшмәде. Рота командиры икенче тапкыр сорады. Бары тик шуннан соң гына стройның сул флангысыннан бер тавыш ишетелде:

– Минеке...

Капитан аның фамилиясен сорады, аннары строй алдына чыгарып бастырды.

Рота командиры, чалбар ременен югалткан сугышчыны гына түгел, барлык курсантларны бик нык кыздырып алганнан соң, каты, кискен итеп әйтте:

– Биш минут эчендә сез тулы сугышчан хәзерлек хәлендә сафка килеп басарга тиешсез. Шуңа өйрәнгәнче, тревогалар төн саен, хәтта төненә берничәшәр мәртәбә булачак. Моны исегездә тотыгыз!

Казармага кереп, яңадан урынга яткач, Газинур күзләрен генә йомарга өлгергән иде бугай, тагын команда ишетелде. Газинур сикереп торгач, аптырап калды: тышта таң аткан иде инде.

– Физзарядкага!.. – дип кычкырды старшина.

## 23

– Курсант Гафиятуллин! Сез – отделение командиры. Дошман көньяк-көнбатышка, Никольск авылына таба чигенә. Сезнең отделениенең бурычы, сез белергә тиешсез, дошман Никольск авылын сакларга уйлыймы, юкмы? Сакласа, нинди көч белән саклый, алгы сызыгы кайда, корылмаларының характеры, ут системасы нинди, резервлары кайда урнашкан... Ничек хәрәкәт итәрсез?

Взвод командиры Газинурга карта белән планшеткасын сузды. Газинур кабаланмыйча, кыска итеп җавап бирде, картада үзенең юлын билгеләде. Аннары смирно басып боерык көтә башлады.

Аның шинель чабуларын җил каера, йөзенә кар катыш яңгыр бәрә иде. Күкрәгенә таккан автоматының прикладына да кар бөртекләре килеп куна һәм шунда ук эри дә.

– Үтәгез, – диде взвод командиры, нәкъ бер сәгатьтән кайтырга кушып. Газинур кулындагы компасына карады, тиешле азимутны билгеләде, кыр уртасындагы түбәсез кирпеч сарайларыннан чыгып, үзенең биш кешелек отделениесе белән көньяк-көнбатышка таба, каршы искән җилгә ян белән борыла төшеп, китеп тә барды. Взвод командиры бүтән отделениеләргә задание бирергә кереште.

Курсантлар иртә таңнан караңгы төнгә кадәр, ә күп вакытта төннәрен дә, ачык кырдан кайтмыйлар иде. Уку программасының төп нигезен Бөек Ватан сугышы тәҗрибәсен өйрәнү тәшкил иткәнлектән, класс дәресләре бик сирәк була. Өйрәнүләрнең иң зур өлеше кырда, сугыш обстановкасына якынлаштырылган шартларда үткәрелә. Курсантларны дошманның ныгытылган оборонасына һөҗүм итәргә, дошман оборонасының эчендә траншея сугышлары алып барырга, авыл һәм шәһәр урамнарында сугышырга, төнлә хәрәкәт итәргә, карта укырга, азимут

буенча йөрергә, чигенүче дошманны эзәрлекләргә, елгалар, сулар кичәргә өйрәттеләр. Курсантлар бер үк вакытта гади солдат булып та, отделение командиры булып та хәрәкәт иттеләр. Дәресләр барышында аларның һәрберсе отделение командиры булып та, гади сугышчы булып та өлгерә иде. Һаваларның нинди булуына – яңгырга, җилгә, давылга, салкынга, пычракка карап тормадылар: расписаниедә нинди дәрес күрсәтелгән булса, шул дәрес төгәл килеш үтәлде. Курсантлар, окоплар, ячейкалар казып, сукыр тычканнар шикелле, бөтен кырны актарып бетерделәр. Шул киң кыр буенча, түшләре белән шуышып, барлык юнәлешләр буенча үттеләр. Су очраса, суга керделәр, сазлык очраса, сазлыкны ерып чыктылар. «Өйрәнгәндә кыен булса, сугышканда җиңелрәк булыр», – ди иде аларга командирлар. Курсантлар моны үзләре дә бик яхшы аңлыйлар иде. Төнге сәгать унбердә, ниһаять, салам түшәккә сузылып яткач, алар, башлары мендәргә тию белән үк, йокыга китәләр, подъем булганчыга кадәр икенче якларына да әйләнмиләр иде. Кая китте ул тирән уйларга чумып, йоклый алмыйча газапланган беренче төннәр!

Төрлесе төрле задание алып киткән отделениеләр бер сәгатьтән яңадан кирпеч сарайларында җыелдылар. Отделение командирлары алып кайткан мәгълүматлары турында взвод командирына доклад бирделәр, аннары тикшерү башланды. Взвод командиры аларның хаталарын, кимчелекләрен күрсәтте, кайберләрен мактап алды.

– Гафиятуллин отделениесе үзенең бурычын начар үтәмәде... – дип дәвам итте лейтенант, калынрак иреннәрен чак кына ача төшеп, аны игътибар белән тыңлап утырган курсантка карап. –Ләкин...

Бераздан алар учак тирәсендә утыралар иде инде. Курсантларның берсе, күшеккән кулларын ялкын өстенә сузып, уйчан гына сөйли башлады:

– Яхшы сугышыр өчен мәктәптә укырга кирәклекне элек башыма да китерми идем. Ә уйлап карасаң, моңарчы мин ярым сукыр килеш сугышканмын.

– Миндә дә шундый уй бар иде. Чын. Нәрсә ул фриц? дип уйлый идем. – Сыткы. Сыттың, бетте-китте.

– Ә ул автоматтан ата...

– Шуңа күрә безне монда җибәрделәр дә, – диде Ильченко, җитди итеп. – Аз кан түгеп җиңәргә өйрәнергә кирәк.

– Тизрәк алгы сызыкка кайтасы иде, – диде өченче бер курсант, – хәзер мин ерактан күреп, киң горизонт белән сугышачакмын.

– Беләге юан берне егар, белеме юан меңне егар, – дип, үз сүзен кыстырды Газинур. Гадәтенчә ул моны бераз көлемсери төшеп әйтте. Русчага сүзгә-сүз тәрҗемә ителгән бу яхшы татар мәкале сәер яңгырады, барысын да көләргә мәҗбүр итте. Газинур үзе дә тамак төбе белән генә көлеп алды.

– Мәгънәсе аңлашылгач, шул җитте, – диде ул.

Икенче көнне взвод тулысы белән нарядка билгеләнде. Газинурларны старшина мунча ягарга җибәрде.

– Карагыз аны, кайнар суы җитәрлек булсын! – дип кисәтте старшина.

– Борчылмагыз, иптәш старшина, кайнары да, салкыны да җитәрлек булыр, – диде Газинур. – Чабынырга теләүчеләр булса, себеркесен дә табарбыз. Тик менә мунчадан соң чәй эчәргә балын гына табып булмас.

Кисәктән генә «бал» сүзе теленә килеп кергәч, Газинур бөтен хыялланганы бал кортлары үрчетү турында булган мәрхүм өлкән сержант Степашкинны исенә төшерде, көрсенеп куйды. Әйбәт кеше иде, кабере якты булсын.

– Мунчадан соң чәйне бал белән эчәргә кирәкмени? – дип елмайды старшина.

– Так точно, юкә балы белән! – диде Газинур. Хәзер инде ул бу старшина белән тәмам дуслашкан, чиратсыз бирелгән нарядны да оныткан иде. – Бөтен сөякләр йомшарып китә, яшәргән күк буласың.

Старшина кычкырып көләргә тотынды.

– Һай, җор икәнсең! Кайда туып, кайда үстең икән син?

– Әткәйнең бүреге эчендә, иптәш старшина. Срогыннан алда туганлыктан, туңып үлмәсен өчен әткәйнең җылы бүрегенә сала торган булганнар.

Бу көнне Газинур, ниһаять, Екатерина Павловнаны күрә алды. Медсанбат мунчадан ерак түгел иде. Мунчаны ягып җибәреп, сулар ташыганнан соң, Газинур, старшинадан рөхсәт сорап, медсанбатка китте. Кар баскан урам буйлап барган чагында, Газинурны кошевка чанага җигелгән һәйбәт тимер-күк ат куып җитте.

– Һай, саклан! – дип кычкырды дилбегә тотып килүче.

Газинур читкә тайпылды, аның яныннан выж итеп Григорьян белән Зәбирә үтеп киттеләр. Ләкин алар Газинурны танып өлгерделәр булса кирәк, старшина бөтен

көченә чабып барган атны авызлыгын каерып туктатты, ә Григорьян, артына борылып, кулын изәде.

Газинур чана янына йөгерде.

– Син нишләп монда йөрисең, Гафиятуллин? – дип сорады разведчик.

– Укыйм, иптәш өлкән лейтенант. Курста, – диде Газинур көләч йөз белән.

– Генераллыккамы?

– Так точно, иптәш өлкән лейтенант, генерал-сержантлыкка.

Өчесе дә кычкырып көлеп җибәрделәр. Аннары Зәбиров җитди итеп сорады:

– Тиз бетерәсеңме?

– Озак тотмабыз, диләр.

Аларның берсе дә Газинурның укып йөрүенә гаҗәпләнмәде. Бу аларга бик табигый бернәрсә булып күренде.

– Йә, ярый, Газинур, уңыш телибез. Генерал булып кайт, – диде Григорьян. – Без ашыгабыз. Син дә ашык!

Зәбиров сызгырып җибәрде. Тимер-күк чаптар элдереп алып китте. Газинур аларга сокланып карап калды. Бер минуттан авызыннан ак күбекләр чәчеп барган ат та, кошевка чана да күздән югалды.

«Менә йөриләр, ичмасам», – дип уйлады Газинур, үзенең дә шундый җил кебек оча торган атка утырып йөрисе килде. Аннары өлкән лейтенантның «Син дә ашык!» дигән сүзләрен исенә төшерде. Нигә әйтте икән ул боларны? Разведчик тикмәгә генә әйтмәс.

Екатерина Павловна Газинурны күргәч чиксез шатланды. Кайдан, ничек бирегә килеп чыктың, яраланмагансыңдыр бит, Володяны күрмәдеңме, дип тезеп китте. Аның алгы сызыкта теге вакыттан бирле булганы юк икән. Газинурның укырга килгәнлеген белгәч, тагын да куанды, ләкин һич тә гаҗәпләнмәде. «Кара, минем укып йөрүгә боларның берсенең дә исе китми бит», – дип уйлап алды Газинур.

Екатерина Павловнаның бүлмәсе кысан, анда бер поход кровате белән кечкенә генә өстәлдән башка әйбер юк иде. Аның каравы өстәл өсте дарулар, китаплар белән тулган. Стенада Володяның тыныч вакыттагы, чиккән якалы ак күлмәк киеп төшкән рәсеме. Володя елмаеп тора, сары бөдрә чәчен артка тараган. Соликамскида ял көннәрендә Газинур аны гел шушылай күрергә күнеккән иде.

Чәй эчкән арада, Екатерина Павловна күбрәк Газинурның укуы турында сораштырды, бик кыен түгелме, диде.

– Җиңел түгел, нык тирләтәләр, – дип җавап бирде Газинур. – Гыйлем алу – инә белән кое казу икән.

– Шулаймыни?

– Әйе, мин әле яңа гына гыйлем китапның эчендә дә, тышында да икәнен аңлый башладым. Алгы сызыкта җиңелрәк иде...

Газинур Екатерина Павловнадан берни дә яшермәде, аның алдында мактанмады да. Ул гүя аның күңелендәге барлык яшерен серләрен белергә тиешле булган бертуган апасы иде. Сүз арасында Екатерина Павловна Галя белән Нинадан хатлар алуын, аларның әле һаман да Карелия фронтында икәнлекләрен, Газинурга атап сәлам язуларын әйтте.

– Онытмаганнармыни әле? – дип гаҗәпләнде Газинур.

– Сине, Газинур, бер белгән кеше һич онытмаячак, – диде Бушуева. Моңа Газинур ни дип тә әйтергә белмәде. Кызлар кебек оялып, керфекләрен түбән төшерде.

Екатерина Павловна өстәл читендәге планшетын алды, аннан бер рәсем чыгарып Газинурга сузды.

– Таныйсыңмы?

– Павел Иванович! Ул да армиядәмени?

– Әйе. Танк полкы командиры иде...

Газинур, еллар үтсә дә, һаман да онытылмаган бу таныш йөзгә озак карап торды. Үзенең беренче тапкыр аның янына курка-курка гына килеп керүләре исенә төште. Ул чактагы ак киемле, көләч йөзле Павел Иванович бу кырыс карашлы танк командирына бер дә охшамаган иде.

– Павел Иванович та киткәч, леспромхозда кемнәр генә калды икән соң? – диде Газинур, рәсемнән күзен алмыйча. – Карп Васильевич, дядя Митрофаннар исәннәрме икән?

– Карп Васильевич хәзер леспромхоз начальнигы дип язганнар иде. Дядя Митрофан бригадир бугай.

– Шәп кешеләр. Гомердә онытасым юк үзләрен.

Екатерина Павловна Газинурның кулыннан рәсемне алып карап тора башлады. Газинур аның йөзе кинәт сагышланып, күзләре дымланып киткәнен күрде.

– Бу – әтинең соңгы рәсеме. Дуслары җибәрделәр...

Екатерина Павловнаның сулышы буылгандай булды, ул өстәлгә капланды, кулбашлары селкенә башлады. Ко-

точкыч хәлнең мәгънәсен әле яңа гына аңлаган Газинур урыныннан сикереп торды, чиксез аптырашка калып:

– Катя Павловна... Катя Павловна, кирәкми, – диде. Ләкин үзенең дә зур кара күзләре мөлдерәмә яшь белән тулды, тавышы калтыранды.

Екатерина Павловна башын күтәрде, яшьле күзләре белән Газинурга карап, сызланып сөйли башлады:

– Әтинең танкысын... гитлерчылар бензин сибеп яндырганнар. Экипаждан берәү дә чыкмаган. Яна торган танк эчендә алар «Интернационал» җырлаганнар...

Екатерина Павловна, Газинурның ике беләгеннән кысып, башын аның күкрәгенә куйды, тагын үкси башлады.

– Авыр, Газинур... Йөрәгемнең ничек өзгәләнүен... синнән башка бу турыда беркемгә дә сөйләгәнем юк иде. Володя да белми әле. Син дә аңа хәзергә берни әйтмә...

Газинур, кулларын йомарлап, тәрәзәдән карлы урамга караган килеш сүзсез калды.

## 24

Әле кайчан гына Газинур шушы юлдан укырга килгән иде. Әле кайчан гына ул үзенең ефрейтор исемен онытып, курсант исеменә күнегә алмыйча интегеп йөргән иде. Кичә генә кебек бит. Кай арада өч ай ярым вакыт үтеп тә киткән!

Менә тагын шул ук фронт юлы. Ләкин Газинур бармый, кайта инде. Алгы сызыкка кайта, һәр адымын атлаган саен, ул үзенең иске дусларына якынлаша, йөрәге очрашу шатлыгыннан дулкынланып тибә. Костя нәрсә дияр? Әй, шатланыр да инде Газинурны күргәч! Рәхмәт, бик еш язып торды, тик соңгы айда гына хаты нигәдер өзелде. Газинур тиздән кайтам дип язган иде. Мөгаен, үзен көткәндер...

Кеше күңеле гаҗәп бит. Ул кайчандыр узган юлына яки бер торган җиренә күпме генә вакыттан соң әйләнеп кайтса да, аңа ике арадагы вакыт күз ачып йомганчы үтеп киткән шикелле тоела. Шул вакыт эчендә бик күп үзгәрешләр булуын – бигрәк тә фронтта – ул уйлап та карамый. Газинур да пульротадагы бөтен хәлләрне бары тик үзе киткән чактагыча гына итеп күз алдына китерә иде. Алай гына да түгел, бу минутта ул курста үткән өч ай ярым вакыт эчендә үз маңгаеннан нихәтле тир түккәнен дә, нихәтле белем алганын да оныткан иде. Аныңча ул һаман да әле элекке Газинур, элекке ефрейтор.

Тирә-як ап-ак кар белән капланган. Күктә, гыйнвар салкыныннан чекерәешкән сыман, сиксән мең йолдыз җемелди. Ни өчен сиксән мең? Җырда шулай җырлана ул. Бу җырны Газинур малай чагында җырлап йөри иде:

Ай белән кояш бер генә,
Йолдыз сиксән мең генә.

Тулган ай, үзенең моңсу нурларын урманнар, кырлар өстенә чәчеп, әкрен генә йөзә. Көз көне кап-кара булып, күңелгә шом салып торган бомба чокырлары, юл буендагы янган машина калдыклары, унар, уникешәр йортлы кечерәк, күбесе җимерелеп беткән авыллар – барысы да кар астында калганнар. Җирнең яралары күренми. Ә күмерләнгән, гарипләнгән агачлар исә чәчәк аткан шикелле утыралар. Аларның ботакларын энҗедәй бәс сарган.

Фронт сызыгы өстендә, камчылау утлары сыман, ракеталар күтәрелә. Фронт якынайган саен, алар күбәя, яктыра баралар. Тирән кар астында йоклап яткан җирне селкетеп, туплар гөрселди, бик зур тегү машинасы бик озын чаршау теккәндәй, пулеметлар тыкылдый. Фронтка беренче тапкыр килүчеләрдә, моны ишеткәч, билгесезлек алдында ниндидер борчылу туса, фронтка кабат әйләнеп кайтучылар таныш стихиягә эләгү тойгысын, анда тизрәк барып җитү теләген генә кичерәләр. Чөнки еракта гы һәрнәрсә үзгәреп күренгән сыман, еракта гы атышлар да ниндидер билгесез бер төс алалар. Ә барып җиткәч, бөтен нәрсә үз урынына баса да ачыклана.

Соңгы бураннар моннан берничә көн элек булып үткән иде. Ләкин урман эченнән сузылган киң юл чиста, аны трактор артына авыр сөйрәгечләр тагып тигезләткәннәр. Ай яктысында юлда машина тәгәрмәчләренең бизәкле эзләре ап-ачык күренеп тора. Машиналардан соң үрәчәле чаналарда үткәннәр. Чана табаннарының ак ефәктәй тасмалары ялтырап тора. Аннары тагын кемдер тимер табанлы кошевкада үткән. Кошевканың тар эзе бизәкле тәгәрмәч эзләре өстендә, шулай ук ак ефәк тасмадай сузылып ята.

Газинур, үзенең элекке разведчик гадәте буенча, юл китабын укып бара башлады. Шул ук вакытта артта калган көннәрен исенә төшерде. Китәр алдыннан ул Екатерина Павловна янына кереп чыкты. Аның йөрәгендәге коточкыч кайгыны белеп тә, шуны аз гына булса да җиңеләйтү өчен берни эшли алмавын аңлаган Газинурга

Екатерина Павловнаны күрү чиксез авыр иде. Әгәр мөмкин булса, ул аның бөтен газапларын үз өстенә алыр иде.

– Саубуллашырга кердем, Екатерина Павловна, – диде Газинур әкрен генә. – Укуны тәмамладык. Төнлә передовойга кайтабыз.

– Шулай тиз үкмени? – дип сорады Бушуева, нәрсәдәндер сискәнгәндәй булып.

– Нинди тиз булсын! Бер ел үткән кебек.

Екатерина Павловна Газинурны сержант исемен алуы белән тәбрикләде, киләчәктә сине офицер итеп күрергә насыйп булсын, диде. Аннары тагын бер тапкыр, шулай тиз үк китәсеңмени? дип сорады. Алайса, Володяга хат та яза алмыйм, диде. Сәлам әйтергә кушты. Бер бушрак ара булса, үзем барып чыгармын, дип вәгъдә итте.

Сугыш припаслары, азык-төлек төягән йөк машиналары, куып җитеп, узып китәләр. Йөк машиналарыннан башка тагын полк минометлары дивизионы, аннары өсләре брезент белән ябылган машиналар да әледән-әле узып китәләр.

– Гвардейскийлар бара, – диде Газинур белән янәшә атлаучы Ильченко. – Димәк, шулай... Вакытлы кайтабыз!

Полк штабына килеп җиттеләр. Биредә яңа сержантларны озак көттермәделәр, алар белән полк командиры подполковник Кремнев (ул инде подполковник иде) бераз сөйләшкәннән соң, аларны үз батальоннарына озаттылар.

Ниһаять, үз батальоны туфрагына аяк баскач, Газинур иркен сулап куйды. «Өйдә...» – дип уйлады ул. Бернигә карамастан үз расчетына йөгерәсе, иптәшләрен кочаклап үбәсе, кулларын кысасы: «Менә, кайттым, кабул итегез», – дип кычкырасы килде. Штаб тирәсендә пульротадан берәрсе юкмы дип каранды. Ләкин пульротадан берәү дә күренмәде.

Яңа сержантларны комбат янына чакырдылар. Комбат урынында Ермиловны күргәч, Газинур тәмам тынычланды. «Гвардия капитанының монда булуы бигрәк тә яхшы. Ул мине үз ротабызга ала», – дип уйлады Газинур. Шунда ул Ермиловның погоннарында майор йолдызына игътибар итте. Газинур юк чакта Ермиловны комбат итеп күчергәнлекләрен аңлады. Бу хәл әле күптән түгел генә булган булса кирәк, чөнки Стариков бу турыда берни дә язмаган иде.

Гвардия майоры Газинурга кул бирде, ничек укуы турында сорашты һәм:

– Йә, хәзер сине кая җибәрергә инде? – дип сорады.

– Үз ротабызга, иптәш гвардия майоры. Башка бер җиргә дә түгел.

Гвардия майоры, ияген кулы белән кысып, бераз уйланып торды да:

– Юк, Газинур, пульротага мин сине җибәрә алмыйм, – диде, сержантның чырае үзгәреп китүен күреп өстәде: – Җибәрә алмыйм. Анда отделение командирлары бар инде. Мин сине иң кыен урынга, беренче укчы ротага, капитан Бушуевка җибәрәм. Син батальонда беренче ротаның нинди урын тотуын белергә тиешсең.

Газинур землянкадан чыккач кына аңына килде. Менә ул солдат язмышы нинди. Ичмасам, башта Стариков янына кереп чыгарга рөхсәт сорыйсы калган. Югыйсә Стариков бер флангта, ә беренче рота икенче флангта. Яңадан гвардия майоры янына кереп рөхсәт сорарга Газинур батырчылык итмәде. Ул арада сержант Ильченко чыкты, һәм алар икәү бергә киттеләр. Ильченко икенче ротага билгеләнгән иде.

Газинур капитан Бушуев землянкасына килеп кергәндә, рота командиры нәрсәдер укып утыра иде. Бушуевның башы ак марля белән уралган. Күзләре ничектер эчкә баткан. Ябыккан да кебек. «Капитан яраланганмы әллә?» – дип борчылып уйлап алды Газинур. Ул ротаның моннан берничә көн элек көндезге разведкага катнашуы, пленныйлар алуы, рота командирының яралануы турында берни белми иде.

Бушуев, томанга уралып кергән сержантны күрмичә:

– Кем анда? – дип сорады.

Гафиятуллин ачык тавыш белән өздереп әйтеп бирде. Бушуев, кызыл тышлы китабын өстәл кырыена куеп, тиз генә урыныннан торды. Ул Газинурның отделение командиры булып кайтуына чын күңелдән шатланды.

– О-о, Газинур! Алгарак уз әле, карыйм, нинди сержант булгансың? – диде ул, Газинурның ике җиңеннән тотып: – Начар түгел шикелле... Йә, котлыйм, Газинур!

Капитан, Газинурны үз янына утыртып, ничек укулары турында сорашты, бик кыен булмадымы дип белеште. Аннары Екатерина Павловна турында сөйләтте. Бары шуннан соң гына Газинурны отделениесе белән таныштырырга алып китте. Моны ул, әлбәттә, взвод командиры аркылы эшләтә ала иде. Әмма Газинурны артык якын

күргәнгә, үзе аның белән чыкты. Аңарчы ул Газинурга беренче отделениенең командиры моннан берничә генә көн элек яраланганлыгын, сугышчыларның аны бик яратканлыкларын әйтте.

– Син аларның күңелләренә башта ук керергә тырыш, югыйсә алар сине чит күрәчәкләр. Сугышчы читсенеп караган командирның эше бервакытта да уң булмый.

...Җылы землянкада, үз отделениесенең солдатлары арасында Газинур тәмәке тартып утыра. Аның янчыгы кулдан-кулга күчеп йөри.

Ул әле яңа гына Соловеев янында булып кайткан. Полк парторгы белән очрашу аның күңелендә үзенә бертөрле ышерен шатлык уяткан иде.

– Син агитатор идең, агитатор булып каласың да, – диде Соловеев, аңа уңыш теләп, һәм менә Газинур, сугышчылары уртасында утырган хәлдә, аларга фронт хәлләре турында сөйли.

Кайчагында, сүз арасында, өр-яңа погоннарын, гимнастерка төймәләрен капшап ала, җитеп килгән кара чәчен кулы белән сыпырып куя, кайчагында тыңлаучыларга сынап караган килеш сүзеннән тукталып кала. Ләкин үзе сүздән туктаса да, күзләрендәге елтыр чаткылар, бигрәк тә ирен почмакларына кунып торган хәйләкәр елмаюы югалмый.

Газинур газетадан кисеп алган сугыш хәрәкәтләре картасын җәеп тезләренә салды.

– Менә карагыз, иптәшләр, 1943 елда Кызыл Армия нихәтле Совет җирен азат итте, – диде ул. Владикавказ, Сталинград, Воронеж һәм Ржевтан алып Витебск, Киев, Кривой Рог, Херсонга кадәр булган бик зур мәйданны бармагы белән урап күрсәтте. – Моннан соң, минемчә, эшләр тагын да кызурак барыр. Хәзер инициатива безнең кулда.

Газинур бераз эндәшми торды, аның карашы әлегә азат ителмәгән җирләрдә тукталып калды. Совет державасының чикләренә барып җиткәнчегә кадәр никадәр юл үтәсе, никадәр елгалар кичәсе бар әле. Аннан ары – Европа. Аны да фашистлардан коткарырга кирәк.

– Без кайчан кузгалабыз икән, иптәш сержант? – дип сорады күк күзле бер солдат.

– Ә сез үзегез ничек уйлыйсыз, иптәш Комлев? – диде Газинур, туры җавап бирмичә. – Безгә монда озак утырудан файда бармы?

– Файда, билгеле, юк, ә менә приказ кайчан булыр?

– Анысын мин дә белмим, – дип елмайды сержант. – Алдан әйтеп куюны кирәк тапмаганнар.

– Кичә мин госпитальдән кайткан бер танышымны күрдем, – дип, икенче бер сугышчы сүзгә кушылды. – Безнең фронтка, ди, исәпсез-хисапсыз гаскәр килә, ди.

Аны Кызыл Йолдыз ордены таккан бер ефрейтор бүлдерде:

– Лыгырдавык икән синең танышың, – диде ул ачу белән. – Безнең Гордеев кебек чебеннән фил ясаучы кешеләр бетмәгән әле дөньяда.

– Ну, ну, уйлабрак сөйләш, иптәш ефрейтор! – Моңарчы мыштым утырган, сакал-мыегы кырылмаган, йокылы-уяулы солдат мыгырданып куйды. – Гордеевның нинди усаллыгы тигән сиңа?

– Тик утыр, югыйсә иптәш сержантка синең тырнаклар эчендә күрсәткән уяулыгың турында тотармын да сөйләп бирермен.

Газинур сугышчыларның елмаюларын күрде, әмма ефрейторның нәрсәгә киная ясавын төшенеп җиткермәде.

«Зарар юк, тиздән ярты сүздән аңлый башлармын», – дип уйлады ул.

– Мин үзем дә авызларыннан тере саескан очыручыларны яратмыйм, – диде Газинур җитди итеп. – Тылда, билгеле, гаскәр җитәрлек. Ләкин оборонаны безнең үзебезгә өзәргә туры киләчәк.

– Точно. Шул турыда сөйләргә дә кирәк, – диде баягы ефрейтор. – Безнең сугыш эшендәге яңалыклар турында сөйләгез, иптәш сержант. Мәктәптә сезгә өйрәткәннәрдер.

– Әйе, өйрәттеләр, – диде Газинур. Ул үзенең белемен уртаклашырга биш куллап әзер иде.

Солдатлар аны зур игътибар белән тыңладылар. Хәтта Гордеев та якынрак күчеп утырды, артык йокымсырамады.

Шулай Газинурның командир булып яшәү дәвере башланды. Шул ук көнне Газинур, бер буш ара табып, үзенең элекке ротасына барды. Стариков юк иде, аның кече лейтенантлар курсына җибәрелгәнлеген әйттеләр.

## 25

Күз ачкысыз буран котыра. Җир белән күкне бергә тоташтырган соры рәшә эчендә өермә кебек бөтерелүче бураннан башка һични күренми, әмма тирә-як мең төрле тавыш чыгарып улый, үкерә, сызгыра, елый. Шул ачы

сызгырулардан, бөтен яктан ишелгән кардан башка дөньяда бернәрсә дә калмаган шикелле. Ләкин чынында, шушы коточкыч буран эчендә күп булса өч йөз, дүрт йөз метрда, ә кайбер урыннарда йөз, ике йөз метрда бер-берсенең бугазына ябышырга әзер торган ике фронт яшеренгән, ә алар арасындагы солдатлар телендә «битараф» дип йөртелгән җирдә бернигә карамыйча, берни белән исәпләшмичә, шул коточкыч буранның туган балалары кебек, ак халатлы сугышчылар үрмәләп-шуышып йөриләр. Бер караганда, алар давыл вакытындагы акчарлакларга, икенче караганда, бозлар арасындагы ак аюларга охшыйлар. Менә аларның алдан барганы, туктап, башын күтәрде. Аның башлыгына гына түгел, кашларына да, керфекләренә дә кар ябышкан, бәзе юка боз белән капланган, әйтерсең битлек кигән. Суык бик көчле. Сугышчының маскхалаты салкынга эленгән юеш кер кебек каткан, теләсәң аны, юка тактаны сындырган кебек, вак-вак кисәкләргә сындыргаларга да мөмкин.

Кар эченнән иң алда шуышып барган бу сугышчы отделение командиры сержант Газинур Гафиятуллин иде. Ул, артына борылып, үзенеке кебек үк ак, туңган халатлы иптәшләренә кул изәде. Алар тагын да алгарак шуыштылар һәм, көтмәгәндә, бик нечкә тимерчыбыктан ясалган киртәгә – Бруно спираленә килеп төртелделәр. Кичә бу киртә биредә юк иде, димәк, аны төнлә куйганнар. Хәзер һичкичекмәстән аның каян кая кадәр сузылганын билгеләргә кирәк. Газинур үзенең отделениесенең бер өлеше белән спираль буйлап уң якка, Комлев берничә сугышчы белән сулга шуышты.

Укчы ротадан разведкага җибәрелгән Газинур отделениесенең бурычы һөҗүм алдыннан дошман оборонасының характерын ачыклау иде. Хәзер инде һөҗүмне берәү дә киләчәк айлар вакыйгасы итеп күз алдына китерми, ул – шушы якын көннәрнең эше. Шуңа күрә күз ачкысыз бураннарда да сугышчылар җылы землянкаларда утырмыйлар. Алар өлкән лейтенант Григорьянның «Арагац бөркетләре» белән бергә дошманның алгы сызыгын көн-төн айкыйлар.

«Җитәр, оборонада күп яттык, югыйсә һөҗүм итүче иптәшләр алдында оят», – дип сөйләнәләр иде алар. Чыннан да, бу айларда Днепр буйлары Жлобиннан Херсонгача дошманнан тулысынча чистартылды инде. Уң як Украинаның бик күп өлкәләре алынды, Корсунь-Шевченковский районында Кызыл Армия гитлерчыларга икен-

че Сталинград ясады. Ленинград дошман блокадасыннан тулысынча азат ителде, Совет гаскәрләре Эстония җиренә аяк бастылар. Белоруссиядән дошманны массовый төстә куу башланды. Икенче Балтыйк буе фронты (Газинурларның дивизиясе хәзер, фронтларның исемнәре алмашыну аркасында, Икенче Балтыйк буе фронтына керә иде), Ленинград фронты белән берлектә, Дно юнәлешендә һөҗүм башлады. Дно инде алынган дип тә сөйлиләр. Барысы да Верховный Башкомандующийның приказын көтәләр. Ә фронт бер канаты белән җилпендеме, аның икенче канаты да селкенмичә калмый.

Газинурның отделениесе разведкадан кайтты. Траншеяда аны рота командиры капитан Бушуев үзе каршы алды. Газинур кыска итеп разведканың нәтиҗәсе турында хәбәр итте. Бруно спирале яңалык иде. Капитан планшетыннан картасын чыгарды, ләкин коточкыч буранда картада берәр нәрсә билгеләү мөмкин түгел иде.

– Әйдә, землянкага керик, – диде Бушуев.

Землянкада ул Газинур отделениесе тапкан яңа тоткарлыкны картасында билгеләп куйды, шул турыда комбатка хәбәр итәр өчен телефон трубкасын алды. Комбат Газинур белән икесен үз янына чакырды.

Менә алар гвардия майоры Ермилов алдында басып торалар. Комбат үзенең чуарланып беткән картасына Газинур тапкан киртәне дә төшереп куйды. Мәсьәләне ачыклый торган берничә сорау бирде, үзенең зәңгәрсу күзләре белән Газинурга карап алды. Шул вакытта ишек ачылды, тәмам карга баткан Григорьян кызу-кызу атлап килеп керде. Ак кием аның каратутлы йөзен, зур кара күзләрен аеруча ачыклап күрсәтә иде. Ул, Газинурга елмаеп, комбат янына узды. Комбат аңа картага төшерелгән спиральне күрсәтте.

– Спираль? Кайдан килгән анда спираль?! – диде Григорьян. – Мин кичә генә бөтен җирне айкап чыктым. Берни юк иде.

Барысы да Газинурга карадылар. Ул, каушамыйча, нык тавыш белән җавап бирде.

– Кичә мин дә анда булдым. Кичә юк иде, бүген бар.

– Яхшы, тикшерербез, – диде Григорьян, үзенең картасына билге ясап.

Бушуев белән Ермилов бер-берсенә карашып көлемсерәделәр. Разведчик үзеннән уздырганны яратмый иде.

Газинурны ял итәргә кайтарып җибәрделәр. Ләкин ул ял итү турында уйламый да иде. Җылы землянкада эреп

йомшарган халатының дымлы җиңе белән маңгай тирен сөртте дә разведкага бармый калган сугышчылары янына борылды. Алар траншеяларга, аралашу юлларына тулган карны көриләр иде. Инде бер атна буенча котырган буран солдатларның теңкәләренә тиеп бетте.

– Буламы, егетләр? – дип кычкырды Газинур күңелле генә.

Кайсыдыр буранның ата-анасын искә төшереп сүгенә башлады.

– Нәрсә сүгенәсең, Гордеев, арыдыңмы әллә? – диде Газинур. – Бар, бераз ял ит.

Газинур аның кулыннан көрәген алып кар көри башлады. Сугышчылар яңа сержантның эш яратуын бик тиз күреп алдылар, ләкин Газинурның йомшак күңелле булуы, солдатны урынсызга кызгануы күпләргә ошап бетмәде. Элекке сержант булса, бу ялкау Гордеевны тәмәке тартырга җибәрер идеме? Юк, башта ул аның җан тирен сыгар иде, ә командир кушуыннан башка да тырышып эшләүчеләрне онытмас иде. Газинур гүя аларны күрми, дөресрәге, кеше яхшы эшләргә тиеш, мактасыннар өчен түгел, ә шулай кирәк булганга яхшы эшләргә тиеш дип саный иде.

Буран эченнән капитан Бушуев килеп чыкты, бераз читтәрәк туктап, Газинурның кар көрәвенә карап тора башлады. Газинур аны күрмәде, һаман эшли бирде. Капитанның йөзе кырысланганнан-кырыслана барды, кашлары җыерылды.

– Сержант, нигә үзегез эшлисез? Кайда сугышчыгыз? – дип сорады ул ахырда. Аның тавышы коры, каты иде.

– Гордеев, арыдым, ди, иптәш капитан, – диде Газинур, беркатлы елмаеп. – Мин аны ял итәргә җибәрдем.

– Ә сез, разведкадан соң, арымадыгызмы? – дип, тагын да басым ясый төшебрәк сорады капитан.

– Юк, арымадым, иптәш капитан.

– Ә Гордеев ни өчен арыган дип уйлыйсыз?

Газинур үзенең хатасын сизеп алды, эндәшмәде.

– Бәлки, сез аңа мич башына ук менеп ятарга кушарсыз? Ул аңа да каршы килмәс. – Капитан кырт борылды, аннары, кире әйләнеп: – Хәзер үк Гордеевны эшкә кушыгыз, ә үзегез минем янга килегез, – дип китеп барды.

Тирән траншеяда басып, котырынган буранга караган Газинур, көрәк сабына таянып, бер минут чамасы уйланып торды, башын кашыды. Бары тик хәзер генә ул үзенең гадәттән тыш арыганлыгын сизде. Ул күзләрен йомды, йөзе шунда ук юка боз белән капланды.

Отделение командиры булып килгәннән соң, Газинурга карата капитан артык каты кылана башлады. Ул гүя үзенең элекке танышлыгын бөтенләй онытты. Газинур пульротада хезмәт иткәндә, Бушуев аның белән очрашса, җәелеп сөйләшә, чәй белән дә сыйлый иде. Ә хәзер боларның берсе дә юк. Киресенчә, бүтән отделение командирларына караганда да Бушуев Газинурдан күбрәк таләп итә, кимчелекләре өчен катырак кыздыра.

Газинур, бозланып ябышкан керфекләрен бармагы белән эретеп, күзен ачты. Буран чак кына басыла, җил чак кына әкренәя төшкән кебек.

Газинур көрәгеп карга кадады да землянкага китте. Гордеев, аркасын җылы мичкә терәп, йокымсырап утыра иде. Беренче тапкыр Газинурның ачуы килде, каты итеп кычкырды:

– Кызылармеец Гордеев!

Кызылармеец күзләрен ачты, ләкин урыныннан тормады.

– Аякка басыгыз! – диде Газинур кискен генә. – Сезнең белән командир сөйләшә! Барыгыз, кар көрәгез. Тиз булыгыз. Әгәр начар эшләсәгез, наряд алачаксыз.

Йомшак күңелле сержантның кинәттән генә болай каты бәрелүенә гаҗәпләнгән, бераз шүрли дә төшкән Гордеев, уктай атылып, землянкадан чыгып китте.

Газинур тәмәке кабызды, дулкынланып тарта башлады. Капитан янына барырга кирәк. Сөйләшүнең «ачы» буласын Газинур алдан ук сизенә, үз-үзенә ачуы килә. «Командир булу өчен погон тагу гына җитми икән шул», – дип уйлады ул, аннары, авыр гына кузгалып, ишеккә юнәлде.

Бушуев землянкада, чишенмичә, ак комбинезоннан утыра иде. Тик башлыгын гына артка ташлап, бүреген салган. Аксыл чәчләре, бөдрәләнеп, марля белән уралган киң маңгаена төшкән.

Капитан үзенең связноена чыгып торырга кушты. Газинур идән уртасында смирно баскан килеш торды. Бушуев эндәшмәде. Ул кулындагы шырпы белән өстәл тактасына сызгалый, аска карый. Газинур сагайды.

– Сугышчыларыгыздан кемнәргә рәхмәт белдердегез? – дип кинәт сорады капитан, Газинурга туры карап.

– Берәүгә дә, иптәш капитан, – диде Газинур әкрен генә.

– Әллә сезнең сугышчыларыгыз барысы да Гордеев кебек начар эшлиләрме?

– Юк, алар начар эшләми, иптәш капитан.

– Димәк, алар рәхмәткә лаеклы?

Газинур эндәшмәде. Капитан урыныннан торды. Аннары, һәр сүзенә басым ясый-ясый, сөйли башлады:

– Менә бер атна инде коточкыч буран дулый. Кем белә, бәлки, шушы буран вакытлыча безнең һөҗүмне дә тоткарлап тора торгандыр, һөҗүмгә һәр минут әзер булып тору өчен сугышчылар көн-төн кар көриләр, ә отделение командиры аларга рәхмәт әйтергә дә кирәк дип санамый. Шәп командир! Сез солдат машина дип уйлыйсызмы әллә? Юк, машина түгел ул! Кеше! Сез алар белән сугышка керәчәксез. Әгәр хәзер, оборонада, алар турында кайгырта белмәсәгез, ут эчендә, һөҗүм вакытында ничек кайгыртырсыз? Әллә барысы да үзеннән-үзе эшләнер дип уйлыйсызмы? Янәсе, без шундый батырлар, дошманны бүрек белән генә бәреп егарбыз! Юк, җиңүне оештырырга, түбәннән, отделениедән оештыра башларга кирәк. Отделениесе нык булган взвод, взводы нык булган рота, ротасы нык булган батальон гына җиңүгә ирешә ала.

Капитан, кулларын артына куеп, идән буйлап бер әйләнде дә, Газинур алдында туктап, тагын сөйли башлады:

– Сез үзегез барлык сугышчыларыгыздан күбрәк чабасыз, күбрәк эшлисез. Бу яхшы, әлбәттә. Сугышчылар ак куллы командирны яратмыйлар. Ләкин Ватан сезне командир итеп билгеләде, шуңа күрә сезнең командир икәнлегегезне онытырга һичбер хакыгыз юк. Сез бит берүзегез барыбер бөтен эшне эшләп бетерә алмыйсыз. Бигрәк тә һөҗүмдә. Ә безгә иң элек һөҗүмне күз алдында тотарга кирәк. – Капитан тагын бераз йөренеп алды, аннары, кырт борылып, өстәде: – Командир җитәкчелек итәргә тиеш! Командир үзенең сугышчылары турында туктаусыз уйларга, кайгыртырга тиеш! Бу аның иң беренче эше!

Газинур, зур кара күзләре белән Бушуевка туры карап, эндәшмичә тыңлады. Тик сулышы гына ешайды, борын яфраклары селкенә башладылар.

– Барыгыз, ял итегез. Төнлә сез миңа кирәк булачаксыз!

Газинур землянкадан чыкты, бер уч кар алып, тирләгән маңгаена куйды. «Шәп сабак булды әле бу мин юләргә».

Газинур, отделениесенә тиешле боерыкларын биреп, җылы сәкегә менеп ятты, күзен йомуга йоклап та китте.

Икенче көнне иртән буран бөтенләй туктады. Күктә кояш ялтырый, ә тирә-як рәхәт җиңеллек, саф яктылык белән тулган. Бураннан соң һава да, гадәттәгечә, җылытып җибәргән, хәтта тирән кар белән капланган кырлар өстеннән яз сулышы бөркелеп килгәндәй була. «Колхозда хәзер инде язгы чәчүгә әзерләнәләр...» – дип уйлап алды Газинур, отделениесенә беркетелгән окопларны карап йөри-йөри. Кар һәр җирдә чистартылган, бруствер өсләре әйбәтләп маскировкаланган иде.

Газинур отделениесен сафка тезде, яхшы эшләгән сугышчыларына рәхмәт белдерде. Гордеевка исә, ялкаулыгы өчен, строй алдында кисәтү ясады. Шул эшләрне башкарып кына бетергән иде, Газинурны рота командиры янына чакырдылар. «Тагын бер-бер ялгышым булдымы икәнни?» – дип уйлый-уйлый, Газинур капитан землянкасына ашыкты.

Капитан, чишенеп, гимнастеркадан гына утыра иде. Аның йөзе дә кичәге кебек сүрән түгел. Газинур килеп кергәч, көлемсери төшеп:

– Концерт тыңлыйсыгыз киләме? – дип сорады.

Газинур аңлап җиткермәде.

– Нигә эндәшмисез? Әллә концерт яратмыйсызмы? – дип сорады капитан.

Полкка артистлар килгән икән. Комбат ротадан өч кеше җибәрергә кушкан. Шул өч кешенең берсе итеп капитан сержант Гафиятуллинны билгеләде. Ул Газинурның җырчы икәнен дә, җыр яратуын да бик яхшы белә иде. Ул үзенең сугышчан сержантын мондый күңелле кичәгә җибәрү мөмкинлеге тууга чын күңеленнән шатланды.

Ниһаять, Газинур барысын да төшенде, бөтен йөзе белән елмаеп:

– Башка керде, иптәш капитан! – диде. – Хәзер чаңгыга басам да очам. Җыр булса, миңа башка берни дә кирәкми, иптәш капитан.

Газинур ялт итеп чыгып китте. Бушуев аның артыннан елмаеп карап калды.

## 26

Мамыктай ак кар баскан зур бакча уртасында ашыгыч кулдан гына эшләнгән сәхнә каршысына, ярым түгәрәк булып, бик күп сугышчылар тезелгән. Аларның муеннарында автомат, бер куллары белән чаңгыларын

кочаклаганнар. Иң алгы рәттә сержант Ильченко, Буранбай, разведчик старшина Зәбиров, Гафиятуллин басканнар. Газинур, башкалар кебек үк, ак комбинезонының башлыгын артка ташлаган.

Сәхнәгә өстенә погонсыз тун, башына колакчын бүрек кигән урта яшьләрдәге бер кеше чыкты. Ул үзенең тере күзләре белән сугышчыларга, аннары ап-ак агачларга, зәп-зәңгәр күккә карап алды да, бик дәртле яңгыраган тавыш белән:

– Сугышчы һәм командир иптәшләр! Концертыбызны ачып җибәрергә рөхсәт итегез, – диде.

Беренче номер итеп, «Гитлер – күрәзәче» дигән сатирик шигырь укыды. Сугышчылар, эчләре катып, бик озак көлделәр, бакчаны яңгыратып кул чаптылар. Аннары сәхнәгә сөяк телләре җем-җем итеп торган зур баян тотып баянист чыкты, «Фронт янындагы урманда» көен башкарды. Газинур терсәге белән Буранбайга төртеп алды. Буранбай ике күзен дүрт итеп баянга карап тора иде.

Кара хәтфә пальтолы, ак мамык шәлле яшь кенә артистканы сугышчылар кул чабып каршы алдылар. Аның исемен ишеткәч, Газинур үз колакларына үзе ышанмады. Чыннан да, бу улмы? Аларның кунак кызы Фатыймамы? Әйе, ул. Күз карашлары, башын кыйшайта төшеп тотулары, елмаюлары – барысы да аныкы. Әнә ул сугышчыларга башын иде, үзеннән алда чыгыш ясаган артистлар кебек үк, башта сугышчыларга, аннары ботакларын кар баскан агачларга карап алды. Күрәсең, тамаша залының сәерлеге артистларга да гаҗәп тоела иде. Менә ул тагын сугышчыларга борылды. Сержантның йөрәге сулкылдап китте: «Миңа карый ич, – дип уйлады ул, – әллә таныдымы икән?» Юк, танымады, ахрысы, әнә ул Ильченкога, Зәбировка, аларның баш өстеннән арткы рәтләргә карый. Аннары тагын, аяз күктә йөзгән тау-тау ак болытларга карап, бераз тын торды да гармунчыга баш какты. Солдатларның сагышлы йөрәкләренә май җиледәй кагылып, беренче аккордлар яңгырады.

Фатыйма русча, украинча, белорусча җырлады, ниһаять, концертны алып баручы:

– Татар халык көе «Шөгер», – диде.

Шуның артыннан ук гармунчы Газинурга бала чактан ук кай ягы беләндер таныш булган көйне сыздырып җибәрде. Ләкин салкын һавада, ап-ак бакча эчендә бу җыр авыл клубларындагыча түгел, ә ничектер башкача, үзенә бертөрле кырыс матурлык белән яңгырады.

Шөгерләргә барам әле,
Шөгер суы тәмлегә.
Бир кулыңны, мин дә бирәм
Аерылмаска мәңгегә.

Бу җыр Газинурның туган як җыры иде. Аның биредә, фронт сызыгында яңгыравы да, Фатыйманың һич тә уйламаганда, көтмәгәндә монда килеп чыгуы да шулкадәр гаҗәп иде, Газинур әле һаман да бу өнме-төшме дип ышана алмый торды. Ул Фатыйманың һәр җырыннан соң бөтен кешедән көчлерәк кул чапты, бөтен кешедән көчлерәк бис кычкырды. Аның бу ташып торган шатлыгына хәтта полк командиры подполковник Кремнев та игътибар итте, янындагы офицерларга нидер әйтеп, башы белән Газинурга таба изәп күрсәтте.

Концерт беткәч, Газинур иптәшләренә, мине бераз көтегез, дип әйтте дә, чаңгыларын кар өстенә ташлап, сәхнә янына омтылды. Фатыйма офицерлар арасында басып тора, нидер сөйли иде. Газинур, алар янына берничә адым җитмичә туктап, полк командирына мөрәҗәгать итте, иптәш артистка белән сөйләшергә рөхсәт сорады. Фатыйма аңа тиз генә борылып карады, ләкин ак комбинезонлы, күкрәгенә автомат аскан, янып торган кара күзле егетне танымады.

– Йә, йә, Гафиятуллин, якташыңны очратуга сөенәсеңме? – диде подполковник, үзе таныштырыр өчен кызга борылды. Ләкин таныштырып торуның кирәге булмады.

– Исәнмесез, Фатыйма, – диде Газинур татарча. – Танымыйсызмы әллә? Мин Газинур булам.

– Газинур?! Газинур, бу синме? – диде Фатыйма, тиз генә аңа таба атлап.

Подполковник Кремнев Газинурның да, Фатыйманың да сүзләрен төшенмәде, әмма сержантның тавышындагы шатлыктан, артистканың аңа таба җитез омтылуыннан һәм сугышчының маңгаеннан үбеп, кулын каты итеп кысуыннан ул аларның иске танышлар икәнен төшенде.

Фатыйма, әле һаман да танымаган кебек, Газинурга карый, үзе һаман бер үк сүзне кабатлый иде:

– Күпме вакыт фронтларда йөрим, бер танышымны очратканым юк иде... Менә сине очраттым. Нинди бәхет! Юк, Газинур, бу чыннан да синме? Нинди шатлык. Һай, ничек үзгәргәнсең. Танырлык та түгел бит сине.

– Ә мин сезне күргәч үк таныдым. Сез бөтенләй үзгәрмәгәнсез. Теге вакытта Гөлләр белән безгә килгәндәгечә.

Фатыйманың күз алдына кечкенә генә «Красногвардеец» колхозы, Гөлләрнең колхозчылар алдында доклад сөйләве, клубта җырлап-биюләр, Газинурны леспромхозга озату минутлары килеп басты. Еракта, бик еракта калды инде ул көннәр. Хәзер инде Гөлләр дә башка – бала анасы, Фатыйма да әүвәлге Фатыйма түгел. Шулай да ул көннәрдән хәтердә ниндидер якты, кояшлы бер тойгы сакланып калган. Бервакытны Фатыйма фронтларда йөреп Казанга кайткач, Гөлләр хәтта: «Безнең танышларны бер җирдә дә очратмадыңмы?» – дип сораштырган иде. Ул чакта Фатыйма: «Фронт бик зур бит ул, кайдан очратасың», – дип әйткән иде.

– Ничек яшисең соң, Газинур? Кайда хезмәт итәсең? – дип сорады Фатыйма.

Газинур елмайды:

– Алгы сызыкта эшлим, ал да гөл яшим.

– Син һаман да шундый ук шаян икәнсең, – диде Фатыйма. – Алгы сызык еракмы? Мин анда барырга теләр идем. Подполковниктан сорыйм әле...

Фатыйма сүзләрен дә әйтеп бетерергә өлгермәде, алгы сызыкта пулеметлар тыкылдарга тотынды. Атыш ничектер кинәт башланып, берьюлы көчәеп китте.

– Бу нәрсә, һөҗүмме? – дип сорады Фатыйма подполковниктан.

Кремнев, елмаеп:

– Землянкага рәхим итегез, – диде.

Фатыйма Газинур белән саубуллаша башлады. Ләкин шул чакта Газинур якында гына берүзе басып торган старшина Зәбировны күрде. Аның йөрәк ярасын белгән Газинур аны кызганып куйды.

– Фатыйма, – диде ул тиз генә, – мин сезне бер «Арагац бөркете» белән таныштырыйм әле. Полкыбызның иң кыю разведчикларыннан берсе – старшина Исхак Зәбиров.

Зәбиров тиз генә Фатыйма янына килде, каты итеп аның кулын кысты.

– Без инде күптәнге танышлар, – диде Зәбиров, көлемсерәп. – Хәтерлисезме «Красногвардеец»ны? Мин сезгә гармун уйнаган идем.

– Сез?! Сез шул гармунчы егетме?

– Хәзер инде минем һөнәрем башка.

Фатыйма, аның күзләренә карагач, нигәдер сискәнеп куйды. Киң җилкәле, озын буйлы, ачык, матур йөзле бу егеткә ул тагын бер тапкыр яшертен генә карап алды. Кайчандыр бала вакытта аңа күрше карчыгы уттан ярал-

ган егет турында әкият сөйләгән иде. Ул егет кемнең дә булса күзенә бер караса, ул кешенең йөрәгенә сүнми торган ут кабына, имеш. Зәбиров Фатыймага ни өчендер нәкъ менә шундый, уттан яралган егет булып тоелды.

– Хәзер сез кая китәсез, иптәшләр? – дип сорады Фатыйма, дулкынланмаска тырышып.

– Безнең урын билгеле инде, – диде Газинур, алгы сызыкка таба баш изәп. – Хушыгыз, Фатыйма. Гөлләргә бик күп сәлам әйтегез. Илнең барлык картына-яшенә сәлам тапшырыгыз.

Кыз Газинурның кулын кысты.

– Хуш, Газинур, исән бул. Илдә очрашырга, озаклап сөйләшергә насыйп булсын. – Фатыйма старшинага да кулын сузды: – Сез дә, иптәш Зәбиров, исән булыгыз, сезнең белән дә очрашырга насыйп булсын.

– Без Берлинны алганда, Берлинга килегез, Фатыйма. Җиңү турында безгә җырлар җырларсыз, – диде старшина.

– Һичшиксез, килергә тырышырмын. Исән булыгыз!

Сугышчылар честь бирделәр дә, чаңгыларына басып, китеп бардылар. Фатыйма, алар артыннан карап, кулъяулыгын болгады, ә күңелендә үзенә дә аңлашылмый торган ниндидер тирән сагыш калды.

## 27

Менә ул көн дә килеп җитте. Дивизия һөҗүмгә күчү турында приказ алды.

Кар баскан, боз белән чылбырланган кышкы Иделгә карасаң, ул бик юаш, бик сабыр, көчсез кебек күренә. Ул үзенең кышкы йокысыннан һичкайчан уянмас кебек. Ләкин яз килә, карлар эри, меңләгән гөрләвекләр челтерәп ага башлый, җирләр ачыла, язның беренче котлаучылары – умырзаялар баш күтәрәләр. Менә шул чакта, томанлы, җылы, язгы көннәрнең берсендә, карт Идел үзенең кышкы авыр йокысыннан уяна. Башта ул үзенең боз юрганы астында икенче ягына әйләнгәндәй була, әкрен генә киерелеп куя, әмма аның бу киерелүеннән кышкы көннәрдә авыр йөк машиналары узганда да исе китмичә түзә торган калын бозлар шартлап ярыла, боз өстенә сары су җәелә. Аннары килеп җитә шундый бер көн, бөек Идел, ярларына сыеша алмыйча, үзәннәрне су астында калдырып, диңгез кебек җәелеп, күрелмәгән бер көч, күрелмәгән бер дәһшәт белән ташып ага башлый...

Һөҗүмгә күчәргә әзерләнүче гаскәр нәкъ менә шушы язгы Иделне хәтерләтә. Приказ бирелгән, ләкин аны үти башлар минут килеп җитмәгән әле. Шул минутны көтеп, хәтсез күп траншеяларда, блиндажларда, землянкаларда, урманнарда, әрәмәлекләрдә, чокырларда, якын-тирәдәге авылларда яшеренгән гаскәр тавыш-тынсыз гына утыра. Язгы кояшка башларын кыйшайта төшеп ара-тирә карап куйгалаган солдатлар йә тәмәке тарталар, йә тегене-моны сөйләшеп алалар. Ут позицияләренә урнаштырылган, чит күздән саклар өчен агач ботаклары яки ак җәтмәләр белән капланган туплар, танклар да бик юаш күренәләр. Ләкин һөҗүм минуты якынлаша барган саен, сугышчыларның эчке киеренкелеге дә үзеннән-үзе арта бара, тәмәкеләр ешрак төреләә, дошман ягына юнәлгән карашлар үткенләнә, мәҗбүри хәрәкәтсезлек солдатларны газаплый башлый, җилдән, салкыннан яргаланып беткән солдат иреннәре:

– Тизрәк башлансын иде! – дип пышылдыйлар.

Ләкин бу минутта инде, командирның корыч ихтыярына, акылына буйсынып, якындагы аэродромнардан самолетлар күтәрелә, артиллеристлар туплары өстендәге чыбык-чабыкларны алып ташлыйлар, туп авызларына кидерелгән чехолларны салдыралар. Туп көпшәләре әкрен генә күтәрелә башлый. Танкистлар, люкларын ябып, танкларына утыралар...

Ә тирә-якта яз сулышы. Иртәнге соры томан эченнән март кояшы тантана белән күтәрелә. Яктылык минут саен арта бара, күңелләр, иксез-чиксез киңлекне тоеп, каядыр җилкенәләр. Җил әле салкын, әмма кар инде салкын түгел шикелле. Кичә, ике фронт арасында үсеп торган агачлар башында, кара каргалар күренде. Ә карга килсә – кар китә.

Газинур партия җыелышыннан кайтты. Бу аз сүзле, кыска җыелыш аны чиксез дулкынландырган иде. Зур, җитди һөҗүм алдыннан партия җыелышына аның беренче катнашуы иде. Бу җыелышта ул партиянең бер җан, бер тән белән сулавын, бергә тупланган куәтле, какшамас көч икәнен тагын да тирәнрәк аңлады.

Җыелышта Газинур парторгтан күзен алмыйча, аның кайнар сүзләрен, үсмер чагында, ерак «Красногвардеец»-та Гали абзыйның ил батырлары турындагы тылсымлы хикәяләрен тыңлагандай, йотлыгып тыңлап утырды. Парторгның ябык йөзе эчке нурдан рухланган, яктырган, ә күкрәктән чыккан тавышында тирән ышаныч, ниндидер тантана яңгырый иде. «Нигә ул шундый? – дип

уйлап алды Газинур, кинәт аның күз алдына күпер өстендә шнурга ут кабызучы яралы парторг килеп басты. – Соловеев ул чагында да шундый булгандыр. Үлем алдында да калтырамагандыр».

Сугышчылар траншеяда җыелганнар, һөҗүмгә чакыручы листовкаларны укыйлар иде. Партия җыелышыннан кайтып килүче командирларын күргәч, алар аңа таба борылдылар. Сержантның күзләре ялтырый иде.

– Башлыйбыз, иптәшләр! – дип кычкырды Газинур. – Башлыйбыз! – диде ул икенче тапкыр һәм янында басып торган пулеметчы кече сержант Комлевның иңбашына кулын салды. – Дуслар! Безгә фрицларны Балтыйк диңгезенә балыкларга азыкка ташларга приказ бар... Ярдәмгә танклар, үзйөрешле артиллерия полкы, «иптап», «катюша»лар килә!

Солдатлар бер-берсенә карап алдылар. Газинур инде шактый күтәрелгән кояшка күз кысып карады:

– Иртәнге сәгать – хәерле сәгать, диләр. Хәерле сәгатьтә башлыйбыз, иптәшләр. Карагыз: тирә-якта яз бит! Сабан туйлары якын... – Газинур ярты сүздә тукталып калды. Мөгаен, ул күңеленә вакытсыз килгән сагыну хисләрен куарга теләгәндер. Аннары кыю рәвештә башын болгап алды. – Юллар бозылып өлгергәнче, иптәшләр, безгә бу сазлыклардан, әрәмәлекләрдән чыгарга кирәк. Яз көне Ловать бик хәтәр ташый, диләр. Ә көнбатышкарак киткәч, туфрак нык, анда яз көне дә туктамыйча алга барырга була.

– Сержант, кая таба һөҗүм итәбез? – дип сорады сугышчыларның берсе.

Газинур елмаеп җавап бирде:

– Гомуми юнәлеш, иптәшләр, бер – Берлин. Ә ротаның, взводның, отделениенең бурычлары турында бераз соңрак, командирдан сугышчан боерык алгач әйтермен.

– Иптәш сержант, һөҗүмдә иң мөһиме нәрсә? – дип сорады бер яшь солдат.

Сугышчылар аны төрле яктан оялта башладылар.

– Менә сиңа мә! – диде Комлев. – Иптәш сержант безгә килгәннән бирле шул турыда сөйләп торды ич. Син колакларыңа мамык тыгып утырдыңмы әллә?

– Сабыр ит, Комлев, – диде Газинур. – Яхшы киңәшне тагын бер тапкыр кабатласаң да зарар итмәс, һөҗүмдә иң мөһиме – тизлек! Дошманга тын алырга, аңга килергә ирек бирмәскә кирәк. Миңгерәүләнгән дошманны кыйнавы ансат, шулай бит? Аннары курыкмаска кирәк. Онытмагыз, куркак көн дә үлә, батыр бер генә үлә...

Газинур тагын нидер әйтергә җыенган иде, траншея буйлап йөгереп узып барган взвод командиры связное:

– Отделение командирлары, взвод командирына! – дип кычкырды.

Газинур, урынбасары кече сержант Комлевка алгы сызыкны җентекләп күзәтеп торырга кушып, взвод командиры янына йөгереп китте.

Взвод командиры траншеяда баскан, кулын каш өстенә куеп, алгы сызыкны күзәтә иде.

– Барыгыз дамы? – дип сорады ул, як-ягына каранмыйча.

– Барыбыз да, – диделәр сержантлар.

– Сугышчан боерыкны тыңлагыз, – диде ул, алгы сызыктан күзен алмыйча, һәм ротаның, взводның, аннары һәр отделениенең бурычлары турында сөйләп китте.

Әйләнә-тирә үтә якты, үтә тын, гаҗәеп чиста иде. Кинәт коточкыч үкерү ишетелде, шуның артыннан ук дошман позицияләре турысында вулкан аткан шикелле булды, һавага кара төтен, туфрак стенасы күтәрелде, тирә-як караңгыланып китте. Ул арада траншеядагы солдатларның баш өстеннән, утлы койрыкларын сузып, яңадан-яңа реактив снарядлар сызгырып үтә башлады, ачулы үкереп самолетлар очты. Җир ыңгырашырга, селкенергә, үкерергә тотынды.

Артиллерия уты көчәйгәннән-көчәя барды. Кайчагында ут валы дошман оборонасының эченә үк тәгәри, аннары, әүвәлгедән күп мәртәбә куәтлерәк көч белән, яңадан алгы сызык өстенә ишелеп төшә. Зур-зур агачлар, тамырлары белән йолкынып, туфрак, кар, бүрәнә кисәкләре белән бергә һавага очалар. Траншеялардагы солдатлар, «сугыш алласы»ның эшенә сокланып, бер-берсенә каш сикертеп куялар, баш бармакларын күрсәтәләр. Моңарчы алар күп һөҗүмнәрдә катнашканнар, күп тапкырлар үзебезнең дә, дошманның да артиллерия әзерлеген күргәннәр. Ләкин бүгенге канонада аларга барысыннан да өстен булып тоела.

Ун минут, унбиш, егерме минут үтә. «Сугыш алласы» һаман үкерә. Ярты сәгать үтә, артиллерия давылының тынарга исәбе дә юк.

Газинур, бөтен гәүдәсе белән алга омтылып, каскасын җилкә чокырына этеп, алга карый. Хәзер инде сүз әйтсәң дә ишетелерлек түгел. Шул чакта кемдер аның аркасына җиңелчә генә сукты, әйләнеп караса, полк разведчиклары узып баралар. Аның аркасына сугучы –

старшина Зәбиров. Ул аны кочты да аргы башка таба йөгереп китте.

Газинур секундларны саный башлады. Менә хәзер артиллерия атудан туктаячак. Менә хәзер бруствер өстенә чыгарга кирәк... Ләкин нindидер көч аны траншеяга кадаклаган кебек. Тән корыч калканнан да ышанычлырак траншеядан аерылырга теләми.

Атака сигналы – һавага кызыл ракеталар оча. Әмма ни өчен берәү дә траншеядан чыкмый? Газинур чак кына калтырап торган бармакларын карга батыра. Тагын бер секунд, юк, бер секунд түгел, секудның уннан бер өлеше үтә. Газинур, үзен траншеяга кадаклаган көчне җиңеп, траншея өстенә сикереп менә. Аның белән бер үк вакытта бруствер өстенә йөзләрчә кешеләр сикереп менделәр, алга ташландылар. Газинур үзенең отделениесе белән тирән кар эченнән алга йөгерде. Бераздан ул тирә-ягына каранды, һәр ике ягында, күз күреме җиткән арада меңнәрчә сугышчылар кар ерып алга баралар иде.

– Идел кузгалды! – дип кычкырды Газинур, ләкин көчле шау-шудан аның тавышын үзеннән башка беркем дә ишетмәде.

Гитлерчылар ут ачтылар. Кемнәрнеңдер ыңгырашуы ишетелде, кемнәрдер егылып калды. Ләкин берәү дә туктамады.

Бушуевның ротасы дошман траншеяларына бәреп керде, җимерелми калган дзот төпләрендә, блиндажларда, землянкаларда кул сугышлары башланды. Беренче траншеяларны алганнан соң, рота дошманның икенче траншеяларына ыргылды. Гитлерчыларның каршылык күрсәтүе тагын да көчәйде. Сугышчылар икенче траншеяны барышлый ук ала алмыйча, кар өстенә ятарга мәҗбүр булдылар. Алга танклар үтеп китте. Пехотаның һәм танкларның бергәләп ясаган ударыннан соң, дошманның икенче траншеясы да алынды. Күп кенә гитлерчылар коралларын ташлый, кулларын күтәрә башладылар. Күзләре атылып чыгарга җитешкән, шашкан кыяфәтле озын бер фашистны Газинур үзе плен алды. Гитлерчы белән Газинур тар траншеяда очраштылар. Борылыштан кинәт килеп чыккан ак киемле рус солдатын күргәч, фашист озын, ябык кулларын күтәрде. Ул Газинурдан буйга шактый озын иде. Кинәт ул, Газинур автоматының көпшәсеннән тотып, читкә борды, суырып алмакчы булды. Ул, мөгаен, бу уртачарак буйлы рус солдаты белән эшне бик тиз бетерермен дип уйлаган булгандыр. Ләкин Газинур аның

корсагына тибеп җибәрде, фашист, авыртуга чыдый алмыйча, җиргә чүгәләде.

– Тор, кабахәт, хенде хох! – дип кычкырды Газинур, автоматын дошманы күкрәгенә төзәп. Миңгерәүләнгән гитлерчы, урыныннан тормас борын ук, кулларын күтәрде.

## 28

Дошманның төп оборонасы ике көнгә дә чыдый алмады. Безнең гаскәрләр пехотаның, танкларның, авиациянең тупланган удары белән аны актарып ташладылар. Дошман, арадаш рубежларда каты каршылык күрсәтә-күрсәтә, көнбатышка таба тәгәрәде. Подполковник Кремнев полкы каршындагы дошман подразделениеләре Овсище авылына таба чигенде. Разведка мәгълүматларына караганда, Овсище авылында гитлерчыларның икенче оборона рубежы башлана. Авыл көчле ныгытылган терәк пунктка әверелдерелгән, гитлерчылар анда каты каршылык күрсәтергә җыеналар. Шуңа күрә мөмкин кадәр тизрәк алга барырга, дошманга ныгырга вакыт бирмәскә кирәк. Сугышчылар ялны да, йокыны да оныттылар. Кыска вакытлы, ләкин бик каты сугышлардан соң да алар туктамадылар. Дошман гарнизоннары урнашкан кечерәк авылларны әйләнеп үтеп киттеләр яки, әйләнеп үтеп, аларга көнбатыштан һөҗүм иттеләр. Мондый атакалардан соң гитлерчыларның бик азлары гына качып котыла иде.

Менә Овсищега килү юлларын саклаучы бу зур авылга да алар аның Көнбатыш ягыннан һөҗүм иттеләр. Төнлә гвардия майоры Ермиловның батальоны, кинәттән генә башланып киткән бураннан һәм караңгыдан файдаланып, авылны ерактан урап үтеп, аның көнбатыш читенә якынлаша башлады. Авыл кырыена җиткәч, батальон, авылдан көнбатышка илтә торган бердәнбер юлны кисеп, кар эченә ятты. Ябалак-ябалак яуган кар әле һаман да туктамаган, әкрен генә явып тора. «Кара карга бураннары», – дип уйлады кар өстендә яткан Газинур. Ул озакламыйча тагын бик каты сугыш башланасын белә, шулай да уйлары туган колхозында иде. Сугышта куркуны белми, иң хәтәр җиргә алдан атылучы бу егетнең күңеленә тыныч хезмәт, сугыш маҗараларына караганда, мең мәртәбә якынрак иде. «Сабир бабай атларга солыны мулрак бирә башлагандыр», – дип уйлый ул, Миңнурыйны, балаларын исенә төшерә, кайчакта күз алдына карт әтисе ки-

леп баса, кыенрак хәлләргә эләксә, Гали абзасы белән күңеленнән сөйләшеп ала, ашкынып алга барган чакларда йә Гөлләр чагылып үтә, йә Фатыйманың дәртле җырлары аның колак төбендә чыңлагандай була иде.

Ләкин солдат солдат инде ул, аның иң беренче эше – туган җирен азат итү.

Газинур, бүтән барлык нәрсәсен онытып, тыңлап тора башлады. Кар пәрдәсе эченнән бер генә эт өргән тавыш та, бер генә әтәч тавышы да ишетелми. Ә хәзер нәкъ менә әтәчләр икенче тапкыр кычкыра торган вакыт. Берәр өйдә ут җемелдәмәсме дип, Газинур никадәр генә тырышып караса да, ичмасам, тычкан күзедәй ут җемелдәвен дә күрә алмады!

Тезмә буенча капитан Бушуевның боерыгын тапшырдылар.

– Сержант Гафиятуллин, ротныйга.

Газинур, урыныннан торып, иелә төшеп, капитан янына йөгерде, аның белән янәшә кар эченә сузылды. Шунда ук гвардия майоры Ермилов та ята иде.

– Гафиятуллин, отделениеңнең иң яхшы биш сугышчысын ал да авылга разведкага бар. Әнә күрәсеңме, – гвардия майоры бияләйле кулы белән алга күрсәтте, – уйсулык сузыла. Шушыннан авыл уртасына кадәр бар да ындыр бакчалары аркылы авылга кер. Барысын да белергә тырыш. Ләкин тавыш чыгарма. Бер сәгатьтән кайт.

Берничә минуттан алты чаңгычы, ак күләгәләр шикелле үтеп китеп, кар эчендә күздән югалдылар. Газинур алдан барды, вакыт-вакыт туктап, башлыгын ача төшеп, тыңлап торды. Авыл һаман да тын иде. «Гитлерчылар киткәннәрме югыйсә?» – дип борчылып алды Газинур.

Разведчиклар, әрәмәлек арасыннан барып, келәтләр янына үттеләр, аннары кемнеңдер бакчасына керделәр, читән артына яттылар. Моннан урамның бер өлеше күренә иде. Кинәт немецча команда тавышы ишетелде, урам буйлап унлап гитлерчының үткәне күренде. «Каравыл үтә, постларны алмаштырып йөриләр», – дип уйлап алды Газинур тиз генә. Гитлерчылар узып киткәч, ул үзенең сугышчыларын ике төркемгә бүлде, бер төркемне авылның көнбатыш ягына җибәрде, икенче төркем белән үзе каравыл артыннан китте.

Авыл уртасындагы мәйданда алар дар агачы күрделәр. Буран эчендә кемнеңдер асылган гәүдәсе әкрен генә чайкалып тора. Дарда тагын биш элмәк бар, ләкин алары буш.

Газинур кычкырып җибәрә язды.

– Безнекеләрне!..

Кайтырга вакыт иде инде. Газинур үзенең сугышчыларын елгага таба алып китте. Елга кырыенда, бүтән барлык йортлардан аерылып, ярым җимерек кечкенә бер йорт тора иде. Газинур туктады. Аның борынына көек исе бәрелгәндәй булды. Ул, сугышчыларына ятарга кушып, үзе тәрәзә янына килде. Ватык пыяла урынына тыккан чүпрәкне бармагы белән төртеп төшерде. Эчтән җылы чыга иде. «Монда кемдер тора», – дип уйлады Газинур. Ул-бу була калса дип, кулына гранатасын тотып, сагаеп тыңлый башлады. Аннары тәрәзәне әкрен генә чиертте. Берәү дә җавап бирмәде, Газинур бераз көтте дә тагын чиертте. Шуннан соң эчтән малай тавышы ишетелде.

– Кем кирәк? Монда мин берүзем.

– Син кирәк, – диде Газинур, – ишегеңне ач әле, энекәш.

Өй эче мунча кебек шәп-шәрә иде. Газинур аны кесә фонаре белән яктыртып карагач, башын гына чайкады.

– Берүзең торасыңмы?

– Берүзем...

Газинур фонарен малайга юнәлтте. Аңа унөч-ундүрт яшь булыр. Йөзе ап-ак, ябык. Өсте сәләмә.

– Без сезне кичә үк көткән идек, – диде малай.

– Кемнәрне? – дип сорады Газинур, сагаеп.

– Кызыл разведчикларны... Мин бит синең бүрегеңдәге йолдызыңны күрдем. Күрмәсәм, ачар идемме...

Газинур малайга сораулар бирә башлады. Малай зирәк булып чыкты. Аның җаваплары тулы, Газинур үзе күзәткән мәгълүматларга да туры килә иде. Авылда дошманның бер ротага якын солдаты, пулеметлары, минометлары, җиңел туплары бар.

– Кемне асканнар? – дип сорады Газинур.

Малай учы белән күз яшьләрен сөртеп алды.

– Алексей Петровичны... Колхоз хисапчысын. Тагын биш кешене кулга алдылар. Укытучы апаны да... Иртәгә асалар, ди...

– Елама, туган, – диде Газинур, малайны кочаклап, – без аларны коткарырбыз.

– Кайчан, хәзер үкме, абый? – дип сорады малай.

– Тиздән, – диде Газинур, малайга курыкмаска кушып, ишеккә юнәлде.

Кинәт малай көлемсерәп куйды, күзләрендә шаян чаткылар күренде.

– Сез һөҗүм итә башлагач, – диде ул горур гына, – мин дә үз отрядымны күтәрәчәкмен. Без биш малай. Тылдан бәрәчәкбез.

– Юк, юк, ярамый, энекәш. Сез тын гына утырыгыз, югыйсә бөтен эшне харап итәрсез, – диде Газинур.

Ишек төбендә ул туктады. Малайны берүзен калдырырга ярамый иде. Ул, үзенең «отрядын» вакытыннан элек кузгатып, бөтен эшне чуалтуы мөмкин.

«Менә бәла», – дип уйлады Газинур, малайны сакларга бер сугышчысын калдырырга мәҗбүр булды.

Авылның көнбатыш ягына җибәрелгән сугышчылар аларны үзәнлектә көтеп торалар иде. Бер-ике авыз сүз белән алар күргәннәрен әйтеп бирделәр. Авылның көнбатыш ягы ныгытылмаган, анда хәтта сакчылар да юк.

Бераздан алар карга күмелеп яткан батальон янында иделәр инде. Кызу килүдән тыны кысыла башлаган Газинур:

– Комбат кайда? – дип сорады.

– Биредә, – диде Бушуев.

– Сөйлә, – диде гвардия майоры.

Газинурның докладын тыңлагач, комбат бераз уйланып торды, авылга кичекмәстән һөҗүм итә башларга боерык бирде. Газинурның отделениесен яңадан алдан җибәрде. Постларны тавыш-тынсыз юк итә барырга кушты.

– Сиңа обстановка таныш. Кыю хәрәкәт ит.

Шыпырт кына бирелгән команда тавышлары ишетелде. Кар эчендә яткан батальон аякка басты, өч яклап авылга таба бара башлады.

Газинур үзенең отделениесе белән алга ыргылды, беренче булып авылга керде, ак күләгәләр кебек тавыш-тынсыз барып, фашист часовойларын берсе артыннан икенчесен хәнҗәрләр белән юк итте. Менә каравыл йорты. Аның каршында торган часовой да кар өстендә ята инде. Ләкин авылда атыш башланды. Хәзер тавыш-тынсыз хәрәкәт итүнең мәгънәсе юк иде инде. Газинур тәрәзә капкачын каерып алды да каравыл урнашкан өй эченә танк гранатасы томырды. Шуның артыннан ук бөтен авыл буйлап «ура!» тавышы яңгырады, атышлар көчәеп китте. Янгын яктысы карга күмелгән авыл өйләрен, урам буйлап йөгерүче солдатларны, чатта ярсып-ярсып ата башлаган станоклы пулеметны яктыртты.

Газинур тоткыннарны япкан келәт ишегендәге йозакны приклад белән бәреп очырды.

– Иптәшләр, сез азат! – дип кычкырды.

Кемдер аны кочаклап алды, үбә башлады...

Таң атып килгәндә, авылда атышлар тынган иде инде. Әсирләрне алып киттеләр. Трофейларны сакларга берничә солдат калдырылды. Ут позицияләрендә гитлерчыларның бер генә тапкыр да атарга өлгермәгән туплары, минометлары тора иде.

Бу төнге сугышта батальон үзенең берничә сугышчысын югалтты. Аларны, дардан төшерелгән бабай белән янәшә, авыл уртасындагы мәйданга күмделәр.

Батальон инде көнбатышка китәр өчен сафка тезелә башлаган иде. Шул чакта урам буйлап шаулаша-шаулаша килгән малайлар төркеме күренде. Алар арасында күкрәгенә немец автоматы аскан ап-ак сакаллы бер карт белән башын бөгеп килгән сәләмә киемле бер кеше бар иде.

– Кем бу? – дип сорады капитан Бушуев.

Ап-ак сакаллы карт, честь биреп:

– Иң зур җинаятьче – комендант Курт Шварц, – диде.

Капитан, бер адым алга атлап, Шварцка карады, ачуын чак тыеп, кулы белән дарга күрсәтте:

– Бу синең эшеңме?

Рус капитаны аны асарга куша дип аңлады, ахрысы, гитлерчы, куллары белән йөзен каплап, кыргыйларча чинап җибәрде.

– Нәрсә, котың очтымы, кабахәт? Сине менә шушы авылда хөкем итәчәкләр.

Малайлар арасында Газинур үзенең төнге танышын күреп елмайды. Бер читтәрәк, халык төркеме эчендә, кулын күкрәгенә куйган яшь кенә бер хатын басып тора иде. Аның йөзе ап-ак, күзләре эчкә баткан, үзе бик ябык, аягында көчкә тора. Кинәт ул урыныннан кузгалды, капитан Бушуев янына килде. Нидер сорады. Капитан, артына борылып, Газинурга күрсәтте. Хатын Газинур янына килде, аның ачык йөзенә, зур кара күзләренә карап:

– Рәхмәт, иптәш... Барысы өчен дә рәхмәт! – диде. Газинурны кочаклап үпте.

Бу үлемнән коткарылган укытучы иде.

## 29

Калинин өлкәсенең соңгы километрлары. Алда кар эченә чумган Овсище авылы. Гитлерчылар аны мина кырлары, тимерчыбыклар, траншеялар, дзотлар белән

чолгап алганнар, һәр йортны кечкенә генә крепость итеп ныгытканнар. Оборона өчен яраклы һәр өйнең нигезенә тишекләр тишеп, пулеметлар куелган. Авылның чокырлы-чакырлы булуы шулай ук исәпкә алынган, анда һөҗүм итүчеләрне бик күп төрле һәм бик күп сандагы киртәләр көтә иде. Бигрәк тә урам чатлары көчле ныгытылган – анда җиргә күмелгән, тыштан гади кар көртенә охшаган танклар, бронеколпаклар, дзотлар тора.

Авылга барышлый ук ясалган атака уңышлы чыкмады. Безнең батальоннар, дошманның көчле утына очрап, авылдан кире чигенергә мәҗбүр булдылар. Шуның өстенә караңгы төшеп килә, солдатлар да бик нык арыганнар иде. Артиллерия артта калды, сугыш припасларын да китертеп җиткерәсе бар.

Полк командиры, тун өстеннән ак комбинезон кигән подполковник Кремнев, батальон командирларын үз янына чакыртып, гомуми атака иртәгә – җиде сәгатькә билгеләнгәнлеген әйтте. Гвардия майоры Ермиловның батальоны авылга маңгайдан һөҗүм итү, өченче батальон төньяктан атакалау бурычын алды. Икенче батальон – резерв.

Полк командирының приказын үтәп, Ермиловның батальоны, төнге бураннан файдаланып, авылга мөмкин кадәр якынрак барып кардан траншеялар казый башлады. Таңга таба артиллеристлар да килеп җитте, әрәмәлек эченә – ут позицияләренә урнаштылар. Чокырларда минометчылар. Өлкән лейтенант Григорьян үзенең разведчиклары белән төне буенча дошманның алгы сызыгын «капшап» йөрде. Разведчиклар гитлерчылардан юри ут ачтырдылар, аткан чакта күренә торган ялкыннарга карап, ут нокталарын билгеләделәр.

Таң алдыннан, караңгылык аерата куерган, йокы белән көрәшү читенләшкән бервакытта, ниһаять, ике як та тынып калды. Арыган, талган разведчиклар кире кайттылар, пехотачылар, атака алдыннан аз гына булса да хәл җыяр өчен, бер-берсенә сыенышып, траншея төбенә утырдылар. Учак ягарга ярамый иде. Авыр эштән соң эсселәнгән тән, хәрәкәттән туктагач, суыкка бик тиз биреште, ярты сәгатьтән соң ук калтырарга тотынды.

Газинур суыкка чыдам кеше булса да, ул да йокыга китә алмыйча тынычсызланды. Бераз гына булса да җылыныр өчен тәмәке кабызды, җиң очына яшереп тарта башлады. Борынга төтен керсә, җылыта, диләр. Бер-

ничә суырганнан соң, Газинур чыннан да бераз җылынгандай булды. Башка вакытларда ул кайда башын куйса, шунда йоклый ала торган иде, бүген аның күзенә йокы кермәде. Траншея төбендә чүгәләп утырган килеш, кар стенага карап торды. Аның уң иңенә Комлев башын куйган, әкрен генә мышный, сул ягында икенче отделение сугышчысы аңа сыенган. Ул да, бала кебек, әкрен генә мышный. Ә өстән һаман йомшак кына кар ява. Җил булмаганга, эре кар бөртекләре туп-туры төшәләр, солдатларның каскаларына, иңнәренә куналар.

Ярым уяу, ярым йокылы Газинурның күз алдыннан әле күптән түгел генә булып үткән күренешләр уза: менә ул траншеядан атылып чыгар өчен алга карап тора, менә дарга асылган колхозчы картның гәүдәсе чайкала, үлемнән коткарылган укытучы аның күзләренә карый. Дөрләп яна торган танк эченнән Павел Ивановичларның «Интернационал» җырлавы ишетелгәндәй була...

Газинур урыныннан торды, траншея төбендә бер-берсенә сыенышып утырып йоклаган сугышчан иптәшләренә күз салды. Характерлары, тормышлары, биографияләре, милләтләре төрле-төрле булган бу кешеләр аңа барысы да бертугандай якын иде. Менә хәзер алар ял итәләр, аларның таң калырлык бернәрсәләре дә юк шикелле. Ә берничә сәгатьтән алар урыннарыннан торачаклар, үзләренең тиңсез батырлыклары белән бөтен дөньяны таң калдырып, тагын алга барачаклар.

Газинур, траншеядан күтәрелә төшеп, үзләре барачак сугыш кырына карады. Кыр уртасында ап-ак алмагач. Сугышка кадәр биредә колхозның алма бакчасы булган, ахрысы. Гитлерчылар, ут секторы ачык күренеп торсын өчен, алмагачларның барысын да кырганнар. Бары тик бер алмагач кына ничектер киселми калган. Мөгаен, ориентир итеп калдырганнардыр.

Бу ап-ак алмагач Газинурның уйларын туган якларына алып китте. Азнакайда, Сугышлыда, Шөгердә, Бөгелмәдә алмагачларны, куян кимермәсен өчен, юкә кабыгы белән уратып куялар иде...

Менә озакламый май килер, карлар эреп бетәр, алмагачлар чәчәк атар. Бу гарип алмагач та чәчәк атар, ул чагында фронт бу җирләрдән ерак булыр, менә хәзер карлы траншеялар сузылган, солдатлар утырган урыннарда колхозчылар яңа яшь алмагачлар, җимеш куаклары утыртырлар. Ә тагын берничә елдан соң монда зур бакча шаулап үсәр. Әйе, бик зур бакча шаулап үсәр!

Газинур кулы белән күзләрен каплады, кинәт аңа бөтен җир шау чәчәккә күмелгән зур бакча эчендә кебек тоелды. Аның кара шомырттай чәчләренә, иңбашларына алсу ак алма чәчәкләре коела, имеш. Ә алма бакчалары уртасыннан, еракка-еракка, зәңгәр офыкка кадәр, туп-туры юл сузылган, имеш. Газинур шул туры юлдан ашыкмый гына бара. Бер кулы белән кызын, икенче кулы белән малаен җитәкләгән. Кызының да, малаеның да муеннарында кызыл галстуклар. Аларны җил тибрәтә. Балалар җырлыйлар, көләләр. Ә кечкенә малаен муенына атландырган, имеш. Аның кулында чәчәкле алмагач ботагы. Кечкенә малай да җырлый, көлә, имеш. Ә янәшәсендә шаян, сөйкемле Миңнурый – гөләп чәчәге бара, имеш...

– Нәрсә, аягүрә төш күрәмме югыйсә, – диде Газинур үз-үзенә, кулын күзләреннән алды. Аның алдында, ай нурында коенып, ялгыз гарип алмагач кына тора иде. Аның ботакларында чәчәкләр түгел, яңа яуган кар бөртекләре. Уңдарак әрәмәлек, ә алда, тонык кына булып, Овсище авылының кырыйдагы йортлары, тимерчыбык киртәләре күренә.

«Иртән без барыбер анда булырбыз», – дип уйлады Газинур. Ул анда булачаклары турында һич тә шикләнми, бу айлы төн аның соңгы төне, бу алмагач аның соңгы күргән алмагачы, ә иртән томанга уралып чыгачак кояш – аның соңгы кояшы буласын, ә кар эчендә яткан борынгы Овсище авылы аның мәңгелек йорты буласын ул уена да китерми иде. Әгәр белсә, ул үзенең тормыш юлына әйләнеп карар иде: ничек яшәде соң ул, кешеләргә нинди файда китерде, нинди яхшы эшләр эшләде, газиз Ватанына нинди хезмәт күрсәтте? Әрәмгә үткәрмәдеме соң ул үзенең алтын яшь гомерен? Соңгы сулышын алганда, эшләнмәгән эшләр өчен ачы үкенүдән йөрәге әрнемәсме? Оят һәм хурлык йөзен кызартмасмы?

Газинур әзергә хәзер булып тумады. Аның үсмер чаклары искенең җимерелүе, яңаның тууы елларында үтте. Илдә кыен иде – Газинурга да кыен булды. Ләкин яшь Совет иле, үзенең яраларын бик тиз төзәтеп, алга атлады. Аның белән бергә Газинур кебек миллионнарча гади кешеләр дә якты киләчәккә атладылар. Ләкин караңгы бер авылда үскән авыл малаена күп нәрсә аңлашылмый иде әле. Күп нәрсәнең дөреслеген ул йөрәге белән генә сизде. Әмма, әгәр дә аның дуслары булмаган булса, ул никадәр батыр йөрәкле булса да, берүзе болай күтәрелә алмас иде.

Карагыз, «Красногвардеец» кайда да, Соликамск кайда, Карелия урманнары кайда да, Икенче Балтыйк буе фронты кайда, Ловать елгасы буендагы пулеметчылар ротасы кайда да, Газинурның беренче уку йорты – полк мәктәбе кайда! Ләкин кайда гына йөрмәсен, һәр җирдә аның җаннан артык дуслары булды. Дуслары аңа санап та, әйтеп тә бетергесез ярдәм күрсәттеләр. Газинур алардан ерак булса да, үзен һич тә алардан аерым итеп карый алмый иде. Дусларның йөрәкләре бер-берсенә күзгә күренми торган җепләр белән тоташа, дип сөйләргә ярата иде ул. Аның иске дуслары яңаларында кабаттан туа барды. Бигрәк тә олы дуслары – коммунист укытучылары турында ул шулай дип әйтә алыр иде. Гали абзый Павел Ивановичка тышкы кыяфәте белән һич тә охшамаган булса да, Гали абзыйның кайсыдыр гүзәл ягы Павел Ивановичта бар иде, ә Павел Иванович һич тә парторг Соловеевка охшамаган иде, әмма аңарда да леспромхоз партия оешмасы секретареның иң яхшы сыйфатлары бар иде. Алар Газинурны бөек тормыш юлында, гүя эстафета кебек, кулдан-кулга тапшырдылар, аларның һәркайсы аны алга алып барды. Алар аңа юл күрсәтте. Тормыш юлында аны җитәкләүчеләр дә алар булды. Аннары калын урманнарда карт имәннәр белән янәшә яшь агачлар да үскән, урманны ямьләндергән кебек, тормышта да олы җитәкчеләр белән бергә кешенең яшәвен тулыландыра, матурландыра торган бүтән кешеләр дә күп бит. Колхоз председателе Хәнәфиләр, ат караучы Сабир бабайлар, Миңнурыйлар, Гөлләрләр, Бушуевлар, саф күңелле Екатерина Павловналар, Стариковлар, Ильченколар, Григорьяннар, Зәбировлар... Әгәр саный башласаң, алар никадәр күп! Аларның күп булулары сөенечле дә.

Газинур шушы тирән уйларга чумып торган чагында, аның янына Соловеев килеп туктады. Билгеле, ул аны атап эзләп килмәде, Газинур аның юлында очраган йөзләрчә коммунистларның берсе иде.

Соловеев, бияләен салып, Газинурның кулын кысты, аның белән бергә ботакларын кар баскан ялгыз алмагачка, карга чумган караңгы авылга карап торды.

– Ничек соң, иптәш Гафиятуллин, Овсищены алабызмы?

Сержантның йөзен тыныч елмаю яктыртты.

– Йөз авылны алдык, иптәш парторг, йөз дә беренчесе алдында туктап калабызмы соң?! Безнең якта картлар әйтә: яз көне кечкенә генә инеш белән дә шаярма. Ә без –

бәләкәй инеш түгел бит, менә дигән елга. Юлыбызга аркылы төшеп карасыннар – тамырлары белән актарып ташларбыз! – Бераз уйлагач, тынычрак тавыш белән өстәп куйды: – Хәзер, иптәш парторг, озак канительләнеп тору бирәүнең дә уенда юк. Дошманны үкертеп куар көннәр килеп җитте.

Бу төндә Соловеев кем белән генә сөйләшмәсен, һәммәсе шуңа охшашлырак сүзләр белән җавап бирделәр. Димәк, солдатларның уйлары бер иде.

– Әйе, Гафиятуллин, син дөрес әйтәсең, озак сугышу безгә кулай эш түгел, һәркайсыбызны илдә хезмәт көтә.

– Мин дә шулай уйлыйм. Менә карагыз, – Газинур кулы белән кырга ишарә ясады, – кайчандыр монда җимеш бакчасы булган, фашистлар аны турап бетергәннәр. Бер генә алмагач калган, анысы да гарип. Ләкин эш алмагачта гынамыни... Күпме авылларны, күпме шәһәрләрне яндырдылар... Аларны бит барысын да яңадан торгызырга кирәк булачак. – Газинур уйчанланып китте. – Әйе, безнең эш бик күп буласы, иптәш парторг. Бик күп!

Соловеев траншея төбендә чүгәләшеп йоклаган сугышчыларга, траншея почмагына сөялеп, аягүрә йоклаган связноена карап алды.

– Дөрес, Гафиятуллин, эш күп буласы. Ләкин безнең кайчан эштән курыкканыбыз бар? Без сугыш җимерекләрен торгызып кына туктамабыз. Без коммунизмны да төзербез әле.

– Коммунизм! – диде Газинур, хыялланып. – Эх, күрәсе иде ул көннәрне!

– Һичшиксез, күрербез, – диде парторг, – без күрмәсәк, балаларыбыз күрер. – Соловеев Газинурның кулын кысты: – Ярар, мин тоткарландым. Безнең сүзләрне сугышчыларга җиткер. Белеп торсыннар.

– Җиткерермен, иптәш парторг.

– Хуш алайса, уңыш телим.

– Рәхмәт.

Соловеев китеп барды. Аның артыннан связное да кузгалды. Газинур алар артыннан бик озак карап торды.

Немецлар ракета чөя башладылар. Автоматлар тырылдашып алды. Аннары тагын тынлык урнашты. Ләкин бу тынлык инде озакка сузылмаячак. Солдатлар уянды. Яктыра башлады. Старшина Михно кайнар аш, аракы китерде. Солдатлар кайнар шулпа салган котелокларын

траншея төбенә, кар өстенә куеп, ашарга керештеләр. Бөтен траншеяга тәмле шулпа исе таралды. Ә котелоклар астындагы кар эри барды, соңыннан траншеяның буеннан-буена түгәрәк котелок эзләре тезелеп калды.

Кайнар шулпа туңган сугышчыларны шактый җылытып җибәрде. Аларның кәефләре күтәрелеп китте.

– Монысы бик ярады, рәхмәт, иптәш старшина, – диде Газинур, – инде эшкә керешергә дә була.

Газинур сугышчыларына карап алды. Әле күптән түгел генә ул алар арасында ят бер кеше иде. Хәзер инде сугышчылар аны үз күрәләр, яраталар иде. Дөрес, солдат мәхәббәте бик тирән яшерелгән, аны тиз генә күреп тә булмый. Бары тик үлем куркынычы янаган минутларда гына ул ачыктан-ачык күренә. Кайнар сугыш барганда, Газинур әллә ничә тапкыр моның шаһиты булды. Сугышчылар аны саклап, аның тирәсендә һәрвакыт корыч калкан булып торалар иде.

– Йә, ничек, егетләр, эшкә керешергә вакытмы?

– Вакыт, вакыт, иптәш сержант!

Траншея буйлап разведчиклар үтеп китте. Старшина Зәбиров бер генә минутка Газинур янында туктады.

– Газинур, – диде ул, – Фатыйманың ире бармы?

Гафиятуллин бу көтелмәгән сорауга каршы рәхәтләнеп елмайды, кара күзләрендә шаян чаткылар биешә башлады, ләкин старшинаның җитди икәнен, бик ашыгуын күреп:

– Юк, Исхак, ул кыз кеше, – диде.

Разведчикның йөзе яктырып китте. Ул нидер әйтергә теләгән кебек иде, ләкин әйтмәде. Бары тик:

– Хәзер башлыйбыз, – диде ул, аннары иптәшләре артыннан йөгереп китте. Газинур сәгатенә карады: җиде туларга ун минут калган иде.

## 30

Бер генә минутка да тынмыйча артиллерия, минометлар ата. Аларга станоклы пулеметларның тыкылдаулары, автомат тырылдаулары килеп кушыла. Көчле дулкын булып кырлар буенча «ура» яңгырый. Пехота атакага бара. Траншеяларда, дзотларда яшеренгән гитлерчылар котырынып каршылык күрсәтәләр. Атакага баручылар арасында әледән-әле кара фонтаннар күтәрелә, кешеләр егылып кала. Ләкин ташкын туктамый, ул һаман алга авыша. Актарылган тимерчыбыклар, траншеялар, дзот-

лар, авыл кырыендагы бортлар ап-ачык күренәләр инде. Дошманның уты тагын да көчәя. Ул һәр метрга кургаш яңгыры яудыра, бигрәк тә флангтан осколочный снаряд белән атучы автоматик туплар сугышчыларны кыра.

Алга барырга мөмкинлек бетте. Пехотачылар тимерчыбык янында ук ятарга мәҗбүр булдылар, күпләр кардан окоплар казый башладылар.

Газинур үзенең отделениесе белән батальонның сул канатында бара иде. Ул батальонның ятарга мәҗбүр булуын күрде. Ләкин отделениесен туктатмады. Биредә дошманның уты ул хәтле көчле булмаудан файдаланып, ул сугышчыларны һаман алга ашыктырды.

Немец тубы алардан чак кына уңдарак иде. Анда тылларына төшәргә җыенучы бер төркем совет сугышчыларын күрмиләр иде бугай. Ләкин икенче дзоттан аларны күреп алдылар, ут ачтылар. Отделение кар өстенә ятты, ләкин туктамады, шуышып алга бара бирде.

Дошман траншеялары күренде.

– Гранаталар! – дип кычкырды Газинур. Дошман траншеяларына гранаталар очты, шуның артыннан ук Газинур, аякка күтәрелеп: – Минем арттан! – дип кычкырды. Ул беренче булып траншеяга сикерде, ялтырап торган кара күзләре белән як-якка каранып алды. Траншея төбендә ике немец тәгәрәп ята иде. – Тупны алабыз! – дип кычкырды Газинур сугышчыларына. Ул үлекләр өстеннән сикерде дә алга ыргылды. Кайдандыр килеп чыккан бер гитлерчыны автоматтан егып салды. Аннары тагын алга йөгерде.

Дзот эченә яшерелгән немец тубы һаман да атып тора иде. Ул шундый тиз ата, әйтерсең пневматик чүкеч белән таш чокый.

Траншея борылышында алдан йөгерүче Газинурга немец автоматчысы атып җибәрде. Газинур артка чигенеп өлгерде. Пуляларның берсе, каскасына тиеп, чыңлап үтте. Газинурның башы шаулап китте. Бер генә секундка ул күзләрен йомды, шунда ук ачты. Гранатасына сузылды, ләкин арттан килүче Гордеев Газинурның башы аркылы граната ташлап өлгерде. Шартлау яңгырады, фрицның ачы илерүе ишетелде.

Бер минуттан алар дзот ишеге төбендә иделәр инде. Анда озын буйлы, пычрак йөзле бер фриц күренде. Ул үзләренчә нидер акырып җибәрде дә ишеккә тотынды. Мөгаен, ябарга теләгәндер. Кече сержант Комлев ишеккә төзәп атып җибәрде. Гитлерчы бөгәрләнеп төште. Гази-

нур дзот эченә танк гранатасы томырды. Каты шартлау дзот эчен тетрәтте, ишектән куе төтен бәреп чыкты. Шуның артыннан ук Газинур дзот эченә атылып керде, насостан су сиптергән шикелле, автоматын төрле якка бора-бора ата башлады.

Фрицларның бары тик берсе ниндидер могҗиза аркасында исән калган. Ләкин ул да шулкадәр миңгерәүләнгән, берни аңлый алмас хәлгә килгән. Авызыннан, борыныннан, колакларыннан кан ага. Газинур аны якасыннан эләктереп ишеккә таба сөйрәде.

– Гордеев, алып кит бу мәхлукны! – дип кычкырды Газинур, үзе калган сугышчылары белән алга омтылды. Ул тирләгән, йөзе кызарган, юеш кара чәчләре маңгаена ябышкан.

Туп атудан туктауга, батальон дәррәү күтәрелде. Капитан Бушуевның ротасы авылга бәреп керде, кырыйдагы йортларны алды. Шуннан соң рота, һәр йортны диярлек штурмлый-штурмлый, авылның үзәгенә таба омтылды. Аңа подваллардан, тәрәзәләрдән, чормалардан аттылар.

Төньяктан һөҗүм итүче батальон да авылга бәреп керде. Хәзер ике батальон икесе дә мәйданга таба ашыгалар иде.

Газинур, аларны көтеп тормастан, үзенең сугышчыларын йорт артлары, ишегаллары аркылы авыл уртасына алып китте. Хәзер иң мөһиме – алга бару, дошманның авыл уртасындагы көчләрен таркату иде. Шуңа күрә Газинур аерым йортларда утыручы автоматчыларга каршы сугышып та тормады. Аларны арттан килүчеләр юк итәчәк.

Гафиятуллинның отделениесе сыер абзары артына яшеренеп туктады. Алда киң мәйдан. Мәйдан артында авылның көнбатыш яртысы башлана. Газинур обстановкага берьюлы төшенеп алды. Мәйданны аркылы чыкмыйча торып, авылның икенче яртысына бәреп керергә мөмкин түгел, ике яктан тирән чокыр сузыла. Ә чокыр буйларында тимерчыбыклар, миналар. Мәйданны аркылы чыксаң, авылны безнең кулда дип исәплә. Мәйдан – бөтен авылның, юк, авылның гына түгел, бөтен терәк пунктның ачкычы!

– Сержант, кара! – диде сугышчыларның берсе, автомат көпшәсе белән мәйдан артындагы бер ишегалдына күрсәтеп. Анда фрицлар туплана иде.

– Комлев, ут! – дип кычкырды Газинур. Кул пулеме-

ты артында яткан кече сержант шунда ук ут ачты. Гитлерчылар кычкырыша башладылар, коймалар артында күздән югалдылар. Берничәсе егылып калды.

– Алга, минем арттан! – дип кычкырды Газинур. Ләкин алар йорт ышыгыннан чыгуга, каршы яктан ут ачтылар. Газинур белән янәшә йөгерүче Комлев, кулы белән күкрәгенә тотынып, бераз чайкалды да пулемет өстенә ауды.

– Ятыгыз! – дип кычкырды Газинур.

Немец пулеметы баш күтәрергә ирек бирмичә атса да, Газинур аның кайдан атуын күреп алды. Каршы якта, нәкъ Газинур турысында, җимерек өй нигезе күренә. Аның бүрәнәләре төрле якка таркалган. Ә бүрәнәләр астында, таш подвалда, дзот.

«Әнә кайда яшеренгәнсең, кабахәт!» – дип уйлап алды Газинур. Бу безнекеләр өчен куркыныч пулемет иде. Типтигез мәйданга килеп кергән сугышчыларны окоп казып өлгергәнче үк кырып бетерәчәк ул. Газинур шуны уйлап кына алган иде, мәйданга урам ягыннан капитан Бушуевның ротасы килеп керде. Шунда ук Газинур алдан йөгереп килүче сугышчыларның егылуларын күрде. Берәү, икәү, өчәү...

Газинурның йөрәге атылып чыгардай булып тибә иде. Ул иптәшләренә борылып карады. Алар, карга йөзтүбән капланып, хәрәкәтсез яталар.

Кар тузаны чәчрәтеп, Газинур янында гына пулялар чыелдый. «Монысы үтте... Менә монысы да...» Бер пуля Газинурның борын төбендә генә карга кадалды. Газинурның йөзенә кар тузаны бәрелде. Ул җирне сытып яшеренергә теләде, ләкин яшеренергә мөмкин түгел иде.

Ул башын чак кына күтәрә төште, атып торган дошман пулеметына карады. Кулы билендәге гранатасына сузылды. Кичегергә ярамый. Газинур дзотка таба шуыша башлады.

Менә ул сулгарак борылды, бомба чокырына тәгәрәде. Ләкин ара ерак, гранатаны ташлап җиткерерлек түгел, Газинур тирә-ягына каранды. Тагын ике солдат, кулларына граната тотып, дзотка таба шуыша иде. Менә берсенең каскасы очып китте. Сугышчы канлы башын күтәрде, дзот амбразурасына караган килеш карга капланды. Икенчесе һаман шуыша иде. Ләкин ул Газинурга караганда да дзотка ераграк.

Газинур чокырдан чыкты да тагын алга шуыша башлады. Хәзер инде аны бөтен батальон күреп алды. Йорт

ышыгында яткан капитан Бушуев, каскасын артка этеп, иреннәрен тешләде.

Фашист пулеметы үкерүдән туктамады. Газинур, шуыша-шуыша, дзотка якын ук килде. Бер секунд хәл җыеп торды. Аннары бераз күтәрелә төште, бөтен көче белән селтәнеп, амбразурага граната томырды. Җир тетрәп китте. Шуның артыннан ук Газинур икенче гранатасын да томырды.

Пулемет тынды. Сугышчылар команда көтмичә үк, урыннарыннан сикереп торып, мәйданга ташландылар. Газинур да берничә адым алга йөгерергә өлгерде. Ләкин кар көрте баскан тар амбразурадан яңадан көчле ут ыргылды. Бер генә минутка туктап торган фашист пулеметы яңадан котырынып ата башлады. Кар өстенә яңа яралылар ауды. Сугышчылар, ут астыннан чыгар өчен, бөтен көч белән алга ыргылдылар, ләкин аларның да сафлары сирәгәйгәннән-сирәгәя барды.

Капитан Бушуев бөтен тавышы белән:

– Ятыгыз! – дип кычкырды.

Сугышчылар икенче тапкыр инде ачык мәйданда кар өстенә ятарга мәҗбүр булдылар.

Сержант Газинур Гафиятуллин барысыннан алда снаряд чокырында иде. Пулемет үкерүен җиңеп, кемнеңдер үлем белән тартышып ыңгырашуы ишетелде. Газинур тирә-ягына каранды. Мәйданның төрле урыннарында кулларына граната тоткан сугышчылар хәрәкәтсез яталар. Тик берсе, кулын алга ташлый-ташлый, гүя язмышына карышып, үлемне куып, һаман алга шуыша. Аның әйләнә-тирәсендә пулялар аеруча күп сызгыра, кар оча. Менә ул да туктады. Газинурның миеннән яшен тизлеге белән куркыныч уй үтеп китте: «Үтерделәр!» Юк, үлмәгән! Сугышчы яңадан шуыша. Хәзер ул, берни күрмичә, йөзе белән кар ерып бара булса кирәк. Ләкин ул еш-еш туктый, хәрәкәтләре әкренәя. Күрәсең, яраланган. Менә ул бөтенләй туктады. Аннары башын күтәрде. Каскасы төшеп калган. Карга буялган кара чәчләре юеш маңгаена сибелгән, кояш яктысында аның юеш йөзе ап-ачык күренә. Газинур аны танып алды: бу Ильченко иде.

Ильченко кар өстенә капланды. Газинурның йөрәге тагын да көчлерәк тибәргә тотынды. «Шундый алтын кешене...» Ул уйлап бетермәде, кулы бил каешына сузылды. Бер генә гранатасы да калмаган! Автоматының да патроннары беткән. Нишләргә?!

Күзләрен зур итеп ачып, күңеле нәфрәт белән ташы-

ган хәлдә, Газинур үкереп торган дошман пулеметына өзгәләрдәй булып карый. Ул якын гына, ләкин аңа барып җитәргә мөмкин түгел. Аның утлы бугазын тыгарлык бер генә көч тә юк шикелле.

– Юк, барыбер туктата алмассың, явыз! Барыбер муеныңны борам!

Газинур күзләрен баскан каскасын юеш кулы белән күтәреп куйды. Ул артына борылып карамады, ләкин командирның гына түгел, бөтен батальонның аңардан кыю хәрәкәт көткәнен сизенде. Ләкин буш кул белән ни эшли ала соң ул? Газинур кулын күкрәгенә китерде. Атылып чыгардай типкән йөрәге янында, гимнастерка кесәсендә партбилеты һәм... Александр Матросовның рәсеме!

– Саша... – диде ул кинәт әкрен генә.

Газинур яткан җиреннән сикереп торды. Моңарчы кара кургашын тутырган сыман авыр гәүдәсе кинәт җиңеләеп киткәндәй булды. Әйтерсең аңа канатлар чыкты.

Ул дзотка таба йөгерә башлады.

Батальон тынып калды. Сержантның ни эшләргә теләве хәзер һәркемгә ачык иде. Ничәмә-ничә сугышларны башларыннан кичергән, ничәмә-ничә тапкыр үлем белән бугазга-бугаз килеп якалашкан сугышчылар таң калды, йөрәкләре тибүдән туктагандай булды. Ничек таң калмасыннар алар? Ничек йөрәкләре тибүдән туктамасын? Аларның күз алдында гади совет солдаты үлем белән үлемсезлек арасын үтә, аларның күз алдында Коммунистлар партиясе тәрбияләп үстергән гади совет кешесе буыннардан буыннарга калырлык, телләрдән телләргә күчеп, легендалар итеп сөйләрлек, җырларда җырларлык батырлык эшли иде.

Ажгырып торган амбразурага берничә адым калгач, Газинур бик азга гына туктады. Язгы аяз күктә, биектәбиектә, бөдрә ак болытлар йөзә иде. Кояш нурлары аларны үтәдән-үтә яктырткан, алар шундый җиңел сыман, өрсәң, тузганак кебек, очып китәр төсле. Үзләре шундый ак, беренче яуган кар да андый ак булмый бугай...

Кайда, кайчан күргән иде соң Газинур шундый ак һәм җиңел болытларны?

Фашист пулеметы котыруының соңгы чигенә җитеп үкерә. Кара амбразурада пулемет авызыннан чыккан ялкын утлы хәнҗәр төсле айкала. Кышкы зәһәр җил кебек пулялар чыелдап сызгыра. Артык бер генә минут та көтәргә ярамый, һәр секунд безнең җиңүебезне тоткарлый, уннарча сугышчыларның гомерләрен алып китә.

Газинурның карары нык. Аның күңелендә курку да, тетрәү дә, икеләнү дә юк.

– Туган ил өчен! – дип кычкырды ул һәм, яшәү белән үлемсезлек арасындагы ике адым җирне йөгереп үтеп, үкереп торган фашист пулеметы авызына күкрәге белән капланды...

Коточкыч дулкынланып көтеп яткан батальоннар бер кешедәй булып күтәрелделәр, дошманны изеп, сытып алга омтылдылар. Аларның ярсуы давыллы көндәге диңгез дулкыннарыннан да көчлерәк иде.

...Капитан Бушуев, гвардия майоры Ермилов Газинурның үле гәүдәсен, амбразурадан үз куллары белән күтәреп алып, кар өстенә салдылар. Газинур гүя үлмәгән, бары тик йоклый гына. Үлем ачысы аның сөйкемле йөзен ямьсезләндермәгән, әйтерсең үлем аңа якын килергә дә курыккан.

Шунда ук Газинурның сугышчан иптәшләре дә басып торалар. Алар да сержантның тыныч йөзенә карыйлар, бу зур кара күзләрнең, инде моннан соң беркайчан да очкын чәчеп ялтырамавына, бу калынрак иреннәрдән инде моннан соң һичкайчан моңлы җырлар, шаян сүзләр яңгырамавына һич тә ышана алмыйлар иде...

Яз шаулый. Җир яшәрә, агачлар яфрак яра. Тирәкләрдә кошлар сайрый.

Совет Армиясе, бөтен фронт буйлап һөҗүм итеп, көнтөн алга бара. Безнең гаскәрләр инде Карпат таулары итәгендә, Румыния җирендә сугышалар. Чехословакия чигенә килеп җиттеләр. Героик Одесса, Севастополь шәһәрләре өстендә кызыл байраклар җилферди, Кырым азат. Совет Кораллы Көчләренең тиңсез җиңүләрен котлап, Ватаныбызның башкаласы Мәскәү көн саен икешәр, өчәр тапкыр салют бирә.

Кешелекнең иң явыз дошманын – фашизмны үз өнендә тукмап бетерер өчен ашкынып алга баручы совет сугышчылары арасында Газинурның сугышчан дуслары да бар. Әнә, бронетранспортерга утырып, капитан Григорьян белән кече лейтенант Зәбиров баралар, әнә шинель итәкләрен бил каешына кыстырган офицер Стариков, әнә маңгаен ак марля белән ураган өлкән сержант Ильченко, әнә, атларга атланып, майор Бушуев белән гвардия майоры Ермилов янәшә баралар, әнә юл чатында, «виллис» янында, сугышчыларына карап, полковник Кремнев басып тора.

Политбүлекчеләр арасында хезмәте белән күзгә артык бәрелмәгән, әмма иң батыр сугышчыларны тәрбияләүче полк партоешмасының җитәкчесе өлкән лейтенант Соловеев бара. Медсанбат машиналарында сөйкемле рус хатыны Екатерина Павловна Бушуева күренеп кала һәм шушы меңләгән сугышчан дуслары арасында, күзгә күренмичә, батыр йөрәкле, саф вөҗданлы совет солдаты – Советлар Союзы Герое сержант Газинур Гафиятуллин да бара...

Ә тирә-якта яз шаулый. Җылы җилләр исә. Күгелҗем урман өсләрендә беренче күкрәү яңгырый. Сугышчылар елмаялар, аларның күзләрендә яңа очкыннар, яңа өметләр кабына. Бу күкрәү аларны киң кырларга, тыныч хезмәткә чакыра, туган җирләрен сагындыра, ашыктыра, җилкендерә.

Солдат плащ-палаткаларына, тракторлар сөйрәп барган зур тупларның озын көпшәләренә, танклар бронясына, машиналар өстенә корылган брезентларга, поход кухнялары өстенә, әкрен генә шыбырдап, кояшлы яңгыр ява. Беренче язгы яңгыр – ләйсән яңгыры! Диңгездән диңгезгә сузылган барлык олы, кече фронт юллары буйлап атлаган совет солдатлары, гүя шушы кояшлы яңгырны да, яңгыр артыннан гаҗәеп бер тантана белән балкып килгән көчле яктылыкны да, тынычлык байрагын күтәреп илткән кебек, үзләре белән бергә алга, соры, салкын томан эчендә иңрәп яткан көнбатышка алып баралар. Колонналар ташкыны ераграк киткән саен, яктылык дәрьясы да арта, киңәя бара. Бу яктылыкта кешеләр өчен иң кадерле, иң изге нәрсәләр – азатлык, тынычлык, ышаныч һәм яшәү нурлана.

– Шире шаг! – дигән дәртле команда ишетелә.

Сугышчылар кызурак атлый башлыйлар. Аларның юлы озын әле, ләкин алар максатларына барып җитәчәкләр.

Яз шаулый. Күгелҗем урман өсләрендә беренче күкрәү яңгырый, ләйсән яңгыры – кояшлы яңгыр ява...

*1951*

ЭЧТӘЛЕК

**Вакыт сынавын үткән әдип.**
*Н.Йосыпова, Г.Гайнуллина*
*7*

**Газинур**
*29*

Беренче бүлек
*31*

Икенче бүлек
*220*

Литературно-художественное издание

**Абсалямов** Абдурахман Сафиевич

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В пяти томах

Том 1

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Әпсәләмов** Габдрахман Сафа улы

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Биш томда

1 том

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Л.З.Әүхәдиева, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.12.2009.
Форматы 84´108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 21,0.
Тиражы 2000 д. Заказ В-1833.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.